


# КАЗАН УТЛАРЫ

3.1987



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАИ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**3**

**1987**


## *Бу санда*

Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА


М. ХӘСӘНОВ. **Зур талант, титаник хезмәт** . . 3
Г. БӘШИРОВ. **Йолдыздай балкып** . . . . . 16
Н. ИСӘНБӘТ. **Остазыбыз иде...** . . . . . . . 19
С. БАТТАЛ. **Олы көрәш юлында** . . . . . . 19
Ә. ЕНИКИ. **Бер сорауга бер җавап** . . . . . 21
ЗӨЛФӘТ. **Ялта тыкрыгында.** *Шигырь* . . . . 23
Р. МӨХӘММӘДИЕВ. **Тагын бер кат «Татар шагыйрьләре» турында.** *Г. Ибраһимов тәнкыйтендә Г. Тукай* . . . . . . . . . . . . . 25
Ш. ХАММАТОВ. **Г. Ибраһимов һәм М. Җәлил** . 34
А. ӘХМӘДУЛЛИН. **Сәхнәдә яңа геройларга юл салганда** . . . . . . . . . . . . . 38
Ф. ӘГЪЗАМОВ. **Матбугат теоретигы һәм тарихчысы** . . . . . . . . . . . . . . 42
Ү. ГЫЙМАДИЕВ. **Г. Ибраһимов — «Чулпан» редакторы** . . . . . . . . . . . . . 46
Ф. САФИУЛЛИНА. **Халыкчан һәм сурәтле тел** . 48
М. МӘҺДИЕВ. **Татарларда рәсем сәнгате һәм Галимҗан Ибраһимов** . . . . . . . . . 52
М. ЗӘКИЕВ. **Бер сорауга бер җавап** . . . . . 55
Б. ИСХАКОВ. **Г. Ибраһимов һәм казах әдәбияты** . 56
Ш. ТУРДЫЕВ. **Г. Ибраһимов һәм үзбәк әдәбияты** . 58
С. АКБИЕВ. **Г. Ибраһимов һәм Дагстан халыклары әдәбияты** . . . . . . . . . . . 61
К. ВӘЛИЕВ. **Бер сорауга бер җавап** . . . . . 63
**Г. Ибраһимовның В. И. Ленин белән очрашуына бәйле документлар** . . . . . . . . . 64
**Кадерле ядкарьләр** . . . . . . . . . . . 66
**Г. Ибраһимовның яңа табылган хатлары** . . . 78
М. ӘХМӘТҖАНОВ. **Галимҗан Ибраһимовның автографлы китабы** . . . . . . . . . . . 81
М. ЗАРИПОВ. **Васыять** . . . . . . . . . 82
С. САДЫЙКОВА. **Бер сорауга бер җавап** . . . 86
Т. ЭЙДИ. **И, кадерле як!** . . . . . . . . . 87


* * *


К. БУЛАТОВА. **Чал тарихның...** *Шигырьләр* . . 94
Ә. ЕНИКИ. **Соңгы китап.** *Повесть* . . . . . . 96
Ш. ҖИҺАНГИРОВА. **Давылларга каршы...** *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . 127
М МАЛИКОВА. **Басып сайрар талы бар.** *Роман* . 129


ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ


Җ. ВӘЛИУЛЛИН. **Ямьле Ык буйларында** *(Мөслим районы)* . . . . . . . . . . . . . 186



КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

**Культура тормышы көндәлеге . . . . . . . . 190**

**В. ЦОЙ. Әдипнең портреты . . . . . . . . . 192**

*Баш редактор*

**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия*

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**
**ӘХӘТ ГАФФАР**
**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**
**САЛИХ МАННАПОВ**
*(җаваплы секретарь)*
**ТУФАН МИННУЛЛИН**
**ФЛҮН МУСИН**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
*(баш редактор урынбасары)*
**РӘФЫЙК НӘФИКОВ**
**НУРИХАН ФӘТТАХ**
**РИЗВАН ХӘМИД**
**НИЛ ЮЗИЕВ**
**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

Безнең адрес: 420066.
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор —53-07-60,
баш редактор урынбасары —
53-07-09,
җаваплы секретарь —53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк —53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар —53-07-63.

## В нашем номере

Материалы этого номера посвящаются столетию Г. Ибрагимова.

Статья первого заместителя Председателя Совета Министров Татарской АССР, доктора филологических наук М. Х. ХАСАНОВА — «Большой талант, титанический труд».

Видные деятели науки и культуры о Г. Ибрагимове: выступления Г. БАШИРОВА, Н. ИСАНБЕТА, С. БАТТАЛА, А. ЕНИКИ, С. САДЫКОВОЙ, К. ВАЛЕЕВА, М. ЗАКИЕВА.

Статьи о жизни и о многогранной деятельности Г. Ибрагимова: Р. МУХАМАДИЕВ — «Тукай в критике Г. Ибрагимова», Ш. ХАММАТОВ — «Г. Ибрагимов и М. Джалиль», А. АХМАДУЛЛИН — «Драматургия Г. Ибрагимова», Ф. АГЗАМОВ — «Теоретик и историк периодической печати», У. ГИМАДИЕВ — «Г. Ибрагимов — редактор «Чулпан»а, Ф. САФИУЛЛИНА — «О языке и стиле произведений Г. Ибрагимова», М. МАГДЕЕВ — «Изобразительное искусство у татар и Г. Ибрагимов».

Творчество Г. Ибрагимова и литература народов СССР. Б. ИСХАКОВ — «Г. Ибрагимов и казахская литература», Ш. ТУРДЫЕВ — «Г. Ибрагимов и узбекская литература», С. АКБИЕВ — «Г. Ибрагимов и литература народов Дагестана».

Новые документы и архивные материалы: о государственной деятельности Г. Ибрагимова под руководством В. И. Ленина. Письма и документы Г. Ибрагимова. Книги с автографом писателя. Воспоминание М. ЗАРИПОВА, статья Т. АЙДИ о земляках писателя.

Повесть А. ЕНИКИ «Последняя книга». Роман М. МАЛИКОВОЙ «Ивушка плакучая». Стихи ЗУЛЬФАТА, К. БУЛАТОВОЙ, Ш. ЗИГАНГИРОВОЙ.

В рубрике «Татарстан — родной мой край» — Муслюмовский район. Хроника культурной жизни.

На наших обложках: портрет Г. Ибрагимова (худ. П. Беньков) и памятник М. Вахитова в Казани.

Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Г. Салихҗанова, И. Ихсанова.*

Производствога бирелде 30.12.1986 ел. Басарга кул куелды 25.02.1987 ел. ПФ 05072. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 67044. Заказ В-547. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1987 ел.

Галимҗан Ибраһимовның 100 еллыгына

**Мансур Хәсәнов,**

филология фәннәре докторы,
Татарстан АССР Министрлар Советы
Председателенең беренче урынбасары.

# ЗУР ТАЛАНТ, ТИТАНИК ХЕЗМӘТ

Татар әдәбияты, мәдәниятының күгендә якты янучы, ерактан күренеп, нур сибеп торучы мәһабәт йолдызлар аз түгел. Әмма алар арасында аеруча якты балкып, сихри бер көч белән үзенә тартып торган, халыкның яшәешенә, рухи дөньясына тәэсир көче ягыннан бөтенләй үзгә урын тоткан ике йолдыз бар. Алар Г. Тукай һәм Г. Ибраһимов йолдызлары.

Бөек шагыйрь Г. Тукайның 100 еллыгын бөтен ил күләмендә олы бәйрәм итеп һәм ЮНЕСКО рамкаларында билгеләп үткәннән соң, турыдан-туры Г. Ибраһимовның бер гасырлык юбилеена күчү — һәм тарихи, һәм символик бер мәгънәгә ия. Бу ике бөек талант татар халкының XX гасыр тормышындагы тарихи-революцион яңарыш, социаль һәм политик үзгәрешләр белән бәйләнешле рәвештә яңа әдәбияты үсешендә, милли тел, сәнгать һәм мәдәният формалашуда, гомумән, халыкның рухи-эстетик җегәре оешу-калыплануында, интернациональ офыклары киңәюдә тарихи роль уйнадылар. Аларның беренчесе — Г. Тукай — туган халкына аның поэтик җанын ачып бирде, иҗатында халыкның социаль һәм рухи азатлыкка омтылышларын гәүдәләндерде, шигърият аркылы татар милләтенең яшәү көчен, потенциаль мөмкинлекләрен раслады. Бөек шагыйрьнең тарихи миссиясе татар тормышын көнчыгыш феодализм артталыгыннан гомумроссия прогрессы юлына алып чыгуга, дини-схоластик торгынлыкны җимереп туган халкын XIX гасыр ахырларында — XX гасыр башларында илебездә киң җәелгән революцион-азатлык хәрәкәтенә китереп кушуга хезмәт итүдә, алда торган бөек тарихи алмашынуларга хәзерләүдә булды.

Г. Ибраһимов исә, Г. Тукай эстафетасын дәвам иттереп, милли тел һәм әдәбиятның, гомумән, рухи культураның бөтен куәтен турыдан-туры дөньяны революцион үзгәртеп кору максатларына җикте, прогрессив әдәби һәм мәдәни көчләрне революция белән, социалистик яңарыш өчен көрәш белән кушуда зур тарихи роль уйнады, ул социалистик революция аша яңа тормыш, әдәбият, сәнгать, культура төзелешендә юл яручы, әйдәп баручы, революцион байрак йөртүче булды. Аның иҗатында шулай ук культура үсешендә дәвамлылык та ачык чагылыш тапты. Ул Октябрьгә кадәрге татар демократик әдәбиятын, мәдәниятны совет әдәбияты, социалистик культура белән тоташтыручы, бәйләүче дә иде. Г. Тукай белән Г. Ибраһимов әдәби мирасы, герой-шагыйрь Муса Җәлил һәм халыкның сөекле композиторы С. Сәйдәшевның поэтик, музыкаль мираслары шикелле үк, татар халкының XX гасыр гомумкешелек рухи культурасына керткән лаеклы өлеше.

Күренекле рус совет язучысы Л. Соболев Г. Ибраһимовны бик хаклы рәвештә татар әдәбиятының титаны дип атаган иде. Моңа өстәп әйтергә кирәк, ул — әдәбиятның гына түгел, гомумән, татар культурасының титаны. Әдип татар совет культурасының бик күп тармакларында гаять зур эш башкарды, халыкның рухи тормышында тирән эз калдырды. Аның күпкырлы иҗтимагый-политик һәм гыйльми-иҗат эшчәнлегенең төп юнәлешләрен күрсәтеп кенә үтү дә әдипнең титаник образын күз алдына китереп бастыра.

Октябрьгә кадәрге чорда революцион азатлык хәрәкәтендә актив кат-

нашкан, социалистик революциянең һәм гражданнар сугышының үзәгендә кайнаган, В. И. Ленин җитәкчелегендә Совет үзәк дәүләт органнарында эшләгән, Татарстан АССРны төзүгә, Совет властеның беренче елларында аны ныгытуга күп көч куйган күренекле революционер, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе; атаклы язучы, сүз остасы, милли әдәбиятның классигы, татар совет әдәбиятына нигез салучы, күпмилләтле совет әдәбиятының күренекле вәкиле; талантлы тәнкыйтьче, әдәбият белгече һәм тарихчысы, бездә тәнкыйтьнең һәм әдәбият фәненең марксистик методологиясен эшләүче; күп кенә татар совет матбугат органнарын нигезләүче, күренекле журналист һәм публицист; тирән эрудицияле тел галиме-филолог; сыйнфый-идеологик көрәш, революцион хәрәкәт тарихын ныклап тикшергән, Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы тәҗрибәсен, аның дөньякүләм революцион процессқа йогынтысын, Коммунистлар партиясе тарихын, В. И. Ленин хезмәтләрен тирәнтен анализлаган, бу өлкәләрдә җитди оригиналь хезмәтләр калдырган атаклы тарихчы, галим, көнчыгышны өйрәнүче; ниһаять, революциягә кадәр һәм совет чорында практик эшчәнлеге һәм педагогик хезмәтләре белән мәгариф, тәрбия өлкәсендә онытылмаслык эз калдырган мәшһүр педагог.

Г. Ибраһимов үзенең көчле таланты һәм күпкырлы иҗаты белән югарыда саналган өлкәләрнең барысын да җыйнап, колачлап ала алган, ул аларның һәркайсында революционер, новатор, галим булган. Талантының һәм иҗат эшчәнлегенең характеры белән ул чын мәгънәсендә яңа гасыр энциклопедисты иде.

Әдипнең революцион көрәш, иҗтимагый хезмәт һәм иҗат гомере аеруча мөһим бер чорга — бай социаль-политик вакыйгалар, кешелек тарихындагы кискен борылыш, бөек үзгәрешләр чорына туры килде. Ул үзенең аңлы гомерендә өч революция кичерде, аларның идеяләре белән рухланып, өзлексез үсештә, камилләшү юлында булды, ә соңгысы — Бөек Октябрь революциясенең ышанычлы солдаты һәм каһарманы иде. Әдип гомеренең соңгы сулышына кадәр социализм өчен көрәшнең алгы сызыгында барып, илдәге бөек үзгәрешләрнең актив катнашучысы, җанлы шаһиты булды. Г. Ибраһимов үткән юл — татар халкының XX гасыр башларыннан алып утызынчы еллар ахырына чаклы, ягъни илдә социализм җиңүенә кадәр булган социаль-политик һәм рухи-мәдәни үсеш юлы ул. Әдипнең тормышы һәм иҗаты халыкның революцион көрәш тарихы, яңа тормыш төзү, социалистик аң һәм культура формалашуы белән аерылгысыз бәйләнгән.

КПСС ҮКның 1985 ел апрель Пленумы һәм XXVII съезды карарлары нигезендә партия җитәкчелегендә илебездә барган революцион яңарыш, җәмгыять тормышын, аның барлык өлкәләрен тирәнтен үзгәртеп кору өчен зур көрәштә Г. Ибраһимов кебек олы шәхесләрнең талант куәте, революцион фидакарьлеге, иҗат мирасларының эстетик тәэсир көче безнең өчен җанлы үрнәк, ныклы таяныч була ала. Әдипнең революцион эшчәнлеге, әдәби һәм фәнни мирасы бүгенге яңарыш заманы таләпләре, партия куйган бурычлар белән аваздаш. Нәкъ менә шуңа күрә дә аның 100 еллык юбилее республикабыз культура тормышында, күпмилләтле совет әдәбиятында күренекле вакыйга булып тора.

## 1

Бөтен тирә-юньгә матурлык һәм ямь биреп, күкрәп үсеп утырган олы, мәһабәт яшел агачны күргәч, җир өстендәге кәүсәсе, киң ябалдашы, ямьяшел яфракларына сокланып кына калмыйсың, аның күзгә күренми торган тамырлары турында да уйлыйсың. Агач ни чаклы биек, ябалдашлары киң, тармаклары бай булса, аның җир астына киткән тамырлары да шулкадәр тирән, нык һәм тармакланган була. Бу бик табигый.

Халыкның әдәбияты, рухи культурасы, талантлары белән дә шулай. Әдәбият, сәнгать, культура никадәр зур, үскән, камилләшкән булса, аның «тамырлары» да халыкның тарихына, үткән дәверләренә, аның әдәби-культура мирасына шулкадәр ныграк тоташкан, тирәнгәрәк, ераккарак киткән була. Татар әдәбиятының, культурасының олы вәкилләре, аларның иҗаты, тарихи язмышлары турында уйланганда, күңелгә әнә шундый чагыштыру килә. Г. Тукай белән Г. Ибраһимовның рухи тамырлары татар әдәбиятының һәм иҗтимагый-фикер үсешенең берничә йөз еллык тарихына, аның бай традицияләренә барып тоташа.

Болгар чорының олы таланты Кол Галинең «Кыйссаи Иосыф» әсәре, Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдъяр, феодализм дәверендә, рухи торгынлык шартларында калкып чыккан талантлар Мәүлә Колый, Утыз Имә-

ниләр, рухи ирек таләп итеп чаң суккан мәшһүр фикер иясе Курсавый, XIX гасыр шагыйрьләре Кандалый, Акмулла, атаклы галим һәм философ Ш. Мәрҗани, күренекле мәгърифәтче, энциклопедист К. Насыйри — гасырдан-гасырга тупланып, үстерелә барган ул җанлы традицияләрнең олы маяклары әнә шулар. Бу бай әдәби мирас, бай халык авыз иҗаты әсәрләре Г. Ибраһимовның аңына һәм күңеленә яшьтән үк сеңә, тәэсир итә килгән.

Аларның кайберләрен, мәсәлән, «Кыйссаи Йосыф»ны ул әле сабый чакта ук, авылда кышкы озын төннәрдә кич утырганда, әбисе яки әнисе яттан көйләп укуында тыңлаган, икенчеләрен, әйтик, казах, татар, башкорт халыкларының уртак шагыйре Акмулла шигырьләрен казах далаларында йөргәндә ишеткән, ә өченчеләре — Курсавый, Мәрҗани һәм К. Насыйри идеяләре аның рухи дөньясына мәдрәсәдә алган дәресләре белән килеп кергән. Туган әдәбиятының бай тарихы белән Г. Ибраһимовның төрле максатларда гомер буе якыннан кызыксынып торуын әйтергә кирәк. Революциягә кадәрге чорда, мәсәлән, ул аңа «Галия» мәдрәсәсендә әдәбият укытканда кирәк булган, ә совет чорында татар әдәбиятын ул Казанда Коммунистлар университетында, башка уку йортларында укыткан, ә гыйльми үзәктә эшләгәндә, фәнни максатлар белән тикшергән, аның үрнәкләрен бастырып чыгарган, киң катлау укучыларга җиткерүгә күп көч куйган. Гомумән, Г. Ибраһимовның дөньяга карашлары формалашуда, аның язучы, көрәшче һәм галим булып җитешүендә милли әдәбият, аның бай традицияләре хәлиткеч факторларның, мөһим рухи чыганакларның берсе була.

Г. Ибраһимовның рухи чыганаклары хакында сүз чыккач, әлбәттә, әдипнең туган җирен, аның бай табигатен искә төшерми мөмкин түгел.

Ул Урал тауларының ерак итәгендә, татар әдәбиятына талантларны бирүдә гаять юмартлык күрсәткән көнбатыш Башкортстанда Солтанморат исемле татар авылында туган.

Г. Ибраһимовның үзе әйтмешли, кешенең олы шәхес булып җитешүе, халык тарихында, аның күңелендә тирән, җуелмаслык эз калдыруы өчен табигый талант кына җитми, моның өчен тарихи җирлек, шул исәптән халык хәтеренең потенциаль көче, социаль-политик шартлар, хәтта — боларга өстәп әйтер идем — географик-табигать шартлары да кирәк.

Г. Ибраһимовның таланты формалашуы өчен беренче мөһим шарт — ул да булса бу төбәкнең бай, бәрәкәтле җир-сулары, урман-болыннары, туган авылының, тирә-юньнең хезмәт һәм сәнгать сөючән, нечкә күңелле кешеләре, аларның холкы, яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре. Булачак язучының табигый талантын тирбәтеп үстергән тәүге тормыш бишеге, һичшиксез, аның туган җире, бу төбәкнең кабатланмас матур табигате булды. Әмма шуның белән бергә яшь талантның мәшһүр шәхес булып җитүе өчен зарури булган тагын берничә мөһим факторны, әдипнең рухи тамырларының башкаларын да күрсәтеп үтәргә кирәк.

Әдипнең рухи тамырлары туган җир туфрагы, милли әдәби традицияләр аша тагын да ераккарак, дөнья әдәбиятының, гомумкешелек прогрессив культурасының тирән катламнарына барып тоташа. Бер якта, төрле тарихи һәм социаль сәбәпләр аркасында Идел-Урал буйларында яшәүче халыкларның рухи дөньясына нык үтеп кергән көнчыгышның гуманистик әдәбияты һәм фәлсәфәсе торса, икенче якта, бөек рус һәм Көнбатыш Европа әдәбияты була. Шул рәвешле әдипнең таланты туган җир бишегендә тирбәнеп, туган туфракта «аякланып» китсә, аның иҗат канатлары ныгуында дөнья әдәбиятлары казанышларының да роле әйтеп бетергесез зур.

Көнчыгыш әдәбияты һәм фәлсәфәсе белән Г. Ибраһимов әле мәдрәсә шәкерте чагында ук таныша башлый. Оренбургның «Хөсәения» (Ибраһимов анда укымаса да, бу мәдрәсәгә абыйсы Шакирҗан янына еш барып йөри, укыр өчен аннан китаплар ала), Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә бай китапханәләр була, аларда дини китаплар гына түгел, дөньяви әсәрләр дә, бигрәк тә гарәп, фарсы, төрки телләрендә басылып чыккан әсәрләр күп була. Г. Ибраһимов мәдрәсәдә укыганда, көнчыгышның Мәгарри, Гомәр Хәйям, Фирдәүси, Сәгъди, Хафиз, Физули, Низами, Нәваи кебек бөек шагыйрьләре әсәрләре белән таныша. Аннан соң мәдрәсәдә гарәп, фарсы телләрен өйрәнү Ибраһимовка ул телләрдәге чыганаклар аркылы борынгы грек мифологиясенә, грек һәм рим әдәбиятларына, философиясенә үтеп керергә мөмкинлек бирә. Ибраһимов әле шәкерт чагында ук Гомер, Данте, Сервантес, Шекспир һ. б. бөек әдипләрнең әсәрләре белән яхшы таныш була. Ул Аристотель, Платон, Сократ, борынгы Кытай философы Конфуций, Әбугалисина, шулай ук Декарт, Спенсер, Жан Жак Руссо идеяләре белән азыклана. Аның, мәсәлән, Декарт хакында махсус мәкалә дә язып чыгуы шуны раслый.

Болар өстенә Г. Ибраһимов дөнья сынлы сәнгатенең бөек вәкилләре борынгы грек скульпторы Фидий, Пракситель иҗатын, Италиянең «Яңарыш дәвере» титаннары Рафаэль, Микеланджело, Леонардо да Винчи әсәрләрен,

Вагнер, Шопен кебек атаклы музыкантларның иҗатын ныклап өйрәнгән, алардагы тирән фикер һәм хисләр белән азыкланган.

Ә Ибраһимовның таланты, дөньяга карашлары формалашуда бөек рус әдәбиятының, эстетик фикер байлыгының, гомумән, культурасының роленә аерым тукталмый мөмкин түгел. Чөнки аның принципиаль, методологик әһәмияте бар.

Әдипнең биографиясендә игътибарга лаеклы бер деталь бар. Ул әле сабый чакта ук рус мәктәбендә яхшы укыганы өчен А. С. Пушкин китабы белән бүләкләнә. Бу гыйбрәтле факт символик мәгънәгә ия. Нәкъ менә Пушкин әсәрләре белән булачак язучының рухи дөньясына бөек рус әдәбияты килеп керә, ул аны гомер буе озатып барачак, рухи баетып торачак.

Г. Ибраһимовның әдәбият мәйданына аяк баскан елларында ук язган иң элекке мәкаләләреннән берсе бөек рус тәнкыйтьчесе В. Г. Белинский иҗатына багышланган булуы да очраклы хәл түгел. «Рус мөхәррирләреннән мәшһүр интикатчы В. Г. Белинский җәнаблары хакында» дип исемләнгән әлеге хезмәт белән ул, тәнкыйтьче һәм әдип буларак, үзенең шәхси иҗат юнәлешен генә билгеләп калмый, ә барыннан да элек милли әдәби-эстетик фикернең барыр юлын, үсеш перспективаларын ачыклый. Алга таба да ул рус әдәбиятыннан, рус революцион-демократик тәнкыйте һәм эстетикасыннан өйрәнүгә даими игътибар юнәлтә һәм үзенең замандашлары, каләмдәшләрен дә шушы юнәлештә нәтиҗәле эзләнүләргә әйди.

Әдәбиятта халыкчанлык һәм тормышчанлык принципларын яклап ул, Белинский белән бер үк дәрәҗәдә, Писарев һәм Добролюбов, Чернышевский һәм Плеханов хезмәтләрен эзлекле рәвештә өйрәнүгә зур игътибар бирә. Гомумән, рус тәнкыйте һәм эстетикасының теоретик нигезләре әдип өчен бөтен иҗат эшчәнлеге дәвамында ышанычлы арка терәге булып килде.

«Халыкка якынлыгы, тик халык өчен яшәве, халык йөрәгеннән туып, аның авыр хәятына бер нур, бер җиңеллек бирүне үзенә вазифа итеп алган булучылыгы белән рус әдәбиятының бөтен дөньяда мөмтаз вә мөстәсәм (күренекле, югары — М. Х.) урын тотканлыгы мәйдандадыр. Рус — әдәбиятыннан үз кайгысына бер җиңеллек көтә... Аның һәр әдибе иң элек үзен халыкның угылы итеп хис кыла, язу дигән сүздән рус хәятының авыр яраларына шифа эзләү дигән мәгънә аңлый»,— дип язды Г. Ибраһимов 1913 елда «Йолдыз»да басылган мәкаләләренең берсендә. Шул рәвешле, әдәбиятның тормышчанлыгы һәм халыкчанлыгы үрнәген ул классик рус әдәбиятында күрде, һәм художникның изге бурычы гади халык массалары мәнфәгатенә фидакарь хезмәттә булырга тиешлеген яклады. Нәкъ әнә шул критерийлардан чыгып ул мәшһүр Т. Г. Шевченко иҗаты хакында махсус мәкалә дә язып чыкты. «Мин аны каһарман дим. Шагыйрь генә димим... Ул — хөррият каһарманы»,— дип бәяләде Ибраһимов Т. Г. Шевченко иҗаты һәм шәхесенә үзенең сокlануын белгертеп.

Димәк, аның рус әдәбияты дигәндә, иң элек Пушкин, Некрасов, Гоголь, Тургенев, Толстой һәм Горький кебек әдип һәм шагыйрьләрне күз алдында тотуы да һич очраклы күренеш түгел иде. Әдәби иҗат эшчәнлегендә исә Г. Ибраһимовның аеруча И. С. Тургенев, Л. Н. Толстой һәм А. М. Горький кебек бөек каләм ияләреннән өйрәнүе мәгълүм. Беренче икесе аны прозадагы фикер байлыклары, психологик анализ тирәнлеге һәм әдәби осталык җәһәтләреннән җәлеп итсә, бөек пролетар әдибендә ул формалашу юлында булган принципиаль яңа әдәбиятның гыйбрәтле иҗат мәктәбен күрде. Әле Киев вакыйгалары чорында ук жандармерия тарафыннан тикшерү вакытында кулга алынган Г. Ибраһимовның әйберләре арасыннан М. Горькийның «Ана» романы килеп чыгу очраклылык булмый, чөнки ул гомере буе үзен бөек пролетар әдипнең шәкерте һәм фикердәше санады.

Гомумән, классик рус әдәбияты һәм революцион-демократик әдәби-эстетик фикеренә йөз белән борылу һәм бу бай мирасны эзлекле рәвештә өйрәнү бер Г. Ибраһимов өчен генә түгел, тулаем милли әдәбият һәм культураның үсеше, прогрессив иҗтимагый-политик һәм әдәби-эстетик фикерләрнең формалашуы өчен дә хәлиткеч роль уйнады. Әлеге бәрәкәтле бәйләнешнең әһәмияте турында Бөек Октябрь революциясеннән соңгы хезмәтләренең берсендә әдип болай дип язды: «Бу мәдәният (рус культурасы — М. Х.) бик күп яктан безгә остаз була килде. Безнең яңаруыбыз, безнең әдәбиятыбыз, безнең гыйлемнәребез, безнең революция хәрәкәтләребез — һәммәсе бу рус мәдәниятенең бик нык тәэсире һәм мөгаллимлеге астында үстеләр».

## 2

Әдипнең бер гасырлык түгәрәк бәйрәме тарихи көннәр — Бөек Октябрьгә җитмеш тулган елда уза. Бер карашка очраклылык кына булып тоелырга

мөмкин булган бу факт символик мәгънәгә дә ия. Октябрь таңында Г. Ибраһимовка утыз була. Ир-атның ныгып, утырып өлгергән чоры. Зур иҗади мәктәп, гыйльми тәҗрибә һәм революцион чыныгу да алырга өлгергән әдипнең рухи һәм физик энергиясе ташып торган еллар...

Табигате белән үк көрәш өчен, яну һәм шул үзе яккан учак җылысында башкаларны да җылыту, рухландыру, ялкынландыру өчен туган шәхес була Г. Ибраһимов. Чөнки аның бөтен иҗат эшчәнлеге, бөтен фидакарьлеге шушы максатларга, туган халкына һәм, гомумән, кешеләргә азатлык һәм бәхет, рух һәм гыйлем нуры өләшүдән, йөрәк кайнарлыгы белән башкаларны да җылытырга, көчле һәм ирекле итәргә омтылудан гыйбарәт иде. Әдәбиятта булсын, әдәби тәнкыйтьтә, фәннең төрле тармакларындамы, Г. Ибраһимов һәр очракта революционер иде һәм бөтен казанышлары һәм хәтта кимчелекләре белән дә ул тормышының соңгы көннәренәчә революционер булып калды. Менә шуңа күрә дә әдипнең иҗтимагый һәм революцион эшчәнлеген аның әдәби һәм гыйльми хезмәтләреннән аерып карау мөмкин түгел. Әдәбиятта революционерларга гына хас ялкын белән янып иҗат итсә, революция һәм иҗтимагый эшчәнлегендә ул һәрчак әдип булып калды.

Әйе, Г. Ибраһимов — революцион эшчәнлеге белән генә дә тарихыбызда күренекле урын алырга лаек шәхес. Аның исеме, хаклы рәвештә, халкыбызның күренекле революционерлары Х. Ямашев, М. Вахитов, К. Якубовлар белән янәшә олылап искә алына.

Г. Ибраһимовның революцион көрәшкә килү юлы да каршылыклар һәм борылышларсыз гына булмады. Әмма ул өзлексез алга, киләчәккә омтылган юл иде. Әле шәкертлек елларында ук ул алдынгы карашлы яшьтәшләре белән бергә иске татар мәдрәсәләрендәге уку тәртипләренә каршы чыгып, аларның заман таләпләреннән нык калышуын аңлый һәм үзенең шәкертләренә дә шуны аңлатырга омтыла. Оренбургтагы Вәли хәзрәтнең кадимчел мәдрәсәсен бер төркем иптәшләре белән ташлап китүе аның революцион көрәш юлына таба беренче кыю адымы була. Тагын берничә елдан, дөньяви гыйлемнән байтак мәгълүмат алырга һәм әдәби тәҗрибә туплап өлгергән яшь әдип Киевка ук барып чыга. Ул анда мөселман студентларының яшерен оешмасында катнашып кулга алына һәм төрмәгә ябыла. Бу фактның да Ибраһимовның революционер, көрәшче буларак чыныгу юлында гаять әһәмиятле икәнлеген искәрми мөмкин түгел. Әле Казанга кайткач та, шушы вакыйгаларга бәйләнешле эшләрен дәвам иткәнлеге өчен, Г. Ибраһимов берничә ел патша охранкасы күзәтүе астында яши. Әмма ни генә булмасын, башлаган юлыннан кире борылмый, һәм әдип, һәм фикер иясе, һәм җәмәгать эшлеклесе буларак алда торган зур вакыйгаларга әзерләнүендә дәвам итә.

Җәмәгать эшлеклесе һәм революционер буларак әдип талантының тулаем ачылуы өчен шартлар Бөек Октябрь белән бергә туды. Ул тиз арада вак буржуаз революционерлык этабын узып, милли чикләнгәнлек һәм эсерлар баткагына да бирешмичә, катлаулы һәм каршылыклы революцион көрәш юлында марксизм-ленинизмга, большевиклар сафына килеп кушылды.

Г. Ибраһимовның политик биографиясендә яңа этап башланды. Аның революционер буларак җитлеккәнлеге һәм политик сизгерлеге аеруча 1918 елның январенда ачылган Учредительное собраниега мөнәсәбәтендә күренде. Мөселман делегатлары, аерым бер фракция төзеп, учредилкага өметләр баглаган, яңгыравыклы лозунглар артына посып, халык һәм революция мәнфәгатьләреннән читләшә барган бер чорда, большевик делегатлар белән бергә ул аны ташлап чыкты. Бу елларда ул көрәштәше һәм чын ленинчы Мулланур Вахитов белән кулга-кул тотышып эшкә алына. Әлеге якын мөнәсәбәтләрнең һәр ике як өчен дә файдалы һәм бәрәкәтле булуын искәртү дә урынлы булыр. М. Вахитов белән Г. Ибраһимов В. И. Ленин җитәкчелегендә үзәк дәүләт аппаратында эшли һәм, даһи юлбашчы белән очрашып, аның кайгыртуын, киңәшләрен тыңлау бәхетенә ия булалар. Ул Советларның III һәм IV съездларында катнаша, Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитетына әгъза булып сайлана. Болар һәммәсе тынгысыз хезмәт һәм коммунистларча фидакарьлек белән үткән давыллы елларның әдип өчен ни дәрәҗәдә җаваплы һәм катлаулы булганлыгы хакында сөйлиләр. Бу катлаулы чорда Ибраһимовның һәр кылган эшен, бөтен эшчәнлеген В. И. Ленин идеяләре яктыртып тора. Аңа бит әле даими төстә, ВЦИК утырышларында катнашып, даһи юлбашчының күп кенә ялкынлы чыгышларын да тыңларга насыйп була. Мондый бай язмыш, һәм мондый да катлаулы, бөек вакыйгалар эчендә кайнау һичкайчан һәм бер генә башка татар әдибенә дә туры килмәгән.

Г. Ибраһимовның әлеге эшчәнлеге партия тарафыннан үз вакытында ук югары бәяләнә. Мәгълүм булганча, большевиклар партиясенә ул официаль рәвештә 1920 елның декабрендә кабул ителә. Әмма актив революцион эшчәнлеген һәм марксизм-ленинизмны пропагандалау юлындагы зур хезмәт-

ләрен искә алып, аның партия стажы 1917 елның 15 апреленнән хисаплап йөртелә. Социалистик революциягә, большевиклар партиясенә вак буржуаз революционерлыгы аша килгән әдипнең эшчәнлегенә бирелгән гаять югары бәя иде бу, чөнки мондый чыгарылмалар партиябез тарихында үтә дә сирәк очракларда гына ясалган.

Даһи Ленин мәктәбен узган, көрәшләрдә чыныккан, бай тәҗрибә туплаган өлкән әдип, дәүләт эшлеклесе, коммунистик идеяләрнең пропагандисты, журналист һәм фикер иясе буларак, Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә дә зур өлеш кертә. Г. Ибраһимов — татар телендә чыккан беренче совет газетасы «Чулпан»ның оештыручысы һәм фактик редакторы. Совет хөкүмәтенең беренче декретлары әлеге газета сәхифәләре аша аның тәрҗемәсендә Россиянең төрки халыклары яшәгән күп кенә өлкәләргә тарала. Гомумән, әлеге газета татар халкының милли үзаңы үсешенә, коммунистик идеяләрне пропагандалау җәһәтеннән шактый ук өлеш кертеп өлгерә.

Партияле көндәлек матбугат тарихыбызны өйрәнүчеләр Г. Ибраһимов эшчәнлегенә әле киләчәктә дә кайтып-кайтып мөрәҗәгать итәрләр. Бүгенге көндә республикабызда чыгучы бик күп органнарның элгәрләре булган газета-журналларның чыга башлавы һәм формалашуы турыдан-туры аның иҗтимагый һәм журналистлык эшчәнлегенә барып тоташа. Әйтик, ул — бүгенге «Казан утлары»ның башлангычы булган «Безнең юл» әдәби-политик журналының оештыручысы һәм беренче редакторы. Шул ук вакытта ул — беренче татар совет педагогика журналын нигезләүче редактор, «Татарстан» газетасы һәм «Коммунистический путь» журналының беренче саннарын Г. Ибраһимов эшчәнлегеннән аерып карау мөмкин түгел. Авторитетлы әдипнең бу фидакарьлеге көндәлек матбугат эшенә башка әдип һәм журналистларны туплау юнәлешендә дә уңай нәтиҗәләр бирә.

Г. Ибраһимов — совет чорында халык мәгарифенә нигез салучыларның да иң күренеклесе. Әле Үзәк Мөселман Комиссариатында эшләгәндә үк ул бу идеологик трибунаның әһәмиятенә гаять зур игътибар юнәлткән иде. Революциягә кадәр белем алган укытучыларны совет платформасына күчеп хезмәт итәргә чакырды, яңа педагогик кадрлар тәрбияләүнең зарурлыгын каткат дәлилләп чыкты ул. Бөтенроссия мөселман укытучыларының 1918 елның маенда Казанда үткәрелгән III съезды һәм 1924 елның февралендә Мәскәүдә узган татар-башкорт мәгариф хезмәткәрләре съезды нәтиҗәләрендә дә аның зирәк акылы һәм кайгыртучанлыгы хәлиткеч әһәмияткә ия була.

Ә инде әдипнең Гыйльми үзәктәге эшчәнлеге — аерым игътибарга лаек һәм шулай ук махсус өйрәнүне сорый торган өлкә. Бу әһәмиятле дәүләт органы Г. Ибраһимов җитәкчелек иткән чорда чын мәгънәсендә гыйльми үзәккә, фән учагына әверелә, ил күләмендәге гыйльми җәмәгатьчелек каршында олы авторитет һәм мәртәбә казана. Республикада тарих, тел һәм әдәбият буенча гыйльми-тикшеренү эшләрен җайга салуда, фән, әдәбият һәм культура өлкәсендә һәркайсы үзбашка яшәп яткан көчләрне туплауда кыска гына вакыт эчендә Галимҗан Ибраһимовның титаник хезмәте һәм фидакарьлеге нәтиҗәсендә зур эшләр башкарыла. Татарстанда гуманитар фәннәр үсеше, марксистик дәреслек һәм кулланмалар чыгара башлауга да монда нигез салына. Гыйльми үзәк татарлар арасында иҗтимагый фикер үсеше һәм революцион хәрәкәт тарихын өйрәнү буенча нәтиҗәле эш башкара.

Ибраһимовның тагын бер зур хезмәте — бу оешма эшенә илнең танылган галимнәрен тартуда, Мәскәү һәм Ленинград кебек гыйльми үзәкләр белән нәтиҗәле һәм күпкырлы бәйләнешләргә нигез салуда. Нәтиҗәдә М. Павлович, А. Самойлович, В. Добрянский, Н. Фирсов, И. Бороздин, П. Коган кебек дистәләгән тарихчы һәм әдәбият белгечләре, Татарстан белән тыгыз мөнәсәбәттә торып, бездә яңа буын фән эшлеклеләре, гыйльми кадрлар хәзерләүгә җитди өлеш керттеләр. Әлеге бәйләнешләрнең башында Г. Ибраһимов кебек зур шәхеснең торуы очраклы булмавы аңлашылса кирәк. Чөнки инде бу елларда аның ил күләмендә билгеле әдип, фән, культура һәм җәмәгать эшлеклесе, утны-суны кичкән көрәшче, революционер дигән мәртәбәле исеме була.

Әдипнең, еллар саны белән исәпләсәң, кыска гына иҗат гомере бай иҗтимагый-политик вакыйгалар, туган халкы тарихындагы бөек үзгәрешләр чорына туры килде. Тарих һәм тормыш сынауларын лаеклы үтеп, ул татар халкының революцион көрәш тарихында җитди эз калдырды. Г. Ибраһимов язмышы татар халкының гомум Россия күләмендә җәелгән революцион-азатлык хәрәкәте аша яңа тормышка, социализмга тарихи күчешен, бу күчешнең ни дәрәҗәдә зарури булуын раслап торган ялкынлы революцион көрәш елъязмасына тиң.

Шагыйрь дигәч тә хәтердә Г. Тукай образы һәм шигърияте яңарганы кебек, язучы, әдип дигәндә безнең укучы, мөгаен, иң элек күз алдына Г. Ибраһимовның калку образын китерә булса кирәк. Табигате һәм тумышы белән үк ул әдип, талантлы художник, сүз остасы иде. Татар әдәбияты тарихында аның кабатланмас һәм мәртәбәле урыны, традицияләре, үзенчәлекле һәм бай иҗади мәктәбе бар. Г. Ибраһимов искиткеч бай һәм масштаблы әдәби мирас калдырды. Аның егермеләп хикәясе, өч повесте, дүрт романы һәм пьесасы бар. Һәм хикмәт әлеге саннарда гына да түгел.

Г. Ибраһимов матур әдәбият дөньясына XX йөз башында татар халкы гомум Россия күләмендә җәелгән революцион-азатлык хәрәкәтенә ныклап тартылган, хезмәт ияләре социаль һәм милли азатлык өчен актив көрәшкә күтәрелгән бер чорда килеп керде. Бу вакытта татар телендә милли вакытлы матбугат нигезләнеп, театр һәм сәнгатьнең башка төрләре үсеше өчен билгеле бер шартлар туган, яңа мөмкинлекләр ачылган иде инде. Әдәби тел формалашкан, әдәби-эстетик фикер иҗтимагый аңның мөстәкыйль юнәлеше буларак нигезләнгән һәм үсүгә юл тоткан еллар була. Нәтиҗәдә милли әдәбиятның үсеше, анда төрле жанрларның чарлануы һәм критик реализм иҗат методының формалашуы өчен бәрәкәтле җирлек һәм киң мәйдан барлыкка килә. Әдип әлеге үзгәрешләрнең кыл уртасында була, катлаулы һәм каршылыклы әдәби-эстетик хәрәкәтнең үзәгендә кайный, аның күренекле вәкиле, әйдәп баручысы була.

Әлбәттә, зур шәхесләр кинәттән генә һәм буш урында дөньяга килми. XX йөз башында татар әдәбияты күгендә кинәт кенә, тулы бер йолдызлыкны хәтерләткән, зур төркем талант ияләре пәйда булу очраклы күренеш түгел. Димәк, халыкның гасырлар дәвамында тупланып, буылып килгән рухи җегәре, иҗтимагый омтылышларының кинәт мәйданга чыгуы өчен кулай шартлар булуы гына кирәк иде. Г. Тукай һәм Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан һәм Г. Камал, Г. Коләхметов һәм Ш. Камаллар иҗаты татар халкының гасырлар дәвамында тупланып килгән бай рухи потенциалының мөлдерәмә тулып ташып чыгуын хәтерләтә.

Г. Ибраһимовның Бөек Октябрьгә кадәрге әдәби иҗат эшчәнлеге, нигездә, ике чорга бүленә. 1907—1912 елларда аның иҗат принциплары башлыча романтик юнәлештә үсте. Аның тормышка художниклык карашы хакимлек итүче стройны романтик кире кагу, аларга романтик идеалны каршы кую белән характерлана иде. Шуның нәтиҗәсе буларак, «Яз башы», «Диңгездә», «Сөю-сәгадәт», «Уты сүнгән җәһәннәм» һ. б. хикәяләрендә иҗтимагый тирәлек белән килешмәүче ярсу рухлы, романтик шәхесләрнең образлары сурәтләнде. Язучының геройлары социаль тәртипләргә кискен протест белдереп, аның белән йөзгә-йөз чәкешсәләр дә, чынбарлыкны үзгәртеп кору юлларын реаль тормышның үзеннән эзләмиләр иде әле. Үзләренә яшәү, хезмәт итү һәм хәтта сөю-сөелү өчен дә кысан булган социаль чынбарлыкка алар матурлык, бәхет һәм мәхәббәт кебек идеалларны каршы куйдылар. Әлеге иҗат үзенчәлеге «Яшь йөрәкләр» романында да предметлы чагылыш тапты.

Гомумән, Г. Ибраһимов романтизмы — сәнгать алымы булу җәһәтеннән генә түгел, социаль эчтәлеге белән дә прогрессив күренеш, татар әдәбиятында һәм беренче чиратта прозасында алга таба ясалган җитди адым иде. Ул романтизм хакимлек итүче җәмгыятьтән ризасызлыкны, азатлыкка, рухи һәм физик сәламәтлеккә, матурлыкка омтылышны чагылдырды. Бу — татар халкының 1905 ел революциясе нәтиҗәсендә уянган милли үзаңының, социаль һәм милли изүгә каршы протестының әдәбияттагы чагылышы булды. Язучы көчле характерлы образлар тудырды, аларны әле яшәүләрендә дәвам иткән патриархаль тәртипләргә каршы куйды. Ибраһимов геройлары реаль чынбарлыкның тар кысаларыннан ычкынырга, яңача яшәүгә, ирекка омтылдылар. Шул рәвешле аның тәүге әсәрләре үк яңа кеше, революция һәм граждaннар сугышы шартларында да сынатмаячак корычтай нык рухлы көрәшче-каһарманнар тәрбияләүгә зур өлеш кертте.

Романтик геройның рухи дөньясын сурәтләве белән әдип кеше табигатенең җанлы хәрәкәтен, аның күңелендә барган ташкын хисләр көрәшен күрсәтте. Татар прозасын лирик психологизм, кискен контрастлардан гыйбарәт бай әдәби буяулар, гадәттән тыш көчле характерлар һәм укучының йокымсырау халәтендәге эмоциясен уятырга сәләтле кискен ситуацияләр белән баетты. Әдипнең бу чор иҗатындагы принципиаль казанышларны күрмичә, аның беренче хикәяләрендәге әдәби-эстетик ачышларга лаеклы бәя бирми узу, гомумән, мөмкин түгел.

1912 ел ахырларыннан, Г. Ибраһимовның политик карашлары үсешенә бәйле рәвештә, аның идея-эстетик эзләнүләрендә дә яңа сыйфат үзенчәлек-

ләре барлыкка килә. Язучы үзенең әсәрләрендә социаль проблемаларга йөз белән борылып, аларны кыю рәвештә күтәреп чыга, изелгән, кимсетелгән катламнан алынган образларны сурәтләүгә даими игътибар бирә. Мисал итеп, «Карт ялчы» һәм «Көтүчеләр» кебек гыйбрәтле язмышларны сурәтләгән, чын реалистик сәнгать югарылыгындагы хикәяләрне искә алырга мөмкин.

Г. Ибраһимовның Октябрьгә кадәрге әдәби иҗатының югары ноктасы — «Безнең көннәр» романы. Аңарда иҗтимагый азатлык өчен революцион көрәшкә күтәрелгән геройларның үзенчәлекле һәм калку образлары сурәтләнде, татар халкының патша самодержавиесенә каршы хәлиткеч көрәшкә хәзерлек этаплары зур гомумиләштерүләр аша киң чагылыш тапты. Шуңа күрә дә бу роман бары тик революциядән соң гына дөнья күрү бәхетенә иреште.

«Мин үземнең әдәби иҗат көчләремнең иркен үсеп китә алулары тик Бөек Октябрь революциясе аркасында гына мөмкин булды дип табам»,— дип язды әдип. Чынлап та, бу тарихи вакыйга Г. Ибраһимовның идея үсешендә генә түгел, художник буларак чынбарлыкка мөнәсәбәтендә, әдәби-эстетик принципларында да зур үзгәрешләр тудырды. Нәтиҗәдә, ул, татар әдәбиятында беренчеләрдән булып, революция һәм гражданнар сугышы вакыйгаларын, яңа җәмгыять өчен көрәшче каһарманнар образын сурәтләп чыкты. Язучының чынбарлыкка яңача мөнәсәбәте барыннан да бигрәк чорның төп антагонизмына — пролетариатның буржуазия белән, революционерларның контрреволюцион көчләр белән көрәшенә — нигезләнгән булуында чагылды. Язучының матурлыкны аңлау критерийлары да инде, эстетик идеалы да, турыдан-туры революцион чынбарлыкның үзеннән килә, аның реаль шартларына бәйле иде. Бу чорда язылган әсәрләрнең геройлары — япа-ялгыз романтиклар түгел, ә аңлы рәвештә хәрәкәт итүче, әдипнең үзе кебек үк зур көрәшләрдә чыныккан революция һәм гражданнар сугышы каһарманнары. Язучы яңа шартларда яңа характерларның чыныгуын, яңа җәмгыять кешеләре тууын тасвирлады. Бу аның художник буларак чын новатор, юл ярып баручы масштаблы талант булуын тагын бер тапкыр ачык раслап килгән факт. Һәм Г. Ибраһимовның Октябрьдән соң ук язылган иң элекке әсәре очраклы рәвештә генә «Яңа кешеләр» дип аталмаган иде.

Инде Г. Ибраһимов каләме көче белән туган геройларга социаль оптимизм, югары революцион пафос һәм үз-үзләренә ныклы ышаныч үзенчәлекләре хас. Моның гыйбрәтле мисалларын шулай ук «Яңа кешеләр» драмасында һәм «Кызыл чәчәкләр» хикәясендә күрергә мөмкин.

Ләкин, әдип реализм принципларының яңадан-яңа мөмкинлекләрен эзләү белән бергә элеккедән дәвам итеп килгән иҗат үзенчәлекләрен камилләштерүдән дә баш тартмады. 1922 елда язып тәмамланган «Алмачуар» хикәясе моның ачык мисалы булды. Романтик рух белән өртелгән көчле, гадәттән тыш характерга ия геройларның дәвамы буларак туган образ — гади крестьян малае Закирның сәламәт рухы һәм бай табигате әле дә булса әдәбият сөючеләрне сокландырудан туктамый. Моның сәбәбе исә Г. Ибраһимовның иҗат методына хәрәкәттәге, үсештәге төшенчә буларак мөнәсәбәтеннән, бу өлкәдә катып калган кануннар булмыйча, яңалык һәм новаторлыкның узган белән тыгыз бәйләнештә генә җитди ачыш һәм уңай нәтиҗәләргә китерү ихтималын аңлап эш итүеннән килә иде. Табигать гүзәллеген, шул гүзәл бишектә үскән кеше психологиясенең табигый хәрәкәтен эзлекле рәвештә тасвирлау җәһәтеннән «Алмачуар» әле булса әдәбият дөньясына килүче яңа буын язучылар өчен бетмәс-төкәнмәс әдәби осталык үрнәге булып кала бирә.

Өзлексез үсештә булган Ибраһимов талантының чираттагы җимеше «Казакъ кызы» романы булды. Бу юлы инде әдип иҗтимагый теманы көнкүреш мәсьәләләре белән тыгыз үрелештә сурәтләү остасы буларак ачыла. Аның югары романтик пафос белән сугарылган реализмы казакъ халкы тормышының эчке рухын, потенциаль мөмкинлекләрен сурәтләүдә, дала халкының үсеп барган иҗтимагый аңын күрсәтүдә күренде. Художникның үткен каләме халык тормышының асылына үтеп керә, гыйбрәтле характер һәм реаль вакыйгалар аша социаль каршылыкларга нигезләнгән җәмгыятьнең яраларын ачып бирүгә ирешә. Сюжет һәм композициясе төзеклеге, геройларның психологиясен үсештә, хәрәкәттә тасвирлавы, көнкүреш детальләре аша әһәмиятле идея-эстетик казанышларга ирешү, табигать һәм кеше рухының бөтенлеген сурәтләү, тел һәм сурәтләү чараларының колоритлылыгы белән «Казакъ кызы» романы татар совет прозасының гүзәл үрнәкләреннән берсенә әверелде. Бу әсәрне иҗат иткәндә автор үзенең шәхси тәҗрибәсеннән генә түгел, рус классик романы казанышларыннан һәм шулай ук казакъ халкының бай фольклор традицияләреннән дә киң файдалана.

Хатын-кыз образын алгы планга чыгарып, аны киң полотнолы герой буларак сурәтләү җәһәтеннән «Казакъ кызы» романы «Татар хатыны ниләр күрми» повесте белән бергә татар совет әдәбиятының гына түгел, гомумән,

төрки телле әдәбиятларның уртак казанышы иде. Соңгысында ачы хакыйкать буларак сурәтләнгән Гөлбану образы — Октябрьгә кадәрге барлык мөселман хатын-кызларының уртак язмышы дигән сүз. «Татар хатыны ниләр күрми» — трагик әсәр, ул Гөлбануның һәлакәте белән тәмамлана. Әдип моның белән иске тормыш кысаларында татар хатынын әлеге һәлакәттән коткару мөмкин түгел иде дигән нәтиҗә ясый. Әмма әсәр укучы күңелендә оптимистик трагедия буларак яңгыраш таба, чөнки аның әлеге варианты Бөек Октябрьдән соң иҗат ителеп, яңа тормышның иң зур казанышларыннан берсе — хатын-кыз азатлыгының тарихи әһәмиятен калку итеп күрсәтүдән гыйбарәт иде. Гомумән, Г. Ибраһимов иҗатында хатын-кыз азатлыгы проблемасы тарихи эзлеклелектә тасвирланып, социалистик революция казанышлары белән бәйләнештә бирелде. Әдипнең иҗатында татар хатынының XX гасыр башыннан алып утызынчы елларга кадәрге эволюциясе реаль чагылыш тапты. Нәкъ менә шушы сыйфатлары белән дә ул бөтен төрки телле тугандаш әдәбиятларның уртак хәзинәсе буларак кабул ителде.

Татар әдәбиятының күренекле вәкилләре кайтып-кайтып хатын-кыз образларын иҗат итү юлында Г. Ибраһимов тәҗрибәсенә мөрәҗәгать иттеләр һәм әле дә аның идея-художество казанышларына нигезләнүләрен дәвам иттерәләр. К. Нәҗми һәм Г. Бәширов, А. Шамов, Г. Кутуй һәм М. Әмир, Ә. Еники һәм А. Расих әсәрләрендәге татар хатын-кызларының колоритлы образлары — кайчандыр Г. Ибраһимов нигезләгән әдәби осталык мәктәбенең закончалыклы җимешләре дигән сүз.

Татар совет әдәбиятында социалистик реализмның иҗат методы буларак формалашуы юлында хәлиткеч роль уйнаган әсәрләрнең күренеклесе,— бәхәссез, «Тирән тамырлар» романы. Монда татар прозасы өчен әлегәчә күтәрелмәгән чирәм булган яңа тема — дөньяны социалистик үзгәртеп кору темасы күтәрелә, ул киң социаль-тарихи перспективада ачып бирелә, яңа, социалистик мөнәсәбәтләрнең һәм моральнең иске вак буржуаз психологияне җиңүе раслана, яңа кеше формалашу процессы күрсәтелә. Яңа тормыш проблемаларын колачлаудагы киңлеге һәм идея-эстетик тирәнлеге, халык язмышын, кешеләр характерын тасвирлаудагы новаторлыгы, вакыйгаларның социаль-фәлсәфи мәгънәсенә үтеп керүе, реализмның җегәре җәһәтеннән татар совет әдәбияты тарихында бер этап, вакыйга булды «Тирән тамырлар».

Тулаем, әдипнең кайсы гына әдәби әсәренә мөрәҗәгать итмә, аның татар прозасы һәм әдәбияты үсешендә бер яңалык, этап булуын таныргa мәҗбүр буласың. Ул әсәрләрнең күбесе тугандаш әдәбиятларның үсешенә дә зур йогынты ясый килде. Казакъ язучысы М. Ауэзов, үзбәк язучысы Айбек, төрекмән әдибе Б. Кербабаев, дөньякүләм танылган замандашыбыз күренекле кыргыз совет язучысы Ч. Айтматов кебек дистәләгән каләмдәшләренең моны тануы һәм югары бәяләве һич очраклы түгел. Г. Ибраһимов таланты милли рекламаларда гына чикләнеп калмады, чын интернационализм принципларына нигезләнеп иҗат ителгән әсәрләр ил күләмендә танылды һәм бөтенсоюз әдәбияты казанышына әверелде.

## 4

Г. Ибраһимов революцион көрәш юлы һәм әдәбиятыбыз тарихында тоткан мәртәбәле урыны аның күп тармаклы гыйльми һәм әдәби-эстетик эшчәнлегеннән аерылгысыз иде. Дөресрәге, аның әдәби иҗат, иҗтимагый-революцион һәм гыйльми эшчәнлекләре үзара гармонияле рәвештә үрелеп бергә үсештә, хәрәкәттә булдылар. Еш кына үзенең теоретик эзләнүләрен — әдәби иҗатта, ә әдәби әсәрләрендәге тәҗрибәләрен гыйльми яктан килеп нигезли, дәлилли барды Г. Ибраһимов. Һәм, кайсы гына өлкәдә яисә жанрда эшләвенә карамастан, ул новатор иде, кәрванбаш дөя сыман, туган халкының иҗтимагый-революцион аңы үсешендә һәм прозада гына түгел, әдәби тәнкыйтьтә, тарих фәнендә һәм башка өлкәләрдә юл күрсәтеп, үзе артыннан әйдәп барды.

Г. Ибраһимов хаклы рәвештә, Г. Тукай һәм Ф. Әмирхан кебек бөек замандашлары белән бергә, татар әдәби тәнкыйтенә нигез салучылардан санала. Ул үзенең беренче тәнкыйть мәкаләләре белән үк татар әдәбиятының ул вакыттагы гомуми хәле, аерым жанрларның үсеше, әдәби процесста теге яисә бу язучының тоткан урыны, татарда сынлы сәнгать, профессиональ музыка тууы перспективалары, журналистика һ. б. мәсьәләләргә киң җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итте. Яшь тәнкыйтьче шул чорда ук инде, үзендә милли әдәбият һәм сәнгать язмышы өчен зур җаваплылык тоеп, әдәбият теориясе һәм эстетиканың аеруча катлаулы һәм моңарчы өйрәнелмәгән мәсьәләләрен күтәреп чыга. Һәм үзенең идея-эстетик эзләнүләрендә ул рус революцион-демократик тәнкыйтенә йөз тотты. Г. Ибраһимов, В. Г. Белинский кебек үк, үзенең беренче тәнкыйть мәкаләләрендә материалистик

эстетиканың үзәк мәсьәләләрен күтәреп чыга һәм сәнгатьнең иҗтимагый функциясен алга куя.

Аның шулай ук татар әдәби тәнкыйтендә иң элеккеләрдән булып «әдәби һөнәрчелеккә», әдәбияттагы дидактизмга, вак-төяк фәлсәфә сатуларга каршы принципиаль көрәш башлап җибәрүе дә зур әһәмияткә ия була. Тәнкыйть-ченең, бигрәк тә 1910—1913 елларда язылган мәкалә һәм хезмәтләрендә, төп игътибарын сүз сәнгатенең үзенчәлеге, әдәби әсәрнең сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсе һәм талант төшенчәсен ачыклауга юнәлдерүе дә очраклы булмый.

Әлбәттә, әдәбият һәм сәнгать проблемаларының барысын да Г. Ибраһимов тәнкыйть эшчәнлегенең беренче чорында ук фәнни дөрес, һичбер каршылыкларсыз гына хәл итте дип аңлату тарихи чынлыкка туры килмәс иде. Аларның бер ишен ул реализм һәм халыкчанлык рухында нигезләп аңлатса, икенчеләрен, көн тәртибенә куеп та, хәл иткәндә кайбер эстетик каршылыкларга очрады. Бу бигрәк тә аның «Татар шагыйрьләре» һәм «Альбом» кебек фәлсәфи-эстетик тәҗрибә характерында язылган хезмәтләрендә ачык чагылыш тапты.

Әмма шуңа да карамастан, Октябрьгә кадәрге демократик татар тәнкыйте һәм эстетик фикер үсеше үзенең югары ноктасына Г. Ибраһимов эшчәнлегендә ирешә. Һәм әлеге казанышлар татар әдәбиятының, тизләтелгән үсеш юлы узып, Бөек Октябрь таңында ук, иң алдынгы әдәбиятлар гаиләсенә тигезләшүен тәэмин итте дә инде. Г. Ибраһимовның революциягә кадәрге тәнкыйть эшчәнлеге әзлекле рәвештә яңа марксистик әдәби тәнкыйтькә килеп тоташты. Һәм аның татар совет тәнкыйтен фәнни нигезгә куючы, тәнкыйтькә марксистик-ленинчыл методологияне кертүчеләрнең бездә иң әлгәресе булуы — һич очраклы күренеш түгел.

Әдипнең совет чорында язылган тәнкыйть мәкаләләрендә һәм хезмәтләрендә марксистик әдәбият фәне методологиясенең күп кенә мөһим проблемалары эшләнә. Ул яңа тормыш төзүдә әдәбият һәм сәнгатьнең роле, язучының дөньяга карашы, иҗат методы, әдәби осталык, үткәндәге мираска мөнәсәбәт һәм әдәбиятның сыйнфыйлыгын ачыклау мәсьәләләренә аеруча зур игътибар бирә. Шунда ук аның татар совет әдәбият белеменең нигез ташларыннан саналырга хаклы хезмәтләре — «Пролетар әдәбияты турында» (1924), «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» (1924) кебек гыйльми гомумиләштерүләргә бай эзләнүләре җитди әһәмияткә ия була.

Тарихи үткәнен өйрәнми торып, әдәбият һәм культураның бүгенгесен үстерү, киләчәк перспективалары турында фикер йөртү, әлбәттә, мөмкин түгел. Татар әдәбиятының күп гасырлык бай тарихын системалы рәвештә гыйльми өйрәнү эшенә марксистик методологиягә нигезләнеп алынучыларның да иң әлгәресе Г. Ибраһимов була. Әдәбият тарихын дәверләргә бүлү принципларын ачыклау, аның әчтәлеген барлау юлында Ибраһимов башкарган эшләр үз чоры өчен җитди хезмәт саналырга лаек.

Г. Ибраһимов тәнкыйтенең буеннан-буена дәвам итеп килгән тагы бер үзенчәлеге — ул да булса яшь иҗат көчләренә даими игътибар һәм әдәбият, милли культураның киләчәге хакында даими кайгырту. Бигрәк тә Совет чорында ул, даими төстә, әдәбиятка килүче яшь талантларны тәрбияләү һәм аларның марксистик-ленинчыл эстетика нигезләрен үзләштерүенә якыннан ярдәм күрсәтеп килде. Әйтик, еллык күзәтүләрендә әдип эзлекле рәвештә таләпчәнлек һәм кайгыртучанлык белән әдәбият мәйданына аяк баскан яңа исемнәргә бәя бирә килә. Үз вакытында Г. Ибраһимовның кайгыртучан тәнкыйть сүзен ишеткән Һ. Такташ һәм Х. Туфан, Ф. Бурнаш һәм К. Нәҗми, М. Җәлил һәм Г. Кутуйлар соңыннан татар әдәбиятының күренекле вәкилләре булып үсеп җитте.

Г. Ибраһимов бу елларда тел белеме, педагогика һәм методика кебек, һәркайсы махсус әзерлек сорый торган специфик өлкәләрдә әйдәп баручы галим булды. Ул татар әдәби теленең үсешенә, аның саф һәм халыкчан булуына әдәби әсәрләре белән генә түгел, гыйльми хезмәтләре, педагогик һәм иҗтимагый эшчәнлеге белән дә зур өлеш кертте. Ул татар теленең байлыгын күрсәтеп чыкты, аның эчке закончалыкларын тикшерде, терминология принципларын ачыклау һәм нигезләү юлында төп юнәлешләрне билгеләде. Шунда ук аның татар теле һәм әдәбиятын укытуда төпле методика булдыру максатыннан башкарылган һәм гыйльми, һәм практик эшчәнлеге гаять җитди әһәмияткә ия иде.

Г. Ибраһимов татар совет культурасының теоретик нигезләрен булдыру һәм бу өлкәдә В. И. Ленин хезмәтләрендә күтәрелгән методологик тәгълиматларны тормышка ашыру юнәлешендә дә җиң сызганып хезмәт күрсәтә килде. Егерменче еллардагы культура төзелешенең фактик тәҗрибәсенә таянып, социализм һәм милли культура, социалистик культурада милли һәм интернациональ сыйфатларның үзара мөнәсәбәте, культурабызның характеры һәм алга таба үсеш перспективалары кебек гыйльми-практик мәсьәләләр күтәрелде аның хезмәтләрендә.

Әдип эшчәнлегенең аерым игътибарга лаек һәм махсус өйрәнү объекты булган тагы бер житди өлкә — ул да булса тарих. Г. Ибраһимов тарих мәсьәләләренә иҗат эшчәнлегенең башлангыч чорында ук даими игътибар юнәлтеп килде. Ә инде Бөек Октябрьдән соң ул, чын мәгънәсендә, күренекле тарих галиме, ориенталист, марксизм-ленинизм идеяләренең ялкынлы пропагандисты буларак танылды.

Тарих өлкәсенә караган күп кенә хезмәтләре арасыннан әдипнең «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» (1925) дип исемләнгән китабын аерым билгеләп узмый мөмкин түгел. Анда, татарлардан беренче буларак, Г. Ибраһимов Октябрь революциясе һәм коммунистлар партиясе тарихын өйрәнү юлында житди адым ясады. Бу хезмәттә Татарстандагы революцион-азатлык көрәшенең ерак тамырлары, тарихи һәм экономик сәбәпләре, политик шартлары тирән яктыртыла, революция алдыннан булган социаль-экономик хәл, революциягә хәзерлекнең идеологик аспектлары бай тарихи чыганаклар, матбугат һәм архив материаллары нигезендә тикшерелә.

Г. Ибраһимовның тарих өлкәсендәге хезмәтләре әһәмиятен бүгенге фән казанышларыннан чыгып түгел, үзенә кадәрге һәм шул чордагы гыйльми чынбарлык белән янәшә куеп бәяләү дөрес булыр. Чынлыкта, ул өйрәнгән әлеге проблемалар хәл ителү түгел, гомумән, кузгатылмаган һәм кайберәүләре көн тәртибенә дә куелырга өлгермәгән була әле. Мисал өчен, кайберәүләр бездә революцион көрәш булдымы соң, татар милләте антагонистик классларга бүленгән идеме-юкмы дип фикер йөрткәндә, Г. Ибраһимов, бай мәгълүматларга нигезләнеп, татар пролетариатының формалашуын, аның илкүләм революцион хәрәкәттәге урынын калку итеп күрсәтеп чыкты. Каһарман якташларыннан Х. Ямашев һәм Г. Сәйфетдинов кебек ялкынлы революционерлар эшчәнлегенә махсус тукталып, аларның житәкчелек ролен басым ясап күрсәтте.

Әдипнең әлеге хезмәтләренең әһәмияте гыйльми кысалар белән генә чикләнми, ул туплаган бай материал киләчәктә бездә тарихи-революцион роман жанрының үсеше өчен дә төп плацдарм булып хезмәт итте. Гыйбрәтле факт ич: әдәбиятыбызда тарихи-революцион роман жанрының беренче үрнәген тудырган (киң полотнолы «Безнең көннәр» романы күздә тотыла) әдип, үзенең гыйльми хезмәтләрендә киләчәктә язылачак яңа тарихи әсәрләр өчен күпкырлы материал туплап калдыра.

Г. Ибраһимов Совет властеның беренче елларыннан ук В. И. Ленин әсәрләрен, аның титаник революцион эшчәнлеген татар халкы арасында пропагандалауга кереште. 1920 елда бер-бер артлы «Пролетар диктатурасы һәм Ленин», «Ленинның әдәби хезмәтләре» дип исемләнгән мәкаләләр белән чыгып, аларда ул даһи юлбашчының революцион эшчәнлеген һәм теоретик хезмәтләрен мавыктыргыч итеп күрсәтергә омтылды. Ә тагы берничә елдан, юлбашчының үлеме турындагы кайгылы хәбәрне ишеткәч тә «Татарстан» газетасының 1924 елгы 24 январь санында болай дип язып чыкты: «Тарих бик олуг даһиларны белә. Күп зур җаннар адәм балаларын авыр коллыктан коткару өмете белән кузгалган көрәшләргә командирлык кылдылар. Ләкин дин, тел, җир, мәмләкәт, гореф-гадәт аермасына карамастан, бөтен дөнья мәзлумнәренең һәммәсенең йөрәгенә бер дәрәҗәдә якын, бер дәрәҗәдә үк кадерле, үзенеке булу — тик Ленинга насыйб булды».

Бу мәкалә көндәлек татар матбугатында даһи юлбашчының вафаты уңае белән дөнья күргән иң житди һәм оператив публицистика үрнәге була. Аның пафосы турыдан-туры Һ. Такташның «Гасырлар һәм минутлар» поэмасы белән авазлаш. Бу очракта талантлы шагыйрь өчен Ленинны күреп, якыннан аралашып белгән өлкән остазы Г. Ибраһимов хезмәтенең билгеле бер дәрәҗәдә этәргеч булу ихтималын да кире кагып булмый. Ни генә булмасын, татар әдәбиятының ике зур таланты В. И. Ленин образының масштабы һәм олылыгын аңлауда уртак позициядә иделәр.

Ниһаять, Г. Ибраһимов В. И. Ленинның бөек образын, аның тәгълиматын үз мәкаләләрендә пропагандалап кына калмады, юлбашчының теоретик мирасын татар телендә бастырып тарату эшенә дә зур өлеш кертте. Ул Ленин әсәрләрен тәрҗемә итү һәм бастырып чыгару өчен партия өлкә комитеты тарафыннан төзелгән махсус комиссияне житәкләде. Бу җаваплы тарихи эшнең дә башында ул — тәҗрибәле революционер-көрәшче, энциклопедист-галим Г. Ибраһимов торды.

Шәхеснең зур, тарихи булуы өчен бер талант көче генә житми, В. Г. Белинский әйтмешли, ул яшәгән чорының бөеклеге, халкының рухи көченең зурлыгы да кирәк. Г. Ибраһимовка нәкъ менә шундый бәрәкәтле туфракта, шанлы елларда яшәргә насыйп була. Әдипнең тормышы чын мәгънәсендә, бай иҗтимагый-политик вакыйгалар, кешелек тарихындагы бөек алмашынулар чорына туры килә. Үз гомерендә өч революция кичереп, ул илдә барган иҗтимагый-политик көрәш, бөек яңаруларның үзәгендә кайный, социализм төзүчеләрнең әйдәп баручысы була. Шул еллардагы иҗтимагый-

политик, әдәбият һәм культура тормышының кайсы гына өлкәсенә мөрәҗәгать итмик, анда Г. Ибраһимов хезмәтләренең якты эзен тоймый-күрми узу мөмкин түгел. Коммунист әдипнең таланты, энциклопедик белеме һәм титаник хезмәте һәрдаим сокландырып тора.

Шулай да, революционер буларак никадәр тарихи, галим буларак ни дәрәҗәдә колачлы хезмәт күрсәткән шәхес булуына карамастан, Г. Ибраһимов иң элек әдип иде, әдип, художник булып туган талант. Һәм матур әдәбиятыбыз тарихында үз мәктәбе булган сирәк әдипләрнең дә күренеклесе ул. Әле әдип үзе исән чакта ук, аның әйләнәсенә бөтен бер буын яшь талантлар туплана, аның кайгыртучанлыгын тоеп, принципиаль тәнкыйть фикерен ишетеп, татар совет әдәбиятының нигез ташларын салышкан шагыйрь һәм прозаиклар үсеп чыга. Һ. Такташ һәм Х. Туфан, М. Җәлил һәм Г. Кутуй, К. Нәҗми һәм Г. Бәширов, А. Шамов һәм М. Әмир, И. Гази һәм Г. Әпсәләмов, Ә. Еники һәм Г. Гобәй, Ф. Хөсни кебек дистәләгән художникларның талант мөмкинлекләре вакытында ачылып китү һәм зур нәтиҗәләр китерүендә, бәхәссез, аның да өлеше бар иде.

Г. Ибраһимов нигезләгән әдәби мәктәп әле булса дәвам итә һәм үзенең күпмеңләгән укучыларын яңа иҗат җимешләре белән шатландыру, рухландырудан туктамый. Аның тарихи һәм тарихи-революцион прозабызны нигезләүгә керткән өлеше безнең замандашларыбыз А. Расих, Н. Фәттах һәм М. Хәбибуллин романнарында дәвам иттерелсә, заман тормышының четерекле социаль-әхлакый проблемаларын күтәрүдәге традицияләрен Г. Ахунов, Х. Камалов, Т. Миңнуллин, М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев һәм Мәхмүт Хәсәновлар сүндерми алып баралар. Әдәбият мәйданына килгән һәр яңа буын, кайсы жанрда һәм нинди юнәлештә иҗат итүенә карамастан, әдәби осталыкка өйрәнү чорында башлап Г. Тукай һәм Г. Ибраһимовка мөрәҗәгать итә.

Туган халкын ул бөек художникларга хас бер олы ярату белән үз итте, бөтен гомерен аның бәхетле киләчәге хакына хезмәткә багышлады. Үзен тәрбияләп үстергән халыкның бетмәс-төкәнмәс рухи җегәр чыганагы, берөзлексез ташып торган чишмәдәй юмартлыгын онытu, аңардан азыкланмый, сусавыңны басмый тору, әлбәттә, мөмкин түгел. Ләкин, туган халкына булган мәхәббәте никадәрле генә олы булмасын, ул башка халыкларга мөнәсәбәттә чын интернационалист булып калды. Революцион хәрәкәттә һәм үзәк совет органнарында эшләү дәверендә ул һәммә тугандаш халыклар язмышын бер дәрәҗәдә кайгыртып, аларның бердәм гаиләдә тигез хокуклы күршеләр булуын яклады. Фәннең кайсы гына өлкәсендә эшләмәсен, дөнья һәм илебез халыкларының ул юнәлештәге уңышлары, казанышларыннан үрнәк алуны, милли культураларның үзара ярдәмләшеп үсүен прогресска илтүче беренче шарт дип санады. Ә аның роман һәм повестьларында исә татар һәм рус, казах һәм башкорт, украин һәм башка халык вәкилләре бер дәрәҗәдә хөрмәт белән, яратып тасвир кылынды. Шуңа күрә дә аның иҗат үрнәкләре һәм күптармаклы эшчәнлеге гомум әһәмияткә ия, рус, украин, казах, таҗик, үзбәк, кыргыз, төрекмән һәм башкорт халыклары тарафыннан бер дәрәҗәдә үз итеп кабул ителә.

Бөек пролетар язучы А. М. Горький, Г. Ибраһимовны күп милләтле совет әдәбияты үсешенә аеруча зур өлеш керткән олы художник санады. А. А. Фадеев бөтенсоюз трибунасыннан торып, әдипләрне аңардан әдәби осталыкка өйрәнергә чакырды. Күренекле француз язучысы Л. Арагон аны татар әдәбиятында роман жанрын нигезләүче дип, аның күпьяклы таланты алдында үзенең баш июен билгеләп үтте. Ә күренекле совет әдәбияты белгече профессор П. С. Коган: «Ул — әһәмияте үз иле чикләреннән ерак китә торган художникларның берсе. Ул кешелек дөньясының иң яхшы шагыйрьләре рәтенә горур атлап керә ала»,— дип язды.

Күренекле революционер, әдип һәм фикер иясе Г. Ибраһимовның ялкынлы, кешелекле иҗаты, күп тармаклы фидакарь эшчәнлеге олы язмышка ия булды. Аның зур таланты һәм титаник хезмәтләре тарих җиле һәм вакыт яңгырларына да бирешмичә, чор белән, Ватан һәм туган халкы белән киләчәккә үтә.

КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре М. С. Горбачев массакүләм информация һәм пропаганда чаралары җитәкчеләре белән очрашуда ясаган чыгышында: «Бөек революциябезнең 70 еллыгы уңае белән аны ясаучыларны күләгәдә калдырырга ярамый. Кешеләрне революция һәм социализм өчен гомерләрен бирүчеләр мисалында тәрбияләргә кирәк»,— диде.

Г. Ибраһимов — Бөек Октябрь революциясе, социализм өчен көрәшкә үзенең талантын, иҗатын, бөтен гомерен биргән олы шәхесләрнең берсе.

Г. Ибраhимовның «Казакъ кызы» романына иллюстрация





Казанда Г. Ибраhимов проспекты

Т. Хаҗиәхмәтов эше




## Гомәр Бәширов

# ЙОЛДЫЗДАЙ БАЛКЫП

Галимҗан Ибраһимов иҗаты яшүсмер елларымнан бирле минем иң акыллы киңәшчем, иң ышанычлы юл күрсәтүчем булып килде. Яшьлегемне күз алдына китерсәм, хәтерем күгендә, йолдызлардай балкып, иң элек Габдулла Тукай белән Галимҗан Ибраһимов килеп чыгалар.

Борынгы грек мифологиясендә мәхәббәт һәм матурлык алиһәсе Афродита диңгез күбегеннән яралган диелә. Безнең әдәбият, сәнгатебездә исә матурлык һәм мәгърифәт йолдызлары хыялый диңгез күбегеннән түгел, бәлки җәмгыятьнең реаль яшәеш диңгезеннән, халык күңелендә кузгалган азатлыкка омтылу дулкыныннан пәйда булдылар. Халыкның караңгылык патшалыгына нәфрәте, хөрриятикә омтылышы шулкадәр көчле иде, аны ярларына сыеша алмыйча ярсып аккан язгы ташкынга тиңләргә була. Әнә шул ярсу ташкын халыкның иң көчле, иң талантлы ул һәм кызларын яңа тормыш өчен көрәш ярларына чыгарды. Ул ташкын әдәбиятка соңыннан халыкның горурлыгы булган бөек затларны — Габдулла Тукай белән Галимҗан Ибраһимовны алып килде, сәхнәләргә зур талантларны күтәрде.

Ф. Достоевский: «Без һәммәбез дә Гоголь «Шинеленнән» чыктык»,— дигән. Әгәр шул образлы тәгъбирне безнең әдәбиятка карата кулланырга уйласак, безнең бик күп әдип һәм шагыйрьләребез әдәбиятка Г. Тукай һәм Г. Ибраһимов тәэсирендә килеп керделәр дип әйтергә мөмкин булыр иде.

Г. Ибраһимовның әдәби эшчәнлеге турында яза башлауга, үзеннән-үзе «беренче» сүзе телгә килә. Чөнки ул күп җәһәттән «чирәм ачучы», алдан юл ярып баручы булды. Мәсәлән, иҗтимагый тормыш белән каһарманнарның шәхси тормышларын табигый рәвештә үрелеп баруын оста тасвирлаган киң сулышлы заманча реалистик романнарны безнең әдәбиятка беренче булып Г. Ибраһимов алып керде.

Г. Ибраһимов белән Ф. Әмирхан татар прозасын башка жанрлар арасында беренче сафка алып чыктылар.

Бу әдип татар әдәбиятын үз халкыбыз эчендә генә бикләнеп калудан коткарып, аны бөтенсоюз мәйданына чыгарды, башка күп халыкларга танытты, яшь төрки әдәбиятларның остазы булып танылды.

Г. Ибраһимов беренчеләрдән булып...

Хәер, беренчелеккә тагын күп мисаллар китерергә мөмкин булыр иде, шулар белән чикләнәм. Чөнки аның иҗатын җентекләп тикшергән әдәбият галиме М. Х. Хәсәнов китабы һ. б. башка әсәрләр бар. Мин исә Г. Ибраһимовның татар әдәби телен яңа баскычка күтәрү өлкәсендәге биниһая зур хезмәте һәм батырлыгы турында гына берничә сүз әйтмәкче булам. Ни сәбәпле моны батырлык дип атыйм? Чөнки Г. Тукай, Г. Камал, Г. Ибраһимовлар яза башлаган елларда халыкның үз телен «гавам теле», «базар теле» дип кимсетүчеләр, элекке корама тел белән язуны мәдәнилекнең югары баскычы итеп санаучылар шактый ук күп иде әле. Әдәбиятның алдынгы вәкилләре ул юнәлешкә каршы чыктылар. Г. Тукай шигърияттә, Г. Ибраһимов прозада татар әдәби телен замана таләп иткән киң мәйданга алып чыктылар. Алар халык сөйләме диңгезенең төбенә үк чумдылар, аннан алып чыккан энҗеләр белән әдәби телне чиксез баеттылар.

Бу тарафларга килеп җиткәч, каләмем мине үзеннән-үзе безнең буынның яшүсмер чагына алып кайта. Ул елларда авыл җирендә юньле китапны кулга төшерү ансат түгел иде. Ничек булса булды, «Диңгездә», «Сөю-сәгадәт», «Табигать балалары» дигән китапларны мин басылып чыккан елларында ук уку бәхетенә ирештем (ул елларда нишләптер китапның кем тарафыннан язылуына әһәмият бирелми иде әле). Бу әсәрләр ничектер беренче укуда ук исемдә калдылар. Алай гына түгел, болар, томан арасыннан килеп чыккан кояш кебек, тормышымны яктыртып җибәрделәр. Моның үзенә күрә җитди генә сәбәпләре дә бар. Ул елларда саф үзебезнең телебездә, телнең барлык нечкәлекләрен файдаланып язылган әдәби әсәр-

ләр юк дәрәҗәсендә аз иде әле. Без, ул заманның яшь буыны, теләр-теләмәс, нигә кергән аңлар-аңламас, ярым гарәп, ярым фарсы телендә язылган дини китаплар укый идек. Шуның өстенә, Г. Ибраһимов әсәрләре, теге китаплардагы кебек, әллә кайдагы ком гарәпләре, хәлвәчеләр, хәрәмсарайлар турында түгел, бәлки үзебез кебек гади кешеләр, күбесенчә авыл табигатен, тормышының безгә таныш булган якларын тасвирлауга багышланган иде. Дөрес, шул табигать, шул гади авыл кешеләре арасында үсүем сәбәпле, бу мохитны балачактан ук яхшы беләм дип уйлый идем. Алай булмаган, мин тормышның тышкы кабыгын гына күргән икәнмен. Бу әсәрләрне укыгач, шул ук гади авыл тормышына яңадан җан өрделәрмени! Авылым тормышының әлек мин күрә алмаган эчке матурлыгы бик кызык, катлаулы, четерекле яклары ачылды. Бөтен әйләнә-тирәмне, якыннарымны, авылдашларымны бөтенләй башкача, элеккегә караганда яхшырак, матуррак, сөйкемлерәк итеп күрә башладым.

Табигатьне аңлауда да Г. Ибраһимов минем беренче остазым булды дип әйтер идем. Мәсәлән, нәрсә ул диңгез? Океаннардан, диңгезләрдән меңнәрчә чакрым еракта яшәгән авыл малаена ул нибары «зур су» гына. Әнә, алай гына түгел икән ләбаса! Табигатьнең өстән караганда гына күренми торган гаҗәп тә бай эчке тормышы, үзенә генә хас матурлыгы да була икән. «Чын» диңгезнең үзен мин егет кеше булып гражданнар сугышына киткәч кенә күрә алдым. Шигъри матурлыгын исә, һич тә кабатланмас гүзәллеге белән, Г. Ибраһимов «Диңгездә» дигән әсәрендә күрсәтеп биргән иде.

Г. Ибраһимов әсәрләре миңа үз-үземне тирәнрәк аңларга да ярдәм итте. Холкымдагы кимчелекләрне ачыграк күрә башладым, нииндидер бик эчкәре яткан яшьлек хисләремә тел ачкычы таптым.

Г. Ибраһимов иҗатының беренче чорында язылган әсәрләре, хосусан өстәрәк телгә алынган хикәяләре (кайчакларны «Казакъ кызы»н да шунда кертеп) турында фикер йөрткәндә, кайбер тәнкыйтьчеләр романтизм, прогрессив романтизм, абстракт алымнар кебек фәнни сүзләр кулланалар. Шунда авторның бу «-изм» тәэсиренә бирелүенә, гәрчә эчтән генә булса да, офтануларын да сизеп каласың. Күрәсең, алар хаклыдыр, фән булгач, шулай кирәктер. Ләкин микронлы төгәллек таләп итәлә торган фәннәрдә һәр нәрсәне кәфен-кәфкә, кафын-кафка китереп үлчәү зарури булса да, әдәбият-сәнгатьтә андый аптека үлчәве ярап бетмәскә мөмкин, аның «уңай» белән «тискәре» микъдарын дөрес үк күрсәтеп җиткермәве ихтимал. Бәлки шул сәбәпледер, кайчакларда фәнни бәяләр тузанлы шүрлекләрдә тын гына ята бирә, укучы әсәрне укый бирә, аңа соклана бирә. Чөнки укучыны әсәрнең нинди «-изм» тәэсирендә язылуы әллә ни кызыксындырмый, ул әсәргә үзенә ничек тәэсир итүеннән, күңел хәзинәсен ни белән баетуыннан чыгып бәя бирә.

Г. Ибраһимов әсәрләренең ул еллардагы яшьләргә тәэсире исә бинһая зур булды. Безнең буын яшьләре моны үз башыннан кичерде. Беренче империалистик сугыш алдыннан иде бу. Ул чагында әле радио үзе түгел, авылда аның исеме дә ишетелми, газетаны санаулы кешеләр генә ала. Яшьләр катып калган патриархаль тормыш кагыйдәләренә, шәригать кануннарына баш игән хәлдә посынып кына яшәргә мәҗбүр (кызлар белән очрашу — гөнаһ, чөнки алар намәхрәм, музыка, җыр, күңел ачулар — һәммәсе шайтан уены, иблис коткысы!). Менә шундый деспотлык кыршавы кысып яткырган авыл яшьләре арасында ялкынлы дәрт, рух күтәренкелеге белән язылган бу хикәяләр таң җиледәй саф һава булып керде. Г. Ибраһимов татар әдипләре арасында беренчеләрдән булып гади игенче эшенең рухландыргыч шигъри матурлыгын, авыл табигатенең гүзәллеген, гадел яшәгәндә, күңелең яхшылыкта булганда, гади генә тормышта да бәхетле булу мөмкинлеген сурәтләп бирде. Бу әсәрләре белән ул туган җирнең матурлыгын күрергә, аның кадерен белергә дә өйрәтте. Карасана, игенче, аңа кадәр язылган кайбер әсәрләрдә әйтелгәнчә, «кара мужик», «авыл гыйбедие» генә түгел икән ләбаса, ул да адәми затның игътибарга лаеклы өлеше, ул да башкалар шикелле үк якты хыяллар, бөек уйлар белән рухланып яшәргә сәләтле нечкә хисле була икән!.. Авыл кешесен әнә шулай тормышның ыбыр-чыбырыннан бераз күтәребрәк, калкурак итеп күрсәтү аның үз-үзе каршында дәрәҗәсен күтәрде, үзен-үзе түбәнсетеп, мескен итеп тотмаска тиешлеген дә искәртте. Шуны аңлау авыл яшьләренең иҗтимагый активлыгын үстерергә ярдәм итте. Бөек революция елларында, гражданнар сугышы чорында татар яшьләре иң актив көрәшчеләр сафына күтәрелеп чыкканнар икән, монда матур әдәбиятның, шул җөмләдән Г. Ибраһимов әсәрләренең дә тәрбияви тәэсире көчле булды дип әйтер идем.

Шулай итеп шул бу әсәрләрнең язу алымын тормыш үзе хуп күрде. Җәмгыятьтә күңел төшенкелеге өстенлек иткән елларда күтәренке романтик стильдә язу Г. Ибраһимов дәрәҗәсендәге әдип өчен бик урынлы булган икән. Бу тагын бер мәртәбә аның философик фикерләвенең тирәнлеген, художниклык сиземләвенең көчле булуын күрсәтте (Садри Җәләлнең шул ук елларда дөнья күргән «Дим буенда» романы белән чагыштырыгыз).

Бер тел галименең миңа язган хатында шундый юллар бар: «Г. Тукай, Г. Ибраһимов чын мәгънәсендә тел чирәме күтәрделәр. Г. Ибраһимов прозада телнең җәүһәрләрен, энҗе-мәрҗәннәрен искиткеч урынлы куллана белде». Г. Ибраһимовның әнә шул кабатланмас маһирлегенә мин гомер буена сокланып яшәдем. Монда сүз аның әсәрләренең сүзлек хәзинәсе, фразеологик һәм сурәтләү чараларының гаҗәп бай булуы хакында гына да бармый. Бердән, бу әдип элек әдәбияттан читтә калып килгән бик күп гади сөйләм сүзләрен кыю рәвештә әдәбиятка кертте, икенчедән, шуның өстенә, анда сүзнең эмоциягә тәэсир итү хасиятен, аның эстетик функциясен сиземләү сәләте ифрат дәрәҗәдә көчле иде. Шул сәләтенә таянып, Г. Ибраһимов әдәби әсәрләрендә сүзне мәгънә аңлату белән бер үк вакытта эстетик ләззәт бирерлек итеп тә кулланды. Ул әйтсә, берәгәйле итеп, тәмам җиренә җиткереп әйтте. Аның җөмләләре философлар телендәгечә тирән мәгънәле, шул ук вакытта образлы, музыкаль яңгырашлы, халыкчан булалар («Без түбәннән күтәрелдек», «Фәхрине үтереп ташладылар» һ. б. бик күпләр). Минемчә, композитор күңеленә килеп төшкән җанга якын, дәртле хушавазлар белән рухланып, шуның белән канатланып яңа музыкаль әсәр тудыргандагы кебек, Г. Ибраһимов та үзенең иң һәйбәт әсәрләрен телебезнең байлыгына, матурлыгына, чын күңелдән бирелеп, күз алдында ачыла барган мөмкинлекләре белән рухланып, шуннан тәм табып, аерыла алмыйча язгандыр. Шул сәбәпле, без дә аның әдәби әсәрләренең эчтәлеген аңлау максаты белән генә түгел, бәлки теленең нәфислеге, тапкырлыгы белән дә мавыгып укыйбыз. Аның «Казакъ кызы» романы бу җәһәттән, минемчә, аерата хөрмәтле урында тора.

«Казакъ кызы» — шигърият белән мөлдерәмә тулган әсәрләрнең берсе. Әмма бу роман телендә, минемчә, башкаларда булмаган, матурлык, чынлык тәэсирен көчәйтә торган тагын бер хасият бар.

Мәгълүм ки, роман казакъ үләңе белән башланып китә:

Киң дала, күрәсең гуй, ана жаткан,
Жебәктәй жәсел чүптә битен жапкан,
Аскар тау, балдан татлы сулары бар,
Ана шул анам инде мине тапкан...

Гаҗәп хәл: менә шушы үләңнең шигъри аһәңе, роман укыганда, һич өзлексез аккомпанемент булып, җанны рәхәтләндереп, күңелең түрендә җырлап тора. Сүзләр, җөмләләр татарча, вакыйгаларның үзгәрешен, дәвамын да шул ук тел ярдәмендә аңлыйсың, казакъ даласының киң сулышын да сизәсең, әмма укучыда бу әсәр казакъ халкының үз эчендә торып, казакъ әдибе кулы белән казакъча язылгандыр кебек тоела. Әдәбиятта еш очрамый торган мондый үзенчәлеккә, мондый сәнгатьчә камиллеккә ирешү өчен, талант кына да җитмәгәндер, зур осталык белән тырышлык та кирәк булгандыр. Әдип казакъ халкының гореф-гадәтен, аның телен, ул телнең ифрат үзенчәлекле музыкаль интонациясен, халык сөйләмендәге сүз сөрешен нечкәлекләренә кадәр яхшы белгән. Әнә ул сихри аһәң сүнмәсен, роман буенча шигъри моң булып сузылып барсын өчен, ул казакъ хатыннары учакларын, коры-сары салып, ара-тирә дөрләтеп җибәргәндәй, әсәрнең теленә әледән-әле казакъ сүзләрен, казакъ әйтелешен өстәштерә барган («Асылкан егетем! Бу ни сүзегез! Сылуның наукаслыгы бетеп тормас гуй!..» яисә: «Асылдың кыягындамы, тулпарның тоягындамы, артык туган идең ау...»). Шуның нәтиҗәсендә, бу әсәрне укыганда, тугандаш халыкның рухи байлыгына, теленең матурлыгына, гореф-гадәтенең күркәмлегенә ихтирамың артканнан-арта бара.

Галимҗан Ибраһимов кыйммәте беркайчан да югалмый торган бай, кадерле әдәби мирас, әдәби осталык үрнәкләре калдырды. Аның иҗат алымнары, ул баетып калдырган әдәби тел әле хәзер дә, яңа заманда да үрнәк булып хезмәт итә. Аның әсәрләре безнең заман кешесенә дә Туган илгә, туган туфракка тирән мәхәббәт тәрбияли, рухи ярлылыктан азат булырга, күңел хәзинәсен гуманистик кешелек сыйфатлары белән баетырга ярдәм итә.

Хәзерге заманның укымышлы кешесе — нинди генә югары белем алмасын, нинди генә һөнәр иясе булмасын — матур әдәбияттан рухи азык алырга, иң аз дигәндә дә иң популяр әсәрләр белән таныш булырга тиеш. Минемчә, Гомер, Шекспир белән Толстойның, Достоевский белән Пушкинның иң популяр әсәрләрен дә белмәгән кешене хәзерге заманның интеллигенты дип атау кыен булыр иде. Әмма кешелек дөньясының уртак мирасыннан тыш, аерым халыкларның үз Шевченкосы, Абае, Руставелие, үз Тукае бар бит әле. Галимҗан Ибраһимов та, бик хаклы рәвештә, әнә шул гали затлар сафында урын алды. Үз халкының үткәнен, аның яңа заманга якты юл ачкан революцион көрәшкә нинди өлеш кертүен, гореф-гадәтен, мәдәниятен, гомумән, нинди халык булуын белеп яшәү өчен, һәр укымышлы кешегә Г. Ибраһимов әсәрләре белән дә таныш булырга кирәктер.

## Нәкый Исәнбәт

# ОСТАЗЫБЫЗ ИДЕ...

Галим буларак, Г. Ибраһимов 1914—15 елларда татар мәдрәсәләрендә үзенең тел-әдәбият дәреслекләре белән таныла. Без, шәкертләр, Г. Ибраһимовның шул дәреслекләре буенча укыдык. Шулай ук аның «Табигать балалары» һәм «Алмачуар» кебек хикәяләрен дә бик яратып укый идек.

1917 елдан үзем дә, тел һәм әдәбият укытучысы буларак, Г. Ибраһимовның татар теле дәреслекләре буенча балалар укыттым (шулай итеп, бу фәннәр буенча мин үзем дә аның шәкертләреннән берсе булып чыгам).

Г. Ибраһимовның бу гыйльми әсәрләре мәдрәсәләр өчен зур табыш булды. Чөнки элек бездә тел, әдәбият буенча язылган дәреслекләр күбесенчә, гарәп ысулы белән язылган булса, Г. Ибраһимовның дәреслекләре татар теле нигезендә язылган иде.

1927 елны кышның иң салкын көннәренең берсендә, без башкорт язучысы Давыт Юлтый белән Уфадан Казанга килгәч, Галимҗан Ибраһимовны күрер өчен, аның квартирына бардык. Ул хәзерге Комлев урамында яши иде. Безне алгы бүлмәдә хатыны Гөлсем ханым каршы алды. Өйләре бик салкын иде. Безнең кем икәнне һәм ни өчен килгәнне белгәч, эчке бүлмәгә кереп китте. Бераз торгач, Г. Ибраһимов үзе килеп чыкты һәм шул чыккан ишеге янындагы урындыкка утырды. Өстендә ак каракүл якалы кышкы бишмәт, башында шундый ук бүрек. Ул бик ябык һәм авыру иде. Исәнләшеп, танышып, хәл-әхвәл сорашып утырдык. Ул безгә Кырымга дәваланырга китәргә җыенуын әйтте. Шул вакыт татар театрының директоры Зәки Баязитский килеп керде. Кулында бер төпләм гәҗит. Ул Оренбургта бишенче елларда Х. Ямашев чыгарган «Урал» газеталары иде. Г. Ибраһимов бу газета һәм уралчылар турында мәкаләме, брошюрамы яза икән. Баязитский бу гәҗитләрне Г. Ибраһимовка тапшырды һәм аны тоткарламыйча чыгып китте. Без Галимҗан Ибраһимовның шушы авыр хәлендә дә һаман язуын күреп, аның бик тырыш кеше булуына гаҗәпләндек. Әдип белән кайбер мәсьәләләр турында сөйләшкәч, аның авыру хәлен күреп, Юлтый белән без дә, аны борчымаска булып, тәмам терелүен теләп, чыгып киттек.

## Салих Баттал

# ОЛЫ КӨРӘШ ЮЛЫНДА

Егерменче елларда еш яңгыраган Буденный маршының «И вся-то наша жизнь есть борьба!» сүзләре белән тәмамлануы очраклы түгел. Без һәммәбез дә рухыбыз белән буденныйчылар — Ибраһимовларны төрмәдә интектергән патша строе, аның көчләре, традицияләре белән көрәшүчеләр идек!

Шуның өчен дә Мансур Крымов рус шагыйре Некрасовның

Мне борьба мешала стать поэтом,
Стихи мешали стать борцом,—

дигән юлларына каршы үзе турында (юк, үзе турында гына түгел):

...көрәш белән
серкәләнде җырлар чәчәге! —

дип, көрәшнең шигырьгә комачауламавын, киресенчә, уңдырышлы фактор икәнен әйтеп, барыбызның да карашын чагылдырды.

Ибраһимов иҗатында ул көрәш, әлбәттә, Буденный маршындагыча түгел, башка планда бара. Укучыны ул бөтенләй сизелмәс дәрәҗәдә гади детальләр, күренешләр

аша үз эченә алып кереп китә: суга барган кыз, чиләген чумырып, «күз кебек» тотырып ала. Ике авыл малае, үзара сөйләшкәндә, берсе әледән-әле таш алып, күздән язарлык югарылыкка ыргыта. Балык тотучы малай, балыгы кулыннан ычкынгач та, су читенә чүгәләп, ычкынган балыгын тотарга өметләнеп, озак кына кармалана. Автор үзенең герое исеменнән: «Мин балык булсам, үз кармагыма гына кабар идем»,— ди.

Болар һәммәсе — зур көрәшнең кечкенә бер детале.

Билгеле инде, язучының көрәш коралы беренче чиратта — тел. Ибраһимов аны яхшы белеп, оста куллану гына түгел, иҗатының беренче елларында ук татар теленең имля, сарыф, нәху (орфография, морфология, синтаксис) кагыйдәләрен төзеде. Революциядән соң без аларны уку китаплары итеп кулландык.

Галимҗан ага Ибраһимов белән мин берничә кабат очраштым. Очкычларның чаңгыдан тәгәрмәчкә күчү чорларында, аэродромнар изрәп, очулар тукталганда, очучыларны көньякка ялга җибәрәләр иде. Шуңа күрә әдип белән күрешүләр дә күбесенчә яз айларында булгандыр дип уйлыйм.

Путевкалар, кагыйдә буларак, Ялта шәһәренә бирелә иде. Анда барышлый да Мәскәүгә туктала идем. Нәкъ шунда инде Мәскәү язучылары, әдип янына керергә киңәш итеп, аның адресын бирделәр.

Ялта шәһәре Кырымның көньягында ярым воронка сыман уелмага кереп урнашкан. Ул баруымда безнең ял йортыбыз шәһәрнең түбәнрәк, диңгезгә якын өлешендә иде. Башка урамнар кебек үк бормалы-бормалы Халтурин урамы буйлап югарыга үрлисең. Офык киңәя бара. Еракта Учан су (оча торган «Очкан су») күренә башлый. Урамның уң ягында таш коймага ишек уелган. Шунда борылып кергәч, ике катлы кечерәк кенә таш өй күренә. Әдип үзенең биш-алты яшьлек улы һәм хатыны Гөлсем ханым белән шул таш өйнең өске катында яши.

Кухня аша, идәндәге ягулык утын өеме янынннан үтеп, әдип яткан бүлмәгә керәсең. Уртада өстәл, сул якта — караватъ. Стенада китап шүрлекләре. Анда китаплар тулы. Иң өске рәтләрендә — В. И. Ленинның тулы мәҗмүгасы. Диванга сөялеп утырган әдип нәкъ рәсемнәрендәге кыяфәттә.

Олы язучы... Кереп күрешер алдыннан шундый халәт кичерәсең, гүяки эссе, бөркү һавадан диңгезгә сикерергә җыенасың... «Сикерү» белән үк сизенәсең — корыдагы кичерешләрең инде үткән, син инде диңгездә «үз кеше», рәхәтләнеп йөзә бир...

— Әйе,— дип куйдым мин күрешүләр, танышулардан соң,— нәкъ теге кеше сөйләгәнчә булып чыкты...

— Кайсы кеше? — дип сорады Галимҗан ага, мияге белән генә утырырга ишарә кылып.— Нәрсә сөйләде?

Мин аңлатып бирдем: 1927—1928 елларда Ибраһимовның нинди уңай беләндер юбилее үткәрелде. Мин Ленинградта курсант идем. Шунда бер иркен генә аудиториядә татарча доклад ясалды. Докладчы Ибраһимовның тормыш эпизодларын искә алганда, аның Себердә аклар тылында гади бер олаучы кыяфәтендә йөрүен дә әйткән иде. Мин шуны әдипнең үзенә карап: «Нәкъ гади бер олаучы агай кебек»,— дип, сүземне тәмамладым.

Ә ул мин көтмәгән дәрәҗәдә кызыксынып:

— Тагын, тагын ниләр сөйләде ул? — дип сорады.

— Тагын шуны әйтте: «Хәзер аның бер үпкәсе авыру, тик сыңар үпкәсе белән генә сулап яши»,— диде.

— Анысы да дөрес,— диде Галимҗан ага, сүлпәнләнә төшеп.

Һәм ул шундый яшәвенең кадерен, кыйммәтен белгән кебек, тәкаллефсез, озакка сузмый гына хәзерге әдәбият мәсьәләләренә күчеп, үземнең ниләр язуым белән кызыксынды:

— Теге картыңны язып бетердеңме әле? — дип сорады.

Мин гаҗәпләнеп һәм уңайсызланып калдым. Гаҗәпләндем, чөнки ул искә алган карт персонаж катнашкан әсәремне мин әле журналда бастыра гына башлаган идем. Ә ул шуны укып барырга, хәтта аның персонажларына әһәмият биреп укырга өлгерә икән! Бер мине генә түгел, әдәбият дөньясына атлаган барлык яшьләрне укып, тикшереп бара икән!

Ә уңайсызлануым шуңар: минем ул телгә алган проза әсәрем бөтенләй чи килеш диярлек басылганда, журнал редакциясе талымсызлык күрсәткән иде. Газиз Иделле шул турыда тәнкыйть мәкаләсе белән чыгыш ясагач кына, минем ул нәрсәм басудан тукталды.

Шул турыда Ибраһимовка әйткәч, ул:

— Гомумән алганда, бәлки Иделле хаклыдыр. Ләкин синең әлеге картың бик тормышчан. Ул образ әрәм булмасын иде,— дип, аның кайбер кыланышларын һәм сүзләрен искә төшереп, көлеп куйды.

Соңрак ул карт минем «Сынау» пьесасына Кадермәт исеме белән килеп керде

Галимҗан ага русча да барлык газета һәм журналларны укып бара икән. Демьян Бедный иҗатына зур бәя биреп: «Чәчәк ата»,— дип куйды.

Гөлсем ханым сүзгә кушылмый, әледән-әле кереп: «Даруыңны эчәргә вакыт түгелме?» — дип, яисә: «Бүген фәлән врачны чакыртыйкмы?» — дип, бер-ике сүз белән генә киңәшләшеп, тагын чыгып китә иде. Әнисенеке кебек зәңгәр күзле уллары да уйнап кайта да әтисенә килеп иркәләнә һәм тагын чыгып китә.

Өлкән әдипне таваф кылучылар, әлбәттә, күп. Ул кемнәрнең килеп-китүләрен әйтеп, кыскача гына характеристика да бирә. Афзал Таһиров турында: «Бик күпне белә»,— дип куя. Татарстан язучылары төркеме дә булып үткән икән. Аларның кайберләрен сөеп кенә көлеп телгә ала: «Такташ атка атланып йөрүче инглизләр чалбарын кигән»,— ди. Тагын бер мәһабәт кушамат белән кул куеп язучы турында: «Ул — кушаматсыз килеш — Хизбулла Хәзрәтев икән...» — ди.

Бүлмә уртасында өстәл, аның да уртасында фарфор аш тәлинкәсе. Тәлинкәдә радио колакчыннары ята. Тәлинкә аларның тавышын шушы бүлмәгә җитәрлек итеп кенә көчәйтә икән. Димәк, хуҗа махсус репродукторның тавышын каты саный, аны яратмый дигән нәтиҗәгә киләм.

Әңгәмә әдәбият теориясенә кагылганда, Гөлсем ханым да кушылып китте, ләкин сүз озак дәвам итә алмады. Чөнки бу өлкәдә минем мәгълүмат чагыштырмача аз, алар өчен кызыклы оппонент була алмадым...

## БЕР СОРАУГА — БЕР ЖАВАП

СОРАУ:

— Татар әдәбияты үсешендә Г. Ибраһимовның роле нинди?

ӘМИРХАН ЕНИКИ:

— Сорау җитди. Галимҗан Ибраһимов — зур шәхес: әдип, галим, җәмәгать эшлеклесе. Шуңа күрә сорауны конкретлаштырып, үземнең бурычны ныграк ачыклыйсым килә. Сүз билгеле, матур әдәбият һәм аның да проза дигән жанры турында барырга тиештер инде: безнең проза үсешендә Галимҗан Ибраһимовның әдип-художник буларак роле нинди?

Бу сорауда игътибарны иң элек үзенә җәлеп иткәне — «үсешендә» дигән сүз... Димәк, проза әдәбиятыбызның Галимҗан Ибраһимовка чаклы хәленә дә күз салырга кирәк була... Һәм күз салу белән ике нәрсәгә хәйран калырга туры килә: бер яктан бик нык артка калу, икенче яктан гаҗәп тиз алга китү... Уйлап кына карагыз: без диңгездәй галәмәт зур Россия уртасында яшибез, бөтен әйләнәбездә рус мохите, русның культурасы, сәнгате, әдәбияты... Бу әдәбиятның Гоголь, Достоевский, Тургенев, Толстой, Чехов кебек бөек әдипләре бар, аларның даһи әсәрләре бер-бер артлы чыгып тора, тарала, укыла, ә бездә әле бернәрсә дә юк. Ягъни, бик борыннан килгән шигъри әдәбиятыбыз булса да, проза дигән яңа реалистик әдәбиятның һаман да әле туа алганы юк. Бу ни эш?.. Әллә безнең халык шуны күрмиме, әллә ул томана сукырмы, уку-язудан бөтенләй мәхрүмме?.. Юк, күрә, ишетә. В. И. Ленин искәртеп үткәнчә, Бөек Октябрь революциясенә кадәр үк ана телендә укый-яза белү җәһәтеннән Россия халыклары арасында алда тора (Ленин В. И. Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә. 39 т. 549 б.). Әмма, шуңа карамастан, бездә беренче реалистик проза әсәре бары 1886 елда гына дөньяга килеп чыга.

...Әйе, без бик озак, бик авыр уянабыз. Мәгәр бер уянгач, аякка тиз басабыз. Башта Муса Акъегетнең «Хисаметдин мелла»сы, аның артыннан ук Заһир Бигиевның «Меңнәр яки гүзәл кыз Хәдичә» романы (1887 елда) дөньяга чыкса, алардан соң тиз арада Риза Фәхретдинев, Фатих Кәрими, Закир Һади, Мәҗит Гафури һәм башка язучыларыбызның яңа проза әсәрләре бер-бер артлы чыга башлыйлар. Боларга ялганып ук диярлек иҗатларын барысыннан элек прозага багышлаган Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал, Садри Җәләл, Ярулла Вәли, Шаһит

Әхмәдиевләр әдәбиятка килеп керәләр. Исемнәр күп... Бигрәк тә Рәсәй өстеннән күкрәп узган бишенче ел давылының татар дөньясына бәрәкәтле йогынтысы гаять зур булды. Кыска гына вакыт эчендә әдәбият, матбугат, нәшрият эшләре искиткеч бер җанлану һәм күтәрелү кичерде. Әмма хикмәт гомуми җанлану, язучылар саны күбәеп китүдә генә түгел иде. Иң мөһиме — сыйфат ягыннан тиз үсү-үзгәрүдә иде.

Телебезнең саф татарчага әйләнә баруы, сүз сәнгате буларак аның нәфисләшүе, образлашуы, бизәкләргә баюы Фатихлар, Галимҗаннар заманына туры килә. Бигрәк тә Галимҗан Ибраһимов иҗатында бу ачык чагыла. Сез аның 1911—14 еллар арасында язган хикәя, повестьлары белән мәкаләләрен генә чагыштырып карасагыз да тел җәһәтеннән болар арасында ярылып яткан аерма күрерсез... Димәк, шушы фактган чыгып, югарыдагы сорауга беренче җавапны да бирергә була:

— Әдәби телебезне сафландыру һәм камилләштерүдә Галимҗан Ибраһимовның тоткан роле гаять зур.

Сыйфат ягыннан үсүнең икенче мисалы итеп, мин прозада жанрларның төрләнүен һәм ачык билгеләнүен әйтер идем. Озак та үтми, романны озын хикәядән (повестьтан), озын хикәяне кыскасыннан аерып була башлый (билгеле, күләм җәһәтеннән генә түгел). Болар жанр буларак формалашу белән бергә, һәркайсының зур осталары да мәйданга чыга. Һәр өч жанрның, бигрәк тә повесть белән хикәяләрнең, гүзәл үрнәкләрен Фатих Әмирхан белән Шәриф Камал бирәләр. Мәгәр шулай да бу өлкәдә дә Галимҗан Ибраһимов иҗаты ныграк аерылып тора. Киң колачлы, социаль эчтәлекле романнарны, төгәл, камил язылган хикәя, повестьларны безнең әдәбиятта башлыча ул тудыра. Димәк, әлеге сорауга тагын бер җавап:

— Татар әдәбиятын прозаның төрле жанрлары белән баетуда Галимҗан Ибраһимовның роле шөбһәсез бик зур.

Һәм безнең проза үзенә иң якын торган бөек рус прозасына хас художество чараларын озакламый күпмедер дәрәҗәдә үзләштерүгә дә ирешә. Мәсәлән, әсәрдәге персонажларның портретларын бирү, характер үзенчәлекләрен ачу, эчке кичерешләрен чагылдыру; вакыйганы хикәяләгәндә тормыш күренешләрен, көнкүреш шартларын сүз ярдәмендә ачык картиналар итеп сурәтләү; кара-каршы сөйләшү формаларын төрләндерү, эчке монологларны киң куллану, хикәяләүне ничек тә тасвирлырак, җанлырак итеп алып бару; ниһаять, табигать күренешләренә киң урын бирү, табигатьне вакыйга белән бәйләү, образның рухи халәтен ачу яки автор фикерен көчәйтү чарасы итеп куллану... Билгеле, бу чараларны һәрбер язучы үзенчә куллана, ләкин инде шулардан башка әсәр язу юк.

Шул рәвешчә, безнең яңа реалистик прозабыз, күп булса бер 20-25 ел эчендә, сүз сәнгате буларак тәмам өлгереп җитә. Моннан тагын бер нәтиҗә:

— Матур әдәбиятыбызның сәнгать булып җитешүендә Галимҗан Ибраһимовның роле шулай ук бик зур.

Ихтимал, мин журнал куйган сорауга тулы җавап биреп бетерә алмаганмындыр. Шулай да, әйтелгән кадәресеннән, дә, ике төрле мөһим нәтиҗә ясарга хакым бардыр дип уйлыйм. Беренчедән, Фатихлар, Галимҗаннардан соң әдәбиятк килгән язучыларга алардан өйрәнмичә, үрнәк алмыйча иҗат итү мөмкин түгел иде инде. Алар «мәктәбен» узмаган берәр язучы булды микән?!. Тик моны сукыр иярү, кабатлау дип кенә аңламаска кирәк... Һәрбер чын язучы. нинди генә «мәктәп» узмасын, ахыр чиктә бары үзенчә, үзе аңлаганча иҗат итә.

Икенчедән, безнең яңа реалистик әдәбиятыбыз революциягә кадәр тугандаш төрки халыклар өчен дә күпмедер дәрәҗәдә үрнәк иде. Безне укыдылар, бездән өйрәнергә тырыштылар... 1957 елны Алма-Атада М хтар әкә Ауэзов белән очрашып сөйләшкән чакта ул миңа:

— Тукай белән Галимҗан Ибраһимов сезнең генә түгел, безнең дә остазларыбыз! — дип әйткән иде.

Әдәбиятыбызга әнә шундый дан-абруй китерде безнең классикларыбыз!

## Зөлфәт

### Ялта тыкрыгында

Җил
    тузанлы юлга шыбырдатып
Койды
Платан яфрагыннан чыкны...
Яктыгарак менеп барыш иде —
Тар тыкрык
            тупик булып чыкты.

Платан төбендәге утыргычка
Чүмәште ул,
            алды сулыш кысып:
Ютәл белән уятмаска иде
Гөләпләрнең таңгы сак йокысын...
Ычкындырды яка сәдәфен ул.
Эшләпәсен салып куйды янга.
Әсәр өчен түгел —
            яшәр өчен
Сулыш җитми менә Галимҗанга...

«Хакмы икән кылган гамәлләрем?
Нишлим икән мин моннан соң?» — дигәч,
Гади генә итеп:
— Эшләгез! — дип,
Иптәш Ленин биргән иде киңәш.

Һәм Галимҗан йөкне ат күк тартты,
Җиңе һәрчак булды сызганулы,
Зарлануны белмәде ул буын,
Танымады сыктау-сызлануны.
Күргәне бар юкса бу тормышта
Үз күзләре белән Галимҗанның
Алмачуар чабыш атларның да
Ярты юлда янып егылганын.

Килми лә шул янып егыласы
Җилле еллар ашкынганда таңга!
Тауга йөк тартканда туктау — үлем...
Икеләтә авыр Галимҗанга.

Тормыш төпләреннән күтәрелеп,
Талпынды ул биектәге утка —
Нишләп илтеп кертте әле язмыш,
Чыгар юлны бикләп тар тыкрыкка?

Ишетелә ярдан диңгез шавы...
Шыбырдаша ташлар күбекләнеп...

Нинди дулкын ярга илтеп бәрде,
Чәрдәкләде олы өметләрне?

...Аһ, сулыш юк, сулыш...
Минме шулай
Гомер уртасында сыгылучы?
Чү!.. Улкае эндәшәме әллә:
— Әти! Әти... Сиңа ни булды соң?!.

Юк, юк!.. Улын да бит югалтты ул...
Болай гына күренәдер күзгә...
Ләкин
Тагын кабатланды тавыш:
— Абый, димен! Нәрсә булды Сезгә?

...Үтеп керде сулыш үпкәләргә.
Тәмам киткән дөнья кайтты кабат...
— Рәхмәт, балам...
Коткардың син мине...
Ташламасын сине шушы савап...

Таныйм да күк... Ялта малаемы?
— Ялтаныкы... Ә мин Сезне беләм!
Әни әйтте: «Ул — Ибраһимов,— дип,—
Казаннан ук шифа эстәп килгән...»

Куркыттыгыз мине...
Әйдә, абый,
Алып төшәм Сезне мин диңгезгә!
Бер явызы адаштырды мәллә?
Бу тыкрыкта нәрсә калган Сезгә?!.

— Бар, диңгезгә ашык, балакаем...
Бар, күңел ач,
Йөгер, ашык ярга!
Адашмабыз...
Андыйлардан түгел...
Без калмабыз, балам, тыкрыкларда!..
Йөгер, балам!

...Бакчы, күр син аны —
Нәкъ бит аның улы төсле икән...
Кузгалырга кирәк... Кояш чыккан,
Яфракларда инде чыклар кипкән.
— Юк! — дип,
Тешен кысты кинәт кенә.—
Куркытма, син, язмыш,
юк, куркытма!
Үзебезчә
Без дә кояш идек —
Кала алмый кояш
тын тупикта!

Ул тамаша кылды сабый сыман
Ал гөләпне җилләр селкеткәнен.
...Белә иде,
Сизә иде йөрәк
Алда авыр, бөек юл көткәнен...




**Ринат Мөхәммәдиев**

# ТАГЫН БЕР КАТ «ТАТАР ШАГЫЙРЬЛӘРЕ» ТУРЫНДА

### Г ИБРАҺИМОВ ТӘНКЫЙТЕНДӘ Г. ТУКАЙ

Габдулла Тукай һәм Галимҗан Ибраһимов... Татар әдәбияты күгендә бер-бер артлы якты йолдыз булып кабынган, кабынган һәм сүнү, сүрелүне белмәгән, менә инде ничә дистә еллар бөтен бер әдәбиятның якты маяклары булып килгән мәшһүр затлар. Бу ике исемнең шулай янәшә килүе табигый хәл. Табигый булмаска, яңа татар әдәбиятының чын мәгънәсендәге реалистик нигезен салучыларның иң күренеклеләре ич һәр икесе. Поэзиядә — Тукай, прозада — Ибраһимов. Татар әдәби тәнкыйтен, эстетик фикерен нигезләүгә дә башлап алынучылар Тукай һәм Ибраһимов. Революцион-демократик вакытлы матбугатыбыз, тел белеме, халык авыз иҗатын өйрәнергә керешсәк тә, иң элек аларга — Тукай һәм Ибраһимовка мөрәҗәгать итәбез. Татар әдәбиятының критик реализм аша мәгърифәтчелектән социалистик реализмга таба тизләтелгән үсеш юлын, татар әдәби-эстетик фикеренең шәрыктән гарепкә ягъни Көнчыгышның романтизм традицияләреннән рус һәм Европа халыклары әдәбиятларының реалистик мирасын өйрәнүгә йөз белән борылу процессын да бөтен нечкәлек һәм каршылыклары белән өйрәним дисәң, Тукайга, Ибраһимовка мөрәҗәгать итәргә туры килә. Китапханәләрдә күптомлыклары, портретлары янәшә, әдәбият дәреслекләрендә иҗатлары хакындагы сүзләр янәшә, хәтта туган еллары, 100 еллык олы бәйрәмнәре...

Ә шулай да Тукай һәм Ибраһимов исемнәрен янәшә атаганда, әле булса кайберәүләрнең колаклары шундук үрә тора. Тукай һәм Ибраһимов арасындагы мөнәсәбәтләр хакында алар үзләре исән чакта ук күпме сүз, күпме имеш-мимеш йөргән. Печән базары почмагында туган имеш-мимешләрнең берсе калмый инде күптән онытылып бетте, ә монысы яши. Имеш, Тукай белән Ибраһимов бер-берен куралмаганнар. ...Имеш, Тукай үзенең шигырьләрендә Г. Ибраһимовны болай дип, тегеләй дип мыскыл иткән. Ә Ибраһимов Г. Тукайны шагыйрь түгел дигән... Ни генә димиләр, ни сөйләмиләр, кыскасы. Тукайның «Шүрәле»сен дә ишетмәгән, үз туган телендә авызын тутырып бер кәлимә сүз әйтергә кыенсынып йөрүче дә мәгълүматлы бу хакта, Ибраһимов томнарын кулында тотып карамаган, «Алмачуар»ны «Башсыз җайдак»тан аермаган затлар, белү генәме, хәтта үзләреннән кушып, өстәп-өстәп җибәрәләр...

Гомумән, кемнәндер ишеткәннәргә генә нигезләнеп яисә Тукайдан, Ибраһимовтан китерелгән кайбер цитаталарга ышыкланып һәм хәтта Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» дип исемләнгән әдәби-эстетик трактатыннан чыгып кына да нәтиҗә ясау ярамый бу очракта. Чөнки сүз халыкның иманы һәм намусын тәшкил иткән олы художниклар, талант ияләре хакында, әдипләр генә түгел, көрәшчеләр хакында. Шул чорның әдәби-эстетик фикере формалашуы, үсеше проблемаларын һәм, табигый ки, каршылыкларын җентекләп өйрәнми һәм күз алдында тотмый торып, әлеге мөнәсәбәтләр хакында нәтиҗәләр ясау, хөкем чыгару ярамас һәм, гомумән, мөмкин дә түгел.

Бу сүзләрем һич кенә дә яңадан велосипед уйлап чыгарырга маташу түгел. Г. Ибраһимов иҗатын һәм тормыш юлын тулаем колачлап, комплекслы рәвештә эзлекле өйрәнү нәтиҗәсендә туган хезмәт — М. Хәсәновның «Галимҗан Ибраһимов»ында (Казан, 1964) әлеге мәсьәлә һәм мөнәсәбәтләргә инде күптән бәя бирелгән. Г. Халитнең «Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән» (Казан, 1975) китабы да XX йөз башы татар әдәби-эстетик фикеренең әлеге үсеш проблемаларына зур ачык-

лык өсти. Бурычымны фундаменталь хезмәтләргә нигезләнеп һәм кайбер яңа табылган мәгълүматлар һәм күзәтүләремә таянып, әлеге четерекле мәсьәләгә янә бер кат ачыклык кертүдә күрәм.

Әдәби тәнкыйтьтә Г. Ибраһимов исеме 1910 нчы елдан күренә башлый. Димәк, татар вакытлы матбугатының һәм, шул исәптән, 1905 ел революциясе давылында туып, аның белән бер биләүдә үскән әдәби тәнкыйтьнең дә инде азмы-күпме тәҗрибә туплап өлгергән еллар була бу. Матур әдәбиятка гына түгел, милли әдәби-эстетик фикер үсешенә дә Г. Тукай, Ф. Әмирхан кебек авторлар шактый ук җитди өлеш керткән. Формалашу юлында булган әдәби тәнкыйтьнең үз предметын, функцияләрен һәм алда торган җитди бурычларын бер кадәр ачыклап өлгергән еллары. Көн тәртибенә инде милли әдәбият һәм культураның киләчәк барыр юлын билгеләү һәм аның әдәби-эстетик кыйблаларын теоретик нигезләү кебек җаваплы бурычлар килеп баскан була. Г. Ибраһимов беренче тәнкыйть хезмәтләре белән ук милли әдәбият һәм әдәби-эстетик фикернең алга таба барыр юлын ачыклауда хәл ителүләре соң дәрәҗәдә зарур һәм кичектергесез булган шушы проблемаларны колачлап алырга омтыла. Әле беренче адымнарын гына атлаучыларга хас саклык белән түгел, җиң сызганып эшкә керешә. Көн, заман таләбе шундый була, алныартны үлчәп кыяр-кыймас атлап йөрер чак түгел. Гомумән, Ибраһимов — табигате белән үк туры һәм тәвәккәл шәхес.

Һәм шул ук 1910 елның башында, хәтта иң элекке тәнкыйть мәкаләсендә ук: «Хәзер шигырь мәйданында иң шәүкәтле һәм галәбәле рольне мөхтәрәм Тукаев уйный. Шул дәрәҗә ки: татар шагыйре диелүгәчә укучы зиһенендә Тукаев мәүҗүд була. Бу шагыйребез көннән-көн күтәрелә. Халык күңелендә хак вә ихтирамлы урын ала барадыр»,— дип вакытлы матбугатта чыгыш ясый. Шул рәвешле, ул үзенең инде Г. Тукай шигырьләре, аларның татар әдәбиятында тоткан урыны һәм укучыларның бу иҗатка мөнәсәбәтен яхшы белүе һәм байтактан күзәтеп килгәнлеген искәртә.

Тагы берничә айдан «Йолдыз» сәхифәләрендә (1910, 1 апрель) «Әдәбият мәсьәләләре» дөнья күрә. Бу хезмәт хаклы рәвештә бездә әдәбият белеме фәнен нигезләү юлында тәүге һәм җитди адымнарның берсе саналырга лаек. Рус әдәбияты дигәндә күз алдына Пушкин, Гоголь, Тургенев, Лермонтов һәм Горький, төрек әдәбияты дигәндә Әхмәт Мидхәт һәм Тәүфикъ Фикрәтләрне хәтерләсәк, татар әдәбияты хакында сүз чыктымы, Г. Тукай һәм Ф. Әмирханның «әдәби һәм шигъри әсәрләре» күз алдына килә дип, янә бер кабат искә ала Г. Ибраһимов. Хәтерләп калыйк: тәнкыйтьче, «әдәби әсәрләр» дию белән генә чикләнмичә, «шигъри» төшенчәсен аерым искә алуны кирәк саный.

Шул ук елның июнендә Г. Ибраһимов, заман әдәбияты һәм халык авыз иҗаты арасындагы мөнәсәбәтләрне күздән кичереп, янә бер кат Г. Тукай иҗатының татар әдәбияты барышындагы кабатланмас урынын билгеләп уза. Татар халкының үз фольклорына мөнәсәбәттә күзен ачуда, аңарга үз авыз иҗатының нинди бай һәм саекмас рухи мирас булуын күрсәтүдә шагыйрь эшчәнлегенең ролен ассызыклый: «Бу турыда һәркемнән артык мәшһүр шагыйребез Тукаевка бурычлыбыз. Ул үзенең матур вә шагыйранә җөмләләре илә шул гавам әкиятләрен тасвир итеп, һәркем тарафыннан сөелеп укырлык бер хәлгә куйды.

Мәсәлән: аның күптән чыккан «Шүрәле»се... «Су анасы» бунын иң гүзәл нәмүнәләреннәндер. Тукаевның бу шигырьләре шулкадәр ачык вә табигый чыккан ки, чи гавамның авызыннан да шулкадәр генә чыгар иде».

Шул рәвешле, тәнкыйтьче Г. Тукайның халыкчанлыгын тулысынча танып, шагыйрь иҗатының табигате, сурәтләү объекты, тел һәм стиле белән үк халык рухына якынлыгын кат-кат искәртеп уза. Бер үк вакытта ул аның шигъри осталыгы һәм татар шигърияттен әдәби осталык җәһәтеннән үстерүгә керткән өлешенә дә битараф түгел. Мисал өчен, «Йолдыз»ның 1911 ел 10 февраль санында ул Н. Думави, М. Гафури, З. Бәшири, М. Укмасыйлар иҗатында әледән-әле шигъри осталыкка игътибар җитенкерәмәвен искәртеп, аларга үрнәк йөзеннән Г. Тукай исемен китерә: «Назым ягы да, шигърияте дә ярыйсы булган вә биннисбә (чагыштырмача — Р. М.) яхшы вә муаффәкыятьле чыккан шигыре мәнзумгә мисал табу өчен без Габдулла әфәнде Тукаевның мәҗмугаләренә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүрмез».

Әйе, Г. Ибраһимов әдәби тәнкыйть эшчәнлегенең таңында ук Г. Тукай иҗатына игътибар күрсәтә һәм аның бәхәссез уңышларын даими күрсәтеп килә. Әмма, бер үк вакытта, ул шагыйрь иҗатына таң калып, аны идеаллаштыру юлына басмый. Тукайның үсештә, камилләшү юлында булган иҗатына, үзенең В. Г. Белинский тәнкыйте югарылыгыннан куелган критерийларыннан килеп, кайбер таләп һәм теләкләрен белгертә килә. «Әле татар рухының бик вә бик күп яклары бер шагыйремез тарафыннан да кузгатылмый тора; хәятымызның күп нокталары шагыйрьләремез-

нең күзенә чалынмый ятадыр; хосусән озак яшәгән вә бик төрле, җанлы вә бик күп хәзинәле булган хәяте мазиябез, тарихыбыз шагыйрьләребез тарафыннан бөтенләй онытылып торадыр». Аңлашылса кирәк, тәнкыйтьче татар поэзиясенең бүгенге халәтеннән, гәрчә анда Г. Тукай үзе булуга да карамастан, бигүк канәгать түгеллеген белгертә. Тукайның әдәби осталыгы хакында сүз чыкканда да ул «иң-иң» дигән эпитетлар кулланырга ашыкмый, ә «чагыштырмача» дигән сүзне кулай таба.

Ни өчен әлеге детальләргә игътибар юнәлтәбез соң әле? Шуның өчен, чөнки бездә Ибраһимовның Тукай иҗатына мөнәсәбәтен ике чорга бүлеп, тәнкыйтьчене эзлексезлектә гаепләү бик киң таралган. Имеш, 1910—1912 елларда Г. Ибраһимов объектив булган, ә инде аннардан соң, Тукайның бер-ике җәйсыз сүзен ишеткәчтен, тенденциозлык юлына баскан булып аңлашыла. Миңа калса, тәнкыйтьченең шигърияткә мөнәсәбәттәге эзлеклелеген күрмәү — үзе үк тенденциозлылык. Аның шактый ук каршылыклар аша үскән әдәби-эстетик принциплары шул дәрәҗәдә эзлекле ки, хәтта әлеге эзлеклелек тәнкыйтьчегә үзенең кайбер хаталануларын да вакытында җиңеп узарга ирек бирми. Эстетик карашларындагы эзлеклелектән килгән каршылыклары аның аеруча Г. Тукай иҗатына мөнәсәбәтендә чагылыш таба.

Г. Ибраһимов тәнкыйтьтә хис, эмоция белән эш итми, башкалар сүзенә, уңга-сулга карангалап фикер йөртүдән дә ерак тора. Әдәбият һәм сәнгать барышы өчен гаять зарур булган җитди нәтиҗәләргә киләме, әллә хаталанамы, аның үз принциплары, критерийлары аермачык булып күзгә ташлана. Әйтеп узылганча, унынчы еллар башы татар әдәби тәнкыйте алдында торган бурыч — милли әдәби-эстетик фикернең үсеш проблемаларын ачыклау һәм нигезләүдән гыйбарәт иде. Теге яисә бу әдипнең, шагыйрьнең иҗатына «яхшы», «яман» мөһерләре сугып чыгу түгел, әдәбият һәм сәнгать үсеше юлында килеп баскан кичектергесез проблемаларны ачыклау, хәл итү зарурияте иҗатка рухландыра тәнкыйтьчеләрне.

Һәм әлеге проблемаларның иң җитдие — әдәбиятның тормышка мөнәсәбәте, иҗтимагый роле, идеялелек мәсьәләләрен заман таләпләре югарылыгында хәл итүгә башлап керешкән тәнкыйтьче Г. Ибраһимов. Аның фикеренчә: «Әдәбият, бигрәк тә романнар, кызык өчен, укып, көлеп тә ахырында ташлар өчен генә язылмый һәм язылмаска тиешле. Анда мөхәррирнең әйтергә теләгән бер уе, күрсәтергә теләгән бер күренеше, халык һәркөн күреп, сөйләп тә сизми кичкән мөһим вә хас бер мәгънә була» («Йолдыз», 1912, 6 август). Игътибар итик, бу өземтәнең башында ук «әдәбият» дип әйтүгә үк, тәнкыйтьче янә бер кабат «бигрәк тә романнар» дип конкретлаштыруны мөһим дип таба. Аның әдәби-эстетик хезмәтләрендә бер генә тапкыр очрамаган, беренче карашка алай әллә ни игътибарга да лаек түгел сыман тоелырга мөмкин булган, шушы кечкенә генә синтаксик детальдә Г. Ибраһимов эстетикасының җитди эзләнүләр чорына хас булган, һәм бер үк вакытта аның Тукай поэзиясенә мөнәсәбәтенең ачкычын тәшкил иткән каршылыкларның асылы чагылып китә.

Г. Ибраһимов, әдәбият дигәндә, беренче чиратта проза әсәрләрен күздә тотып, шигырьне бу төшенчәдән күпмедер читләштереп, өстенрәк жанр итеп карады. Тәнкыйтьченең хезмәтләрендә, шигырь, әдәбияттан бигрәк «сәнаигы нәфисә»гә якынрак итеп куела. Шигырь һәм шагыйрь төшенчәләрен ул байтак еллар дәвамында традицион мәгънәләрендә аңламады һәм аны әдәбиятның гадәти бер жанры итеп кенә кабул итүчеләргә принципиаль төстә каршы чыкты. Әле Бөек Октябрь революциясеннән соң дөнья күргән «Әдәбият кануннары» хезмәтендә дә әлеге караш үзен сиздерә иде.

Шагыйрь, иң элек, зур талант булырга тиеш һәм гүзәл табигать кочагында, чәчәктән-чәчәккә кунып, матурлыкка хозурланып йөргән күбәләк, бал кортларын, сайрар кошларны хәтерләтергә тиеш аның уенча. Шигырь — чынбарлыкның кара һәм каршылыклы картиналарыннан югарырак торган идеаль матурлыкны тасвирларга тиешле дип саный. «Татар шагыйрьләре» һәм «Альбом» кебек, тәнкыйть хезмәтләре булудан бигрәк, әдәби-эстетик трактатка тартым җитди тәҗрибәләрендә бу аеруча ачык һәм эзлекле төстә чагылыш тапты. «Шагыйрь — әгәр дә ул чын мәгънәсе илә шагыйрь булса, шөбһәсез хиссият колы» булырга тиеш, зур талант җирдәге вак, гади тормыш белән генә канәгатьләнә алмый дип раслады ул яңадан кайтып-кайтып.

«Соң, шигырь нәрсә?», дип үз-үзенә сорау биргәч тә «Татар шагыйрьләре» хезмәтендә тәнкыйтьче болай дип җавап бирә: «Телдән, яки гакыл вә зиһеннән түгел, бәлки адәмнең рухыннан, күңеленнән, хыял вә хисеннән туа» шигырь.

Гомумән, әлеге сорау һәм аңарга җавап эзләү XX йөз башы татар әдәби тәнкыйтендә шактый әһәмиятле проблема булып тора. Шигъриятнең табигатен аңларга омтылган, шагыйрьләр иҗатына туры һәм объектив мөнәсәбәте булган күренекле тәнкыйтьче Җ. Вәлиди дә шул ук 1913 елда «Вакыт»та дөнья күргән бер мәкалә-

сендә үз-үзенә «Шигырь! Бу нәрсә?...— дигән сорау куеп, уйлана, җавап эзли: — Мәхәббәт тавышы түгелме?..» Әдәбият һәм сәнгатьтә материалистик эстетика кануннарын эзлекле яклап килүенә дә карамастан, Җ. Вәлиди шулай ук шагыйрьне — гүзәл сурәт ясаучы рәссамга тиңли. «Аны (шагыйрьләрне — Р. М.) һәрбер матурлык җәлеп итә. Ул беразга һәммә матурлыкны сөеп, һәр гөл каршысында сайрап ала (...) Бик күп шагыйрьләр фәкать шуның белән генә яшиләр. Хосусан, хөррият фикрия вә тәрәккыять гыльмия мәйдан алмаган җирләрдә мәхәббәт шигырьләре үзенең иң югары дәрәҗәсенә ирешә (...) Без бу хәлне шәрык-ислам әдәбиятында бик ачык күрәбез».

Әлбәттә, Г. Ибраһимовның шагыйрь һәм шигырь төшенчәләрен аңлатудагы берьяклылык күзгә ташланып тора. Ул сәнгатьтәге идеаль һәм субъектив башлангычларны романтик рухта аңлаудан гыйбарәт иде. Әмма, бер үк вакытта, әлеге мавыгуның сәбәпләре һәм табигате дә игътибарга лаек. XX йөз башы татар әдәбиятында, аеруча поэзиясендә, дидактизм, үгет-нәсихәт һәм натурализм традицияләре шактый киң таралыш тапкан иде. Мәгърифәтчелек реализмы рухында тәрбияләнгән укучыны сәнгатьчә матурлык төшенчәсенә йөз белән бору өчен шигырь тәнкыйтеннән ифрат дәрәҗәдә зур көч таләп ителгән еллар бу. Г. Ибраһимов әлеге ихтыяҗны рухы белән тоеп, заман укучысының әдәби-эстетик зәвыгын күтәрү кебек җаваплы эшкә җиң сызганып керешкән тәнкыйтьче. Кайбер каршылыклар һәм мавыгуларга юлыгуына да карамастан, бу елларда ул милли әдәби-эстетик фикер үсешенә әйтеп бетергесез зур өлеш кертте.

Гомумән, Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» әлегәчә әдәби тәнкыйтебез тарихында уникаль хезмәт булып кала бирә. Г. Тукай иҗатына бирелгән бәядәге принципиаль хаталарга да карамастан, бу тәнкыйди әсәр әле булса үзенең эстетик кыйммәтен югалтмаган. Менә күпме еллар инде бер тирәдә таптанып, буш әйләнеш биреп торган бүгенге тәнкыйтебезгә үрнәк булырдай сыйфатлар аңарда тулып тора. Критерийлар ачыклыгы, принципиальлек, турылык һәм кыюлык җәһәтләреннән булсын, әдәби әсәрләргә хас укылышы, композициясе һәм полемик рухы белән булсын, «Татар шагыйрьләре» — әдәби тәнкыйтебез тарихында тиңдәше булмаган җитди әсәр. Соң чиктә, хәтта үзенең хатасы белән дә әдәби тәнкыйть үсешенә зур этәреш, стимул ясаган хезмәт ул. Чөнки, Г. Тукай иҗатының халык күңелендәге һәм әдәбият тарихындагы урынын ул аз гына да төшермәде, киресенчә, моңарчы күрелмәгән зур полемикага сәбәпче булып, Тукай иҗатына гомум игътибар юнәлтте. Нәкъ менә Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» белән бәхәстә тулы бер буын тәнкыйтьчеләр чыныкты, әдәбият һәм тәнкыйтьнең үсеше өчен гаять әһәмиятле булган әдәби-эстетик проблемалар кузгатылды, өлешчә хәл ителде.

Тәнкыйтьче һәм әдип үзе дә 1915 елда «Йолдыз»ның 15 һәм 20 октябрь саннарында басылган «Актык сәлам» дигән мәкаләсендә бу уңайдан беркадәр ачыклык кертеп узуны кирәк таба: «Бу тәнкыйть,— дип язды ул,— үзенең әдәби кашында гомуми агымга иярмәве сәбәпле, бик күп «шау-шу» тудырды. Менә ничә ел инде ул һаман теллардән, каләмнәрдән төшми йөри... Мин аны, башка нәрсәдән бигрәк, Тукайның үзе өчен, һәрвакыт яхшы ягын сайрап торган матбугатка бер реакция тудыру, әдәби мөназара тудыру өчен язган идем. Тукайның вафаты белән минем өметемнең иң зур бер өлеше вөҗүдкә килмәде» (тормышка ашмады — Р. М.).

Чынлап та, Г. Тукай иҗаты хакында сүз кузгалды исә, ул елларда әдәби тәнкыйть югары бәя һәм матур эпитетларны кызганмый. Шагыйрь иҗаты хаклы рәвештә югары бәягә лаек табыла. Әмма шунысы аяныч: ул мәкаләләрнең күбесендәге югары бәяләр анализлар аша киленгән җитди бәя булудан ерак тора, ә нибарысы гомум атмосферага ияреп белдерелгән шәхси эмоциягә генә кайтып калалар. Тукай иҗатының көче белән әсәрләнү шул дәрәҗәдә була ки, әлегедәй чиккә ташланулардан — анализсыз бәя бирүләрдән — хәтта күренекле фикер ияләре һәм тәнкыйтьчеләр дә азат булмый. Берничә мисал: «...Газетага бер зиннәт биреп килмәктә улган (...) гүзәл шигырьләр» (Р. Фәхретдинев); «татар галәменең иң оста юмористы...» (Ф. Әмирхан); «Тукай — татарның җаны. Аны халык үзе бик күп төрле шагыйрьләребез арасыннан аерып, табып алды, аңар үземнең шагыйрем дип исем бирде» (Г. Кәрам). Берсүзсез хак бәя һәм урынлы сүзләр, әмма, тәнкыйди бәя булудан бигрәк, асылда эмоциягә корылган хөкем. Гәрчә бу авторларның чын мәгънәсендә принципиаль тәнкыйтьче икәнлекләрен һичкем инкарь итәргә алынмас.

Менә шул шартларда, һәм алай гынамы әле, очраклы рәвештә бөек шагыйрьнең вафаты көннәренә дә туры килеп, Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» дөнья күрә. Хезмәтнең беренче юллары ук сагаерга мәҗбүр итә: «Татар шагыйрьләре» дигәч тә, хәтеремә Сәгыйть Рәмиев килә,— дип сүз башлый тәнкыйтьче,— бу шагыйрьне «шигърият ягыннан караганда иң алгысы вә иң куәтлесе» санап. Хезмәтнең икенче бүлегендә Дәрдмәнд поэзиясенә югары бәя бирелә, аның татар шигърияте

тарихындагы кабатланмас урыны билгеләнә. Әлеге ике бүлеккә җентекле анализ ясап тормастан, шуны гына әйтәсе килә: татар поэзиясендә С. Рәмиев һәм Дәрдмәнд иҗатларының әһәмиятен чагылдыру, аларның әдәби осталыгын анализлап күрсәтү юлында «Татар шагыйрьләре» әлегәчә әдәби тәнкыйть тарихында тиңдәшсез үрнәк булып тора. С. Рәмиев һәм Дәрдмәнд иҗатларының шигъри осталык җәһәтеннән татар поэзиясе үсешенә керткән өлеше әйтеп бетергесез зур. Безгә Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре»ндә тәкъдим ителгән анализны кат-кат күңелдән кичерергә, өйрәнергә кирәк әле.

Шулай да, «Татар шагыйрьләре» хезмәтен никадәр генә югары бәяләмик, сүз Г. Тукай иҗатының татар поэзиясендәге урынын бәхәс иткән әсәр хакында баруын да оныту мөмкин түгел. Алай гынамы, «Тукаев шагыйрьме, түгелме?..» кебек сорауны кая куярга?.. С. Рәмиев һәм Дәрдмәнд иҗаты хакында сүз чыкканда, бу шагыйрьләрнең аеруча камил һәм күркәм әсәрләренә мөрәҗәгать итеп, Тукай шигъриятеннән мисалларны, нигездә, аның башлангыч чоры белән генә чикләүне ничек аңларга?.. Бу тенденциозлык түгелме?..

Түгел!.. Һәм ни өчен шулай фикер йөртүемнең кайбер сәбәпләре хакында инде югарыда сүз булган иде. «Татар шагыйрьләре»ндә тәнкыйтьче, гомумән, аерым шагыйрьләр иҗатын анализлауны төп бурычы күрми, ул — әдәби-эстетик трактат, автор үзе искәртеп узганча «бер тәҗрибә»дән гыйбарәт. Тәнкыйтьче һич кенә дә, кайберәүләр аңлаганча, С. Рәмиев белән Дәрдмәндне күккә чөю, яисә Г. Тукайны «юкка чыгару» бурычыннан торып эш итми. Өч татар шагыйренә ул талант һәм шигырь турында уйланулары, поэзиянең чынбарлыкка мөнәсәбәтен ачыклау юлында игътибарга лаек һәм гыйбрәтле дәлилләр кирәк булганга мөрәҗәгать итте дип санау дөресрәк булмасмы?! С. Рәмиев, Дәрдмәнд һәм Г. Тукай әсәрләреннән дә кулайрак нинди мисал табу мөмкин иде соң бу уңайдан?! Әлеге өч шагыйрь иҗатында, һәм нәкъ менә Г. Ибраһимов тәкъдим иткән тәртиптә, шәрыктән гарепкә таба үсеш юлында булган иҗтимагый аң, әдәби-эстетик фикер хәрәкәте ачык чагылыш тапты.

Ләкин, XX йөз башындагы әдәби җәмәгатьчелек бу хезмәтне берьяклырак аңлады. Мөгаен, ул аны башкача аңлый да алмагандыр. Чөнки ул, инде югарыда искәртелгәнчә, Тукайның вафаты киң массаларга аяз көндә яшен суккандай тәэсир иткән көннәрдә басылып чыга. Әлеге атмосфераны хәтерләп Җ. Вәлиди болай дип язды: «Мин, Тукай үлгәндә, «Вакыт»та (Оренбург каласында татар телендә чыгып килгән көндәлек орган — Р. М.) яза идем. «Вакыт» газетының ун елдан артык дәвамында һичбер мәсьәлә вә һичбер вакыйга мөнәсәбәте белән Тукай үлү мөнәсәбәте белән килгән кадәр мәкалә вә мәктүпләр килмәде. Килгән бер ящик мәкалә вә шигырьләр эчендә иң күбесе ярымграмотный авыл халкы вә эшчеләр тарафыннан язылган булып, һәркайсының соң дәрәҗә бер ихлас вә самимият белән язылганлыгы күренеп тора иде». Ул көннәрдә татар телендә чыгып килгән күп кенә башка вакытлы матбугат органнарында да шундый ук хәл була. Газеталар алынган телеграмма һәм хатларның озын-озын исемлекләрен китерәләр, дистәләгән мәкаләләрнең өзекләрен бастырып чыгаралар. Шагыйрь иҗатына һәркайсында идеаллаштыру югарылыгындагы бәяләр бирелә.

Мисал өчен, шуларның берничәсе.

«Рухы өлкән, каләме үткен булган шагыйребез Габдулла Тукаев...» (Чиләбе яшьләреннән килгән телеграммадан); «...Олуг шагыйрь — халкыбызның тормыш, шатлык һәм кайгыларының җырчысы» (Уфа яшьләреннән 33 кеше кул куйган телеграммадан); «Руслар Пушкиннары, инглизләр Байроннары белән ифтихар иткәндә, безгә дә Тукаебыз белән горурланырга юл ачылды...» (И. Габидинең «Сагыну» дип исемләнгән хатыннан»); «Әдәбият кояшыбыз сүнде, ләкин ул чәчеп калдырган нурлар һәрбер киләчәк нурлардан үзләренең яктылыклары белән өстен булачак...» (Оренбург шәкертләреннән хат); «Тукаевның сайрый торган көе башка булган кеби, милләтнең аны ишетә торган колагы, ләззәтләнеп сулкылдый торган йөрәге дә башка иде» (Х. Кәримов мәкаләсеннән); «...Йортыбызга нигез салып бирдең, җырчы! Татар синең җырларыңны мәңге җырлар, синеке булган өчен түгел, үзенеке булган өчен җырлар» (З. Ярмәки мәкаләсеннән) һәм башкалар.

Тәнкыйть «Татар шагыйрьләре»н, бертавыштан дип әйтерлек, Тукайга каршы юнәлдерелгән хезмәт дип кабул итте. Һәм Г. Ибраһимов белән полемикада Г. Тукай иҗатының гаять әһәмиятле үзенчәлекләре, казанышлары күрсәтелде. Характерлы берничә мисалга мөрәҗәгать итик.

Г. Кәрам: «...Бердәнбер шагыйребезне бәгъзе бер тәнкыйтьчеләр: — Тукаев шагыйрьме, түгелме? дип, аның шагыйрьлегеннән шөбһә итәләр вә аның кыймммәтен төшерергә азапланалар. Тукаев реклама аркасында, берәр интрига тәэсире илә генә шагыйрь булган кеше түгел, аны халык үзе бик күп төрле шагыйрьләнүчеләребез арасыннан аерып, табып алды, аңар үземнең шагыйрем, дип исем бирде... Ул халык рухын белә, халыкның эченнән сизеп тә, теле белән әйтә алмаган хисләрне, шул ук халыкның үз теле белән матур итеп, табигый итеп әйтеп бирә ала.

Моннан башка Тукаевның иң зур хасәсе заманның кидшатына вә фикер мәйданына карап каләм йөртә белүедер. Кирәк кем, кирәк ни язсын, Тукаев чын мәгънәсе белән шагыйрь һәм дә халык шагыйре булып калачактыр».

Н. Думави: «Хәлбуки, халыкның үз карашында Тукаев андый үлчәүләргә хәтта сыймаслык зурдыр. Бу ялгышу, бу хата кемдә? Мин уйлыйм Галимҗан әфәндедә. Чөнки ул Тукаевны гареп шагыйрьләренә карап, гареп аңы белән үлчәде»... (гарепкөнбатыш — Р. М.)

Ф. Әмирхан: «Тукаев — кайгы-хәсрәт баласы, моңнар шагыйре, авыр тойгылар, авыр мәшәкатьләр җырчысы иде. Ул шуларны җырлап үскән, шуларны җырлап торды, шуларны җырлый-җырлый вафат та итте...»

«Габәй»: «Галимҗан әфәнде (...) бәлки әдәбият бабында тирәнрәк чума ала торгандыр. Ләкин ул бераз хиссият тәэсире астындарак эш күргән кеби тоела».

Шулай да бу хезмәтнең күпчелек сәхифәләрендә очрап торган рациональ орлыкка, кызыклы күзәтү һәм әдәби-эстетик нәтиҗәләргә битарафлык күрсәтелде дип әйтү дә дөрес булмас. Мәсәлән, «Уйгур» псевдонимы астында язучы тәнкыйтьченең «Йолдыз»да басылган мәкаләсе үзенең җитдилеге белән игътибарны җәлеп итә. «Галимҗан әфәнде Сәгыйть белән Дәрдмәндне бөтенләй диярлек уң яктан тикшереп, аларның тискәре якларына бармаклар аша гына карап уза, әмма Тукаевка килгәч, эш башкарак. Тукаевны тәнкыйтьчә бик нык, җентекләп тикшерә...», дип яза ул. Һәм, Ибраһимовның үз критерийларыннан килеп, Дәрдмәнд һәм С. Рәмиев шигырьләрендәге кайбер җитешсезлекләргә игътибар юнәлтә. Әмма шул ук вакытта ул «Татар шагыйрьләре»нең төп кыйммәтен танудан тайчанмый: «Галимҗан әфәнденең бу әсәре чын тәнкыйть. Әдәбиятыбыз мондый тәнкыйтькә күптән мохтаҗ иде. ...Галимҗан әфәнденең тәнкыйть галәмендә алга таба бик зур адым атлаганын күрәбез»,— дип яза «Уйгур», гәрчә Ибраһимовның Тукай иҗатына бирелгән бәясе белән нигездә килешмәвенә дә карамастан.

1915 ел ахырларында, «Татар шагыйрьләре» хакындагы шау-шу ике елдан артык дәвам иткәннән соң бераз сүрелеп торган арада, Г. Ибраһимов шушы уңайдан «Йолдыз»да «Актык сәлам» исемле мәкалә белән чыга. Күп дистәләгән мәкалә һәм язмаларда белгертелгән канәгатьсезлек һәм тәнкыйть фикерләреннән ул бары Җ. Вәлиди тәнкыйтен генә игътибарга лаек таба. Соңгысының шулай ук «Татар шагыйрьләре» дип исемләнгән күләмле тәнкыйть мәкаләсе «Вакыт» газетасының 1913 ел, 24, 25, 26 июнь саннарында басылган. Җ. Вәлидинең оперативлыгын күрсәткән күпсанлы мисалларның берсе бу.

Г. Ибраһимовның бу мәкаләне игътибарга лаек табуы һич кенә дә Җ. Вәлидинең аның яклы булып фикер йөртүеннән түгел. Киресенчә, Җ. Вәлиди, Г. Тукай иҗатына аеруча игътибарлы һәм хөрмәтле тәнкыйтьче буларак, хөкемендә шулай ук аяусыз: «Тукаев шигырьне Аполлон вә аның җирдәге табынучылары өчен сөйләми иде. Ул халык илә бергә, халык өчен халык йөрәгеннән сөйли иде... Шуның өчен берничә дистә сәнгатьне сәнгать өчен дип белүчеләргә бервакытта да ул сәнам була алмас».

Хөкем аяусыз, әмма аңарда, күп кенә башка язмаларда күзгә бәрелеп торган гаеп ташлау, Г. Ибраһимовны тенденциозлыкта гаепләү юк. Җ. Вәлиди тәнкыйтьчеләр дөньясында шигырь һәм аның урынын өч төрле аңлау яшәгәнлеген күрсәтүдән башлый сүзен. Һәр өч төрнең шигъриятта булсын, әдәби тәнкыйтьтә булсын, үз тарафдарлары барлыгын искәртә. Г. Тукай шигърияте һәм Г. Ибраһимов тәнкыйте арасындагы килешмәүчәнлек һәм каршылыклар шигырьнең функцияләрен аңлауда Көнбатыш Европа һәм рус эстетикасында күптән мәгълүм булган әлеге аермалылык белән аңлатыла дигән нәтиҗә ясый Җ. Вәлиди. Һәм әлеге һәр өч төрнең дә яшәүгә хокуклы булуын мөмкин дип саный.

Г. Ибраһимовның шигъриятне аңлауда «өченче төркем» позициясен яклавы, Европа романтикларына якын торуын истән чыгару мөмкин түгел ди ул. «Боларча шигырь вә шагыйрьләр синең-минем фикердән, караштан югары торырга, дөньяның көнлек вагы-төягеннән өстен йөрергә тиеш. (...) Безнең рух вә хыялымызга тәэсир итәчәк, хиссиятемезне кузгатачак һәрбер нәрсә дип тәгъриф итәләр».

Җ. Вәлиди шигырьгә мондый мөнәсәбәтнең яшәү мөмкинлеген кире какмый, әмма үзенең башка позициядә торуын искәртә: «Шигырьдә исә сәнаигъ нәфисәнең башка төрләренә караган вакытта да фикер ачык вә аңлаешлы булырга тиеш»,— ди ул үзенең тормышчанлык һәм халыкчанлык тарафдары икәнлеген белгертеп.

Әгәр дә киң катлам укучылардан нинди шагыйрьләрне беләсез дип сорасалар, дип дәвам итә Җ. Вәлиди, «боларның күбрәге иң элек ошбу өч исемне әйтәчәкләренә күңел ышана: Габдулла Тукаев, Дәрдмәнд, Сәгыйть Рәмиев. Һәм боларны ошбу, без язган тәртип белән әйтерләр төсле тоела. Галимҗан әфәнде дә гомумияттән еракка китмәгән, үзенең «Татар шагыйрьләре» исемле яза башладыкы тәнкыйтенең хәзер басылып чыккан беренче җөзә (кисәге, бүлеге — Р. М.) өчен шул өч шагыйрьне

алган...» Искә алыну тәртипләре генә күпчелек фикеренә капма-каршы чыккан,ди. Һәм шунда ук янә бер кабат моның һичнинди шәхси мөнәсәбәт түгел, ә тәнкыйтьченең шигырьне кабул итүдәге үзгәлегеннән килгән күренеш дип аңлата. Чөнки «ул шигырьне махсус вә мөстәкыйль бер сәнгать итеп таный», аныңча шигырь нәфислек һәм гүзәллекнең шундый идеаль бөеклеге һәм балкуыдыр ки, аның каршында кеше хөрмәт һәм мәхәббәт йөзеннән тез чүгә.

Җ. Вәлидинең «Татар шагыйрьләре» белән полемикасы XX йөз башы татар әдәби тәнкыйтенең идея җәһәтеннән булсын, эстетика җәһәтеннән булсын биеклеген билгеле торган гыйбрәтле үрнәк. Татар әдәби тәнкыйтенең Бөек Октябрьгә кадәрге чорда ук мондый югарылыкка күтәрелүе милли әдәби-эстетик фикернең зур казанышы булды.

Г. Ибраһимовның С. Рәмиев һәм Дәрдмәнд иҗатларына ясаган анализының әдәби-эстетик һәм тарихи әһәмияте хакында инде искәртелгән иде. Җ. Вәлиди исә әлеге кыйммәтле башлангычны тагы да дәвам гына итте. Аның һәр өч шагыйрьнең иҗатларына бирелгән объектив бәясе шулай ук әле дә әһәмиятен җуймаган. Янә тәнкыйтьченең үзенә сүз бирик: «...Дәрдмәндне ул бакчадагы үзенең гаҗәеп исе, нәфис сабагы, янып торган ал, кызыл йөзе илә мөмтаз булган бер чәчәккә охшата (...). Мин Галимҗан әфәнденең язганнарына кушылам вә Дәрдмәндне мөмтаз шагыйребез дип беләм. Ләкин, тәнкыйтьче әфәнденең тасвир итдеке бакчада теге гаҗәеп исле, нәфис сабаклы, мөмтаз чәчәкнең дәрәҗәсе мөһим вә кыйммәтле булса, аңа караганда күп калын вә тупас булган имәннәр, карамалар да үз урыннарында кыйммәтле вә мөһимдерләр».

Нәкъ менә шул сыйфатлары — житди хезмәткә принципиаль критерийлардан чыгып килгәнлеге өчен дә, никадәрле генә ачы тәнкыйть булуына да карамастан, Г. Ибраһимов Җ. Вәлидинең әлеге хезмәтенә лаеклы бәя бирә. Шигырь һәм шагыйрьләрне аңлауда капма-каршы позициядә торган тәнкыйтьчеләр үзара полемикада бәхәсләшә, фикер алыша, дөреслекне эзли, әмма бер-беренә шәхси үпкә ташламыйлар. Игътибарга лаек факт!

Югарыда язылганнарга өстәп, тагы ни әйтә, Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре»ндә шәхси мөнәсәбәтләрдән өстен булуын аңларга теләмәүчеләргә тагы нинди дәлил һәм аргументлар китерә алабыз соң?..

1914 нче елның башында Г. Ибраһимов «Әхмәт Мидхәт әфәнде» дигән баш астында мәкалә язып чыга. Анда сүз төрек мәгърифәтче язучысы турында бара. Ә. Мидхәт әсәрләренең дә гавам арасында киң таралуын, яратып укылуын Г. Ибраһимов аларның халыкчанлыгы белән аңлата. Һәм шунда ук Ә. Мидхәт иҗатына югары бәя биргән Р. Фәхретдинев белән полемикага кереп, аларның сәнгать ноктасыннан чыгып караганда дәрәҗәсе бик чамалы булуын күрсәтә. «Әхмәт Мидхәт әфәнде әсәрләрендә садәлек, гавам тарафдары иде (...). Сәнгать ноктаи назарыннан бер кыйммәтне хаиз булмыйлар» (сәнгатьлелек күзлегеннән кыйммәткә ия түгелләр — Р. М.).

Әлбәттә, үзләренең заман, халык тормышына мөнәсәбәте ягыннан әлеге төрек мәгърифәтчесе әсәрләрен Г. Тукай поэзиясе белән янәшә кую дөрес тә булмас. Шуңарга да карамастан, Ә. Мидхәт төрек әдәбиятында үз вакытында шулай ук зур хөрмәт казанган, күренекле фигура була. Халык теленә, аның авыз иҗатына мөнәсәбәте белән дә төрек әдибенең Тукайга якынлыгы зур. Шулай да хикмәт әлеге уртаклыкта түгел. Г. Ибраһимовның һәр ике авторның иҗатын бәяләүгә бер үк критерийлардан килеп хөкем йөртүендә. Бу очракта да «Татар шагыйрьләре»ндә куелган әдәби-эстетик таләпләр күзгә бәрелеп тора. Ә инде Г. Ибраһимов белән төрек язучысы Ә. Мидхәт арасында нинди дә булса шәхси мөнәсәбәтләр булган дип әйтергә берәүнең дә теле бармас.

Гомумән, Г. Ибраһимов кебек туры сүзле, кыю һәм принципиаль тәнкыйтьчене, шәхси мөнәсәбәтләрдән чыгып кына, үзенең эстетик принципларына хыянәт итте дип уйлау һичнинди рамкаларга сыймый. Киресенчә, үзе белән якын, дустанә мөнәсәбәттә булган кайбер авторлар иҗаты хакында сүз чыкканда, аның бернигә дә карамастан, принципиаль анализ ясап, йомшак әсәрләрнең тетмәсен тетү очраклары бер генә түгел. Бу хакта ул 1914 елда басылган тәнкыйть хезмәтләренең берсендә бик ачык һәм аңлаешлы итеп әйтеп уза: «Әсәрнең әдәби мәртәбәсе, ияләренең шөһрәте белән үлчәнә торган булса, без аңа кушыла алмыйбыз. Әсәрне исем белән үлчәү бу гавам эше, (...) зәвыктан мәхрүмнәр эше». Замандашларына гына түгел, безнең көннәргә дә адресланган, әдәби әсәрләр турында хөкем йөртергә алынган һәр автор, бар тәнкыйтьче бүген дә хәтердә тотарга тиешле сүзләр!..

Г. Тукай иҗатына килсәк, аның реалистик поэзиясен, ачы социаль сатирасын һәм халыкчанлыгын кабул итмичә, иҗади үсешен һәм татар поэзиясе үсешендә тоткан урынын бәяләп җиткермәүче тәнкыйтьчеләр Г. Ибраһимовтан тыш та булмады түгелләр. Мәсәлән, шагыйрьнең зур талантын, гомумән, иң әлек булып күр-

сәтеп, «...милли шагыйрьләремезнең дәһиларыннан улачагына өмид итәбез» дип чыккан (1906 елда ук) Р. Фәхретдинев та соңрак, Г. Тукайның иҗтимагый тормыш мәсьәләләрен күтәргән реалистик шигырьләрен аңлый алмады, аларның әһәмиятен цик астына куйды. «Габдулла әфәндедә бик яхшы истигъдат вә гүзәл шигырьләр сөйләргә әсаслы бер икътидар (куәт, сәләт — Р. М.) барлыгы мәгълүм иде, ләкин лазем дәрәҗәдә «тәрбия» ителмәгәнлектән һәм дә мәхәббәт дөньясы берлә галәкасе булмадыгыдан, зар вә моңнар берлә мөнәсәбәт хасил итмәдегеннән гали матлабка (теләнелгән, омтылган нәрсә — Р. М.) бара торган чагында башка урынга борылып җибәрелдегеннән өмет кылган нәтиҗәләр чыкмады. (...) Безнең беренче дәрәҗәдәге шагыйрьләремез башкалардыр».

Классик Көнчыгыш поэзиясе рухында тәрбияләнгән һәм шул шигъри традицияләрнең аяусыз пропагандисты булган фикер иясе сүзләре иде бу. Р. Фәхретдиневтә Тукайга аерым бер хөрмәт һәм элек-электән килгән симпатия булуга да карамастан әйтелгән фикер!

Бу уңайдан да әдәби тәнкыйтьтә ачыклык кертеп узучы Җ. Вәлиди була: «Шәрыкчеләр... болар инде Тукайга бөтенләй икенче яктан карап бәйләнәләр. Моның бездә иң зурысы Риза казыйдыр. Ул шигырьне хикмәтле сүзләр, мәсәлләр, афоризмнар мәгънәсендә аңлый, Тукаевта шулар юк, ди». Р. Фәхретдинев белән полемикага кереп, ул Тукайда хикмәтле сүзләрнең дә шактый киң урын алуын искәртә һәм алар астына күп кенә Көнчыгыш классиклары хәтта үз кулларын куярга риза булыр иде дигән нәтиҗәгә килә.

Шигъриятта шәрык поэзиясенең идеаль башлангычларын һәм романтикасын үзенә өлге итеп алган Н. Думавиның да Г. Тукай иҗатына мөнәсәбәте каршылыклы булды. «Чын үзебезнең шагыйребез Тукаев, белмим, бер улчәүченең куәтеннән куркыпмы, баштарак язган шәркыйләрен югалтты. Лермонтов, Пушкиннар аша Байрон школасына кереп китә язды. Әгәр шәркыйлеген дәвам итсә, зур шагыйрь булырлык барып чыккан бер шәрык кабилияте (сәләте) иде»,— дип язды ул 1915 елны «Йолдыз»да басылган мәкаләсендә. Игътибар белән укысак, монда «бер үлчәүченең куәтеннән куркыпмы» кебек гыйбарәне күрми узу мөмкин түгел. Сүз Г. Ибраһимов тәнкыйте хакында. Әйе, Н. Думави һәм Р. Фәхретдиневләр Г. Тукайны саф шәрык шагыйре итеп күрергә теләгәндә, Г. Ибраһимов аның иҗатына Европа һәм рус романтиклары эстетикасы критерийларыннан чыгып таләпләр куйды. Чынбарлык һәм үз халкының рухы җырчысы булган Тукайны шул рәвешле һәр ике яклап тарткалау, йолыккалауга охшаш күренеш иде бу. Һәр ике як үзләренең шигырь һәм шагыйрь төшенчәләрен аңлаудагы идеалларына туры килгән зат итеп күрәселәре килде Тукайны. Әмма шагыйрь аларның бу өметен акламады.

Соңрак Н. Думави үзенең югарыдагы фикерен тагын да конкретлаштыра төште. «Аның әвәл язган шигырьләре — чын шигырь идеәр. Чөнки (...) рамкасыз уйлый, үлчәүсез тәэсир итә иде, хыялындагы мәгънәләр белән шаяра, әллә кемләргә әллә нинди искиткеч мәхәббәтләр гарыз кыла, бу мәхәббәтләр бөтен бер шигъри гармония булып дөньяга чыга иде»,— дип тә язды ул. Ачынып язды, әдәбиятның чынбарлыкка мөнәсәбәтен аңлату юлында Тукай иҗатының үзенә юлдаш һәм кулай дәлил була алмавына ачынды. Ә бит Тукай шигърияте мисалында үзенең эстетик тәҗрибәләренә дәлил табу берәүгә дә зыян итмәгән булыр иде. Әлеге принципиаль бәхәсләрнең очы әнә кая барып тоташа...

Ә инде Н. Думавиның Тукай иҗаты хакындагы хөкемен җавапсыз калдырмыйк дибез икән, янә Җ. Вәлидигә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булабыз. «Нәҗип әфәнденең Тукай хакындагы сүзләренә ни дип әйтергә? — дигән сорау куя ул үз-үзенә «Шәрыктән — гарепкә» дип исемләнгән хезмәтендә.— Тукаевның шәрекъ тәэсирендә чыгып гареп тәэсиренә бирелүендә бер дә ис китәрлек эш юк. Ул башта шигырь намына фәкать төрек диваннарын гына күрә вә аларга тәкълид (иярә) итә иде. Соңра рус әдәбиятын аңлап гареп тәэсиренә бирелде. Бу — бер Тукаевта гына түгел, безнең бөтен язучыларыбызга гомуми булган бер хәл. Безнең соңгы 10—15 еллык бөтен тарихыбыз шул шәрык тәэсиреннән гареп тәэсиренә авышудан гыйбарәттер. Моннан Тукаев кына ничек аерылып калсын...»

XX йөз башында татар әдәбияты, тизләтелгән үсеш юлы узып, санаулы гына еллар эчендә кискен борылыш һәм яңарыш кичерде. Мондый шартларда татар тәнкыйте һәм әдәби-эстетик фикере үз кабыгына гына төренеп, милли рамкалар белән генә чикләнеп кала алмый иде. Табигый рәвештә, дөнья әдәбиятларының идея-эстетик байлыгын һәм прогрессив традицияләрен өйрәнү, үзләштерү зарурлыгы көн тәртибенә килеп басты. Кайбер тәнкыйтьчеләр һәм фикер ияләре Көнчыгыш (шәрык) һәм Көнбатыш (гареп) әдәбиятларын бер-берено каршы куеп, аларның я берсен, я икенчесен генә кабул итәргә мөмкин дигән фикерне яклады лар. Шушы нигездә байтак кына бәхәс һәм полемикалар булып узды. Г. Тукай иҗаты тирәсендә барган кызу бәхәсләрдә дә чагылып-чагылып алды әлеге эстетик каршылыклар.

Шулай да дөнья әдәбияты классикларының һәм бигрәк тә рус реалистик әдәбиятының традицияләрен һәм әдәби-эстетик фикерләрен кабул итүгә зур әһәмият биргән Г. Ибраһимов әлеге бәхәсләрдән, нигездә, югары торды. Югарыда күздән кичерелгән каршылыклар аның шигырь һәм шагыйрь төшенчәләрен әдәбияттан аерып, илаһи бер мәгънә салып, романтикларга хас идеаллаштырып аңлавыннан килә иде. Ә хакыйкатьтә ул үзенең «Киләчәк көнебезнең яктыруы өчен Гареп әдәбияты белән файдалануыбыз никадәрле лязим булса, шул нисбәттә үк, безгә Шәрекънең үткәне белән дә танышырга, Шәрык даһиларының хикмәт вә шигырьләре белән дә азыкланырга тиеш», дигән сүзләреннән кире кайтмады.

Әлбәттә, бу мәкаләдә Г. Ибраһимов тәнкыйтенең эстетик эзләнүләр чорындагы кайбер каршылыкларына гына игътибар юнәлтелде. Әмма болар һич кенә дә аның әдәби тәнкыйть һәм эстетик фикеребез формалашу чорындагы әйтеп бетергесез зур һәм киң масштаблы хезмәтләренең ролен киметми. Г. Ибраһимов хезмәтләре татар әдәби тәнкыйтенең формалашу чорында хәлиткеч әһәмияткә ия булдылар. Бу исә аның замандашлары тарафыннан да югары бәяләнде. Таләпчән замандашлары аны еш кына «Әдәбиятыбызның бердәнбер тәнкыйтьчесе» дип искә алдылар. Аның туры сүзле, принципиаль шәхес, тирән анализ остасы булуы матбугат битләрендә кабат-кабат билгеләнеп үтелә. Аңарга хәтта, язучылыгын ташлап, бары тик тәнкыйть эшчәнлеге белән генә шөгыльләнергә киңәш итүчеләр дә була. Бәхәссез ки, болар һәркайсы — Г. Ибраһимовның әдәби тәнкыйтебез тарихында кабатланмас бер урын тотуы турында сөйли торган фактлар.

Г. Ибраһимовның Бөек Октябрьга кадәрге актив тәнкыйть эшчәнлеге нибарысы алты ел вакытны үз эченә ала. Ләкин бу эшчәнлек үзенең колачы, иҗтимагый активлыгы һәм фикер тирәнлеге белән хәйран калдыра. XX йөз башы татар әдәбияты өчен әһәмияткә ия булып та, Г. Ибраһимов тәнкыйтендә чагылмый калган мәсьәләләр, мөгаен, юктыр. Чөнки ул бөтен бер әдәбият язмышы өчен үзен җаваплы хис иткән олы җанлы, югары зәвыклы принципиаль тәнкыйтьче. Шуңа күрә аның тәнкыйте конкрет заман рамкалары белән генә чикләнми, ул яклаган әдәби-эстетик карашларның төп өлеше бүген дә үзләренең әһәмиятен һәм актуальлеген югалтмый. Бу мирас, әдәби тәнкыйтебезнең үзәк тамыры буларак, яшәвендә дәвам итә. Г. Тукай һәм Г. Ибраһимовлар мирасы янәшә һәм алар киләчәккә атлый. Г. Ибраһимовны Г. Тукай иҗатына мөнәсәбәттә тенденциозлыкта гаепләү, аңлашылса кирәк, урынсыз. Кайчандыр һәм кемнәрнеңдер беркадәр хискә, эмоциягә бирелүе нәтиҗәсендә ашыгычлык белән чыгарылган мондый бәя, хөкемне, соңарып булса да, онытуы хәерле. Тарихи хакыйкать шуны таләп итә.

---

*Галимҗан Ибраһимов иҗаты гомуми пролетариат әдәбияты фондына әһәмиятле өлеш булып керде. Андый кешеләр безнең арада күп түгел.*

М. ГОРЬКИЙ.

*Әсәрләренең әһәмияте үз илендә генә калмыйча, еракларга китә торган сәнгатьчеләр була. Галимҗан да шундыйларның берсе. Ул кешелек дөньясындагы иң яхшы шагыйрьләр арасына күкрәк киереп керә ала... Ул — матурлык җырчысы.*

Профессор П. С. КОГАН.

---

*Төрки язучы-реалистлары арасында Галимҗан Ибраһимов гаять күренекле урын тота. Аның йөзендә татар прозасы хәзерге заман совет әдәбиятына сизелерлек өлеш кертте. Г. Ибраһимовтан җитди тормышны җитди өйрәнергә мөмкин.*

ЧЫҢГЫЗ АЙТМАТОВ,
кыргыз язучысы,
Ленин премиясе лауреаты.

**Шәмси Хамматов,**
тарих фәннәре кандидаты

# Г. ИБРАҺИМОВ ҺӘМ М. ҖӘЛИЛ

*Г. Ибраһимов — татар әдәбияты тарихында зур фигура.*

М. Җәлил.

Муса Җәлилнең музей-квартирасында минем игътибарны бер китап җәлеп итте (Галимҗан Ибраһимов. Пролетариат әдәбияты турында. «Нәшрият» кооперативы нәшре. 1924, М. 62 б.). Битләрен актарам. Минем күземә иң әүвәл матур итеп, гарәп хәрефләре белән китапның эчке тышлыгына күренекле әдип Галимҗан Ибраһимов язган сүзләр чагылды. Ул сүзләрне дулкынланып укыйм: «Яшь шагыйрь Муса Җәлил иптәшкә ядкарь итәм. Галимҗан Ибраһимов. 1925. Февраль».

М. Җәлилнең 1922—1925 елларда Казанда «язучылар белән күрешә», аралаша башлавы, Г. Ибраһимов, Ф. Бурнаш шикелле җәмәгать эшлеклеләре белән очрашуы аның иҗатында кискен борылыш тудыра. «1924 елда мин бөтенләй икенче рухтагы шигырьләр яза башладым. Революцион көрәш, эшчеләр тормышы, завод-фабрикалар, яңа авыл темалары миндә реаль төстә чагылдылар,»— дип язды М. Җәлил. (Муса Җәлил. Әсәрләр. Дүрт томда. 3 т. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1976, 451 б.)

М. Җәлил китапханәсендә сакланган «Пролетариат әдәбияты турында»гы әлеге әсәрендә Г. Ибраһимов яшь әдипләр арасында тарала башлаган «элекке шигырь калыпларына каршы ачык сугыш игълан кыйлынды», «композиция мәсьәләсен, шигырьне сөйләү рәвешенә тарту мәсьәләсен кузгаттылар»,— дип әйтә. «Яшь шагыйрьләребез эчендә форма үзгәртүне тагы да киңрәк куярга теләү тәҗрибәләре булды,— дип яза Г. Ибраһимов.— Футуризм, символизм, имажинизм хәрәкәтләре менә шуның бер мисаллары иде». Аннары ул «яшь көчләребез форманы китаптан яки үзләренең миләреннән эзләмәсеннәр, бунын өчен массаның үзәгендә булсыннар, нинди калыпка салганда яхшы булачагын шунда өйрәнсеннәр!— һәммәбез шунда өйрәник, шуннан «илһамланыйк!»— дип киңәш итә.

Муса Җәлил, үзенең остазлары Г. Тукай, Г. Ибраһимов һәм Ф. Бурнаш йогынтысында иҗат итеп, формаль эзләнүләр юнәлешеннән бармый. Шагыйрь моны гаепләп, соңга таба, 1931 елны «Ударниклар» журналында басылган бер мәкаләсендә ул «чорда футуризмнан башка әдәбият юк» дип лаф орып, «Сулф» айгырлары кешнәп чыктылар. Бөтен залларны яңгыратып, диспутлар ачып, башка язучыларга ук атып, футуризмга гегемонлык алырга теләделәр» дип язды (Муса Җәлил. Әсәрләр. Дүрт томда. 3 т., 30 б.).

Шул рәвешле, Казанда «Татарстан» газетасы редакциясендә эшләү, Татар рабфагында уку (1922—1925 еллар), күренекле язучылар, публицистлар, бигрәк тә Галимҗан Ибраһимов, Фәтхи Бурнаш кебек дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре белән якыннан аралашу, киңәшләр алу, матбугатта басылган әдәбият тарихына, проблемаларына караган материаллар белән танышып бару, Муса Җәлилнең әдәбият, культура дөньясына карашын киңәйтә, иҗат мөмкинлекләрен ачып җибәрә.

М. Җәлил белән бергә укыган, анда комсомол ячейкасы секретаре, ә соңыннан Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре булып эшләгән З. И. Муратов Мусаның әдәби түгәрәк оештыруын, аңа җитәкчелек итүен, анда татар әдәбияты классиклары әсәрләрен укуларын, М. Горькийның «Ана», В. Маяковскийның «Владимир Ильич Ленин» әсәрләрен өйрәнүләрен искә төшерә («Советская Татария», 1986, 13 август)

Муса Җәлил Г. Ибраһимовның яңа пролетариат поэзиясе турында җәмәгатьчелек алдында сөйләгән лекцияләрен тыңлаган, аның «Тирән тамырлар», «Кызыл чәчәкләр» әсәрләрен укыган. З. И. Муратов түгәрәктә Г. Тукай иҗатын тикшерүгә игътибар аеруча зур булды, матбугатта халык шагыйре турында басылган Г. Ибраһимов белән Ф. Бурнаш мәкаләләре әдәбият түгәрәге членнары арасында кызу бәхәсләр тудыра торган иде дип сөйләде.

Мәскәүдә эшләгән елларда да М. Җәлил Татарстан матбугаты, «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясе, әдипләр, культура эшлеклеләре һәм Галимҗан Ибраһимов белән бәйләнешын өзми.

Без 1986 елның октябрь аенда Г. Ибраһимовның тормыш иптәше Гөлсем апа Мөхәммәдова белән очраштык. Ул хәзер Казанда яши.

Гөлсем Даутовна: «Г. Ибраһимов яшь көчләрне тәрбияләү эшенә бик зур әһәмият бирә, аларга ярдәм итә, хатлар яза, әсәрләрен укый, хаталарын төзәтә, кирәк җирдә аталарча шелтәли, уңышлары өчен шатлана иде. Муса Җәлилнең иҗатташ иптәшләре — Һади Такташ, Кави Нәҗми, Гомәр Гали, Гомәр Толымбайский кебек үсеп килгән яшь язучылар безнең өйгә — Галимҗан янына бик еш киләләр иде»,— дип сөйли.

«1929 елны тугандаш республикаларга сәяхәткә чыккан бер төркем татар язучылары, культура эшлеклеләре,— дип дәвам итә аннары Гөлсем апа,— Галимҗанны күреп сөйләшү өчен Кавказдан Ялтага килгәннәр иде. Алар арасында Ш. Камал, К. Тинчурин, Г. Кутуй, К. Нәҗми, М. Әмир, С. Әдһәмова, Г. Иделле, С. Сәйдәшев һ. б. бар иде. Аның янына илебезнең төрле төбәгеннән — Татарстаннан, Башкортстаннан, Кырымнан, Мәскәүдән, илебезнең башка урыннарыннан татар, башкорт, рус һәм төрле милләт әдипләре, аны ихтирам итүчеләр хәлен белергә, киңәшергә килеп торалар иде... Хәтеремдә нык сакланган: 1928 елның көзендә Ялтага, Галимҗан Ибраһимов торган йортка, ике яшь егет — Муса Җәлил һәм удмурт шагыйре Аркадий Клабуков килгән иде. Мәскәү университеты студентлары буларак, путевка белән алар Севастопольгә ял йортына килгән булганнар. Яшүсмерләр Галимҗан абыйлары белән бик озак сөйләшеп утырдылар».

Муса Җәлилнең Ялтада Г. Ибраһимов янында булуы турында аның иң якын дусты, каләмдәше Мәхмүт Максуд, үз истәлекләрен язып, матбугатта бастырган. Мәхмүт Максуд үзе дә 1928 елның җәендә Ш. Камал, Ш. Госманов белән бергәләп Г. Ибраһимов янында була. Сүзне М. Максудка бирик:

«1928 ел иде, көз көне Муса Кырымнан кайтып килде, — дип яза М. Максуд.— Ул Севастопольдән Ялтага хәтле (80 километрны) үз адымнары белән санаган.

Мусаның Кырым сәяхәтеннән алып кайткан тойгылары арасында Кырымның үзенә дә, диңгезенә дә турыдан-туры һич тә бәйләнмәгән көчле бер тойгы бар иде, менә шул минем дә хәтер сандыгында сакланган.

Ялтага барып җиткәч, Муса, ни сәбәптәндер, беренче эше итеп диңгезгә дә чуммый, өс-башын да алыштырып тормый, туп-туры Галимҗан ага Ибраһимов квартирасына юнәлә, диңгездән читтәрәк тауга таба үрмәләгән тар урамнарның үзенә кирәклесен эзләп таба. Яшь туристны авыру өлкән мастер якты чырай белән каршы ала, үзенең иң яраткан энесе килгән шикелле шатлана...

Муса, онытылмый торган бер истәлек итеп, шуларның барысын да миңа сөйләде.

— Я, үзең уйлап кара инде,— ди ул,— мин кем аның каршында. Бер малай бит! Ә шундый хөрмәт, шундый кайгыртучанлык! Бик уңайсыз булды булуын, ә шулай да җаным рәхәтләнде. Көч җыйдым мин анда...

Үзенең яшь каләмдәшен карт мастер иң самими, Мусаны да таң калдырырлык бер самимилек белән каршы ала. Табын янында ике иптәш арасындагы әңгәмә, авыру Галимҗан аганың һәрвакыттагы гадәтенчә, бик җитди әдәби мәсьәләләр турында бара һәм өзлексез агыла» (Мәхмүд Максуд. Сагынган минутларда (Муса Җәлил турында истәлекләр һәм уйланулар). Казан, 1963, 20—23 бб.).

Г. Ибраһимов 1930 елны Татарстан АССР төзелүгә ун ел тулу уңае белән «Ерактан сәлам» дигән мәкаләсен төгәлли. Ул анда: «Яшьләр тормышыннан, иң соңгы яшь буынның пролетариат революциясе казанында кайнап, алдагы зур сугышларга хәзерләнүләрен, чыгуларын үзенең пьесасында чагылдырган яшь каләм Минскийлар, мәскәүле Муса Җәлилләр... тагы башка әллә ничаклы яңадан-яңа исемнәр, көчләр, талантлар үсеп чыга торалар... Татарстан җөмһүрияте һәм башка туфракларындагы татар әдәби иҗаты да тик менә шул гомуми пролетариат революциясенең масса хәрәкәте һәм Коммунистлар партиясенең тугры юлбашчылык тәэсире генә мондый зур иҗади кайнашны күрергә насыйп итте»,— дип яза (Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. 5 т., 503—504 бб.).

«Мәскәүле Муса Җәлилләр» кебек яңа талантларның үсеп чыгуын күреп шатлана әдәбиятыбызның күренекле вәкиле, өлкән коммунист Галимҗан Ибраһимов. Шатланырлыгы да булган шул!

Максим Горький традицияләрен дәвам иттереп, А. Фадеев һәм Э. Багрицкий редакциясендә, М. Җәлил катнашы белән 1930 елны Мәскәүдә рус телендә «Татар әдәбияты альманахы» басылып чыга.

Альманахта О. Тархановның «Хәзерге татар әдәбияты турында» зур гына мәкаләсе бирелгән. Анда татар әдәбиятының Октябрь революциясенә кадәрге һәм совет чорына кыскача күзәтү ясала, шактый әдипләр иҗатына, шул исәптән Галимҗан Ибраһимов иҗатына да, характеристика бирелә. «Г. Ибраһимов — татар халкының иң зур художнигы», «иң кызыклы колоритлы фигурасы», аның иҗаты революциягә хәтле дә бик куәтле демократик тенденцияләр белән нык сугарылган иде»,— дип яза автор мәшһүр әдип турында (Альманах татарской литературы. М., 1930, 3 б.).

Г. Ибраһимов «Татар әдәбияты альманахы» белән танышкач, бер хатында үз карашын белдереп болай ди: «... русча Мәскәүдә, АПП, Фадеев карамагында басылган «Алманах татарской литературы»ның мәҗмугасында Тарханов тарафыннан язылган сүз башында, тагын Казанда Татарстанның ун еллык бәйрәменә чыгарылган әдәби альманахның ахырында, библиография бүлегендә бераз исемлек бар. Боларда төрле фикер, төрле караш үткәрелә. Мин үз турымда булган ул әдәби анализларның кыйммәтенә керешмим, шулай ук күп әсәрләремдә чәчелгән күп типларымны тикшереп торырга да... мондый хатта мөмкин түгел». Аннары Г. Ибраһимов хатында реализм үзе өчен төп лозунг булуын әйтеп: «Ансыз әдәбият та юк, әдәби сәнгать тә юк... мин үземнең бөтен әдәби иҗат юлыма ул формуланы маякларның берсе, ерактан күренә торган итеп куйганмын» (Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр. Сигез томда. 5 т., 1978, 521—522 бб.).

Шулай итеп, МАППның татар язучылар секциясе секретаре Муса Җәлил, А. Фадеев белән бергәләп альманах-җыентык чыгарып, Галимҗан Ибраһимов һ. б. язучыларның иҗатын рус телендә пропагандалады.

ВКП(б) Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать оешмаларын үзгәртеп кору турында»гы карарына бер ел тулу уңае белән М. Җәлил редакциясендә 1933 елны Мәскәүдә рус телендә «Хәзерге татар әдәбияты» исемле җыентык басылып чыга. Ул революциягә хәтле һәм Октябрь социалистик революциясеннән соң совет әдәбияты позицияләрен ныгытуга шактый зур өлеш керткән кайбер әдипләргә кыскача характеристика бирә. «Г. Ибраһимов,— дип яза М. Җәлил,— татар әдәбияты тарихында иң зур фигура. Ул революциягә кадәр берничә роман, хикәяләр язды. Аларда ул күп очракта шәһәр интелегенциясе һәм татар авылы тормышын чагылдырды. Үзенең әсәрләрендә ул капиталистик хуҗалык системасында каршылыкларның көчәю шартларында вак буржуаз интеллигенциясе рухын гәүдәләндерде. Ибраһимов авылны төсле бизәкләрдә сурәтләде».

Галимҗан Ибраһимов «Октябрьдан соң 1905 ел революциясенә багышланган «Безнең көннәр» романын (зур трилогиянең беренче кисәген), Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы турында «Кызыл чәчәкләр», казахлар тормышын чагылдырган «Казакъ кызы» повестьларын һәм «Тирән тамырлар» романын язды. Ибраһимов соңгы әсәрендә пролетар реализмы позициясенә бик нык басканын күрсәтте».

Галимҗан Ибраһимов белән Муса Җәлилнең яңадан күрешүләре, әдәбиятыбыз турында фикер уртаклашулары Казанда, 1933 елның көзендә була. Республикабыз башкаласында 1933 елның сентябрь ахырында колхозчы-ударникларның икенче Бөтентатарстан съезды ачыла. Съезд эшендә М. И. Ульянова (В. И. Ленинның сеңлесе) катнаша. Съездга партия өлкә комитеты, Татарстан хөкүмәте һәм Татарстан язучылар союзын Оештыру комитеты тарафыннан Галимҗан Ибраһимов та чакырыла.

Галимҗан Ибраһимов, колхозчы-ударникларның икенче Бөтентатарстан съездына катнашу өчен, Казанга юнәлә. Ләкин ул башта Мәскәүдә туктала. Шунлыктан съезд утырышына соңга калып килә. Аның хөрмәтенә 1933 елның 29 сентябрендә Мәскәүдә «Коммунист» редакциясендә язучы, журналистлар белән очрашу кичәсе үткәрелә. Газетада бирелгән отчеттан күренгәнчә, Г. Ибраһимов очрашуда язучыларның Беренче Бөтенсоюз съездына әзерлек, рус язучылары белән аралашу, А. Фадеев җитәкчелегендә төзелгән комиссиядә катнашу, социалистик реализм методын куллану, яшь язучылар белән эшләү кебек җитди мәсьәләләрне күтәрә.

«Очрашу кичәсенә,— диелә отчетта,— Мәскәү татар язучылары, журналистлар, хәбәрчеләр һәм берникадәр татар эшчеләр активы җыелган иде. Г. Ибраһимов үзенең кыска гына речендә татар совет язучылары алдында торган конкрет бурычларны санап үтә.

«Хәзерге иң мөһим мәсьәлә,— ди иптәш Ибраһимов,— совет язучыларының беренче Бөтенсоюз съездына хәзерләнү. Бу эшкә бөтен язучылар, бигрәк тә коммунист язучылар бик нык катнашырга тиешләр. Съездның көн тәртибенә бик күп, бик мөһим мәсьәләләр куелды. Шул җөмләдән татар әдәбияты турындагы докладны күрсәтеп үтәргә була. Тик татар язучылары үзләре, үзләрен читтә тотмыйча, эшкә бик нык катнашырга тиешләр».

Аннары Г. Ибраһимов чыгышы турында отчетта болай дип әйтелә: «Мәскәү язучылары өчен, теория белеме ягыннан үсү өчен зәмин (җирлек) зур. Тик аны файдалана белергә кирәк. (...) Шагыйрьләрдән Ә. Ерикәй, М. Крымов, Ә. Фәйзи һәм М. Җәлил иптәшләр, А. Фадеев җитәкчелеге астында төзелгән проза комиссиясендә эшләсәләр, үзләренә зур теоретик һәм практик белем алачаклар» («Коммунист», 1933, 3 октябрь).

Галимҗан Ибраһимов Казанга килеп, 1 октябрьдагы кичке утырышта колхозчы-

ударниклар съезды делегатларының алкышы астында ялкынлы чыгыш ясый. Ул Татарстан хезмәт ияләренең Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә промышленность, авыл хуҗалыгы, культура, мәгариф өлкәләрендә зур уңышларга ирешүе белән котлый.

Г. Ибраһимов республиканың кайбер завод-фабрикаларында, Арча районы колхозларында була. Казанда язучылар, сәнгать, фән работниклары белән очраша. Аны шагыйрь Нур Баян озатып йөри. Ул мехкомбинат каршындагы әдәбият түгәрәге членнары белән сөйләшә, киңәшләр бирә.

Икенче Бөтентатарстан съезды эшләгән көннәрдә Галимҗан Ибраһимов Муса Җәлил белән дә очраша. Ул елларда ВЛКСМ өлкә комитетының бүлек мөдире булып эшләгән, шагыйрьне якыннан белгән, хәзер Лаеш районының Атабай авылында яшәгән Фатих ага Исхаков болай дип искә ала:

«М. Җәлил бер көнне соңгарак калып кайтты. Галимҗан Ибраһимов аны сөйләшеп утырырга чакырган икән. Ул Мусага өлкә комитеты секретаре Михаил Разумов янында булуы турында, тормышы, иҗаты белән кызыксынуын сөйләгән. Галимҗан Ибраһимов Мусаның иҗаты турында сорашкан. Ул Муса белән киләчәктә хат аша бәйләнеш тотарга вәгъдә иткән, Ялтага кунакка чакырган. Галимҗан Ибраһимовның гадилеге, ягымлылыгы, сүзгә юмартлыгы, таләпчәнлеге Мусада зур тәэсир калдырган. Муса Ибраһимов яныннан күтәренке рух белән, шатланып кайткан иде» (Үлемсезлек таңында. Муса Җәлил турында истәлекләр. Казан. 1971, 33 б.).

...М. Горький җитәкчелегендә СССР язучыларының беренче съездына хәзерлек башлана. М. Горькийга Оештыру комитеты президиумы беренче номерлы билет бирергә карар чыгара. Татарстаннан СССР Язучылары союзына беренчеләрдән булып Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал, Фәтхи Бурнаш, Хәсән Туфан, Муса Җәлил һ. б. кабул ителә.

1934 елның 25 июлендә совет язучыларының беренче Бөтентатарстан съезды ачыла. Почетлы президиумга Максим Горький һәм Галимҗан Ибраһимов сайлана. М. Җәлил съездда катнаша һәм чыгыш ясый.

Язучыларның беренче Бөтенсоюз съездына делегат итеп Татарстаннан М. Горький, Г. Ибраһимов, шулай ук А. Новиков-Прибой, К. Нәҗми, К. Тинчурин, И. Гази һ. б. сайлана. М. Җәлил Бөтентатарстан һәм беренче Бөтенсоюз съездын үткәрү, аның эшен татар матбугатында яктырту эшендә актив катнаша. Шулай итеп, Татарстан Язучылар союзының тууы М. Горький, Г. Ибраһимов, М. Җәлил исемнәренә килеп тоташа.

Съезддан соң А. Фадеев, Максим Горький кебек үк, татар язучыларының иҗаты белән, шул исәптән Г. Ибраһимов һәм М. Җәлил иҗаты белән даими кызыксынып тора.

1943 елның октябрь аенда үткән СССР Язучылар союзы президиумы утырышында А. Фадеев председательлегендә һәм аның тырышлыгы белән «Бөек Ватан сугышы көннәрендә татар язучыларының эше» турында мәсьәлә карала. А. Фадеев утырышта Муса Җәлилне «танылган зур шагыйрь» дип атый, аның шигырьләрен бастыру өчен чаралар күрүне таләп итә. Аннары А. Фадеев Г. Ибраһимов һәм башка татар әдипләре турында болай дип әйтә: «Мин өлкән буын татар әдипләре иҗаты белән таныш̧мын, алар фәкать үзләренең политик биографияләренә бәйле рәвештә генә басылмыйлар, мәсәлән, Ибраһимов. Мин әйтергә телим: татар классикларына үз хезмәтләренә карата тәнкыйтьчел мөнәсәбәт хас. Алар художестволы әсәр өстендәге хезмәтнең нәрсә икәнлеген яхшы төшенеп эш итәләр» («Казан утлары», 1966, 2 сан, 16 б. Нил Юзиевның «А. Фадеев һәм Җәлил» турындагы мәкаләсе). Мәскәү һәм Казан архивларында сакланган бу тарихи документны дулкынланып укыйсың...

Әнә шулай итеп, Максим Горькийның күркәм эшләрен дәвам итүче, ВКП(б) Үзәк Комитеты члены, СССР Язучылар союзы җитәкчесе Александр Фадеев татар халкының сөекле уллары Галимҗан Ибраһимов белән Муса Җәлилгә ихлас күңелдән ышаныч белдерә. Галимҗан Ибраһимов белән М. Җәлилнең үлемнәреннән соңгы язмышын хәл итүдә дә рус әдибе А. Фадеевның роле әйтеп бетергесез зур.

Әйе, культурабыз, сәнгатебез маяклары Галимҗан Ибраһимов белән Муса Җәлил йөргән эзләрдән үткәндә, үзеңне бәхетле итеп сизәсең. Бу бөек шәхесләрнең иҗат, хезмәт, көрәш батырлыгы алдында баш иясең.

---

*Галимҗан Ибраһимов үз заманының сулышы белән яшәп, үз заманының иң актуаль мәсьәләләре турында шәһәр тормышыннан да, авыл тормышыннан да искиткеч осталык белән әдәби җәүһәрләр тудырган.*

Г. ӘПСӘЛӘМОВ.

---

**Азат Әхмәдуллин**

# СӘХНӘДӘ ЯҢА ГЕРОЙЛАРГА ЮЛ САЛГАНДА

Г. Ибраһимов иҗат мәйданына чыккан еллар — реалистик татар әдәбиятының ныгып килгән, татар сәнгатенең күп кенә тармаклары, шул җөмләдән театрының да, яралган һәм үсә башлаган чор иде. Яшь язучы башта ук үзенең әдәби тәнкыйть иҗатында сәхнә сәнгатенә һәм драматургиягә ныклы игътибар бирә. Аның мәкаләләрендә һәм хезмәтләрендә бу жанрның мөһим бер сәнгать тармагы булган театрның нигезендә ятуы искә алынып, аңар махсус илтифат күрсәтелә. «Милли шагыйрь, милли әдәбият, милли театр —болар безнең каршыда хәятның биргән вә бирәчәк нәрсәләренең иң газизләреннәндер»,— дип, Г. Ибраһимов сәхнә уенын әдәбиятның һәм сәнгатьнең башка тармаклары белән тиң күреп карый. Бу аңар пьесаларга да, аларның сәхнә вариантына да дөрес таләпләр куярга ярдәм итә.

Әйе, әдипнең драматургиягә һәм театрга карашлары бербөтен система тәшкил итә. Аның нигезендә исә художество иҗатының иҗтимагый вазифасын тану ята, шуны беренче планга кую тора. Бу караш аның барлык теоретик хезмәтләрен дә, мәкалә һәм рецензияләрен дә үтәли сугара. Һәм аның шул чорлардагы иң алдынгы эстетик таләпләргә якын торуын күрсәтә. Икенче сүзләр белән әйткәндә, язучы эстетиканы материалистларча аңлый. Киң эрудицияле философ-галим буларак, Г. Ибраһимов эстетика фәненең нигезендә бары тик матурлык кына күрүче галимнәр белән бәхәскә керә, бу яктан ул — Н. Г. Чернышевский тәгълиматы тарафдары. Эстетика фәненә әзлекле һәм ачык карашын әдип беренче мәртәбә тулы төстә 1915 елда «Альбом мөнәсәбәте белән бер-ике сүз» исемле хезмәтендә уздыра. Монда аның эстетика фәненең кайдан һәм кемнән башлануын яхшы белүе дә, ул фәннең нигезләрен аңлауда ялгыш кимчелек хаталарны дөрес аңлавы да күренә. «Эстетика» терминын фәнгә беренче булып XVIII гасыр немец галиме Александр Баумгартен кертә. «Баумгартенның җиңел кулы белән башлап, гасыр ярым буена сәнаиге нәфисә (сәнгать) — матурлыкка хадим (хезмәтче), матурлыкны ифадәдән (аңлатудан) гыйбарәт дигән нигездә кордылар,— дип яза Г. Ибраһимов.— ...Дөрест, сәнаиге нәфисәдә матурлык беренче урынны тота, ул матурлыкны тәҗәссем иттерә (гәүдәләндерә), ул матурлыкны аңлау хисен куәтли дә; шулай булса да, анда матурлыкны ифадә итү дип ясап куелган бер максат юк». Ә төп максат нидә соң? Г. Ибраһимов моңа XIX йөз француз галиме, сәнгатьне иҗтимагый күренеш дип аңлаткан Ипполит Тэн сүзләре белән җавап бирә: «Сәнгать — бер нәрсәнең, бер табигатьнең маһиятен (асыл сыйфатын) ачудан гыйбарәт». Ягъни, сәнгать — гәрчә ул матурлыкка нигезләнгән булса да, иҗтимагый аңның бер төре, дөньяны танып белүнең үзенчәлекле бер формасы. Менә ни өчен сәнгать әсәрнең төп юнәлешен чынбарлыкны, шул җөмләдән иҗтимагый тормышны да танып белүдән эзләргә кирәк.

Г. Ибраһимов бу карашларын әдәби-тәнкыйть эшчәнлегендә, шул исәптән драматургиягә һәм театрга караган хезмәтләрендә, чыгышларында да эзлекле төстә уздыра. Пьесаның һәм аның буенча куелган спектакльнең сәнгатьчә эшләнешен һич кенә дә күздән ычкындырмастан, язучы аларны иң әүвәл иҗтимагый үсеш процессы һәм сыйнфый көрәш ноктасыннан торып бәяли. Мәсәлән, Ф. Сәйфи-Казанлының «Ямьсез тормыш» исемле пьесасын, аның 1915 елның январь аенда куелышын Г. Ибраһимов иң беренче шул яктан алып карый һәм анализлый. Рецензентның төп игътибарын пьесадагы яңа типлар җәлеп итә,— алар аңа шул чордагы татар җәмгатьчелегенең аерым катлауларын биләгән алдынгы фикерләрне дөрес чагылдырулары белән ошыйлар. Мөхәммәт, Саттар, Һаҗәр кебек аерым оригиналь образларны бәяләгәндә, Г. Ибраһимов аларның әсәрдәге һәм спектакльдәге үзәк идеягә нинди яңалык кертүләреннән чыгып эш йөртә. Баш персонаж Мөхәммәт ярдәмендә уздырыла торган алдынгы фикерләрне, мәсәлән, һәммә халыкларның тигез хокукка ия булулары хакындагы фикерне рецензия авторы яклый һәм үстерә. Берәүләр, ди рецензент, «милләт» һәм «халык» сүзләрен иң элек үз мәнфәгатьләре өчен файдаланалар, алар белән сату итәләр. Ә Мөхәммәт — алай түгел. Аның максаты: «...милләтемезнең 90 процентын ясый торган ярлы татар арасына» керү, «ярлылык сәбәпле үрчи алмый торган авыл халкына, эшнең иң авырын эшләп, акчаның иң азын ала торган завод-фабрика халкына, көн уздыру кайгысыннан котыла алмый торган шәһәр әһеленә үзләренең кеше икәнен» аңлату. Заманы өчен алдынгы булган шушы

идеяне уздырганы өчен дә Мөхәммәт әдәбиятыбыз һәм театрыбыз өчен яңа бер тип дип саналырга хаклы.

Г. Ибраһимов драма һәм сәхнә турындагы караш-фикерләрендә бөтендөнья әдәбияты һәм сәнгатенең бай тәҗрибәсенә таяна. Ул бу өлкәдә бик тә хәбәрдар. Мәсәлән, француз язучысы Эдмон Ростанның «Жантеклер» исемле аллегорик пьесасы Парижда 1910 елда сәхнәгә куела, ә бер елдан соң ук Г. Ибраһимов аның турында искә ала («Яңа китап мөнәсәбәте илә» мәкаләсендә). Л. Андреев драмалары («Тәрҗемә һәм аның шартлары» мәкаләсе, 1910), В. Шекспир трагедияләре («Альбом мөнәсәбәте белән бер-ике сүз», 1915), Мольер комедияләре («Вакытсыз һәлак булды», 1922) һ. б. — боларга һәм күренекле башка драматургларга, язучыларга, аларның әсәрләренә Г. Ибраһимов иркен мөрәҗәгать итә.

Дөрес, драмага, аның әдәби жанр буларак үзенчәлекләренә әдипнең карашлары баштан ук шулай тирән һәм ачык булып формалашкан дип әйтә алмыйбыз. Иң беренче мәкаләләрендә һәм чыгышларында ук язучының проза һәм поэзия турындагы белемнәре тирән, эзлекле. Ә менә драмага ул, тәнкыйтьче һәм әдәбият теоретигы буларак, бары тик 1915 еллар тирәсендә генә иркен мөрәҗәгать итә. Ягъни, аның жанр үзенчәлекләрен истә тотып мөрәҗәгать итә, аны театр белән тыгыз бәйләнештә карый башлый. Югыйсә, аны гомуми әдәби калыпка салып карау алданрак та очрый. Мәсәлән, 1912 елда әдип «Җанлы курчаклар» исемле Кәбир Бәкер пьесасын рецензияли. Монда ул аңа жанр ягыннан артык игътибар итми, әсәрне бары тик тормышчанлык ноктасыннан характерлый, өлгергән мәсьәлә күтәреп чыгуы өчен бәяли. «Хикәя халык өчен кызыклы, күңелле генә, ләкин ашыгыбрак язылган» дигәндә дә, «татарның башка хикәяләрендәге кеби, монда да конструкция зәгыйфь» дигән юлларда да сәхнә әсәренең жанр үзенчәлекләрен исәпкә алу әлегә юк.

Ә инде шул ук Ф. Сәйфи-Казанлының «Ямьсез тормыш» драмасын анализлау жанр таләпләре ноктасыннан алып барыла. Мәсәлән, монда инде аның әсәр композициясе турындагы фикерләре ачык: «Пьесаларда... булса да, булмаса да ярарлык нәрсә урын алмаска тиеш,— ди ул.— Пьеса шундый бер калыпка куелган булсын ки, аның бер җирен төшерү яки киметү өйнең бер почмагын җимереп алу дәрәҗәсендә хис ителерлек булсын». Һәр нәрсә бер юнәлешкә, төп фикерне ачуга хезмәт итәргә тиеш — Г. Ибраһимов драма әсәренә әнә шундый таләпләр куя.

Бөек Октябрь революциясеннән соң зур дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимов иҗат активлыгын һич тә киметми. Киресенчә, көндәлек тәнкыйть эшчәнлеген тагын да җанландыру белән бергә, ул драматургия һәм театр тарихчысы буларак та чыгышлар ясый, үзе дә драматургиягә мөрәҗәгать итә, совет чорында беренче әдәби әсәр булган «Яңа кешеләр» исемле драмасын яза. Социалистик әдәбият һәм сәнгатьнең нигезләрен салганда, йөзләрчә теоретик мәсьәләләрне һәм практик бурычларны хәл иткәндә, әдипнең бу тармаклардагы эшчәнлегенең һәрберсе мөһим, һәрберсе кирәкле һәм вакытлы иде. Күпчелек мәсьәләләрне ул бик урынлы һәм вакытында куя, тиешле теоретик югарылыкта хәл кыла белә.

Егерменче еллар яңалыкның туктаусыз һәм җиңүле һөҗүме, ләкин әле еш кына идея-эстетик позицияләрен ачыклап бетерә алмавы белән, ә искелекнең төрле төскә кереп, үз позицияләрен саклап калырга тырышуы белән характерлана. Бу шартларда реакцион идеологиянең һәм артта калган сәнгать принципларының активлашуы, күптөрле формаларга кереп яшәргә тырышуы театр сәнгатендә дә көчле,— аларны күрә һәм фаш итә белергә кирәк иде. Г. Ибраһимов бу хәрәкәтнең башында тора, һәм уң, һәм сул тарафтан алып барылган һөҗүмнәрнең асылын ярып сала, аларга отпор бирә.

Яңалык иске җирлектә туа, үзенең беренче яралгыларын иске эчендә җибәрә. Татар социалистик әдәбияты һәм сәнгате дә үзенең башлангыч адымнарын Бөек Октябрьга кадәр үк атлый башлый. Г. Ибраһимов монда беренчелекне Г. Коләхметовның пролетар эчтәлекле әсәрләренә бирә. Пролетар язучысының әдәби иҗатын, аның рухын һәм эчтәлеген Г. Ибраһимов аның заманы белән, эшчеләр хәрәкәте, аерым алганда, Казанның Пороховой татар эшчеләр районы белән бәйләп карый. Ул район, ди әдип, «1905 ел ярдәме белән безнең матур татар әдәбиятына беренче марксизм рухын өрде».

Г. Коләхметов һәм пролетар поэзия белән башланган яңа дәвер татар әдәбияты тарихына, андагы күренекле шәхесләр һәм аның үсеш баскычлары мәсьәләсенә Г. Ибраһимов кабат-кабат әйләнеп кайта. «... аңарчы кысылган, авызы, теле бәйланган татар социализм әдәбияты Февраль белән бергә сугыш мәйданына чыкты»,— дип язганда («Дүртенче елга кергәндә», 1920), ул нәкъ менә Коләхметовлардан башланган, М. Гафурилар, Ф. Бурнашлар аркылы үсеп килгән әдәби агымны күз алдында тота. «Соңгы вакытта Мәҗит «Эшче» дигән поэма язды. Ике табаклык бу әсәр татар революция шигырьләренең таҗы улачактыр»,— дип, М. Гафуриның бу әсәренең яңа әдәбияттагы урынын билгели (шунда ук). Сүз уңаенда әйтеп үтик: бу поэма мотивлары буенча икенче татар операсы «Эшче» язылганда, аның либреттосы

нэкъ менэ Г. Ибраһимов тэкъдиме буенча язылa. Ф. Бурнашның «Таһир-Зөһрә» трагедиясе һәм «революционный поэмалары» «пролетариат хәрәкәтенең көчле дулкыннары астында, шулар тәэсире белән чыкты»,— ди ул икенче бер урында. Г. Ибраһимов «Яшь йөрәкләр» пьесасын да яңа дәвер әсәре санап, Ф. Бурнашны «пролетар шагыйрьләреннән» дип атый («Татар әдәбияты», 1922).

«Галиябану» драмасының татар әдәбияты тарихындагы урынын, аның яңалыгын билгеләүгә әдип аерата игътибар бирә. Бу пьесаны ул «эшче-крестьян гаммәсенә бик якын» драма дип атый («Татар җөмһүриятенең икенче елында әдәбиятыбызның язмышы», 1922). Драма Г. Ибраһимовны, иң беренче, эчтәлегенең яңалыгы — үзендәге геройларның тулы бер сыйныфны чагылдырулары, аларның чынбарлыкка якынлыгы, алар язмышында иҗтимагый тормыш тирән гәүдәләнүе аркасында җәлеп итә. «Беренче мәртәбә диярлек һичбер буяусыз, саф булганча, үзләренең үенкөлкеләре, җырлары, музыкалары, гыйшыклары, интригалары, бәетләре, көрәшләре белән крестьян егетләре, крестьян кызлары бу әсәр аркылы безнең театр галәменә килеп керәләр,— ди ул һәм пьесаның төп кыйммәтен билгели.— Бу драманың халык каршында зур муаффәкыять (уңыш) казануының төп сәбәбе менә шул яңа дәвердә җәмәгать мәйданына чыккан яңа сыйныфларның шатлыклы-кайгылы, көрәшле хәятларын сәхнәгә мендерүендәдер»[1].

Яңа рухлы мондый геройларны чагылдырган әсәр уңае белән Г. Ибраһимов әдәбиятыбызның тарихи юлын аңлау өчен гаять мөһим булган түбәндәге мәсьәләгә дә кагылып уза. «Крестьян эчендәге яшьлекне төп мөндәриҗә (эчтәлек) итеп алуы, саф реализм нигезендә сыйнфый каршылыкларны табигый әдәби рәвештә ачып бирүе кебек хасиятләр «Галиябану»ны бездә соңгы 7-8 ел эчендә туып килгән яңа — өченче дәвер әсәрләренә якынлата, аны шул дәвернең беренче сандугачлары кабиленнәнрәк (төркеменнәнрәк) бер урынга мендерәдер»,— дип, әдип М. Фәйзи драмасын Бөек Октябрьдан соң тулы иркенлек алган яңа әдәбиятка якынайтып карый. Ә бу әдәбиятның гомерен ул мәкалә язылган 1922 елдан алдагы 7-8 ел белән билгели, ягъни 1915-1916 еллардан ук башлануын әйтә. Димәк, Г. Ибраһимов «Галиябану»ны критик реализм җимеше генә түгел, ә пролетар әдәбияты белән башланган өченче дәвер, совет чорында чәчәк атып килүче яңа тип әдәбият вәкиле төсендә тәкъдим итә.

Татар әдәбиятын дәверләргә бүлгәндә, ул анда кемнең һәм ничек сурәтләнүен, кешенең иҗтимагый процесста нинди урын тотуын алгы планга куя. Шул ноктадан карап, әдип «Татар әдәбиятында өченче дәвер» (1922) исемле хезмәтендә өченче дәверне хронология һәм эчтәлек ягыннан түбәндәгечә билгели: «Өченче дәвер — моның төп нигезе, беренче адымнары Герман сугышы заманындагы зур, авыр матди үзгәрештә чак кына сызыла. Февраль моңа юл ача. Октябрь аякка басарга ярдәм итә. Нәтиҗәдә татар әдәбияты үзенең мөндәриҗәсе буенча да, фикере буенча да, юл тоткан кәгъбәсе буенча да бөтенләй яңа бер дәвергә керә. Монда төп рух — сыйнфый көрәш...» Г. Ибраһимов мисалларны да бик ачык күрсәтә: «Моннан 8 ел элек басыла башлап та, цензур туктату сәбәбеннән бу елларда гына чыга алган «Безнең көннәр» трилогиясе, Бурнашның «Һәйкәл чәчәк», «Ялгыз каен» кебек шигырьләре һәм революцион поэмалары, элеккеге дәверләр эчендә үсә-үсә, революцияне аңлауга җитешкән Мәҗит Гафуриның «Эшче» поэмасы, аның «Кызыл байрак»ында басылган «Изге юл», «Сәлам» кебек шигырьләр; Шамил Усмановның «Беренче адым», Сәйфинең «Дошманнар», ... ахыр гомерендә революцияне җырлап үлгән Бабичның кызыл нәрсәләре, тагы боларга башка да, сыйнфый көрәшләр, хезмәт хәрәкәтләре белән сугарылып, яңа кыйблаларга карап бара торган әллә ничаклы яңа, яшь талантлар — һәммәсе менә шушы өченче дәвер бакчасының чәчәкләредер».

Г. Ибраһимовның төрле уңай белән әйтелгән югарыдагы сүзләреннән бер нәрсә ачык аңлашыла: «Галиябану», «Безнең көннәр» кебек әсәрләр инде критик реализм дәвере әдәбиятыннан үсеп чыкканнар, эчтәлекләре һәм формалары ягыннан совет әдәбиятына якын торалар; болар — хәзерге термин белән әйткәндә, социалистик реализмга күчеш чоры әсәрләре. Дөресен әйткәндә, бу — В. И. Ленинның бер милли культура эчендә ике культура барлыгы турындагы тәгълиматын расләучы менә дигән мисал. Совет чорында яңа сәхнәдә ныклы урын алган геройларның килүен Г. Ибраһимов, шулай итеп, «Яшь гомер»ләрдән, «Галиябану»лардан, «Безнең көннәр» һәм «Таһир-Зөһрә»ләрдән үк башлап күрә.

Бу яңа геройларның сыйфат үзенчәлекләрен Г. Ибраһимов мәкалә һәм рецензияләрендә генә түгел, «Яңа кешеләр» әсәре белән дә расларга алынды: 1920 елда иҗат ителгән һәм Бөек Октябрьның 3 еллык юбилеена сәхнәдә уйналган драма уңыш казана, хуплап каршы алына. Аның төп уңышы, күрәсең, сәхнә әсәре булудан бигрәк, олы язучының, В. И. Ленин белән бергә эшләгән күренекле җәмәгать эшлеклесенең көн сорауларына җавап бирә алуында була.

---

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр, 5 т., 302 б.

Әсәрдә төп проблема итеп пролетар гуманизм алынган. Заманы өчен гаять мөһим, гаять катлаулы мәсьәлә, миллионнарның игътибарын җәлеп иткән проблема. Идел һәм Урал буйларында гражданнар сугышы бара. Еш кына авыл кулдан-кулга күчә, аклар да, кызыллар да «хаклык өчен сугышабыз» диләр, кара акылга кайсының дөрес булуын аерып алу җиңел түгел. Бу бәрелешләр, мондый власть күчешләре кан һәм күз яшьләре эчендә, үтерешләр һәм кисешләр ярдәмендә бара. Андый шартларда кан түгүләргә гомумән каршы булу, андый эшләрне кире кагу гади крестьян өчен генә түгел, ә зыялыларга да хас. Хаклык өчен сугышның эчке законнарын аңламаган кеше, гомумән, сугышка каршы чыга, читтә тору, катышмаска тырышу, ризалашу позициясенә баса. Бу — зарарлы күренеш, революцияне һәлакәт чокырына төшерә торган әйбер. Һәркем өчен революциянең арифметикасы ачык булырга тиеш: яки... яки...

«Яңа кешеләр»нең баш герое Батырхан менә шул фәлсәфәне иң ачык төстә алга сөрә. Ул — нык һәм каты куллы кеше, ләкин һич тә дошман канына сусаган, җан кыярга гына торган кеше түгел. Киресенчә, әнә ул гөнаһсыз кан коюларга каршы чыгып, артык каты кылanучы Тимеркәй белән бәхәс алып бара. Шуның белән бергә сыйнфый көрәш көч кулланудан башка була алмый, революцияне кылыч белән саклый белергә кирәк. Ә монда инде дошманны син җиңмәсәң, ул сине үтерә. Шуңа күрә дә Батырхан үзенең оппоненты, «кан түгүгә киткәч, шәп түгел инде ул!» дип караган Шәйбәк картка каршы чыгып, «канлы юл — изге юл!» булуын әйтә, моның котылгысызлыгын мисаллар ярдәмендә раслый. Алай гына да түгел, пьесада гәүдәләндерелгән тормыш картинасы үзе Батырханнар тоткан юлның бердәнбер дөрес юл булуына ышандыра.

Беренче революцион пьесалар арасында «Яңа кешеләр» проблематикасының катлаулы булуы, куелган мәсьәләләрне ахыргача һәм дөрес хәл итүе белән уңай якка аерылып тора. Автор сыйнфый көрәш фәлсәфәсен күп төрле политик, иҗтимагый һәм этик мотивлар үрелмәсе-катнашмасы рәвешендә тәкъдим итә. Заманга һәм яңа геройларга хас булган үзенчәлекләр драмада шактый ук тулы ачыла. Батырхан, Тимеркәй, Камәр кебек образлар белән татар сәхнәсенә сыйнфый азатлык көрәшенә ахыргача бирелгән яңа геройлар чыкты; алар Г. Коләхметов, Ш. Усманов, Ф. Сәйфи-Казанлы, Ф. Бурнаш, Һ. Такташ, Ш. Камал, К. Тинчурин һ. б. драматурглар иҗат иткән геройлар образлары белән бергә совет сәхнәсенең төп үсеш тенденцияләрен билгеләштеләр.

Менә бу һәм башка күп төрле фактлар: әдәби-тәнкыйть эшчәнлеге, театрга һәм драматургиягә караган күп санлы мәкаләләре һәм рецензияләре, ниһаять, «Яңа кешеләр» драмасы Г. Ибраһимовны татар сәхнә сәнгатенә зур өлеш керткән әдип һәм талантлы оештыручы итеп карарга тулы мөмкинлек бирәләр.

---

*Билгеле булганча, аның (Г. Ибраһимовның — ред.) кызыксыну диапазоны да гаять киң иде. Ул менә дигән язучы да, тарихчы да, телче дә, әдәбиятчы да һәм һәр җирдә дә үзенең сүзен әйтә ала иде.*

Профессор И. Н. БОРОЗДИН.

*Бу әдәбиятның (татар әдәбиятының — ред.) Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Җәлил кебек титаннары, Н. Исәнбәт, Г. Бәширов, С. Хәким, М. Әмир, Ш. Маннур, А. Шамов, Г. Әпсәләмов, Ф. Хөсни кебек бөтен илгә танылган язучылары бар...*

ЛЕОНИД СОБОЛЕВ.

*Г. Ибраһимов романнары татар совет романына юл салдылар.*

ЛУИ АРАГОН, француз язучысы.

---

Флорид Әгъзамов

# МАТБУГАТ ТЕОРЕТИГЫ ҺӘМ ТАРИХЧЫСЫ

Галимҗан Ибраһимов эшчәнлегендә публицистика белән журналистика аерым бер урын тота. Ул үзе дә күп тапкырлар зур горурлык белән: «Мин — журналист»,— дип белдергән. Аның журналист һәм публицист буларак эшчәнлеге И. Рәмиев, М. Гайнуллин, Г. Халит, Х. Госман, А. Шамов, Т. Насыйров, С. Поварисов, Р. Мөхәммәдиев, Р. Гайнанов, Й. Гәрәй, Р. Хисмәтов һәм башкаларның хезмәтләрендә аерым яклары белән чагылыш тапкан. Бу игелекле эшкә М. Хәсәнов, Ү. Гыймадиев, Р. Нуруллина аеруча зур өлеш кертәләр. Әмма Г. Ибраһимовның журналистлык эшчәнлеген тикшерүдә әлегә беренче адымнар гына ясалган. Аның матбугатны оештыручы һәм җитәкләүче буларак хезмәтләре (мәгълүм ки, ул «Аң», «Ирек», «Безнең юл», «Чулпан», «Мәгариф» һ. б. органнарны оештыручы булган), матбугатка, аның тарихына карашлары, публицистик иҗаты махсус тикшерүгә лаек.

Г. Ибраһимовның турыдан-туры матбугатка караган хезмәтләре үзе генә дә — үтә бай, күпьяклы һәм колачлы мирас. Һәрхәлдә аны өч юнәлештә карарга мөмкин: 1) матбугат теориясе; 2) матбугат тарихы; 3) матбугат практикасы. Әлбәттә, бу — шартлы бүленеш. Әлеге өч тармак бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән. Һәм, гомумән, Г. Ибраһимов хезмәтләренең үзенчәлеге шунда, аларда теоретик мәсьәләләр практика ихтыяҗларыннан чыгып карала, шул чор матбугаты күренешләре һәм тарихи фактлар җирлегендә тикшерелә (мәсәлән, «Яңа әсәрләр, яңа имзалар вә яңа куәтләр», «Яңа мәдәният төзү юлында гыйльми-әдәби коллективлар») һәм, киресенчә, матбугат тарихи фактлары, күренешләре, аерым әдип-журналистларның иҗаты теория күзлегеннән үткәрелә, аларның хәзерге дәвер өчен әһәмияте ачып бирелә («Революция тарихына материаллар (кыска бер фиһрист)», «Урал» бәйрәменнән гыйльми яктан файдалану», «Урал» һәм «урал»чылар). Бу җәһәттән Г. Ибраһимов әйбәт сабак бирә. Югыйсә бит бездә матбугат теориясен бәян иткән хезмәтләр еш кына декларатив, абстракт, фәнгә охшатылган, тарихи җирлектән аерылган булып чыга. Тарихны теория белән сугара, теорияне практик ихтыяҗларга бора, бүгенге һәм тарихи тәҗрибәгә таяндыра белү әле һаман да зур әһәмияткә ия. Зурдан кубыбрак әйткәндә, сүз гыйльми тикшеренүнең бик мөһим бер принцибы — теоретик һәм эмпирик, логик һәм тарихи башлангычларның, теория белән практиканың диалектикасы, аларның берлегенә ирешү турында бара.

Г. Ибраһимовның матбугатка карашларын барлаганда, без аларның үсеш-үзгәрешен, ягъни эволюциясен күз уңыннан төшерергә тиеш түгелбез. Аның матбугатка революциягә кадәрге карашлары — бер баскыч, ә инде Октябрьдан соң марксистик-ленинчыл методологиягә, В. И. Ленинның матбугат турындагы тәгълиматына нигезләнгән карашлары — икенче, югарырак баскыч. Алары фәннирәк тә, эзлеклерәк тә.

Революциягә кадәрге хезмәтләрендә Г. Ибраһимов матбугатны белем чыганагы, мәгърифәт чишмәсе итеп карый. «Уфа йоклый» исемле мәкаләсендә ул шәһәр җәмгатьчелегенең йокы хәлен, политика һәм культурадан читтә торуын матбага, газета-журналлар, нәшир һәм нәшрият җәмгыятьләре, язучылар булмавы белән аңлата. Һәм публицист-галим матбугатны, газета-журналларны милли үзаң формалаша башлау, рухи яктан уяну, революцион яңарыш күренеше һәм шуның бер куәтле чарасы дип саный. «Телләре башка булса да, күңелләре бер» дигән хезмәтендә ул төрки халыкларның төрле төбәкләрдә бер үзәккә туплана баруының хәлиткеч шартлары рәтендә матбугатны да ассызыклап күрсәтә. Чөнки «һәр халык үзенең рухын матбугатта чагылдыра»[1].

Г. Ибраһимов матбугатның барлыкка килүендә һәм тернәкләнеп үсеп китүендә янә бер закончалыкка игътибар итә. Бик күп милләтләрнең тарихи тәҗрибәсе раслаганча, матбугат сыйнфый бәрелешләр, халык массаларының революцион күтәрелеше, азатлык хәрәкәтенең көчәюе чорында аеруча киң колач ала. Татар матбугатында да шул ук закончалык күзәтелә. Моны күздә тотып, Г. Ибраһимов «Татар матбугаты» исемле күзә-

---

[1] Маркс К., Энгельс Ф. Соч., 2-е изд., т. 1, 44 б.

түендә үк (1910 ел) болай дип яза: «Хөррият һәм хәрәкәте гомумиядән соң, язгы ташкын кебек, безнең матбугат бик кызу мәйданга атылган иде» (5, 5).[1]

Әдип-публицист матбугат белән җәмәгатьчелек фикере диалектикасын яхшы аңлый. Мәгълүм булганча, ирекле матбугат, бер яктан, җәмәгатьчелек фикере продукты булып тора, икенче яктан, ул үзе шул җәмәгатьчелек фикерен тудыра. Г. Ибраһимов теге яки бу иҗтимагый ихтыяҗны матбугатта күтәрелгән проблемалар белән билгели. Мәсәлән, «Мәктәптә әдәбият дәресләре» дигән рецензиясендә ул милли әдәбият укытуны заман ихтыяҗы дип санап, моны җәмәгатьчелек фикере, аны чагылдыручы матбугат чыгышлары белән нигезли (5, 47).

Әдип-публицист прогрессив журналистиканың халыкка хезмәт итәргә тиешлеген яхшы аңлый. «Куәт — халыкта»,— дип белдерә ул. Аның карашынча, революция җәелә барган җаваплы дәвердә матбугатның бурычы — «кулдан килгән кадәре хезмәт итү, халкыбызның иң караңгы җирләрдә калган өлешләренә дә безнең хәлләрнең әһәмиятен аңлатырга тырышу». Халыкның аңлавына, үз теләкләрен белдерүенә ирешү өчен аңлы рәвештә, гайрәт һәм каһарманлык күрсәтеп көрәшү кирәк, ди ул.

Г. Ибраһимов журналистиканың һәм журналистларның бертөрле түгеллеген ачык күрә. Ул социалистик революциягә кадәр үк инде аларның сыйнфыйлыгын һәм партиялелеген аңлау дәрәҗәсенә күтәрелә бара. «Өченче социалистик газетә» дигән мәкаләсендә, мәсәлән, «Кызыл байрак» газетасының чыгуын хәбәр итеп, аның үз юнәлешен социалистик дип билгеләве белән генә чикләнергә ярамавын әйтә. Кайсы партиягә каравын батырып әйтүне зарури итеп куя, моны дәвер ихтыяҗы белән аңлата (6, 127).

Ул, каләмдәшләре кебек үк, матбугатка һәм аның эшлекләренә карашларын теге яки бу уңай белән аларга таләпләр рәвешендә бәян итә, һәм ул әлеге таләпләрне матбугат практикасыннан чыгара. Менә ул таләпләрнең кайберләре. Башка милләтләр тәҗрибәсенә таянып, Г. Ибраһимов каләм эше белән шөгыльләнү — тормыш, әдәбият һәм фәннән хәбәрдар булган талант иясе эше, дип саный (5, 5). Тормышны, аның проблемаларын яхшы белгәндә, аларны фән күзлегеннән чыгып, әдәби яктан камил яктыртканда гына журналист, нәшир үзенең вазифасын уңышлы үти ала.

Әдип-публицист журналистларның тормышны тирәнрәк гәүдәләндерү мөмкинлекләрен киңәйтү юллары турында уйланды. Һәм шуларның берсен аларның специальләшүендә күрде. «Яңа әсәрләр, яңа имзалар вә яшь куәтләр» дигән хезмәтендә Г. Баймбитов һәм И. Биккуловларның иҗатына күз ташлап, берсенең авыл, икенчесенең шәһәр журналисты булырлык мөмкинлекләре барлыгын һәм шул мөмкинлекләрне файдаланырга кирәклеген ассызыклый. Ул Г. Баймбитовның авыл кешесенең яшәү рәвешен тирәннән белүен, гомумән, авыл хуҗалыгы белән яхшы таныш булуын искәртә. «Менә аңардан, әгәр дәвам итсә, «авыл журналисты» (шундый тәкъбир булса) чыгар өмиде бик куәтле иде. Чөнки ул авылны белә генә түгел, авыл йөрәгенең тибүен сизә һәм шуны бер дә боргаламыйча яза иде» (5, 215). И. Биккуловның исә Казан хәятының эченә кереп язуын күреп, аның шәһәр журналисты була алуы ихтималын әйтә.

Г. Ибраһимов журналист иҗатының бер үзенчәлеген ассызыклап күрсәтә: ул тормыш турында фикер сөйләргә түгел, ә шул тормышны фактлар аркылы ачарга тиешле (5, 216). Ул бу фикерне киңәйтеп тормый торуын, әмма анда журналистиканың методына кагылышлы ифрат әһәмиятле мәгънә ята.

Әдип-публицист журналистның кыйбласы, иманы, позициясе мәсьәләсен бик җитди куя. Аның фикеренчә, бу — үзәк мәсьәлә. Ул «үз йөрәгеннән килгән тәэсиргә, үз рухыннан килгән тавышка колак салырга» (5,216) куша. Журналист И. Биккуловның, кулга каләм алгач, як-ягына карануын, кайсы идарә өчен язганын дикъкатькә алуын, ничек язганда кемгә һәм кемнәргә ничек тәэсир итүен уйлавын, каләмне шул нокталарга каратып йөртүен гаепли (5, 26). Монда сүз укучылар ихтыяҗын исәпкә алып эш итү турында түгел, ә мәсләкнең, позициянең тотрыксызлыгы, борынны җилгә тоту турында бара.

Шул рәвешле, революциягә кадәрге хезмәтләрендә үк Г. Ибраһимов матбугат теориясе һәм практикасының әһәмиятле мәсьәләләрен күтәрә, аларны позитив хәл итү юлларын күрсәтергә омтыла.

Әмма аның матбугатка эзлекле марксистик-ленинчыл карашлары, әйткәнебезчә, Октябрь социалистик революциясеннән соң формалашты. Ул яңа матбугатның яңа җәм-

---

[1] Г. Ибраһимов әсәрләренең чыганаклары Татарстан китап нәшрияты чыгара килгән сигезтомлык буенча китерелә. Беренче сан — томны, икенчесе аның битен күрсәтәчәк.

гыять төзүдәге урынын, эш принциплары һәм алымнарын, совет матбугатының беренче адымнарын, Россиядәге революцион матбугатның, бигрәк тә татар коммунистик матбугатының үсеш юлларын, реакцион прессаның тарихын, халыкка каршы асылын, эш «принципларын» һәм «методларын» өйрәнеп, шуның нәтиҗәләрен фәнни хезмәтләрендә, публицистик мәкаләләрендә бәян итте.

Революцион көрәштә актив катнашу, журналистлык тәҗрибәсенең артуы, В. И. Ленин әсәрләрен өйрәнү аны матбугатның сыйнфыйлыгын һәм партиялелеген, аның яңа җәмгыятьтәге вазифасын фәнни аңлавына китерде. Г. Ибраһимов матбугатны сугыш көннәрендә — штык, парламентлар чорында — оратор, университетта — профессорның лекциясе, баррикада вакытында шрапнель белән тиңләде. Әдип-публицист партия-совет матбугатының социалистик революциядән соңгы вазифаларын билгеләгәндә дә В. И. Ленин идеяләренә таянды. Мәгълүм булганча, юлбашчы бу вазифаларның иң мөһимен эшчеләр сыйныфының һәм ярлы крестьяннарның социализм төзү коралы булуда күрде. Кызыл каләмгә «искене җимереп, яңа азат тормыш төзүдә кызыл штык, чүкеч һәм урак белән бер дәрәҗәдә хезмәт йөкләтелгән» (5, 237).

Г. Ибраһимов сыйнфый җәмгыятьтә ике культура, димәк, ике матбугат барлыгын, шуларның берсе хакимлек итүче булуын аңлап эш итте. Аның хезмәтләрендә без реакцион, ягъни клерикаль-феодаль һәм буржуаз журналистикага төгәл сыйфатламалар, аның халыкка каршы юнәлгән асылын, эш «принципларын» һәм алымнарын фаш иткән тирән фикерләр очратабыз. Ул барыннан да элек реакцион матбугатның гомерен кичергән, тарих үзенең чүплегенә себереп түгәчәк сыйныф һәм социаль катлауларга хезмәт итүен ачып бирде.

Феодаль-клерикаль һәм буржуаз журналистиканың һәм аның эшлекләренең халык мәнфәгатьләрен санга сукмавы, сатлык һәм алдакчы булулары аларның хаким сыйныфларга экономик, политик һәм идеологик бәйлелегеннән килә. Г. Ибраһимов боларга өстәп тагын буржуаз журналистларның вәгъдәсезлек, аумакайлык, мактанчыклык, тотнаксызлык кебек сыйфатларын саный. «Халыкны саташтырмагыз!», «Дошманнар арасында дүрт ай», «Революция тарихына материаллар», «Бөек Октябрьның беренче елларында», «Кара маяклар, яки Ак әдәбиятлар» һ. б. әсәрләрендә ул югарыда саналган сыйфатларның конкрет матбугат органнары һәм журналистлар эшендә ничек гәүдәләнгәнен ачып бирде.

«Бөек Октябрьның беренче елларында» исемле хезмәтендә Г. Ибраһимов буржуазиянең пролетариатка каршы өч төрле корал-гаскәр, «дини-милли» оешмалар, матбугат белән көрәшүен билгеләп үтә, татар капиталының өченче коралдан оста файдалануын күрсәтә (6, 493).

Югарыда бәян ителгәннәр Г. Ибраһимовның матбугат теориясенең әле бүген дә актуаль һәм кызып-кызып бәхәсләшә торган проблемаларын тикшергәнлеген раслыйлар. Моңа өстәп, аның яңа матбугат алдында торган практик мәсьәләләрне һәм аларны хәл итү юлларын күтәрүен, көндәлек матбугатка кайнар эздән күзәтүләр, репликалар бирүен дә әйтеп узыйк.

Г. Ибраһимов татар матбугатының киң колачлы тарихчысы иде. Аның бу өлкәдәге мирасы аеруча бай. Без бу мираста аерым чорлар, сыйныфлар матбугатына, аерым газета-журналларга, әдип-публицистлар иҗатына кагылышлы хезмәтләр, матбугат тарихын өйрәнүнең актуаль мәсьәләләрен куйган мәкаләләр очратабыз.

Ул чын мәгънәсендәге татар матбугатының барлыкка килүен хаклы рәвештә 1905 елгы революция, ул алып килгән азатлык җиле белән бәйләп карады. Әмма ул аның элгәрләрен дә онытмады. Аны иң элек Каюм Насыйриның журналистлык эшчәнлеге кызыксындырды. Чирек гасыр буе чыгарып килгән календарьларын күздә тотып, аны көндәлек татар матбугатына нигез салучы дип санады («Башлангыч», «Каюм бабайның йөз еллыгы»). «Беләсез, бездә татар гәзитләре тик 1905 елда гына чыга башлады,— дип язды ул.— Ләкин Каюм Насыйри бу эшкә иң башлап керешүче иде... Ул ярым гәзит, ярым журнал, ярым календарь булган мәҗмугаларын, бик мәшәкать белән булса да, ел саен алып барды» (5, 487). Монда безне, беренчедән, К. Насыйрига бирелгән бәя, икенчедән, аның календарьларына карата әйтелгән сыйфатлама кызыксындыра. Әлеге тезисны фәнни нигезләү өчен (һәм, гомумән, матбугат тарихын булдыру максатында) К. Насыйри календарьларын җентекләп өйрәнәсе бар[1].

---

[1] Бу җәһәттән беренче тәҗрибә ясалды. Карагыз: Ә. Кәримуллин. Каюм Насыйри календарьлары. К-пта: Әйдә халыкка хезмәткә. Казан, 1985, 11—26 бб.

Г. Ибраһимов 1905 ел тәэсирендә барлыкка килгән татар матбугатын тикшерүгә аеруча зур игътибар бирде. Ул төрле сыйныф һәм социаль катлауларның мәнфәгатьләрен чагылдырып, Россиянең байтак шәһәрләрендә барлыкка килгән татар газета-журналларын типларга аерып өйрәнде. Гомумән, революциягә кадәрге матбугатның типологиясен эшләү Г. Ибраһимовның зур теоретик һәм тарихи өлеше булды.

Г. Ибраһимов типологиянең нигез критерийларын эшләде. В. И. Ленинның матбугат турындагы тәгълиматына таянып, ул типологияне азатлык өчен көрәш тарихы белән бәйләп карады һәм иң мөһиме — сыйнфый-икътисади бүленүдән һәм шул җирлектә туган өч политик хәрәкәттән китереп чыгарды. Атап әйткәндә, сыйнфыйлык һәм партиялелек Г. Ибраһимов типологиясенең нигез ташын тәшкил итте. Галим-публицист сыйнфыйлык һәм партиялелекнең конкрет чагылышларын да игътибардан читтә калдырмады. Менә алар: матбугат органының политик партия белән элемтәсе; программасы, эчтәлеге; җитәкчеләре һәм авторлары составы.

Г. Ибраһимовның типологиясе, эволюция кичереп, камилләшә барды. «Иҗтимагый революция вә татар зыялылары», «Революция тарихына материаллар (кыска бер фиһрист), «1905 ел революциясе эчендә татарларның хәрәкәтләрен өйрәнү өчен материаллар җыю турында» исемле хезмәтләрендә ул татар матбугатын өч төркемгә бүлсә, «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре», «Урал» һәм «Урал»чылар» исемле капиталь хезмәтләрендә аны дүрт төркемгә аерып карый: 1) большевистик матбугат; 2) реакцион-клерикаль матбугат; 3) либераль матбугат; 4) эсерлар матбугаты (7, 448).

Әлбәттә, бу типологиянең тулы ук булмаганлыгын да икърар итәргә тиешбез. Әйтик, Г. Ибраһимов, профессор М. Хәсәнов хаклы рәвештә искәрткәнчә, милли матбугат ташкынында революцион-демократик юнәлешне аерып чыгармый. Аерым алганда, сүз «Азат», «Азат халык», «Карчыга», «Әлгасрелҗәдит» һәм башка газета-журналлар турында бара. Бу органнарның кайберләрен Г. Ибраһимов урынсызга вак буржуаз социализм юнәлешенә кертә[1]. Ләкин, ничек кенә булмасын, хәзерге тикшеренүчеләр дә Г. Ибраһимовның нәтиҗәләренә таяналар.

Галим-публицист бу юнәлешләрнең һәркайсын өйрәнүгә зур өлеш кертә. Өйрәнүнең төп принциплары итеп ул күтәрелгән мәсьәләләрне киң документаль җирлектә һәрьяклап тикшерү, аларны колачлы социаль-политик фонда карау, сыйнфый-партиячел якын килү, тарихилык, сүз белән эшнең берлеге кебек таләпләрне ала.

Г. Ибраһимов саналган агымнардан коммунистик матбугатны төп тикшеренү объекты итә, моның зур әһәмиятен ассызыклый. Бер яктан, бу матбугатның тарихы большевикларның ул чорында көрәшләре белән халкыбызны таныштыру, шул яктан тәрбия кылу өчен кирәк, икенче яктан, фән өчен зарур (6, 465).

Галим-публицист беренчеләрдән булып татар телендә чыккан листовка әдәбиятының бер өлешен өйрәнде, «Урал» газетасын, шул газета редакциясе нәшер иткән брошюраларны анализлады.

Ул «Урал» газетасының партия комитетлары җитәкчелегендә һәм алар ярдәмендә чыгарылуына аеруча басым ясый, аның большевиклар партиясе программасы буенча эшләвен ассызыклый. Ул, газетаның эчтәлеген өйрәнеп, андагы материалларны ике төркемгә аера. Беренчесе — гомум мәсьәләләргә кагылышлылары, икенчесе — татар тормышына караганнары.

Галим-публицист большевистик татар матбугатын Россиядәге коммунистик матбугатның состав өлеше дип карады. Шуңа күрәдер ул гомумән Россиядәге коммунистик матбугат белән дә кызыксынды. «Русиядә пролетариат матбугаты тарихыннан» дигән хезмәтендә ул бик белеп һәм шактый җентекләп рус телендәге пролетар прессаның юлын яктыртты.

Г. Ибраһимов революциядән соң партия-совет матбугатының һәр адымын күзәтеп барды; үз вазифаларын уңышлы үтәүче матбугат органнарын хуплады, җитешсезлекләрне күзгә карап әйтте, аларны бетерү юлларын күрсәтте («Пролетариат сүзе», «Дүртенче елга кергәндә», «Идеология фронтының ышанычлы көрәшчеләреннән берсенә» («Яшь эшче» журналының 1 еллыгы уңае белән һ. б.).

Галим-публицист тәүге пролетар журналистларга, аларның иҗатларына, журналистлык эшчәнлекләренә беренче бәя бирүче булды, корбан булганнарының изге ядкаре, исәннәренең иҗаты, яшәү шартлары турында кайгыртты.

Г. Ибраһимовның матбугат тарихын өйрәнүнең методологик һәм методик принциплары, алымнары исә — бүгенге тарихчыларыбыз өчен ышанычлы ориентирлар алар.

[1] Карагыз: Хасанов М. Галимджан Ибрагимов. Казань, 1977, 330—331 бб.

*Үзенең табигый истигъдады буенча беллетрист, сүз сәнгатьчесе булган хәлдә, Галимҗан Ибраһимов бик яшь вакыттан ук үзендә иҗтимагый бер тамырның бик нык типкәнен сизде. Бу тамыр иҗтимагый көрәшкә катнашырга каты рәвештә өнди иде.*

*Ул үзенең бөтен кыйммәтле көчләрен татар хезмәт ияләре файдасына хезмәткә багышлады.*

Профессор Н. Н. ФИРСОВ.

**Үзбәк Гыймадиев,**
филология фәннәре докторы

# Г. ИБРАҺИМОВ — «ЧУЛПАН» РЕДАКТОРЫ

Татар совет матбугатының тууы Г. Ибраһимов исеме белән аерылгысыз бәйләнгән. Аның матбугат өлкәсендәге киң колачлы эшчәнлегенең бер сәхифәсе — «Чулпан» газетасы редакторы буларак башкарган хезмәтләре. «Чулпан»ның беренче саны 1918 елның 18 январенда Петроградта чыкты. Ул чакта Үзәк мөселман комиссариаты председателенең урынбасары булып эшләгән Галимҗан Ибраһимов комиссариатның бу матбугат органын оештыручы, аның фактик редакторы булды.

«Чулпан» — илебездә татар телендә чыга башлаган беренче совет газетасы. Алай гына да түгел, Г. Ибраһимов үзе әйткәнчә, ул Россиядәге бөтен төрки халыклар арасында беренче зур, рәсми совет газетасы булды. «Чулпан» — хәзерге вакытта киң колач алган татар совет матбугатының башлангычы, беренче карлыгачы.

«Яңа социалистик газета» дигән хәбәрендә «Правда» (1918, 23 январь, 17 сан) болай дип язды: «Петроград шәһәрендә татар телендә «Чулпан» («Таң йолдызы») дигән социалистик, интернационалистик газета чыга башлады. Газета Эчке Россия мөселманнарының Милләтләр эше Халык Комиссариаты членнары тарфыннан чыгарыла... Ул мөселман хезмәт иясе массалары арасында социалистик идеяләрне киң пропагандалау һәм мөселман руханиларының реакцион йогынтысына каршы көрәш алып баруны максат итеп куя». «Правда» «атаклы татар язучысы Г. Ибраһимовның» газетада эшләвен аеруча күрсәтә.

Ул чактагы шартларда газетаны оештыру җиңел булмый. «Без хәбәр, тәрҗемәче тапмыйча, корректор тапмыйча бик җәфа чиктек, зур газетаның хәбәрләренәчә үзебезгә язарга туры килгән чаклар күп булды»,— дип хәтерли Ибраһимов соңыннан. Ләкин бу хәл күпкә бармый. Озакламый бер төркем сәләтле яшь журналистлар «үзләре теләп, яратып», совет газетасына эшкә килә. Билгеле, монда Г. Ибраһимовның шәхси авторитеты, оештыру сәләте зур урын тота. Аңа хат, телеграммалар аша гына түгел, төрле урыннарга барып, комиссариатта һәм газетада эшләү өчен кадрлар табарга, аларны өйрәтергә туры килә. Мәсәлән, 1918 елның февраль башында Ибраһимов шушы максат белән ашыгыч рәвештә Псков шәһәренә барып кайта. Тиздән Төньяк фронтының мөселман солдатлары комитетында һәм аның татар телендә чыгып килгән «Сугыш сафы» исемле газетасында эшләүчеләр — барлыгы унбер кеше — Петроградка эшкә күчәләр. Мәхмүт Алиев, Һади Килдебәков, Дулат-Али, Минһаҗ Конов кебек революционерларның, журналистларның газетада хезмәттәшлек итә башлавы, тәҗрибәле наборщикларның килүе эшне шактый җиңеләйтә.

«Чулпан»ның тиражы шул заман өчен шактый зур сан тәшкил итте: 20—30 мең чамасы булды. Газета, башлыча, губерна, өяз, волость советлары, җирле советларның мөселман комиссариатлары аша таратылды.

Совет хөкүмәте декретларын, күрсәтмәләрен халык массаларына җиткерү, аларның эчтәлеген аңлату, халыкны шул карарларны гамәлгә ашыруга туплау беренче совет

газеталарының төп бурычларыннан исәпләнде. Бу өлкәдә «Чулпан» һәм аның редакторы зур эш башкарды. Совет хөкүмәтенең беренче документлары Г. Ибраһимов тәрҗемәсендә басылдылар. Ул газетаның күп баш мәкаләләрен, юнәлеш бирүче материалларын гына түгел, вак хәбәрләрен дә язды.

«Чулпан»ның беренче санында баш мәкалә урынында Учредительное собраниене тарату турында В. И. Ленин тарафыннан язылган Декрет тәрҗемә итеп урнаштырылган. Шунда ук Г. Ибраһимовның «Мәрхүм Учредительное собрание» дигән мәкаләсе бар. Депутатның үз сайлаучыларына хисабы формасында язылган бу мәкаләдә Учредилканың чын йөзе ачып бирелә. Әдип анда контрреволюцион көчләрнең Учредительное собраниене властьны үз кулларына алу өчен корал итеп файдаланырга тырышулары һәм шуның өчен аның бик хаклы рәвештә куылуы турында яза. Ул халык массаларын Учредилкадан ваз кичәргә, бөтен өметне тик Советларга гына бағларга, шунда эшләргә чакыра. Чөнки, ди ул, «безнең икътисади» сәяси вә милли теләкләребез бөтенесе шуларда табыла... Без, ярлы халык, Октябрь революциясен көчәйтү, тирәнәйтү өчен эшче, солдат вә ярлы авыл халкы шуралары тирәсенә җыелырга, буржуазия белән мөнәсәбәтне тәмам өзәргә, икътисади коллыктан азат ителү юлында көрәшергә тиешбез».

Г. Ибраһимов Советларның III Бөтенроссия съездында тавыш бирү хокукы белән катнашып, аның эшен газетада яктыртты. Аның «Федерация, туфраклы мохтарият һәм шуралар хакимияте» (24 январь, 2 сан) һәм «Бөек бәйрәм! Җиргә социализация канун булып кабул кылынды!» (31 январь, 4 сан) дигән зур мәкаләләрендә съездның иң мөһим документларының эчтәлеге сөйләп бирелә, әһәмияте күрсәтелә.

Г. Ибраһимовның «Чулпан»дагы бер төркем мәкаләләре («Җиңеләләр! Идел-Урал җөмһүриятендә хакимият мәсьәләсе» (23 февраль, 6 сан), «Идел-Урал җөмһүрияте» (16 март, 10 сан), «Караңгылык эчендә» (8 март, 11 сан) һ. б.) территориаль автономия һәм власть мәсьәләсенә багышланганнар. Гамәлдә бу мәкаләләрдә татар һәм башкорт халыкларының үзбилгеләнү хокукын тормышка ашыру формалары турында сүз бара. Хезмәт иясе массаларының омтылышын чагылдырып, Г. Ибраһимов советлар нигезендә төзелгән автономия өчен ялкынлы көрәшче булды.

Г. Ибраһимовның газетада сугыш һәм солых мәсьәләләре буенча ясаган чыгышлары да игътибарга лаеклы. Яшь совет республикасының язмышы өчен бик мөһим булган Брест солыхы өчен көрәшнең кискен чорында (1918 елның февраль һәм март айларында) ул бу турыда өч тапкыр баш мәкалә язып чыга («Бөек өметләр алдында», «Авыр трагедия», «Шатлык түгел, мәҗбүрият»). Сул эсерлар һәм партия эчендә «сул коммунистлар» группасы солых договорына каршы котырынкы кампания ачкан вакытта, Ибраһимов зирәк акыллылык һәм килеп туган хәлне ленинча аңлавын күрсәтә. ВЦИК утырышында да, Советларның IV съездында да ул Ленин позициясендә тора. Ибраһимовның сул эсерларның өске катламы белән күптән башланган фикер каршылыклары бу вакытта аеруча кискен төс ала, ә Мәскәүдә сул эсерларның Советларга каршы фетнәсеннән соң, ул алар белән бәйләнешне тәмам өзә.

Г. Ибраһимов мәкаләләрендә («Чулпан» һәм комиссариат», «Татар матбугаты» һ. б.) «Ил», «Кояш», «Иттифак», «Тормыш» кебек контрреволюцион буржуаз газеталарның ялганнары, кара гайбәтләре, «Милли идарә» һәм башка шуныңише буржуаз оешмаларның реакцион асылы фаш ителә.

Урыннарда беренче татар совет газеталарының барлыкка килүе Үзәк мөселман комиссариаты һәм «Чулпан» газетасының эшчәнлеге белән бәйле. «Чулпан» ярдәмендә һәм аның үрнәгендә 1918 елда Казанда — «Эш», Оренбургта — «Мөхбир», Уфада — «Көрәш» — барлыгы 20 дән артык газета чыга башлады. «Чулпан» алар өчен абруйлы остаз, катлаулы политик көрәштә терәк булды. «Чулпан» битләрендә аларга күзәтүләр, аеруча мөһим материалларыннан өзекләр басылды. Г. Ибраһимов аларның идея юнәлешен билгеләүдә ярдәм күрсәтте, «Эш», «Көрәш» газеталарында үзенең мәкаләләре белән дә катнашты.

«Чулпан» 1918—1919 елларда 45 сан чыкканнан соң, Казан шәһәр советының мөселман комиссариаты органы — «Эш» газетасы белән кушылды. Димәк, «Чулпан»ны, билгеле бер дәрәҗәдә, хәзерге «Социалистик Татарстан»ның элгәресе дип исәпләргә мөмкин.

Совет дәүләт аппаратында энергияле эшен журналистлык эшчәнлеге белән кушып алып барып, Г. Ибраһимов ленинчыл милли политиканы тормышка үткәрергә булышлык итте, хезмәт ияләрен интернационалистик рухта тәрбияләде, илебез халыклары арасында дуслыкны ныгытуга булышлык итте.

## Флера Сафиуллина

# ХАЛЫКЧАН ҺӘМ СУРӘТЛЕ ТЕЛ

Г. Ибраһимов әсәрләрендә язма әдәби телнең иң күркәм традицияләре халыкның җанлы сөйләм теле белән органик рәвештә кушылып, үзенчәлекле яңгыраш барлыкка килә. Әлбәттә, бу ике стихиянең кушылуы табигый, көчле бер агым буларак формалашканчы, әдип зур тормыш һәм иҗат юлы үтәргә тиеш иде әле.

Әсәрдән-әсәргә Г. Ибраһимовның каләме чарлана килде. Ул «бизәк өчен генә бизәкләрдән», ясалма матурлыклардан арына барды, табигый һәм уйнак халыкчан тел белән яза башлады. Нәтиҗәдә, Г. Бәширов әйткәнчә, «...әгәр Габдулла Тукай халыкның поэтик рухын, аның тел байлыгын, ул телнең матурлыгын, тапкырлыгын һәм эчке мөмкинлекләренең чиксез икәнлеген шигырьдә ачкан булса, шуларны ук Галимҗан Ибраһимов прозада ачты...»

Г. Ибраһимов прозасында традицион язма тел үзенчәлекләре дәвам итә. Язучы аларны тагын да камилләштерә: салмак, эпик, саллы хикәяләр көчәя. Шул ук вакытта милли әдәби телнең халыкчан нигезләре салынган бу чорда Г. Ибраһимов матур әдәбият теленең җанлы сөйләм теленә таянып үсүен яклый, үз иҗаты белән шуның гына перспектив юл икәнлеген раслый. Әдип иҗатында матур әдәбият теленең нигез, традицион элементларын да, яңа туып килә торган прозаның әле бөреләнә генә башлаган үзенчәлекләрен дә күрергә мөмкин. Хәзерге прозада Г. Ибраһимовта булмаган бер генә тел-стиль, яисә хикәяләү чарасы да юк. Аннан соңгы чорда бу яралгылар, яңа тенденцияләргә әверелеп, тагын да үстерелгәннәр. Хикәяләүне җанлы сөйләмгә кору һәм сөйләм теле гыйбарәләрен күп куллану, «мин» исеменнән хикәяләү, лиризм, пейзажны тасвирлау, персонаж сөйләмен индивидуальләштерү, хикәяләүдә диалогларны күп куллану һәм аларны драматургиядәгечә — әйтүгә мөнәсәбәтле фигыльләрдән башка кертеп җибәрү, хикәяләүне үзенчәлекле, әеруча динамик башламнардан алып китү, еш кына кыска-кыска җөмләләр белән язу һ. б. үзенчәлекләре аша Г. Ибраһимов прозада стиль ягыннан үз сүзен әйтте.

Г. Ибраһимовның беренче чор иҗатына караган әсәрләре шул заман язма әдәби теле традицияләренә ияреп язылганнар. Аларда автор үзе хикәяли, персонаж сөйләме юк дәрәҗәсендә аз, хәтта алар урынына еш кына автор сөйли. Соңга таба «мин» исеменнән язылган әсәрләрдә теге яки бу иҗтимагый катлам вәкиле хикәяли башлый һәм шуларга бәйле рәвештә хикәяләү бертөслелектән, күпсүзлелектән котыла. Моңа хәтле өстенлек иткән хәбәр формалары (-ды, -де, -иде, -мыш, -меш) юкка чыга баралар. Әсәрләрнең сүзләр җыелмасы да үзгәрә бара. Моны дәлилли торган кызыклы гына бер эксперимент та эшләнгән. Г. Мөхәммәт «Татар телендә чит сүзләр» мәкаләсендә аерым язучыларның телендә рус, гарәп-фарсы, интернациональ сүзләрнең, төрки-татар сүзләренең кулланылыш дәрәҗәсен тикшерә («Безнең юл», 2 сан, 1927). Г. Ибраһимов теле буенча күзәтүләр шактый кызыклы. Аның беренче хикәяләрендә урыны-урыны белән 33 процентка җиткән гарәп-фарсы алынмалары, «Табигать балалары»нда 2,8 процентка кала, «Алмачуар»да исә бөтенләй бетә. Димәк, әдипнең теле киләксез, халык кулланмый торган алынмалардан арына барган саен, аның хикәяләвендә гадилек, табигыйлек, җанлы сөйләмгә хас самимилек, җыйнаклык, эмоциональлек арта бара. Ләкин һәр әсәрнең телен андагы иҗтимагый вакыйгалар, чорның үзенчәлеге, идея-эстетик юнәлеше белән бәйләп карау зарури. Шул чорның халык күтәрелешен, төрле мәсләкле иҗтимагый катламнар көрәшен, беренче рус революциясе чорын күрсәткән «Безнең көннәр» романында, мәсәлән, гарәп-фарсы алынмалары 8,5 процентка менә. Бу күзәтүләргә өстәп, тагын шуны да искәртеп китик: алынмалар автор сөйләменнән бигрәк, персонаж теленең үзенчәлеген чагылдыру өчен кулланылалар; биредә рус алынмаларының да заман пульсын күрсәтү өчен сизелерлек дәрәҗәдә артуын күрсәтергә мөмкин.

Әдипнең теле бай һәм халыкчан, ул кулланган сүз байлыгын әле хәзер дә тиешле дәрәҗәдә өйрәнелеп беткән дип әйтеп булмый. Беренчедән, ул кулланган сүзләрнең саны гына да ачыкланмаган. Бу үзе генә дә нихәтле зур күрсәткеч булыр иде. Икенчедән, бу сүзләрнең стилистик кулланылыш сферасы, катламнары тикшерелмәгән. Өченчедән,

әдипнең татар теленә алып килгән яңалыгы, үзе ясаган яңа сүзләре беркетелмәгән. Дүртенчедән, Г. Ибраһимов әсәрләрендәге фразеология гомумиләштерелмәгән, өйрәнелмәгән һ. б.

Боларны дәвам иттерергә мөмкин булыр иде. Тел гыйлемендә язучы теленең сүзлекләрен төзү практикасы бар. Безнең илдә Пушкин, Лермонтов, Шевченко сүзлекләре басылып чыкты. Пушкин 21 мең, Лермонтов 14 мең сүз кулланып язган икән. В. И. Ленин сүзлеген төзүчеләрнең мәгълүматы буенча, аның әсәрләрендә 35 мең сүз урын алган. Кайчандыр бездә дә Тукаебызның сүзлеге төзелгән иде. Кызганычка каршы, ул басылып чыкмый калды. **Безгә Г. Ибраһимов сүзлеген төзү кирәк.** Әдип дистәләрчә еллар буе татар әдәбиятының, культурасының үзәгендә торган. Аның телендә бу өлкәгә һәм шул елларга караган дистәләрчә мең сүз беркетелеп калган. Татар теле тарихын, шул катлаулы заманнарны чагылдырып, теркәп калдырган әдип иҗаты искиткеч бай чыганак булып тора. Заманнар үтәр, шул чорны үз күзләре белән күргән, үз авазын яңгыраткан, шул вакыттагы вакыйгаларны сурәтләгән әдип иҗаты тарихи документлар дәрәҗәсендә ышанычлы булыр. Халкыбызның хезмәт төрләре, һөнәрләре, тормышы-көнкүреше, авыз иҗаты, тормышы, аның гореф-гадәтләре, ышанулары, бәйрәмнәре, материаль һәм рухи культурасы, аңа караган бай сүзлек җыелмасы үзе генә дә ни тора!

Әдипнең сүз байлыгы турында күп язылды. Бу байлык татар телендәге барлык стилистик катламнарны үз эченә ала. Әлбәттә, иң кадерлесе — гомумхалык теле җәүһәрләре, гомумкулланылыштагы сүзләр. Телдәге һәрбер сүз, язучының каләме, тынгысыз йөрәге аша үтеп, сурәткә әйләнә. Чорның үзенчәлеген, геройларның иҗтимагый йөзен, характерын ачу өчен, язучы телдәге барлык сүзләрне дә куллана: бу — искергән сүзләр, тарихи сүзләр, яңа сүзләр; бу — гади сөйләм сүзләре, вульгар, дорфа сүзләр; бу — поэтик сүзләр; бу — китап теле сүзләре; бу — терминнар, профессиональ сүзләр... Әдәби әсәргә килеп кергәч, алар сурәт буларак кабул ителә башлыйлар. Г. Камал драматургиядә төрле иҗтимагый катлам, профессия кешеләрен үзенчә сөйләткән булса, Г. Ибраһимов шушы байлыкны прозада эшкә җигә. Гади сөйләм сүзләренең, мәсәлән, кулланылу ешлыгы аеруча зур. Әдип аларны иң беренче чиратта персонаж сөйләменең үзенчәлекләрен бирү максатында куллана.

Әдәби телне баетуда, бигрәк тә автор сөйләмен, автор хикәяләвен шигъриләштерүдә дә Г. Ибраһимовның зур өлеше бар. Поэтик лексиканың һәм синтаксисның матур үрнәкләре романтик характердагы әсәрләренә карый («Диңгездә», «Уты сүнгән җәһәннәм», «Табигать балалары», «Казакъ кызы» һ. б.). Еш кына табигать күренешләренә бәйле мондый бизәкле сүзләр аша язучы билгеле бер халәт тудыра, илаһи бер яңгыраш барлыкка китерә. Бу мәгънәдә Г. Ибраһимов Ф. Әмирханның поэтик синтаксисын хәтерләтә, әмма фразаларының җиңеллеге, кыскалыгы, уйнак булуы белән аннан аерыла.

Без тел тарихын хәзер җирле сөйләшләрдә сакланып калган сүзләр, гыйбарәләр, этнографик детальләр аша өйрәнәбез. Диалектологларыбызның халыктан язып алган өзекләрен сокланып укыйбыз. Аларда элеккеге туйлар, бәйрәмнәр, җыеннар, гореф-гадәтләр, ризыклар, уеннар һ. б. турында сөйләнә. Шул ук нәрсәләр Г. Ибраһимов әсәрләрендә дә тулып ята. Бу мәгънәдә язучының әсәрләрен XIX йөз ахыры, XX йөз башы татар тормышының энциклопедиясе дип атарга мөмкин.

«Татар хатыны ниләр күрми» повестенда Гөлбануның килен булып төшү картинасын гына искә алыйк: кыз сорарга бару, никах мәҗлесе, «ишек бавы», зөфаф кичәсе, авыл яшьләренең киенү-бизәнүләре, арчилар, килен бүләге тутырган сандык, киленне каршылау, ак сөзмә белән буяшу, килен бирнәсен өйгә элеп кую, киленгә беренче тапкыр су юлы күрсәтү, яшь киленнең кияү өендәге беренче көне, туй көнне мылтык ату, туй мәшәкатьләре һ. б....

«Алмачуар»дагы сабантуй, җыен күренешләре, аерым әсәрләрендәге авыл хезмәте поэтикасы, печән чабу... Боларның барысын да халык тормышының тирән катламнарын яхшы белгән, аның гореф-гадәтләрен, бай, сурәтле телен яхшы аңлаган оста художник кына шулай яза ала.

Шәкерт тормышының бөтен яклары «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы», «Безнең көннәр»нең аерым бүлекләрендә энциклопедик яктырту алган. Бу тормышка гыйбарәләр, сүзләр, әйләнмәләрне Г. Ибраһимов, әйтерсең, безнең тарихыбыз өчен махсус теркәп калдырган.

«Казакъ кызы» повестенда Г. Ибраһимов хөр дала балаларының тынгысыз, шаулы, мәшәкатьле тормышын сурәтләде. Бу әсәрнең сулышы башка: монда иксез-чиксез дала,

аның хәр күңелле бүз егетләре, кыз-кыркыннары, кабилә арасындагы ызгыш-талашлар, халыкның аңы уяну, ирекка сусау... Шушы дөньяны Г. Ибраһимов безгә үзенчәлекле казах лексикасы, геройларның исемнәре, җир-су атамалары, этнографик детальләр һәм сүзләр, казахча гыйбарәләр һәм үзенчәлекле интонация аша сурәтли. Аерым урыннарда шәрык дастаннарына, әкиятләренә хас алымнар да куллана.

Җанлы сөйләм үзенчәлекләрен әдип иң беренче чиратта персонаж сөйләмендә куллана. Персонаж сөйләме реплика-кабатлауларга, грамматик һәм лексик кабатлауларга бик бай. Әдип аларның күп төрле калыпларын әдәби әсәр битләренә алып керә. Беренче чор иҗатында очрамаган бу үтемле чара әсәрдән-әсәргә арта бара, язучының халыкчан телгә һаман якынаюының бер дәлиле булып тора: «Анысы алай да бит, атасы, елауның елавы бар шул» («Татар хатыны ниләр күрми»). «Иртәгә барсам барырмын» («Көтүчеләр»). «Адәм бу чаклы үзгәрсә үзгәрә икән!» («Кызыл чәчәкләр»)...

Г. Ибраһимовтан килә торган тагын бер стиль чарасы бар. Бу — өч тапкыр кабатлауга корылган синтаксик тезелмәләр. «Яшь йөрәкләр»дән «Тирән тамырлар»гача килгән әлеге алымны Г. Ибраһимов фразаны аһәңлерәк итү максатында куллана: «Әмма бусы инде, гакылың да китәр, шундый дәртле, шундый дәртле, шундый дәртле!» («Яшь йөрәкләр») «...туктап су эчәргә ирек бирмәстән, каядыр куа да куа; куа да куа; куа да куа» («Кызыл чәчәкләр»). «...чабалар, йөгерәләр, кычкырышалар, елыйлар, елыйлар, елыйлар! («Кызыл чәчәкләр») һ. б.

Г. Ибраһимовның хикәяләүгә алып кергән яңалыгыннан тагын берсе — өченче кеше сөйләмен бирү. Бу, бер яктан, татар халык әкиятләренә барып тоташса, икенче яктан халыкның җанлы сөйләм теле үзенчәлеген әдәбиятка алып керә: «Әнә, ди, хәзрәт килгән, ди, Идел буйларын күреп йөрер идем, ди, син, ди аны йөртеп кайтар, ди» («Тирән тамырлар»). «Бер базар көн, дип әйтә ди, телеграм алынды...» («Кызыл чәчәкләр»). «Мин дип әйтеп әйтә имеш, ди, йортымдагы актык казыгым беткәнче тырышам мин...» («Яшь йөрәкләр»).

Халыкның җанлы сөйләм теленә тартымлык язучының кушма җөмлә оештыруында да сизелә: ул аерым җөмләләрне, сөйләм телендәгечә, теркәгечләрдән башка гына, интонация аша гына бәйләнешкә кертә: «Бу малайның күз карашы йөрәгемә төште, тавышы, акыллы сүзе бөтенләй хәлемне бетерде» («Кызыл чәчәкләр»). «Нидәндер телләр аз сөйли, күзләр авыр, кайгырып карый» («Яшь йөрәкләр»). «Тышта җил туктады, тәрәзәдән күкнең кечкенә бер кисәге күренде — анда болытлар таралган, йолдызлар ялтырыйлар иде» («Казакъ кызы»).

Г. Ибраһимов матур әдәбият теленең нигезе итеп халыкның җанлы сөйләм телен саный. Аның уенча, яңа формалар, яңа «калыплар кемнеңдер кабинетында уйлану юлы белән түгел, бәлки революция мәйданнарында, урам митингларында, кызыл казарма эчендәге әдәби түгәрәкләрдә, татар пролетариатының кайнаган урыннарында боларның направлениесе биреләчәк, шуннан кузгалып, профессиональ әдәбиятчылар каләмендә үзенең ахыр матурлыгын табачак. Ягъни яшь көчләребез форманы китаптан яки үзләренең миләреннән эзләмәсеннәр, моның өчен массаның үзәгендә булсыннар...» (Әдәбият мәсьәләләре. Казан, 1960, 181 б.).

Г. Ибраһимов татар әдәбиятында персонаж сөйләмен индивидуальләштерүче оста буларак та танылды. Бу осталыкка ирешү юлында күп эзләнүләр кирәк иде. Беренче иҗат тәҗрибәләрендә, беренче хикәяләрендә автор сөйләме белән персонаж сөйләме арасында аермалар сиземләнми диярлек. Лирик герой сөйләме аша сурәтләнгән персонажларның сөйләмендә үзенчәлекле бизәкләрне табу мөмкин түгел әле. Әмма Г. Ибраһимов «мин» исеменнән язылган хикәяләрендә халык арасыннан, тормышның төбеннән чыккан геройларның үз авазларын, үз тавышларын табарга омтыла, шулар сөйләме аша хикәяләүнең үзенчәлекле һәм яңа стилен барлыкка китерә.

Романтик рух белән сугарылган бу хикәяләрдә Г. Ибраһимов үткәндәге мәхәббәт белән яши торган карт шагыйрьнең дә («Сөю — сәгадәт»), рухына тынычлык эзләп йөри торган яшь лирик геройның да («Диңгездә»), изелгән карт ялчының да («Карт ялчы»), карак мулланың да («Карак мулла»), көтүче малайның да («Көтүчеләр»), самими хисләр җырчысы Хафизның да («Табигать балалары») сөйләменә генә хас булган сүзләр, гыйбарәләр, җөмләләр яңгыраш тапкан. Шуның белән бергә алардагы романтик рух һәртөрле кабатлаулар, риторик эндәшләр һәм сораулар, тойгыга бай сорау һәм хикәя җөмләләр, үзенчәлекле поэтик лексика һәм иң әһәмиятлесе — халыкның җанлы сөйләм теле белән тәгъбир ителгән.

Г. Ибраһимов хикәяләвендә ул заман өчен яңа булган, килеп чыгышы белән җанлы, табигый, алдан уйланмаган сөйләмгә бәйле булган керешмәләр дә кулланыла башлый-лар: «Якында гына, кигәвеннәрдән үзен кая куярга белми дулап, арканына уралып, дүрт аягы бергә килеп беткән соры бия бар икән, шуны тиз генә җиктек тә, Әсманың энесе (минем кайнишем булыр, ходай кушса!) белән кайтарып җибәрдек» («Табигать балалары»). «Зыяның атасы Җәләш (Җәләлетдиннән үзгәртелгән) хәзрәт кыяфәте белән бабаларына охшый...» («Яшь йөрәкләр»). «Балалар укытырга (ләгънәт төшсен шул гәзитләргә!) икенче бер манигъ чыкты» («Габдрахман Салихов»).

Г. Ибраһимов татар прозасына тагын бер яңалык алып керде. Моны Г. Нигъмәти «Г. Ибраһимов һәм аның әдәби иҗат юлы» дигән мәкаләсендә сиземләсә дә, әле тиешенчә аңлатма бирә алмый, чөнки бу алым татар әдәбиятында ул чорда юк диярлек. Соңыннан татар әдәбиятында уртак сөйләм дип аталачак күренеш турында бара сүз. Өлгергән проза өчен генә хас бу алымның «Яшь йөрәкләр» әсәрендә кулланылуын әйтеп, Г. Нигъмәти алда күрсәтелгән мәкаләдә болай дип яза: «Яшь йөрәкләр»дә еш очрый торган бер сөйләү төре — әдипме яки каһарманмы әйткәнлеге турында шөбһә калдырырлык итеп бирелгән фразалар булып, гадәттә әдип үз каһарманнары кичерешенә хикәя итүченең дә (монда авторның) катнашканын, бүлешкәнен күрсәтергә теләгәндә, мондый алымнан файдалана (Сайланма әсәрләр. Казан, 1958, 86, 89 б.).

Чыннан да, Ш. Мөхәммәдев, Ш. Камал әсәрләрендә сиземләнеп килгән бу алымны кулланырга Г. Ибраһимов үзенең моңа хәтле язылган романтик, лирик әсәрләре белән инде әзер була. Җанлы сөйләмнең әдәби әсәр тукымасында күпләп урын алуы, автор һәм персонаж сөйләменең синтаксик-структур яктан кискен аерылган булуы, диалогларның күп кулланылуы, һәм иң мөһиме, проза жанрының татар әдәбиятында тәмам формалашып җитүе хикәяләүдә уртак сөйләмнең барлыкка килүенә сәбәп була. Уртак сөйләм инде әдипнең башка әсәрләрендә дә кулланыла башлый: «...малай яшь җиңгәсен бөтенләй үзенә дус кебек тоеп китте. Бүген утауда ул инде бөтен күңеле белән ярата башлады. Көн буе сабан сөрергә, тырма тырматырга, печән җыярга, урман, көлтә ташырга — һәммәсенә Миңлегалим риза, һәммәсен, эт булып арса да, яратып эшли. Әмма менә утау — аның дошманы! Бил дә авырта. Билчәннәр кулны да чәнчә. Эшләгән эшең дә күренми. Ул ел да шулай сукрана, җае чыкса, башка эшкә күчү ягын карый иде. Бүген дә дәртсез килде, һаман билен тотып, борынын казып, утамый азапланды. Шулай да алыны артта калмады. Менә бәхет! Яшь җиңгәсе башын да күтәрми, һаман утый да утый, утый да утый! Үзенеке белән бергә ялкау малайның алынын да сыдырып алып бара. Менә бит уңган җиңгәң белән янәшә туры килсәң, ничек рәхәт икән! («Татар хатыны ниләр күрми»). Күрүебезчә, монда малайның уйлары автор сөйләме белән керешеп китеп, үзенчәлекле хикәяләү барлыкка килгән.

Татар прозасына алга таба үсешенә Г. Ибраһимов тагын бер яклап тәэсир итте. Бер төрле хәбәрләр, аларның һәрвакыт җөмләне тәмамлап куюы прозада монотонлык тудыра иде. Г. Ибраһимов исә хикәяләүгә төрле төзелештәге, бигрәк тә сорау һәм тойгылы җөмләләр китереп кертә, еш кына инверсияләр куллана. Шул рәвешле хис, тойгы, кичерешләрне сурәтләүдә яңа алым барлыкка килә.

Г. Ибраһимов әсәрләрен тикшерүчеләр әдипнең башлам җөмләләрен һәрвакыт телгә алалар. Аларның фикерләрен кабатламыйча, Г. Ибраһимовның бу өлкәдәге яңалыгын гына билгеләп үтик. Моңа хәтле татар прозасындагы башламнарның бер төре әкиятләрдән килгән юнәлештә булса, икенче төре язма әдәбият традицияләренә нигезләнгән булып, үзенең зур күләме, еш кына әдәби әсәрнең композициясенә бәйләнешсез характеры белән аерылып тора иде. Г. Ибраһимов киеренке, динамик башламнары белән әдәбиятта үз сүзен әйтте, киләчәктә татар әдәбиятындагы башламнарның үсеш юнәлешен билгеләде. Хәзер аңа ияреп язылган башламнар бик күп булса да, «Фәхрине үтереп ташладылар» («Тирән тамырлар») һәм «Без түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелдек» («Кызыл чәчәкләр») кебек башламнар сирәк очрый.

Әйе, Г. Ибраһимов ил яшәешенә тыгыз бәйләнгән татар тормышының «каты көрәшле, күп катлаулы, бай, каршылыклы, тирән процессларын» сурәтләү өчен телебезнең барлык мөмкинлекләрен, катламнарын осталарча эшкә җиккән. Ул үз иҗаты белән татар прозасын өлгергән, зур әдәбиятлар дәрәҗәсенә күтәргән. Ул үзеннән соң килер әдәбиятның үсеш тенденцияләрен сызымлаган. Татар прозасының хәзерге казанышларында, тел-стиль үзенчәлекләрендә без бөек әдипнең тәэсирен күрәбез, аны тоябыз.

# Мөхәммәт Мәһдиев

## ТАТАРЛАРДА РӘСЕМ СӘНГАТЕ ҺӘМ ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ

Безнең әдәбиятта рәсем сәнгатенә карата җиңелчә бер фикер урын алган: имеш, татарда 1905 ел революциясе нәтиҗәсе буларак, рәсем сәнгате дә туган, ягъни, театр, матбугат тугач, музыка сәнгате үзенә юл алгач, нигә әле рәсем сәнгате дә тумасын?

Бу — хата фикер. Рәсем — ул сәнгатьнең специфик төре. Әгәр җырлау, бию, импровизация (башка кеше булып сөйләшеп яки хәрәкәтләнеп күрсәтү) бик күп кешеләр өчен элементар формада гына мөмкин булса да, музыка коралында уйнау, көй чыгару, рәсем ясау — аерым шәхесләргә генә бирелгән табигать бүләге. Ләкин «табигать бүләге» белән генә дә булмый әле. Аерым бер милләттә сәнгатьнең бу төре үсеп китсен өчен, ягъни конкрет бер шәхес композитор, рәссам булып формалашып үсеп китсен өчен иң беренче чиратта, әлбәттә, традиция кирәк. Татарда исә рәсем сәнгатенең традициясе юк дәрәҗәсендә һәм моның, әлбәттә, тарихи сәбәпләре бар иде.

Бу сәбәпләргә егерменче гасыр башында Тукайлар, Җ. Вәлидиләр, Әмирханнар игътибар иттеләр. Әмма рәсем сәнгатенең тарихи миссиясен татар халкына аңлатып бирүдә төп рольне Галимҗан Ибраһимов уйнады. Бу мәсьәләдә ул да традициягә таянды. Традиция исә Шиһабетдин Мәрҗанидән килә иде...

Дин тарихын аз гына белгән, үз гомерендә турист буларак кына да бер-ике мәчет күргән кеше сизә, аңлый: ислам дине кеше сурәтен бирү белән бик артык мавыкмаган. Мәчетләр үзләренең архитектура сыйфатлары (мозаика, витраж һ. б.) белән күзеңнең явын алып утырсалар да, аларның эчендә христиан чиркәүләрендә, храмнарындагы кебек кеше сурәтләре, сюжетлы картиналар (роспись) юк. Нигә шулай? Ислам дине рәсемне шул дәрәҗәдә тыйганмы?

1905 ел революциясе белән кузгалган татар демократик яшьләре рәсем, музыканы шәригать коллыгыннан азат итү процессында Мәрҗани фикерләрен корал итәләр. Казанның, гомумән, татар халкының иң зур, абруйлы мулласы Шиһабетдин исә кадимчеләрнең рәсемне тыеп килүләрен үзенең бер-ике вәгазе һәм бер-ике хәрәкәте белән юк итә.

«Ислам дине рәсемне тыя, рәсемгә төшү — гөнаһ» дип авызларыннан төкерек чәчә-чәчә исбат итеп килгән динчеләр бервакыт телсез калалар: динчеләрнең иң зурысы һәм иң абруйлысы, галим Ш. Мәрҗани, Америкадагы бер бизнесменның үтенече буенча рәсемгә төшеп, почта аша аңа җибәрә. Бу хәбәр халыкка тарала. Бераздан аның рәсемен Лондондагы бер гыйльми җәмгыять сорый. Мәрҗани моңында инде рәсеменә кыскача автобиографиясен дә кушып сала. Шулай итеп Мәрҗани татар муллаларыннан беренче буларак фотообъектив каршына баса. «Безнең халык бик гаҗәпкә калыр инде,— дип сөйли ул рәсемгә төшкәч.— Аларны «төрекләр дә рәсемгә төшә,— дип кенә тынычландырып булмас, Бохара әмиренең дә рәсеме бар»,— дисәң генә тынычланырлар».

Шулай да рәсем сәнгатен кадимчелер коллыгыннан азат итәр өчен үзең рәсемгә төшү фактының гына җитмәвен Мәрҗани аңлый, әлбәттә, һәм ул, тарихчы буларак, шәригатькә таянып рәсем сәнгатен тыеп килүнең тарихи тамырларын эзли һәм вәгазьләрендә моңа кат-кат туктала. Тарих исә менә моннан гыйбарәт икән: ислам дине тугач та мәҗүсилеккә каршы көрәшкән. Бу көрәш рәхимсез, компромиссыз булган. Мәҗүсиләр исә сурәткә (пот) табынганнар. Бу көрәш процессында сурәткә аз гына йомшаклык күрсәтү гарәпләрнең яңадан потпарәстлеккә (мәҗүсилеккә) кайтуына юл калдыруы мөмкин. Шунлыктан Мөхәммәт вакытында һәртөрле сурәт нык тыелган. (Игътибар итик: «Кыйссаи Йосыф» поэмасында шундый эпизод бар. Зөләйха үзенең сараенда Йосыф белән гыйшык уйнарга теләгәч, Йосыф бер санәмгә (потка) күрсәтә: «Әнә бит, аллаң карап тора»,— ди. Зөләйха шунда потның өстенә шәлен ябып куя. Бу хәл намаз укучы әби-бабаларда да дәвам иткән. Намаз укырга утыр-

гәндә, алар стенадагы рәсем, календарь һ. б. әйберләрне каплап куялар. Ләкин Мәрҗани бу гадәтнең хәзер кирәксез, мәгънәсез икәнлеген гап-гади формада ачып бирә: «Хәзер исә мөселманнарның мәҗүсилеккә кире кайту ихтималлары юк, шуңа күрә рәсемгә тыю юк».

Татар интеллигенциясе 1905 ел революциясе көннәрендә Мәрҗанинең бу фикерләрен күтәреп ала һәм сәнгатьне шәригать коллыгыннан азат итү өчен көрәш башлый.

Рәсем сәнгатенең теоретик мәсьәләләре бөтен җитдилеге белән Г. Ибраһимов тарафыннан күтәрелә. 1910 елда аның зур күләмле «Рәссамлык» исемле мәкаләсе «Йолдыз» газетасында басыла. Татарлар арасында бишенче ел революциясеннән соң театр, әдәбият, музыканың җанлануы турында әйтеп автор рәссамлыкны шул театр, музыка «белән туарга тиеш булып та, ни өчендер тумый калган бер нәрсә» дип атый. Г. Ибраһимов карашынча, рәсем сәнгате ул «коры бер күңел ачу вә кызыклану өчен генә» түгел, ә бәлки культуралы кешелек дөньясының аралашу теледер. «Рәсемнәр каршында француз, немец вә рус аермасы юк. Күзе, зәвыгы вә хиссияте булган һәр адәм рәсемнәрнең әйтергә теләгән мәгънәсен, теләсә кай кавемнән булса да, аңлый вә хис кыйладыр».

Бу чор — Г. Ибраһимов һәм Тукайның сәнгать тарихы белән мавыккан еллары. Л. Н. Толстойның «Об искусстве», «Что такое искусство?» дигән хезмәтләре дөньяга чыккан, татар зыялыларының шуларны йотылып укыган чоры. Г. Ибраһимов яза: Толстой кыйммәт торган, күп расходлар таләп иткән купшы рәсемнәрне бик үк яратып бетермәсә дә, «авыл крәстияннәренең ярым-ялангач балаларының җылашып торулары кеби аяныч манзараларны рәсем белән күрсәтергә дәгъвәт кыйладыр».

Г. Ибраһимов бу мәкаләсендә татар халкының рәсем сәнгате буенча традициясе булмавына борчыла һәм форсаттан файдаланырга чакыра: 1905 ел революциясе мөмкинлекләр ачты бит! Шул мөмкинлекләрне әрәм итмәскә иде! «Халкымызның мөтәхәссис кыйсьме,— дип яза ул,— татар дөньясының рәсем һөнәреннән, рәссам вә рәсемнәрдән көлләи мәхрүм булуын зур вә тиздән тутырырга тиешле булган бер бушлык саныйдыр» [1].

Г. Ибраһимов рәсем сәнгате мәсьәләсен татар халкына мөнәсәбәттә фәлсәфи-тарихи планда куя. Аныңча, татар халкының үз художнигы булмау, бу халыкның талантсыз булуыннан түгел, бәлки талантлар туу өчен билгеле бер «хәят юклыгыннан». Димәк, самодержавие шартларында талантлар һәлак була, үсә алмый.

Татарның үз рәссамын булдыру, үстерү турында «Йолдыз», «Кояш» газеталарының идарәләре дә талпынып карыйлар: рәсем ясарга сәләтле егетләр эзлиләр, тапканнарына матди ярдәм күрсәтәләр, укырга урнаштыру якларын кайгыртalар. Әлбәттә инде, ялгызларга ярдәм оештыру юлы белән генә сәнгатьнең язмышын хәл итеп булмый. Г. Ибраһимов моның шулай икәнлеген бик яхшы аңлый һәм сәнгать мәсьәләсен тарихи-фәлсәфи планда өйрәнә. Ул эшләгән «Аң» журналы подписчиклар санын арттыру максатында аларга 1915 ел өчен бүләк итеп «Альбом» әзерли. «Альбом»ның максаты — татар яшьләрен сәнгать әсәрләренең репродукцияләре белән таныштыру. «Сәнаигы нәфисә мәҗмүгасы» исеме белән чыккан бу альбомга кереш сүзендә Г. Ибраһимов дөнья сәнгате үсешенең тарихи этапларын күрсәтеп чыга. Борынгы Греция «Сәнаигы нәфисәсенең» бөтен кешелек дөньясы өчен матурлык идеалы булып торуын әйтү белән Г. Ибраһимов Маркснең сәнгать теориясенә бик якын килә. Мәгълүм булганча, К. Маркс борынгы грекларның «нормаль бала» булуын һәм алар тудырган сәнгатьнең бүген дә гүзәллек үрнәге, сәнгатьнең соклангыч самими «балачагы» булганын язган иде.

«Альбом»га сүз башы — Г. Ираһимовның шул чордагы дөньяга карашларының сыгынтысы. Монда халык тормышын басып яткан «кара ташлар», киләчәктә өмид ителгән «кояш ачылу»лар, «шифалы яңгырлар» турында сүз бара. Болар мисалында без Г. Ибраһимов публицистикасындагы образлылык белән әдәби әсәрләрендәге образлылыкның бердәм система тәшкил иткәнен күрәбез. Татарда ни өчен Рафаэльлар, Микеланджелолар юк? Чөнки халыкның «сәнаигы нәфисә орлыгын» зур бер таш каплап тора. Шул ук вакытта, Г. Ибраһимов бу ташның соңгы вакытларда ярыла башлавын әйтә. Игътибар итик: бу — Тукайдан килә. 1910 елда «Шәрык клубы»нда сөйләгән лекциясендә Тукай болай дигән иде: халык әллә нинди кара көчләр

[1] Мөтәхәссис кыйсьме — белгечләр; көлләи — бөтенләй.

басканга күрә генә, бу күренештә йөри. Ләкин бу хәл, вакытлы гына килгән бер авыру кеби, гаризый бер хәлдер». Димәк, демократик әдәбият вәкилләренең тарихи барышка мөнәсәбәтләрендә, дөньяга карашларында уртак нокталар булган. Бу карашларның нигезен исә тарихи оптимизм тәшкил иткән. «Әдәбият туды, музыка белән тәрсссем туарга якын бер хәлдә. Бу аның туар заманының якынланганын төрле галәмәтләреннән күрәбез һәм аларны тудырырлык һава вә туфрак безнең хәятыбызда да ясалып килгәнен хис кылабыз... Өмид ки: кояш ачылыр, һава төзәлер, рәхмәт яңгыры явар — шуның соңында без дә көткәнебезне күрербез».

Г. Ибраһимовның бу хезмәтендә тарихи барышны дөрес сиземләү, материалистик фикер йөртү өстенлек итә. Ләкин бу вакытта әле марксистик әзерлеге булмау язучыны сәнгатьне иҗтимагый тормыштан аерып карауга китерә. Г. Ибраһимов сәнгатьнең туу сәбәпләрен кешенең биологик ихтыяҗларына кайтарып калдыра һәм идеалистик эстетикага ташлама ясый.

Ләкин сәнгать тарихында зур бер эш эшләнә инде: рәсем сәнгатен дин коллыгыннан азат итү юлында беренче әһәмиятле адым ясала. «Рәсемне шәригать тыя» дигән уйдырма тулысы бәлән юкка чыгарыла, рәсем сәнгатенең рухи тормыштагы гуманистик роле исбат ителә. Г. Ибраһимовның сәнгатькә кагылышлы хезмәтләре тәэсирендә бөтен бер буын татар яшьләре тәрбияләнә.

Г. Ибраһимовның сәнгать турындагы мәкаләләре, эзләнү-фикерләү алымнары бүгенге көн өчен бик тә гыйбрәтле. Кайсы ягы беләнме?

XX гасыр башы әдипләре әдәбият белән сәнгатьне бербөтен итеп караганнар. Әдәбият тәнкыйтьчесе ул чорда сәнгать тәнкыйтьчесе дә булган Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Ш. Әхмәдиев кебек шәхесләр публицистик яки тәнкыйть хезмәтләрендә күп очракта рәсем, музыкага кагылышлы фикерләрен әйтә барганнар. Сәнгать тәнкыйтенең алгы сызыгында зур теоретик багажы белән Г. Ибраһимов торган. Гыйбрәтле диюебез шунда, бүгенге тәнкыйтьчеләребез, язучыларыбыз сәнгать мәсьәләләренә бөтенләй кагылмыйлар, бу өлкәне читләтеп узалар. Безнең рәсем сәнгатебез, мәсәлән, бөтенләй үзбашка яши. Әйтер сүзләр күп булырга тиеш иде, югыйсә. Моның шулай икәнлегенә Тукайның тууына 100 ел тулуга багышланган рәсем күргәзмәсе ишарә ясады. Рәсем сәнгатендә Тукай образы тудыра алмаганбыз икән бит. Рәссамнарыбыз бу юнәлештә әле һаман эзләнәләр генә икән! Менә кайда кирәк ул Г. Ибраһимов каләме! Менә кайда кирәк Тукайлар, Әмирханнар сүзе! Г. Ибраһимовның сәнгатькә багышланган хезмәтләрен укыганда, шулай, ирексездән бүгенге язучыларыбыз, тәнкыйтьчеләребезнең сәнгатьтән аерылганлыклары турында уйлап сыкранып куясың...

---

*Г. Ибраһимов ару-талуны белми торган гаҗәп зирәк һәм булдыклы, зур талант ияләренә генә хас күпкырлы бер эшлекле иде.*

Г. ТЕРЕГУЛОВ, профессор, медицина фәннәре докторы.

*Галимҗан ага бик ягымлы, йомшак күңелле, үткен карашлы, киң колачлы галим иде.*

Х. МӨШТӘРИ, физика-математика фәннәре докторы, профессор.

---

## БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

СОРАУ:

— Әдип исемен йөртүче Институтның эшчәнлеге, Г. Ибраһимовның иҗат мирасын барлау һәм дөньяга чыгару өлкәсендәге хезмәтләре турында сөйләсәгез иде.

МИРФАТИХ ЗӘКИЕВ, филология фәннәре докторы, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры:

— СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты һәм аның хезмәткәрләре татар әдәбиятының атаклы классигы, галим һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов эшчәнлеген, аның тормышын, иҗатын күп еллардан бирле өйрәнеп, пропагандалап киләләр.

1956 елда Татарстан китап нәшрияты Г. Ибраһимовның институтның өлкән галиме филология фәннәре докторы Гали ага Халит тарафыннан төзелгән өч томлык «Сайланма әсәрләре»н бастырып чыгарды. Шул вакыттан бирле Галимҗан Ибраһимов исемендәге Институт әдип иҗатын өйрәнү һәм пропагандалау буенча төп үзәк ролен кулыннан төшергәне юк. Институтның гыйльми хезмәткәрләре Г. Ибраһимов иҗаты буенча төп белгеч булган Мансур Хәсәнов җитәкчелегендә әдипнең сигез томлыгын әзерләделәр. Моның өчен әдәбиятчы-текстологлар көче белән бөек әдипнең күп санлы басма органнарда таралып яткан каләм мирасы фидакарьләрчә тупланды, басмага хәзерләнде, аларга тәфсилле аңлатмалар язылды. Шуның белән Галимҗан Ибраһимовның зур иҗат мирасы бүгенге һәм киләчәк буын укучылар өчен ачык булган бер бай хәзинәгә әйләнде. Бу эшне башкаруда Рашат Гайнанов, Сәлам Алишев, Фазыл Фәсиев, Лена Гайнанова һ. б. катнашты. Бүгенге көндә әдип әсәрләре җыелмасының җиде томы дөнья күрде инде.

Сигез томлык җыелма Галимҗан Ибраһимовның бай һәм күпкырлы әдәби, фәнни һәм иҗтимагый эшчәнлеген чагылдырган зур хезмәт булачак. Институтта Г. Ибраһимовның әдәби, фәнни әсәрләрен тикшерү өлкәсендә фәнни мәкаләләр языла, конференцияләр уздырыла, диссертацияләр яклана. 1965 елда Институт хезмәткәрләренең коллектив хезмәте «История татарской советской литературы» Мәскәүдә «Наука» нәшриятында басылган иде. Анда бөтенсоюз укучысына әдәбиятыбыз классигы Г. Ибраһимовка багышланган сәхифәләр дә тәкъдим ителде (авторы Гали Халит) һ. б. 1974—1975 елларда Институтның фәнни хезмәткәре Искәндәр Абдуллин олы әдибебезнең 30 дан артык билгесез хатларын һәм үзе төзәтмәләр керткән бер китабын, Алма-Ата шәһәреннән табып, Татарстанның Бәрләштерелгән дәүләт музее каршындагы әдәбият бүлегенә тапшырды.

1967 елдан башлап Институт Галимҗан Ибраһимов исемен йөртә.

1977 елның 15 мартында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында әдипнең тууына 90 ел тулуга багышланган зур фәнни конференция уздырылды. Конференциядә Институт һәм Казан, Мәскәү, Ташкент, Уфа шәһәрләреннән килгән әдәбиятчы галимнәр доклад ясадылар. Конференция чын мәгънәсендә халыклар дуслыгы бәйрәме төсендә үтте. Аның материаллары 1980 елда Казанда, рус телендә «Писатель, революционер, ученый» исемендә аерым җыентык рәвешендә басылып чыкты.

1983 елда Институтның фәнни хезмәткәре Рәфыйк Мөхәммәтшин Галимҗан Ибраһимовның иҗтимагый фикер карашларын өйрәнүгә багышланган темага кандидатлык диссертациясе яклады.

Галимҗан Ибраһимов исемендәге Институт коллективы бөек әдипнең тууына йөз ел тулу көннәренә зур хәзерлек алып бара. 1987 елның мартында зур фәнни конференция уздырылачак. Институтта Галимҗан Ибраһимовның музей бүлмәсен оештыру планлаштырылды. Анда әдипнең кульязмалы, автографлы китаплары, фоторәсемнәре, аның әсәрләре басылган көндәлек матбугат үрнәкләре һ. б. куелачак. Институтның фәнни хезмәткәрләре Татарстан матбугаты битләрендә мәкаләләр белән чыгыш ясаячаклар.




**Бөркет Исхаков,**
язучы

# Г. ИБРАҺИМОВ ҺӘМ КАЗАХ ӘДӘБИЯТЫ

Татар әдәбияты күгендә балкыган якты йолдызларның берсе — Галимҗан Ибраһимов. Ул ялгыз татар совет язучыларына гына түгел, бөтен Урта Азия һәм Казахстан каләм ияләренә дә остазлык итте. Сәнгатьчә осталыгы, укымышлылыгы белән барлык Совет Көнчыгышы язучыларына үрнәк булды.

Совет Көнчыгышы күренекле язучыларыннан кайсысы иҗатын гына алсак та, Г. Ибраһимов әсәрләренең чагылыш-тәэсирен күрергә мөмкин. Мәсәлән, таҗик язучысы С. Айни, үзбәк язучысы Г. Кадыйри, казах язучысы Б. Майлин, кыргыз язучысы А. Токымбаевларның иҗади осталыгы үсүендә Галимҗанның күренекле өлеше бар. Моны заманында югарыда саналган язучылар үзләре де раслый.

Галимҗан шәкерт чагында казах җирен, аерым алганда, Кустанай далалары белән Кызылъяр тирәсен күп гизгән. Кайвакыт, казах авылларында озакка тукталып, балалар укыткан. Шунлыктан ул казах иленең тормышын, гореф-гадәт, йолаларын яхшы белгән, тарихын, телен һәм әдәбиятын иркен үзләштергән.

Соңрак Г. Ибраһимов, үзенең казах даласында үткәргән яшьлек елларын искә алып, болай яза: «Казах җыры, казах үләңе — гаҗәп!.. Казах халкы — үтә сәләтле, талантлы халык. Киң җәйләүдә, җәйнең тымызык кичендә чиртелгән думбыра авазы нинди тамаша!» («Җолдыз», 1962, 4 сан, 159 б.)

1914 елны Уфадагы татар мәдрәсәсе «Галия»дә сабак биреп йөргән дәверендә Г. Ибраһимов казахның Б. Майлин, Җ. Теләпбиргәнев, Н. Манаев, Габдрахман Мостафин шикелле булачак акын-язучыларына да остазлык итә. Алар белән фикердәш, сердәш була. Шул шәкертләрен исенә төшереп, ул соңыннан: «Миннән укыган, фикердәш булган казах шәкертләре үтә зиһенле, зирәк иде»,— дип яза (шунда ук, 160 б.).

Г. Ибраһимов казах даласында булган чакларында халкыбызның бай авыз иҗаты белән, язма әдәбияты белән, Абай башлаган яңа әдәбияты белән танышкан, аны югары бәяләгән, аның чын дусты, ялкынлы танытучысы булган. Мәсәлән, ул әлеге 1914 елда казах теле белән әдәбиятын санга сугарга теләмәгән татар шәкертләренә каршы чыгып: «Казах әдәбияты инде булган бер факт. Бөтен казах сахрасына әдәби азык булып килгән үләң вә җырлар, безнең хәзерге шагыйрьләремездән күп элек яшәп, киң далада авазы яңгыраган Ибраһим Конанбайлар, соңгы Сералин вә Дулатовлар, «Казахстан», «Казах», «Айкап»лар, казах мәктәпләренә кереп тамыр җәеп барган «уку кораллары» — гомумән, казах телендә баш күтәргән әдәбият хәзер инкяр итәргә мөмкин булмаган бер факттыр» («Аң», 1916, 5 сан, 88 б.).

1928 елда бөтен илебез Г. Ибраһимовның язучылык хезмәтенә егерме ел тулуын билгеләп үтте. Шул елларда казах язучысы Б. Майлин, Г. Ибраһимов юбилеена багышлап, махсус мәкалә яза. «Революциядән элекке татар язучыларының күренеклесе Галимҗан булып килде. Сүзгә осталыгы, зирәклеге, китабының чын тормыш көзгесе булуы аркасында, укучыларны үзенә әсир итеп килде»,— ди ул «Иңбәкче казах» газетасының 1928 елгы 11 март санында. Икенче бер казах әдәбиятчысы Әхмәт Байторсын исә Г. Ибраһимов турындагы мәкаләсен «Төрек-татар белгече, төрек-татар язучысы, төрек-татар уйчысы» дип атый («Безнең юл», 1928, 2 сан, 27 б.). Г. Ибраһимов турындагы мондый югары фикерләрне башка казах язучылары чыгышларыннан да, хосусан, Аскар Тукмагамбитовның «Галимҗанның егерме еллык бәйрәме» («Ленинчыл җас», 1928, 16 март), Таир Жаро-

ковның «Татар әдәбиятчысы» («Иңбәкче казах», 1928, 11 март), Җакан Сыздыковның «Атаклы татар язучысы Галимҗан Ибраһимов» («Бустандык туы», 1928, 28 март) Рәхим Сүгерулының «Галимҗан иптәшкә юлыккан-да» («Казах әдәбияты», 1936, 12 февраль) исемле мәкаләләреннән дә күрергә мөмкин.

Галимҗанның төп әсәрләреннән берсе — «Казакъ кызы» романы. Ул 1909—1911 елларда языла. Ләкин бу әсәрне революциягә кадәр бастырып чыгару әмәле табылмый. Ул бары тик 1924 елда гына дөнья күрә, 1934 елда Гайшә Шәрипова тәрҗемәсендә рус телендә дә чыгарыла. Роман татар әдәбиятына гына түгел, бөтен совет әдәбиятына кушылган кыйммәтле хәзинә рәвешендә кабул ителә.

Г. Ибраһимов «Казакъ кызы» романында казах халкының революциягә кадәрге иҗтимагый тормышын, андагы ыру талашлары белән төркемнәр көрәшен, казах хатын-кызларының аяныч лы авыр хәле белән аның азатлыкка омтылу хыялын әтрафлы сурәтли. Язучы шуның белән бергә казах халкының әхвәлен, гореф-гадәт, йолаларын да мәхәббәт белән гәүдәләндерә. Бу әсәр соңрак казах әдәбиятында Б. Майлинның «Азамат Азаматович», С. Мукановның «Бутакүз», М. Ауэзовнең «Абай юлы» роман-эпопеяларының туууына юл ачты, өлге булды. Нәкъ менә шуның өчен академик язучыбыз С. Муканов Галимҗан Ибраһимовны «үз язучыбыз, үз әдибебез» дип атады («Литературная газета», 1962, 13 март).

Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» романы турында егерменче елларда ук «Ак юл» (Ташкент) газетасы белән «Яңа әдәбият» (Кызыл-Урда) журналында берничә мәкалә бастырыла. Билгеле, галим Шамгали Сарыбаев әсәр турында: «Үтә күренекле татар язучысы Галимҗан Ибраһимовның романында казах тормышының эчке һәм тышкы дөньясы бердәй гәүдәләндерелгән. Бу роман казахларны татар халкына таныштыру максатында язылган. Галимҗан казахларның тарихы белән тормышын бик яхшы белә икән. Шунлыктан ул аларны үтә оста һәм җанлы күрсәтә алган. Бу романны казах теленә тәрҗемә итү кирәк. Үтә хаҗәт китап»,— ди («Яңа әдәбият», 1929, 7 сан). Бу уңайдан, Р. Нургалиевнең «Казах әдәбияты» (1962, 26 октябрь) газетасында бастырган мәкаләсендә дә роман хакында игътибарга лаек фикерләр барлыгын искәртү урынлы булыр.

Казахның бик күп акын-язучылары заманында Г. Ибраһимов белән дуслаша, очрашып, серләшеп, үзара хатлар алышып яши. Бигрәк тә Галимҗан белән Сәкен Сәйфуллиннең дуслык бәйләнешләре истәлекле. Гомер юллары, фикер уртаклыгы, иҗади эзләнүләре охшашлыгы бу дуслыкның нигезен тәшкил итә. Икәве дә иҗтимагый хәрәкәт, әдәбият мәйданына егерменче йөз башында килә, әсәрләре дә бер дәвердә басыла башлый. Икесе дә Октябрь революциясе җиңүен шатланып каршы ала, үз туган якларында Совет хакимлеген ныгытуда актив катнаша, милли культуралары аякка басуына ялкынланып хезмәт итә. Аларның соңгы язмышлары да, ике тамчы судай, бер-берсенә охшый.

Совет чорында Сәкен дә, Галимҗан да, Совет органнарында җаваплы эшләр башкару белән бергә, байтак күренекле әсәрләр иҗат итә. Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романы белән С. Сәйфуллиннең «Тар юл, тайгак кичү» әсәрендә әллә никадәр уртаклык табарга мөмкин. Боларның икесендә дә Совет хакимлеген урнаштыру өчен көрәшүче большевикларның каһарманлыгы тасвирлана. Патшаны, байгураларны яклаучылар һәм милләтчеләр фаш ителә.

Күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Бәембәт Майлинның «Галия» мәдрәсәсендә Г. Ибраһимовтан укуы да, беренче әдәби сабакны татар остазыннан алуы да укучыларга мәгълүм. «Галимҗанның егерме еллык бәйрәме» дигән мәкаләсендә ул остазының иҗатын гаять югары бәяли.

М. Ауэзев, С. Муканов, М. Җомабаев, Җ. Сыздыков, Р. Сүгеревләр Галимҗанның һәр әсәрен укып барган, яраткан, Мәскәүдә һәм Кырымда күрешеп, бер-берсенә әсәрләрен бүләк итешеп, өлкән каләмдәшләренең киңәшләрен тыңлаганнар.

Галимҗан Ибраһимов әсәрләре бездә озак еллар асыл нөсхәсендә укыла, аннары үзе тере чакта ук казах теленә тәрҗемә ителә башлый. Утызынчы елларда «Кызыл чәчәкләр» повестеннан аерым өзекләр бастырган Җакан Сыздыков, соңрак «Казакъ кызы» белән «Алмачуар»ны туган телебездә аерым китап итеп чыгарды. Бәхтияр Миндегазин «Тирән тамырлар» романын, Ә. Атыгаев «Безнең көннәр»не казах укучыларына тәкъдим итте.

Язучыга йөз яшь тулу — Казахстан җәмәгатьчелеге өчен дә зур вакыйга. Бу бәйрәмне казах халкы да мәхәббәт һәм ихтирам белән билгеләп уза.

*Алма-Ата шәһәре.*

**Шерали Турдыев,**
филология фәннәре кандидаты

# Г. ИБРАҺИМОВ ҺӘМ ҮЗБӘК ӘДӘБИЯТЫ

Татар совет прозасына нигез салучы күренекле язучы Галимҗан Ибраһимовның хикәя-повестьлары, романнары, фәнни-публицистик, тарихи хезмәтләре Үзбәкстанда, үзбәк укучылары арасында да киң билгеле. Бөек Октябрь революциясенә кадәр үк үзбәк интеллигенциясенең алдынгы вәкилләре бөек татар шагыйре Г. Тукайның «Туган тел», «Шүрәле», «Ишан зары» һ. б., Фатих Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» шикелле әсәрләре белән бергә Г. Ибраһимовның «Карак мулла», «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәяләрен, «Яшь йөрәкләр» романын, иҗтимагый-политик һәм әдәбият гыйлеме мәсьәләләрен яктырткан әсәрләрен, хезмәтләрен яратып укыганнар һәм өйрәнгәннәр.

1915—1917 елларда Уфадагы татар мәдрәсәсе «Галия»дә эшләгән чорында, Г. Ибраһимов күпкырлы педагогик һәм тәрбия эшләре алып бара. А. Бикмурзин, Сәйфи Кудаш, Ләзиз Азиззадә һәм башка күп кенә язучыларның истәлекләреннән күренгәнчә, Г. Ибраһимов татар шәкертләре белән бергә, Кавказда, Казахстаннан һәм Урта Азиядән килеп гыйлем эстәүче яшьләргә дә сабак биргән. Алар арасында яшь үзбәк шагыйрьләре һәм язучылары: Мирмөхсин Шермөхәммәдев, Лотфулла Алими, Наим Сәед, Шакир Сөләйман, Б. Майлиннар һ. б. да булган. Г. Ибраһимов аларның яңа дәвер үзбәк, казах әдәбияты һәм телен барлыкка китерүдәге гаять зур тырышлык, көч һәм талант сорый торган хезмәтләренә теләктәшлек күрсәтә, көченнән килгән кадәр ярдәм итә. Шулай ук ул төркмән, уйгур һәм башка төрки әдәбиятларның үсешенә дә зур игътибар бирә. Үзенең лекцияләрендә һәм мәкаләләрендә Г. Ибраһимов әдәбиятлар арасындагы дуслык һәм үзара тәэсир итешү идеясен киң пропагандалый, яшьләрне төрле халыкларның әдәби мирасын, шул исәптән шәрык һәм Көнбатыш Европаның, беренче чиратта реалистик рус әдәбияты традицияләрен тирәнтен өйрәнергә, үзләштерергә өнди. Болар барысы да үз чиратында реалистик яшь үзбәк прозасының, публицистика һәм драматургиясенең формалашуына уңай йогынты ясады. Мисал рәвешендә Хәмзәнең шул елларда иҗат ителгән «Милли роман»ын, Абдулла Кадыйриның «Бәхетсез кияү»ен (1915), Мирмөхсин Шермөхәммәдевнең «Баласыз Ачилдибай» (1914) һ. б. әсәрләрне күрсәтергә була.

Октябрь революциясенең ялкынлы җырчысы, үзбәк совет әдәбиятына нигез салучы Хәмзә Хәкимзадә алдынгы татар көндәлек матбугатының һәм интеллигенциясенең Үзбәкстанда мәгърифәтчелек һәм социалистик идеяләрне таратудагы ролен ассызыклап билгеләп үтте. «1907 елда, хаҗга баручы әтиемне Кашгарга кадәр озата барганда, мин «Вакыт» һәм Бакчасарайның «Тәрҗеман» газеталарын укырга гадәтләнеп киттем. Шул вакыттан алып мин искедән калган төрле хорафатларга, юк-барга ышанулар, мәдрәсәдә уку-укыту, халык тормышындагы яңалыклар, экономика һәм культура мәсьәләләре белән даими кызыксына, алар турында уйлана башладым. Шул ук вакытта мин 1905 елгы эшчеләр революциясе турында мәгълүмат алдым. Кашгарда кулдан басу станогында брошюралар һәм листовкалар басучы яшь татар егете бар иде. Мин аның белән атнага ике тапкыр очрашып сөйләшә идем. Күрәсең, ул миңа шактый зур йогынты ясагандыр, чөнки нәкъ менә шул вакытта минем шигырьләрем революцион характер ала барды» [1],— дип язды күренекле үзбәк әдибе.

Татар-үзбәк әдәби бәйләнешләры Бөек Октябрь революциясеннән соң совет чынбарлыгы шартларында тагын да көчәеп китә. Бу чорда — безнең халык культурасының гомум күтәрелеш дәверендә — А. С. Пушкин, Л. Н. Толстой, М. Горький, В. В. Маяковский кебек мәшһүр әдипләр белән бергә күренекле татар әдипләре Г. Тукай, М. Гафури, Г. Ибраһимовларның әсәрләре дә үзбәк теленә тәрҗемә ителә.

Үзбәк реалистик прозасына нигез салучы Абдулла Кадыйри Совет властеның беренче елларында ук Г. Ибраһимов иҗатын югары бәяләде һәм классик әдипнең «Безнең көннәр» романында тасвирланган тарихи вакыйгаларның үзбәк укучысына да якын һәм таныш булуын басым ясап әйтте. Ул Г. Ибраһимовны «Бөек татар язучысы» дип олылады. Бу елларда Урта Азиядә, шул җөмләдән

[1] Султанов Ю. Хамза (Очерк жизни и творчества). Ташкент, 1973, 112—113 бб.

Үзбәкстанда да, Г. Ибраһимовның хикәя-повестьлары, романнары гына түгел, татар халкының революцион көраше сәхифәләрен яктырткан, татар пролетар әдәбияты үсеше мәсьәләләренә багышланган хезмәтләре дә киң катлау укучыларда зур кызыксыну уята. Мәгълүм булганча, үз чиратында Г. Ибраһимов та Урта Азия халыкларының әдәбияты һәм матбугаты белән якыннан кызыксынган. Бөек үзбәк фикер иясе һәм шагыйре Галишер Нәвоины Г. Ибраһимов Руми, Сәгъди, Фирдәүсиләр белән беррәттән «Шәрыкның шигъри кояшы» дип атады. Ул бу мәшһүр шагыйрьләрнең үлемсез әсәрләре татарчага тәрҗемә ителергә һәм көнбатыш әдәбияты классиклары (Данте, Шекспир һ. б.) әсәрләре белән бергә тирәнтен өйрәнелергә, үзләштерелергә тиеш дип саный. Бөек Октябрь революциясеннән соң Г. Ибраһимов безнең республикага килергә һәм үзбәк халкының тормышы белән якыннан танышырга ниятли. Профессор Булат Салиев һәм язучының башка үзбәк дуслары аны олы кунак итеп Үзбәкстанга чакыралар. Ләкин бөек каләм иясенең бу теләге гамәлгә ашмый кала. Үзбәкстан белән бәйләнеш башлыча хат алышу рәвешен ала. Ул күп кенә үзбәк язучылары һәм Үзбәкстанда яшәүче татар галимнәре, шул җөмләдән, А. Кадыйри, Г. Сәгъди, А. Хашимов, Ләзиз Азиззадә, Ш. Сөләйманов һ. б. белән хат аша хәбәрләшеп тора. Көнчыгышны өйрәнүче үзбәк галиме Ләзиз Азиззадә 1926 елда Бакуда тюркология съездында, ә 1923—1927 елларда Мәскәүдә Көнчыгыш халыклары коммунистик университетында укыган чорда берничә тапкыр Г. Ибраһимов белән очрашкан. Бу очрашулар вакытында күренекле әдип марксизм-ленинизм теориясен үзләштерүнең зарурлыгы һәм аның милли әдәбиятларның үсешендәге әһәмияте хакында сөйли. Г. Ибраһимов шулай ук үзбәк прозасының талантлы остасы Абдулла Кадыйрига булган тирән ихтирамын да белдерә.

Ләзиз Азиззадә истәлекләренә караганда, Г. Ибраһимов «Классик үзбәк әдәбиятының Лотфи, Нәвои һ. б. күренекле шәхесләре бар» дип сокланып сөйләгән. Ә үзбәк совет әдәбияты әле формалашып кына килә. Хәзерге үзбәк язучыларыннан, минемчә, советларга иң якыны — Хәмзә,— дип сөйли торган булган.

А. Кадыйриның «Үткән көннәр» (1925) әсәрендә XIX йөзнең 40 елларында Урта Азиядәге төрле ханлыклар арасында барган үзара сугышлар фонында Атабек белән Көмешнең ялкынлы мәхәббәте сурәтләнә, аларның кеше бәхете һәм ирек өчен алып барган көраше күрсәтелә. Ә «Мөнбәрдән чыккан кара корт» (1928—1929) исемле әсәрендә язучы халык тарихын сурәтләүдә алга таба тагын бер адым ясый. Бу романында А. Кадыйри ханлык чоры тәртипләрен кискен рәвештә тәнкыйтьләү белән генә чикләнмичә, Әнвәр һәм Рано мәхәббәте мисалында, илдә хөкем сөргән феодаль деспотия тәртипләренә риза булмаган кешеләрнең Россия кул астындагы Ташкентта үзләренә сыеныр урын табуларын да күрсәтә.

Абдулла Кадыйри, үз халкының үткәне турындагы романнарын иҗат иткәндә, Г. Ибраһимовның бай иҗат тәҗрибәсенә таянды. Бу А. Кадыйриның «Мөнбәрдән чыккан кара корт»ын Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» романы белән чагыштырганда аеруча күзгә ташлана.

Егерменче еллар азагында, Г. Ибраһимовның әдәби иҗат һәм иҗтимагый-политик эшчәнлегенә 20 ел тулуны билгеләп үтү уңаеннан, Үзбәкстан матбугатында күренекле әдипнең тормышы һәм иҗаты турында күп кенә мәкаләләр дөнья күрә. Мәсәлән: Ш. Сөләйман «Егерме еллык әдәби хезмәт» («Мәгариф вә укытучы», 1928, 1 сан, 63—64 бб.), Г. Толымбайский «Галимҗан Ибраһимов — татар халкының бөек язучысы» («Җир йөзе», 1928, 3 сан); З. Бәшири «Галимҗан Ибраһимов юбилее» («Кызыл Үзбәкстан», 1927, 2 декабрь) һ. б. Бу зур бәйрәм уңаеннан үзбәк шагыйре Шакир Сөләйман «Талантлы язучы Г. Ибраһимов халыкта киң билгеле. Шуңа күрә без аның юбилеен түземсезлек белән көтәбез»,— дип язды.

Г. Ибраһимовның күп әсәрләрен үзбәк укучылары үз ана телләрендә укыйлар. 1926 елда аның «Кара маяклар яки ак әдәбиятлар» исемле хезмәте, ә 1930 елда «Табигать балалары» исемле әсәре үзбәк телендә дөнья күрә. 1932 елда «Казакъ кызы» романы һәм «Кызыл чәчәкләр» повесте үзбәк теленә тәрҗемә ителә. Г. Ибраһимовның милләттәше үзбәк әдибе Абдулла Уразаев соңгы елларда «Казакъ кызы» романының яңа тәрҗемәсен эшләде. Шулай ук «Тирән тамырлар» романы да аның тәрҗемәсендә үзбәк телендә дөнья күрде.

Галимҗан Ибраһимовның тормышы һәм күпкырлы иҗаты, аның Урта Азия һәм Казахстандагы тугандаш халыкларның әдәбиятлары үсешенә бәрәкәтле йогынтысы хакында көндәлек матбугат битләрендә Мохтар Әуэзов, Сабит Муканов, Берды Кербабаев, Гафур Гөләм, Иззат Солтанов кебек күренекле язучыларның һәм галимнәрнең бай, тирән эчтәлекле мәкаләләре басылып чыкты. Алар Г. Ибраһимов талантына югары бәя бирү белән бергә, классик әдипнең үз иҗатла-




рына көчле тәэсир итүен, илһам өстәвен тәкрарлап әйтәләр. 1962 елда «Правда» газетасының 13 март санында басылган мәкаләсендә төркмән әдәбиятының күренекле вәкиле, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Берды Кербабаев, башка күп кенә язучылар һәм галимнәрнең уртак фикерләрен чагылдырып, болай дип язды: «Минем беренче әсәрләрем төркмән хатын-кызларының азатлыгы темасына багышландылар. Икърар итә алам һәм моны шатланып эшлим: минем әсәрләрем Галимҗанның зур йогынтысы белән иҗат ителделәр. Ул, совет язучыларыннан беренче булып, гаилә һәм җәмгыять изүенә каршы баш күтәргән мөселман хатын-кыз образын иҗат итте».

*Ташкент шәһәре.*

---

*Галимҗан Ибраһимов һәм башка бик күп татар язучыларының исемнәре якут халкына якын таныш. Якут укучылары аларның аерым әсәрләрен үз ана телендә укыйлар.*

СЕМЕН ДАНИЛОВ, якут язучысы.

*Галимҗан Ибраһимов... казахлар аны үз язучылары итеп исәплиләр.*
*Галимҗан Ибраһимовның, талантлы зур язучының, гүзәл кешенең исеме күп милләтле социалистик культурабыз тарихына мәңгегә керде.*

САБИТ МУКАНОВ, академик, казах язучысы.

---

**Солтанморат Акбиев,**
филология фәннәре кандидаты

# Г. ИБРАҺИМОВ ҺӘМ ДАГСТАН ХАЛЫКЛАРЫ ӘДӘБИЯТЫ

Г. Ибраһимовның күпмилләтле Дагстан әдәбияты, дагстанлылар белән бәйләнеше мәсьәләсе махсус тикшеренүгә лаек.

Мәгълүм булганча, Г. Ибраһимов 1906 елның көзендә Уфага килә һәм «Галия» мәдрәсәсенә укырга керә. Кыш үтеп, укулар тәмамлангач, ул җәйге каникулын Кавказда үткәрә, анда мөгаллим булып эшли. Г. Ибраһимовның дагстанлы нугайлар арасында укытучылык итүе хакында замандашларының истәлекләре безнең көннәргәчә килеп җиткән. 1937 елда Ялтада Г. Ибраһимов үзенең күптәнге танышы, комык галиме, Баку университеты укытучысы Мөхәммәдкәрим Садуллаев белән очраша. Садуллаев истәлекләренә караганда,[1] ул Г. Ибраһимов белән 1926 елда Бакуда I Бөтенсоюз тюркология съезды барган көннәрдә танышкан. Ялтада исә алар арасында дустанә мөнәсәбәт тагын да җылырак төс ала. Г. Ибраһимов дагстанлы дустына «Безнең көннәр» романын бүләк итеп бирә. Садуллаев Ибраһимов янына еш кереп йөри башлый, кайвакытларда бергәләп Кара диңгез буена йөрергә чыгалар. Кардәш халыкларның үткәне, бүгенгесе турында, телләрнең үзара бәйләнеше, гореф-гадәтләрнең якынлыгы һ. б. мәсьәләләр буенча фикер алышалар. Шундый әңгәмәләрнең берсендә Г. Ибраһимов Садуллаевка халык мәгарифе өлкәсендәге беренче адымнарын Кавказда ясавы хакында сөйли. 1907 елның көзендә Дагстаннан китсә дә, ул гомеренең соңгы елларына кадәр дагстанлылар белән аралашып яши. «Галия» мәдрәсәсендә белем алучы Дагстан шәкертләре Г. Ибраһимовтан сабак алалар, икенчеләре аның талантлы әсәрләре аша тугандаш татар әдәбияты белән таныша, әдәби осталыгын чарлый, өченчеләре исә эчтәлеге белән социалистик формасы милли булган культураны һәм әдәбиятны үстерүдә аның белән кулга-кул тотынып эшли. Тауларга сыенып утырган ерак Унчукатль авылыннан ике туган Корбаналиевлар — Г. Ибраһимовның үзеннән дәрес тыңлау бәхетенә ирешкән дагстанлылар. Аларның берсе, ул чакта яшь шагыйрь, ә хәзер инде лак поэзиясенең аксакалы Ибраһим-Хәлил Корбанали улы Корбаналиев була. Элекке Казикумух округындагы дини мәктәпләрнең берсендә башлангыч белем алган Корбаналиев 1914 елда, 23 яшендә Уфага килә һәм «Галия» мәдрәсәсенә укырга керә. «Галия»дә укыган еллар авыр булса да, иң бәхетле еллар булды, дип яза шагыйрь үз истәлекләрендә. Монда ул илнең төрле төбәкләреннән җыелган төрле милләт яшьләре белән аралаша. Алар арасында булачак карачай галиме, революционер һәм дәүләт эшлеклесе Умар Алиев та була. «Галия» чорында Корбаналиев татар әдәбиятын тырышып өйрәнә. Ул хәзергә кадәр З. Кәмали, Г. Шнаси кебек укытучыларын искә ала. Әмма Корбаналиевның хәтеренә иң сеңеп калганы «уртачадан аз гына калкурак буйлы, каракучкыл йөзле, озыч чәчле» кеше — Г. Ибраһимов була.

Г. Ибраһимов һәм татар культурасының башка вәкилләреннән алган белем, аларның әсәрләрен уку, өйрәнү И.-Х. Корбаналиевның эшчәнлегенә һәм иҗатына бәрәкәтле йогынты ясый. Бөек Октябрь революциясеннән соң ул Дагстанга кайта һәм таулар иленең иҗтимагый-мәдәни тормышына актив катнашып китә. Кызыл партизаннар сафында сугыша, соңыннан югары уку йортын тәмамлый, төрле культура оешмаларында эшли, Бөек Ватан сугышында катнаша, революцион рух бөркелеп торган, хезмәт кешесенә дан җырлаган шигырьләр иҗат итә. Корбаналиевның поэзиясе — публицистик рухлы поэзия. Аның иҗатына дагстанлы революционер шагыйрьләрнең генә түгел, беренче остазы Г. Ибраһимовның да тәэсире зур булган, әлбәттә. Егерменче елларда иҗат ителгән «Күңел түрендәге хыял», «Иптәш» шигырьләрен, «Беркөн вакыйгалары» очеркын Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми», «Яз башы», «Табигать балалары» һ. б. әсәрләре белән чагыштырсак, Корбаналиевның күренекле татар әдибенең реалистик традицияләрен дәвам иттергәнлеген ачык күрербез. Корбаналиев та Ибраһимов кебек үк хатын-

[1] М.-К. Садуллаевның машинкада басылган истәлекләре аның дусты, Дагстанның халык шагыйре Аткай Аҗаматовның шәхси архивында саклана.

кыз азатлыгы мәсьәләләрен алгы планга куйган. Г. Ибраһимовның дагстанлы шәкерте И.-Х. Корбаналиев хәзер дә сафта. Ул хәзер дә иҗат итә, әле дә үзенең беренче остазы, классик әдип, галим һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимовны сагынып искә ала. Г. Ибраһимов иҗаты Манай Алибәков, Мөхәммәт Казанбиев, Әбүсуфьян Акаев һ. б. комык әдипләренең язучылык осталыгын чарлауда саллы өлеш кертте. Хәзерге заман комык әдәбиятына нигез салучы мәгърифәтче-демократ, ялкынлы шагыйрь Нухай Батырморзаев та Г. Ибраһимов иҗатыннан өлге алды, аннан өйрәнде. Билгеле булганча, Г. Ибраһимовның беренче әсәрләре матбугатта дөнья күргән чорда, Н. Батырморзаев Казанда яши һәм бертуган Кәримовлар типографиясендә эшли. Бу хәл үз нәүбәтендә аның иҗатында да чагылыш тапкан, әлбәттә. Н. Батырморзаевның «Нухай җавабы» (1910) поэмасы, «Һарун белән Зөбәйдә, яки бәхетсез Җанбикә» (1914) повестьларын Г. Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (1907), «Татар хатыны ниләр күрми» (1908) һ. б. хикәяләре белән чагыштырып өйрәнү татар классигы әсәрләренең Н. Батырморзаев иҗатына тәэсирен бик ачык күрсәтә. Г. Ибраһимов кебек үк Батырморзаев та үзенең әсәрләрендә мөселман хатын-кызларының авыр хәле турында ачынып яза, дини мәктәпләрдә уку-укытуны кискен тәнкыйтьли. «Һарун белән Зөбәйдә, яки бәхетсез Җанбикә» повестеның герое — Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрендәге Гөлбануга авабдаш. Көн саен төрле кимсетүләрдән, кыйнаулардан гаҗиз калган Җанбикә үз-үзенә кул сала, ә Гөлбану залим ире йортын ташлап кача.

Типологик планда караганда, Батырморзаевның «Давылда» (1917) һәм Ибраһимовның «Диңгездә» (1911) хикәяләрендә дә охшаш моментлар аз түгел. Ике әсәрдә дә вакыйгалар табигать кочагында — диңгездә бара. Һәр ике әсәрдә дә лирик геройлар — үзләрен чолгап алган тирәлектән бизгән шәхесләр. Алар капитализм алып килгән газаплы тормыштан риза түгелләр.

Бөек Октябрьдән соң, Г. Ибраһимовның иҗтимагый-политик эшчәнлеге һәм иҗаты чәчәк аткан чорда, Дагстан белән Татарстан арасындагы мәдәни һәм әдәби бәйләнешләр тагын да куәтләнеп китә, яңа баскычка күтәрелә. Дагстан әдипләре татар язучылары ирешкән иҗат тәҗрибәсеннән теләп файдаланалар. Татар культура әһелләре дә Дагстан белән элемтәләрне ныгытуга зур игътибар бирәләр.

Югарыда искә алып үтелгәнчә, 1926 елда Бакуда төрки халыклар өчен яңа алфавит төзү мәсьәләсен караган I Бөтенсоюз тюркология съезды була. Съездга Мәскәүдән, Ленинградтан һ. б. шәһәрләрдән, Урта Азия республикаларыннан галимнәр, язучылар җыела. Партиянең Татарстан өлкә комитеты карары белән Г. Ибраһимов Татарстан делегациясенең җитәкчесе итеп җибәрелә. Дагстан делегациясе җитәкчесе Җәләлетдин Коркмасов була. Съезд делегаты, нугай мәгърифәтчесе А.-Х. Җанибәков[2] (1879—1955) истәлекләреннән күренгәнчә, фикер алышулар съезд утырышлары арасындагы тәнәфесләрдә, кунакханә бүлмәләрендә дә дәвам итә. Татар халкының борынгы һәм хәзерге әдәбиятын, культурасын яхшы белгән һәм яраткан Җанибәк ирексездән Казаннан килгән кешеләр янына тартыла.

Съезд барган көннәрдә Җанибәков Г. Ибраһимов белән якыннан таныша һәм күп тапкырлар әңгәмәдәш була. А.-Х. Җанибәков истәлекләренә караганда, Г. Ибраһимов сүзгә оста, тапкыр була. Җанибәковның якташлары — нугайлар арасында укытучылык иткән вакытларын искә төшерә, нугай халкының тарихы, халык мәгарифенең торышы белән кызыксына. Ул Җанибәковның нугай алфавитын төзү, нугай этнографиясе һәм шулай ук үз ана телендә әдәби әсәрләр иҗат итүен хуплый, моңа чын күңелennән куана. Ибраһимов нугай халкының бай авыз иҗатын җыю һәм өйрәнү мәсьәләсенә аеруча нык игътибар бирә. Җанибәковның халык авыз иҗаты җәүһәрләреннән бай коллекция туплавын ишеткәч, сөенеченең чиге булмый. Җанибәковның Г. Ибраһимовка булган ихтирамын ул чорларда Дагстанда дөнья күргән мәктәп дәреслекләре дә ачык күрсәтеп тора. Мәсәлән, «Аз белемлеләр мәктәбе өчен нугай теле дәресләре» исемле хрестоматиядә Г. Ибраһимовның гыйбрәтле тормышы, күпкырлы әдәби һәм иҗтимагый-политик эшчәнлеге яктыртыла. Бу китапка шулай ук әдипнең фоторәсеме һәм «Чехлар килгәндә» исемле хикәясе дә урнаштырылган. Дагстан дәүләт нәшриятында беренче тапкыр 1934 елда басылып чыккан бу дәреслек Г. Ибраһимовның соңгы елларына, ягъни 1938 елга кадәр берничә кабат дөнья күрә.

Г. Ибраһимовның дагстанлылар белән элемтәләре, күпсанлы әсәрләренең Дагстан халыклары әдәбиятына бәрәкәтле йогынтысы мәсьәләсе югарыда телгә алынган мәгълүматлар белән генә чикләнми, әлбәттә. Алар әле киләчәктә тагын да җентеклебрәк тикшерүгә, өйрәнүгә лаек.

---

[2] А.-Х. Җанибәковның Г. Ибраһимов турындагы истәлекләрен без аның улы Әнвәр Җанибәковтан язып алдык.

## БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

СОРАУ:

— Галимҗан Ибраһимов иҗатының Сезнең тормышыгызда тоткан урыны нинди?

КАМИЛ ВӘЛИЕВ, академик, Ленин премиясе лауреаты:

— Кечкенә — егерме генә йортлы татар авылын күз алдыгызга китерегез. Сугыш алды... Колхоз кырларында күмәк хезмәтнең тәмен белеп эшли башлаган еллар... Авыл бәләкәй булса да, революция һәр өйгә, һәр гаиләнең тормышына зур мәгънә алып килгән: халыкның сулышын киңәйткән, тормыш агышын тизләндергән. Әнә клуб: аннан күңелле гармун тавышы ишетелә, һәр көнне яшьләр кичке уенга җыела. Менә дүрт сыйныфлы мәктәп (бер бүлмәдә икешәр класс). Мәктәп — авылның күз өстендәге кашы. Һәр гаиләдә мәгърифәт культы, балаларны белемгә өндәү рухы. Кичләрен, кышкы озын төннәрдә кычкырып китап укыйлар, кызыклы кыйссалар турында гәп куерталар. Сабакка йөрүче балалар артыннан кечерәкләре иярә, мәктәпкә барганчы ук хәреф танырга өйрәнә.

Мин дә шул мохитта, шулар арасында. Миңа алты яшь, инде йөгерек укыйм, хисапның дүрт гамәлен үзләштердем, китап укудан тәм табам. Олылар минем бу омтылышымны хуплыйлар...

Безнең гаиләдә аеруча ике исемгә ихтирам зур иде. Аларның берсе Габдулла Тукай булса, икенчесе — Галимҗан Ибраһимов.

Тукай шигъриятенең кабатланмас моңы-аһәңе, халыкчан зирәк фикере, без сулый торган һава кебек үк, табигый, якты. Татар баласының теле Тукай белән ачыла. Аның шигырьләре балачакның тылсымлы төшләре, өмет-хыяллары белән күңелгә сеңә, гомерлеккә истә кала.

Икенче класста укыганда минем кулга Галимҗан Ибраһимов китабы килеп керде. Аһ, ул көннәр! Мин язучы каләме генә хасил итәргә мөмкин булган могҗизага кагылдым, үзем өчен өр-яңа дөньялар ачтым.

«Алмачуар» хикәясендәге хәлләр миңа аеруча якын: үземә яшьтәш булырлык малайның бөтен хис-кичерешләре, эш-хәрәкәтләре шулкадәр таныш (без дә колыннар тирәсендә чуалабыз, ат сакларга йөрибез!), хәтта вакыт-вакыт мин бу малай белән кушылып киткән төсле булам. «Шул көннән алып Алмачуар минем тормышымның үзәге була. Шатлыкларым, кайгыларым шуннан чыга, шуңа кайталар. Төшемдә шуны күреп саташам...» Күз карасы кебек кадерләп үстергән Алмачуардан аерылганда, минем дә күңелемдәге ниндидер кыл шартлап өзелгән кук булды.

«Татар хатыны нилэр күрми» — бөтенләй башка рухтагы, бүтән төрле материалга корылган әсәр. Колак төбендә үк күрәзәче карчыкның саташулы тавышы: «Иолдызың каралып бара синең... Бәхетсезлегең зур, кара көнең күп...» Бер караганда, аны балалар өчен язылган дип кем әйтер. Әмма минем сабый җанымда бу гаҗәеп әсәрнең үз урыны бар иде.

Ул китапта тагын бүтән әсәрләр булдымы-юкмы икән,— анысы хәтеремдә калмаган. Шушы ике әсәрне исә кабат-кабат укып та туя алмый идем. Андагы һәр хәрәкәт-ым, хәзер дә күз алдымда булып, мине чиксез дулкынландыра, һәр төсне күрәм, исләрне тоям... Еллар ераклыгыннан торып карaганда, бер хакыйкатьне ачык аңлый барам: Галимҗан Ибраһимов әсәрләре безнең өчен гаҗәеп тәэсир көченә ия кешелеклелек мәктәбе булган икән. Зур дөньяга безне шул мәктәп әзерләде.

Билгеле булганча, Г. Ибраһимов язучының каләм көчен «халыкның йөрәгендә булып та, теленә килә алмый торган тойгыларны әйтеп бирү һәм укучыны үзе теләгән рәвешчә уйландыру, тәэсирләндерү»дә күргән. Әдипнең чын мәгънәсендә халыкчан, патриотик, югары сәнгатьчә дәрәҗәдәге әсәрләре дә әнә шундый көчкә ия. Һич икеләнүсез әйтергә мөмкин: Галимҗан Ибраһимов иҗаты минем өчен дөнья әдәбиятына да тәрәзә ачты.

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ В. И. ЛЕНИН БЕЛӘН ОЧРАШУЫНА БӘЙЛЕ ДОКУМЕНТЛАР

Ленин белән очрашу вакыйгасын Галимҗан миңа болай сөйләгән иде:
— 1918 елның җәендә Мулланур Вахитов Казанга киткәч, Комиссариатта җитәкчелек эше минем өстемә йөкләнде. Мин ул вакытта Коммунистлар партиясенә рәсми рәвештә кермәгән идем але, сул эсер-интернационалистлар партиясендә хисаплана идем. Ләкин үземнең практик эшемә килгәндә, мин революциянең беренче көннәреннән ук Коммунистлар партиясе сызган юл белән бардым, шул юл өчен көрәштем. Сул эсерлар яшь Совет властена хыянәт иттеләр, Мәскәүдә коралы восстание ясадылар. Алар башка шәһәрләрдә дә эш ташладылар, Советка һәм коммунистларга каршы күтәрелделәр. Ләкин мин Ленинның күрсәткән юлын дөрес дип таныдым һәм эсерларның бу эшләрен революциягә каршы турыдан-туры һөҗүм дип санадым. Шул сәбәпле, үзем рәсми рәвештә сул эсер булып хисаплансам да, Комиссариаттагы һәм газетадагы эшемне ташламадым, дәвам иттердем. Шулай булса да, бик уңайсыз бер хәлдә калдым. Юлым — коммунистлар белән бергә, партиям — коммунистларга каршы. Хәлемнең шулай булуы нәтиҗәсендә, эштә дә көтелмәгән уңайсызлыклар тууы ихтимал иде. Шуның өчен мин Владимир Ильичтан мине кабул итүен үтендем. Мин аңа Коммунистлар партиясенә, аның сәясәтенә, карарларына булган карашымны һәм «сул коммунист», «сул эсер»ларның оятсыз хәрәкәтләренә булган мөнәсәбәтемне, үземнең хәзер уңайсыз хәлдә калуымны — һәммәсен ачыктан-ачык сөйләп бирдем. Ленин мине бик дикъкать белән тыңлады.

Ленин миннән бу вакыткача кайда, нинди урыннарда эшләвемне сорашты, соңыннан, һич шикләнмичә, икеләнмичә, миңа: «Эшегездә дәвам итегез!» — дип, кисеп әйтте. Пролетариат революциясенең бөек юлбашчысы булган Владимир Ильичның миңа шулай ышануы минем күңелемне күтәрде, рухландырды һәм минем бөтен киләчәк язмышымны билгеләде...

Галимҗан үзенең Ленин белән бу очрашуын бик зур бәхет итеп саный, уңае туры килгәндә, бу турыда һаман сөйли иде.

**Гөлсем МӨХӘММӘДЕВА.** Истәлекләрдән.

*Мөселман эшләре комиссариаты председателе урынбасары Г. Ибраһимовтан*

ип. ЛЕНИНГА

*1 сентябрь, 1918 ел.*

Үзәк мөселман комиссариаты коллегиясе дөнья пролетариаты юлбашчылары ип. Ленинга җинаятьчел һөҗүм һәм ип. Урицкийны мәкерле үтерү уңае белән үтерүчеләргә, революциягә хыянәт итүчеләргә карата тирән ачу белдерә һәм мөселман пролетариатын революция һәм Совет власте юлбашчылары тирәсендә тыгызрак тупланырга, аларны үз яклавына алырга һәм контрреволюция белән аяусыз көрәшкә әзер булырга чакыра.

*Комиссариат председателе урынбасары Г. Ибраһимов.*



*Ленин янында киңәшү*
Валерий Скобеев картинасыннан
репродукция

1918 елның январь ахырлары. В. И. Ленин Милләтләр эшләре Халык Комиссариаты каршындагы Үзәк мөселман комиссариаты членнары Мулланур Вахитов, Галимҗан Ибраһимов һәм Шәриф Манатов белән очраша. В. И. Ленин Казандагы Сөембикә манарасын һәм Оренбургтагы Кәрвансарайны халыкка тапшыру турында декретның проектын хуплый һәм аны Үзәк мөселман комиссариаты исеменнән бастырып чыгарырга киңәш итә. Бөек юлбашчы, үз декретларын тормышка ашырып, Комиссариатның халыкта абруй казанырга тиешлеген дә искәртә.

**Владимир Ильич Ленин. Биографическая хроника.**
М., т. 5, 1974, 222 б.

# КАДЕРЛЕ ЯДКАРЬЛӘР

## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ БИОГРАФИЯСЕНӘ МАТЕРИАЛЛАР

### 1

### БЕРКЕТМӘ № 1

1913 елның 18 апрелендә, мин, Аерым жандармнар корпусы подполковнигы Вахнин, Дәүләт тәртибен һәм җәмәгать тынычлыгын саклау чаралары турында 1881 елның 14 август көнендә Патша Галиҗәнаблары раслаган Положение нигезендә түбәндә аталучыдан сорау алдым; ул болай аңлатты:

| | |
|---|---|
| 1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Ибраһимов Галимҗан Гыйрфанович |
| 2. Туган вакыты һәм урыны | 1887 елда, Уфа губернасының Стәрлетамак өязе, Солтанморат авылы |
| 3. Дине | ислам |
| 4. Килеп чыгышы, кайсы халыктан, подданныйлыгы һәм шәхси дәрәҗәсе | татар, россияле, Уфа губернасы Стәрлетамак өязе крестьяннарыннан |
| 5. Даими торак һәм гаскәри хезмәт үтү буенча теркәлгән урыны | Солтанморат авылы, шунда ук теркәлгән, гаскәри хезмәткә 1908 елда чакырыла, сәламәтлеге йомшак булу сәбәпле азат ителә |
| 6. Шөгыле һәм мал табу чыганагы | әдәбиятчы, газеталарга язышам, Киевта дәресләр бирәм |
| 7. Гаилә хәле (хатыны яки иренең исеме һәм атасының исеме, балаларының исеме, аларның шөгыле, яшәү урыны) | буйдак |
| 8. Туганлык элемтәләре: ата-аналары, ир һәм хатын-кыз туганнарының исемнәре, аларның тору урыны, шөгыле, ата-аналарының экономик хәле | Әтисе—Гыйрфан Нурмөхәммәтов, 65 яшь тирәсе, әнисе Хәсәнә Заһит, 56 яшь тирәсе, ир туганы Шакирҗан 28 ләрдә, өйдә яши, Габделхәким 15 яшьләрдә, өйдә, хатын-кыз туганнары Нәгыймә, Хәйрия Мәхмүдова 30 яшьләрдә, авылда яши (танып булмый) |
| 9. Ата-аналарын яки опекуннарын алыштыручы туганнарының даими тору урыны | Солтанморат авылы |
| 10. Уку йортларында (түбән, урта, югары) тәрбияләнүе. Күпме вакыт укыган, ни сәбәпле ташлаган, кайчан кергән, кайчан һәм ни өчен киткән һәм кем хисабына тәрбияләнгән | Солтанморат авылында рус-татар мәктәбен тәмамлаган. Оренбургта мәдрәсәдә (дини мәктәп) җиде ел, Уфада шундый ук мәктәптә өч ел укыган |
| 11. Чит илләрдә булганмы, кайларда һәм нинди максат белән | булганы юк |
| 12. Сорау алуга тартылганы бармы, булса, кайчан һәм сорау алу нәрсә белән тәмамланган. | Тартылмаган һәм тентелмәгән |

Үземә тәкъдим ителгән сорауларга җавап бирәм:

Миңа күрсәтелгән «Знамя труда» газетасының унөч саны һәм «За народ» газетасының бер саны минем фатирымнан алынды («Знамя труда» газетасының 1912 елгы 41 саны — 1 данә, 42 саны — 1 данә, 43 саны — 1 данә, 44 саны — 2 данә, 45 саны — 2 данә, 46 саны — 2 данә, 47 саны — 2 данә, 1913 елгы 48 саны — 2 данә һәм «За народ» газетасының 1912 ел, октябрь саны күрсәтелгән иде). Бу газеталарны мин урамда, өч йөз еллык юбилей бәйрәм ителгән вакытта тапкан идем.

Миңа күрсәтелгән «Дом Самозвановых» дигән брошюра «Знамя труда» һәм «За народ» газеталары яткан төргәктә иде (С. р. партиясе нәшир иткән № 8 «Дом Самозвановых» брошюрасы күрсәтелде). Студент Хәлиулла Еникиевны беләм, ул минем белән бер губернадан. Аның белән ул Уфада гимназист чагында танышкан идем. Киевта аның белән 1912 елда, монда килгәч очраштым.

---

*Документлар матбугатта беренче тапкыр басыла.*
*Аларны редакциягә өлкән язучыбыз Афзал ага Шамов әзерләп тапшырды.*

Миңа күрсәтелгән «ст. медик Хәлиулла Еникиевка» дигән адреслы конверт минем фатирымнан алынды, кәгазь салынган бу конвертның миңа кайчан һәм нинди хәлләрдә килеп эләккәнен белмим, элек аны күргәнем юк иде.

Бу конвертка мин тимәдем, андагы язмаларны алмадым һәм укымадым, шунлыктан аларның эчтәлеге буенча аңлатма бирә алмыйм (адресына Киев, Университет, ст. медик Хәлиулла Еникиевка дип язылган конверт күрсәтелгән иде). Мөселман студентларның җыенга яки җыелышларга җыелулары элек миңа мәгълүм түгел иде, кичә мине кулга алгач, участокта полициянең мөселман студентлар һәм курсисткаларны кулга алганлыгын белдем, әмма ул җыелышның максаты нинди булу миңа билгеле түгел. Мөселман студентлар белән очрашканда, аларның үз түгәрәкләрен легальләштерергә рөхсәт сорарга теләүләре турында ишеткәнем бар иде. Өстәп әйтәм, «Знамя труда», «За народ» газеталары һәм «Дом Самозвановых» брошюрасы салынган төргәкне, София соборы янында бугай, кемдер толпага ыргытты, төгәл кайчан икәнен тәгаен генә әйтә алмыйм.

«Хәлиулла Еникиевка» дип язылган адреслы конвертның миннән алуынын кире кага алмыйм. Аны элек үземдә күргәнем юк. Студент Еникиевның кайбер китаплары миндә («Җенес һәм характер», «Сүзлек» h. б.) һәм, бәлки, конверт алар арасында булгандыр.

Еникиев миндә якынча 12 яки 13ендә булды, ләкин нәкъ кайчан икәнлеген төгәл әйтә алмыйм — хәтерләмим.

«Миндә түгел», «студент Еникиев онытты», «берничә тапкыр» дигән сүзләр сызылган, «өч», «...дан», «эләккән» сүзләре төзәтелгән, өскә «минем тарафтан» дип язылган. Күрсәтмәләр минем сүзләрдән дөрес язылган һәм миңа укып чыгылды.

Имзалар: Галимҗан Гыйрфанович Ибраһимов
Подполковник Вахнин.

---

Украина ССРның Үзәк дәүләт архивы. 274 ф., I тасв., 3151 эш, 318—319 бб.

## 2

## СУД ТИКШЕРҮЧЕСЕНӘ

Унсигезенче апрельдә сорау алу вакытында әйткән сүзләремә өстәп, түбәндәге сорауларга аңлатмалар бирәм:

Мин хөкүмәткә каршы булган бер оешмада да тормыйм һәм торганым юк. Быел (1913 ел) январь аенда Еникиев фамилияле таныш бер студент, Уфа шәһәре буенча якташым, Киев мөселман студентлары үзләренең якташлык җәмгыятен легальләштерергә телиләр дип, миңа бер сөйләгән иде. Аннары бераздан соң ул миңа студентларның әлеге якташлык җәмгыяте уставын раслатыр өчен губернаторга җибәргәннәр икән, ә губернатор аны расламыйча кире кайтарган икән дип тә әйткән иде. Февраль аендамы, әллә марттамы, анысын ачык хәтерләмим, Еникиев миңа: «Мөселман студентлары съездын җыяр өчен үткәреләчәк киңәшмәне әзерләү комиссиясе сине үзенең утырышына чакыра», диде. Комиссия утырышында мин ике тапкыр булдым. Мин катнашкан беренче утырышта, көн тәртибендәге мәсьәләләрнең берсе булып, съездның йөзен билгеләү мәсьәләсе каралды. Мин: «Съездда бары политик мәсьәләләр генә каралырга тиеш», дигән тәкъдим керттем («Төзү» дигән сүз сызылган.— Ред.). Комиссия съездда каралачак мәсьәләләрне билгеләү эшен Еникиев белән икебезгә тапшырды. Аның белән икәү бергә кайбер мәсьәләләрне билгеләвебезне хәтерлим. Мәсәлән, без съезд көн тәртибенә: руханиларга мөнәсәбәт; Дәүләт Думасындагы мөселман фракциясенә мөнәсәбәт; башка халыкларга мөнәсәбәт мәсьәләләрен кертергә кирәк дип яздык. Ләкин анда хөкүмәткә каршы юнәлдерелгән бер нәрсә дә юк иде, — хәтеремдә шулай калган. Ул язуны мин комиссиягә бирмәдем («мин» дигән сүз сызылган. — Ред.). Еникиев («үзенекен» дигән сүз сызылган. — Ред.) биргәнме, юкмы, — анысын белмим. Ул миңа үзе: «Без билгеләгән мәсьәләләрне бер утырышта тикшерделәр», — диган иде. Ләкин анда ул мәсьәләләрне, җентекләп тикшереп, кабул иткәннәрме, юкмы икәнен әйтә алмыйм. Икенче утырышта да булдым мин. Тик аның кайсы айда һәм кайсы числода булуын хәтерләмим, шулай ук анда нинди мәсьәләләр каралганы да хәтеремдә калмаган. Еникиев ничектер бер вакыт миңа: «Син катнашмаган бер утырышта сине дә, мине дә съезд программасын әзерләү подкомиссиясенә член итеп керттеләр», дигән иде; ләкин ул эштән мин баш тарттым (тентү вакытында алынып, 18 нче номерлы беркетмәгә теркәлгән гаепләү әйбере күрсәтелә). Миңа күрсәтелгән бу хатны

мин Хәнәфи Кайбышев исемле бер таныш студентка язган идем. Ул хатны шул студентка тапшыру өчен Еникиевкә бирдем. Ул рождество вакытында өенә, ягъни Уфага, Казан аркылы кайтачак иде. Ул хатта мөселман студентлары җәмгыятен легальләштерергә теләү факты киләчәктә булачак вакыйгаларның берсе рәвешендә әйтелә. Шуңа күрә мин Казан студентлары бу эшкә ничек карарлар икән дип кызыксындым, чөнки мин, әдип буларак («һәм» дигән сүз сызылган, аның өстенә «яшьләрнең» дигән сүз язылган. — Ред.), яшьләрнең рухи халәтләре һәм аларның иҗтимагый мәсьәләләргә булган мөнәсәбәтләре белән кызыксынмыйча булдыра алмыйм. Квартирамда тенту вакытында, рус газета-журналларыннан тыш, шулай ук татар телендәге күп кенә кулъязмаларым белән бергә газеталар һәм китаплар да алынды. Ләкин матбугатка бирергә әзерләнгән янсә әзерләнү хәлендә булган ул материаллар киләчәктә цензура аркылы үтәргә тиешләр, аларда хөкүмәткә каршы бернәрсәнең дә булуы мөмкин түгел. Шуннан артык бер төрле дә аңлатма бирә алмыйм. Показаниене үз кулым белән яздым. «Тәзү», «мин», «үзенекен», «һәм» дигән сүзләрне сыздым; «яшьләрнең» дигән сүзне юл өстенә яздым. Аларның шулай язылуына ышанырга. Галимҗан Гыйрфанович Ибраһимов.

---

Украина ССРның Үзәк дәүләт архивы. 274 ф., I тасв., 31—51 эш, 561—562 бб.

3

## В. Г. ГЫЙЛЬМИЯРОВКА

Август, 1917 ел. Агыйдел пароходы.

1. Кем ыңгырашса, шуңа ярдәм кулы суз!
2. Мин үзем өчен яшәмәдем һәм яшәмәм!
3. Хәзерге көнлек теләгемез — федерация, йиргә социализация һәм барча инсаннарның ирекле, тигез, бәхетле булуларыдыр.

Галимҗан.

---

Текст фотокүчермәдән алынды. Автограф мәрхүм В. Гыйльмияров архивында саклана (Бирск шәһәре).

Бу автографның кыска гына тарихы бар. 1917 елның августында укытучы Вәсфи Гыйльмияров, Г. Ибраһимовны Бирск шәһәренә бара торган Агыйдел пароходында очратып, аңардан хатирә итеп бер-ике сүз язып бирүен үтенә һәм аңа кулындагы блокнотын суза. Әдип шундук аңа күңелендәге өч фикерне язып бирә.

...йиргә социализация... — эсерлар партиясе лозунгысы. Большевиклар партиясе исә Россиядәге барлык җирләрне национализацияләргә, ягъни дәүләт милкенә әверелдерергә тәкъдим итте.

1917 елда Г. Ибраһимовның җир турында эсерлар партиясе политикасын яклавы гаҗәп түгел, чөнки бу вакытта әле ул сул эсерлар партиясе члены иде. Шулай да ул күп кенә политик мәсьәләләрдә большевиклар белән бер сафта барды. Бу турыда үзе түбәндәгеләрне яза: «Сул эсерлар партиясенә член булып торган заманда җыелышларда, митингларда булсын, матбугатта һәм административ эштә булсын, минем бер урында да революциянең нигез мәсьәләләре турында большевик иптәшләр белән бер тапкыр да җитди фикер каршылыкларына килгәнем, бәхәсләшкәнем һәм полемикага кергәнем булмады. Киресенчә, полемист журналист һәм работник буларак, мин бөтен көчемне буржуаз хәрәкәткә һәм аның лакей агентларына каршы юнәлдердем».

4

## УКУЧЫ ЯШЬЛӘРГӘ

Казан, сәнә 1921, июль 2

Ерак Төркстан илләрендә яшәүче, шунда укып, халыкны агарту хезмәтенә хәзерләнүче яшь иптәшләргә Тойгы туташ Исхакова аркылы үз революционерлык сәламнәремне күндерәм.

Галимҗан Ибраһимов.

---

Текст А. Шамов архивындагы төп нөсхәдән алынды.

Тойгы туташ Исхакова — Мәрьям Шәйхетдин кызы Исхакова (Тойгы — әдәби псевдонимы).

Ташкент «Белем йорты»нда ачылган татар бүлегендә укучы М. Исхакова 1921 елның җәендә Казанга кайта, Г. Ибраһимов белән очраша һәм аңа үзе белән бергә укучы татар яшьләренең сәламен тапшыра. Әдип Төркстанда укучы якташларыбызның тормышлары, укулары, белемнәре белән кызыксына, мәктәпне тәмамлаганнан соң, аларны Татарстанга хезмәткә кайтырга чакыра һәм аларга бу хатны язып җибәрә.

**5**

## ТАТАРСТАН МАТБУГАТ һӘМ НӘШРИЯТ КОМБИНАТЫНА

Шагыйрь Мәҗит Гафуриның бу мәҗмугасы 1921 елда Татарстан җөмһүриятенең дәүләт нәшрияты тарафыннан сатып алынган иде. Хәзер инде ул договорның көчехокукы бетте, чөнки үткән дүрт ел буенча дәүләт нәшрияты һәм комбинат баса алмадылар. Минем фикеремчә, шагыйрьнең әсәрләрен басып тарату турында комбинат яки яңа төзеләчәк Татар[стан] дәүләт нәшрияты яңадан сөйләшергә — яңа договор язарга кирәктер.

Г. Ибраһимов — 1925 — сентябрь 1 — Казан.

Бу мәҗмуганы югарыда әйтелгән сәбәп буенча яңадан мөхәррирго бирдем. Бу хакта комбинатка аерым кәгазь биреле.

Г. И.

---

Текст Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтындагы төп нөсхәдән алынды: 12 ф., 1 тасв., 7 эш. Записка М. Гафуриның кульъязма хәлендәге «Мәҗмугаи асаре»ның титул бите читенә кыеклатып язылган.

...дәүләт нәшрияты һәм комбинат... — Дөресе: Татарстан матбугат һәм нәшрият комбинаты дип атала иде.

Яңа төзеләчәк Татарстан дәүләт нәшрияты... — Татарстан матбугат һәм нәшрият комбинаты 1926 елның башыннан Татарстан дәүләт нәшрияты дип атала башлады.

Бу мәҗмуганы ... яңадан мөхәррирено бирдем. — Шагыйрьнең «Мәҗмугаи асаре» басылмый калган. Кульъязма Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында М. Гафури кульъязмалары арасында саклана.

**6**

1 сентябрь, 1925.

## ТАТАРСТАН НӘШРИЯТ КОМБИНАТЫНА

1921 нче елда Мәҗит Гафури иптәшнең шигырьләр мәҗмугасы ул вакыттагы дәүләт нәшрияты тарафыннан алынып, басарга карар бирелгән иде. Мин берничә мәртәбә кузгатсам да, комбинат идарәсендә эшләүче иптәшләр: «Хәзергә төрле сәбәпләрдән болай мәҗмугаи асарләр басарлык чама юк, бераз кичектерергә мәҗбүрбез», — дия килделәр. Шулай кичегә килде.

Озаклык сәбәбеннән 1921 нче ел договорының хокукы, әлбәттә, чыкты инде. Хәзер бу мәҗмуганы шагыйрьгә биреп, басар өчен яңадан сөйләшергә кирәк, чөнки комбинат-нәшрият идарәсе шул күп вакыт эчендә үз хакыннан файдаланмады, шулай ук договор буенча шагыйрьнең әсәрләрен басып, дөньяга чыгара алмады.

«Татар әдәбияты көтепханәсе» сериясендә Мәҗит Гафури иптәш исеме бар. Анда аның әсәрләреннән 6-7 табак керер. Буны аерып сөйләшергә кирәк. Гыйльми үзәк буларны үз карамагында җыеп, аерып тапшырыр.

Гафури иптәш киткәнче Ленинградтан кайтып җитә алмавым ихтимал булганга, Гыйльми үзәкнең рәисе сыйфаты белән бу мәҗмуга хакында шул фикеремне хәзердән әйтеп үтәм: мәҗмуга әлбәттә, басылып чыгарга тиешле әсәрләрдән. М. Гафури иптәш, бездә 1905 нче елдан туып, реакция, сугыш, февраль аркылы пролетариат революциясе идеологиясенә килеп ирешкән бердәнбер карт шагыйремез булганга, аның әсәрләре классик матбугат җөмләсеннән булып басылачак нәрсәләрдәндер.

Гыйльми үзәк рәисе: Галимҗан Ибраһимов.

---

Текст А. Шамов архивындагы фотокүчермәдән алынды. Хатның төп нөсхәсе Уфада, М. Гафури архивында.

...комбинат-нәшрият... матбугат һәм нәшрият комбинаты.

Гафури иптәш киткәнче...—1925 елның җәендә М. Гафури Казанга килә. Г. Ибраһимов белән очраша.

Ленинградтан кайтып җитә алмавым ихтимал.— 1925 елның сентябрендә Татарстан хөкүмәте Г. Ибраһимовны, Казан гыйльми делегациясенең җитәкчесе итеп билгеләп, СССР Фәннәр академиясенең 200 еллыгы юбилеена җибәрә. Әдип Мәскәүдә, Ленинградта аның тантаналы утырышларында катнаша.

Гыйльми үзәкнең рәисе сыйфаты белән...— Г. Ибраһимов 1925 елның 7 январенда Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк председателе булып билгеләнә.

...1905 елдан туып...— иҗади туу мәгънәсендә.

# 7

## РКП (б)ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНА

### ИПТӘШ ӘХМӘДИЕВ ТУРЫНДА

I. Иптәш Әхмәдиевне мин 1901 елдан бирле беләм. Шул елны ул үзеннән өлкәнрәк яшьтәге бер иптәше белән бергә Оренбургтагы кадим мәдрәсәсенә, кесәсендә бер тиен акчасы булмаган хәлдә, яланаяк килеп керде.

Соңыннан мин аның өеннән качып килгәнен белдем. Чөнки әти-әниләре, ярлы булганлыктан, аны укытырга теләмәгәннәр,— дәресрәге, укытырга хәлләре булмаган.

Кечкенә Шәһит Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсе барлыгын, анда мәшһүр Әхмәт байның шәкертләрне үз акчасына, бер тиен түләтмичә укытуын, ашатып-эчертеп, бөтен яктан тәэмин итеп торуын каяндыр ишеткән булса кирәк. Шәһит, шул мәдрәсәгә килеп, керү имтиханнарының барысын да бирә, аны укырга алмакчы булалар, ләкин аның белән бергә килгән иптәше керү имтиханын бирә алмый. Иптәше алынмагач, Шәһитнең дә ул мәдрәсәгә керәсе килми. Шуннан соң алар мин укый торган мәдрәсәгә килделәр. Икесе дә чамасыз ярлы иде, шулай да укырга теләкләре бик зур иде. Шул көннән башлап Шәһит безнең мәдрәсәдә бик зур мохтаҗлыкта яшәп укыды. Оренбургта укыганда, ул, тамагын туйдырыр өчен, бай шәкертләргә аш пешереп, самовар куеп тора, шуның өчен алардан ай саен утызар тиен ала һәм шуның белән яши иде.

Бераз үсә төшкәч, 1910 елга чаклы, ул укуын дәвам иттерү өчен һәр җәйне, берәр хезмәт эзләп, мәдрәсәдән 3-4 айга чыгып китә башлады һәм шулай эшләп тапкан акча белән яшәде.

II. Иптәш Әхмәдиев 1905 елдан башлап шәкертләр арасындагы ислахчылык хәрәкәтенә актив катнашып килде, кадим, схоластик мәдрәсәләргә каршы көрәште һәм шуның өчен Оренбург мәдрәсәсеннән куылды. Шуннан соң ул Уфадагы җәдит мәдрәсәсенә барып керде. Аннан да ул шәкертләр җыелышларында муллаларга һәм байларга каршы чыгып сөйләгәне өчен куылды.

Шул вакыттан башлап ул журналистика һәм җәмәгать эшләре белән шөгыльләнә башлады, реакция елларында тантана иткән татар буржуаз милләтчеләр хәрәкәтенә һәрвакыт оппозициядә булып килде.

III. Февраль революциясеннән соң ул татар буржуазиясенә каршы ачыктан-ачык көрәшә башлый, социалистик мәсләкле «Аваз» газетасын чыгара, приказчикларның революцион оешмаларына җитәкчелек итә, иптәш Вахитов белән бергә Мөселман социалистлар комитетында эшли, аның җитәкчеләренең берсе була, «Бетсен сугыш!» «Бөтен власть Советларга!» һәм башка шуның кебек лозунгларны тормышка ашыра.

IV. Октябрь революциясе көннәрендә Казанның революция штабы Советларында актив эшли, Вакытлы хөкүмәткә каршы көрәшә.

1918 елның гыйнварында без иптәш М. Н. Вахитов белән бергә Милләтләр Советы янындагы Үзәк мөселман комиссариатын оештырганда, төрле губерналарда да җирле комиссариатлар оеша башлады. Иптәш Әхмәдиев Казанда шундый комиссариатны оештыручыларның беренче сафында булды.

Аның эшчәнлеген күрсәткән тагын бер моментны искә алып китәргә кирәк: 1917 елның ноябрендә Уфада төрек-татар милли парламенты дип аталган Милләт мәҗлесе җыелды. Без, Милләт мәҗлесенең сул канатында торучылар, баштагы утырышларның берсендә Петроградка, В. И. Ленин җитәкчелегендәге Халык Комиссарлары Советына котлау телеграммасы җибәрергә дигән тәкъдимебезне гомуми утырышка куйдык. Безнең бу тәкъдимебезне утырышка иптәш Әхмәдиев кертте һәм аның әһәмиятен аңлатып бирде. Моны ишетеп, буржуаз делегатларның котлары очты, бөтенләй каушап калдылар (тәкъдимебез тормышка ашмады, бары 17 тавыш кына алды).

V. Шул чактан башлап Әхмәдиев көрәшнең иң авыр моментларында һәрвакыт беренче сафта булып килде, массаның да, революцион хәрәкәт җитәкчеләренең дә ышанычын казанды. Ул 1917-1918 елларда, максималист чагында ук большевик иптәшләр тарафыннан һәрвакыт иң җаваплы эшләргә билгеләнде. Мәсәлән, 1918 елның сентябрендә, Казанны ак чехлардан азат иткәч, иптәш Пестковский (Сталинның урынбасары) аны, комиссиягә член итеп кертеп, Казанда совет учреждениеләрен аякка бастыру һәм контрреволюциягә каршы көрәшү өчен Татарстанга командировкага җибәрде.

1919 елның башында ул Урта Азиягә бара торган «Шәрык поезды»ндагы җаваплы политик эшкә билгеләнде. Аңа кадәр ул, максималист чагында ук әле, РКП(б)ның Казан губерна комитеты тарафыннан татар телендәге «Кызыл Армия» газетасына

редактор булып билгеләнгән иде. Болар барысы да партия оешмасының аңа ышанганлыгын исбат итәләр.

Гомумән, ул революциянең беренче көннәреннән башлап, РКП(б) сафына рәсми рәвештә кергәнче үк, һәр эштә, һәр мәсьәләдә, хәтта аерым детальләрне хәл иткәндә дә үзлексез рәвештә большевик иптәшләр белән бергә барды.

Мин аның үзен һәм эшләрен яхшы беләм. Ул эше белән дә, фикере белән дә большевик иптәшләрдән беркайчан да аерылмады. Шуңа күрә дуслары да, дошманнары да аны большевик дип исәплиләр иде.

Биографиясенең дә шуннан соңгы өлеше бөтенебезнең күз алдында узды, шунлыктан мин аның ул өлешенә туктауны артык саныйм.

Иптәш Әхмәдиев бары җәмәгать эшләре белән генә кызыксынып яшәде, бөтен көчен, белемен шуңа багышлады.

Ул — партия юлыннан һич тә тайпылмыйча баручы иң тотнаклы һәм иң революционер татар большевикларының берсе.

Иптәш Шәһит Әхмәдиевне мин менә шундый кеше итеп беләм.

$1925 \frac{8}{XII}$ Г. Ибраһимов.

---

Текст КПССның Татарстан Өлкә Комитеты архивындагы төп нөсхәдән алынды: 292 ф., 1353 эш. Русчадан тәрҗемә.

...Оренбургтагы кадим мәдрәсәсенә...— Вәли мулла мәдрәсәсенә.

«Хөсәения» — Оренбург шәһәрендәге җәдит мәдрәсәсе (1905—1918). Бөек Октябрь революциясеннән соң аның бинасына укытучылар институты урнашты.

Әхмәт бай — Хөсәенов Ә. (1837—1906). Оренбург сәүдәгәре.

...алар мин укый торган мәдрәсәгә килделәр.— Г. Ибраһимов Оренбургта кадимлеге, яңалыкка, прогресска каршылыгы белән дан тоткан Вәли мулла мәдрәсәсендә укыган.

...Оренбург мәдрәсәсеннән куылды.— Бу мәдрәсәдән шулай ук Г. Ибраһимов та куыла. Әдип үзе бу турыда: «Яңа фикерле булуым һәм уку-укыту эшендәге көнчыгыш схоластикасына каршы көрәшүем өчен куылдым»,— ди.

...Уфадагы җәдит мәдрәсәсе...— Мәдрәсәи «Галия». Г. Ибраһимов та шунда укый.

...Аннан да... куылды.— Бу мәдрәсәдән шулай ук Г. Ибраһимов та куыла.

«Аваз» — 1917—1918 елларда Казанда чыккан социалистик юнәлештәге татар газетасы.

Вахитов — Мулланур Вахитов (1885—1918)

Мөселман социалистлар комитеты — 1917 елның апрелендә Казанда Мулланур Вахитов җитәкчелегендә оештырылган комитет. Бу оешмага большевиклар һәм 1917—1918 елларда рәсми рәвештә яшәп килгән башка вак буржуаз партияләр членнары да кертелгән. Комитет 1918 елның августына чаклы яши.

Милләт мәҗлесе — төрек-татар вак буржуаз элементларыннан тупланган бу мәҗлес (парламент) үзенең «эшчәнлеген» 1917 елның 20 ноябрендә башлап, 1918 елның 11 февраленә чаклы дәвам иттерә. Мәҗлес Идел-Урал штатлары төзелүен игълан итә һәм Милли идарә сайлый.

Пестковский — Пестковский С. С. Совет хөкүмәтендә Милләтләр эше халык комиссариаты урынбасары.

«Шәрык поезды» — 1918-1920 елларда Совет хөкүмәте тарафыннан оештырылган агитпоездларның берсе. Лекторлар, агитаторлар, газеталар, китаплар, типография, кинофильмнар белән тәэмин ителгән бу поезд Мәскәүдән Төркстанга ике рейс ясады, шул өлкәләрдә яшәүче халыклар арасында Совет хөкүмәтенең һәм Коммунистлар партиясенең политикасын аңлату эшләре алып барды, җирле халык телләрендә «Кызыл Шәрык» исемле газеталар чыгарды һәм башка шуның кебек эшләр башкарды.

«Кызыл Армия» — 1918—1921 елларда Казанда һәм берникадәр вакыт Мәскәүдә чыгып торган татар совет газетасы.

## 8

26 март, 1926.

## ГӘҖУР МӨДИРЕ СӘЛАХ АТНАГУЛОВ ИПТӘШКӘ

### ӘДӘБИ КОМАНДИРОВКА ТУРЫНДА

Гыйльми үзәк яшь әдәби көчләрне эшче-крестьян районнарына мәгълүм вакытка әдәби максудлар өчен командировка бирү ысулын кулланырга карар бирде. Моның өчен бераз матди ярдәм кыйлачак. Беренче нәүбәттәгеләрдән берсе Һади Такташ билгеләнде. Ул апрельнең 15еннән июль башына ($2\frac{1}{2}$ ай) кадәр йөриячәк. Гәҗур

идарәсенә утенеч: шагыйрь Такташны шул эш вакытына Гыйль[ми үзәк]гә җибәрсәгез иде. Аның [хезмәт] урыны, әлбәттә, сакланырга тиеш.

Гыйльми үзәк рәисе: Галимҗан Ибраһимов.

---

Текст Татарстан Берләштерелгән дәүләт музее архивындагы төп нөсхәдән алынды. Гыйльми үзәк рәисенең грифлы рәсми кәгазенә язылган.

Гәжур — яңалифне тормышка үткәрү чорындагы газета-журналлар нәшрияты (егерменче елларның икенче яртысы, утызынчы елларның ахыры).

Гәжурга язылган бу кәгазьнең читенә түбәндәге резолюция салынган: «Һади Такташны ике ай ярымга Гыйльми үзәккә командировать итеп торырга Гәжур каршы килми. Сәлах Атнагулов. 26.III.1926».

## 9

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ. КАЗАН

## ВКП(б) ЧЛЕННАРЫН ҺӘМ КАНДИДАТЛАРЫН ТИКШЕРҮ ҮЗӘК КОМИССИЯСЕНӘ

ВКП(б)ның Казан Югары-Шәһәр оешмасындагы 11 нче номерлы ячейка (Татарстан Мәгариф Халык комиссариатында) члены, коммунист язучы Галимҗан Ибраһимовтан; партия билеты № 0979217, партия стажы 1917 елның 15 апреленнән

## ГАРИЗА

1927 елның апрелендә Татарстан республикасының Югары партия-совет органнары мине, каты авыру булуым сәбәпле, Кырымга — Ялта шәһәренә дәваланырга җибәргәннәр иде. Мин куркынычлы, күп кан килеп тора торган каверналы, 3 нче стадиядәге туберкулез белән авырыйм. Кырымда үпкәмнән тагын бер тапкыр кан килде. Шуның өстенә 1928—1929 елның кышында тамагым авырый башлады. Хәлемнең шундый булуына карамастан, климатның яхшылыгы, пневмоторакс, бик нык режим белән яшәү һәм дәвалануның башка шартлары нәтиҗәсендә сәламәтлегем системалы рәвештә рәтләнеп килә иде. Мин инде быел җәй көне вакытлыча Казанга да кайтып килермен дип ниятләнгән идем. Ләкин апрель-май аенда яңадан өзлектем — туберкулезлы үпкәмдә экссудативлы плеврит хасил булды.

Кризисның әле узганы юк һәм шуңа күрә якын арада Казанга кайту сәламәтлегем өчен зарарлы һәм куркынычлы.

Татарстан республикасы Үзәк тикшерү комиссиясенең миңа бу хәлдә нишләргә икәнен күрсәтүен үтенәм: сәламәтлегем өчен зарарлы булуга карамастан, якын арада тикшерүне узу өчен Казанга кайтыргамы яисә экссудативлы плевритым узып киткәнче, Комиссия миңа көзгә чаклы кайтмый торырга рөхсәт итәме?

Иптәш Ярославскийның 16 нчы Конференциядә ясаячак докладының тезисларында, 12 нче пунктында, авыру коммунистларның тикшерү вакытында аерым шартлар белән файдаланачаклары турында бер ишарә бар. Инструкциядә (32 нче пункт) түбәндәге сүзләр әйтелә:

«Әгәр партия члены яисә кандидаты тикшерелүне үтү өчен билгеләнгән вакытка мөһим сәбәпләр аркасында килә алмый икән, бу очракта ул, терелгәннән соң, тиешле контроль комиссия тарафыннан үз ячейкасында тикшерелергә тиеш. Кагыйдә буларак, тикшерелә торган иптәшне үзе булмаганда тикшермәскә тиешләр. Тикшерү комиссиясенә чакырылган партия членнарының һәм кандидатларның килүләре мәҗбүри».

Оптимист идем мин, бер-ике айдан терелеп, Казанга эшкә кайтырмын дип уйлаган идем. Шуңа күрә Кырым оешмасына күчмәдем. Һаман да ВКП(б)ның Казан Югары-шәһәр оешмасына кергән, Татарстан Мәгариф Халык Комиссариатындагы 11 нче номерлы ячейкада член булып торам; алар белән даими бәйләнештә яшим, аларга үзем турындагы информацияне системалы рәвештә җибәреп торам.

Ничек кенә булмасын, каты авырып ятуым сәбәпле, мин Кырым оешмасында да эшли алмаган булыр идем: Ялта шәһәре һәм шулай ук Мәскәү Врачебно-контроль комиссиясе тарафыннан да мин 1 нче группа инвалиды булып табылган кеше һәм пенсионер.



*Г. Ибраһимов. Кырым. Ялта. 1930 еллар тирәсе.*



*Г. Ибраһимов һәм Батыр Гозәеров (сулда). Кырым. Ялта. 1930 ел.*

*(Фоторәсемнәр матбугатта беренче тапкыр басыла).*

11 нче номерлы ячейка бюросында минем хакта белешмә булырлык материаллар бар,— мин аларга аны күптән түгел генә җибәргән идем. Әгәр кирәк икән, тиешле материалларны, документларны һәм шулай ук аңлатмаларымны да сезгә теләсә кайвакыт җибәрә алам.

Үтенечемне йомгаклыйм:

Әгәр мөмкин булса, тикшерү Үзәк Комиссиясенең миңа нишләргә икәнен ачык итеп күрсәтүен бик үтенәм:

1. Сәламәтлегемә зарар килүенә карамастан, якын арада миңа Казанга кайтыргамы, юкмы?
2. ~~Яисә~~ Татарстан Үзәк Комиссиясе тикшерелүемне, кимендә, көзгә чаклы кичектереп торырга мөмкинлек тапмасмы? Көзгәчә хәлем яхшырыр дип өметләнәм.
3. Яисә инде комиссия каты авырып ятучы коммунист язучы Ибраһимовны, үзе кайтмаса да, тикшерергә мөмкинлек табармы?

Коммунистлык сәламе белән: Галимҗан Ибраһимов.

16 июнь, 1929 ел, Ялта, ул. Халтурина, 5.

---

Текст КПССның Татарстан Өлкә Комитеты архивындагы төп нөсхәдән алынды. 1378 ф., 1987 эш, 147 б.

## 10

### КАВИ НӘҖМИГӘ

1 март, (?), Ялта.

Сайланма томнарымны бастырып чыгару өчен Татгосиздат белән ике арадагы договорга кул куюны сиңа тапшырам.

Ибраһимов.

---

Төп нөсхәсе А. Шамовның шәхси архивында саклана.

## 11

### ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӨЛКӘ КОНТРОЛЬ КОМИССИЯСЕНӘ

ВКП(б)ның Казан Югары-шәһәр оешмасындагы 11 нче номерлы ячейка (Татарстан Мәгариф Халык комиссариатында) члены, коммунист язучы Галимҗан Ибраһимовтан; партия билеты № 0979217, партия стажы 1917 елның 15 апреленнән

### ГАРИЗА

Партия үзәкләренең карары нигезендә ВКП(б) членнарын һәм кандидатларын тикшерү, чистарту эше партиянең XVI съездына чаклы тәмамланырга тиеш. Аңа вакыт бик аз калган, һәм шуңа күрә мин, партия тарафыннан тикшерелүне мин ничек үтәргә тиеш икәнен аңлатып бирүегезне үтенеп, Сезгә мөрәҗәгать итәм (беренче гаризамны 1929 елның июнендә җибәргән идем). Сезгә, бәлки, мәгълүмдер: 1927 елның апрелендә партия-совет органнары мине, каты авыру булуым сәбәпле, Кырымга дәваланырга җибәргәннәр иде. Шул көннән бирле мин Кырымда, Ялтада дәваланам. Төп авыруларым: 1) 3 нче стадиядәге туберкулез; 2) тамагымда туберкулез процессы; 3) каты дәрәҗәдәге үлекле плеврит. Мин хәзер хезмәткә яраклы кеше түгел — 90 процентка ятып авыручы. Хәлемнең шундый булуы аркасында, мин узган елны Казанга кайта алмадым. Бу турыда Сезгә хәбәр иттем, гариза җибәрдем (шулай ук ячейкага да). Шулай да мин 1930 елның язында партия тикшерүен узар өчен, Казанга кайта алырмын дип, бик нык ышанып тора идем. Ләкин хәзер, бигрәк тә быел яз башында яңадан кан төкереп авырганлыктан, андый ерак сәяхәтнең авыру организмым өчен бик зарарлы булачагы ачыкланды. Хәзер һәр ике атнага бер тапкыр плевраларымдагы үлекне суыртып алалар, юдырталар. Сәламәтлегемнең шундый хәлдә булуы партия тикшерүен узар өчен Казанга кайтырга мөмкинлек бирми.

Минем партия тарафыннан тикшерелүем мәсьәләсен хәл итүегезне үтенәм. Бәлки, соң дәрәҗәдә каты авырып ятучы коммунистка ташлама ясау рәвешендә, аны мин терелгәч үткәрергә мөмкинлек табарсыз. Коммунист буларак, бу мәсьәлә мине бик борчый һәм шуңа күрә мин Сезнең бер билгеле фикергә килүегезне — җавабыгызны көтәм. Бу үтенечем белән мин Үзәк Контроль Комиссиясенә мөрәҗәгать иттем.

Сәламәтлегемнең ни дәрәҗәдә икәнлеге турында соңгы вакытта алган белешмәне җибәрәм.

Коммунистлык сәламе белән: Г. Ибраһимов.

18 май, 1930 ел.

P.S. ВКП(б) Өлкә Комитеты агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире Г. Касыймовта һәм ВКП(б) Өлкә Комитеты партия тарихы бүлеге мөдире иптәш С. Гафуровта минем

турыда түбәндәге материаллар бар: 1) Автобиография, 2) документларымның копияләре; оригиналлары үземдә.

Югарыда күрсәтелгән материалларга тагын «Кызыл Татарстан» газетасының 85 нче санында басылган мәкаләләремне өсти алам. Ул мәкаләмдә мин культура мәсьәләләрендәге хаталарымны тануым турында язам. Шул ук газетаның [19]28 ел, 13 маенда чыккан санында яңалиф мәсьәләсенә багышланган икенче мәкаләм дә басылган.

Адресым: Ялта, ул. Халтурина, 5.

---

Текст КПССның Татарстан Өлкә Комитеты архивындагы төп нөсхәдән алынды. 1378 ф., 1987 эш, 145 б.

## 12

## ВКП(б) ҮЗӘК КОНТРОЛЬ КОМИССИЯСЕНӘ

Кырымда, Ялтада дәваланып ятучы, Казаннан килгән коммунист язучы Галимҗан Ибраһимовтан; партия билеты № 0979217, партия стажы 1917 елның 15 апреленнән

## ГАРИЗА

1927 елның апрелендә Татарстанның партия-совет органнары мине, каты авыру булуым сәбәпле, Кырымга дәваланырга җибәргәннәр иде. Хәзергә кадәр, беркая китмичә, Ялтада дәваланам. Сәламәтлегем бик начар: 1) күпләп кан килә торган актив формадагы, 3 нче стадиядәге үпкә туберкулезы; 2) тамагымда туберкулез процессы; 3) авыр формадагы үлекле плеврит. Чама белән һәр ике атнага бер тапкыр плевраларымнан үлекне суыртып алырга, юдыртырга кирәк.

Мин 90 процентка ятып авыручы кеше. Гәрчә кайчак, хәлем бераз яхшыланып китеп, урамга чыккалыйм, ләкин андый хәл бик сирәк була. Сәламәтлегем шундый начар булу сәбәпле, никадәр теләсәм дә, партия тикшерүен үтү өчен, Казанга кайта алмадым.

Минем белүемчә, бөтен тикшерү эшләре партиянең XVI съездына чаклы тәмамланырга тиеш. Вакыт бик аз калган. Сәламәтлегем хәзерге хәлдә булганда мин, партия тикшерүен үтү өчен, съездга чаклы Казанга кайту мөмкинлегеннән бөтенләй мәхрүммен. Каты авыру булуым (ул миңа барыбер Кырым оешмасында эшләргә мөмкинлек бирмәс иде) һәм Т[А]ССР партия-совет органнары белән иҗтимагый һәм материаль бәйләнештә торуым сәбәпле, мин шушы көнгә чаклы Казан оешмасындагы учеттан чыкмаган идем һәм, шулай итеп, Кырым оешмасына күчмәдем. Шуңа күрә мин, билгеле, партия тикшерүен Татарстан республикасында, Мәгариф Халык комиссариаты янындагы үзебезнең ячейкада үтәргә тиешмен. Бу турыда мин узган елны үзебезнең ячейкага һәм шулай ук Татарстан республикасының ВКП(б) Өлкә Контроль Комиссиясенә гариза җибәргән идем.

Сәламәтлегем начар булганлыктан, тиз арада (съездга чаклы) Казанга кайта алмавым хәзер тәмам ачыкланды.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, мин Сездән, каты авырып ятучы коммунистка ташлама ясау рәвешендә, партия тарафыннан тикшерелүемне сәламәтлегем беркадәр яхшырганга чаклы кичектереп торуыгызны үтенәм. Коммунист буларак, бу мәсьәлә мине бик борчый. Шуңа күрә мин аңа Сездән рөхсәт алырмын дип өметләнәм.

Коммунистлык сәламе белән Галимҗан Ибраһимов

18/V—1930 ел.

Сәламәтлегем турындагы кайбер документларның копияләрен гаризама терким.

Адресым: г. Ялта, ул. Халтурина, 5.

---

Текст КПССның Татарстан Өлкә Комитеты архивындагы нөсхәдән алынды. 1378 ф., 1987 эш, 143 б.

## 13

## КАВИ НӘҖМИГӘ

Кави, Сочи хатыңны алдым. Нык тазар. Үзеңә дә, Сәрвәргә дә теләк шул.

Бездә исәнлек, дөресрәге, исәнлек өчен үпкәдәге микробларга каршы туктаусыз көрәшү! Башка юк!

Әлманах килде, шәп чыккан. «Кояшлы яңгыр»ны бик яратып укыдым.

«Атака» чыккан, гәзиттә аның турында Мобарның зур мәкаләсе басылды.

Сочидан Ялта аркылы кайтып, безгә керсәгез, күңелле булыр. Гөлсем дә Сәрвәрне бик сагынып көтә.

Туры безгә төшегез! Сыярбыз, ачыкмабыз. Кудаш белән Булат андалар икән, үзләренә сәлам әйт. Ялтага килсеннәр! Кудашның бик күптән хат-хәбәре дә юк.

Хәзергә башка нәрсә яза алмыйм, үзегезне Ялтада көтеп калам.

Сәлам белән: Галимҗан.

$1930 - \frac{13}{\text{VIII}}$

---

Төп нөсхәсе А. Шамовның шәхси архивында саклана.

Әлманах — «Ун ел эчендә татар матур әдәбияты» (Казан, 1930) исемле альманах. Шул альманахта 1930 елда К. Нәҗминең «Кояшлы яңгыр» повесте басыла.

Мобар... Фазыл Мөбарәкшин (1903 елда туган) — журналист.

Кудаш... Сәйфи Кудаш (1894 елда туган) — Башкортстан халык шагыйре.

Булат... Булат Ишемгулов (?) — журналист.

## 14

## ТАТОБКОМ, СЕКРЕТАРИАТ. КАДЕРЛЕ АБДУЛЛИН ИПТӘШ!

Татобком исеменнән җибәргән телеграмыңны алдым. Ялта райкомы ул турыда тиешле чарасын күрде. Монда ризык эшләренең гадәттән тыш авырлыгына карамастан, мөмкин була торган дәрәҗәдә булышлык күрсәтү өчен, райком кирәкле җитәкчелекне итә тора.

Татобкомның телеграмы бу юлда, әлбәттә, бик таяныч булып төште.

Бу уңай белән Разумов иптәшкә һәм сиңа иптәшләрчә рәхмәт әйтүне үземнең бурычым саныйм. Минем дәвалануым, гомумән, алга бара. Мин инде туберкулез микробларын җиңдем. Тамагым да төзәлә. Миндә актык фронт: эренле-сулы плеврит калды. Бу да үзенең куркыныч стадиясен үтте. Алты ай бөтенләй бетеп торды. Бу ел яз тагын бераз кузгала кузгалуын, ләкин үткән тәҗрибә буенча аны җиңүемә нык ышанам, бөтен көрәшем хәзер менә шуңа юнәлгән. Бу дәвалануда ризык эше беренче планда торганга, Татарстан организациясенең үзенең авыру солдатын онытмау моменты минем каты режим белән бу чиргә каршы көрәш алып баруыма бик зур ярдәм булып төшә. Үземне тизрәк терелтеп, эшкә тотындырасым килә. Әле дә кәефем яхшырак чакта эшли башлау дәрте нык уяна, «Атака» белән «Кызыл Татарстан»га ара-тирә язгаларга өмет итәм.

Мин монда Электровод ячейкасына теркәлгәнмен. Хәлем килгәндә барам. Ләкин әлегә нагрузкалар үти алмыйм. Ячейка бюросы шуңа риза булды.

Минем бу җавап хатым бик кичекте. Аның сәбәбе шул: улым үлде. Бу эш белән байтак борчылдым. Аннан эрен суырттырганда хирург-докторның бер уңышсызлыгы аркасында бераз җәфаландым.

Абдуллин иптәш! Сез анда ВКП(б)ның Казан оешмасы солдатын — авырып, дәваланучы солдатын онытмагыз; терелермен, Татобком карамагына, эш-көрәш фронтына кайтып, кулдан килгәнчә хезмәткә җигелермен.

Коммунистлык сәламе белән: Галимҗан Ибраһимов

$19\frac{30}{\text{IV}}31$ ел — Ялта.

Текст КПССның Татарстан Өлкә Комитеты архивындагы нөсхәдән алынды. 15 ф., 12 тасв., 282 эш, 1 б.
Абдуллин... Абдуллин Бари Габдуллович (1899—1937) — 1930—1935 елларда ВКП(б)ның Татарстан Өлкә Комитеты икенче секретаре.

Разумов... Разумов М. О. (1894—1938) — Ул елларда ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре.

## 15

### ВКП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫНЫҢ ТАТАРСТАНДАГЫ УПОЛНОМОЧЕННЫЕ ЯНЫНДАГЫ ПАРТКОЛЛЕГИЯГӘ

Хөрмәтле иптәшләр, 1937 елның 8 февралендә язылып, иптәш Динмөхәммәдов кул куйган, 101 нче номерлы хатыгызны алдым.

Сезгә кирәк булган мәгълүматлар турында түбәндәгеләрне хәбәр итәм:

1. ВКП(б) членлыгына мин 1920 елның декабрендә Болак арты-Пеләтән районы оешмасы тарафыннан кабул ителдем.

Большевикларның Коммунистлар партиясенә керүем уңае белән мин Казандагы татар газеталарында («Кызыл Армия», «Эш», 1920 ел, ноябрь, декабрь айлары) «Редакциягә хат»ымны бастырдым; анда сул эсерлар партиясеннән кайчан чыгуымны һәм коммунистик оешмалар кул астында даими рәвештә эшләвемне күрсәттем.

2. Иптәшләрнең киңәше белән мин башта гаризамны, мине партиягә кабул итүне үтенеп, Өлкә Комитетына биргән идем. Ләкин аннан гаризамны үземә кире кайтарып бирделәр һәм миңа: бу мәсьәләне Өлкә Комитетында махсус карауның кирәге юк, ВКП(б) сафына сез гомуми нигездә гомуми тәртип буенча кабул ителә аласыз диделәр. Шуннан соң мин гаризамны Камил Якубов исемендәге типографиядәге эшчеләр ячейкасына бирдем. Мине партиягә шунда кабул иттеләр. Бу мәсьәләне район комитеты да карады. Соңыннан Болак арты-Пеләтән районы оешмасының гомуми җыелышында мине ВКП(б) члены итеп расладылар.

Күрәсез, мин, партия Өлкә Комитетының күрсәтүе буенча, партиягә гомуми нигездә гомуми тәртип белән кабул ителдем, гомуми исемлек белән гомуми тәртиптә партиянең югары оешмалары тарафыннан расландым.

Стажымны билгеләгәндә, минем Бөек Октябрь социалистик революциясенең беренче айларыннан ук көчемнән килгән һәм мөмкинлегем булган хәтле Коммунистик оешмалар җитәкчелегендә эшләвемне, шуның өстенә тагын 1918 елның январенда ук партиянең һәм пролетариатның бөек юлбашчылары иптәш Ленин һәм иптәш Сталин кул куйган махсус декрет белән Ленинградта Совет төзелеше фронтындагы җаваплы эшкә билгеләнүемне һәм башка, һәм башка шуның кебек хезмәтләремне искә алдылар.

Партия сафын чистартуларның барысында да һәм партия документларын алмаштырганда, боларның һәммәсе искә алынды һәм тикшерелде.

Коммунистлык сәламе белән: Галимҗан Ибраһимов.

19.II.1937. Ялта.

---

Текст КПССның Татарстан Өлкә Комитеты архивындагы нөсхәдән алынды. 1378 ф., 1987 эш, 17 б.

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ЯҢА ТАБЫЛГАН ХАТЛАРЫ

Язучы хатлары... Хатларында аның шәхси тормышы да, кешеләргә, дөньяга, ниһаять, үз мирасына мөнәсәбәте дә — һәммәсе дә ачык чагыла. Иҗат кешесенең лабораториясен өйрәнүдә алар кыйммәтле чыганак булып тора.

Бөек әдип Г. Ибраһимовның рәсми оешмаларга язган телеграмма-хатлары матбугатта 1928 елларда, Ялтада дәваланган чагында басыла башлый. Аерым кешеләргә адресланганнары исә әдипнең иҗади мирасы арабызга яңадан әйләнеп кайткач, беренче мәртәбә 1956 елларда дөнья күрә. Шул вакыттан алып бүгенге көнгә кадәр әдәбият һәм тел белгечләре, язучылар, башка профессия кешеләре, төрле урыннарда эзләнүләр алып барып, аның күп санлы хатларын газета-журналларда бастырып чыгардылар. Г. Ибраһимовның аралашкан даирәсе искиткеч киң булган. Хатлар табылуында дәвам итә. Журналның бу санында филология фәннәре кандидаты Фатыйма Ибраһимова тарафыннан Г. Ибраһимовның соңгы вакытта табылган ике хатын урнаштырабыз.

## Хәлим Искәндәревкә [1]

*13 май 1914 ел. Сухум. Уфа «Сабах» китап ширкәтенә[2]*

*Хәлим иптәш!*

*«Йолдыз» һәм Баттал[3] мәсьәләсе турында. Син «Йолдыз»ның мәгънәви рухын күтәрү турында әйтәсең, мин моны аңлыйм. Аны үз органыбыз итеп үз кулыбызга алу турында үткән ел ук сөйләшкән идек бит. Башкалар бит редакция органнарын әкренләп «үзләренеке» итәләр, безгә дә бу нәрсә, һичшиксез, кирәк.*

*Баттал анда чакта син дә, мин дә газетадан китмибез. Ә менә аның мәгънәви рухын ничек күтәрәбез — бу мәсьәләне бергәләп эшләү юлы белән генә хәл итәргә мөмкин. Моның өчен безгә күбрәк кеше һәм күбрәк көч тупларга кирәк. Баттал ярыйсы, ләкин аның кирәкле кешеләр туплау сәләте юк, әллә ул үзен бик югары тота, әллә халыкны аңлый алмый, шулай булса да, ул редакциядә эшли башлау белән, «Йолдыз»ның хәле яхшырды. Мин синең дә шуны ук эшләвеңне телим. Гомумән, мин сиңа Казанда тормыш башларга киңәш бирәм. Казан сине дә, мине дә тәэмин итә. Казаннан хәбәрдар булмыйча, аннан читтә торырга ярамый. Һәр матбугат эшлеклесе шул казанга керергә һәм шунда кайнарга тиеш. Мин бу кышта синең «Йолдыз»да булуыңны бик телим. Син миңа ачуланма, анда синең эшең казенный мәкаләләр язып, телеграммалар күчереп утырудан гына тормас, анда фантазияңне тулы көчкә җәелдереп җибәрү өчен киң мәйдан ачылачак. Анда син үзең теләгән өлкәне сайлап ала аласың, яисә эшкә кергән вакытта бу турыда Баттал яки Һади[4] («Йолдыз»ның редакторы) белән ныклап сөйләшергә кирәк. Менә Җәләй[5] («Вакыт» сотрудникы) күп яза. Синең дә әдәби багажың Җәләйнекеннән бер дә ким түгел. Әгәр дә бу урынны үзеңә алсаң, Баттал да аның рухи әһәмиятен күтәрер иде.*

*Мин үзем дә шунда гына язарга уйлыйм, ләкин беләсең, миңа вакыт-вакыт кына язарга мөмкин, дөресрәге, кирәк чакта даими рәвештә язып тора алмыйм. Гонорар шулай ук кыйммәтрәк булачак. Мин ышанам: һичшиксез, син бу эшкә алынырсың. Миңа калса, сиңа Казанда булырга һәм бу казанда кайнарга кирәк. Баттал үзен начар хис итә дип әйтәсең, ул, минемчә, үзен аз гына да начар урынга эләккән кеше хәлендә сизми.*

*Син нәрсә әйтмә, минемчә, кеше үзенә каршы төшүчеләр белән көрәштә генә акыл җыя, шуңа күрә мин аның «Йолдыз»да калуын телим, һәрхәлдә, мин «Йолдыз»да аның физиономиясе чагылышын күрәм, бары тик мәгънәсез Һадиның философиясе генә газетадан алган тәэсирне боза,югыйсә, Батталның эшли башлавы белән, «Йолдыз»ның физиономиясе күпкә үзгәрде. Минем теләгем — Һадины «Йолдыз»ның редакторлыгыннан читләштерү, аның урынына Батталны кую.*

*Һади бары нәшир генә булып калырга тиеш, чөнки ул анда бернинди роль уйнамый. Мин уйлыйм: синең килүең белән, газета зур популярлык казаныр иде. Син бит Уфада бик көчле исәпләнәсең. Син май аенда Уфада буласың. Уфадагы май айларын мин дә сагынам... Иптәшләргә миннән сәлам әйт. Фәхри[6] анда бугай. Зинһар*

*өчен хат яз. Мин монда сөргендә яшәгән кебек яшим. Хаттагы һәр сүзне минем йөрәгем кояш кыздырган комга тамган тамчы кебек сеңдерә.*

*Галимҗан.*

---

Хат рус телендә, Татарстан Үзәк Дәүләт архивының Казан губерна жандарм идарәсе фондыннан (199 ф., тасв., 2480 эш) алынды.

Г. Ибраһимов, Киевта мөселман студентлары хәрәкәтенә катнашуда гаепләнеп, 1913 елның 17 апрелендә кулга алына, бүлмәсенә тентү ясала. Кулъязмалары, документлары, китаплары, аңа килгән хатлар — һәммә әйберләре Киев губерна жандарм идарәсе карамагына күчә. Киев губерна жандарм идарәсе, үзләрендә татар тәрҗемәчесе булмаганлыктан, ул әйберләрне (дүрт төргәк) Казан губерна жандарм идарәсенә җибәрә. Монда татар телендәге кулъязмаларны штабс-ротмистр Трентовиус рус теленә тәрҗемә итә. Хат шул вакытта тәрҗемә ителгән булырга тиеш. Аның төп нөсхәсе кайда — билгеле түгел.

[1] Хәлим Искәндәрев Фәттах улы (1888—1958) — педагог, журналист, кечкенә хикәяләр, «Белек йорты» (беренче һәм икенче кисәк, 1912—1913) исемле уку китабы авторы, Г. Ибраһимовның Уфада «Галия» мәдрәсәсендә бергә укыган шәриктәше. 1913—1914 елларда ук Уфада «Сабах» ширкәтендә эшли. Хат җибәрелми калган булырга тиеш. Х. Искәндәрев ул вакытта Казанга килмәгән.

[2] Уфада «Сабах» ширкәте... — бу ширкәт 1911 елның декабрь башында Казандагы «Сабах» китап бастыру һәм сату ширкәтенең аерым филиалы буларак ачыла һәм Уфа губернасында китап сәүдәсе эшен җәелдереп җибәрә.

[3] Баттал... Габделбарый Батталов Габдулла улы (1883—1969) — буржуаз тарихчы, журналист, «Йолдыз» газетасында 1913 елның август аеннан алып эшли.

[4] Һади... Әхмәтһади Максудов Низаметдин улы (1868—1941) — педагог, телче, дәреслекләр авторы.

Г. Ибраһимов Һади Максудины «Йолдыз»ның редакторлыгыннан читләштерү фикере тормышка ашмый. Һ. Максуди 1906—1918 елларда Казанда чыккан либераль-буржуаз «Йолдыз» газетасының башыннан ахырынача редакторы һәм нәшире булып тора. Газета либераль буржуазия һәм демократия арасында тирбәлгәнлеге, ныклы бер мәсләге булмаганы өчен, аны татарның алдынгы карашлы демократик язучылары тәнкыйть итәләр.

[5] Җәләй... Җамалетдин Вәлидов (1887—1938) — күренекле тәнкыйтьче, татар теле һәм әдәбияты галиме, педагог, журналист. Ул 1913 елның башыннан алып «Вакыт» (1906—1918, Оренбург) газетасында эшли. «Вакыт»та башта Җәләй, аннан соң Җамалетдин Вәлидов имзасы белән татар әдәбияты тарихына, төрле язучыларның иҗатына караган күп санлы әдәби тәнкыйть мәкаләләре бастыра.

[6] Фәхри ... Фәхри Әхмәтов Шәйхетдин улы (1889—1938) — журналист, Г. Ибраһимовның «Галия»дә бергә укыган шәриктәше.

## Мөхәммәд Таһировка

*Мөхәммәд туганым![1]*
*22 ноябрь 1927 ел, Ялта.*

*Хатыңны алдым. Бераз аңлашылмауга охшаш хәлдә калдым. Ул 20 еллыкны[2] былтыр ук кайбер иптәшләр кузгаткан иде. Мин аңа бөтенләй каршы идем. Быел көн тәртибе телеграммалары алгач, иптәшләрчә бер сәламләп хәтерләү, авыруның күңелен юату дип уйлаган идем. Соңгы көннәрдә килгән хәбәрләр, газетадан кисеп җибәрелгән мәкаләләр буның хәзер төсенә керүе ихтималын күрсәтә. Мин 20 елны азга саный идем. Мондый көрәшләр кызган чорда коммунист өчен бер үз мәсьәләң белән халыкны мәшгуль итү ярамый дип тә карый идем. Әле дә шулай дим. Ләкин Сәгыйдуллин мәкаләсеннән күренгәнчә[3], анда инде машина әйләнергә тотынганы күренә. Казан хәлләрен яхшы белмәгәч, дөньядан хәбәрсез яшәгәч, ни дип әйтергә дә аптырабрак калдым. Үзегез тагын быелның декабреннән калдырмаска дисез. Шул арада ике телдә мәҗмуга чыгарырга[4], әсәрләрнең тулы җыелмасын[5] да басарга уйлыйсыз. Мин үзем, беләсең, берничә юбилейлар үткәрдем. Болар минем билемне бөкерәйттеләр. Сезнең комиссиягә кергән иптәшләр[6] һәммәсе гадәттән тыш мәшгуль иптәшләр. Алар ничек җыелышка килеп озаклап утырыр да ничек материалларны карар? Ягъни декабрьгә ничек өлгерерсез? Ашык-пошык эшләп, әллә ни чаклы хаталар, гафләтләр, мөсаһәләләр китү, тиешенчә оештырып җитә алмау, ни апара, ни камыр булу ихтималы бик-бик якын түгелме? Тарихи мәсъүлиятле бер эшне башлап та, бик зәгыйфь бер нәрсә алдында калуыгыз ихтимал түгелме? Хәзерлекнең,*

*вакытның азлыгы, иптәшләрнең бик мәшгульлеге теге югарыгы сәбәпләр өстенә минем сәлби карашыма болар да кушылалар түгелме? Ничек тә эш бик мәсъулиятле. Ничек очлап, тиз арада оештырып чыгарсыз, шуңа тәнкыйтьле күз белән карыйм. Бу хакта иптәшләргә, аеруча сиңа нык уйлап карарга кирәк. Минем тәнкыйтьле карашымны әйтеп, Сәгыйдуллин белән дә, Сәйфи Фатих*[7] *белән дә сөйләшеп үт әле. Бәлки тагын язармын, чөнки үземнең мондагы хәлләрем турында язарга хәзер арыдым. Кайбер мәсьәләләр турында Тулбайның соравынча*[8] *берничә җавап яздым. Син шуны алып карасаң ярар иде. Ул хатлар җибәрелгән инде. Сиңа җавап та әле кайта яза торырга хәлем җитми, арыдым.*

*Син Рифгатьнең библиографиясе турында*[9] *язгансың. Ялгышлык булмасын өчен син Рифгать белән сөйләш әле. Ул аны Гөлсем белән икесенең исеменнән чыгарган буладыр бит, чөнки Гөлсем берничә ел эшләп, ул библиографиянең әсасын җыеп, машинкада бастырып, син тагын арттыр, тутыр, икәү чыгарырбыз дип, үткән ел Рифгатькә биреп киткән иде. Гөлсем бераз борчылып калды: минем ничә ел түккән хезмәт югалмасын иде дип. Ул шул библиография мәсьәләсе өчен Казанга кайтып килергә дә дәртләнеп китте.*

*Хуш. Иптәшләргә сәлам әйт. Дуслык сәламе белән Галимҗан.*

---

Гафләт — наданлык.

Мөсаһәлә — игътибарсызлык.

Мәсьүлиятле — җаваплы.

Сәлби — кире, тискәре.

Әсас — нигез.

Хатның төп нөсхәсе КПССның Татарстан Өлкә Комитеты архивында (15 ф., 43 тасв., 22 эш) саклана. Гарәп шрифты белән язылган.

[1] Мөхәммәд ... Мөхәммәт Таһиров (1895—1929) — 1926—1927 елларда Татарстан Мәгариф халык комиссары, 1927 елның ахырыннан Татарстан Мәгариф халык комиссариаты каршындагы Академик үзәк председателе.

[2] 20 еллыкны ... — Г. Ибраһимовның 20 еллык иҗат юбилее тантанасы 1928 елның 10 мартында үткәрелә. Язучының иҗаты турында докладны татар телендә Г. Нигъмәти, рус телендә профессор Г. Линсцер ясый. Каты авыру булганлыктан, Г. Ибраһимов тантанага үзе кайта алмый.

[3] Сәгыйдуллин мәкаләсеннән күренгәнчә...— бу мәкалә табылмады. Миңлегәрәй Сәгыйдуллин бу вакытта Татарстан Өлкә комитетында агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире булып эшли.

[4] Ике телдә мәҗмуга чыгарырга... — Г. Ибраһимовның юбилее уңае белән өч җыентык чыгарылган: а) Галимҗан Ибраһимов (XX еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт бәйрәменә каратылып чыгарылган гыйльми-тәнкыйди җыентык). Казан, 1928; б) Галимҗан Ибраһимов (XX еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт түенә каратылып чыгарылган мәҗмуга). Ташкент, 1928; в) Галимджан Ибрагимов. Статьи П. С. Когана, А. Н. Самойловича и др. Казань, 1928.

Әсәрләрнең тулы җыелмасы ... — юбилей уңае белән «Галимҗан Ибраһимов әсәрләре»нең җиде томын чыгару планлаштырыла. 1929 елда 2 нче томы (Казан, «Яңалиф») дөнья күрә. 1, 3, 4 —7 томнары дөньяга чыкмый кала.

[6] Комиссиягә кергән иптәшләр ... — Г. Ибраһимовның юбилеен үткәрү комиссиясе 1927 елның 17 ноябрендә төзелә. Комиссия составына Н. Мөхетдинов (председатель), Г. Баһаутдинов, Ш. Камал, И. Рәхмәтуллин, М. Давыдов (секретарь), М. Таһиров, Ф. Бурнаш, С. Борһанов, Г. Сәгъди керә.

[7] Сәйфи Фатих ... — Фатих Сәйфи-Казанлы, Камалетдинов (1888—1942) — язучы, журналист, ул вакытта «Яңалиф» журналының редакторы.

[8] Тулбайның соравынча берничә җавап язам...— Тулбай — Гомәр Толымбайский (Габделхак Шаһиахмәтов) (1900—1938) — татар совет язучысы. Г. Ибраһимовның 1927 елның 2 ноябрендә язган хатының аерым өзекләрен Г. Толымбай «Безнең юл» (1927, 12 сан) журналында, «Кызыл Татарстан» (1927, 4 декабрь) газетасында бастырып чыгара. Бу хатта киң күпчелек өчен кызыклы булган мәсьәләләр күтәрелүен әйтә.

[9] Рифгатьнең библиографиясе турында ... — Рифгать Шакирҗан улы Таһиров (1903—1977) тарихчы, педагог, профессор, Татарстанда библиография эшен фәнни нигездә коруга зур хезмәт керткән кеше. Ул һәм Гөлсем (Мөхәммәдева Гөлсем Давыт кызы, 1903, Г. Ибраһимовның тормыш иптәше) бергә Г. Ибраһимов әсәрләренең библиографиясен төзиләр һәм ул библиографияне «Галимҗан Ибраһимов» (Казан, 1928) исемле мәкаләләр җыентыгында бастырып чыгаралар.

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ АВТОГРАФЛЫ КИТАБЫ

Атаклы каләм осталарының һәрбер язмасы, алар турындагы истәлекләр әдәбият сөючеләр тарафыннан кызыксынып кабул ителә. Бу шулай булырга тиеш тә. Зур традицияле әдәбиятларда эш нәкъ шулай тора. Бик еракларга китеп тормастан, рус әдәбияты һәм укучылары арасындагы хәзерге мөнәсәбәткә күз төшерсәк, бу фикернең дөреслегенә ышану кыен булмас. Татар әдәбияты да борынгы һәм зур традицияле әдәбиятларның берсе. Йөзләгән әдип-шагыйрьләребезнең гасырлар дәвамында халык кулында сакланып килгән әсәрләре безнең замангача килеп җиткәннәр. Соңгырак гасырларда яшәгәннәренең автограф кульязмалары, китаплары да бар (мәсәлән, Батырша, Габдерәхим Утыз Имәни, Г. Кандалый, Гали Чокрый һ. б.). Алар турында халык телендә төрле риваять-легендалар, мәзәкләр дә сакланган. Мондый характердагы материаллар белән кызыксыну бездә соңгы елларда аеруча көчәйде. Моңа мисал итеп фәнни үзәкләргә әдипләребезнең иҗат мирасларын туплау, аларның биографик материалларын өйрәнү, истәлекләр бастырып чыгару һ. б. шушы җәһәттән башкарылган эшләрне күрсәтергә мөмкин.

Татар әдәбияты классигы, күренекле галим һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына йөз ел тулу уңаеннан да аның иҗатын һәм тормышын өйрәнүдә шактый зур эшләр башкарылды: әдипнең сигез томлык әсәрләр җыелмасы бастырылды, биографиясе буенча капиталь хезмәт дөнья күрде, аның хакында истәлекләр җыентыгы чыкты. Ләкин шуңа да карамастан, әдәбиятчыларыбыз аның шәхесе алдында бурычлы булып калалар сыман. Әдипнең мирасын һәм үзен пропагандалау җитешми әле. Архивларда, шәхси кулларда кызыклы материаллар саклануы шөбһәсез. Шундый әйберләр табылу — Г. Ибраһимовның иҗатын өйрәнүне тагын да үстерүгә этәргеч булыр иде. Эзләнгәндә ни булса да табылу мөмкинлегенә үрнәк итеп, әдипнең автографлы бер китабы хакында язып үтмәкче булабыз. Г. Ибраһимовның бай архивы, китапханәсе булса да, безгә килеп җитмәгән, шунлыктан аның анда-санда гына калган аз санлы автограф язмалары да безнең өчен кыйммәтле.

Бөтен гомерен Казанда үткәргән финанс хезмәткәре Зөфәр ага Абдуллин безгә үзе тапкан бер төргәк төрле иске китаплар биргән иде. Шул төргәктәге бер китапка күзем төште. Бу Галимҗан Ибраһимовның «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы» исемле әсәре (Казан, 1922). Китапның тышлыгы юк, беренче битенә «Бу хезмәт Шәрыкның вакытсыз һәлак булган бөек революционеры Мулланур иптәш Вахитов хатирәсенә багышлана» дип зур итеп басылган. Ул язудан өстәрәк коңгырт кара белән кулдан «Г. Газиз иптәшкә ядкарь итәм буны. Галимҗан Ибраһимов. 1922 — май 26. Казан», — дип язып куелган. Әлеге язма китапның кызыклы тарихы булуы хакында сөйли. Г. Ибраһимов аны күренекле тарихчы һәм язучы Газиз Гобәйдуллинга (Г. Газиз) биргән булган. Зөфәр ага Абдуллин аны Казандагы Нариман урамы тирәсендәге бер ташландык сарайдан тапкан. Анда, Ватан сугышына китеп, вакытсыз һәлак булган татар әдәбиятчысы Мөхәммәтша Маминның да кайбер китаплары булган. Ихтимал, автографлы китапны башта М. Мамин тапкан булгандыр, ләкин аның саклануы өчен без Зөфәр агайга бурычлы. Бу китап күп нәрсәләр хакында сөйли ала. Шуларның берсе Г. Ибраһимов һәм Г. Газизнең үзара мөнәсәбәтләре мәсьәләсе. Алар арасындагы мөнәсәбәтләр, чыганакларга караганда, төрле төсмерләр алган. Мәсәлән, егерменче еллар ахырында Г. Ибраһимов Г. Газизне кискен тәнкыйтьләп чыгышлар ясый. Әгәр без татар культурасының бу ике күренекле вәкиленең үзара мөнәсәбәтен егерменче елларның ахырларында булган халәткә нигезләнеп кенә билгеләсәк, аны берьяклы хәл иткән булыр идек. Яңа табылган автограф әлеге мөнәсәбәтләрнең иптәшләрчә булуын да күрсәткән бер документ буларак әһәмияткә ия.

**Марсель ӘХМӘТҖАНОВ,**
филология фәннәре кандидаты.




**Мәхмүд Зарипов,**

физика-математика фәннәре докторы, профессор

# ВАСЫЯТЬ

Утыз алтынчы елның августы... Мин, Казан педагогия институтының базасы булган 13 нче урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Кырымның Симеиз дигән урынында ял итәм. Симеиз — Кырым ярымутравының иң көньяк ноктасы. Табигать гаҗәп гүзәл. Диңгез... Мин аны беренче тапкыр күрәм, аның суының үтә күренмәле булуы, кайчагында тыныч кына дулкынлануы, ә кайбер вакытларда дулавы, ниндидер илаһи көч белән ярларга кагып, җирне тетрәтүе мине гаҗәпләндерә, сокландыра. Ә менә шул шаулап торган диңгезгә йөгереп кереп, катып калган кыз, аның артыннан чабып килгән монахның юлын кискән мәче кыялары диңгездән, аның дулауларыннан курыкмагандай горур басып торалар. Дулкыннар, дәһшәтле дулкыннар Кыз кыясына бәреләләр дә кире чигенәләр...

Минем күңелемдә Кырымга барачагым хәл ителгәч үк туган бер теләк, зур теләк бар. Ул бер генә минутка да хәтердән чыкмый. Ялтада, халкыбызның бөек әдибе Галимҗан ага Ибраһимов яши, дәвалана! Ничек кенә булмасын, аны барып күрәсе килә. Без — кечкенәдән үк аның әсәрләрен укып, өйрәнеп, аның әсәрләрен бәхәсләр, әңгәмәләр аркылы үткәреп, талантына сокланып, үзен яратып, үз итеп үскән яшьләр идек. Ул безнең күз алдына иң бөек язучы булып килеп баса. Аны күрергә теләк бик зур, ләкин ничек үзеңдә батырлык табарга да, аның алдына барып басарга?.. Ялтага сәяхәтне көннән-көн калдыра килсәм дә, ниһаять, теләк җиңеп чыкты. Төн йокламадым, уйладым-уйладым да, юлга чыктым.

Автобус диңгез ярлары өстеннән бормаланып-бормаланып сузылган юл буенча алга — Ялтага йөгерә. Мин диңгезгә карыйм, ул яр башыннан уч төбендәге кебек ачык күренә. Хәтергә «Безнең көннәр» романының беренче юллары килеп төшә:

«Төн караңгы. Дөнья тын. Ләкин диңгез шаулый. Диңгез төбәндә кемгәдер ачу белән үкерә. Аның куәтле дулкыннары, тау-тау булып, биек, ташлы, текә ярларга һөҗүм итәләр. Күңелгә шом килә: гүя менә-менә тагы бер тапкыр ыргып атылачаклар да дөньяны каплап китәчәкләр...» Чыннан да, диңгезгә күзләре төбәлгән кешегә шундый уйлар килә. Нинди оста язган мондый халәтне Галимҗан ага!

Ләкин ул уйларны күңелдән чыкмаган борчылу хисе баса — әле бит Галимҗан аганы эзләп табасы бар...

Көтмәгәндә, бу мәсьәлә җиңел хәл ителде — адреслар өстәлендә тиз генә «Боткинский урам, 25» дигән белешмә бирделәр. Мин урамны озакламый эзләп таптым.

Тын урам. Урамның ике ягында да агачлар, шулар арасында йортлар... 25 нче йорт — таш нигез өстенә корылган рәшәткәләр артындагы бакча эчендә салынган, ике этажлы. Ниһаять, мин бакча эченә кереп, ишек янына килдем дә, кыңгырау тоткасын тарттым. Бераздан баскычтан төшкән кеше аяк тавышы ишетелде һәм ишек ачылып китте. Мине бик чибәр, ягымлы карашлы бер апа каршылады. Мин кыяр-кыймас кына Казаннан килүемне, Галимҗан аганы күрергә бик теләвемне әйттем. Апаның йөзе караңгыланып киткән кебек булды, ул:

— Белмим шул... кабул итә алыр микән, авырып тора бит,— диде. Мин югалып калдым. Хәлем шунда ук йөземдә чагылды ахрысы, апа — мине юатасы килепме:

— Ярар, энем, син көтеп тор әле, мин аның белән сөйләшеп карыйм,— дип өскә менеп китте. Өмет өзелә язып калды, көтү бик озакка тартылды кебек тоелды.

Менә, баскычтан түбән төшмичә генә, әлеге апа мине чакырды. Мин ашыгып икенче этажга мендем. Апа миңа:

— Аның кәефе шәптән түгел, бик ялыктырма инде син аны,— дип пышылдады да бер бүлмәгә алып керде.

Зур булмаган бүлмә, стеналары акшар-

ланган, түрдә тәрәзәләр, тәрәзә янында язу өстәле, китаплар, урындык. Стена буенда карават, ап-ак җәймәләр җәелгән урын-җир. Караватта кара костюм кигән, галстук бәйләгән, одеялы биленә кадәр генә ябылган килеш Галимҗан ага ята... Мин килеп исәнләштем...

Мин аны фоторәсемнәре, бигрәк тә художник П. П. Беньков язган портреты буенча күз алдына китерә идем. Без, мәктәп балалары, рәсем дәресләрендә аның портретын ясарга тырышабыз, кайбер уңышлы чыккан рәсемнәрне класс бүлмәләренең стеналарына элеп куябыз, күргәзмәләрдә күрсәтә идек. Ул безнең күз алдына сабантуйларындагы көрәшче батырлар кебек физик яктан көчле, мәһабәт бер кеше кебек килеп баса иде. Әмма аңа беренче күз ташлау мине шул хәтле тетрәтте, мин елап җибәрә яздым, чак-чак кына үземне кулга алып өлгердем. Караватта сирәк чал чәчле, мыеклары да агарган бик ябык кеше ята иде. Күрешкәндә, аның кулы шул хәтле кечкенә, коры сөяккә калган кебек булып тоелды...

Мин аның янындагы урындыкка утырдым да ни әйтергә белми югалып калдым. Ул миңа гаҗәпләнмәде булса кирәк, үзе сүз башлады:

— Я, егет, сөйлә әле, Казан нихәл? — дип сорау бирде. Билгеле инде, мин Казан дигәч, үзем яшәгән Яңа бистә турында сөйли башладым. Анда яңа завод, фабрикалар оештырылуын, мехкомбинат төзелүен, Яңа бистәнең бик күп кешесе хәзер шунда эшләвен, минем әтиемнең дә мехкомбинат эшчесе булуын әйттем. Яңа бистәгә трамвай юлы салуларын мактанган кебегрәк сөйләп бирдем. Яңа бистәнең бер мәчетендә мехчылар клубы ачылуын, анда һәркөн кино, спектакльләр куелуын, балалар өчен дә күп эшләр эшләнүен сөйләп бирдем. Кичәләрдә, концертларда бик кызык номерлар була, әле менә бер тапкыр, трамвайны тәнкыйтьләп, кызык җыр да чыгардылар:

Яңа бистәгә салдылар
Трамвай юлын сузып.
Мәхүп карчык җәяү кайткан
Шул трамвайны узып.

— Ә эшчеләр ничек яшиләр соң, тормышлар ничек? — дип сорады Галимҗан ага.

— Ару гына,— дидем мин,— күптән түгел ике катлы универсаль магазин төзелде. Фабрикаларда медпунктлар ачылды, ләкин күп кеше, бигрәк тә олы яшьтәгеләр, Исмәгыйль докторга (Исмәгыйль ага Усманов — күптәннән Яңа бистәдә яшәгән, халыкны дәвалаган доктор) йөриләр, чөнки йомшак табигате, һәрвакыт кешегә ярдәмгә килергә хәзер торуы аңа зур ихтирам тудырган һәм аңа зур ышаныч белән баралар. Бистәдә әле кустарьлар да бетеп җитмәгән, ләкин эшчеләр аларга караганда әйбәтрәк яшиләр.

— Хәзер инде үзең укыган мәктәп турында сөйлә! — диде ул.

— Мин беренче класстан алып 7 ел буе Тукай урамындагы элеккеге рус-татар учительская школа бинасында урнашкан 12 нче үрнәк мәктәптә укыдым. Аның директоры күренекле тел галиме, педагог, Габбас ага Сәйфуллин иде. Беренче класста безне Мәдинә апа Сагыйтова укытты; ул революциягә хәтле Аитово гимназиясендә укыткан укытучы иде. Аннан соңгы классларда безне Нәфисә апа Багданова, Шакир абый Нигъмәтуллиннар, ә икенче баскычта Мәхмүт абый Рәхмәтуллин, Һашим абый Вәлиев, Әхмәт абый Тимерханов укыттылар. Һашим абый безне бакчачылык эшенә өйрәтте, мәктәпнең тәҗрибә бакчасында без төрле яшелчәләр үстерергә, җиләк-җимеш куакларын, агачларын утыртырга, карарга, зур уңыш алырга өйрәндек. Әхмәт абый исә безне физика өлкәсенә алып керде, без электромоторлар ясадык, электр линияләре үткәрдек, радиоалгычлар белән кызыксындык һәм радиосөючеләргә әйләндек. Бу мәктәптә әдәбият түгәрәге күптән эшләп килә иде. Түгәрәк җыелышларына шагыйрьләр — Һади Такташ, Гадел Кутуй еш килделәр, шигырьләрен укыдылар, яшь шагыйрьләргә киңәшләрен бирделәр. Түгәрәк членнары арасында хикәя, шигырь язучылар да бар иде. Шулар арасында, авылдан килеп, Әхмәт бай йортында урнашкан мәктәп интернатында яшәп укучы Галимҗан Мөхәммәтшин да бар иде. Ул инде хәзер яшьләрнең яраткан шагыйре булып үсте. Әдәбият кабинетында стеналарда рәсем түгәрәге членнары ясаган портретлар — Галимҗан ага, сезнең портретыгыз, Һади Такташ, Габдулла Тукай портретлары бар иде. Мәктәптә еш кына әдәби кичәләр оештырылды, анда башлап язучылар үзләренең хикәяләрен, шигырьләрен укыдылар. Моннан башка Тукай урамында элекке Кәримовлар типографиясе белән янәшә йортта «Шәрык» китапханәсе бар иде. Аның түбән катында балалар әдәбияты, ә икенче катында зурлар әдәбияты тупланган иде. Без ул китапханәгә еш йөрдек, класстан-класска күчә барган саен, акрынлап беренче катыннан икенче катына мендек.

Мин җиденче классны бетерү вакыты безнең илдә 10 еллык урта мәктәпләр оештыру заманына туры килде. Ләкин 8 нче классларны туплау мәгариф органнары өчен читен мәсьәлә булып чыкты. Нәтиҗәдә, берничә мәктәптән 8 нче класста укырга теләүчеләрне җыеп, 13 нче номерлы Яңа бистәдәге үрнәк-тәҗрибә мәктәбендә 8 нче класс ачтылар. Мин дә шул мәктәпкә укырга күчтем. Бу мәктәп Казан

дәүләт педагогия институтының база мәктәбе булып китте. Монда барлык фәннәрдән дә тәҗрибәле укытучылар килделәр.

13 нче мәктәптә дә әдәбият түгәрәге оешты һәм ул бик актив эшли, анда өметле каләмнәр — Гарәфи Хәсәнов, Җәвад Тәрҗеманов, Ильяс Әхмәтгалиев, Лотфулла Фәттахов кебек иптәшләр бар. Түгәрәкнең күп члennары «Яшь ленинчы» газетасы, «Октябрь баласы», «Пионер каләме» журналларының актив хәбәрчеләре булып киттеләр. Мәктәпнең үзендә дә «Әдәбиятчы» исемле даими стена газетасы чыга торды. Мин дә бу газеталарда, журналларда шигырьләрем, хикәяләрем, очеркларым белән катнаштым, хәтта «Яшь ленинчы» битләрендә ВЛКСМ Өлкә комитеты оештырган әдәби конкурста икенче дәрәҗәдәге бүләккә дә лаек булдым. Безгә шагыйрьләр, язучылар еш килделәр, ярдәм иттеләр. Без мәктәптә генә түгел, Габдулла абый Алиш оештырган шәһәр күләмендә эшләүче әдәби түгәрәк эшендә дә актив катнаштык. Безнең драмтүгәрәк тә үзебез язган кайбер кечкенә әсәрләрне сәхнәгә куйды. Кайбер пьесаларны без мәктәп сәхнәсендә генә түгел, мехчылар клубында, «Кызыл Шәрык» клубы сәхнәләрендә эшчеләргә дә уйный идек. Зуррак пьесаларны куйганда, ике мәктәп укучылары бергә кушылып иҗат иттек. Икенче мәктәп укучылары арасында Гөлсем апа Болгарскаяның кызы Фирдәвес Болгарская, Галиәсгар ага Камалның кече улы Фаик Камал, Сәет Шәкүров тә бар иде.

Шул вакытта апа килеп кереп, минем сүзне бүлде:

— Син инде бик арыгансыңдыр. Сиңа бит озак сөйләшергә ярамый, хәлең китә. Егет тә инде сине күрде, тынычлангандыр,— диде дә миңа карап алды. Мин тиз генә урынымнан сикереп торып, гафу үтенергә керештем.

— Юк, — диде Галимҗан ага, — мин арымадым гына түгел, авыруымны да онытдым әле. Бик кызык хәбәрләр алып килгән бу егет. Сөйләсен, син инде безгә комачаулый күрмә,— диде. Ялыныбрак әйтеп куйды.

Апа чыгып китте. Галимҗан ага миңа «утыр»! дигәндәй ияк какты да сүзне дәвам итәргә кушты.

— Без әдәбиятны бик яратып укыйбыз. Әдәбиятны гына түгел, аның тарихын да, тел тарихын да кызыксынып өйрәнәбез. Тик менә ул китаплар хәзер юкка чыкты инде, чөнки алар иске әлиф белән басылган иде. Ул күп китапларны яңалиф белән ничек тиз арада басып өлгертсеннәр,— дип офтанып куйдым.

— Әйе шул,— диде Галимҗан ага, ләкин башка сүз әйтмәде.

Мин дәвам иттем.

— Без әле менә 10 нчы класста укыла торган әсәрләрне ничек анализларга, ничек аңларга дигән мәсьәләләргә дә тукталдык. В. И. Ленинның «Лев Толстой — зеркало русской революции» дигән әсәрен өйрәндек. Шул уңай белән мәктәп директоры мине матбугат йортына язучы Гомәр абый Толымбай янына җибәрде. Мин анда килгәч, Гомәр абый хәл-әхвәл сорашкан кебек итте дә аннан соң укучыларның В. И. Ленин әсәрен ничек аңлаулары турында сораша башлады. Сорау артыннан сорау бирде, минем җавапларымны дәфтәренә терки барды. Бу очрашу минем өчен шактый катлаулы имтихан булды. Ниһаять, сораулар бетте. Ул миңа рәхмәт әйтеп кайтарып җибәрде.

— Ул сиңа бернинди дә киңәш бирмәдеме? —дип сорады Галимҗан ага.

— Юк,— дидем мин,— хәтта дөрес җаваплар бирдемме, әллә ялгыштыммы, аны да белә алмадым.

— Алайса, мин киңәш бирим сиңа, — диде ул.— Ленинның әдәбият турындагы фикерләре бик тирән мәгънәле. Аның сез өйрәнгән әсәре дә — зур әһәмиятле әсәр. Һәрбер әсәрне укыганда, өйрәнгәндә, анда сурәтләнгән вакыйгаларны, кешеләрне, аларның тоткан юлларын анализлаганда, Ленинның сүзләрен истә тотарга, Ленинча аңларга тырышырга кирәк. «Лев Толстой — рус революциясе көзгесе» дигән әсәр шундый анализның гүзәл бер үрнәге ул,— диде. Ул бу сүзләрне сөйләгәндә, мин аның язуы гына түгел, сөйләве дә гаҗәп тасвирлы, күңелгә ятышлы һәм бик аңлаешлы булуына сокландым. Сүзләре җаны үзегеннән чыккан кебек тоелды. Бу сүзләрне әйткәндә, аның йөзендә нур балкып китә, иреннәре арасыннан алтын тешләре ялтырап ала иде.

Мин сүземне дәвам иттем:

— Без, Галимҗан ага, шигырьләрне дә бик яратабыз. Тукай безне «Туган тел» аркылы яңа дөньяга алып керә дә аның матурлыгын да, тормышның әчесен-төчесен дә сөйләп бирә, халыкны җәберләүче байларга, надан муллаларга нәфрәт уята, киләчәкне матур итеп тасвирлый. Аның бар сүзе күңелгә үтеп керә, уйланырга чакыра... Һади Такташ та безнең сөекле шагыйребез, без аның әсәрләрен көтеп алабыз да ятлыйбыз, күп шигырьләрен күңелдән беләбез,— дидем дә «Мокамай»ны сөйләп киттем. Аннан соң Тукайның «Көзге җилләр»ен...

Белмим, мин бу шигырьне бик дулкынланып сөйләдемме, әллә Галимҗан аганың хәтеренә нинди дер хәлләр, узган көннәр килеп төштеме, ул аны бик әсәрләнеп тыңлады. Без тынып калдык.

— Тик менә мәктәптә Тукайны өйрәнгәндә, безгә — укучыларга аңлашылмаган кайбер моментлар кала. Тукай, гомере буе авыр тормышта яшәгән, халыкның бәхете өчен бөтен көчен куеп эшләгән Тукай, аның иҗатын өйрәнүгә нәтиҗә ясаганда,

вак буржуа шагыйре дип атала. Без моңа бер дә риза түгел; без борчылабыз да, укытучыбыздан аңлатуын үтенәбез. Бу сораудан соң укытучының йөзе сытыла, аны ничектер борчу басып киткәндәй була. Ул бары «шулай исәпләнә инде» дип кыяркыймас кына җавап бирә. Без Бөек Октябрьдән соң туган, октябрят, пионер булып тәрбияләнгән, комсомол булып җитешкән яшьләр безнең иң яраткан шагыйребезне, бөтен гомерен халкы өчен, аның бәхете өчен, матур киләчәге өчен корбан иткән шагыйребезне болай вак буржуа шагыйре дип атау һич тә мөмкин түгел дип исәплибез. Дөреслек кайда? — дидем дә куз яшьләремне тыя алмадым... Галимҗан агага бу сүзләр бик нык тәэсир итте ахрысы. Ул миңа карап-карап торды да:

— Мин үзем дә бу турыда күп уйландым. Тукайның иҗаты турында күп уйладым. Ул иҗатны тирәнтен өйрәнергә, Ленин кушканча өйрәнергә кирәк! — диде.

Берникадәр вакыт үткәннән соң, мин тынычлана төшкәч:

— Минем сезгә — яшьләргә сүзем шул — Тукайны укыгыз, Тукайны яратыгыз, Тукайны өйрәнегез! Ул бу сүзләргә аеруча басым ясады, күтәренкерәк тавыш белән әйтте.

Аның бу сүзләре мине тынычландырды. Ул моны күреп, миңа сорау бирде.

— Син инде мәнә урта мәктәпне тәмамлагансың. Хәзер нишләргә уйлыйсың соң?

— Мин үземә юл сайладым. Казан университетының физика-математика факультетына кердем. Мәктәпне алтын аттестатка бетергәнлектән, имтихансыз кабул итteләр дә, әле менә монда Кырымда ял итәргә путевка да бирделәр,— дидем.

— Син инде, алайса, тырышып укы, мәктәбеңнең йөзенә кызыллык китермә! Сиңа уңыш телим! — диде ул.

Сөйлисе сүзләр беткән иде бугай, көн дә икенче яртысына авышты. Минем янымда фотоаппаратым бар иде. Мин Галимҗан аганы рәсемгә төшерергә теләп, рөхсәт сорадым.

— Юк инде, энем,— диде ул,— син мондый хәлдә мине рәсемгә төшермә, югыйсә Казанда мине ятып тора торган авыру дип күз алдына китерәләр. Менә бер язучы үлгән иде, шуны күмәргә баргач кына авырып киттем. Болай мин әле язам да, эшлим дә, йөрим дә... Синең килүең, сөйләгән сүзләрең мине дәртләндереп җибәрде әле. Казанга кайтасы, сезнең арада буласы, сезнең — яшьләрнең уңышларын, эшләрен үз күзем белән күреп шатланасым килә. Ул бәлки шулай булыр да әле. Менә шунда рәсемгә төшерерсең,— дип, миңа кулын бирде. Мин аңа рәхмәтләр әйтеп, изге теләкләр теләп, бүлмәдән чыктым.

Апа мине озата чыкты. Мин аннан Галимҗан ага янында озак торуым өчен гафу үтендем.

— Галимҗан ага үзе мине җибәрмәде бит,— дип акланып та куйдым. Аңа бу очрашу өчен зур рәхмәтләр әйтеп, баскычтан төшеп киттем.

Урам тын. Беркем дә юк. Кояш кыздыра, ләкин тротуарда, агачлар арасында күләгә. Мин урам буйлап киттем. Күз алдында Галимҗан ага... Бәгырь өзгәләнә. Аңа авыруын җиңәргә ярдәм итәсе килә. Юкмыни соң медицинаның көче? Кызганыч, бик кызганыч. Җан әрни...

Мин, борылып, кире Галимҗан ага яшәгән йорт янына киләм. Китәсе килми. Үзен рәсемгә төшереп булмады, истәлек өчен ул яшәгән урынны урам яктан рәсемгә төшереп алам. Ниһаять китәм. Ләкин тагын әйләнеп кайтам. Күп тапкырлар шулай. Миңа ни булды, үзен дә аңлый алмыйм...

Кич якынлашты. Соңгы автобуска бармый булмый.

Тагын да диңгез буе. Борылмалы юллар. Автобус мине Симеизга алып кайта. Мин диңгезгә күз салам — ул шаулый, гаҗәеп зур дулкыннар ярга атылалар. Менә алар ярлардан чыгарлар да Галимҗан ага торган йортка килеп бәрелерләр кебек булып тоелды. Мин сискәнеп киттем. Йөрәкне шом чолгап алды... Юк, юк, алай булмас! Әнә диңгез дә тынычлана төште бугай. Ничектер тын булып китте. Шул тынлыкта Галимҗан аганың тавышы яңгырый:

— Тукайны укыгыз, Тукайны яратыгыз, Тукайны өйрәнегез!

---

*Галимҗан Ибраһимов үз заманының сулышы белән яшәп, үз заманының иң актуаль мәсьәләләре турында шәһәр тормышыннан да, авыл тормышыннан да искиткеч осталык белән әдәби җәүһәрләр тудырган.*

Г. ӘПСӘЛӘМОВ.

---

## БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

СОРАУ:

— Сара ханым, 1922 елның 21 мартында «Татарстан хәбәрләре» газетасы Галимҗан Ибраһимовның «Бөек өмидләр алдында» исемле мәкаләсен бастыра. Анда Сезнең иҗатыгыз да телгә алынган. Әдипнең бу игътибары Сезнең иҗатка йогынты ясадымы?

САРА САДЫЙКОВА, ТАССРның халык артисткасы, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе:

— Болай булды ул. «Бүз егет»не без беренче тапкыр 1921 елның декабрендә куйдык. Спектакль, Татарстандагы бөтен музыкаль көчләргә таянып, Солтан Габәши тарафыннан әзерләнде. 1922 елның мартында кабат уйнадык. Галимҗан абый мәкаләсен спектакльне икенче тапкыр карагач, ягъни җитди уйланулардан соң язган. Мин ул вакытта педагогия училищесында укый идем. Газетаны иптәшләрем күтәреп килделәр.

— Күрдеңме, синең уйнавыңны Галимҗан Ибраһимов мактаган!— диләр.— Менә, тыңла! «...Бүз егет» фаҗигасендә гашыйк хан кызы Сәхипҗамал ролен уйнаучы Сара туташ Донская (әтиемнән шикләнеп, мин фамилиямне үзгәрткән идем) ...теләсә үзенең тавышы белән, теләсә хәрәкәтләре белән һәмма халыкта тирән бер өмид уятты. Бу, шөбһәсез, туып киләчәк... талантларның... яңа куәтләрнең бередер».

— Кем ул? Теге зур Галимҗан абыймы?— дим. Алар барын да аңлатып биргәч, бөтенләй каушап калдым. Галимҗан абый ул чакта ук бик абруйлы, дәрәҗәле шәхес иде. Шул кеше, зур өметләр баглап, бөтен халыкның игътибарын сиңа юнәлтсен әле! Күңелдә курку уянды: «Өметләрен аклый алмасам, оятымны кая куярмын, күзләренә ничек күренермен?»

Без ул елларда кулдан килгәннең барын да халыкка, гомуми үсешкә, алга барышка багышлый идек. Шәхси даншөһрәт турында уйлау да юк. Бәхетебезгә, остазларыбыз ифрат дәрәҗәдә игътибарлы булдылар. Әнә шушы 1922 елда ук Татарстан мине Мәскәү консерваториясенә укырга җибәрде. Соңыннан да иҗатым һәрчак игътибар үзәгендә торды, газета-журналларда сәхнәдәге уңышларыма, композиторлык эшемә карата язылган мәкаләләргә урын күп бирелеп килде. Әмма беренче адымымны күреп алып, шуңа зур өмет баглап, сәнгатьнең тагын да биегрәк үренә әйдәгән Галимҗан Ибраһимов мәкаләсе гомерем буе мине, авырлыкларга баш имичә, армый-талмый хезмәт итәргә дәртләндереп торды.

Шуңа өстәп әйтим әле: зур әдибебезнең татар сәнгатен үстерүгә куйган көче бүгенге язучыларыбызны да уйландырсын иде! Яшьләребезгә игътибар кирәк. Илтифатсызлык аларны, бер яктан, боектырып, нәүмизләндереп калдырса, икенче яктан, әрсезлеккә, тыйнаксызлыкка да өйрәтүе ихтимал. Иөриләр кайберәүләр булыр-булмас тавышлары белән мактау сүзен язар кеше эзләп. Бар андыйлар. Сәнгать юлына аяк баскан һәр яшь көчне игътибар үзәгенә алсак, барыбыз өчен дә һәйбәт булыр.

*Искәрмә: Бу җавап Сара Садыйкованың вафатына ике атналап калган көннәрдә, 1986 елның 22 маенда Кояш Тимбикова тарафыннан язып алынган иде.*

*Галимҗан — сүз остасы; аның сүзе укучыны тылсымлый, китаплары җанлы чынбарлыкның киң панорамасын гәүдәләндерә.*

БӘЕМБАТ МАИЛИН, казах язучысы.

**Тәүфикъ Әйди**

# И, КАДЕРЛЕ ЯК!

«Яратам мин үзебезнең авылны, бигрәк тә яратам авылның төньягын каплаган зур тауларны! Аңардан да бигрәк яратам шул таулар өстендә мең еллар буенча шаулап утырган зур карт урманны»...

Г. Ибраһимовның һәр әсәрендә туган авылына, аның кырларына-тугайларына, елгалары-күлләренә, үзәннәре-тауларына мәхәббәте әнә шулай кайнар сурәтләнгән. Бәлки аның туган авылына нигез салган гаярь егет Солтанморат та бу тирәләргә шулай сокланган булгандыр. Патшага хезмәт иткәндә күп батырлык күрсәтүе өчен аңа шушында буш яткан урманлы-тугайлы җир бүләк ителгән. Монда ул 1761 елда якыннарын да күчереп алып килгән, һәм тиздән Авыргазы суы буенда яңа татар авылы барлыкка килгән. Аңа монда беренче казык каккан Солтанморатның исемен кушканнар.

Авыл әкренләп үскән, ныгыган. Тора-бара, ил-көннең йоласын, гореф-гадәтләрен барлап, күзәтеп тоту, өлкәннәргә үгет, яшьләргә белем, тәрбия бирү өчен, тәҗрибәле, укымышлы бер кешенең җитмәве сизелә башлаган. Дөнья булгач, тумыш бар, үлмеш бар, картларны соңгы юлга озату, балаларга ата-баба рухын сеңдерү, сабыйларны тормыш итәргә өйрәтү вазифасы бар. Менә шул эшләрне башкару өчен Солтанморат халкы бер заман Бөре өязеннән Әхмәт ахунны чакырып китергән. Ул монда йорт-кура гына түгел, үзенә ияреп килгән шәкертләрен һәм шушы авылның балаларын укыту өчен, мәдрәсә дә салдырган.

Әхмәт ахуннан — Нурмөхәммәт, Нурмөхәммәттән — Гыйрфан, Гыйрфаннан инде сөекле әдибебез Галимҗан туган.

Солтанморат туфрагына аяк басканда, әдипнең әсәрләрендә чагылдырылган күренешләрне ирексездән шушы авыл табигате белән чагыштыра башлыйсың, очраган кешеләрдән яраткан каһарманнарының чалымнарын күрергә ашкынасың.

Кайда гына яшәсә дә, Галимҗан Ибраһимов онытылмаслык итеп тасвирлаган «Зәңгәр чишмә»не, «Әшкүл елга»сын, «Ялгыз каен»ны, «Яманташ» тавын, «Кондызлы күл»не, Закир, Шаһи карт, Гөлбану кебек дистәләгән каһарманнарны күңелләрендә саклаган күпләр әдипнең туган җиренә аяк басарга талпына. Хыялында Авыргазы, Түрсәгәле буйларына килеп җиткән укучыларга олуг улыңның язмыш йомгагын сүт, аның кайнар эзләрен саклаган урамнарыңны, яланнарыңны күрсәт, безне бөек улыңның замандашлары һәм оныклары белән таныштыр, и кадерле Солтанморат авылы!

Заманнар уза — бер буынга алмашка икенчесе килә. Буыннан-буынга кешелекнең хәтере күчә, үткәннең тәҗрибәсе, казанышлары бүгенгә хезмәт итә. Язу дигән могҗиза, чал тарихтан иң кирәкле нәрсәләрне безгә тапшырып, хисләребезне баета, акылыбызны камилләштерә. Әмма шулай да тере үткән белән йөзгә-йөз очрашасы килү теләге сүнми дә, сүрелми дә!

1901 елда туган Фәсахәт әби Бигелдина — күпләр өчен аяклы тарих. Солтанморатта бүген инде аңардан өлкәнрәк кешене табу бик кыендыр. Тик ул безгә өлкәнлеге аркасында гына түгел, гомеренең зур өлеше сөекле язучыбызга бәйләнгән булганлыктан да кадерле. Фәсахәт әби — Ибраһимовларның орынып торган күршесе.

Галимҗан Ибраһимов туып-үскән йорт инде күптән юкка чыккан, без хәзер шунда әйләнеп-тулганып гомер иткән Фәсахәт әбидән генә аны тасвирлата алабыз.

«Галимҗан абыйларның өе зур, ике катлы иде,— ди ул миңа.— Аның асты — таш, өсте бүрәнә. Буе ун метрдан озынрак, иңе алты чамасында иде. Өске каты өч бүлмәле. Аларның уң яктагысы мичсез, җәйге ханә санала, урам якка бер генә куш

тәрәзәсе карап тора. Гыйрфан бабай нәкъ менә шунда вафат булды. Уртадагысы да бер тәрәзәле. Аның түрендә иркен сәке, шуңа орынып диярлек уң стена буенда — өстәл, сул якта — мич. Мичнең аркасы яртылаш олы як бүлмәгә чыгып тора. Урта бүлмәнең ишек катында уң якта табак-савыт шкафы, аш-су әзерләү өстәле, сул якта — кием элгечләр. Сул як һәм урта бүлмәләргә коридордан ишек уелган, бу ике бүлмә үзара да мич буендагы ишек аша тоташкан. Уң яктагы салкын бүлмәгә урта бүлмә аша гына кереп була, сул як бүлмә арада иң зурысы, аның уртасында — озынча өстәл, тирәсендә — урындыклар, түрдә, мич буенда — карават. Түрдәге ике тәрәзә арасында — көзге, сул почмакта — сәгать. Сул стена буенда, ике тәрәзә арасында һәм түрдә — китап шкафлары. Ишек катында кием элгечләр.

Аскы каттагы бүлмә өй буеның яртысын гына алган, калган өлеш — биек нигез рәвешендә иде. Ул якта — бәрәңге базы. Аскы бүлмәдә кечерәк мич бар, анда гадәттә мал азыгы әзерләнә. Нәни тәрәзәсе бар, ишеге коридорлы якка чыга. Икенче катның буеннан-буена такта коридор, аңа буйдан да, яннан да ишек уелган иде.

Бүлмәләрнең идән-түшәмнәре буялмаган сап-сары такта иде.

Артта — бәрәңге бакчасы, аның уң буена мунча салынган. Бакчада суган, чәчәк түтәлләре дә бар. Агачлардан канәфер, сәрви куаклары утыртылган. Шулар арасына җәен өстәл, карават куела, боларның өстенә түбә дә ясала иде. Галимҗан абый шунда китап укый, яза-сыза, ятып ял итә иде.

Хәсәнә әбекәй дә бүгенгедәй исемдә. Кызлары Нәгыймә апа Тәпәреш авылына кияүгә чыккач һәм уллары берәм-берәм читкә укырга киткәч, ул берүзе генә торып калды. Шул елларда мин аның янына гел иптәшкә керә идем. Бервакыт, тарантас җигеп, Хәсәнә әбекәй белән икәү ерак басудагы игеннәрен карап кайттык. Кунаклар килсә, әбекәйгә аш-су әзерләшү, мунча ягу, су ташу да минем өстә иде.

Хәсәнә әби ябык, кара тут йөзле, озынча буйлы иде. Укымышлы. Иске китапларны кулыннан төшерми. Галимҗан абый әсәрләрен дә күздән кичереп бара, аннары сагынып ирен искә ала, сәгатьләр буе балаларын хәтергә төшереп утыра иде.

Галимҗан абыйның җиңел атлаулары, болдырдан җилбердәп менеп китүләре әле дә күз алдымда. Безнең бер тәрәзәбез алар ягына карый, бакчалары да, ишегаллары да шуннан уч төбендәгедәй күренеп тора иде. Җәен Галимҗан абый ак күлмәк, ак чалбардан, яланбаш йөри. Туган йортына аяк басуга, җиң сызганып хуҗалык эшләренә тотына — әнисенә булыша иде.

Галимҗан абый авылга кайтуга, өйләренә иптәшләре агыла башлый. Кайдан белеп өлгерәләр! Корманайдан Гыйбадулла Алпаров, Сәмәннән төркемнәре белән егетләр килә, аларга бүтәннәр ялгана. Мин кунакларга табын әзерләргә керешәм.

Галимҗан абыйның кайтуы бәйрәм кебек була иде. Күчтәнәчләрен авыз итәбез, яңалыкларын тыңлыйбыз — күңелле. Аннары ул өйдәге өч өстәлне бер итә дә зур якта эшкә утыра. Бөтен өстәлләрне китап, газит-журналлар белән күмә. Бик тиз яза, кулына күз иярми.

Өйләрендә китап күп, ике шкаф та туп-тулы. Аларны алып укуга берзаман мин дә ияләштем. Бу һәвәслегемне белгән Галимҗан абый миңа бервакыт:

— «Әлфе ләйлә вә ләйлә» китабын да җибәрермен әле үзеңә, анда пәри кызлары турында бик кызык язылган,— диде.

Ул миңа Шакирҗан абый артыннан Казаннан да ике китап биреп җибәргән иде. «Көлке капчыгы» дигәне әле дә исемдә. Башка җирләрдән дә салгалады. Шунысы гына кызганыч: бер елны төнге уникедә әти йорты кинәт янып китте, шул йорттагы бөтен китапларыбыз, җөмләдән, Галимҗан абый әсәрләре дә әрәм булды».

Бөек әдип Г. Ибраһимовны күреп белүчеләр Авыргазы буйларында елдан-ел азая бара. Шуларның берсе — арада иң өлкәне — Мостафа бабай Мөсәлләмевтер (1895).

«Безнең якларда белем тарату өчен көрәшүчеләр шушы Ибраһимовлар иде инде,— дип сүзен башлый Мостафа бабай.— Аларның мондый даны Солтанморатта гына түгел, тирә-як авылларда да чыккан иде. Безнең Кешәнледә, мәсәлән, балаларга Мотаһар Ибраһимов — Галимҗанның туганнан туган абыйсы сабак бирде. Соңрак Галимҗанның бертуган абыйсы Шакирҗан абый белән дә аралашырга туры килде.

Галимҗан абый белән бердәнбер очрашуым исә 1912 елда булды. Мин инде авылыбызда мәдрәсәне дә, өч класслы русча земство мәктәбен дә тәмамлаган идем. Моның белән генә каласым килми, тик кая барырга?

Июль ахыры, август башлары иде бугай. Көне эссе. Тәвәккәлләп, Ибраһимовларга килеп кергәч, мине сул як бүлмәләрендә өстәл янына утырттылар. Галимҗан абыйның авылга кайткан чагы икән.

Аның төсен-кыяфәтен онытпым инде. Хәтердә калганы — Галимҗан абыйның бик хәрәкәтчән булуы. Ут кебек иде. Өздереп сөйләшә, тавышы артистларныкы кебек. Кеше ярата икән, бик ачылып гәп кора. Җиренрәк кәчтүм кигән. Белемле, төпле кеше икәнлеге әллә кайдан сизелеп тора. Ышанычлы, батырып сөйләшә.

Мин, яшьлегем беләнме, әллә шундый мәшһүр мөхәррир белән очрашуымнан дулкынланыпмы, исәнләшүне дә «онытканмын» икән. Галимҗан абый шундук шәкерт кешегә моның килешмәвен искәртеп куйды. Кызарындым. Галимҗан абый сүзен дәвам итеп:

— Дөньяви гыйлемне нинди дәресләкләрдән укыдың соң? — диде.

— «Шура»ны да, башка газит-журналларны да су кебек эчәм инде. Сезнең мәкаләхикәяләрегезне дә...

Галимҗан абый көлемсерәп тыңлап торды да сүземне бүлде:

— Һәй, туган, газит-журнал укып кына белем алып булса иде. Сабыйлык лабаса бу!

Унҗиде яшьлек егетне «сабый» дип атап, икенче кимчелегемне дә фаш иткәч, гарьләнгән һәм колак яфракларыма кадәр янган хәлдә урынымнан сикереп тордым.

— Чү, чү, утыр! — дип боерды Галимҗан абый.

Бу әңгәмә ике сәгатьләр дәвам итте. Сораштылар, белемемне капшадылар.

— Уку бик әйбәт эш, тик иң әүвәл кая барасын үтә җитди уйлап хәл итәргә кирәк,— диде Галимҗан абый.— Оренбургның Вәли мулла мәдрәсәсе кебек сөрсегән бер җирдә ми черетергә дә мөмкин. Казанның Татар учительләр мәктәбенә барып чын белем диңгезенә чумарга да була. Бер җыенгач, синең инде әнә шул соңгысын сайлавың хәерле. Тик анда керү уен эш түгел, имтиханына әйбәт хәзерләнүең фарыз.

— Әгәр ярдәм итсәгез...

— Соңрак килгәнсең, энекәш. Бүген-иртәгә уракка төшәргә торабыз: андый җиргә кергәндә, атна-ун көн әштер-өштер әзерләнүең генә җитмәячәк, җиңел-җилпе карама. Моның өчен, актык сарыгыңны сатып булса да, махсус үчител яллау лазем. Шунсыз һич тә ерып чыга алмассың!

Галимҗан абый ашыкмый-кабаланмый сөйләште, миңа төрле уку йортлары, аларның программалары, белем бирү дәрәҗәләре турында иркенләп сүз алып барды, төрле дәреслекләр тәкъдим итте. Халыкның күзен ачарга, милләтне караңгылыктан чыгарырга йөрәкле, чын мәгънәсендә тирән укымышлы егетләр кирәклеген кат-кат төшендерде.

— Алган юлыңнан чигенмә, энекәш. Теләсә нинди корбан бир, тик максатыңа ирешми ярты юлда туктама! — дип озатып калды.»

* * *

Солтанморатта кич утырабыз. Мин Ибраһимов томнарын ачам да бернечә юл укыйм, тыңлаучылар өзекнең кайсы әсәрдән икәнлеген әйтергә һәм шуңа аңлатма бирергә тиеш. Барысының да игътибары миндә. Рәисә ханым гына учак тирәсендә таба чыжлатып йөри, әмма ул һәрбер сүзебезне колагына элеп барырга да өлгерә, җавапны беренче әйтергә чәчрәп тора.

«Әнә безнең алдыбызда — барачак юлыбызда, киң яшел ялан белән биек һәм урманлы тау уртасында, зур, түгәрәк сихерле күл ялтырый... Авылдан өч чакрым ераклыкта булган бу зур күлгә миңа балачактан ук бик күп йөрергә туры килә иде».

— Кондызлы күл бу, Кондызлы күл!

— Синең географиядән көчле икәнеңне беләбез,— дип елмая Үзбәк абый.— тик башта әсәрнең исемен әйтергә кирәк, энисе.

Ул арада Гарифулла абый Хәкимов телгә килә:

— «Яз башы» хикәясеннән бу. Ибраһимовның монда Кондызлы күлне тасвирлавы ачык. Тик бу күл чынлыкта авылдан ярты чакрымда гына. Без балачакта бик зур иде, балыкка да бай иде. Тора-бара яңгыр сулары белән агып килгән балчык басты үзен. Күлне саклар өчен буа будык хәзер.

«Төш якынлый. Көн кыза башлый, кыза башлый. Кошлар авызларын ачып, елга буйларына төшәләр. Балыклар, хәлсезләнеп, камыш төпләренә яталар».

Бу юлы беренче булып Солтанморат мәктәбенең укыту бүлеге мөдире Фәүзия Рәхмәтуллина җавап бирә:

— «Табигать балалары» бу.

«Юлымда «Яманташ» дигән бер тауны үтәсем бар. Моннан мендерү көн коры чакта да бик җиңел булмый. Хәзерге кебек явым-чәчемле вакытларда бу инде сират кичүдән бер дә ким саналмый.»

— «Карт ялчы»,— ди Зәлифә Шәйхетдинова.— «Яманташ» шунда телгә алына.

— Әшкүл елгасы буенда ул,— дип аны тулыландыра Гарифулла абый.— Авылдан бер-ике чакрым төньякта. Яманташ — агачлык эчендәге бик текә таш кыя. Шуның астыннан куыш аша уза торган су юлы бар. Әшкүл елгасы, суы бик мул чакта гына өстән ага. Бернечә тапкыр сыерлар югалгач, куыштагы юлны төшеп тикшердек: озын икән, чыга торган тишеге тар икән.

«Монда өч яктан өч елга килеп кушыла. Болар кушылалар да, ул җиргә чаклы кечкенә бер «кул» гына булып агып яткан Өзән елганы берьюлы зурайтып җибәрәләр.

Таулар, болыннар буйлап килеп, безнең авылның буеннан аккан бу елга — Өршәккә, Өршәк — Димгә, Дим Агыйделгә коя».

— «Алмачуар»дан укыдыгыз, моны мин беркайчан да бүтән әсәр белән саташтырмыйм инде,— ди Хәкимов.— Балачактан ук кат-кат укып киләм мин аны. «Өзән елга» дип Ибраһимов Авыргазыны тасвирлый. Солтанморат янында гына аңа Түрсәгәле белән Әшкүл килеп кушыла.

— Авыргазы Өршәккә койса да, Өршәк Димгә кушылмый ич,— дип аваз бирә Рәисә ханым.— Өршәк белән Дим янәшә агып киләләр дә икесе дә туп-туры Агыйделгә коялар.

— Юк, юк, «Өзән елга» — барыбер Авыргазы! Андагы бөтен табигать, геройларына кадәр шушыннан алынган бит. «Алмачуар»да сурәтләнгән Закир, Садыйк абзый, бүтән әсәрләрдәге дистәләгән каһарманнар да үз исемнәре белән кертелгән Солтанморат кешеләре!

— Нигәдер Гарифулла абый гына җавап бирә әле,— дим мин.

— Анысы дөрес инде,— дип килешә Рәисә ханым.— И, энем, Салават Рәхмәтуллин бар иде ич әле монда. Менә ул йөрде инде Галимҗан Ибраһимов өчен көрәшеп. «Мулла малае бит ул, ник чабасың шуның өчен?!» — дип битәрләсәләр дә, туктамады. Эзтәрлетамакта хәзер, әле дә кайткалап йөри...

«Мин Зәңгәр чишмәгә җәяүләп, аркама әйберләремне асып килеп кергәндә, кояш батып бара иде инде».

— «Алмачуар»...

— Юк, юк, Гарифулла абый, бу өзек «Кызыл чәчәкләр»дән,— дип бүлә Хәкимовны Зәлифә Шәйхетдинова.

— Зәңгәр чишмә әле дә бар,— ди бераз уңайсызланган Гарифулла абый.— Авылдан өч чакрым чамасы төньяк-көнбатышта тибеп тора.

— Үзебезнең мәктәптә эшләгәндә, Салават Рәхмәтуллин әдәби түгәрәк оештырган иде,— ди Фәүзия ханым.— Ул да Галимҗан Ибраһимовка илһам биргән «Зәңгәр чишмә» исемен йөртә.

«Ул чабышкыларга якынрак килде дә:

— Вакыт җитте, китә башлагыз, алдан китүчеләр «Ялгыз каен» янында көтәрләр,— дип кычкырды.

... Ялгыз каен бездән унбиш чакрым.»

— Менә бу юлы «Алмачуар» инде,— ди Гарифулла абый көлемсерәп.— Ибраһимов монда да тормыштагыны бераз үзгәртеп алган. Авылдан бер чакрым чамасы басуда үсеп утыра иде ялгыз каен. Хәзер юк инде. Урынына былтыр яшьләр ике төп каен утыртты, берсе китмәсә, икенчесе үсәр, дип. Әмма икесеннән дә юнь чыкмады. Җәренгә яңаны утыртырга җыенабыз, басуның Галимҗан абый заманындагы төсе саклансын әле.

Коймак өлгергәч, китапларны бер якка куеп торырга туры килде. Табын янында без инде барыбыз да күбрәк Гарифулла абыйны тыңладык.

Ул 1914 елда туган, бик яшьли комсомолга кереп, спектакльләр, концертлар куюда катнаша башлаган. Солтанморатта күмәк хуҗалык оештырганда да алгы сафта йөргән. Аннары Авыргазы профессиональ театрында уйнаган. Фронт юлларын азагынача кичкән, Кызыл йолдыз һәм икенче дәрәҗәдә Ватан сугышы орденнары белән бүләкләнгән. Укыткан, райкомда инструктор, Солтанморатта партоешма секретаре, авыл советы председателе булып эшләгән, әле дә колхоз, авыл тормышына катнашып яши.

— Галимҗан Ибраһимов әсәрләре белән яшьтән үк азыклана киләм,— ди ул.— Чагылдырган һәр кешесе, һәр вакыйгасы бик таныш, бик тансык безгә. Әйтик, менә Әпсәләм, Дүртөйле, Карамалы — барысы да күршедә генә. Авыргазы елгасы буена утырган авыллар. Ә «Татар хатыны ниләр күрми»дә тасвирланган хәлләр? Балыклыкүл кызы Хәтимәнең язмышы күрсәтелә бит анда! Мин аның белән очраштым да 1946 елда «Чулпан» авылына пионер лагере башлыгы итеп җибәрелгәч, балдызым белән Хәтимә әбиләргә (повестьта — Гөлбану) фатирга төшкән идек без... Мин — «Татар хатыны ниләр күрми»нең беренче басмасын укыган кеше. Соңгы варианты элгәресеннән шактый аерыла. Тормыш вакыйгаларыннан читкә чыгыла. Сәнгать әсәре өчен шулай отышлыректыр, күрәсең. Ә чыны болай: Хәтимәне Дүртөйле авылына көчләп кияүгә бирәләр. Каенанасы явыз, ире эчкече булып чыга бичараның. Тормыш түгел, җәһәннәм башлана Хәтимә өчен. Эшкә уңган, төскә-биткә, гәүдәгә дә күркәм, шулай да ярый алмый ул яңа гаиләгә. Беркөнне суга дип китә дә, көянтә-чиләген елга буенда калдырып, авылдан кача. Арбага яткырып, киез белән каплап Агыйдел буендагы — таулар арасындагы бер авылга алып кайткан юлаучылар, чибәрлегенә, уңганлыгына кызыгып, Хәтимәне үзләренең унөч-ундүрт яшьлек улларына кияүгә бирәләр. Гарьләнә Хәтимә. Ир-ат кием е әзерли дә урман эченә кереп киенә, аннары, сал агызучыларга барып, иптәшкә алуларын үтенеп ялына. Үзен «Миңлеяр» дип

таныта. Шулар белән бераз эшләп йөргәч, Сәмән авылы баена хезмәтче булып керә. бала чактан мал асрап үскәнлектән, ат карарга да оста икән. Бай ярата моны, кучер итеп йөртә. Ялгыз кызлары бар икән, карчыгы белән уйлашалар да аны ипле Миңьярга (Миңлеярга) кияүгә бирмәкче булалар, чакырып, хезмәтчеләре белән сөйләшәләр. «Ярар, тик мин әти-әни белән дә киңәшим инде»,— ди «егет» һәм туган авылына барып килергә рөхсәт ала.

Балыклыкүлдә ул атасына: Агай, мин бер мосафир, юлым ерак, кич кунарга кертмәссезме икән?» — дип мөрәҗәгать итә.

Әти кеше кызын танымый, шулай да кертә. Чәй эчеп утырганда, әни кеше шикләнә: «Бигрәк Хәтимәмә охшаган, сул яңагында миңе дә бар»,— дип уйлый. Шуннан ул юлаучыны мунчага җибәрә, бераздан үзе дә күрше киленен ияртеп, өстенә барып керә. Сер ачыла, елашып күрешәләр.

Хәтимә шуннан соң авылдан-авылга йөреп, тегү тегүче бер Казан ягы кешесенә кияүгә чыга, өч бала үстерә.

Безнең бер туганыбыз Сәмәнгә кияүгә чыккан иде, бай кучерының тарихын миңа шул сөйләде. Аннары Габдулла Ильясов дигән бер танышым Әпсәләм авылында кучер йөрде. Сәмән бае кучерын заманында ул да белгән булган икән. Бездә базарлар чиратлашып уздырыла иде. Бүген — Солтанморатта, иртәгә — Карамалыда, берсекөнгә — Корманайда. Сәүдәгәрләр һәркайсына бара, Сәмән баен йөртүче Миңьяр да йөри, бергәләшеп ат сугаралар, гәп куерталар. Әмма Миңьяр, егетләр су коенган чакта, яннарына да бармый, «Сусыз якта үстем мин, куркам»,— дип кенә җибәрә. Кайвакыт юлда аңа, ясаган чабаталарын сатарга дип базарга баручы элекке ире дә очраштыргалый. Андый чакта Миңьяр «ялгыш» кына «хәләл»енә сыдырып китә торган була... 1967 елда мин Казанга, Г. Ибраһимов юбилеена барганда, Хәтимә (Миңлеяр-Гөлбану!) исән иде әле, сиксәннәр тирәсендә иде. Аны олы улы Урта Азиягә алып китә, тәрбияләп тота.

Фатирга кергәч, Хәтимә ападан әлеге хәлләрне бик сөйләтәсем килде, әмма телен чишә алмадым. Үткәндәге михнәт-газапларны искә төшереп, йөрәген бозасы килмәгәндер инде...

Ибраһимов әсәрләренең һәммәсендә дә дип әйтерлек солтанморатлыларга таныш булыннарда чәчәкләр үсә, сулар ага, кошлар сайрый, урамнарда, өйләрдә алар әле дә онытмаган вакыйгалар бара.

«Бик сагындым инде,— ди әдип 1933 елда Ялтадан М. Гафурига язган хатында.— Мәскәү, Казан, Уфа якларына, үзебезнең Солтанморат, «Урак» колхозына табан да кайтып килү беренче планда тора».

Ләкин аңа 1920 елдан соң туган авылына кабат аяк басу насыйп булмый. Монда аның сәлам хатлары, әсәрләре генә килеп ирешә.

•

— Революция алдыннан авылыбызда биш йөздән артык хуҗалык булган,— ди миңа Гарифулла Хәкимов.— Өч мәчет, ике мәдрәсә. Мәдрәсәләр тәбәнәк, җиргә сеңеп беткән.

Гектарыннан уртача алты-җиде центнер уңыш алганнар. Авылда фәкыйрьләр күп булган. Аларның хәле инде бигрәк тә мөшкел.

Мин бүгенге Солтанморатның асфальт җәелгән озын урамы буйлап уздым. Очтан-очка ике яклап рәшәткә тотылган, матур итеп бер төскә буялган, агачлар утыртылган. Коелар, курчак өе шикелле, матур чатыр эченә алынган. Мескен куышлар, черегән, янтайган, җиргә чүккән йортларны күрермен димә — көлеп торган ташпулатлар, бүрәнә өйләр генә тезелеп киткән. Каралты-курага кадәр калай, шифер башлы.

— Яңа оешкан чакта «Урак» колхозына унсигез хуҗалык кергән иде,— ди Гарифулла абый.— Беренче рәисебез Хәкимҗан Ибраһимов ун чакрымдагы яланда куныш эшләүчеләр янына, чабатасын киеп, иртүк килеп җитә иде. Яшелчә үстерү буенча республикада беренче урынга чыктык, бүләккә радиоалгыч бирделәр.

Ул еллардан соң күп сулар аккан, игенчелек чагыштыргысыз дәрәҗәдә алга киткән. Җирне ашлау, корткычларга, үсемлекләрнең авыруларына каршы фән казанышларын кулланып көрәшү, туфрак эшкәртү, чәчү һәм урып-җыюда куәтле техника — утыз трактор, унсигезәр комбайн һәм автомобиль файдалану, һәр эшне вакытында һәм тиз башкару аркасында, былтыр һәр гектардан егерме алтышар центнер борчак, утызар центнер бодай, илле берәр центнер арыш уңышы алынган. Элекке замандагыдан биш-алты тапкыр артыграк! Колхоз дәүләткә планнан тыш унҗиде мең центнер бөртекле ашлык саткан.

Солтанморат алдынгы игенчеләре белән дә мактана ала. Былтыр Гаяз Сәетов, мәсәлән, «Нива» комбайны белән җиде йөз тоннадан артык иген суктырган. Фәнис Мөхәммәдиярев исә бер улын бишенче класста укыганда ук комбайнчы һөнәренә өйрәтә башлаган. Уртанчылары Фәних белән Фәһим дә аталары һөнәрен сайлаганнар.

Үз эшен яратып башкаручылар исәбеннән Хәмит Бигелдин, Бари Шәфиев, Әнвәр Идрисов, Рәшит Моратовларны да санап китәргә мөмкин.

Соңгы дәвердә алты йөз баш савым сыерына исәпләп төзелгән һәм өр-яңа техника белән җиһазланган ферма терлекчелекне алга җибәрергә этәргеч биргән — бер ел эчендә генә дә сыер башына сөт саву уртача дүрт йөз литрга арткан. Монда мал асрау шартлары байтак яхшыртылган, авыр эшләр киметелгән. Әйбәт кызыл почмагы, алтмыш урынлы ашханәсе булган терлекчеләр йорты корылган. Шушында ук урнашкан профилакторийда колхозчыларның сәламәтлеген кайгырту да юлга салынган.

Колхоз белгечләр, механизаторлар һәм терлекчеләр өчен ел саен өч-дүрт йорт сала, колхозчыларга өй кору өчен материал, транспорт бирә. Авылда культура йорты, шифаханә, кибет, идарә бинасы, бүтән хуҗалык корылмалары да төзелгән. Киләчәктә сәүдә үзәге, кунакханә, көнкүреш хезмәте йорты, кафе булдыру планлаштырылган, аларның кайберсенә инде нигез дә салынган. Хәзер ике йөз илле хуҗалыктан гына гыйбарәт авыл өчен бу инде бер дә аз түгел.

Солтанморат авыл советына Бакай, Чишмә, Чобайтал авыллары да керә. Шушы авылларда һәм Солтанморатта җәмгысе 1154 кеше (1.1.1986), шул исәптән, соңгысында 831 кеше яши. Аларның унҗиде яше тулмаганнары — егерме ике, унҗиде-утыз яшьтәгеләре — шулай ук егерме ике, утыз бер-кырык яшьтәгеләре — җиде, кырык берилле яшьтәгеләре — унбиш, илле бер-алтмыш яшьтәгеләре — унбер, шуннан өлкәнрәкләр егерме өч процент тәшкил итә. Илле сигезе — коммунист, биш йөз бише — профсоюз әгъзасы, егерме бише — авыл, өчесе — район советы депутаты. Дүрт йөзләп кеше колхозда эшли, йөз илле дүрт бала мәктәптә укый, аларга егерме өч укытучы һәм тәрбияче белем бирә. Балалар бакчасындагы егерме сабыйга дүрт кеше хезмәт күрсәтә. Колхоз җитәкчеләренең дүртесе югары, икесе урта махсус белемле. Сәүдәдә — уникe, почтада — биш, нефть чыгаруда биш, сәламәтлек саклауда дүрт фельдшер һәм акушерканы күрәбез. Шуларга культура учакларында, авыл советында һәм партқомда, профкомда һәм колхоз бухгалтериясендә егермеләп хезмәткәрне кушсак, Г. Ибраһимовка йөз яшь тулыр алдыннан, авылдашларының социаль портретын абайларбыз.

Солтанмораттан Бөек Ватан сугышында өч йөз илле кеше катнаша, шуларның бер йөз җитмеш сигезе яу кырында һәлак була. Дошманны җиңеп кайтучылар арасында ике тапкыр Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнгән Хәмәт Нуркиев, Дан ордены кавалерлары Вәлиҗан Мәгъдәнев, Зәйнулла Фәйзуллин, Кызыл Йолдыз ордены казанган Батырхан Мөхәммәтшиннар да бар. Мәшһүр Шаһбазлар, Солтаннар каһарманлыгын дәвам итүчеләр болар.

Авыл совет председателе Мәдинә Рәхмәтуллина белән партком секретаре Вәкил Гыйльметдиновлар мине Солтанморат халкының рухи казанышлары белән таныштырды.

— Матур яшәргә омтылабыз. Һәр елны март аенда кул эшләре күргәзмәсе, аш әзерләүчеләр конкурсы уздырабыз, җиңүчеләргә бүләкләр бирәбез.

— Китапханәбездә ун меңнән артык басма бар. Культура йортыбызга эстрада музыка кораллары, ике немец баяны сатып алдык. Районыбызда беренче эстрада ансамблен нәкъ менә без оештырдык. Бию кичәләребезгә тирә-як авыл яшьләре дә агылып тора.

— Үзешчән сәнгать гомумән җанлы бездә. Спектакль, концерт белән күршеләргә дә барабыз, смотрларда гел алдынгы урында. Вәкил үзе дә гармунчы, аның җитәкчелегендә яшьләребез Кырмыскалы, Уфа сәхнәләрендә дә әйбәт чыгыш ясады.

Мәктәп директоры Зөфәр Сәйфуллин — аккордеончы, пионервожатый Зөлфия Әлимбәкова, шофер Ринат Кәримов, терлекче Рәмил Нуркиевлар — җырчы. Үзешчән сәнгать түгәрәгенә егермеләп кеше даими йөри икән.

Г. Ибраһимов туган авылда китап җене кагылган затлар да булу табигый. Киләчәк Хәмит Шәрипов, комбайнчы Бари Шәфиевлар — нәкъ менә шундыйлардан. Хисапчы Вәли Шәмсетдинов, укытучылардан Мөбәйнә Әлимбәкова, Наил Галләмов, Галимҗан Галиәсгаров, Зөфәр Сәйфуллиннар шулай ук шәхси китапханәгә ия. Аларның һәркайсы Ибраһимов әсәрләрен дә булдырырга тырыша. Бу яктан Вәкил Гыйльметдинов үзе дә сыната торганнардан түгел.

Солтанморат авыл советына караган 360 хуҗалык быел да күп санда көндәлек матбугат алдыра. Туган телдә чыга торган республика газетасы «Кызыл таң» — 296, район газетасы «Ватан юлы» 322 данә тарала. Татарстаннан 29 «Казан утлары», 45 «Ялкын», 110 «Азат хатын» журналы килә. Рус һәм башкорт телендәге басмаларга да язылучылар ишле.

Туган телгә, туган әдәбият-сәнгатькә ихтирамлы мондый авылның данлы улы Галимҗан Ибраһимовны һәрвакыт күңел түрендә тотуы, аның белән горурлануы табигый. Әдипнең әсәрләре яңадан укучылар кулына кайтарылу белән, Солтанморат

халкы аеруча канатланып китә: тантаналы кичәләр уздыра, мәктәптә музеен ача, укытучылардан Салават Рәхмәтуллин, Галимҗан Кәримовлар колхозга язучы исемен бирүне күтәреп чыгалар. Бу теләк 1985 елның икенче февралендә тормышка аша. Аннары Солтанморатта — Галимҗан Ибраһимов исемендәге колхозның үзәгендә әдипнең махсус музей-йорты корыла, һәйкәле куела.

* * *

Март ае Авыргазы буйларына ел саен бәйрәм алып килә. Дөнья халыкларының фашизмга каршы көрәшен сурәтләгән «Без үлемебездән өлкәнрәк» китабының авторы, беренче һәм икенче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары кавалеры Вәли Бикташов, композитор Бәхти Гайсин, филология фәннәре докторы Үзбәк Гыймадиев — шушы тирәдә үскән егетләр — тантаналарда катнашырга ашкына. Очучы Мидхәт Буләкколов, биолог галим Венер Вахитов, драматург Фәрит Богданов та туган авылларына шушы айда кайтырга тырыша. Күрше районнардан, шәһәрләрдән, Уфадан һәм Казаннан кунаклар җыйнала — аларның һәммәсен дә монда бөек әдипнең нигезе тартып китерә. Шуларның барысы алдында Солтанморатта туып-үскән шагыйрь Салават Рәхмәтуллин:

Сиңа кайттым юллар, еллар узып,
(Кайтам диеп күпме җыендым!..)
Авыргазым минем, Авыргазым,
Чал Иделдә су коенган чакта,
Синең суың, диеп коендым,—

дип шигырь укый.

Әгәр бер генә минутка терелсә, туган авылын өзелеп яраткан, ләкин гомеренең соңгы өлешен Идел буенда уздырган Галимҗан Ибраһимов бу юлларны, мөгаен, бик рәхәтләнеп кабатлар. Солтанморатның яңа казанышларын, бүгенге йөзен, үзенә алмашка дәртле-дәрманлы күп яшь көчләр җитешүен күреп куаныр иде.

*Солтанморат — Казан.*

---

*Сезнең Галимҗаныгыз бер татар халкының гына булмыйча, барлык шәрык халыкларының да зур язучысы.*

СӘМӘД ВУРГУН, әзербайҗан язучысы.

*Язучы, лингвист, җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов турында күп сөйләргә мөмкин. Мин аны тере итеп, бетмәс-төкәнмәс энергияле итеп, үзе салышкан һәм аның өчен күп көрәшкән юлдан безнең белән бер сафта баручы итеп күз алдыма китерәм. Мин аны зирәк, даһи, акыллы итеп, вөҗданы белән бернинди компромиссларга юл куймаучы, яхшы киләчәк өчен какшамас көрәшче итеп күрәм.*

БЕРДИ КЕРБАБАЕВ, төркмән язучысы.

---

# Клара Булатова

●

Чал тарихның бер почмагын чеметеп
Ачып карыйм әле...
                    Латыш иле.
Легендалардагы Юратаның
Гәрәбә-яшь белән катыш җире...

Кем яшәгән рәхәт,
                    кем тир түккән,
Кем өчендер халык гөл үстергән...
Үткәннәрнең гаделсезлегеннән
Боегышып калган суүсемнәр.

Латышларны читләр изү беткән,
Тигезсезлек сүзе юк та монда...
Кай чорларның сагышлары икән
Лиелупе төнбоекларында?

●

Үз көенә нидер көйләп-сөйләп,
Чал дулкыннар ярга кагыла.
Юрмалада Райнис наратлары
Кушылып җырлый диңгез шавына.

Бу агымга күңел колагыңны
Куеп тыңла: нәрсә агыла?
...Заманнарны үтеп, шагыйрь җаны
Якыная шагыйрь җанына.

●

Гәрәбәне Бәхет ташы диләр,
Сөенәләр тапкан кешеләр.
Ә син миңа бүләк иткәнеңдә
Нарат исе... һәм кан төсе бар.

●

«Кабатлау — белемнең анасы»,
Электән, галимнәр телендә...
Кешелек!
                    Кабатла һаман да
Үзеңә кирәген бүген дә.

---

КЛАРА БУЛАТОВА — *шагыйрә, «Язлар алда», «Җәйләр җитсә», «Печән өсте» һ. б. шигырь китаплары авторы, Әлмәттә яши.*

Яз көне чәчүне кабатла,
Кабатла көз уңыш җыюны...
Тик, зинһар, кабатлап яңартма
Сугышны —
җирдә кан коюны.

Миндә дә шагыйрьләр җаны!
Бар анда күп төрлесе:
Бар анда җәйге яңгырның
Салават күперлесе.

Бар анда көзге томан да,
Бар анда кышкы буран.
Бар анда язгы гөрләвек —
Бу җанга бар да сыйган.

Мәктәптә менә шуларның
Барсы да зарур, кирәк.
Миндә дә шагыйрьләр җаны —
Көрәшче җаны, димәк.

Ураллар урамадык,
Байкаллар айкамадык,
Кая анда Урал, Байкал! —
Казанда да калмадык.

Бер авылга ябыштык та
Укытырга тотындык.
Уйлап куям: әллә оттык,
Әллә инде оттылдык?

Нәрсә таптык?
Ни югалттык?
Кем бәяли?
Кем белә?..
Кемнән дә гафу сорамыйм,
Кичерсен гомерем генә.

Елларын барлап карый да
Бәхилли гомерем юлы:
Үземнең шушы дөньямда
Бәхетем тулы, оулы.

Мин үзем җитә алмаган
Уралы, Байкалында,
Карпатта, Амур ярында,
Каф тавы аръягында —

Кайда юк безнең шәкертләр!
Сәламнәр килми кайдан...
...Яшьлектә янган хыяллар
Яшьлектә — безнең дәвам!

## Әмирхан Еники

# СОҢГЫ КИТАП

## Таш калада

*Казан каласы — таш кала.*
*Күп калага баш кала.*

Борынгы җырдан.



Мин аптырауда, хөрмәтле укучым: исемне зур итеп куйдым, әмма китапны ничек итеп төгәлләргә — ачык кына белмим. Китапның баш өлешләрен язарга керешкәндә үк инде, аның ахыры мине бик уйландырган, бик борчыган иде. Чынлап та, күпләрдә шик уяткан сәер исемле бу китапны ничек дәвам итәргә дә ничек кенә очлап чыгарга?..

Без менә ике Дәүләкән егете, онытмаган булсагыз, 1925 елның август урталарында Казан туфрагына аяк бастык. Бабайлар каны сеңгән изге туфракка зур өметләр белән дип әйтәсем килә. Шуннан соң алтмыш ел вакыт узып китте. Мин һаман да әле шушы туфракта яшим, шуның каты асфальтына басып йөрим, ә Фәтхелислам дустым күптән инде дөньяда юк. Казанга килгәндә, миңа уналты яшь иде, хәзер исә җитмеш алты... Уналты яшькә кадәр күргәннәрне һәм ишетеп белгәннәрне язу биш елга сузылса һәм чама белән 20 табакка җитсә, Казан белән бәйләнгән алтмыш ел гомерне язып чыгуга күпме вакыт китәчәк тә күпмегә сузылачак ул?.. Дүрт тапкыр артыграккамы?.. Юк, бу мөмкин түгел. Моңа көч тә, ихтимал, вакыт та җитмәс иде. Ләкин моннардан тыш тирәндәрәк яткан икенче бер җитдирәк сәбәп тә бар. Бу таш калада күпне күрергә, күпне татырга туры килде. Менә шулардан нәрсәне сайларга һәм ничек сайларга?.. Әле гөнаһсыз бала — үсмер чакларны язганда да илаһи-уптым һәммәсен дә тутырып булмады. Ә Казан дәвере бит инде ул минем балигъ булган чагым, үз көнемне үзем күрә башлаган чагым, яшәү өчен көрәшә-көрәшә, ниндидер максатларга ирешергә тырышып, елдан-ел әкренләп олая барган һәм үзем дә сизмәстән, ниһаять, картлыгыма килеп җиткән чагым. Бу озын гомер эчендә нинди вакытларны кичерергә дә нинди генә хәлләрне күрергә туры килмәде. Ләкин аларның барысын да «кучасы» белән өеп салу бер дә урынлы булмас түгел. Кагыйдә буларак, язучының үткән юлын кыска итеп, кирәклесен генә чүпләп алып язалар түгелме соң?! Бәлки, миңа да шулай гына итәргә кирәктер? Мин инде шактый ук танылган язучы, күпмедер уңышларга ирешкән кеше, бәс шулай булгач, нигә шушы ирешелгән дәрәҗә һәм уңышлар белән генә чикләнмәскә, нигә, әйтик, бу ирешүләрнең озын юлын, авырлыкларын, газапларын язып торырга?.. Хәзерге укучы битәрләнганны бер дә яратмый, ә мин үзем ни сәбәптер мактанырга яратмыйм...

ӘМИРХАН ЕНИКИ *(1909) — прозаик, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, «Саз чәчәге», «Рәшә», «Без дә солдатлар идек», «Гөләндәм туташ хатирәсе», «Юлчы» һ. б. китаплар, күпсанлы хикәяләр һәм сәнгать турындагы мәкаләләр авторы. Казанда яши.*

Икенче яктан, уйлап торам да, үземә әйтәм: минем язмышымда бәлки заманның башкалар үрнәгендә ачылмаган яклары чагылып куяр — нигә, бу кызыклы түгелмени?..

Кыскасы, әнә шундый икеләнү-уйланулар... Әмма ләкин китапны дәвам иттерергә һәм соңгы ноктасына ничек тә барып җитәргә кирәк. Язу эшенең бер хосусияте шунда ки, кайчагында каләм үзе авторны тиешле ноктасына илтеп җиткерә. Без дә шуңа таяныйк әле булмаса: «Әйдәле, әйдәле, алып бар әле!» — диеп карыйк сыналган каләмебезгә.

...Хуш, шулай итеп, без Казан туфрагына аяк бастык.

* * *

...Һәм татар каласына аяк басуыбызны шунда ук тойган шикелле дә булдык. Килеп төшкән җиребез «Үсия» дип атала икән — бик җанлы урын, халык күп, бик чуар, нинди генә милләт кешесе юктыр монда, ә шулай да татар агай-энесен еррактан ук танып була. Кырмыскалар шикелле барысы да хәрәкәттә — килүчеләр, китүчеләр һәм нидер эшләп йөрүчеләр белән яр башы мыжгып тора. Әнә аркаларына «ияр» кигән, кыска-киң балаклы крушниклар аллы-артлы тезелешеп пароходтан тюклар, капчыклар, әрҗәләр чыгаралар. Яр өстендә билен кызыл билбау белән буган төптәй таза ломовойлар крушниклар чыгарып өйгән йөкләрне сәкедәй арбаларына төйиләр. (Атларының сырты да ястык кебек — ятып йокларлык). Ярдан бераз читтәрәк тезелешеп киткән лареклар, ишекләре киңенчә ачык чәйханәләр, озын лапас астында азык-төлек сатып утыручы хатын-кызлар — монда ниләр генә сатылмый да нинди генә исләр аңкымый... Ул заманда су юлы Казанны күп шәһәрләр белән бәйли торган бердәнбер юл булган һәм Казан халкы ак пароходта Нижнийга менәргә, Әстерханга төшәргә, Кама-Агыйдел буйларына кайтырга бик яраткан. Хәзер дә ярата ул бу өч елга буйлап сузылган күк юлны, әмма елга буйлары үзләре соңгы елларда бик нык үзгәрде. Безнең Үсиябез дә күптән инде су астында калды һәм «Үсия» дигән сүз үзе дә тәмам онытылды диярлек.

Пароходтан төшеп, тирә-юньне әнә шулай бераз күзәткәч һәм Үсиягә генә хас су исе белән тозлы балык исен дә күпмедер сулагач, без калага таба юл тотарга булдык. Ул чакларда Үсиядән шәһәргә, Бишбалта аша, трамвай йөри иде. Минем бу трамвай дигән нәрсәне Самарада күргәнем бар иде инде, ләкин утырганымны бер дә хәтерләмим... Казан үзе моннан шактый ерак булгач, без аллага тапшырып дигәндәй, шул вагонга утырырга булдык. Халыкка иярен, тукталышына бардык та сары трамвайларның берсенә эләгеп тә киттек. Сәер дә, кызык та икән... Вагон, шалтырап һәм селкетеп, кызу гына алып бара, йөртүчесе идәндәге бер йомры тимергә басып, тышындагы кыңгыравын да «чың-чың» суктырып ала, ә без акыллы этләр сыманрак вагонның тар, ачык тәрәзәләреннән әле уңга, әле сулга каранып барабыз. Ниндирәк кала, нинди урам, нинди йортлар монда — гүя шуларны белеп, отып калырга тырышабыз... Минем куен кесәсендә Казан докторы Әбүбәкер абзый Терегулов исеменә атакай язып биргән хат — без менә шул абзыйны эзләп табарга тиешбез.

Трамвайдан кайда төшүебез, кайсы урамнар буйлап эзләп йөрүебез, билгеле, күптән онытылган, ләкин артык озак җәфаланмыйча гына без үзебезгә кирәк йортны эзләп таптык. Бу шәһәрнең нәкъ үзәгендә, Проломный белән Телеграфный урамнары чатындагы, Казан халкына бик билгеле һәм бик матур йорт иде. Менә шуның өченче катында Әбүбәкер абзыйлар торырга тиеш (бу йортны кайчандыр «Тум» дип тә йөртәләр иде, чөнки аның беренче катында ул чагында ук инде «Тум» дигән зур универсаль магазин урнашкан иде).

Фәтхелисламны әйберләр белән түбәндә калдырып, мин тәвәккәлләп һәм бераз гына каушабрак, карана-карана, югары күтәрелдем. Менә биек, таза, кызгылт-көрән ишек, аңа «Доктор А. Г. Терегулов» дип язылган кечкенә генә эмаль такта кагылган. Ишек янагындагы ак төймәгә сакланып кына бастым. Аз гына көттереп, миңа ишекне юка гына, пөхтә генә бер татар хатыны ачты (хадимәләре икән). Мин, кереп, Әбүбәкер абзыйга килүемне әйткәч, ул каршыдагы зал ишеген ачып, кемгәдер дәште. Залдан марҗаларча киенгән бик төз буйлы, озын-мәһабәт ханым чыкты. «Сезгә кем кирәк?» — дип сорады ул миннән ирләрчә калынрак, әмма ягымлы күкрәк тавышы белән... Мин Дәүләкәннән килүемне әйтеп, кесәмнән хатны чыгарып, аңа суздым. Ул хатны алып, адресын укып карады да миңа: «Аз гына көтеп торыгыз»,— дип, залга кереп китте. Бу мәһабәт озын ханымның Әбүбәкер абзый җәмагате Әминә апа икәнлеген мин шунда ук аңлап алдым. Ул ят бер малайның килеп керүенә ризасызлык

сиздермәде, шулай ук якты чырай да күрсәтмәде — ничектер бик гади генә мине каршы алды.

Бераздан, Әминә апа белән бергә, кулына ачык хатны тотып Әбүбәкер абзый үзе дә чыкты. Урта буйлы, тулырак тыгыз гәүдәле, карарак йөзле, куе җыйнак кына мыеклы, чал куна башлаган чәчен дә кыска гына (русча әйтсәк, под ежик) калдырып алдырган, кырыклар чамасындагы бер кеше иде ул. Безнең өчен зур кеше — татар докторы. Каргалы өлешендә язганымча, ул да шул авылдан чыккан морзалар нәселеннән, атакай аны яхшы белгән, Әбүбәкер абзый үзе дә минем атайны хәтерләргә тиеш иде. Һәм, чынлап та, иң элек ул миннән:

— Нигъмәтҗан абзый малаемы? — дип сорады.

— Ийе,— дидем мин.

— Укырга дип килдеңме?

— Ийе, бер иптәшем белән.

— Та-а-ак... Ә кая кермәкче буласыз?

Мин, буталыбрак булса да, әлеге рәссамчылык-һәйкәл-тараш мастерскойларын атадым. Әбүбәкер абзый бераз гына дәшми торды да русчалап:

— Ну что же! — дип куйды, аннары Әминә апага карап: — Атасы Нигъмәтҗан абзый бездән шәкертләрне вакытлыча кабул итүне сораган... Керсеннәр булмаса,— диде дә, үзе шунда ук борылып, эчкәре кереп тә китте.

Инде Әминә апа миннән сораша башлады

— Исемең ничек?

— Әмирхан.

Ул гаҗәпләнде:

— Әмирхан?! Сездә дә бармыни бу исем?

— Бар, ник булмасын...

— Алай икән... Ә ипдәшең кем?

— Фәтхелислам.

— Кайда соң ул?

— Түбәндә... Әйберләр янында.

Шуннан соң Әминә апа миңа сынабрак карап торды да ничектер өздереп кенә:

— Ярый, туганым, вакытлыча кереп торырсыз... Укырга урнашканчы...— диде, аннан ишек ачкан асрау хатынга борылып әйтте: — Эчке бүлмәгә керт үзләрен!..

Шулай итеп, Әбүбәкер абзыйлар безне кабул иттеләр. Мин тиз генә төшеп, Фәтхелисламны әйберләре белән алып мендем. Асрау хатын безне кухня аша бер кечкенә бүлмәгә кертте.

— Шушында торып торырсыз, ятарыгызга урын-җир бирербез,— диде.

Без әйберләребезне идәнгә куйдык, үзебез урындыкларга утырдык. Бу инде безнең урнашуыбыз иде. Ләкин шулай да без әле үзебезне кул-аякларыбыз бәйләнгәндәй читен бер хәлдә хис итә идек. Шәп йортка, мөхтәрәм дәү кешеләргә килдек тә мәшәкать ясадык — ярыймы, килешәме бу?!. Икебез дә шулай уйлый идек бугай, һәм, шәкертләрчә кулыбызны тезләребезгә салып, селкенмичә дә тик кенә утырабыз. Хәтта сөйләшергә дә кыймыйбыз... Беренче минутлар әнә шулай үтте. Аннары мин карана башладым: вакытлы торагыбыз — бер генә тәрәзәле җыйнак кына бүлмә, кечкенә өстәле, ике урындыгы, комод кебек нәрсәсе дә бар. Стена буенда пөхтә итеп җыештырган тар гына тимер карават тора — бу әлеге асрау хатын бүлмәседер ахрысы... Торып, тәрәзәдән тышка да карадым. «Безнең» йорт күрше йортлардан биегрәк икән — аларның кызыл түбәләре бер-берсенә тоташып киткән, тик биеклекләре генә бер түгел... Шулай да шәһәр кызыклы — күпме халык аслы-өсле салынган читлекләрдә тора. Без дә бер заман «читлектә» торучы кала кешесенә әйләнербез микән? Ләкин күңел нигәдер әле моңа ышанып бетми иде.

Шулай каранып, яңа урынга әзрәк ияләшкәч тә без чыгып китәргә булдык. Әлбәттә, бүген үк күз төбәп килгән мәктәбебезне эзләп табарга кирәк — бу һич кичектермәс беренче эшебез... Ләкин кузгалырга өлгермәдек, асрау хатын безне кухняга чакырды.

— Әйдәгез, тамак ялгап алыгыз! — диде ул безгә.

Без икеләнебрәк калдык — монда ашап-эчеп алуны бер дә уйламаган идек. Кыюсыз гына рәхмәтебезне әйттек, ә асрау хатын авыз да ачтырмый:

— Әйдәгез, әйдә, бүген ашаганыгыз юктыр бит әле. Кыстатып торырга, ярамаганны!..

Шулай дигәч, чыктык инде, ак клеенка япкан зур гына өстәл янына утырдык. Кухня иркен, бик чиста, бөтен җире тәртиптә — монда чебеннең заты да юк

иде. Өстәлдә ак самавыр, бизәкле чынаяклар, сөт, шикәр, май, тәлинкә тулы ап-ак кумәч. Асрау хатын үзе безгә чәйне ясап, сөтне салып бирде. Бик ачыккан булсак та, без, әдәп саклап, кабаланмыйча гына ашарга тырыштык. Ак май да, кумәч тә бик тәмле иде. Беренче Казан ризыклары!

Ул да булмый, безнең янybызга саф татарча киң җиңле, озын күлмәк кигән, башына ак батист яулык бәйләгән, кулына тәсбих тоткан, бик пөхтә, бик мөлаем йомры гына бер карчык килеп керде. Бу — Әбүбәкер абзыйның анасы икән. (Бәлки әле Каргалыча «анакай» дип дәшә дә торгандыр).

Без олы кешегә хөрмәт йөзеннән тормакчы да булган идек, ләкин карчык кулы белән генә ишарә ясап, утырырга кушты. «Ризыгыгыз бүленмәсен»,— диде ул безгә... Аннары бер читкә үзе дә утырып һәм күтә төшеп, бездән җайлап кына исемнәребезне, ничек килеп җитүебезне, әти-әниләребезне, кая укырга кермәкче булуыбызны сораша башлады. Мөлаем карчыкның тавышыннан һәм күз карашыннан ук безне чын-чынлап кызгануын, кайгыртуын, ярдәм итәсе килүен сизеп була иде. Һәм, әйтергә кирәк, бу йортта тору дәвамында ходай бирмеш һәр көн безне ашатып-эчертеп, хәлләребезне белешеп, озатып һәм каршы алып торучы шушы ике изге җан — хадимә хатын белән Әбүбәкер абзыйның әнисе карчык булды. Төп хуҗалар Әминә апа белән Әбүбәкер абзыйны без бик сирәк күрә идек.

* * *

Чәйдән соң үзебезгә кирәк әлеге мәктәп-мастерскойны тизрәк эзләп табарга булдык. Кулыбызда адресы бар, аннары хуҗалар да бераз өйрәтеп чыгардылар: шушы аркылы урам белән тауга менәсез, анда Чернышевский урамы булыр, менә шуның белән уңга борылып, бер квартал барырсыз, университетка җитәрәк, сулга борылып, әзрәк түбән төшәрсез, башта бер бакчаны, аннан икенче — «Бакыр бабай» бакчасын үтәрсез дә нәкъ сезгә кирәк урам өстенә барып чыгарсыз, диделәр... Шактый ук буталчык иде бу безнең өчен, ләкин юнәлешне бер белеп алгач, тел үзе дә илтеп җиткерер әле дип уйладык без чыгып китешли...

Шул рәвешчә, тау менеп, уңга һәм сулга борылып, ике бакчаны да үтеп, без, ниһаять, үзебезгә кирәк урам өстенә килеп чыктык. Ләкин башта «Бакыр бабай» һәйкәле янында тукталмыйча китә алмадык. Әкрен генә әйләнеп, башны каерып, авызны да ача төшеп, бу безгә әле юньләп билгеле дә булмаган озын чәчле кешенең һәйкәлен игътибар белән тамаша кылып чыктык. Әйе, зур, мәһабәт, бик шәп һәйкәл, чынлап та бакырдан икән үзе, тик «бабайның» утырып торган күтәртмәсе генә шома кара таштан. Казан халкы аңа «Бакыр бабай» дип, бик дөрес исем биргән икән[1].

...Ярый, мәшһүр «бабайны» да күрдек, мәмнүн булдык, инде бакча алдыннан гына узган урамның кайсы очына таба китәргә? Узып баручы бер чибәр туташтан сорарга туры килде. «Әнә уңга таба барыгыз»,— диде туташ, нәфис кулын селкеп... Киттек, карана-карана барабыз, ләкин никтер һаман җитә алмыйбыз. Бу элек Грузинская дип йөртелгән, хәзер исә Карл Маркс исеменә күчерелгән Казанның иң озын һәм иң төзек урамы иде. Барысы да диярлек таштан салынган, әмма бер-берсенә охшамаган, зур, таза, бай йортларга карый-карый бара торгач, без менә ахырда Дәүләкәннән үк уйлап килгән, тик әле күреп кенә өлгермәгән бинабыз алдына килеп чыктык. Шушымы соң?.. Шушы икән шул!.. Әмма бу хәтле үк мәһабәт матур булыр дип һич тә көтмәгән идек. Мондый бинаны «мастерской» дип атарга мөмкинмени?! Бу бит иң шәп уку йорты булырга тиеш ләбаса!.. Хәер, ул чынлап та рәссамнар укытып чыгарыр өчен гасыр башында ук махсус салынган бина икән — без моны озак та тормыйча белдек, әлбәттә.

Урам капкасыннан да тазарак, ләкин бик пөхтә итеп, матурлап эшләнгән авыр имән ишегеннән эчкәре кердек. Аз гына узып, берничә мәрмәр баскычтан күтәрелгәч, безгә тагын шундый ук таза-нәфис бер ишекне ачарга туры килде, һәм безнең нәкъ каршыбызда түргә таба сузылган киң генә коридор ачылды. Бер ягында тезелеп киткән бүлмә ишекләре, икенче ягында исә төрле төстәге пыялалардан зур тәрәзәләр иде. Әмма безне тәмам хәйран иткәне яшел-зәңгәр пыялалы тәрәзәләрдән дә бигрәк коридорның ике як мөешендә басып торган

---

[1] Бу рус шагыйре Г. Державинга куелган һәйкәл иде. Хәзер аның бакчасы урынында Татар дәүләт опера һәм балет театры.

ике арыслан сыны булды (хәзерге вакытта бу мөешләрнең берсендә В. И. Ленин, икенчесендә М. Горький сыны басып тора). Ак таштан эшләнгән, икесе дә бер төсле үк арысланнар туп-туры ишеккә карап, гүя сакта торалар. Моның әллә берәр төрле мәгънәсе дә бар микән? Ягъни син, кеше, кая килеп кергә-неңне белеп кер, һәм лаек булсаң гына атлап үтәргә җөрьәт ит! Һәм без моны, акыл белән уйлаудан элегрәк, күңелләребез белән тоеп өлгердек. Юк, чынлап та без гади бер уку йортына гына килеп кермәдек бугай... Инде тагын бер хикмәтле нәрсәне күргәч, бездәге бу тойгы аеруча көчәйде. Коридорның түренә таба, нәкъ уртада, сәке сыман агач күтәрмә өстендә йөзтүбән капланып, галәмәт бер адәм сыны ята иде. Без әкрен генә шуңа якынлаштык: кем бу, нәрсә бу?.. Адәм гәүдәгә гади кешедән ике-өч мәртәбә зуррак, аңардагы көч-куәт тә чамасыз булса кирәк — кулы, аркасы, ботындагы мускуллар эре-йомры ташлардай буын-буын калкып торалар... Мөгаен, борынгы әкияттән алынган берәр пәһлевандыр дип уйладык. Әмма аның коточкыч бер киеренкелек белән аягын җиргә терәп, бармакларын куе чәчләренә батырып йөзтүбән ятуында әллә ярсу-ачудан, әллә көчсез-гаҗизлектән шундый бер дәһшәтле газап сизе-леп тора иде ки, аңа карап, ирексездән тетрәнмичә һәм сихерләнмичә калу мөмкин түгел иде. Яныннан китә алмыйча хәйран булып торганда, без бу пәһлеванның кем икәнлеген ачык кына белмәсәк тә, аның кеше хыялы белән тудырылган сәнгать әсәре булуын шулай да аңладык. Әнә нәрсә икән ул «һәйкәл-тараш»! Шушында өйрәтәләр икән бу гаҗәеп сәнгатькә!.. Без, ике Дәүләкән малае, моңа һичшиксез балаларча сөендек, һәм шул ук вакытта ирексез туган шик-шөбһәдән ныграк каушый да төштек. Насыйп булыр микән керүләре? Әмма чигенү юк, чигенергә һич тә ярамый, тәвәккәл таш йоткан диләр... Пәһлеван яныннан кире борылып, туры кәнсәләрия бүлмәсенә киттек — ул тышкы ишек-тән кергәч тә уң кулда иде... Хуш, инде кем башлап ача бу кәнсәләрия ишеген?! Фәтхелислам миңа төртә — мин — өйдән чыкканнан бирле — алдан йөрүче... Ачтым — кердек, алдан ук язып куйган гариза белән документларыбызны кем-гәдер бирдек. Хәзер инде ул кешенең кем икәнен дә, бездән нәрсәләр сорашка-нын да хәтерли алмыйм. Килеп, белешеп торырга кушты бугай... Шуның белән эш бетте, һәм без, ниндидер бер җиңеллек хис итеп, артык юанмыйча шәһәр гизәргә чыгып киттек.

* * *

Без килгән чактагы Казан — ул кадимче Казан иде әле, ягъни анда бернинди үзгәреш юк, бернинди яңа салынган бина-мазар да юк, әйтик, 1915 елны ул нинди булган булса, ун елдан соң да шундый ук иске шәһәр иде. Дөрес, күптән түгел үтеп киткән сугыш еллары, революция вакыйгалары, ачлык-бөлгенлек вакыты шәһәрнең урам һәм йортларында үзенең ниндидер эзләрен калдырган. Безгә, яңа килүчеләргә дә, моны күрү әллә ни читен түгел иде. Мәсәлән, урам тротуарлары күп җирдә ватык, чокыр-чакырлы, күп кенә йорт-ларның штукатурлары купкан яки керләнеп беткән, фанер белән капланган тәрәзәләр дә күренгәли, хәтта кайбер йортлардан лазарет исе дә килә иде... Шулай да Казан безгә бик ошады. Мин яхшы гына белгән Уфадан ул зуррак та, җанлырак та, зур-зур таш биналар да күбрәк, трамвайлар да йөри, аннары, әнә, калкулык өстендәге таш диварлар белән әйләндерелгән, эче эреле-ваклы чиркәүләр белән тулган һәм шулар арасыннан ялгыз гына күккә сузылган нечкә-нәфис манаралы мәһабәт ак Кремле дә аның борынгы кала булуын әллә кайдан ук күрсәтеп тора. Гомумән, чиркәүләр бик күп, мәчетләр дә аз түгел икән — унсигез дип ишеткәнем хәтердә калган.

Менә шул көннәрдән соң алтмыш ел гомер узды да китте. Бу вакыт эчендә Казан берничә мәртәбә зурайды һәм искиткеч үзгәрде. Ләкин шулай да калабыз үзенең борынгы йөзен югалтып бетермәде. Шуның белән кадерле дә бит ул безгә һәм, заманнар узу белән, аның кадере тагы да артачак кына...

Ә алтмыш ел элек безгә иң элек шәһәрнең үзәген күрергә туры килде, чөнки йөри торган юлыбыз хәзергә Бауманнан Карл Маркс урамына чаклы иде. Урамнарның да күбесе иске исемнәрен саклыйлар иде әле. Бауман урамы ул чакта Большая Проломная, янәшәсендәге Профсоюзная — Малая Пролом-ная, Куйбышев урамы Рыбнорядская, Бутлеров урамы — Старо-Горшечная дип йөртелә иде. Әзрәк иләшә төшкәч, татар ягына — Печән базарына да, Кабан күле буена да баргалый башладык. Нэп диган «хөрлекнең» бу иң көчәйгән, иң котырган чагы иде. Проломныйдагы искедән калган бөтен кибетләр ачык, Гостинный дворның (Татарстан музее урнашкан йортның) бик күп бүлекләре сату итеп ята, хәзерге Кольцо дигәнебез ул чакта вак кына кибетләр белән

шыгрым тулы иде... Инде Печән базарына барсаң, анда сату-алу эшләре «Кисекбаш» заманындагы шикелле гөрләп тора. Тимер ишекле таш кибетләр барысы да ачык, товарлары урамга ук чыгарылган — өлгер хуҗалары урамнан узучыларны чакырып-дәшеп торалар. Мәскәүский (хәзерге Киров) урамындагы бакча урынында толчок иде. Шунда бер читтәрәк зур чуеннарда аш пешереп сатучылар — моны «бирәннәр» (обжора) рәте дип атыйлар иде. Тирә-юньдәге йортларда чәйханәләр, сыраханәләр — аларда кызарган, бүртенгән «агай-эне» шау-гөр килеп утыра. «Болгар», «Амур», «Сарай» номерларында татар рестораннары, татар музыкантлары, татар җырчылары (дөресрәге, шансонеткалары) — монда инде кичләрен нэпманнарның кәттәләре типтерәләр булса кирәк... Урамнарда даңгыр-доңгыр узган ломовойлар, тротуар буйларында сала агайларының ат-арбалары — кыскасы, нэп тудырган чын базар, чын сәүдә оясы! Ихтимал, Тукайлар, Камаллар заманында да ул шулайрак булгандыр, бары тик «Көфер почмагы» гына юкка чыккан булырга тиеш.

...Мәчетләрнең дә барысы да эшлиләр иде шикелле. Манаралардан иртәкич азан тавышлары ишетелә, бүрек, җилән кигән агайлар, ашыга-ашыга, намазга баралар... Минем әле хәтеремдә шул замандагы рамазан ае да. Кичкырын икенде ахшам вакытында мәчет аллары муеннарына сай тартма асып, кәләвә, как-төш, чәк-чәк, балда катырган мәк сатучы малайлар белән шыгрым тулы була торган иде. Мәчеттән чыгучы агай-энене бу малайлар яшел-зәңгәр тавышлар белән: «Кәләвә! Кәләвә!», «Как-төш!» — дип кычкыра-кычкыра каршы алалар. Һәм мөселман ни дә булса алмыйча китми — күрәсең, изге айның бер йоласы булгандыр инде бу. Тагын бер нәрсә мине бик гаҗәпләндергән иде — хәер сорап утыручы гарип-горабаның күплеге... Бәлки мәчет алларында гына барысы бергә җыелып утырганга күрәдер... Алай дисәң, урамнарда да төрле гарипләр — зур башлы кәрләләр, бөкреләр, сукырлар еш кына очрап торалар. Ә кәкре аяклыларны әйткән дә юк — болары аеруча хатын-кызлар арасында еш очрый... Бичара Казан кызларына мондый бәхетсезлек кайдан, нәрсәдән килә икән дип уйлаганым да бар иде. Ишетүемә караганда, Казан халкының эчә торган суында ниндидер матдә җитешми икән. Шунлыктан рахитик балалар күп, шулар кәкре аяклы булып үсәләр имеш. Белгечләр бу хакта ни әйтә торгандыр, ләкин татар ягында торучылар суны чынлап та күбрәк Кабаннан эчкәннәр. Шулай да эчкәннәр, чөнки акмый яткан ябык күл элек-электән үк Казан халкының бердәнбер төп су чыганагы булып килгән.

...Күл һәм Болак дигән сусыз, тирән чокыр, билгеле булганча, Казанны нәкъ уртасыннан икегә бүлеп узган. Без килгән чакларда каланың югары һәм түбән ягы дип йөртелгән бу ике өлеше бер-берсеннән шактый нык аерыла иде. Татарлар тыгызланып утырган түбән якта яшеллек бик аз, зур бакчалар юк, күп җире сазлык, урамнарда һәрвакыт тузан... Иске бистә белән Яңа бистә арасындагы зур сазлыктан таралган үзе әче, үзе яман сасы ис җәйнең бөркү көннәрендә Болакка хәтле үк килеп җитә иде.

Иске Казан, иске заман... Монда диннең көчле булуын әдәбияттан да укып белә идек. Әнә бит бер катлы, ике катлы агач йортларны да кыйблага каратыр өчен урамга кырынрак итеп салып куйганнар — бу безнең өчен яңалык иде. Сүз уңаеннан шуны да әйтеп үтәсе килә, Казанда элек мәшһүр байлар күп кенә булса да, алардан калган зур, матур йортлар бик сирәк күренә иде. Тукай урамындагы Шамил йорты белән аркылы урамдагы Апанаевлар йортын исәпләмәгәндә, Казанның татар ягы архитектурага ярлырак булган икән. Байлык җитмәгәнме, әллә вакытмы?..

Татар ягында йөргәндә тагын бер нәрсә күзгә ташланмыйча калмады. Монда саф мөселман агай хатынын артыннан ияртеп йөри икән... Кызык! Хәер, безнең Дәүләкәндә дә Әхмәтвәли исемле Казаннан килеп чыккан бер абзый хатыныннан гел бер-ике адым алдарак йөри иде. Ул үзе кечерәк буйлы, вак-вак кына атлап, кызу гына тыраклый, ә хатыны озын-таза, аякларын салмак кына эре-эре итеп сала. Кешеләр күреп алсалар:

— Әнә Әхмәтвәли агай дөясен җитәкләп килә! — дип көлә торганнар иде... Әмма Казан урамнарында Әхмәтвәли ишеләр шактый ук икән әле.

Ләкин барыбер чал Казан — иске Казан түгел иде инде. Яңа заман галәмәтләрен дә таш каланың һәр җирендә ачык күрергә мөмкин. Иң элек бик табигый рәвештә без моны уку йортлары тирәсендә күрдек. Безнең ише ерактан, мәсәлән, Уралдан, Ырынбурдан, Әстерханнан, Донбасстан, Себердән һәм мишәр якларыннан укырга дип килгән татар егетләре, татар кызлары кая гына барсаң да очрап кына торалар. Алар бик төрле, бик чуар — өстеннән әле шинелен дә салмаган «картлары» һәм өеннән беренче мәртәбә генә чыгып киткән бик яшьләре дә бар. Күпчелеге авылдан — боларны кыяфәтләреннән

үк танып була. Ләкин төрле шәһәрләрдән килүчеләр дә аз түгел. Һәммәсе дә зур өмитләр белән килгән — беренче мәртәбә бит аларга барлык уку йортларының ишекләре киңенчә ачык!.. Кер, укы, белем гранитын кимер!.. (Бу сүз ул чакта модада иде). Бәлки барысы да кереп бетә алмас — шуңа күрә аларның йөзендә шатлык белән бергә каушау да чагыла... Тик ни сәбәптер алар арасында Казанның үз яшьләре сирәк күренә — моңа да нэп гаепле булмады микән?!

Урамнарда йөргәндә без һәр очраган вывесканы укымыйча үтмибез. Әлбәттә, барысы да ике телдә — татарча һәм русча. Ләкин татарчасы хәзергегә караганда башкачарак, мәсәлән, дәүләт биналарына куелган такта яки калайга: «Татарстан автономияле социалистик шуралар җөмһүрияте» дип язылган... Бу яңа, бу горурлык уята, «Татарстан... шуралар җөмһүрияте» — димәк, безнең үз дәүләтебез!..

Халык комиссариатларының да кайберләре бүтәнчәрәк атала иде: финансныкы — малия, юстициянеке — гаделия халык комиссариаты дип язылган була иде. Хәтта университетка да «дарелфөнүн» дип язылган иде ул чакта. Инде татар ягындагы кибетләр арасында йөрсәң, монда әллә кайдан ук татарча гына язылган зур-зур вывескалар күзеңә ташлана: фәлән ширкәт тә төгән ширкәт!.. Ләкин арада бик хөртиләре дә очрый — болары вак сатучы яки һөнәрченеке булырга тиеш. Мәсәлән, шундый хөрти вывесканың берсе әле дә хәтеремдә: Тукай урамындагы бер капкада «галуш җамыйм» дип язылган калай кисәге эленеп тора иде.

Тагын нәрсә?.. Урамнарда йөк ташучы ломовойлар, чатларда резин ходлы извозчиклар... Ат-арба заманы. Акчаң булса, утыр да кит — үзләре үк чакырып торалар. Ә кичләрен бу извозчиклар спектакль бетүгә театр алдына килеп тулалар. Тамашадан чыккан бай нэпманнарны утыртып, бер-бер артлы, таш урамнарны шакылдата-шакылдата җилдереп алып та китәләр. Аның каравы, безнең ише «люмпеннар» өчен ул елларда «барабыз»лар бар иде. Чана юлы төшкәч, алар Дөбъяз тирәсеннән киләләр иде бугай. Үрәчәле чанага алашасын җиккән чикмәнле агай 10—15 тиенгә сине теләсәң кая илтә дә ташлый торган иде.

Ярый, сүзгә мавыгып, әзрәк читкә дә чыктым. Безнең бит әле яңа гына килгән чагыбыз, кала белән бары тыштан гына танышып йөрибез. Эчендә аның ниләр бар — хәзергә билгесез. Әгәр калырга язган булса, «эче» дә әкренләп ачылыр.

* * *

...Килүебезгә берничә көн үтеп китте. Документлар бирелгән, имтиханнар башлануын көтәбез, ә хәзергә урам таптаудан башка эшебез юк. Әбүбәкер абзыйлардан иртән чыгып китәбез, кич кенә кайтып керәбез. Хуҗаларга артык мәшәкать ясамас өчен көндез кайтмаска тырышабыз. Кесәбездә юлдан калган күпмедер акчабыз бар, арзанлы ашханәләрнең берәрсенә кереп, тамак та ялгап чыгабыз. Кольцодагы хәзерге «Чулпан» ресторны ул чакта әнә шундый ашханәләрнең берсе иде. «Нарпит» дип атыйлар иде аны... Бу нарпитта 10 тиенгә бер тәлинкә аш алсаң, шуны дүрт-биш телем икмәк белән әйбәт кенә сеңдереп чыгасың. Икмәк түләүсез иде шикелле, өстәлләрдә өелеп ята иде — теләсәң күпме аша!

Ләкин, «Фатир»га соң гына кайтсак та, безне көн дә диярлек аш белән көтеп алалар иде. Асрау хатын безнең соңлап кайтуыбызга әз генә үпкәсен белдереп, шунда ук ашын да, ите белән бәрәңгесен дә җылытып бирә. Без, ашап кайттык, тамагыбыз тук, рәхмәт дия башласак, ул чын шелтә белән: «Нигә, акчагыз әтәч булып кычкырамыни?» — дип әйтә торган иде. Әбүбәкер абзыйның әнисе миһербанлы мөлаем карчык та, гаҗәпләнүен яшермичә: «Ник читтә ашап йөрисез, килешми ич ул, кунак бит сез безгә!» — ди иде. Шуннан соң инде без, ике сантый, алдыбызга китереп куйган сыйларны, кызарынып, сүзсез генә ашарга утырабыз.

Аларның безне шулай кайгыртулары, көтеп алулары, хәлебезне дә сорашып торулары безгә, әлбәттә, бик ошый иде. Чит-ерак җирдән килгән безнең ише кеше, ничек дим, беркадәр ятим кеше, шуңа күрә ул һәрвакытта җылы сүз, яхшы мөгамәләгә мохтаж... Ләкин дә бит ике таза малай урын биләп ятабыз!.. Көн дә кайтып-китеп, мәшәкать ясап йөрибез. Шушы нәрсә безне һаман борчый, шушы нәрсә җаныбызга тынычлык бирми иде...

Әбүбәкер абзый ул елларны Казандагы бармак белән генә санарлык татар докторларының иң танылганы иде. Бөтен татар ягы аңа йөри иде дисәм

дә хата булмас... Иртәрәк кайткан чагыбызда, аңа килгән авыруларның каршыдагы залда көтеп утыруларын күрә торган идек. Әбүбәкер абзыйның зур гына кабинеты ишектән кергәч тә сул кулда — авыруларны ул көн дә диярлек шунда кабул итә иде. Болай үзендә кабул итү ул электән үк килгән законлы бер эш, шуңа күрә һәрбер врачның тышкы ишегендә исем-фамилиясе язылган кечкенә генә бакыр яки эмаль такта була торган иде. Кабул итү, әлбәттә, түләү белән — аны гонорар дип кенә әйтәләр иде... Минем үземә дә соңыннан әнә шул кабинетта Әбүбәкер абзыйга бер-ике тапкыр күренергә туры килде — билгеле, түләүсез генә, чөнки мин аңа үз кеше...

Авырулар кабул итмәгәндә дә алардан кеше өзелми иде диярлек — кичләрен еш кына зур залда үзләре кебек интеллигент кешеләр җыелышып утыралар. Алар арасында медицина әһелләре генә түгел, художниклар, артистлар да була икән... Бик җанлы мәҗлес, өзлексез сөйләшү, көлешүләр — шулар арасыннан мәһабәт-төз буйлы Әминә апаның көр тавышы ап-ачык ишетелә... Менә шундый чакта кайчак без звонок биреп кайтып керәбез һәм, җилкәләребезне җыерып, мыштым гына кухня аша үз бүлмәбезгә үтеп китәбез. Дөрес, кунаклар безне күрмиләр, ләкин шулай да уңайсыз. Мондый чакта кайтмый тору яхшырак та бит, әмма нишлисең, бүтән чараң булмагач! Җитмәсә әле, мәрхәмәтле асрау хатын кунакка әзерләгән сыйлардан безгә дә өлеш куя. Менә шулай, кәбәм!..

Тагын бер мәртәбә кабатлап әйтәм, бу йортта ике атнадан артыграк торып, без хуҗалар тарафыннан бернинди ризасызлык сизмәдек. Кайчанрак күчәрсез икән дип, читләтеп кенә булса да, бездән теш елтыратып сораучы булмады. Бер караганда, төп хуҗаларның бездә эшләре юк шикелле тоелса да, безгә булган игътибарның, әлбәттә, Әминә апа ризалыгы һәм боерыгы белән эшләнгәнен аңлавы читен түгел иде. Мондый гаиләдә башкача була да алмый торгандыр инде ул... Әмма ләкин бу изгелекне нәрсә белән кайтарырга?.. Әгәр аларга берәр төрле эш эшләргә, әйтик, су китерергә, утын ярып кертергә кирәк булса, без «эһ» тә димичә рәхәтләнеп эшләгән булыр идек. Ләкин аларда безгә яраклы бер төрле дә эш юк иде.

Хәер... бер эш шулай да табылды. Әбүбәкер абзыйның салпы колаклы, аклы-сорылы, бер чуар ау эте бар иде. (Без аны икенче көнне генә күрдек, чөнки аның урыны ишек төбендә түгел, каядыр түрдә иде бугай...) Менә шушы акыллы эт, кемнәр икәнебезне белгәч, безгә бик тиз ияләште. Кайтып керүебезгә, чабып яныбызга килә, бүлмәгә дә: «Әйдәгез, әйдә»,— дигәндәй, алдан үзе кереп китә, куанычыннан нишләргә белмичә бөгелә-сыгыла, бертуктаусыз әле миңа, әле Фәтхелисламга сырпалана... Аннары бераз тынычлангач, башын тезәмә сала да туп-туры күзләремә карап тора башлый. Адәм баласыныкыдай күзләре аның нидер сорый, нидер көтә. Ах, әйтә дә алса иде ул!.. Ахырда без сиздек, аның, мөгаен, йөрергә чыгасы килә торгандыр... Асрау аша Әминә ападан алып чыгарга рөхсәт итүен сорадык. Әминә апа үзе безгә, пажалысты, алып чыга күрегез, Әбүбәкер абзагызның аны йөртергә бер дә вакыты юк, диде. Шуннан соң, Фәтхелислам белән икәү, һәркөнне диярлек чуар этебезне алып чыгып, Болак буйларында күңеле тәмам хушланганчы йөртә торган булдык. Каешыннан ычкындырмый идек ычкындыруын, әмма аның өчен бу чыгулар барыбер гаять зур хөрлек иде. Хәлдән тайганчы безне сөйрәп чаба иде, бөтен җирне иснитырный иде, һәр очраган бағананы «тамгалап» китә иде... Бу иреккә чыгуларны ул озак оныта алмагандыр, безне бик юксынгандыр, бәлки әле боегып, җылап та йөргәндер.

Сүз җаеннан әйтмичә үтә алмыйм, этләрне мин үзем бик яратам. Алар үзләре дә миңа һәрвакытта шәфкатьле булдылар. Чылбырдагы усал эт янына барганым бар — карады, иснәде, тимәде. Эт гаять сизгер ул, акыллы ул, инсафлырак та ул. Начар белән яхшы кешене әллә кайдан ук сизеп тора. Начарга якын да бармый, ә яхшыга үзе үк килә. Мәкерле алдау гына аны харап итәргә мөмкин... Яхшылыкка каршы ул бервакытта да начарлык эшләмәс. Адәм баласыннан «этлекне» күп күрдем, әмма этләрдән — юк. Хәзер дә әле мин очраган бер эткә, ышанычлы дуска дәшкәндәй, «нихәл син!» дип дәшмичә узмыйм.

Әйткәнемчә, без Әбүбәкер абзыйларда ике атнадан артыграк — укырга керү мәсьәләсе хәл ителгәнчегә чаклы тордык. Кайчан, кая китүебезне түбәндәрәк язармын, ә хәзер исә бер үкенечемне әйтеп үтәсем килә: күргәнебезчә, безгә шундый яхшылык эшләгән һәм күпмедер дәрәҗәдә миңа нәселдәш булган шушы бик әйбәт, бик хөрмәтле гаилә белән мин ни өчендер соңыннан элемтәмне югалттым. Дөрес, моның минем үз хәлем белән бәйләнгән җитди сәбәпләре булды. Хәлбуки, сугыштан соң авыр еллар узып, тормышлар да бер әзгә төшкәч, үзем дә инде олаеп, язучы да булып киткәч, өзелгән элемтәне яңартырга

бик мөмкин иде. Әбүбәкер абзыйның үзен дә, Әминә апаны да якыннанрак белергә, алар күреп уздырган заман, тормыш һәм кешеләр турында сорашырга бик кирәк иде. Зур кызганычка каршы, «кирәклеген» белеп йөргән хәлдә, мин аны да эшли алмадым. Әллә урынсыз тыйнаклык, әллә ваемсызлык, әллә тормышның ваклыклары — нәрсәдәр мине чабуымнан тоткандай тыйды да торды.

Ә бит мин, килгән елларны, авыр чакларда аларга баргалый идем. Мәрхәмәтле карчык белән асрау мине үз итеп каршы алалар, хәлемне сорашалар, кухняда гына ашарга да утырталар. Инде Әминә апа өйдә булып, түр бүлмәләрдән чыкса, аз гына сөйләшүдән дә хәлемне аңлап, берәр сум акча да биреп җибәрә иде.

...Ике-өч тапкыр Әбүбәкер абзыйга да күрендем. Үпкәләрем таза түгел иде ул чакта. Язга чыгу белән, кәефнең начарлануын сизеп, беренче мәртәбә аңа баргач, ул мине әйбәтләп карады, тыңлады да: «Сиңа саф һава, таза ашау, кымыз эчү кирәк, монда тузан йотып йөрмә, тизрәк өеңә — Дәүләкәнеңә кайтып кит!» — диде, һәм бу бик дөрес киңәш иде.

Икенче мәртәбә белешмә алу өчен аңа күренергә туры килде (нинди белешмә һәм ни өчен — бу хакта вакыты җиткәч). Ә өченче мәртәбә күренүемнең сәбәбе болай булды: мин ат казылыгы ашап агуландым. Төн буе күз дә йома алмыйча газапланып чыктым, укшудан бөтен эчем актарылды, берни дә калмады. Иртән көч-хәлгә торып Хәбибрахман янына киттем — аның медфакның дүртенче курсында укыган чагы иде. Ул, мине ияртеп, хәзерге Вишневский клиникасына алып китте. Алар курсы шул көнне анда практика үтәләр икән. Хәбибрахман курс җитәкчесе врач-ассистенттан мине каравын үтенде. Ассистент бик рәхәтләнеп риза булды һәм бөтен группа алдында мине чишендереп өстәлгә салды. Әзрәк сорашканнан һәм үзе караганнан соң, студентларның да барысына карарга кушты. Ну, шул чактагы хәлемне белсәгез иде! Студентка кызлар җылы-йомшак куллары белән минем бушап калган эчемне әле уңнан, әле сулдан басып-басып карыйлар, җитди генә нидер әйткән булалар, үзара сөйләшкән булалар. Шунда берәрсе шырык-шырык көлеп тә куя. Ә мин ыштан изүен тотып, сикереп торырдай булып ятам.

Карау-сорашулар беткәч, врач-ассистент нәтиҗә ясап, үземнең диагнозны куйды.

— Картина ачык. Авыруның сәбәбе — аппендицит. Приступ шуңардан... Егетнең сукыр эчәген кисәргә кирәк!..— Һәм миңа озакка сузмыйча, берәр атнадан операциягә керергә кушты.

Киенеп урамга чыккач та мин тиз генә тынычлана алмадым. Бу операция дигән нәрсә мине чынлап торып хафага салды. Кисү-ярүны моңарчы бик сирәк ишетергә туры килә иде, һәм бик сирәкләр генә исән калалар да иде шикелле... Белмим, бәлки болай курку-шикләнү урынсыздыр да, ләкин нишләмәк кирәк, хәвефле уйлар күңелгә килә дә тора. Соңрак миңа Хәбибрахман да сукыр эчәкне кистерүнең бик җиңел операция булуын аңлатырга тырышты. Юатырга оста инде ул, аның сүзләреннән соң бераз тынычланган кебек тә булам, тәвәккәллек тә кайткан шикелле була, ләкин озакка түгел — тагын төрле шик-шөбһә күңелне әкрен генә кимерә башлый. Нишләргә инде? Күзне йомып, ятарга што ли?.. Әмма аяк тартмый гына бит... Инде бер атна вакыт та узып китте, врач биргән срок та килеп җитте. Ә мин үземне, үч иткәндәй, бик әйбәт хис итәм, ашау-эчү дә элеккечә шәп бара, бер генә җирем дә авыртмый — йә, шушы хәлдә бар да пычак астына ят имеш!.. Туктале, дидем, «асылынсаң асыл — алмагачның асылына» дигәннәр — тоттым да Әбүбәкер абзыйга киттем. Кабул итте. Әйбәтләп карады һәм әйтте:

— Пока операциягә керми тор,— диде.— Әгәр приступ яңадан кабатланса, килерсең, карарбыз!..

Менә шул. Әйтерсең, авыр ташны өстемнән алды Әбүбәкер абзый. Рәхмәт кенә аз аңа! Шулай да баштарак яңа приступны көтебрәк йөрдем, ләкин ул килмәде, һәм мин бик тиз тынычландым — сукыр эчәкнең барын да оныттым. Шуннан соң менә, әйткәнем булсын, алты дистәгә якын гомер узып китте, бер генә тапкыр да приступка охшаган нәрсә кабатланмады. Һәм моннан соң да... Хәер, моннан соң ни буласын юрамый тору яхшырак.

Инде югарыда әйткән миндәге үкенү хисе ул Әбүбәкер абзыйның яхшылыгын онытудан гына туган нәрсә түгел, әлбәттә (хәлбуки, бу да зур үкенеч). Сәбәп тирәндәрәк ята: хикмәт шунда ки, Әбүбәкер абзый да, Әминә апа да — тарихи шәхесләр. Татар халкының чын зыялылары, киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм кешеләр. 1885 елны Уфада туган Әбүбәкер Батыргәрәй улы Терегулов 1911 елны Казан университетының медицина факультетын бетереп чыга. Совет вакытында Германиягә барып белемен арттыра, докторлык диссертациясен

яклый. Татарлардан беренче атаклы доктор һәм медицина профессоры. Сугышка чаклы һәм сугыштан соң да Татарстан Верховный Советына депутат булып сайланган иде. Күрәсез, игътибарга бик лаек кеше.

...Ахрысы, шуңа күрәдер дә язучы Габдрахман Әпсәләмов үзенең мәшһүр «Ак чәчәкләр» романындагы карт доктор Әбүзәрнең прототибы итеп Әбүбәкер абзый Терегуловны алган булган — һәрхәлдә шулай дип сөйләделәр. Ләкин әсәрдәге образ белән тормыштагы прототип күп очракта төгәл туры килеп бетми — аерма һәрвакытта була һәм шактый зур да була. Менә бу очракта да аерма, минемчә, зур иде. Озак еллар дәвамында миңа да бит Әбүбәкер абзыйны күрергә, күзәтергә, сөйләшкәләргә туры килде. Һәм мин аны үз бәясен яхшы белгән, һавалырак, әмма ачык йөзле, бөтен торышы-тотышы белән чын бер интеллигент кеше дип таный идем. Йөргәндә ул бик пөхтә киенеп, эшләпәсен яки бүреген яшьләрчә кырынрак салып йөри торган иде. Эт ияртеп ауга йөрүче, китап җыючы, сәнгать әһелләре белән утырырга яратучы, кыскасы, тормыштан тәм табучы иде ул, миңа калса. Һәрхәлдә, кешеләргә мораль укып, акыл сатып йөрүче резонер түгел иде.

Миндә иске бер фоторәсемнең Срур тутакай күчертеп биргән копиясе саклана. 1911—1912 елларда булса кирәк, Дим буена кымызга килгән бер төркем татар зыялылары авыл кырындагы яшел чирәмдә фотога төшкәннәр (Авылы «Кара Якуп» түгел микән?). Рәсемдә Мәҗит Гафури, хатыны Зөһрә ханым белән, Сәгыйть Сүнчәләй, Гаяз, тагын кем булулары ачылып бетмәгән берничә кеше — һәм шулар арасында Әбүбәкер абзый белән Әминә апа да бар... Әнә шундый бәйләнешләр...

Моңа артык гаҗәпләнергә дә туры килми. Әминә апа бит ул — Ибраһим Терегуловның өлкән кызы. Ә Ибраһим Терегулов культура тарихыбызда мәгълүм кеше — мәгърифәтче, педагог, җәмәгать эшлеклесе... Күп еллар Учительская школада эшләгән, рус классикларын татар телендә бастыра башлаган, «Шәрык клубы»н оештыручыларның берсе һәм беренче рәисе булып торган. Җәмәгате Бибигайшә ханым да мәдәни эшләрдән читтә тормаган — русчадан татарчага тәрҗемә итү белән шөгыльләнгән (аның хакында «Азат хатын» журналының 1984 ел, 10 нчы санын карагыз). Димәк, бу гаилә үз заманының мәдәни хәрәкәтендә якыннан катнашып, барлык алдынгы кешеләре белән аралашып яшәгән. Әдипләрне, шагыйрьләрне, артистларны да алар яхшы белгәннәр. Билгеле инде, житеп килгән кызлары да бу даирәдән читтә тормаган. Әминә апа, мәсәлән, 1905-06 нчы елларда ук йорт спектакльләрендә катнаша башлый. Моны мин Шәриф җизни Сүнчәләйдән ишеткән идем — ул да бит шул елларны Учительская школада укый һәм демократик яшьләр хәрәкәтенә якыннан катнаша. Шагыйрь Сәгыйть Рәмиевнең Әминә апага мөкиббән гашыйк булуы турында да ишеткәнем бар. Чын булса, шагыйрьнең «Сызла, күңелем!» шигыре турыдан-туры Әминә апага атап язылган...

Сызла, сызла, сызла, күңелем!
Сызла бер туктамыйча,
Сызла айлар, сызла еллар,
Сызла төн йокламыйча!

Сызла, сызла, син мәхәббәт
Ялкынын гөлләр яса,
Мәнге хәсрәт һәм кара төн
Елларын көннәр яса!..

...Кызыклы заман, таң вакыты (шагыйрь әйткәнчә), әмма татар йокламый — татарның уянган чагы. Әбүбәкер абзый белән Әминә апа да нәкъ шул заман яшьләре — йөргәннәр, күргәннәр, эчендә кайнаганнар. Бигрәк тә Әминә апаның хәтерендә һәм күңелендә күп нәрсәләр сакланган булырга тиеш иде. Ләкин ни кызганыч — барысы да үзләре белән китте. Хәзер инде үкенүдән мәгънә юк — мин үз гаебемне өстемә алдым... Әмма... мондый үкенү бер миндә генә микән?.. Без бит озак вакытлар тарихыбызның иң кызыклы, иң гыйбрәтле дәверенә игътибарсыз булып кала бирдек. Һәм шул вакыт эчендә ул дәвернең Әминә апа кебек җанлы шаһитлары аз киттемени бу дөньядан?.. Юк, үкенүчеләр дә аз булмаска тиеш.

* * *

Без кабул итү имтиханнарын көтеп йөрибез. Башка эшебез юк, көн дә Карл Маркстагы чибәр йортка барабыз (хезмәткә йөргән шикелле). Барган саен анда үзебез кебек читтән килгәннәрне очратабыз. Барысы да егетләр,

кызлардан ни өчендер бераү дә юк. Егетләрнең һәммәсе дә диярлек төрле шәһәрләрдән — Ырынбурдан, Әстерханнан, Самарадан — ә менә Стәрлетамактан берьюлы өч егет килгәннәр. Болар инде безнең якташлар, алар белән бик тиз дуслашып киттек... Мортаза Абдуллин дигәне белән минем дуслык даими төс алып, мәрхүмнең үлгән көненә кадәр дәвам итте. Аның хакында сүз булачак әле...

Йөри торгач, имтиханнар көне дә килеп житте. Читтән килгән, гариза биргәннәрнең барысын да үткәргәннәр. Беренче имтиханга керүебезнең тәгаен числосын күптән онытканмын, һәрхәлдә, августның егермеләре тирәсендә булды шикелле... Шулай ук нәрсәләрдән имтихан бирүебез дә истә калмаган, әмма берсе, иң куркытканы, хәтердә әле булса саклана. Бу — рәсем буенча иде. ягъни рәсем ясап күрсәтергә тиеш идек без... Ә миндә рәсем ясауга бер дә сәләт юк, булса да бик зәгыйфь... Бала чакта кеше башы белән песи башын (болар бер-берсенә бик охшаганнар) алама гына сызгалап маташуны исәпләмәгәндә, мин рәсем ясау белән юньләп шөгыльләнмәдем дә һәм чынлап мавыкмадым да... Ләкин шунда ук сездә: «Алайса, ни пычагыма монда килеп кердең?» — дигән сорау үзеннән-үзе туа торгандыр бит инде. Нәрсә дип әйтим?. Махсус уку йорты булгач, рәсем ясарга да өйрәтерләр әле дип ышанганмындыр ахрысы. Әмма мине барысыннан элек уку йортының исеме, дәрәҗәсе, сәнгать белән бәйләнгән булуы тартып китерде бугай... Аннары, керә алсам, архитекторлыкка укырмын дип тә уйлаган идем. Тик менә архитекторның да рәсем ясый алырга тиешлеген белми идем. Хәзер инде чигенеп булмый, егетләр!.. Ни булса шул, тәвәккәлләргә туры килә.

...Иркен генә бүлмә, төрлечәрәк куелган мольбертлар, биек кенә өстәл сыман нәрсәдә гипстан эшләнгән адәм башы. Безгә бераәр табак каты-калын кәгазь, йомшак кара карандашлар бирделәр. Кәгазьне кнопкалар белән мольбертка беркетергә куштылар. Ярый, монысын да эшләдек... Инде хәзер әнә шул ходай орган адәм башын ак кәгазьгә төшерергә тиешбез. Егетләр кыю гына эшкә дә керештеләр. Ә мин торам әле, күршеләремә караштырам: ничегрәк сызалар? Шуннан мин дә бик сак кына сыза башладым... Иллә мәгәр шәп төшми, дөрес төшми сызыкларым!.. Бозам да тагын сызам... Ярый әле, безнең эшләгәнне карап йөрүче рәссам бик рәхимле кеше булып чыкты, бер-ике мәртәбә яныма килеп, карап, менә болайрак кирәк дип, минем эшне үз кулы белән төзәткәләп тә китте. Башкаларга да әнә шулай күрсәткәләде ул. Күрәсең, зәгыйфьләр бер мин генә түгел. Бу исә минем хәлне бераз гына җиңеләйткән кебек тә булды.

Кыскасы, без барыбыз да — кайсыбыз алданрак, кайсыбыз соңрак — бу адәм башын тирләп-пешеп булса да төшереп бетердек. Безгә әле ошап та китте бу азаплану — яхшымы-начармы, ак кәгазьдә үзебез ясаган сурәт калды. Рәссам булырга теләүнең сере дә бәлки шул сурәт ясау белән сихерләнүдәдер?!

Имтиханнар бетте, хәзер инде нәтиҗәне көтәргә кирәк иде. Минем үтә алуыма өмитем аз, ә менә Фәтхелислам һичшиксез үтәчәк. Бөтен имтиханнарны да шәп бирде, хәтта рәсем буенча да... Сәләте дә зуррак, хәзерлеге дә көчлерәк иде шул аның!

Күпмедер борчылып, көтеп йөргәннән соң, ниһаять, укырга алынучыларның исемлеге чыкты. Барыбыз да шуңа ябырылдык. Иң беренче исем — Мортаза Абдуллин. Гаҗәп түгел, ул рәссам булачак егет. Бераз түбәнрәк минем фамилия дә тора, шайтан алгыры! Бу мин, әлбәттә, чөнки бүтән «Еникеев» юк керүчеләр арасында... Я, хода!.. Мин алынганмын, мин укыячакмын, мин — студент, мәтәлеп китим!.. Их-ма!.. Арада Фәтхелислам да бар, Фәтхелислам да алынган, ләкин ул тыныч, ул алынасын алдан ук белеп торды... Әмма бу безнең икебез өчен дә бик зур бәйрәм!.. Әле бит бер ай элек кенә Дәүләкәннең тузанлы урамын таптап йөргәндә Казан нинди ерак иде бездән, ә бирегә килеп, рәссамнар мәктәбенә укырга керә алу тагы да ераграк иде — инде менә тәвәккәлләгәч, шөйлә генә булды да куйды, мин сиңа әйтим!

* * *

Болай ансат кына үтүебезнең сәбәбе нәрсәдә дип уйласак, моны татар яшьләренә укырга керү шартларының җиңеләйтелгән булуы дип аңларга да ярый торгандыр. Чынлап та, яңарак кына автономия алган милли республиканың һәр тармактан кадрлар җитештерү өчен уку йортларының ишекләрен киңенчә ачып куюы бик табигый иде. Нәкъ шушы елларда инде татар яшьләренең төрле яктан Казанга агылып килүе дә башланды.

Менә без дә, ике Дәүләкән егете, махсус уку йортының — рәссамчылык, һәйкәлтараш, гыймарәт мастерскойларының (Архумасның) студентлары булдык.

Безнең язмышыбызда моның нинди әһәмияткә ия булуын аңлап беттек микән әле без шул чакта, әллә ул хакта уйлап та тормадык микән?.. Юк, уйлаганбыздыр, һичшиксез, уйлаганбыздыр — бу бит безнең киләчәгебез, ә киләчәк турында уйламыйча торып буламыни?! Ләкин безне шунда ук башка уйлар, башка мәшәкатьләр биләп алган иде инде. Без тизрәк Әбүбәкер абзыйлардан китәргә һәм башка студентлар белән бергә кайдадыр тора башларга тиеш идек. Ул елларда Казанда студентлар өчен торак йортлар аз иде. Күп кенә хәллерәк студентлар хосуси йортларда бүлмә яки почмак алып торалар иде. Архумасның торагы бармы-юкмы икәнен без әле белми дә идек. Ләкин имтиханнар бетеп, кабул ителгән студентлар үзләренә торыр урын сорый башлагач, безнең барыбызны кемгәдер иртәгә, бер йортка җибәрделәр. Бу ике катлы, ал төскә буялган кирпеч йорт хәзерге Ирек мәйданы артында, Касаткин белән Бассейнный урамнары чатында иде (соңгы елларда гына, Обкомның икенче бинасы салынгач, андагы йортларны рәте белән сүттеләр). Ниндидер байдан калган чибәр генә йортның икенче катына барып кердек. Бишме-алтымы тәрәзәсе урамга караган, шар тәгәрәтерлек шыр ялангач бер зур зал иде бу... «Менә шушында урнашыгыз»,— диде иртәге килүче безгә. Без күп түгел идек, уникеләп кенә кеше, барыбызга да урын җитәрлек иде.

Шул ук көнне без, Фәтхелислам белән икәү, берничә атна буена безгә жылы урын биргән Әбүбәкер абзыйлардан, һәммәсенә дә рәхмәтебезне әйтеп, шушы шәрә залга күчеп тә килдек. Берәм-берәм башка егетләр дә капчыккәрзиннәрен күтәреп килеп җиттеләр. Ләкин безгә уку йортыннан берниндн урын-җир нәрсәсе бирмәделәр. Карават та юк, матрас та, одеал да юк,— үзегез табыгыз, диделәр. Әйтергә кирәк, безнең Архумас укучыларын тәэмин итү ягыннан бик хәерче булып чыкты. Без моны бик тиз татый башладык... Ә хәзер исә һәркем үзенә яту урыны әмәлләргә керешге. Ул чакта Бассейнный урамында кечкенә базар бар иде (аны яһүдләр базары дип тә йөртәләр иде шикелле). Шунда ук тагын бер ташландык бакча да бар. Безнең егетләр менә шул базардан төнлә белән бер-ике буш әрҗә күтәреп яки бакча рәшәткәсен каерып алып кайтып үзләренә топчан кебек нәрсә әмәлләделәр. Фәтхелислам белән без дә каяндыр зур гына бер ишек күтәреп кайттык. Ике кузла ясап, шуның өстенә ишекне салдык... Менә икебезгә бер «карават» та булды. Таррак инде, ләкин жылырак булыр дидек. Соңыннан шул ук базардан ике капчык «табып», аларны сүтеп, яңадан икесен бер итеп һәм шуңа әйбәт кенә печән-салам тутырып, матраслы да булдык. Шулай итеп, һәркем үзе белгәнчә һәм тапканча әкренләп үзенә ятар урын әзерләде. Тик Самар егете Гата Юсупов кына әрҗә урлап, топчан ясап тормады, каяндыр тапкан озын капчыкка салам тутырды да, шуны стена буена сузып салып, өстенә менеп ятты. «Бердән, иркен, икенчедән, ишелеп төшү куркынычы юк»,— диде ул... Гаҗәп ваемсыз егет иде бу Самар мишәре... Ә менә икенче бер иптәшебез байларча дип әйтерлек урнашты. Бу Ырынбурдан килгән Рәхмәтуллин фамилияле, барыбыздан да яшькә шактый олы бер абзый иде. Ул инде хатынлы да, бала-чагалы да кеше икән, ләкин шуңа да карамастан, аның укып, рәссам буласы килгән. Күрәсең, үзендә ниндидер оетка барлыгын сизгәндер инде. Өеннән дә ул нык хәзерләнеп чыккан — кием-салымы да бик бөтен, өстәвенә мамык мендәре белән кызыл тышлы сырган юрганы да бар иде. Каяндыр тимер карават та табып китерде. Урынның да әйбәтен сайлап алды. Кыскасы, төпле урнашты бу абзый!..

Әмма без үзебезгә ничек кирәк шулай урын хәстәрләсәк тә, зур залыбызның житешмәгән җирләре бик күп иде әле. Бер урындык заты юк, бөтенебезгә бер өстәл юк, су алып керергә чиләгебез юк — әлхасил, юктан башка берни дә юк!.. Бигрәк тә нык борчыганы — залыбызны яктырту белән жылыту мәсьәләсе иде. Көннәр бит һаман кыскара, әкренләп суыкларга таба бара. Заманында нәрсә белән яктыртылгандыр инде бу зал, хода белсен, хәзер исә түшәм уртасында калкытып эшләнгән түгәрәк эченнән таза тимер ыргак кына тырпаеп тора (хуҗалар вакытында аңа зур якты лампа эленгән булгандыр, мөгаен). Димәк, гади генә булса да «кәрәчин» лампасы табарга кирәк. Залның бер почмагында, зур голанка миченең биек аркасы чыгып тора. Авызы баскычка чыга торган алгы бүлмәдә... Рәхмәтуллин абзый мичне җентекләп карагач, бу, егетләр, безгә ярый торган мич түгел диде. Моны жылытыр өчен көн дә ярты йөк утын кирәк булачак имеш... Хуш, ә нишләргә соң?.. Зал уртасына бәләкәй генә бер мич салмыйча булмас ахрысы диде Рәхмәтуллин абзый, бераз башын кашып торгач. Ә материалын кайдан табарга: кирпеч, балчык, комын?.. Әмма, чынлап еласаң, сукыр күздән яшь чыга дип, белмичә әйтмәгәннәр икән. Эзләнәйөри торгач, барысы да табылды ахырда... Кирпечне, мәсәлән, Архумасның үзеннән табып китердек.

Мичне Рәхмәтуллин абзый үзе салырга булды. Калагын да, чүкечен дә каяндыр тапкан... Киндер алъяпкычын бәйләде, җиңен сызганды һәм эшкә дә

тотынды. Без аңа измә ясап, кирпеч биреп тордык, ә ул зал уртасына бәләкәй мичне җыйнак кына иттереп, ике көндә салып та куйды. Өстенә карап кына торырлык. «Болай ук кирәкмәс иде!» — дигән була хәйләкәр абзый үзе дә.

Хәзер безнең мичне теге зур мичкә илтеп тоташтыру өчен калай торбалар табу мәсьәләсе алдыбызга килеп басты. Искергәннәр ярамый, таза булырга тиешләр. Ләкин бит торбалар җирдә аунап ятмыйлар, кайдан аларны табарга?.. Хәер, унике кеше эзләргә тотынгач, табыла икән анысы да... Берничә көннән егетләр табып китергән торбаларны Рәхмәтуллин абзый бер-берсенә ялгап, әлеге зур мичнең аркасына илтеп кертте. Аннары бисмилласын әйтеп, ягып та карады. Бәләкәй мичебез күңелле генә гөрләп яна да башлады. Ни әйтәсең оста кешенең эшенә?! Димәк, җылы булачак. Шулай итеп, гаять мөһим бер мәсьәләбез хәл ителде. Икенче бик мөһиме — утын мәсьәләсе иде. Утынны безгә беркайдан да бирмәячәкләр иде. Без аны бары үзебез табарга тиеш идек. Һәм без һәркайсыбыз барган-йөргән җиребездән ягарга ярарлык бөтен нәрсәне күтәреп кайта торган булдык. Бигрәк тә каршыбызда гына базар булуы безнең хәлне күпмедер дәрәҗәдә җиңеләйтте... Әнә шулай торып киттек без байлардан калган таш йортның зур залында!

Без унике кеше идек дидем мин... Кемнәр иде алар? Уникегә туламы? Алтмыш елдан соң берәмләп искә төшерүе дә бик читен. Һәрхәлдә, күпчелек татарлар иде.

Арабызда яшькә олырак тагын берәү — бу Мәсәгутов фамилияле Әстерхан егете. Исеме Зиннур иде бугай — шулайрак истә калган... Бик чибәр егет иде ул. Уртадан калкурак бик төз буйлы, ак чәһрәле, коңгырт чәчле, озын керфекле — аның бу матурлыгында әз генә Христоска охшашлык та бар иде кебек... Тик менә хәрәкәткә сүлпән, сүзгә саран, беркемдә дә эше юк, бары үзен генә белә — шулайрак тоелды ул безгә баштарак. Хәер, без аны сирәк күрә идек, чөнки иртә тора да каядыр китә, кич кенә кайтып топчанына сузылып ята торган иде. (Мич киртләчендәге калай лампаның яктысы бик зәгыйфь, зал ярымкараңгы, укып яки язып утырырлык түгел иде). Ләкин тора-бара бу егет безгә күп яклары белән ачылды. Иң элек шуны белдек — ул Татар коммунистлар университетында (мәшһүр ТКУда) даими художник булып эшли икән. Плакатлар, лозунглар яза, стена газетасы чыгара, көне дә, ашау-эчүе дә шунда үтә. Мохтаҗлыкны белми диярлек. Әмма болардан да бигрәк, безнең матур егетебез, хәзергечә әйтсәк, күпкырлы талант иясе дә булып чыкты. Рәссамчылыктан башка тагын шигырь-поэмалар да яза, скрипкада да чибәр генә уйный, шуның өстенә ул бик оста сөйләүче дә икән әле. Әстерхан тормышын, татарларның ничек яшәүләрен, балык, җиләк-җимеш байлыкларын, аннары шуларга ялгап, даладагы бакчаларда карбыз саклап ятканда марҗа кызларының аңа сагыз булуларын, этисенең «малайны харап итәләр бит» дип һаман борчылуын бик кызык итеп кичләрен безгә сөйли торган иде. Тәрәзәләр зур, лампа зәгыйфь, бөтен әйләнәдә су эчен хәтерләткән серле ярымкараңгылык — шунлыктанмыдыр аның әкиятләрен күпме генә тыңласаң да ялыктырмый иде. Кыскасы, без Мәсәгутовны яраттык. Ачык, гади, ягымлы, өстенлекләре белән масая да белми...

Ләкин унике кешенең һәркайсы турында болай язып китсәм, артык озынга сузылыр дип куркам. Тизрәк уртак мәсьәләләргә күчәсе килә... Тик шулай да бер егет — Мортаза Абдуллин турында кыска гына әйтеп китмичә булмас ахыры... Без — якташлар — яшьләребез дә бер чама, билгеле, без тиз якынайдык. Дөрес, баштa талаштык, сугыша да яздык (ул минем язып маташуымнан көлгән иде), ләкин барыбер дуслашып киттек. Һәм бу дуслык бервакытта да өзелмәде. Архумаска бергә кергән егетләрнең бөтенесен дә диярлек мин әкренләп югалтып бетердем, тик ике кеше — Фәтхелислам белән Мортаза белән генә якын бәйләнеш аларның соңгы гомерләренә чаклы дәвам итте.

Архумасны (соңыннан техникумны) тәмамлаучылардан бары Мортаза гына Ленинградтагы Художество академиясенә укырга киткән иде. Шунда дүрт ел укып кайткач, ул Татар академия театрында әүвәл художник-декоратор, аннары баш художник булып эшләде. Менә шул чакларда без аның белән тагы да ныграк дуслашып киттек. Мортаза, ничек дим, кабатланмас кеше иде. Кыяфәте үк башка, сәнгать әһеле икәнен әллә кайдан ук күрсәтеп тора: бик матур тарап куйган чем-кара бөдрә чәч, куе кара кашлар, ә йөзе кершән яккандай ап-ак! Үзен ул зәвыклы ханымнар шикелле карый иде, бик көяз иде, иң соңгы мода белән бик пөхтә киенергә ярата иде. Шуның өстенә Мортаза гаять үзсүзле, бик принципиаль бер кеше дә иде. Аңа җайлашуы җиңел түгел... Шул кискен характеры аркасында еш кына кешеләр белән бозылыша да торган иде. Әмма эчкерле түгел, ачу сакламый, яңадан берни булмагандай дуслыкны яңартырга әзер... Асылда ул нечкә-йомшак күңелле иде — аның шулай икәнен миңа күп күрергә туры килде. Малай чагыннан ук уйнарга өйрәнгән скрипкасын ул бер вакытта да үзеннән калдырмады. Әйтергә кирәк, татар көйләрен Мәсәгутовка караганда нечкәрәк тоеп, дөресрәк, үтемлерәк итеп уйный торган иде.

Сугыш алдыннан Мортаза, ни өчендер Казанны ташлап, Мәскәүгә китте (мин дә бу вакытта читтә идем). Сугыш башланып, армиягә алынгач, ул Фрунзе академиясендә художник булып эшләде. 1943 елның көзендә, кыска гына вакытка фронттан Казанга кайтышлый, без Мәскәүдә очраштык. Төне буе аның бүлмәсендә, каяндыр тапкан «күчтәнәч»ен әз-әзләп кенә эчеп һәм салкын бәрәңге, әче суган капкалап, керфек тә какмыйча сөйләшеп чыктык. Бу безнең иң соңгы очрашуыбыз булды... Художник Мортаза Абдуллин 1945 елның, ялгышмасам, көзендә саркомадан үлеп китте — бары утыз биш яшендә!

...Ә хәзер яңадан үлемнең нәрсә икәнен дә белмәгән тап-таза, ябь-яшь чакларыбызга кайтыйк әле. Караңгылы-яктылы залыбызда шаулап ятабыз, дәрт-теләк, уен-көлке хәттин ашкан, әмма... Әмма ләкин хәлләребез дөресен генә әйткәндә, шәптән түгел иде. Менә инде сентябрь үтеп бара, ә безгә әле булса стипендия биргәннәре юк. Бик кысып кына тоткан акчаларыбыз чыгып бетте диярлек... Ашау яклары бик хөртиләнде. Жылы ашны атналар буенча күрмибез, бөтен ашаганыбыз пеклованный икмәк белән көйгән касмаклы кайнаткан сөт... Икмәкне чаттагы яһүд кибетеннән, ә сөтне йорт каршында гына сатып утырган маржалардан алабыз. Күпме ашасаң да биздерми торган тәмле, туклыклы ризык... Ара-тирә мич авызында гына чәй кайнатып эчәбез.

Лекцияләргә йөргән булабыз, мастерскойга барган булабыз, ләкин ачлы-туклы хәлдә укып маташуның бер дә кызыгы юк иде. Аптыргач, эш эзли башладык. Берәүләр каядыр йөк бушатырга китәләр, буявы, пумаласы булганнар вывеска-мазар язу кебек эш табалар, кыскасы, берәү дә тик ятмый, тамак кайгысы һәркемнең дә башына төшкән иде. Арада иң тук яшәгән безнең Рәхмәтуллин абзыебыз да Архумасның үзендә үк бер зур мичне сүтеп салу турында сөйләшеп кайткан иде (оста кешегә эш аяк астыннан да табыла икән). Үзенә ярдәмчеләр итеп ул Фәтхелислам белән мине алды. Атнадан артык без шул пычрак эшкә йөрдек. Башта сүтелгән мичнең ватыгын носилка белән ташый-ташый, аннары зур ялгашта көрәк белән бутап, измә ясый-ясый, куллар кабарып бетте. Минем мондый авыр эшкә беркайчан да җигелгәнем юк иде әле. Акчасы күпме генә булгандыр инде, әмма тәмам ватылып, тузан-пычракка батып эшләү бик туйдырды мине...

Стипендия мәсьәләсендә берничә тапкыр кәнсәләриягә кереп, сөйләшеп тә карадык. Эш бездән тормый, Наркомпростан тора, ул һаман суза бу мәсьәләне диделәр безгә. Шуннан соң бер кечне җыелышкач, укучылар исеменнән Наркомпроска вәкил җибәрергә кирәк, дигән фикергә килдек. Ләкин кемне? Берәүнең дә ни өчендер барасы килми. Рәхмәтуллин абзыйны, син олы кеше дип, кыстап карыйбыз, юк, якын да килми — янәсе, ул нәчәлниклар алдына барып, соранып йөрергә яратмый (тамагы тук, шуңа күрә яратмый торгандыр). Ахырда Мамлеев дигән берәүне кыстый башладык. Дөрес, ул безнең зиннәтле залыбызда тормый, килеп-китеп кенә йөри, ләкин шома егет, русчасы да шәп, кыяфәт тә шәһәрчә — башында эшләпә, өстендә киң путалы сары пальто. Риза булды, тик иптәшкә кеше сорады: — «Ату бер үземә генә скучно!» — диде... Шуннан иптәшләр миңа ябыштылар: Давай да давай, син җиңел сөякле, син йөрергә иренмисең имеш... Минем чынлап та җәмәгать эшләре белән йөрүдән тәм таба торган чагым иде — артык кыстатмыйча, теләп диярлек риза да булдым.

Мамлеев белән без Наркомпроска ике тапкыр бардык. Наркомның үзенә үк, билгеле, керә алмадык. Ләкин шулай да, коридорда күпмедер таптанганнан соң, зуррак кешеләрнең берсенә кереп, авыр хәлебезне сөйләдек. Зур абзый безне тыңлады тыңлавын, әмма сүзен бик кыска тотты: «Юкка килеп йөргәнсез, егетләр, мөдирегез барысын да белә, кайтыгыз да аңардан сорагыз, ул аңлатыр»,— диде. Әлбәттә, мондый киңәш белән кайтып, иптәшләрне тынычландырып булмаячак иде, шуңа күрә без икенче көнне үк Кремль тарафларына юл тоттык. Һәм бу юлы инде туп-туры Наркомпросның бухгалтериясенә барып кердек. Хәлебезнең никадәр авыр булуын сөйләп биргәч, андагы баш кеше безгә кыскача гына аңлатты: «Стипендия мәсьәләсе карала, тикшерелә, хәл ителергә тора, көтегез, тиздән алырсыз», — диде... Волокита дигән нәрсә ул заманда ук шактый тамыр җибәреп өлгергән иде инде, шулай да карала, тикшерелә, тиздән алырсыз дигән сүзләр безне беркадәр тынычландырды. Торактагы көтеп ятучылар янына кайткач та без аларны шул ук өметле сүзләр белән куандырырга тырыштык.

Тагын күпмедер көткәннән соң, ниһаять, стипендия мәсьәләсе хәл ителде. Тиздән исемлек игълан ителәчәк диделәр безгә... Анысын гына көтәргә була... Һәм, берничә көн үтүгә, ул исемлекне дә чыгарып элделәр. Барыбыз да шуңа ябырылдык. Озак зарыгып көтүдәндер инде, берәү дә стипендиясез калу ихтималын, билгеле, күңеленә дә китерми иде. Әмма... бу ни хәл? — исемлектә бары минем генә фамилиям юк... Кат-кат исемлек буйлап карап төшәм — юк кына бит!.. Тәмам аптырадым, бер читкәрәк киттем, ни уйларга да белмим. Әллә ялгыш төшереп калдырдылар микән?!. Кәнсәләриягә кереп, әдәп белән

гена ни өчен исемлектә минем фамилиям юк икән дип сорадым. Һәм миңа әйттеләр: комиссия сезгә, хәлле кешенең баласы булганга күрә, стипендия бирүне кирәк дип тапмады, диделәр... Менә шул... Ә уку?.. Укырга хакыгыз бар, ләкин стипендиясез генә.

Моны ишетеп чыгу миңа бик авыр булды. Минем җылыйсым килде, ә бәлки җылаганмындыр да, хәзер инде искә төшерүе дә бик читен... Хикмәт монда бер мине мәхрүм итүдә генә түгел иде — стипендиясез калу минем хәлемне бик нык читенләштерәчәк тә иде. Укуны, ихтимал, ташларга да туры килер, чөнки өйдән мин ай саен акчалата ярдәм көтә алмый идем. Өйдәге хәл миңа ачык: атакай сәүдәсен ташлады, әйтергә кирәк, бөлеп туктады, шуңа күрә дә тимер чыбыктан элгечләр, таба аслары үрергә тотынды. Я, мондый хәлдә мин өйдән нинди генә ярдәм көтә алам?.. Юк, булмас, ышаныч бик аз... Әйе, төште башка авыр хәсрәт...

Көне-сәгате белән аңлап җиткермәсәм дә, бу минем социаль чыгышым аркасында күргән беренче бәхетсезлегем иде, өмитләремнең беренче мәртәбә какшавы иде...

Егетләр беренче стипендияләрен алып кайттылар. Торакта бүген бәйрәм. Әмма ләкин эчү юк, бары тик ашау гына (эчәргә акча әрәм итүдән бигрәк, аның «тәмен» белгән-татыган кеше дә юк). Иң мөһиме — туйганчы бер ашап калу һәм төрлесеннән авыз итү... Ак калач, ак май, каймак, хәлвә, ат казылыгы — моңарчы бик сирәк эләгә торган әнә шундый ризыклар... Әлбәттә, болай сыйлану бары бер генә тапкыр, чөнки бу стипендиянең һәр тиене исәптә (ялгышмасам, ул аена 9 сум иде шикелле). Ә студент, ач утырасы килмәсә, исәпли белергә тиеш.

Фәтхелислам да үзенең кадерле стипендиясен алып кайтты. Моңарчы безнең бөтен нәрсәбез, өстәге киемнән башкасы, һәрвакытта уртак булды. Бергә таптык, бер табактан ашадык. Хәзер дә ул шулай булып калды. Ләкин күпмегә кадәр?.. Һәрхәлдә, бер стипендиягә икәү яшәп булмаячак. Моны икебез дә беләбез, тик Фәтхелислам бу хакта бер сүз дә әйтми, димәк, минем үземә үз хәлем турында чынлап уйларга кирәк булачак.

* * *

Тукай урамы белән Париж коммунасы чатында таштан салган ике катлы зур гына күк йорт тора. Кайчандыр ул «Бәрадәрән Кәримовлар» матбагасы булган диләр, ә хәзер ниндидер төзү фабрикасының бер цехы бугай. Каршы чатта Галимҗан Баруди мәчете, аның күршесендә генә элекке «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең кирпеч биналары... Хәер, мин боларны соңыннан гына белдем. Ә менә чаттагы күк йорт белән тиз танышырга туры килде. Әллә ишетеп, әллә йөргәндә туры килеп, шул йортта китапханә барлыгын белдем. Билгеле инде, мин аңа кермичә уза алмадым. Һәм вакыт тапкан саен баргалап йөри дә башладым. «Шәрык» китапханәсе дип атала иде ул... Көзге кыска көннәр, озын күңелсез кичләр, барыр җир юк, эч поша, торак салкын һәм караңгы — менә мин якты эзләгәндәй шул китапханәгә барып, аның икенче катындагы тыгызрак, әмма бик тыныч, җылы залында утырырга ярата идем. Миңа калса, бу китапханә бик бай иде, бөтен иске һәм яңа әдәбият бар иде, революциягә хәтле чыккан барлык газета-журналлар анда саклана иде. Нәрсә генә сорасаң да, бирәләр — ярамый, тыелган дип әйтү юк иде. Яңа килгән газеталарны карап чыккач, мин әнә шул иске журналларны ала торган идем. Бигрәк тә «Аң»ны карарга ярата идем. Яхшы кәгазьгә бик ачык басылган, рәсемнәре дә ачык төшкән — укырга кызыклы, күңелле, җиңел иде. Гарәп хәрефләре өйрәнү өчен бәлки авыр булгандыр, әмма бер өйрәнгәч, үзеннән-үзе гаҗәп тиз укыла иде. Укый идек барсын да — искесен дә, яңасын да.

Китапханәгә йөрүчеләр әллә ни күп түгел иде. Берничә бабай, берничә кыз, тагын минем кебек яшьләр... Шушы соңгылар арасында мин барган саен бер егетне күрә идем. Ул да даими йөрүче, шулай ук иске гәзит-журналларны актарырга ярата. Ихтимал, шуңа күрәдер, минем игътибарымны җәлеп итте бу егет... Миннән берничә яшькә олырак булыр, таза-төз гәүдәле, озынчарак зур битле, күз кабаклары төшебрәк тора, кыскасы, матур түгел, әмма чын ирләргә генә хас ниндидер бер тарта торган көч бер үзендә... Очрашып, бер-беребезне күргәләп йөри торгач, без ахырда танышып киттек. Рабфак студенты икән, фамилиясе Ярмиев икән (исемен ни өчендер әйтмәде). Беренче сөйләшүләрдән үк аның татар әдәбиятын — искесен дә, яңасын да бик яхшы белүе ачыкланды. Гомумән генә түгел, җентекләп белә: кем кайчан нәрсә язган, кем-кемне тәнкыйтьләгән яки кем-кем белән бәхәсләшкән, кыскасы, күп нәрсәдән хәбәрдар булып чыкты. Бу хәл мине аңа бик тиз якынайтты, ешрак күрәсе килә башлады, ә аның белән сөйләшүе ничектер бер күңел ихтыяҗына әйләнде. Әнә шулай

очрашып, сөйләшеп йөри торгач, без ансат кына дуслашып та киттек. Бу 1925 елның шыксыз көзендә булды. Менә шуннан бирле бу дуслыкның өзелгәне юк. Алтмыш ел гомер... Яшь-яшь егетләр идек, инде карт бабайлар булдык. Шушы озын гомер эчендә без бары сугыш вакытында гына бер-беребезне күздән югалтып тордык. Сугыш беткәч тә, янә табыштык. Ләкин арабыз ерак, ул Ташкентта, мин Казанда. Әмма бу нәрсә безнең дуслыкны һич кенә дә киметмәде, киресенчә әле саф итеп, нык итеп саклады. Мин Ташкентка барсам, аны күрер өчен барам, ул Казанга кайтса, иң элек мине күрер өчен кайта.

Кем соң ул минем шундый озын гомерле дустым? Таныш булыгыз — Габдерәхим Каюм улы Ярмиев, элекке Зөя өязе, Олы Урсак авылында 1906 елны туган. Казанда Госрабфакны бетерә, Иваново шәһәрендә энергетика институтын тәмамлый. Инженер-электромеханик. Казанның яңа электростанциясендә 4—5 ел эшләгәч, Ташкентка күчеп китә. 1941 елдан партия әгъзасы. Тирән белемле, киң эрудицияле, шуның белән бергә, бик гади, утә гадел, намуслы кеше. Тик, кызганыч, бөтен гомерен ул өйләнмичә, ялгыз буйдак булып уздырды. Болай «утырып» калуының сәбәбе, әйтүенә караганда, чынлап торып ярата алырлык хатын очрата алмаган... Менә сиңа характер, әйтсәм әйтим! Картайгач та күнегеп беткән шул ялгызлыгыннан котылырга теләмәде. Бу хакта бәхәсләшеп киткән чакларыбыз да булгалады. Әлбәттә, мәхәббәтнең зарурлыгын мин дә инкарь итмим, ләкин картлыкның да үз таләпләре бар бит әле... Картлык өчен иң хәтәре — ялгызлык!

«Вөждан» дигән әсәремне язганда, төп геройның прототибы итеп беркадәр аны, Рәхим дусны күздә тоткан идем. Чөнки минем героем Ташкентта яшәүче ялгызак кеше булырга тиеш иде. Аннары алдауны, хыянәтне без икебез дә бер үк дәрәҗәдә яратмыйбыз.

...Теге чакта «Шәрык» китапханәсендә бары ике кеше эшли иде. Берсе аның, олырагы — озын гына буйлы чандыр кеше — китапханә мөдире. Икенчесе — тәбәнәгрәк буйлы, түгәрәк битле, зур соры күзле егет — китаплар биреп торучы. Баштарак мин аларның исем-фамилияләрен дә белмәдем, ләкин алар мине, еш килеп йөргәнгә күрәдер инде, танныйлар иде бугай. Чөнки көннәрдән бер көнне әнә шул китап биреп торучы үзе минем белән сүз башлады.

Әйтергә кирәк, минем хәлләр шәптән түгел иде. Матди ягым бик начарланды. Өйгә язып карадым. Аннан күпмедер акча килде, ләкин бу юлга дип җибәрелгән акча иде. Хатларында бик үтенеп, миңа кайтырга кушканнар: «Өйгә кайтуның ояты юк, кайт, балам, насыйп булса, киләсе елда тагын барырсың»,— дигәннәр. Әмма минем Дәүләкәнгә һич тә кайтасым килми, ничек кенә юатмасыннар, оят бу... Андагы иптәш малайларга кайтуның сәбәбен ничек аңлатырга? Дөресен әйтергә көчем җитмәячәк, алдашырга телем бармаячак. Аннары малай халкы ышанмаячак та.

...Бик аптыраган көннәрдә Әбүбәкер абзыйларга да кереп чыга идем. Ник кергәнемне юньләп аңлата да алмыйм, дөресен генә сөйләргә көчем дә җитми, ләкин алар, өстемә карап дигәндәй, хәлемне аңлыйлар иде шикелле. Миһербанлы асрау апа шунда ук мине кухняга алып кереп, ашарга утырта, ә Әминә апа чыгып киткән чагымда: «Йә, укулар ничек бара соң?» — дип, юри сынагандай сораган була, мин исә башымны читкә борып кына: «Ярый, хәзергә әйбәт кенә бара»,— дигән булам. Шуннан ул башта ук учында тоткан берничә көмешне миңа тоттырып җибәрә иде. «Рәхмәт»,— ди идем мин көчкә генә, ә баскычларыннан төшкән чакта яшьләремне тыя алмый идем.

...Юк, ярамый болай, оят болай... Каңгырып йөрүне ничек тә бетерергә кирәк. Бердәнбер чара — тотарга да эшкә керергә! Башкача булмый, башкача мөмкин түгел. Уку кала икән — калсын (барыбер миннән рәссам чыкмас инде), җәйгә чаклы эшләрмен дә башка берәр уку йортына керергә тырышырмын. Әле вакыт узмаган, солдаттан кайтып та укыйлар хәзер.

Ниһаять, әнә шул карарга килдем мин һәм шул максат белән берничә мәртәбә хезмәт биржасына да бардым. Хәзерге укучыга, бәлки, сәер дә тоелыр, ул елларда Казанда эшсезләр күп иде. Алар өчен хезмәт биржасы дигән нәрсә дә бар иде. Аның урнашкан җире Некрасов урамы чатыннан аз гына югарырак, хәзерге Куйбышев урамындагы өч катлы таш йортта иде. Эшсезләр һәр көнне иртән менә шул йорт каршына җыела торганнар иде. Тәгаен бер сәгатьтә биржадан кулына кәгазь тоткан кеше чыга да, кай җиргә нинди эшчеләр кирәклеген кычкырып әйтергә тотына. Һөнәре туры килгәннәр шунда ук кулын күтәреп, башкаларны этә-төртә, тизрәк дәшүче янына барып басалар. Ләкин моның ише «бәхетлеләр» аз була иде — йөзләгән кешедән бер ун-унбишләп кенә... Биржа кешесе кулындагы кәгазен укып бетергәч, үзенә яраклы эш-урын чыкмаганнар сүлпән генә тарала... Һәркөнне иртәнге якта шушы хәл кабатлана. Эш көтүчеләрнең күбесе дәү агайлар, минем кебек «мыексызларга» таләп бөтенләй юк диярлек. Барган саен, мин аннан бик өметсезләнеп кайта идем.

Әнә шулай бик аптырап йөргән чагымда, әлеге китап биреп торучы абый үзе минем белән иплән кенә сүз башлады. Кайдан килүемне, кем булуымны сорашырга тотынды. Ул ахрысы минем авыр хәлемне чамалагандыр... Шуңа күрә мин аңа, үзе башлап кызыксынгач, барысын да яшермичә сөйләдем дә бирдем... «Инде ни эшләргә уйлыйсың?» — дип сорады ул миннән. Эшкә керергә теләвемне, көн дә эш эзләвемне әйттем мин аңа... Хәзер инде тагаен генә искә төшерүе дә читен — әллә шул ук көнне, әллә икенче килүемдә бу абый мине теге өлкәнрәк абзый янына алып керде дә, кыскача гына нинди хәлдә калуымны аңлатып, егеткә ничектер ярдәм итәргә кирәк иде бит диде. Шуннан алар тагын бераз үзара сөйләшкәч, өлкән абзый миңа сынабрак карап, исем-фамилиямне сораганнан соң кулыма записка язып бирде. «Энем,— диде ул, бик ачык итеп,— менә бу записканы Проломный урамындагы китап магазиның мөдире иптәш Рәҗәповка илтеп тапшыр. Магазинның кайда икәнен беләсеңме?.. Белсәң, сыздыр... Рәҗәпов абзаң сиңа бәлки берәр эш табар».

Мин чын ихластан рәхмәтемне әйтеп, тизрәк урамга ашыктым. Ләкин вакыт соң иде инде, кибетләр ябылган, караңгы торакка гына кайтырга туры килде. Нинди өмитләр белән кайтуымны берәүгә дә сиздермәдем, хәтта Фәтхелисламга да. Булып бетмәгән эш турында алдан кычкырудан мин инде саклана башлаган идем... Төне буе адашып йөрүләр белән бәйләнгән буталчык төшләр күрә-күрә үткәргән начар йокыдан соң, иртә генә торып, бозлы су белән битне чылаттым да канатлар үскәндәй магазинга йөгердем. Билгеле, ашыкканмын, магазин тирәсендә әле бер җан иясе юк, аның ачылганын урам таптый-таптый көтеп алырга туры килде.

Хәзерге китап магазины белән бутамас өчен әйтергә кирәк: ул чактагы китап кибете Проломный (Бауман) белән Лобачевский урамнары чатындагы таш йортның беренче катында иде. Барлык йортларның аскы катлары шикелле үк, бу да ниндидер купецлардан калган кибет булырга тиеш — эче тулы шүрлек, тәрәзәләре тоташ пыяла. Күптәннән инде монда беренче номерлы гастроном, ләкин аның китап кибете булган чакларын белүчеләр бардыр әле. Утызынчы елларның башларына чаклы яшәде ул. Ә урам аша чатта (хәзерге Татар ашлары йорты урынында) канцелярия һәм уку әсбаплары белән сату итә торган икенче бер кечерәк кибет бар иде.

Аның эченә кергәч, сатучыларның берсе миңа Рәҗәповны күрсәтте. Янына бардым, исәнләштем, записканы бирдем... Һәм карап торам, көтеп кенә түгел, беркадәр гаҗәпләнеп тә, сокланып та. Ничектер бигрәк пөхтә, чиста, көяз кеше икән. Өстендәге киемнәре дә элеккеге яшь купшы байларныкы шикелле — бик килешле утырган кара-зәңгәр бостон костюм, кардай ап-ак күлмәк, зур гына кара бантик, ә аякларында ялт иткән шиблетлар (болай киенүчеләр ул елларда бик сирәк очрый иде)... Мин шунда ук: «Бу абый электән үк китап сәүдәсе белән шөгыльләнгән белгечтер»,— дип уйлап куйдым. Шундый фартовый кеше булуына карамастан, ул минем белән бик гади сөйләште. Башта, записканы укыгач, үзалдына бераз: «Так, так!» — дип торды, аннары «Вафаның туганымы?» — дип сорады. Юк, дидем мин кыюсыз гына. «Ну ярар әләсә»,— диде ул гүя игътибарсыз гына, һәм мин аның мишәр икәнлеген сизеп алдым. Тагын сорады: грамотаң ничек, эшләгәнең бармы?.. Юк, дидем мин янә, бу юлы инде шүрли дә башлап. Ахырда абзый кеше аз гына уйланып: «Курьер булып эшләргә ризамы?» — дип сорады. Гөнаһ шомлыгына каршы, мин курьерның нәрсә икәнен белми идем. Нәрсә дим, тоттым да, «нинди эшкә дә риза» дип кенә җавап бирдем. Шуннан соң бу әйбәт кеше: «Ну, ярый, брат, иртәгәдән курьер булып эшли башларсың, сәгать 10 га килеп җит»,— диде һәм шуның белән сүз дә бетте. Абыем үз юлы белән китте дә барды. Нинди эш, нидән гыйбарәт, айлыгы күпме — ул хакта әйтеп тә тормады. Хәтта гаризаны да эшли башлагач кына яздырып алды.

Мин, әлбәттә, бик шат идем, бигрәк тә китап кибетенә эләгүемә шат идем. Миңа калса, китап сәүдәсеннән дә яхшырак, мәдәнирәк бүтән сәүдә юк иде. Монда идән себерүче булып эшләсәң дә оят түгел иде кебек (хәлбуки, идәнне миңа еш кына себерергә туры килде)...

Хуш, ә шушы яхшы урынга мине юнәлдергән, миңа шундый зур игелек эшләгән кешеләр кемнәр иде соң? Записка язып бирүчене башта ук белдем — ул китапханә мөдире Вафа Бурнаш дигән кеше иде. Күпмедер вакытлардан соң мин аның атаклы шагыйрь Фәтхи Бурнашның бертуган энесе икәнен дә белдем. Ә менә Вафа абзый янына мине җитәкләп алып кергән егетнең исемен озак кына белмичә йөрдем (үзе әйтмәгәч, мин сорарга кыймаганмындыр инде). Ләкин йөри торгач барыбер белдем — ул Габделхәй Хәбиб дигән кеше булып чыкты. «Шәрык» китапханәсендә күпме эшләгәндер — анысын әйтә алмыйм, әмма соңыннан ул татар матбугатында эшләп, журналист булып танылды. Ватан сугышында да журналист буларак, фронт газеталарында эшләде. Сугыштан соң

«Чаян» журналында җаваплы секретарь булып эшләгән чагында без Хәбиб абый белән шактый ук якынаеп та киткән идек. Күп кенә әйберләрем аның кулы аша узып, журнал битләрендә басылып чыкты. Гади, ачык, шат күңелле әйбәт кеше иде мәрхүм.

Кибет сәгать унда ачыла — эшкә соңга калу куркынычы юк. Ләкин инде кич сәгать сигезләрдә генә кайтырга туры килә. Архумас белән арам өзелде. Җан сыкранды, билгеле, әмма өмит дигән нәрсә калды — тагын көзләр килеп җитәр, насыйп булса!

Торуым исә һаман шул торакта. Фәтхелислам белән бергә. Син хәзер студент түгел, монда торырга хакың юк дип, ичмасам, юри генә дә әйтүче булмады. Бу торакка бергәләп түккән көч һәм бергә кичергән нужа безне тәмам бертигез иткән иде инде.

Минем эшем нидән гыйбарәт? Иң элек мин контора яки бухгалтерия әзерләп куйган төрле рәсми кәгазьләрне таратып йөрим. Моның өчен миңа искереп беткән бер брезент портфель белән кызыл тышлы зур гына контор кенәгәсе бирделәр. Башта әзерләнгән кәгазьләрне шул зур кенәгәгә тәртип белән язып чыгам да, аннары барысын портфелемә салып, тиешле җирләргә илтеп, кул куйдырып тапшырам. Бу минем төп эшем. Һәм курьер дип аталуым да шул эшем өчен икән. Ләкин кәгазь таратып йөрүем озакка бармый — бер ике-өч сәгатьтән бетә торган иде. Калган вакытны инде мин, кичкә кадәр, ни кушсалар, шуны эшләп үткәрәм. Мәсәлән, приказчиклар өчен самавыр куям, идән себерәм, түбәннән (магазин астындагы подвалдан) югарыга китап ташыйм, яки подвалдагы упаковщикларга түкләр тегәргә булышам. Читкә озатыласы китапларны түкләр итеп ике татар абзые тегәләр иде. Мин шуларга киндерләрен җәешеп, шпагатларын сүтешеп, китапларын өешеп булыша торган идем.

Әнә шулай уза иде минем эш көннәрем. Тик тотмыйлар иде мине, ләкин шулай да бернинди эш кушмаган чаклар да булгалый иде. Мондый чакта мин берәр аулак урында, шүрли-шүрли генә булса да, китап укып утырырга тырыша идем. Бу җәһәттән магазинның файдасын шактый күрдем дияргә дә ярый — теләгән китапны алып кайтып укырга да рөхсәт итәләр иде.

Әмма ничаклы тырышсам да, бик мөһим бер нәрсәне исемә төшерә алмыйм: күпме хезмәт хакы алдым соң мин?.. Егерме дигән бер сан башымда әйләнә-әйләнүен, әллә 21, әллә 23 сум, һәрхәлдә шуннан да артык булмагандыр, мөгаен... Ул заманда хезмәт хаклары зур түгел иде, ләкин арзанчылык аркасында бәрәкәтле иде.

Беренче хезмәт хакын калтыраныбрак санап алу һәм шуны эчке таза кесәгә салып кую ул үзе ниндидер бер тылсымга ия дияр идем. Син үсә дә төшкәндәй буласың, үз-үзеңә ышаныч та арта, киләчәгеңә дә курыкмыйчарак карый башлыйсың... Аннары ул көнне, ягъни беренче мәртәбә кесәгә акча кергән көнне, нидер гадәттән тышрак нәрсә эшлисе килеп китә. Мәсәлән, киногга керергә, циркка барырга яки инде бик тәмле, бик күп итеп ашап чыгарга!..

Мин әле шуларның кайсын сайларга белмичә, Рыбнорядский (хәзерге Куйбышев) урамы буйлап әкрен генә кайтып барам. Шул чакта бер йортның ачык ишегенә күзем төште. Борыныма тәмле ис тә килеп бәрелгәндәй булды. Һәм мин уйлап та тормыйча шул ишектән кереп тә киттем. (Бу өч катлы таш йорт — Кольцодан менгәндә сул якта, Татсоюзның яңа кибетен үткәч тә — түбәнге катында хәзер дә әле кечкенә кафесы бар). Кердем, агач баскычтан туры югары катка менеп киттем. Кечкенә зал, беркем дә юк диярлек, беренче буш өстәлгә утыруым булды — ак алъяпкыч бәйләгән официант яныма килеп тә житте. Ул минем бик яшь булуыма карап ахрысы, ышанмыйчарак:

— Сезгә нәрсә кирәк? — дип сорады.

— Ашарга кердем,— дидем мин.

— Бездә ресторан.

— Булсын... Ашарга бардыр бит?

— Ә нәрсә телисез?

— Нәрсә бар соң?

Официант аш исемнәрен әйтә башлады. Ләкин алар барысы да миңа ят, берсенең дә исемен отып алырлык түгел иде.

— Первый белән второй! — дидем мин тиз генә аның сүзен бүлеп. Официант көлемсерәп, иңбашын җыерып куйды.

— Третий да кирәкме?

— Давай анысын да!

Шулай аңлашканнан соң, официант минем алдыма көмеш чәнечке, пычак, кашыклар тезеп куйды да кухняга таба китте. Менә мин дә ресторанда утырам, имеш!.. Күреп белсәм дә, моңарчы бер тапкыр да керергә туры килгәне юк иде әле. Нарпит дигән җиргә кергәләгән бар иде. Аңа күбрәк безнеңише һәр тиенен

исәпләп тотучылар кирәләр иде бугай. Арзан. 15—20 тиенгә кәбестә шулпасы белән тары боткасы яки котлет алып, тамакны әйбәт кенә туйдырып була иде. Хуш, инде булмаса, ресторанныкын авыз итеп карыйк.

Официант кечерәк миски белән аш китереп, минем тәлинкәмә бушатты. Исе дә тәмле, куе да икән үзе... Әчкелтемрәк бу ашны бик яраттым, рәхәтләнеп, хәтта кәефләнеп ашап бетердем (акча түләгәндә белдем: солянка булган икән ул). Шуның артыннан зур гына тәлинкәдә, әйләнәсенә бәрәңге һәм төрле яшелчәләр салып, бияләй хәтле кыздырган ит китерде. Бу ниг ъмәтнең исемшәрифләре ничек булгандыр, әмма мин аны да бик яраттым, бөртеген дә калдырмыйча ялтыратып куйдым. Шуннан соң инде фәкыйрегез алдына кеч-кенә генә көмеш чәйнек белән каһвә дә килде. Сөте де, шикәре дә бик кечкенә аерым савытларда, хәтта эчә торган кечкенә генә чәшкәсе дә уенчык кебек кенә иде. Кызы-ык!.. Тик ничегрәк итеп эчәләр икән бу каһвәне?.. Бәлки әз-әзләп кенә озаклап эчәргә кирәк булгандыр — мин инде ике салып, ике йотуда бетереп тә куйдым.

Казанга килгәч, бу минем беренче мәртәбә шулай туйганчы сыйлануым иде... Ярый, аш булсын, актыгы булмасын! Хәзер инде һәммәсе өчен дә түләргә кирәк иде... Әлбәттә, бу 15 тиенлек кенә ашау түгел иде, бәлки ике мәртәбә кыйммәтрәк түләргә туры килер, ну черт с ним!.. Официант кечкенә счетында шалт-шолт салды да: «Сездән җәмгысы 60 тиен!» — диде... Әнекәем, алтмыш тиен?! Мин бер мәлгә, ни әйтергә дә белмичә, телсез калдым. Кем уйлаган шул хәтле түләргә туры килер дип?.. Әмма берни эшләр хәл юк — түләргә кирәк, түләмичә булмый...

Сез минем болай хафага төшүем өчен бер дә гаҗәпләнмәгез. Чөнки 60 тиен ул минем өч көнлек мәгыйшәтем дигән сүз... Онытмагыз, ак калачның кадагы 3 тиен иде ул чакта!.. Шушы сыйланудан соң мин бер биш ел ресторан тирәсенә аяк та басмадым...

* * *

...Язмышны алдан юравы бик читен. Укырга дип, ашкынып килеп, менә йомыш-юлга йөрүче малай булып киттем. Кайчагында уйлап куям: Казанда калмыйча кире Дәүләкәнемә кайтып китсәм, нәрсә булган булыр иде икән? Бер елдан тагын әйләнеп килер идемме икән, әллә бүтән тарафларга (мәсәлән, Урта Азиягә) китеп барыр идемме, яки бөтенләйгә Дәүләкәндә утырып калыр идемме икән?.. Һич әйтә алмыйм, әмма Дәүләкәндә утырып калу минем өчен иң аянычлы язмыш булыр иде. Бу кечкенә җирдә укырга да, эшләргә дә перспектива юк диярлек, күп булса берәр волость (соңыннан район) оешмасында счетовод-мазар булып калыр идем. Юк, түзмәс идем мин мондагы шартларга, Дәүләкән үзе, Димнәре-тугайлары җаныма никадәр якын булса да, башымны барыбер берәр якка алып чыгып китәр идем. Димәк, хәзергә, эш табып, Казанда калуым, һичшиксез, дөресрәк булгандыр — шулай юатам мин үземне киләчәк турында өмитләнеп уйлаган чакларымда...

Без үзебезнең шыксыз торагыбызда кәефле генә яшәп ятабыз. Егетләр торалар да Архумаска йөгерәләр, ә мин — эшкә... (кайберәүләр ни өчендер урыннарыннан тормыйча ятып та калалар). Кич халык җыелгач, торак җанлана. Мичне ягып җибәрәбез, кәтилүкләрдә чәй кайнатып, ашап-эчеп алабыз. Егетләр ишеткән-күргәннәрен сөйлиләр. Уен-көлке, сүз-бәхәс — барысы бергә... Әйтергә кирәк, егетләр бик ярлы яшиләр. 9 сум стипендия аларның ашарларына да җитми, шуңа күрә һәркайсы нинди дә булса эш табып, акча эшләп алу ягын карый. Әгәр шуңа ирешсә, ул инде тук һәм шат. Байлык турында уйлау да, сөйләү дә юк. Ач булмаса, өстендә бер кат кием булса, студент шуңа бик канәгать. Ул чактагы аңлавыбыз буенча, байлык буржуйда гына булырга мөмкин, акча да әнә нэпманнар кулында гына!.. Хәтта зур урыннардагы совет работниклары да байлыкның нәрсә икәнен белмиләр дип уйлыйбыз. Һәм аларга көнләшеп карау да юк иде. Бәлки дәрәҗә-авторитетларына гына кызыгу булгандыр.

Кыскасы, ашау такы-токы, өс-баш юка булса да, күңел көр, зарлану юк, барысы да бик табигый, шулай булырга тиеш тә кебек иде. Яшьлекнең өстенлеге һәм кодрәте бу... Уйнау-көлү, кызык сөйләү, бер-берен үртәү һәм шаярту — менә арып кайткан егетләрнең бөтен эше шул дияргә дә ярый (китап уку, хат язу, ертык-сүтекне тегүдән кала). Шаярту дигәннән, егетләрнең хыяллары бу юнәлештә бик шәп эшли иде. Бер генә мисал. Безнең арада һәркөнне диярлек бик соңга калып кайтучы бер иптәшебез бар иде. Бәшәр дип йөртә

идек без аны... Менә шул Бәшәр барыбыз да йокыга киткәч кенә кайтып керә дә кыштыр-кыштыр йөрергә тотына, һәм шуның белән ачуыбызны бик китерә иде. Ахырда егетләр моны кызык итәргә булдылар. Каяндыр таза бау табып, аның топчанын шул бау белән түшәм уртасындагы әлеге тимер ыргакка күтәртеп, асып куйдылар. Бер заман егетебез, гадәтенчә, бөтенебез ятып беткәч, караңгы торакка кайтып керде, шак-шок басып, ята торган урынына барды һәм туктап, тынып калды. Ә без, йоклаган булып, тын да чыгармыйча тыңлап ятабыз. Бәшәр әкрен генә капшанып, топчанын эзли башлады, шырпы яндырып та карады, ә топчан юк кына бит... Бик аптырады малай, «ый-й» дигән рәнҗүгә охшаш бер аваз чыгарды, аннары сүгенеп, бәрелә-төртелә зал буйлап йөрергә тотынды. Егетләр исә уянган булып, кычкыра башладылар: «Нәрсә йөрисең мунча пәрие шикелле, көн дә йокы бозып, безобразие!.. Ят хәзер үк, югыйсә үзеңне дә типкәләп чыгарабыз!..» (кайберәүләр тәкатьләре бетеп, юрганнары астында буыла-буыла көләләр). Бәшәр тагын бераз сукранып, әрле-бирле йөрде дә, топчаны торган буш җиргә бишмәтен җәеп, ахырда йокларга ятты. Ә егетләр һаман аны үртиләр: «Иялөшеп алды бер нэпман кызына, понимаешь!.. Ә без монда аның кайнар пәрәмәч белән сыйланып кайтканын көтеп ятыйк, имеш!.. Булмый болай, хватит!..»

Хәлбуки, Бәшәрнең хатын-кыз яныннан кайтуы бик мөхәл иде. Үзе ул буе-сыны белән бәләкәй — арык кына, шуның өстенә кыюсыз-мокыт кына бер егет — белмим, нәрсәсе белән генә хатын-кызга ошый алыр икән?! Мөгаен, берәр җирдә эш табып, берәүгә дә әйтмичә, шунда эшләп йөргә булгандыр.

Бичара, бу төнне ул ихтимал юньләп йоклый да алмагандыр, әмма иртәгесен тәмам яктыргач, күзен ачып җибәрсә, ни күрсен: моның топчаны сәләмә матрасы белән ак түшәмгә терәлеп үк асылынып тора!.. Егет шаккатудан телсез калды диярлек, бары тик «ый-й» дигән шатлык авазы гына чыгарды, аннары инде үзе дә тыела алмыйча кычкырып көлеп җибәрде...

Моның ише кызыклар безнең «ночлежка»да әледән-әле булып тора иде. Тик кайчагында шаулап көлү белән генә чикләнеп калмыйча, бик нык үпкәләшеп, хәтта тәпәләшүгә дә барып җитә идек. Бер җирдә өелешеп яшәгәч, шунсыз булмыйдыр ахрысы...

* * *

...Бу хакта хәзергә сүзне бүлеп, күптән үз чиратын көткән яңа бабка күчәргә вакыттыр ахрысы. Минем бит әле һаман да әдәбият дөньясы турында бер сүз дә әйтә алганым юк — сез дә, ихтимал, шуны көтә торгансыздыр. Мин бит башта ук кая, нинди тарихи җиргә, нинди хикмәтле калага килүемне белеп килдем. Белеп кенә түгел, зур өмитләр баглап килдем. Казан — ул татар мәдәниятенең үзәге, Казан — ул татар әдәбиятының бишеге, шушында инде аның бөтен атаклы әдипләре һәм шагыйрьләре... Тукай үлгәнгә дә әле күп еллар узмаган, аның бөтен замандашлары исән-сау диярлек, шушында яшиләр һәм эшлиләр... Алардан башка монда хәзер күпме яңа әдипләр, яңа шагыйрьләр калкып чыкты. Мин аларның да кайберләрен, мәсәлән, Шамил Усмановны, Такташны укып та, ишетеп тә белә идем. Билгеле инде, минем Казанга килүдән беренче максатым уку булса, икенчесе — һичшиксез, шул әдип, шагыйрьләрне күрү, шулар арасына әкренләп булса да керү иде. Язып үткәнемчә, мин бит инде үзем дә Дәүләкәндә чакта ук каләм «тибрәтә» башлаган идем, шулай булгач, мондагы әдәбият дөньясының мине үзенә никадәр тартып торганын әйтеп тору бәлки артыктыр да. Кыскасы, шул ук елның көз ахырында яки кыш башында булса кирәк, миңа бу мавыктыргыч дөньяның бусагасыннан, ниһаять, атлап керергә дә туры килде.

Мәгәр башта тере әдипләрдән кемне һич көтмәгәндә генә күрү бәхетенә ирешүемне язып үтим әле... Китап кибетенә барганда-кайтканда, еш кына Ленин бакчасы аша үтеп йөри идем. Көннәрдән беркөнне менә шул бакча аша үтеп барам. Көз ахыры, агачлар инде шәрә, бакча юллары сары яфраклар белән түшәлгән. Тын-буш юлларның берсеннән ак сакаллы кечерәк бер бабай тәгәрмәчле креслоны әкрен генә этәреп килә. Креслода пенсне кигән бер кеше утыра... Каршыма килеп җитмәс борын ук мин ниндидер бер күңел сизенүе белән креслодагы кешенең Фатих Әмирхан икәнен танып алдым. «Я, хода!»— дидем ирексездән эчемнән генә һәм шунда ук адымнарымны әкренәйттем... Әнә шулай бик әкрен генә без кара-каршы якынлаштык. Иң мәшһүр әдип, бөек Тукай замандашы, укып беләм, рәсемнәрен күреп беләм, гарип булуын да ишеткәнем бар иде — бәлки шуңа күрәдер, мин ниндидер изге бер затка очрагандай эчке киеренкелек һәм дулкынлану белән бөтен дикъкатемне җигеп, аның йөзенә карап уздым. Ахрысы

шуңадыр, өстендәге киемнәре хәтеремдә дә калмаган, тик башында фетр эшләпә иде бугай... Әмма йөзен яхшы хәтерләп калдым. Протретларына бик охшаган — озынча ак йөз, калын гына иреннәр, калын пенсне аша караган коңгыртрак зур күзләр... Тагы күңелгә кереп калганы — аның карашы да, чырае да миңа ни өчендер бик уйчан-җитди булып күренде. Соңыннан, еллар узып искә төшергән чагымда да минем күз алдыма гел генә аның әнә шул уйчан-җитди кыяфәте килә торган иде. Димәк, хыялым эше генә булмаска тиеш бу. Бабай белән әдип минем яннан, корган яфракларны кыштырдатып, сөйләшмичә әкрен генә уздылар. Бер арык кына егетнең, туктый язып, йотылып карап китүенә дә алар игътибар итмәделәр шикелле. Әллә тагын каршыларына чыгыймы икән дип уйлаган идем дә, ярый әле андый әрсезлектән тыелып кала белдем.

Фатих Әмирханны икенче тапкыр күрүем «Сания» операсында булды. Өч кеше — Солтан Габәши, Газиз Әлмөхәммәтов һәм Василий Виноградовлар тарафыннан язылган беренче татар операсы «Сания», мәгълүм булганча, 1925 елның июнендә, ягъни Татарстан республикасының 5 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә беренче мәртәбә куелган булган. Казанның мәдәни тормышында ул зур вакыйгадан саналган, ул хакта газитәләр дә күп язган. Галимҗан Ибраһимов премьера көнне пәрдә ачылыр алдыннан нотык та сөйләгән. Фатих Әмирхан үзе дә аның хакында, әсәр әле сәхнәгә чыкмас борын ук, моңарчы хыялларда гына йөргән опера сәнгатенең, ниһаять, бездә дә тууына сөенеп махсус мәкалә бастырган.

Менә шул «Сания» яңадан 1926 елның январенда уйналачак иде. Афишаларын күрүгә, миндә бик табигый рәвештә көчле теләк туды — ничек кенә булса да барырга, карарга!.. Бу теләк сәнгатебез өчен күңелләрдә үзеннән-үзе уянган милли горурлык белән бәйләнгән иде. Аннары бит минем опера дигән нәрсәне күргәнем дә юк әле, ишетеп кенә беләм, ничек инде аны — үзебезнең саф татарча операбызны күрмичә калырга мөмкин ди?!. Әмма аңа әләгүе ансат булмаячак, хәзер кышкы театр сезоны, «Сания»нең икенче тапкыр гына уйналуы, халык, әлбәттә, ябырылып киләчәк. Хәер, чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыгады,— мин дә йөри торгач билетның арзанлысын, ниһаять, кулыма төшердем. Аның каравы, минем урыным иң югарыда булачак.

Ләкин бер кимчелек шатлыгымны бозып, эчемне гел пошырып тора иде. Театрга киеп барырлык юньле киемем юк. Чиста ак күлмәгем бар, ә менә пинҗәгем бик хөрти — җиң очлары сүсәргән, җитмәсә, бер терсәге дә тишелгән. Бу кием белән ничек итеп бармак кирәк?.. Оят бит! Ярлылыкка күнеккән кеше дә театрга ертык кием белән бармый торгандыр инде. Терсәкне ямарга, ичмасам, ямаулыгы да юк. Нишләргә соң, егетләр?.. Ахырда уйлана-борчыла торгач, үземчә бер хәйләсен таптым: пинҗәкне эчтән киеп, аның өстеннән ак күлмәкне кидем дә, билемне каеш белән кысып, буып куйдым... Бу чын, монда бернинди арттыру да, ялган да юк. Торактагы иптәшләр көлеп, мине тынычландырдылар да әле: «Синә болай кию килешә дә икән, әзрәк тулыланып киттең»,— диделәр. Әйе, бар иде, бар иде, «талдин нечкә» сылу чаклар!

Шулай итеп, мин пинҗәк өстеннән күлмәк киеп, беренче татар операсын карарга бардым. Ә театрда халык — үзе бер тамаша! Кемнәр генә юк. Укымышлы зыялылар, әдипләр, шагыйрьләр, төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр һәм хәрбиләр, шулай ук укучы яшьләр — кыскасы, шәһәри Казанның бөтен каймагы җыелган булырга тиеш. Һәм шулар арасында килеш-килбәтләре белән үк аерылып торган шактый зур бер төркем — яңа байлар (нэпманнар) белән аларның тулы хатыннары... Ирләре иске заманча бик шәп тройка костюмнан һәм кара кәләпүштән, ә хатыннарының өстендә атлас та бәрхет, энҗе-мәрҗән дә асылташ... Болар, әйтерсең, опера караудан бигрәк үзләрен күрсәтер өчен килгәннәр...[1] Шул зиннәтләре белән алар күз явын алып, хуш исләр таратып, зур фойеда әкрен генә әйләнеп йөриләр. Әйе, гаҗәеп бер чуарлык һәм аермалык бүген монда... Әмма беренче татар операсы уяткан хисләр уртак һәм кәефләр дә бер төсле иде, минемчә.

Үз ишләремне дә караштырдым. Ләкин алар бик аз иде бугай. Ә менә элеккеге студент формасындагы яшел тужуркалы, жиз төймәле җитү егетләр күренгәләде. Шулай ук кечкенә калфаклы зифа туташлар да күзгә чагылмыйча калмады. Мин аларга бик кызыксынып һәм ирексездән сокланып карадым — гүя

---

[1] Күптән түгел Исмәгыйль абзый Һилалов сөйләде: шул заманда алар белән бер йортта торган тегүче хатыннан нэпман бичәләре «Сания» операсына махсус киеп барыр өчен 70 күлмәк тектергән булганнар.

алар үтеп киткән, инде яңадан кайтмас заманның сирәк кенә сакланып калган соңгы яшьләре иде... Кыскасы, үзем кебек өтекне һәм арыкны мин монда очратмадым. Мәгәр моңа бер дә көенмим. Мине бирегә этем дә белми, урыным да каядыр өченче катта, ичмасам, тыныч җан белән уенны карый алачакмын.

Хуш, инде «Сания»не тамаша кылыйк. Иң әүвәл, пәрдә ачылмас борын, сәхнә алдындагы чокырда утыручы музыкантлар, бер куе чәчле, какча гына кешенең нечкә генә таягын селкүгә, төрле уен коралларында дәррәү генә уйнап җибәрделәр. Операның башымы, керешеме булса кирәк бу (увертюра дигән сүзне ишеткән юк иде әле)... Оркестр күпмедер уйнаганнан соң пәрдә әкрен генә ачылды. Сәхнә бик түбәндә булгач, андагы бөтен нәрсә ничектер ерагаеп, кечерәеп күренә икән. Уйнаучыларның да мин иң элек баш түбәләрен генә күрәм. Әнә кырпу бүрек кигән егет, әнә кечкенә калфак кигән туташ, тагын әнә кама читле бүрек кигән бер агай да йөри (бусы Солтан Габәши уйнаган староста булып чыкты). Алар барысы да оркестр уйнаган көйгә ияреп, үзара җыр белән генә сөйләшәләр, җыр белән генә аңлашалар. Мәсәлән, гап-гади «Исәнме, абзый!» — дигән сүзне дә җырлап-сузып әйтәләр. Опера шулай булырга тиеш тә инде ул — бу кадәресен генә без дә беләбез. Мин дикъкать белән тыңлыйм. Операның үзәгендә мәхәббәт вакыйгасы торуын мин башта ук аңладым дияргә була... Музыка өзлексез уйный, геройлар да өзлексез җырлыйлар, җыр-музыканың миңа ошаган урыннары күп, ошап бетмәгән урыннары да юк түгел, әмма никадәр бирелеп тыңласам да, бер нәрсә мине һаман борчыды да торды: җыр белән сөйләшүне мин юньләп аңлый алмыйм икән. Нәрсә хакында сүз бара, бер-берсенә нәрсә дип әйтәләр — менә шуны тота гына алмыйм бит. Гаҗәп!.. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне мин күбрәк хәрәкәтләренә, чырайларына, тавышларына карап кына чамалыйм. Ә сүз юк, сүз миңа килеп җитми, шуның аркасында күп нәрсәне аңламыйча калам. Бу хәлгә аптырадым да, пошындым да, бәлки урыным начарга күрәдер дип тә уйладым. Ләкин ничек кенә булмасын, операдан чын ләззәт алдым дип әйтергә телем бармый. Хәер, минем яшьтә һәм беренче мәртәбә генә караулда бу, бәлки, мөмкин дә түгелдер. Ә шулай да беренче татар операсын күрә алуыма бик шат булып, халык кичергән горурлыкны мин дә чын ихластан кичереп, мактанып та йөрдем.

Моңа инде күп еллар узды. «Сания» операсы күптән онытылды, әмма гаҗәпкә каршы, бер хакыйкать шулай да сакланып калды. Соңыннан, тәмам дәү абзый булып җиткәч караган опералар белән дә шундый ук хәлне татырга туры килә иде. Нинди генә операга барсам да мин, билгеле, музыкасын тыңлыйм, бай декорациягә, зиннәтле киемнәргә карап утырам, ә менә җырлап әйтелгән сүзләрнең уннан берен дә аңлый алмыйм. Шулай итеп, операга салынган фикер, мәгънә миңа килеп җитмичә кала. Бу бик зур оттырыш, чөнки мәгънәне мин сүздән табарга гадәтләнгәнмен. Ахрысы шуңадыр, опера мине бервакытта да чынлап торып җәлеп итә алмады. Ихтимал, бу минем бик зур кимчелегемдер, наданлыгым, мокытлыгымдыр, ләкин «культурный» булып күренер өчен генә аңлыйм, яратам дип ялганлыйсым килми. Ә бит мин балачактан ук җыр ишетеп, җыр белән сихерләнеп үскән идем. Алайса, хикмәт нәрсәдә?

...Бәлки һәр сәнгатьнең үз вакыты бардыр. «Сания» операсы язылган елларда безнең татар тамашачысы бу бик катлаулы, бик нечкә сәнгатьне тиешенчә аңлап, кабул итү дәрәҗәсенә килеп җитмәгән иде әле. Операны заказ белән яздырып булса да, аны аңларлык тамашачыны махсус хәзерләп булмый, билгеле. Димәк, икесе дә бергәрәк өлгерергә тиештер инде. Тагы да ачыграк әйткәндә, һәрбер сәнгать халыкның мәдәни үсеше белән бәйләнгән рухи ихтыяҗыннан туса гына, аны җиңел аңлап та, табигый кабул итеп тә була торгандыр. Моның шулай икәнен безгә шул ук елларда үсеп киткән һәм беренче нәүбәттә Салих Сәйдәш исеме белән бәйләнгән музыкаль сәхнә әсәрләре бик ачык күрсәтте. Халык бу әсәрләрне бердән яратты, бердән кабул итте, чөнки ул инде «Галиябану»дан соң җыр-музыка кергән драма әсәрләрен көтеп кенә тора иде. Димәк, андый әсәрләргә ихтыяҗ тәмам өлгереп җиткән булган. Һәм шуннан соң инде операга да ерак калмый кебек. Ихтимал, аны тудыручылар шулай уйлаганнардыр да, әмма кайчагында якын араны да бик авыр үтәргә туры килә. Ләкин нихәтле генә авыр булмасын, революциядән соң опера сәнгате союздагы төрки халыклар арасыннан иң элек бездә туды. Мәдәни тормышыбызда бу зур вакыйга иде, һәм халык аны шулай кабул да итте. Инде операны аңлау, ярату мәсьәләсенә килгәндә, бу төрле кеше өчен төрлечә — монда уртак кагыйдә булуы мөмкин түгел. Әгәр шулай икән, гаепләштән булмасын. Ә менә операның үзен беренче булып, тәвәккәллек белән фидакарьлек күрсәтеп иҗат итүче Габәши, Әлмөхәммәт, Виноградовларны без истән чыгармаска һәм тирән хөрмәт белән, һичшиксез, яд итәргә тиешбез.

Сүзем бит минем Фатих Әмирханны икенче тапкыр күрүем турында иде. Нәкъ менә «Сания» операсында, кайчандыр үзе хыял иткән милли опера тамашасында!.. Антракт вакытында мин түбәндәге фойега төштем — читтән генә булса да шунда әйләнеп йөргән Казан публикасын әзрәк күзәтәсем килгән иде... Карасам, залга үтә торган ике ишек арасындагы стена буена Фатих Әмирханны креслосы белән чыгарып куйганнар. Минем игътибарым шунда ук аңа күчте. Якынрак бардым, ләкин инде әдипне аның үз геройларына охшаган студент формасындагы егетләр һәм калфаклы туташлар урап алганнар иде. Мин, билгеле, алар арасына кысылып керергә кыймадым, тик шулай да түгәрәкнең әле бер ягыннан, әле икенче ягыннан килеп, әдипнең йөзен күрергә тырыштым. Егетләр һәм туташлар аңа комплимент һәм мактау сүзләре әйтәләр, ә ул саран гына елмаеп, башын селеккәли, нидер әйтә дә шикелле, ләкин миңа ишетелми иде. Ә менә чырае, бакчада күргәндәгечә, һаман шулай җитди-уйчан иде (хәтта боеграк та кебек иде). Шулай торып калды әдипнең йөзе-чырае минем хәтердә һәм шулай гына сакланды да хәзергә кадәр... Вакыт-вакыт хыялым эше түгелме икән бу дип шикләнеп тә куям, әмма барыбер Фатих Әмирханны башкача күз алдыма китерә алмыйм. Чөнки ул минем өчен бер үк вакытта гаҗәпләнү, кызгану һәм соклану катыш тирән ихтирам уяткан бөек әдип кеше иде (хәер, еллар узу белән, кызгану тойгысы үзеннән-үзе диярлек бетте, чөнки рухи көчле фидакарь затларны гариплеге өчен генә кызгану мөмкин түгел икән). Менә шул затны мин тере чагында күреп калу бәхетенә ирештем!

Ә нәкъ ике айдан инде Фатих Әмирхан дөнья белән дә бәхилләште («Сания» операсы 16 январьда уйналган иде, Ф. Әмирхан 13 мартта вафат булды). Зур үкенечкә каршы, мин әдипне озату вакыйгасын күрә алмадым. Нәкъ шул көнне мине кибет хезмәткәрләре исеменнән ниндидер бер профсоюзлар җыелышына җибәргәннәр иде, бөтен көнемне бик гадел рәвештә шунда утырып үткәрдем. Хәлбуки, күрүчеләр Фатих Әмирханны озату шактый хикмәтле булды дип сөйләделәр. Бер яктан совет җәмәгатьчелеге Ирек мәйданында митинг ясап, нотыклар сөйләгәннәр, икенче яктан әдипнең якыннары, мәрхүмнең васыяте буенча дип, муллалардан аңа җеназа укытканнар. Һәм бу ике төрле озату каршылыксыз, шома гына узмаган булса кирәк.

Ул көннәрдә матбугат Фатих Әмирхан турында күп язды. Тукайдан соң татар әдәбиятында бу иң зур югалту иде. Моны һәркем диярлек шулай аңлады. Әмма Фатих Әмирханның нинди язучы булуына килгәндә, монда инде бик тиз катгый бер караш өстенлек алды: Фатих Әмирхан — буржуа язучысы!.. Үлүенә багышланган беренче мәкаләләрендә үк (мәсәлән, Г. Сәгъди мәкаләсендә) ул караш ачык әйтелгән иде, аннары, күп тә узмый, андый караш әдипкә, көйдереп суккан тамга шикелле, кырып та бетермәслек итеп ябыштырылды. Бу эштә Г. Толымбайский аеруча зур тырышлык күрсәтте. Әдипнең үлүенә бер ел тулу уңае белән ул болай дип язып чыкты:

— Фатих Әмирхан, буржуа сыйнфы сәнгатьчесе буларак, буржуа сыйнфы алга барганда алга барды. Буржуа сыйнфы бетүгә йөз тоту белән бергә, ул да зәгыйфьләнде, түшенкелеккә йөз тотты («Безнең юл», 2 сан, 1927 ел).

Бусы — әдипнең иҗатына карата әйтелгән сүзләр. Ә менә әдип үлгәннән соң ике ай да үтмәгәндер, аның әсәрләре турында ул, Толымбайский, мондый карар чыгарырга да өлгерде:

— Бу китапларның хәзерге вакытта эшче-крестьяннәргә бер тиенгә дә кирәкләре юк. Шулай булгач, хәзерге көндә боларны бастырып тарату сәяси җинаять булачак («Безнең юл», 5—6 саннар, 1926 ел).

Күрәсез, нинди рәхимсез хөкем!.. Әйе, төрлесен ишетергә, төрлесен күрергә туры килде. Ярый әле, моның ише хәлләр саташулы авыр төш шикелле үтте дә китте. Мең шөкер, без Фатих Әмирханның исемен дә, бай мирасын да баш очындагы мәрмәр ташын да югалтмадык[1]. Без аңа һәрвакытта баш иеп узабыз. Күптән юкка чыккан буржуазия түгел, ә татар халкы чын хуҗа аның үлемсез мирасына!..

Г. Толымбайский үзе дә бик кызганыч. Әдәбият күгендә Г. Нигъмәти ачкан биш йолдызның берсе иде бит... Әмма язмыш дигәнең аны да аяп тормады. Күктән җиргә сөрелгәндәй, бичара, юкка чыкты. Каберен дә белмибез. Тагын

---

[1] Бу таш әдипнең каберенә 1927—1928 елларда куелган. Кара мәрмәрне Яңа бистәдә Әмирхановлар гаиләсе белән якыннан аралашып яшәгән Исхак Карташев Ленинградтан барып алып кайткан. Ташка «Әдип Фатих Әмирхан» дигән сүзләрне бик матур итеп Кәлмәтов фамилияле кеше язган булган. Болар барысы да җәмәгатьчелектән җыелган акчага эшләнгән... Моны миңа Исхак абзыйның улы, сугыш һәм хезмәт ветераны Заһид Карташев сөйләде (Ә. Е.).

бер шөкер итик, язганнары югалмады, ичмасам! Малай чагымда кеше кулында гына бер китап күргән идем. Исеме — «Үзеңә кайта». Ни хикмәттер, укылмаган китапның исеме шушы көнгә кадәр күңелдә сакланган. Нидер аңлаткан булса кирәк ул миңа... Үзеңә кайта! — бик гыйбрәтле сүз бу, минемчә.

* * *

Әдәбият дөньясы... Нindирәк икән ул?.. Бик мавыктыргыч та һәм куркыныч та кебек бу дөнья! Бигрәк тә минем ише ерактан килгән, үзенә әле бик үк ышанып та бетмәгән бер үсмер егеткә. Хәер, миннән соңрак килеп тә, әдәбият дөньясына ансат кына кереп киткән һәм тиз арада түренә үк узарга өлгергән егетләр дә булды булуын... Ләкин мондый уңышны кешенең акылы, таланты, булдыклылыгы белән генә аңлатуы читен — монда заман белән бәйләнгән ниндидер объектив сәбәпләр дә булырга тиеш иде. Минем максатым исә, хәзергә бик тирәнгә кермичә, үзем күргәнне һәм үземә кагылганны сөйләү белән генә чикләнү — калган яклары тора-бара шулардан да бәлки беркадәр ачыкланыр.

Хуш, ничек таптым соң мин ул әдәбият дөньясының ишеген? Ирек мәйданындагы хәзерге Әфисәрләр йорты без килгән елларда комклуб дип атала иде. Көн дә яныннан үтеп-сүтеп йөрибез, ләкин эченә кергәнебез юк, анданиләр барын белмибез. Күпмедер вакыттан соң әлеге ТКУда эшләп йөрүче Әстерхан егете Мәсгуттән ишеттек: ул клубта атна саен татар язучыларының җыелышы була икән ләбаса! Бу хәбәр миндә шунда ук зур кызыксыну уятты: кемнәр, нинди язучылар җыела, нәрсәләр сөйлиләр анда, язучы булмаган кешегә дә керергә ярый микән? Мәсгут үзе дә ара-тирә ул җыелышларда булгалаганга күрә, миңа бик белеп: «Бернинди тоткарлык юк, пажалысты, барасың да керәсең!» — диде. Бу инде ноябрь ахырлары булгандыр. Җыелышлар була торган нәүбәттәге җомганың киче килеп җиткәч тә мин, Фәтхелислам белән Мортазаны кыстый-кыстый ияртеп, әлеге шул комклуб дигән җиргә, ахшам кичәсенә ашыккан шәкертләр шикелле, шагыр-шогыр атлап киттек. Бардык, кердек, кемнәндер язучылар җыелышы кайда монда дип сорадык. Җыелыш бара иде инде — безгә юньләп игътибар итүче дә булмады. Таза имән урындыклар монда рәткә тезеп куелмаган, һәркем үзе теләгәнчә куйган да утырган (кайберләре исә атланып та). Ишек төбеннән ерак түгел безгә дә урын табылды — мыштым гына узып, без дә шунда чүгештек. Кеше әллә ни күп түгел, шулай да бер утызлап булыр. Минем чамадагылар да әзрәк күренә, күпчелеге исә 20 белән 25 ләр арасындагы җитү егетләр. Шулардан да олыраклар берничә кеше генә. Өс-башлары да бик чуар. Юка пальто, бушлат, шинель, башларында кепка да фуражка — кыскасы, ни тапсалар, шуны кигәннәр, кием-салымга гүя полный талымсызлык! Тик менә кашне дигән нәрсә бик модага кереп бара икән. Өсләреннән салсалар да, кашнены муеннан алу юк. Аның бер башын алга, икенчесен артка салындырып куялар — моны кайбер язучыларның фоторәсемнәрендә дә бәлки күргәнегез бардыр.

Ярый, болары кайбер вак-төякләрне искә төшерү генә... Мине иң кызыксындырганы — кемнәр монда һәм нәрсә турында сүз алып баралар? Берсен дә әлегә танымыйм. Сөйләүченең фамилиясен әйтсәләр генә белеп калам. Ләкин монда трибуна юк, һәркем утырган җиреннән генә тора да сөйли башлый, күбесенең фамилиясен әйтеп тә тормыйлар. Менә кара бер егет ялкынланып гүя нотык сөйли — кем ул, хода белсен!

Хәлбуки, мин әле Дәүләкәннән ике яңа язучыны белеп дигәндәй килгән идем. Болар — Шамил Усманов белән Һади Такташ. Соңгысының «Җир уллары» дигән китабы безгә дә килеп җиткән иде. Элегрәк шигырь белән язылган сәхнә әсәре яки озын шигырьләр бездә сирәк укыла иде, без әле, дөресен генә әйткәндә, аларның «тәмен» дә белеп җиткерми идек. Әмма «Җир уллары» һәм аның ахырындагы «Үтерелгән пәйгамбәр», «Таң кызы», «Бакчачылар» кебек шигырьләре безнең әдәбият сөючеләрне берьюлы әсир итте дә куйды. Кайберәүләр аларны яттан да шашынып сөйләп йөри башладылар... Мин үзем дә, билгеле, ул шигырьләрдән бихуш булган идем... Менә шуларны язган Такташ дигән кеше бармы монда, булса, кайсысы, ничек итеп танырга?

Шамил Усманов исеме дә миңа яхшы таныш иде. Хикәяләрен укыганым бар, аннары «Канлы көннәрдә» дигән драмасы бездә кат-кат уйналган да иде. Ул абый да биредә булырга тиештер инде.

...Соңгы вакытларда колакка тагын Нәҗми белән Кутуй дигән исем бик еш керә башлады. Бик зәһәр шагыйрьләр булса кирәк. Алар да мондадыр, әлбәттә. Тик бераз көтәргә генә кирәк, ачылмыйча калмаслар, явыллар, мишәр әйтмешли...

Әмма сүз, бәхәс нәрсә турында соң монда — башта шуны белик әле. Алай, баксаң, монда күбрәк берәр әсәр — шигырьме, хикәяме — укып, шуның хакында кызу сүз алып баралар икән. Әйтергә кирәк, сөйләшү бик хөр бара. Торып сөйләүче әсәрне чөеп мактаса да, бетереп ташласа да әйтергә теләгәнен яра да сала. Тыйнакланып, хәтер саклап тору юк. Мәгәр еш кына укылган әсәрне онытып, бөтенләй башка мәсьәләгә күчеп, үзара талашыр дәрәҗәдә бәхәсләшеп тә китәләр. Бер-берсен шулай ук аяп тору юк, теләнә ни кылсә, шуны тота да чәпи. Тыңлавы бик кызыклы, тагын ни ишетермен дип көтеп кенә торасың, һәм шуның белән бергә үзеңне ничектер энәләр өстендә утыргандай итеп тә тоясың...

Беренче килүебездә мин кемнәрне күрүемне дә, ниләр ишетүемне дә хәзер инде ачык кына исемә төшерә алмыйм. Әмма комклубтагы бу шау-шулы җыелышларга бик теләп йөри башладым. Әле беркемгә билгесез үсмер егет кенә булсам да, бу инде минем әдәбиятка якынаюым, язучылар арасына керә башлавым иде. Хыялның әкренләп чынлыкка әйләнүе... Озак та үтми, мин инде монда Такташны да, Кутуйны да, Кави Нәҗмине дә, Гомәр Галине дә, Хәсән Туфанны да, Толымбайскийны да күрдем, танып калдым, сөйләгәннәрен дә ишеттем. Болар — атаклылар, боларны тиз белеп була, ләкин алардан да яшьрәк, танылып өлгермәгәннәр дә аз түгел — миңа беренче нәүбәттә менә шундыйлар белән әкренләп танышырга кирәк булачак иде. Билгеле, бу җыелышларга йөрүчеләрнең иң зур күпчелеге укучы яшьләр иде. Үзләре язалармы-юкмы, әмма мондагы бәхәсләрне тыңларга да, кирәксә бәхәскә кереп китәргә дә яраталар. Алар арасыннан үзләрен өстен тотулары һәм кискен чыгышлары белән бигрәк тә ТКУ студентлары аерылып тора иде.

Дәүрәк язучылардан Шамил Усманов, Фәтхи Бурнаш, Кәрим Әмириләрне мин монда очратмадым. Шулай ук Галимҗан Ибраһимов, Фатих Сәйфи-Казанлы, Кәрим Тинчурин кебек зур язучыларның да килеп чыкканнары булмады. Бу, әйткәнемчә, бары яшьләр җыелышы гына иде. Төп ядрәсе дә аның Такташ, Нәҗми, Кутуй кебек 25 тән узмаган язучылар иде. Шул ук елнымы, әллә соңракмы, ул җыелышлар «яшь язучылар түгәрәге» дигән исем белән йөртелә дә башлады.

Һәр җыелыш кемнең дә булса берәрсенең күтәреп килгән әсәрен укудан башлана. Аны бик игътибар белән тыңлыйлар. Аннары инде сүз китә, сүз кыза, бәхәсләр кабына. Ул чакта ни сөйләсәң дә ярый иде кебек. Ягъни шул заманның әдәбиятындагы төрле агымнарга иярүчеләр һәркайсы үз юлын аклый, яклый һәм башкаларга да тагарга тырыша. Тарихтан мәгълүм ки, бездә ул чакта Кутуйны футурист, Нәҗмине имажинист, Такташны символист дип йөртәләр иде. Мәгәр агымнары төрле булса да, максатлары бер: иң элек аларның һәркайсы иске әдәбияттан баш тарта, иске язучыларның берсен дә үзе өчен авторитет дип санамый (хәтта Тукайны да). Һәркайсы иске буржуаз әдәбияты урынына яңа, пролетариат әдәбияты булырга тиеш дип бара, шуны кайгырта, шуның өчен җаны-тәне белән көрәшергә әзер тора. Аннары инде һәркайсы яңа эчтәлекле яңа форма кирәк дигән карашны алга сөрә. Ә нинди форма пролетариат әдәбиятына яхшырак туры килә — менә бу мәсьәләдә инде алар кылычларын уйната башлыйлар. Һәркайсы үзенекен мактый, башкасын яманлый, бары үз «агымы» өчен сугыша. Хәер, сугыша дип әйтү артыграк булыр, чөнки алар үзара бик дуслар, бер-берсенә сәяси гаеп тагу юк әле ул чакта, кызып бәхәсләшәләр дә көлешә-көлешә таралышалар.

Күп нәрсәдән хәбәрсез булганга күрәдәр инде, мин ул җыелышларда сөйләгәннәрнең барысын да аңлап та бетерми идем. Мәсәлән, нәрсә ул имажинизм? Кайдан килгән нинди җәнлек?.. Күпме ишетсәм дә, ачык кына белә алмадым мин аны. Мәгәр җыелышларның барышы, кабатлап әйтәм, бик кызыклы иде. Катнашучыларның «исемле» яки «исемсез» булуларына карамастан, үзләрен бер тигез итеп тотулары, берәүдән дә курыкмыйча иркен-кыю сөйләүләре, авторитетлар белән дә артык хисаплашмаулары миңа да ошап киткән иде (дөрес, мин моңарчы күбрәк иске әдәбиятны укып үскәнгә күрә, иске язучыларның, Галимҗан Ибраһимовтан кала, һәммәсен дә диярлек себереп түгүләрен ничектер күңелем белән кабул итеп бетерә алмый идем. Ләкин моны барысы да пролетариат әдәбияты хакына эшләгәч, бәлки шулай кирәктер, шунсыз булмыйдыр дигән уй да ирексездән башка килмичә калмый иде).

Җыелышларның әнә шул хөрлеге белән мавыгып булса кирәк, мин дә бер килүемдә кул күтәреп сүз сорарга җөрьәт иттем. Дәүләкәндә яза башлап та Казанга килгәч бетергән бер әйберем бар иде — менә шуны мондагы дәү абыйларга, әйдә ни булса ул дип, тәвәккәлләп укырга булдым. Миңа рөхсәт иттеләр, исем-фамилиямне сорадылар. Тордым, кулымдагы озын кәгазьләрне калтырата биреп, кызу гына укый башладым. Бик ашыкканга күрәме, мин

үземнең ничегрәк укуымны да, хәтта тавышымны да юньләп ишетмәдем дә диярлек. Ләкин мин тотлыкмыйча тиз укырга күптән өйрәнгән идем инде. Бәлки шуңадыр, мине тынлык саклап, игътибар белән тыңладылар кебек — һәрхәлдә, шулай тоелды миңа укыган чагымда. Ә менә укып бетергәч, кемнең дә булса сорау бирүен яки торып берәр төрле фикер әйтүен белмим, юк, һич кенә дә хәтерли алмыйм. Әмма бер нәрсә бик нык хәтеремдә торып калды: Гомәр Гали дигән язучы кулымдагы кәгазьләрне: «Кая, энекәш, бу нәрсәңне миңа биреп җибәр әле»,— дип, миннән сорап алды. Мин аның «Безнең юл»да эшләгәнен белми дә идем, ләкин абый кеше сорагач бирдем дә җибәрдем. Ни өчен, нинди максат белән алганын сорап та тормадым... Ә күпмедер вакыттан соң Гомәр Гали минем шул әйберемне, яртылаш кыскартып, «Озын көй тыңлаганда» дигән исем белән «Безнең юл»да басып та чыгарды. (1926 ел, март саны)... Һич көтелмәгән гаҗәеп бер эш булды бу минем өчен... Беренче тапкыр дөньяга басылып чыгуым, җитмәсә, «Безнең юл» кебек иң дәрәҗәле, иң күренекле бер журналда!.. Әгәр шул санны ачып карасагыз, сез анда Галимҗан Ибраһимов һәм Габдрахман Сәгъди мәкаләләрен, Такташ, Кутуй, Туфан шигырьләрен, Толымбай, Гомәр Гали хикәяләрен күрерсез — әнә кемнәр арасына килеп кергән бит без фәкыйрегез дә!..

Билгеле, минем шатлыгым баштан ашкандыр инде, ләкин озакка бармагандыр дип уйлыйм. Чөнки журнал битләрендә чыгу ничектер җиңел иде ул чакларда. Әнә күрдегез, бер Гомәр Галинең теләге җитте минем әйберне журналда басу өчен... Һәм әнә шулай ансат кына чыгып, тиз арада танылып китүчеләр дә аз булмады — яшь көчләр өчен әдәбиятка киң юллар ачылган иде бу бик кызыклы һәм шау-шулы вакытта...

Инде минем әйбернең үзенә килгәндә, ул шәкертләрчә ияреп язылган нәсер сыман бер парча иде. Эчтәлеге болай: Шәйморат исемле башкорт агае кырын ятып, озын көй тыңлаганда, үзенең үткәнен — бишенче ел революциясе вакытында җирле алпавытка каршы баш күтәрүен, шуның өчен төрмәләрдә утыруын, Себер җибәрелүен, анда күргән газап-михнәтләрен күз алдыннан кичерә. Бу, әлбәттә, миңа китаптан күчкән (революциясен дә, алпавытын да, төрмәсен дә минем бит күргәнем юк). Әнә шул укып-белгәнемне озын көй белән бәйләп, аңа сыйнфый мәгънә салып, язып чыкканмын инде. Бәлки шуның өчен ул журналга кереп тә киткәндер. Әгәр дә ки мин моңлы башкорт көен тыңлаганда үзем ниләр кичергәнемне язсам, ул нәрсә, ай-һай, болай ансат кына үткән булыр идеме икән әле?!

Кыскасы, уйламаган-көтмәгәндә генә мин әдәбият дөньясына беренче адымны атладым. Һәм, әйтергә кирәк, бу минем иң җиңел адымым булган икән. Башка инде ул кабатланмады.

* * *

1926 елның июнь башларында без, өйләребездән бергә чыгып киткән ике егет, шулай ук икәү бергәләп Дәүләкәнебезгә кайтып китәргә булдык. Фәтхелисламның укулары тәмамланды, ә мин эшләгән җиремнән расчет алдым. Язга чыгу белән, үпкәләремнең начарлануын сизеп, Әбүбәкер абзый Терегуловка күренгәч, хәтерлисездер, ул миңа тизрәк Дәүләкәнемә кайтып китәргә кушкан иде. Ә законлы отпускага бик ерак иде әле, шул сәбәпле китап кибетеннән аерылырга туры килде. Без инде болай да Дәүләкәнебезне бик сагынган идек, һәм, озын юлга күп вакыт әрәм итмәс өчен, әкрен йөзгән пароходка утырмыйча, кызу чапкан поезд белән кайтуны артыграк күрдек. Рузаевкада Уфа якларына китүче поездга күчеп утырганнан соң, Самара аша тәүлек ярым дигәндә, үзебезнең кечкенә станциябезгә кайтып та төштек (ә пароход белән Уфа аша кайтканда, биш тәүлек киткән булыр иде).

Ахрысы алдан хәбәр иткәнмендер инде, каршы алырга атакай белән энем станциягә килгәннәр иде. Беренче мәртәбә читтән, ерак җирдән кайтканга күрә, алар мине чак күтәреп кенә алмадылар. Мондый сөенечле, мондый бәхетле каршы алуны мин бүтән татымадым да шикелле — хәтта сугыштан исән-сау кайтып кергән чагымда да! Мин әле Дәүләкәнгә беренче кайтуымда газиз бала идем, дөрес, буй җиткән, инде үз көнемне үзем күрә башлаган, әмма барыбер кадерле — газиз бала идем. Ихтимал, атакайның бу хәтле шатланып каршы алуында сагыну гына түгел, мине егет итеп күрү горурлыгы да булгандыр... Инде өчәүләшеп өйгә кайтып кергәч, инәй бичара, сүзен дә әйтә алмыйча, юеш иреннәре белән минем битемнән үбеп алды. Сабый чагымда үпкәннәрен хәтерләмим, соңыннан күпме җирләрдә йөреп кайткан чакларымда да мине

болай үпкәне булмады — бердәнбер онытылмыйча сакланганы шушы беренче кайтуымда кабаланып, ыңгыраша биреп үбүе булды. Тамгасы битемдә калмаса да, күңелемдә гомерлеккә җуелмаслык булып калды.

Мин Казаннан матурланып кайткан идем. Буйга да сузыла төшкәнмен, чәчләрем дә алкаланып тора, битем дә чәчәктәй бик чиста — әлхасил, малай чакның «кытыршылыклары» бетеп, нәфис кенә, нечкә генә егет булып киткәнмен... Әнинәй, бичара, кечерәйгән, инәй, бер могҗизага караган шикелле, миңа түбәннән авыру күзләре белән исе китеп карый («Матурлык» хикәясен исегезгә төшерегез). Гүя ышанып та бетә алмый — арык, чирләш малайдан бер ел эчендә шушындый бер сылу үсеп чыгар икән?!

Мин әзрәк мактанып ташладым бугай. Ләкин дөресе шулай, читтә уздырган елга якын вакыт минем егет булып өлгерүемне чынлап та тизләткән иде. Тик шунысы аяныч: Казан шикелле данлыклы бай каладан кайткан бу сылу егетнең кесә ягы бик такыр иде. Хезмәт хакым бәләкәй булгач, расчет вакытында миңа акча, билгеле аз тиде. Шул акчадан мин әле үземә чалбар белән ботинкалар да алдым (югыйсә, өстем бик хөртиләнгән иде). Инәйгә бүләк итеп, бер батист яулык та алдым, энемә дә нидер алдым бугай, тагын нәрсә? — бәлки кәнфит, хәлвә кебек әзрәк кенә күчтәнәчем дә булгандыр инде. Ләкин шулай да акчамны бөтенләй үк тотып бетермәскә тырышкан идем. Казан хәтле Казаннан бөтенләй үк буш кул белән кайтып керүнең оят булачагын мин, әлбәттә, аңлый идем. Һәм кесәмдә минем бер 7—8 сум акча да кайткан. Ул чактагы арзанчылыкта бу вак-төяк расходка җитәрлек ярыйсы гына «сәмән» иде.

Июнь аеның тансык матур көннәре... Тузып, искереп бетәргә өлгермәгән Дәүләкәнебез бер көе тын һәм тыныч кына яшәп ята. Ни шәһәргә әйләнмәгән, ни чын авыл булып кала алмаган тузанлы бу зур салалны ни өчен без шулкадәр яраттык икән?.. Беренче нәүбәттә бай табигате — якты Диме, киң тугайлары, камышлы күлләре, ак балыклары өчендер инде. Дәүләкәнгә кайту ул безнең өчен әнә шул байлыкка, гүзәллеккә кайту иде. Әйе, без, читкә китүчеләр, барыбыз да аңа гашыйк идек, аңа ашкына идек. Дәүләкән хакында мин күп яздым, яңадан кабатлыйсым килми, тик шулай да әйтмичә үтә алмыйм: әгәр миндә шушы көнгә кадәр Дәүләкәнне азмы-күпме сагыну тойгысы сакланып калган икән, ул башлыча минем Казаннан кайтып йөргән әнә шул 1926—1928 елларга туры да килә инде. Иң әлек бу еллар Дәүләкәннең иң тук, иң тыныч, иң имин вакыты иде. Базарлар бай, азык-төлек күп керә, шуның өстенә арзанчылык та. Билгеле, төрле кешенең хәле төрлечә, берәүләр таза, икенчеләр фәкыйрь тора, әмма ризыкка интеккән, хәерчелектә яшәгән кеше юк иде диярлек. Кечкенә урында аз гына хезмәт хакы алып эшләгән кешенең дә тамагы тук, өстенә киеме бар иде. Холера вакытында йорт башын югалткан ятим семьялар да, базарчы кертеп, тегермәннәргә капчык ямап, ару гына торып яталар иде.

Шулай ук безнең үз хәлебез дә бер дә зарланырлык түгел иде. Бурабай сыерыбыз бар, тавыкларыбыз бар, су буеннан әпен-төпен үрдәкләребез кайта. Шулар өстенә безнекеләр күркә дә асрый башлаганнар. Ишегалдында ата күркә яман кабарынып, «голдыр-голдыр» гайрәт чәчеп, озын сыйраклы котсыз чебиләрне саклап йөри. Ә бу чебиләр зурайгач, җилдән симерер өчен коймага, хәтта абзар кыекларына очып менә башлыйлар. Кыскасы, сөт, катык, каймак, йомырка — үзебезнеке, күпме ашасаң да җитәрлек, көн дә базардан берәр кадак яшь тәкә ите алып керәбез, шуның өстенә Акколайдан дус башкорт көн саен бер чирек кымыз да кертеп калдыра. Шулай итеп, мин атам өендә курортник булып ятам.

Бу имин, тыныч елларда Дәүләкәндә яшьләр дә күбәеп китте. Кичәге малайлар, үсмер кызлар бүген инде егетләр һәм туташлар булып җиттеләр дияргә дә ярый. Искеләргә бу яңалар да кушылып, Дәүләкәнне бөтенләй җанландырып җибәрделәр. Һәртөрле уеннар, күңел ачулар, концерт-спектакль куюлар шушы чакларда аеруча бер көчәеп алды. Яшьләр арасында татулык бар иде әле, иҗтимагый нигездә дошманлашулар үзен артык сиздерми иде — мондый хәлләр соңрак, 28—29 еллардан башлап, кинәт бик куәтләнеп китте.

Ярар булмаса... Инде әлеге кайтып-китеп йөрүләрдән күңелдәниләр генә сакланып калды соң?.. Бу бит минем егет булып өлгергән, көч җыеп чибәрләнгән елларым иде. Бер дә бетмәс-үтмәстәй булып тоелган, әмма очкан коштай үтеп киткән яшьлегем!.. Барысы да булып узды гомернең төштәй иң кыска шушы дәвере эчендә — татлы хыяллар, яшерен өмитләр, керсез дуслыклар, уңышсыз мәхәббәт, сызлану-сыкраулар, дөньяны бары якты, кешеләрне бары яхшы итеп күрергә теләүләр һәм шул ук кешеләр тарафыннан кагылу-сугылулар — әйе, барысы да булып узды... Һәм шушы төрлесен татырга туры килгән бик кыскатыгыз дәвернең Дәүләкәнгә тигән өлешендә минем өчен баштагы бер-ике елы

гына азмы-күпме искә төшерерлек һәм сагынып сөйләрлек булып калды. Хуш, нәрсә минем исемдә соң, нәрсәне мин хәзер дә сагынам?

...Ике ел рәттән без, Дәүләкән яшьләре, «Ачлы күлгә» бардык. Сезнең «сәхрәгә чыгуны» ишеткәнегез яки укыганыгыз бардыр — элекке заманда ял итү, күңел ачу өчен табигатьнең иркен, матур бер җиренә аш-сулар белән чыгуны әнә шулай дип атыйлар иде. Менә без дә мәшһүр күл буена өч көнгә сәхрәгә чыгарга булдык. Моны Дәүләкән тегермәннәре биргән акчага комсомол оештырды (Дәүләт кулына күчкән зур тегермәннәр акчаны комсомолга «агарту эшләре» өчен бирә торган булгандыр инде). Башта, билгеле, актив тарафыннан зур гына хәзерлек үткәрелде. Егетләрдән һәм кызлардан концерт программасы да төзелде (бер-ике авылга да керергә тиеш идек). Шулай ук азык-төлек, савыт-саба, балта-пычкы кебек кораллар да әзерләнде. Аннары «Ачлы күлгә» кемнәрне алып бару мәсьәләсе хәл ителде. Сайлаганда, иң беренче нәүбәттә әдәп белән дисциплинага игътибар ителде. Бигрәк тә әдәпкә таләп зур иде, чөнки халык арасына чыгабыз, ә комсомол үзен бу җәһәттән бик сакларга тырыша иде... Инде соңгысы — ничек бару мәсьәләсе. «Ачлы күл» Дәүләкәннән кимендә бер 25 чакрым булыр. Әйбер күп, күтәреп кенә барырлык түгел. Ул елларда әле аркага таудай рюкзаклар асып йөрүне белми идек. Димәк, атлар кирәк. Аларны атлы кешеләрнең малайларыннан сорарга туры килде: җигеп килсәң, барасың, килмәсәң — юк! диделәр аларга... Шулай итеп, унике җигүле ат Волкомол йорты янына җыелды. Бер-ике арбага бөтен әйберләрне төяп, шулар өстенә зур казанны да каплап, калган арбаларга дүртәр-бишәр кеше утырышып, җомга көн, сәгать уннар тирәсендә «Ачлы» тарафларына кузгалып киттек.

...Кырга чыккач та алдагы арбаларның берсендә гармун тартып җибәрделәр. «Җомга»ны сиптерәләр генә. Шунда ук арба тирәсенә җыр яратучылар җыелышып та алдылар, һәм китте җырлау, очынып-шашынып җырлау, аратирә өздереп сызгырып та җибәрү — һавадагы тургайлар тавышы да ишетелмәс булды... Бар иде ул чакларда Дәүләкәннең тургайлар белән ярышырлык җырчылары!..

Баручыларның иң күбесе минем чамадагы 17—18 яшьлек егетләр һәм кызлар иде. Арабызда иң зурлар Зөфәр белән Сәетгали булгандыр — алар инде егермедән узган комсомоллар, безнең белән җитәкчелек итүчеләр... Юл буенча диярлек гармун тавышы тынмады, җыр туктамады. Без, яшьрәкләр, арбаларга юньләп утырмадык та, кыр буйлап һаман куышып та чабышып бардык. Мин Гыйззетдин абзый кызы Мәрьямне куа-куа хәлдән таеп беттем. Бөтенесен кычкыртып куып тотам, ә бу болан баласын һич кенә дә житеп булмый бит... Кызганыч, спорт ярышлары булмаган без яшь чакларда. Хәзер инде Мәрьям дә — 75 яшьлек карчык... Шулай үтә икән ләбаса гомерләр!..

Төштән соңрак Корыятмаска барып җиттек. Бу «Ачлы күл» таулары артына, уйсурак җиргә урнашкан бер генә урамлы башкорт авылы — бәлки «Корыятмас» дигән исеме дә шуңардан килә торгандыр... Безнең җитәкчеләр шунда ук мондагы «активларны» эзли башладылар, кызларыбыз кайбер йортларга кереп, андагы кызлар, яшь бичәләр белән танышырга тотындылар. Ләкин бу бәләкәй генә авылда бернинди «актив» юк иде бугай, эзләсәләр дә, андыйны тапмадылар, әмма бераздан кызыксынып, сүзсез-йомык кына егетләр һәм кыюрак кызлар безнең тирәгә җыелдылар. Арага керергә дә, кермәскә дә белмичә, күзләрен ялтыратып, бер читтә генә өелешеп торалар. Аларны, әлбәттә, тартырга кирәк иде. Безнең кызлар урам чирәмендә түгәрәк ясап, чаштор-чоштыр биергә дә тотындылар, аннары барыбыз бергә «сакчылы», «әйлән-бәйлән» кебек уеннарны да башлап җибәрдек. Өелешеп, түземсезләнеп һәм чакыруны көтеп кенә торган авыл яшьләре, бер генә «әйдәгез!» дию белән, шунда ук уенга кушылып та киттеләр. Ул чакта әле авылның баерак кешеләрен ачыктан-ачык «кулак» дип атау юк иде һәм аларның кызларын, егетләрен дә арага кертәләр иде. Таңкәле җилән киеп, озын чулпылар таккан кызлар, кара чалбар белән күн итек кигән егетләр әнә шундый хәллерәк йортлардан килеп кушылганнардыр инде. Хәер, монда, өс-башы, торыш-кыланышы белән бер-берсеннән нык аерылып торганнар юк диярлек, барысы да һәр җәһәттән бер чамадагы шат күңелле тыйнак кына яшьләр иде... Шул рәвешчә, урам уртасында Корыятмас яшьләре белән бергә уйнап танышканнан соң, кызлары — кызларыбызны, егетләре— егетләребезне бүлешеп, үзләренә чәйгә дә алып керделәр. Читтән килгән үз ишләрен әнә шулай кунак итү — бу башкорт яшьләренең бер матур йоласы иде. Ә кичен, көтү кайтып, халык бушый төшкәч, кемнеңдер коймасы буенда, ачык һавада концерт та бирдек. Тамашага яшьләр генә түгел, өлкән агайлар, җиңгиләр, хәтта иңенә тунын салып, бабайлар да килгәннәр иде... Әйтергә кирәк, концертыбыз безнең шәп узды. Арада Гөлсем һәм Маһирә кебек матур җырчыларыбыз, Зөфәр кебек

оста гармунчыбыз, Әпәләй кебек бик шәп биючебез дә бар иде. Мондый концертның бу авыл тарихында беренче генә булуыдыр ахрысы, җыелган халык, хәтта тик тормас бала-чага да, бихуш булып, шылт та итмичә тыңладылар. Һәм безнекеләр дә кечкенә авылның йолдызлар да тыңлап торган зәңгәр күге астында, читән койма буенда, бер-берсен алыштыра-алыштыра, бөтен белгәннәрен, бөтен дәртләрен биреп бетерергә тырыштылар. Беренче этәчләр кычкырып, тынгач кына, йортларга таралыштык. Кызларыбызны өйләргә алып керделәр, ә без башкортның яшел «бесән» китереп өйгән абзар түбәсенә үрмәләдек. Арууалуыбыз шул дәрәҗәгә җиткән икән, хуш исле печәнгә бату белән сеңдек тә киттек. Иртән «җитәкчеләребез» уятып йөрмәсә, бәлки төш җиткәнче дә йомшак абзар башыннан төшә алмаган булыр идек.

Атларны җиккәннәр, урам буена тезелешкәннәр. Кырыклап кешенең җыелып беткәнен көтәләр. Өлкәннәребездән Зөфәр белән Сәетгали дә әле күренмиләр, ниндидер эш кырып йөриләр ахрысы... Чынлап та, бераздан алар таза гына бер йортның капкасыннан ике яшь тәкә күтәреп чыктылар. Бу ни хикмәт дип көтеп торабыз. Аяклары бәйләнгән тәкәләрне болар бер арбага китереп салдылар. «Нәрсә, әллә конфисковать иттегезме?» — дип сорыйбыз. «Юк,— диләр көлеп,— сез бирәннәрне сыйлар өчен тегермән акчасына сатып алдык»,— диләр. Алар моны Дәүләкәннән чыгып киткәндә үк уйлап куйганнар икән. Бер арбага каплап салган зур казан да шушы тәкәләр өчен, имеш!..

Әйтергә кирәк, ул чакларда акча тоту мәсьәләсендә контроль йомшак булса да, гаделлек бик көчле иде. Бер тиенне исраф итү юк, йомып калу да, әлбәттә, юк иде. Гомумән, акчага, байлыкка, зиннәтләргә табыну яшьләр арасында үзе бер начар эштән санала иде.

Ниһаять, унике ат тезелешеп, бу сөйкемле, тын авылдан чыгып киттек. Корыятмас яшьләре арбаларыбызга тотынып, авыл очына кадәр озата бардылар. Әмма аларның берсе дә, чакырып карасак та, «Ачлы күл»гә хәтле барырга җөрьәт итмәде. Күрәсең, алар «комсомолга ияреп» китәргә әле өлгереп җитмәгәннәр иде.

«Ачлы күл», таулар аша туры гына барганда, Корыятмастан ерак булмаска тиеш. Ләкин ат юлы шактый урау булып чыкты. Бара-бара төш вакыты җитә язды. Ахырда бер калкулык өстеннән алдыбызда кинәт кенә күлнең бер башы ачылды. Без инде аңа килеп тә җитә язганбыз икән — түбәндә генә тип-тигез су өсте көмештәй тонык кына ялтырап ята.

«Ачлы күл» түгәрәк түгел, ә озынча күл — буе сигез чакрым чамасы, иңе өч чакрым булыр. Даны еракларга таралган бу күлне беренче мәртәбә күрүем. Әмма шулай да «Ачлы күл» миңа бик таныш кебек, чөнки аның хакында күп ишеткәнем бар. Аннары Мәҗит Гафуриның «Зыятүләк белән Сусылу» әкияте буенча да ул минем хыялыма нык кереп калган иде. Халык арасында таралган даны исә, беренче нәүбәттә, бу күлнең шифалы булуына ышану белән бәйләнгән. Якын тирәдән генә түгел, ерак авыллардан килеп тә аның комында күмелеп ятканнар һәм гаҗәеп саф, йомшак суында коенганнар.

Күлнең көньягында да тау, төньягында да тау — гүя ул кайчандыр тоташ булган зур тауны икегә аерган да шуларның уртасына кереп яткан. Әнә, каршыда гына «Нора» тауның күлгә киселеп төшкән текә кызыл яры да күренеп тора. Мәгәр каршыдагы «Нора» белән бирге яктагы тау кайчандыр бер бөтен булгандыр дип күз алдына китерүе читен. «Нора» — шәп-шәрә ялгыз тау, ә монда таулар өстендә таулар өелеп тора. Алар биекләр, аларның күл өстендә үк стенадай басып торганнары бар, шулай ук күлдән читенеп, киң аланлык ясаган урыннары да бар. Кыскасы, без килеп туктаган бу якның таулары да мәһабәтматур, иркен аланлыклары да куе үлән, эрәмәлек карт агачлар белән капланган... Һәм бары бу якта гына кайчандыр текә таулардан кубып төшкән зур өстәл, хәтта кечерәк келәт хәтле кызгылт ташлар да күл читендә генә яталар. Шул ташларның суга кереп торган берсендә Сусылу чәчен тарап утырган имеш (аны хәзер дә «Сусылу ташы» дип йөртәләр икән). Күл асты патшасының бу сылу кызы шаһзадә, Түләкнең үзенә якынлашуын сизгәч, таштан тизрәк суга сикергән, ләкин озын кара чәчләре күпмедер вакыт су өстендә батмыйча торган, менә шул чакта егет тә тиз генә сикереп, кызның батарга өлгермәгән чәчләреннән эләктереп алган да Сусылу артыннан күл төбенә төшеп тә киткән имеш!.. Әнә шулай сакланып калган минем хәтердә Гафури кулы белән язылган әкиятнең кызыклы бер күренеше!..

Хуш, ә без күлдән аз гына өстәрәк, тау итәгенең яшел чирәмле тигезрәк бер җиренә чегән табыры булып урнаштык. Әйбәт урын, су да якын, яр кырында куе эрәмәлек тә бар, читтәрәк ялгыз карт агачлар да үсеп утыра — тагын ни кирәк?! Атларны тугардык, әйберләрне бушаттык. Ләкин башка эшләргә тотын-

ганчы, барыбыз бердән кубып, иң элек су керергә төштек.

Күлнең чите буеннан-буена тыгыз ак комлык. Ул шундый чиста ки, адәм ташлап калдырган бер генә чүп тә тапмассың монда!..

Әйткәнемчә, зур күлнең бөтен әйләнәсе ак комлык. Төбе тап-такыр... Бер җирендә дә камыш үсми, бер генә төшендә дә мәте юк. Чөнки күлнең бөтен әтрафы тирән кермәгән чирәм җир. Туфрак та, чүп тә аңа агып төшмәгән. Башкортлар күлне әнә шулай саклаганнар. Үзләре дә аның ярына утырмаганнар һәм читләрне дә җибәрмәгәннәр. Мәгәр революциягә чаклы ук әле «Нора» тау яклап, күлнең көнчыгыш очына бер рус авылы килеп утырган (рөхсәтсез утырган дип әйтәләр иде). Исемен дә инде хәтерләмим, ләкин без барып йөргән вакытларда шушы салам түбәле бик озын авыл гына «Ачлы күл» буен «бизәп» тора иде.

Су кереп чыккач, безнең барыбызны да яңадан «мәйданга» (яр башына) җыйдылар. Килмичәрәк торганнарны кычкырып, дәшеп алдылар. Сүз җитди булды, җитәкчеләр тарафыннан таләпләр каты куелды. Бөтен эш — ашау-эчү, су керү, уеннар оештыру, тауга менү, кырда йөрүләр — бары бергә, бары бер үк вакытта гына булырга тиеш. Таралышып йөрүләр, төркемнән аерылып китүләр, бигрәк тә парлап йөрү катгый рәвештә тыела. Бу соңгысы әллә ничек сәер дә иде. Ни өчен егет белән кызга кайчагында икәүдән-икәү генә сөйләшеп йөрергә ярамый?.. Моның ни гаебе бар? Әмма юк, ярамый, бу коллектив, коллективтан берәүнең дә аерылып йөрергә хакы юк, янәсе.

Без «Ачлы күл» буенда ике көн яттык. Ничек ял итүебезне, ниләр эшләвебезне тәфсилләп язып тормыйча, җыеп кына әйткәндә, вакытны монда гаять күңелле уздырдык. Безнең бәхеттән бу ике көн гел аяз, гел эссе булып торды. Көне буе диярлек судан чыкмадык, җылы комда аунадык. Һәм шушында ята торгач, бер зур гына фәүкылгадә бер вакыйга да булып алды. Хөсәен исемле иптәшебез тоткан да күлнең аръягына ялгызы йөзеп чыгып та киткән. Егетнең чыгып киткәнен без соң гына шәйләп алдык — күл уртасына таба бер кара нокта бара да бара: нәрсә бу, кем бу? Хөсәен күренми, Хөсәендер, мөгаен, диделәр. Аптырап калдык, курка калдык, ә башлыкларыбызның гаять ачуы килде. Йодрыкларын төйнәп, авыз эчләреннән генә сүгенеп, су читендә арлы-бирле йөрергә тотындылар. Ләкин егетне кычкырып та, сызгырып та туктатып булмаячак — ул инде бик ерак киткән иде. Бөтенебез су читенә тезелешеп, һаман ераклаша барган «кара ноктага» карап торабыз. Кайбер кызларыбыз шыңшый да башладылар... Бер дә кызыклы тамаша түгел шул, күңелгә төрле шомлы уйлар да килә — ни булып бетәр моның ахыры?..

Ике егетебез аның артыннан йөзеп китмәкче дә булганнар иде, ләкин башлыкларыбыз җибәрмәделәр: берәү урынына өчәү батсагыз, бик күпкә китәр диделәр. Мәгәр Хөсәен арабызда яшькә олырак та, тазарак та һәм тыйнаграк та егет иде. Үз хәлен, үз чамасын белмичә, башбаштакланып кына ул мондый хәтәр эшкә бармаска тиеш иде, югыйсә. Башына тай типмәгән булса!..

Һәм менә бервакыт «кара нокта» күздән дә югалды. Кая китте, ни булды — без хәтта тын алудан туктадык. Күп тә калмаган шикелле иде бит, күп тә... Ә бераздан күлнең аргы читендә нечкә генә бер карачкыл күренде. Әнә безгә карап, кулын да күтәрде бугай... Бу ул, бу Хөсәен! — шатлыктан без дә кулларны күтәреп, аңа «ура» кычкырдык. Бер мизгелдә курку, шомлану, ачу — барысы да юкка чыкты. Алар урынына һәркайсыбызда ирексездән соклану, горурлану, хәтта «аның урынында нигә мин түгел» дигәнрәк көнләшү дә туган кебек булды.

Ә кичкырын бөтенебезне җыеп, Хөсәеннең бу кыюлыгын бик каты хөкем итү булды. Әгәр дә мәгәр яңадан мондый башбаштаклык эшләсәң, белеп тор, беркая да алып чыкмыйбыз, ияртмибез диделәр аңа. Хөсәен тезләрен чәнчеп җиргә утырган килеш бөтен шелтә-тиргәүләрне ничектер иренеп кенә тыңлады. Үзен аклап, бер сүз дә әйтмәде... Әмма күпме генә шелтәләмәсеннәр, аңа сокланып карамыйча мөмкин түгел иде. Һәм соңыннан да барысы онытылып, тик Хөсәеннең «Ачлы күл»не иңләгән» дигән даны гына торып калды.

Монда бик мөһим бер нәрсәне әйтәсе калган икән әле... Теге Корыятмастан алып килгән ике яшь тәкәне беренче көнне үк Сәетгали белән ике егет читтәге карт имән төбенә илтеп суйдылар, әйбәтләп тунадылар, түшкәсен бүлгәләп, кызларга бирделәр. Ә кызларыбыз ике көн рәттән зур казанда ашын пешерделәр. Ачык һавада, яшел чирәмдә әкрен генә кайнап пешкән тәкә итенең һәм шулпасының тәмлелеген әйтеп кенә бетерерлек түгел иде. Торыпша җәйгән зур табын әйләнәсенә аяк бөкләп яки кырын ятып ашаган бу ашны соңыннан да берәү дә тиз генә оныта алмагандыр. Әле шуны да әйтергә кирәк: монда бернинди эчү дигән нәрсә юк. Аны уйлаган, теләнә алган кеше дә юк. Комсомол

абыйлар тыйганга күрә генә түгел, ә эчүнең тәмен, нәрсә икәнен белмәгәнгә күрә... Без яшь чакта аракыны өйгә дә кертмиләр иде. Агудан сакланган шикелле аңардан саклыналар иде. Эчкән кеше — беткән кеше дип әйтә торган иде минем атакай да... Шуның өстенә мәдрәсәдә укыганда хәмер эчүнең шаригать тарафыннан катгый рәвештә тыелганын, «билкөлли харам» икәнлеген, аны истигъмал итүчеләрнең туп-туры җәһәннәмгә озатылачагын безгә тукып кына тордылар... Шулай итеп, ата-ана тәрбиясе, шаригать куркытуы һәм комсомол тыюы безнең дәвердә бер вакыткарак туры килде. Шуңадыр ахыры, без озаграк «бозылмыйча» тордык. Безнең арада бер генә тәмәке тартучы да юк иде әле — әнә нинди саф чакларыбыз булган икән ләбаса!

Өченче көнебездә кояш белән бергә торып, сулар кереп, чәйләр эчкәннән соң, кайтырга җыена башладык. Атларны җиктеләр, әйберләрне арбага салдылар. Бу эшләрне бетергәч, гүя саубуллашыр өчен, барыбыз да күл читенә җыелыштык. Кызларыбыз суга таңкә дә ташладылар: «Хуш инде, Ачлыкай, үпкәләп калма»,— диделәр аңа, тере җан иясенә дәшкәндәй... Кузгалып киткәч тә, без һаман әле артыбызга борылып карый-карый бардык. Тик серле, тын күлебез тау артына күмелгәч кенә аерылышуыбыз белән килешкәндәй булдык.

Кайтканда да юл буе җырлаудан, уйнаудан, төшеп йөгерешүләрдән туктамадык. Һәм шунысы кызык: кайткач, тәмам сеңеп йоклавыма карамастан, минем колагымда берөзлексез әкрен генә гармун тавышы һаман чыңлап торды. Гүя су өстендә чайкалган шикелле музыка кочагында тибрәнеп йоклыйм, имеш!.. Өч көн буена тыңлаган җыр-гармун тавышы кешегә бу кадәр дә сеңәр икән?!

...Еллар узды, күп хәлләр онытылды, ә менә «Ачлы»га барып кайтуыбыз онытылмый, хәтерләрдә һаман да саклана. Хәзер инде ул «баруларга» катнашкан, уйнаган-көлгән, җырлаган-биегән яшьләрнең күбесе юк, үлеп беттеләр. Мин исән дә, тагын өч кенә кешене беләм: Маһирә, Мәрьям һәм Гөлсем карчыкны... Тик менә Гөлсемне егерменче елларның ахырыннан бирле күргәнем юк. Төсе-бите белән чибәр, японкаларга охшаганрак, бик сөйкемле һәм нечкә җанлы кыз иде ул... Бик матур җырлый да иде. Спектакльләр куйганда, беренче героинябыз иде... Күпләр аңа гашыйк та иде... Чәчәктәй нәфис, нечкә хисле кызыбыз ниндирәк икән менә хәзер... Күрәсе дә килә, күрергә дә куркам. Бәлки минем үземә дә күренергә кирәкмидер инде. Барысы да искечә, «Ачлы» буйларында йөргәндәгечә генә саклансын — шулай кадерлерәк.

Яшьлек, саф, пакь, гөнаһсыз яшьлек таң алдыннан күргән кыска төш кебек кенә булып калды. Әмма яшьлекнең үзен сагынудан да бигрәк, минем өчен иң мөһиме яшьләр арасындагы татулык иде. Без әле бер-беребездән читләшергә, ятлашырга, хәтта дуслык җепләрен дә өзәргә өлгермәгән идек. Тик нихәл итәсең, озакка бармады бу дәвер. Ике-өч ел да үтмәгәндер, яшьләрнең шактый өлеше, көчле җил туздыргандай, төрле якка чәчелеп тә бетте. Кайберләренең кая киткәнен дә белүче булмады.

*Ахыры бар.*

# Шәмсия Җиһангирова

«Давылларга каршы
Бер ялгызым барып,
Берчак, түзәлмичә,
Туктамаммы арып?

Сынмасмы күңелнең
Иң нечкә кыллары?
Җитәкләп барыр соң
Мине кем куллары?

Ыргытмасмы язмыш
Тирән упкыннарга?!» —

Дип, минме кайгырыйм
Синдәй ярым барда?!
Синдәй парым барда?!

Күзенә карыйм да
Асылын белергә тырышам
Юлымда очраган кешенең:
Бу нинди кеше дим,
Мин белгән кешеме?
Әллә соң эчендә
Бөек сер йөртәме?
Бүгене нindирәк?
Нindирәк үткәне?
Ышанасым килә,
Бушанасым килә
Сыенып кешегә —
Нәкъ синдәй кешегә,
Нәкъ миндәй кешегә —
Нәкъ бездәй кешегә...
Кайчакта минем дә
Күңелем күшегә —
Мин дә бит кеше лә!
Гап-гади кеше лә!

Карыйм да ... үземә
Мең сорау яудырам:
Бу нинди кеше дим.
Зур микән
Күләме эшенең,
Замана
Бизмәнгә салдырса?
Ут йота микән дим,
Ялгышып, аз гына
Кешенең хәтерен калдырса?
Сораса кешелек
Нindирәк кеше дип,
Әйтерлек булсын дим
Бер дигән кеше дип,
Мәкерсез эче дип.
Нәкъ синең төсле дип,
Нәкъ минем төсле дип,
Нәкъ безнең төсле дип.
Иң кирәк чагында
Таяныр кеше дип...

Күзенә карыйм да
Очраган берсенең,
Асылын белергә тырышам
Гап-гади кешенең —
Нәкъ үзем ишенең,
Нәкъ синең ишенең,
Нәкъ безнең ишенең...

ШӘМСИЯ ҖИҺАНГИРОВА — *«Төсле моң» исемле шигырь китабы авторы. Проза жанрында да эшли. Казанда яши.*

❁

*Сагышларым адаштырыйм*
*Каеннар арасында...*

Г. Мөхәммәтшин

Сөю сагышларым белән
Яшәүдән тәмам арып,
Ияртеп бер көн үзләрен
Урманга киттем алып...

Килеп кергәч урманнарга —
Куесы, карасына,—
Сагышларым адаштырдым
Каеннар арасында...

Йөгереп чыктым болыннарга,
Алсу гөлләрен өздем,
Челтерәп аккан чишмәләрнең
Суларын эчеп йөрдем.

Шул көннән соң минем барча
Эшләрем уңга китте.
...Бәхеттән шашып йөргәндә,
Каеннар искә төште.

Йөгереп барып урманнарга,—
Куесы, карасына,
Сагышларым эзләп таптым
Каеннар арасында.

Минем сагыштан каеннар
Саргайганнар, кипкәннәр,
Кайгылардан кангырышып,
Җиргә кадәр чүккәннәр.

Сагышлардан сарыларга
Сабышса да йөзләрем,
Мин бит каеннар шикелле
Сынмадым, бөгелмәдем...

Каеннарның үземнән дә
Көчсезлеген аңладым;
Сагыш-кайгыларны кире
Үз йөрәгемә алдым.

Үземдә генә торсыннар,
Беркая китмәсеннәр.
Миннән башка беркемне дә
Моң-зарлы итмәсеннәр...

❁

Хәтәр сүздән, хәнҗәр сүздән
Хайран булдым, калдым өнсез.
Өзелеп сөйгән ярым булса,
Әйтер идеме авыр сүз!

Борылды да китте үзе —
Әйтерсең, берни булмады.
Гамьсез бер сүз йөрәгемнең
Ярты ягын уеп алды.

Яман бер сүз, хәтәр бер сүз
Таштай итте, күңел сине...
Өзелеп сөйгән ярым булса,
Әйтмәс иде мондый сүзне...

❁

Яз иде бит әле,
Яз иде бит!
Кай арада сары көз җитте?
Тәрәзәгә карап уфтандым мин:
Булды да бетте дип,
Булды да бетте.

Бала идем әле,
Бала идем!
Кайчан гомер уртасы җитте?
Яшьлегемне сагынып уфтаныйммы:
Булды да бетте дип,
Булды да бетте...

Үтеп китәр гомер,
Үтеп китәр
Йөгереп кенә үткән яз төсле.
Уфтанмаска иде, үкенмәскә! —
Булды да бетте дип,
Булды да үтте...

Яз иде бит әле...

**Мәдинә Маликова**

# БАСЫП САЙРАР ТАЛЫ БАР

РОМАН

## 1

Бу — минем сыналыр чагым,— диде Сафия үз-үзенә.— Язмышым, киләчәгем хәл кылыныр вакыт. Тик нишли алам соң мин? Кемгә бара алам?..

Тирәсендәгеләр, шаулашып, урыннарыннан кузгала башлагач, ул үзен кулга алырга тырышты: артык дулкынланганыңны сиздерергә ярамый иде. Сумкасын актарган булып, ишеккә юнәлде, кемгәдер орынып узды. Даян икән.

— Сафия, ә син нишләп бер сүз дә әйтмисең?

Сафия тыныч кыланып:

— Әйбәт ич...— диде.

— Әйбәт кенәмени? Ошатмагансың инде алайса. Башка чакта болай гына чыгып качмый идең...

Даян үпкә-рәнҗү аша елмаерга тырышып калды, Сафия китү ягын карады.

Өйгә кайтырга, тизрәк ялгыз калырга.

Тар бүлмәсендә ул ишекле-түрле бик озак йөренде, үз-үзенә урын тапмады, нишләгәнен, ни ашап-эчкәнен аңламады. Ниһаять, болай бер ялгызы бәргәләнеп йөрү дә бик авыр була башлады, аңа кем беләндер серләшергә, эчен бушатырга кирәк иде. Ләкин кемгә барып сыенырга? Тәүлекнең иң ямансу һәм авыр чагы — төн уртасы житкән иде инде.

Сафия, ярдәм эзләгәндәй, як-ягына каранды һәм, стенадагы рәсемгә күзе төшеп, тукталып калды. Менә бит, бар бит аның якын кешесе, ничек әле ул оныткан? Беркая барасы, беркемне борчыйсы юк. Бөтен серләреңне яшермичә сөйләргә була. Хат аша.

Ул өстәлдәге китапларны читкәрәк этәрде дә кулына каләм алды.

«Мине бүген күрсәң, син шиксез: Ни булды? — дип сорар идең. Вакыйга шул: безнең театрда яңа пьеса укылды. Башка берәү моны ишетсә, көләр генә, билгеле: «Харап икән! Сезнең театрда елына ун пьеса укыла торгандыр, эшегез шул ич сезнең!» — дияр. Ләкин син мине аңлар идең. Мондый пьесаны безнең Даян Ризванов кебек драматург гомерендә бер генә яза ала һәм аны сәхнәләштерү бәхете дә режиссер Әнвәрбәков кебекләргә бер генә тапкыр насыйп була. Андый спектакльдә уйнау да миндәй актрисаның сирәгенә эләгә.

---

МӘДИНӘ МАЛИКОВА *(1935) — прозаик, РСФСРның атказанган культура работнигы, журналистларның Х. Ямашев исемендәге премиясе лауреаты, «Шәфкать» романы, «Казан каласы — таш кала», «Янар таулар яктысында» повестьлары һәм башка әсәрләр авторы. Казанда яши.*

Шушы сирәк, бик сирәк очрый торган бәхетне өмет итә минем күңел!

Пьесаның төп герое — хатын-кыз. Аның илен дошман яулап алган. Рәхим-шәфкать белмәс илбасарлар ир-егетләрне кырып бетергәннәр, башы арба күчәреннән узган балаларны хәтта һәлак иткәннәр. Канга туенган җирдә, хәрабәләр арасында карт-коры, сабыйлар, хатыннар гына калган.

Менә шул хатыннарның берсе залим патшаның үзе белән йөзгә-йөз килеп көрәшкә чыга.

Бу язмыш минем өчен болытлы көнне яктыртып җибәргәндәй итте. Сиңа да ул бик якын тоелыр. Яуда һәлак булган эткәңне исеңә төшерер, дошман басып алган җирдә могҗиза белән генә исән калган әңкәңнең башыннан кичкәннәрне искәртер. Мин дә үз эткәм-әнкәмне уйладым. Алар кичергән дәһшәтләрнең ачысы безнең күңелләргә дә күчкән. Минем аны җанландырып, халык алдында бастырып күрсәтәсем, ул булып яшисем килә!

Тик... бирерләрме андый мөмкинлек?

Театрыбызның баш режиссеры ул рольне — Кадимбикә ролен миңа тапшырырмы, әллә башка берәүгәме? Артык дулкынлануымнан нишләргә белмәдем, үзенә барып әйтү җаен таба алмадым, аңа күңелем белән генә ялварам: «Миңа бир Кадимбикәне, миңа!» — дим. Ләкин алай ялваручы бер мин генәмени? Әгәр, бер могҗиза булып, шушы төндә Казан каласындагы барлык утлар сүнсә һәм Кадимбикәне уйлап янган йөрәкләр күзгә күренә башласа, шәһәрнең төрле төшләрендә шактый чаткылар шәйләнер иде, мөгаен. Артисткаларның кайсы гына андый роль хакында хыялланмас икән!

Әнвәрбәков үзе дә бу минутларда йоклый алмыйдыр, бу рольне кемгә бирәсен уйлыйдыр. Беренче чиратта ул, әлбәттә, иң яраткан актрисасы Исмегөлне күз алдына китерер, аннары Шәфика Абилованы. Ә мине, мине уйлармы соң ул?

Шушы соравыма җавап эзләп, син ясаган портретка карыйм. Ул нәкъ өстәл турында, каршымда эленеп тора. Ә нигә режиссер минем хакта уйламаска тиеш әле? Син мине диңгез буендагы бакчада, йөзләгән кеше арасында күреп алган идең бит. Хәтерлисеңме? Килдең дә: «Гафу итегез, сез һаман шушы эскәмиядә япа-ялгыз китап укып утырасыз. Ә мин артист халкын ялгызлыкны яратмый дип уйлый идем»,— дидең. «Минем артистка икәнемне каян белдегез?» — дип сорадым. «Килеш-кыяфәтегездән»,— дип җавап бирдең. Аннары портретымны ясарга рөхсәт сорадың.

Менә ул портрет — минем каршымда. Бакча эскәмиясендә утырган кызның йөзенә яфраклар арасыннан иртәнге кояш нуры төшкән. Түгәрәк ак йөз, калын иреннәр, кыеклабрак уелган күз кабаклары, зәңгәрсу рәшә белән тоташкан кара чәч бөдрәләре. Син минем йөземдәге шәрык чалымнарын бик ачык сурәтләгәнсең. Ләкин хикмәт анда түгел. Хикмәт шунда: әгәр сиңа ышансаң — мин бәхетле. Җәйге иртәне гөлбакчада каршы алган кыз бала үз агачына басып сайраган кош кебек бәхетле!

«Бу кыз Кадимбикәгә охшаганмы?» — дип сорадым мин үз-үземнән. Ә нигә охшамасын ди? Ул, бәлки иленә яу килгәнче, нәкъ менә шушындый булгандыр да.

Ләкин аның батырлыгын тасвирлау өчен миңа башка кыяфәт, башка хисләр, яңа көчләр кирәк булачак.

Бармы алар миндә?

«Синең күп нәрсәгә көчең җитә, тик үз мөмкинлекләреңне белмисең бугай әле»,— дигән идең син.

Ә миңа үз мөмкинлекләремне белергә генә түгел, күптән файдаланырга кирәк иде инде. Утыз өч яшемне тутырдым бит инде! Утыз өч! Әйтергә генә ансат! Ә үзем теләгән роль уйналмаган, максатка якын да киленмәгән! Әгәр монысын да ычкындырсам, тагын кайчан андый мөмкинлек булыр?

Рәсемдә син кулларымны нык, көчле итеп сурәтләгәнсең. Һәр иртәне

акробатик күнегүләр ясавым юкка түгел икән. Борынгы заман кызлары хезмәт белән гомер кичергәннәр, аларның һәр хәрәкәте төгәл, ипле булгандыр. Ә мин нинди?.. Язуымнан тукталып, бер-ике сальто ясап алдым әле. Бик җиңел ясадым, үземне коштай хис итәм!

Ул минеке, минеке! Минем моңарчы яшәвем шушы рольне уйнарга әзерлек кенә булгандыр. Син миңа: «Бәхетле булачаксың»,— дигән идең. Болай гына әйттеңме, әллә белепме? Ә бәлки, син күрәзәчедер, тылсым көчең бардыр? Ул чакта күрсәт бер могҗиза: шушы төндә, шушы минутта Әнвәрбәковның күңеленә мине китер! Шул ераклыктан, телепатия көче белән аның зиһененә тәэсир ит! Мине уйласын ул, Кадимбикә ролендә мине күз алдына китерсен!

Безнең халыкта нәзер әйтү дигән сүз бар. Бу теләгем чынга ашса, фәлән кешегә фәләнчә яхшылык кылыр идем дип, үз-үзеңә вәгъдә бирүне аңлата ул. Мин дә бүген нәзер әйтәм: әгәр Кадимбикәне миңа бирсәләр, авылыңа барып, аны синең үзең өчен генә уйнап күрсәтер идем. Тик изге теләктә генә тор.

Шушы сәгатьтә, безнең арабызда меңнәрчә чакрым караңгылык булып яткан салкын төн аша, киң далалар, тирән дәрьялар, тынгысыз утларын җемелдәткән зур калалар, шомлы урманнар аша мин сиңа беркемгә әйтеп булмый торган иң яшерен хыялларымны ышанып тапшырам. Бу кичтә сүз кушарлык якын кешем юк бүтән. Бу кичтә мин әкрен генә син өйрәткән җырны көйләп юанам, шулай үз күңелемне үзем күтәрергә тырышам. Югыйсә иртәгәге көнне көтү газапларына түзә алмас идем. Дөньяда яшәвең өчен дә мең рәхмәт сиңа, безне очраштырып, шушы хатны язарга мөмкинлек биргән өчен мең рәхмәт язмышка...»

Сафия, хатны бөкләп, авиаконвертка салды да адрес язып, пальто җиңнәрен кия-кия, урамга атылып чыкты. Тышкы ишекне ачуга, кара көзнең ачы җиле тынны куырды. Ул якасын күтәреп, пальто чабуларын үзенә кысты. Шыксыз дөньяда күз кунарлык берәр ямьле тап эзләп, күккә карады. Анда, биектә йолдызлар, шәһәр утларыннан читләшеп, ерагайганнар, болыт пәрдәсе аша көчсез, кыюсыз гына карый, гүяки алар да салкын җилдән калтырана иде. Аларның хәлсезлеге Сафияне кинәт аңына китерде. «Изге теләктә тор», имеш! Бу хат кайчан барып җитә бит әле! Аңарчы Кадимбикәнең язмышы әллә кайчан хәл кылынган булачак инде!

Бу уй Сафиянең җанына көз салкыны булып үтеп керде, башны идерде, җанны куырды. Ул ишегалды аша үтте дә рәшәткәле тимер капкадан урамга чыкты, конвертны чаттагы почта тартмасына салды. Тартма боздай салкын иде.

## 2

Даян, тәрәзә пәрдәләрен ике якка ачып, тышка карады. Урамда кара көз. Усал җил әллә кайлардан ажгырып килә дә, шәрәләнеп, каралып калган агач ботакларындагы соңгы яфракларны йолкып алып, сәбәпсез ачу белән орып-бәреп алып китә. Багана башларыннан төшкән яктылык түгәрәгеннән очып үткәндә, ул яфраклар аеруча кызганыч булып күренә. Әле кайчан гына алар тирә-юньгә — ямь, күзләргә һәм күңелләргә — ял, эссе чакларда җиләслек һәм күләгә биреп торалар иде. Җанлы, җылы иде алар. Ничек шул кадәр танымаслык булып үзгәрә ала икән бу тереклек? Аның иң ахыргы үзгәрешләре нилектән шушы кадәр кызганыч һәм, әйтергә кирәк, ямьсез була икән? Нилектән?

Дөньяда көзге төн һәм ачы җил берләшеп алганнар да барча тереклек ияләре өстеннән рәхимсез хакимлекләрен урнаштырганнар иде кебек. Аларның шәфкатьсезлегеннән сыкранып чайкалган агачларның сагышлы шавы, ике кат пыяла аша саркып, күңелгә сеңә иде сыман. Даян, җанына ял эзләп, карашын каршы йортның тәрәзәләренә төбәде. Аларның кайсыннан зәңгәрсу, кайсыннан алсу яктылык бөркелә. Ул

тәрәзәләрне каплаган пәрдәләр артында җылыдыр, ямьледер. Язмыш дигәнең андагы кешеләрнең һәммәсе күңеленә сөенеч очкыннарын һәм хәсрәт ялкыннарын төрлечә өсти торып, һәр җанны үзенә генә хас утларда яндырадыр. Кемнәр яши анда, нишли алар бу минутта, ни уйлый, ни кичерә? Һәр кешенең башыннан мең әсәргә җитәрлек хәлләр кичә, дип кабатларга ярата Даян. Тик аларны тотып ала белергә, сәнгатьтә талантлы итеп күрсәтергә генә кирәк. Менә хәзер дә, аның уенча, каршы йортның тәрәзә пәрдәләре артында язучы өчен бетмәс-төкәнмәс хәзинә ята, тик аларны алып кына булмый...

— Әнә, безнең Исмегөлне күрсәтәләр.

Гайшәнең бу сүзләре Даянны сискәндереп, уйларыннан айнытып җибәрде. Хатынының тавышында, елмаю астында яшерен көнләшү чагылып узды. Даян, йомшак келәмгә тавышсыз гына басып, бүлмә уртасына чигенде. Почмактагы телевизордан аның йөрәк ярасы карап тора иде.

Менә ул, Исмегөл Солтанбаева, чакырганны да көтеп тормады, якты елмаеп, өйгә килде дә керде. Даяннарга гына түгел, миллионнарча кешеләрнең каршына кереп басты ул. Мәскәүдә әле генә тәмамланган яшь талантлар конкурсында өч артист җиңеп чыккан икән: ике егет һәм безнең Исмегөл. «Матур үзең, утә сүзең, СССРда бер үзең»...— дигән җыр килде Даянның күңеленә. Йөрәккә көз, төн һәм зәһәр җил салган авыр хисне пыяладан балкыган елмаюы белән генә дә юып алды Исмегөл.

Бөтенсоюз телевидениесе хәбәрчесе көйле, йомшак тавыш белән җиңүчеләрнең һәркайсыннан берәр генә сорауга җавап бирүләрен үтенде.

— Нинди роль уйнау турында хыялланасыз? — диде ул һәм микрофонын кызның нәфис иреннәренә китереп терәде. Исмегөлнең күзләрен һәм тешләрен балкытып елмаюында артистларга хас бераз чытлыклану сизелә, шул ук вакытта бөтен кыяфәтенә балаларча куану, дулкынлану да бәреп чыккан иде. «Я алла, бирсәң дә бирерсең икән бер кешегә шушы хәтле байлыкны!» Бу кызны күргән саен Даян шуңа гаҗәпләнә һәм аңа карап туймый иде. Исмегөлнең йөзендә Чыңгыз Әхмәрев картиналарындагы нәфислек, рухи нечкәлек бар. Нәфислек үрнәген күрәсегез килсә, театрга барып, актриса Солтанбаеваны карагыз. Анда аңа һәркем рәхәтләнеп, кинәнеп, керфеген дә какмыйча сәгатьләр буе карап утыра ала. Тик Даян гына, аны күрүгә, күзе чагылгандай, керфекләрен түбән төшерә, чөнки карашындагы утны башкалар сизәр дип курка, үз-үзеннән дә ояла. Чыннан да, яше кырыктан узган, мыегына беренче кырау төшкән, корсагы бил каешыннан ике яклап бүселеп чыга башлаган, күңеленә шактый елларның тузаны сарган ирнең яшь сылуга мөкиббән китеп, авыз суын корытып йөрүеннән дә мәзәк нәрсә бар микән бу дөньяда? Ул әле менә хәзер телевизорга да иркенләп, туры итеп карарга кыенсына, күзләрен кысып басып тора.

— Минем хыялым — яшь замандашыбызның тулы канлы образын тудыру,— дип җавап бирде Исмегөл хәбәрченең соравына.

Даян, тамагына көнбагыш кабыгы утыргандай, йөткергәләп куйды, күзләрен чет-чет йомгалады. Тезелеп киткән энҗе тешләр арасыннан, пешеп торган иреннәрдән дә шундый тапталган, күп артистлар авызында иләнеп, искереп беткән сүзләр чыгар икән!

Гайшә, шул кирәк сиңа дигәндәй, ирен үчекләп елмаеп тора иде. Кеше сүзсез елмаю белән генә дә туксан тугыз төрле фикер әйтә ала, диләр. Булыр-булыр, Гайшә кебекләрнең елмаюы йөз төрледән дә артып китәдер әле.

Даян, зәңгәр спорт чалбары кесәсеннән кульяулык алып, зур кара кысалы күзлегенең пыялаларын сөртеп маташты. Күзлеген салса, ул үзен кешеләрдән читләшкәндәй, ялгыз калгандайрак хис итә, хәтта тавышларны да гүяки ерактанрак ишетә иде. Шунлыктан ул янәшәсендәге хатынының бераз гына ясалмарак тавыш белән әйткән сүзләрен аңламыйчарак торды. Аннары сискәнгәндәй итеп:

— Ә, нәрсә? — дип сорады.

— Әмир белән сөйләшкәнсездер бит инде.

Гайшә моны, барын да яхшы беләм, болай гына сорыйм, дигәндәй хәйләкәр елмаеп әйтте.

— Ишетеп тордың бит ни сөйләшкәнне. Ярый, яхшы, куярбыз, диде.

Башка вакытларда, Даянның яңа пьесасын укып чыкканнан соң, Әмир баскан урынында тик тора алмыйча таптангалый, кулларын угалый торган иде. Бу юлы алай итмәде итүен, таптанмады, кулларын угаламады. Аның тыныч кына уйга чумып басып торуы Даянның эченә бераз пошаман салган иде салуын. Тик драматург үз күңеленнән шик кортын тизрәк куарга тырышты: кайсы гына автор, шуңа карап кына, әсәрендә кимчелек барын таныр икән? Язучының һәр язганы үзенә даһи әсәр булып тоела, тик укучы гына моны күп очракта аңлап бетерми.

Даян, күзлеген киеп, хатынының йөзенә текәлеп карады. Гайшә, аның карашыннан кыенсынгандай, какча яңакларыннан шома чәчен колак артына җыйды. Аның бармаклары озын, нәфис иде.

— Син анда Кадимбикә турында үз фикереңне әйткәнсеңдер инде? — дип сорады ул җиңелчә генә.

— Әмирнең холкын үзең беләсең, ул миңа соңгысында: «Синең үз эшең, минем үз эшем, кысылып йөрмә»,— дип кырт кисте. Тегеләй ит тә, болай ит, дип күрсәтмә биреп йөртергә, баш режиссер ул сиңа мальчишка түгел!

Гомерендә көнләшмәгән, көнләшүне культурасызлык дип санаган укытучы Гайшә унбиш ел бергә гомер сөргән ирен яшь бер актрисадан көнли башлаган иде. Ул моны сиздермәскә тырыша. Солтанбаева фамилиясен ишетүдән курка, шул ук вакытта дөреслекне белми дә түзә алмый иде.

— Рольләргә артистлар сайлап та нервы бозар хәл юк инде.— Хатынының тар иңенә кулын салган Даян Гайшәнең калтыранганын тоеп алгач: — Үз эшем дә муеннан,— дип өстәде.

— Үзгәрдең син, үзгәрдең! — Гайшә учлары белән яңакларын кысты.— Элекке пьесаларыңны ничек яза идең дә монысын ничек яздың, ә? Элеккеләренә минем күпме сүзне кертә идең, һәр җөмләңне миңа ничә кат кычкырып укып кына чыга идең! Ә бу юлы гәүдәң генә өйдә утырды, күңелең әллә кайларда йөрде. Бүлмәңә ялгыш кына барып керсәм дә, язганнарыңны каплап куясың, өйдән чыкканда, өстәл тартмаларыңны бикли торган иттең!

Чыннан да, пьесасын язган ике ай эчендә хатыны белән сөйләштеме соң әле Даян? Бу уй аның үзенә дә сәер тоелды, ул, башын чайкап, үзалдына елмайды да, борылып, кече бүлмәгә кереп китте.

Аның эш бүлмәсенә килеп кергән һәркем иң элек бер як стенаны тоташ биләп торган киштәләргә карый. Бу китапны каян алдың да тегесен ничек кулга төшердең? — дип сорый күбесе. Ә менә тәрәзә буендагы язу өстәленә һәм андагы яшел эшләпәле лампага берәүнең дә исе киткәне юк әле. Хәлбуки гаҗәеп өстәл ул. Андагы лампа Галәветдиннең тылсымлы лампасыннан могҗизалырак көчкә ия. Аларга якынайгач ук, Даянның йөзе үзгәрә. Менә ул урындыгын җайлабрак куйды, күкрәген өстәл кырыена терәп утырды, өстәл тартмасыннан чиста кәгазь бите алып, яктылык түгәрәгенә куйды. Шул ук тартмадан кара тутырылган автомат ручка чыгарды. Барча халык шариклы ручкалар белән мавыккан бу заманда бер аңа гына сыгылмалы корыч каләм аша уйлар, хисләр кәгазьгә җиңелрәк күчә кебек тоела.

Ул ашыгып яза башлады, ләкин шунда ук киң селтәнү белән язганнарын сызып ташлады. Күңелдә нидер кайный, тик аның кайнарлыгы каләм аша кәгазьгә күчә алмый, бу агым юлында, чишмә юлын буган таш шикелле, нәрсәдер ята иде.

Даян тураеп утырды, карашын бүлмәнең күләгәле почмагына төбәде. Вак бизәкле яшькелт обой почмак турында түшәмнән идәнгәчә яры-

лып купкан иде. Ничә тапкыр сыладылар инде, ләкин атна үтүгә ярык элекке эзеннән тагын сызыла да чыга. Бу квартир йортның ниндидер җөенә туры килгән, имеш. Таш диварларның да төзәлмәс яралары була икән, инде адәм баласы турында ни әйтмәк кирәк? Даян йөрәгендә дә бар шундый җәрәхәт һәм ул һаман сызлап тора.

Димәк ки, СССРда бер чибәр һәм талантлы актриса Солтанбаеваның замандаш образын тудырасы килә икән... Ә соң син, сеңелкәш, нинди роль уйнап шулай беренчелекне алдың да, кем аркасында балкып, телевизорга чыктың әле? Чибәрләр күп ул дөньяда, ләкин безнең заманда бу кадәрле күтәрелү өчен, мондый дан казану өчен, чибәрлек кенә җитми шул. Күтәрелер өчен бик нык һәм биек баскыч кирәк. Менә шушы күзлекле ахмак Даян абыең, шушы кадәр көч түгеп, үзенең йөрәк хисләрен, бөтен уйлаганнарын синең аягың астына баскыч итеп куймаса, ил сәхнәсенә ничек менәр идең дә кем сине мактар иде? Шушы карт исәр юктан бар иткән образларны уйнап, бөтен илдә макталасың түгелме? Ә бүгенге сүзне әйткәндә, аның күңеленә каты тияр бу, дигән уй килмәдемени яшь башына? Әллә акылың үсеп җитмәү бәласеме бу?

Хәер, бер караганда, шулай булуың хәерлерәк тә. Ашыкма, тормыш абзаң үз вакыты белән бик шәпләп, шап иттереп акылга утыртып куя ул. Артык акыллы булу — картаю билгесе. Яшьлек, чибәрлек барысын да кичертә, шундый ахмак һәм авыр сүзләр әйткәндә дә йөрәккә бик якын шул син, Исмегөл...

Ә шулай да, нигә әле син бүгенге көн кешесен уйнау гына заманга муафыйк дип уйлыйсың? Ә Кадимбикә? Сиңа булган мәхәббәтемнән яралган Кадимбикәне кая куясың?

Даян өстәл тартмасыннан пьесасы кулъязмасын алды һәм аны, бәлки, менә меңенче тапкырдыр, укырга тотынды:

«Каты бәрелештән соң тынып калган яу кыры. Төн. Еракта, анда-санда янган учакларның уты күренә. Түрдә зур ак чатыр шәйләнә. Алгы планда, актарылган җир өстендә, ватылган, җимерелгән сугыш кораллары ауный. Караңгылыктан ике хатын шәүләсе аерылып, алгы планга якынлаша.

Сабира. Әйдә, арырак барыйк әле. Кадимбикә. Аннан да карап килик. Бәлки, синең Нариманың шунда ятадыр. Табып алып, кадерләп, аның да гәүдәсен җир куенына урнаштырыйк.

Кадимбикә. Өч нарасыемны, өч улымны җирләдем инде мин бүген.

Сабира. Нихәл итмәк кирәк, бу җиһанда безгә тапшырылган соңгы бурыч шулдыр, күрәсең. Газизләребезнең каберләрен күз яшьләре белән сугарырга да үзебезгә, хәсрәтләрдән кибеп-корып, әкренләп туфрак булырга язгандыр.

Кадимбикә. Әкренләп туфрак булырга?

Сабира. Дошман җиңде, ирләребез һәлак булды, балаларыбыз үтерелде. Безгә бу дөньяда яшәүнең бер мәгънәсе дә калмады.

Кадимбикә. Ләкин без исән бит.

Сабира. Ил һәлак булгач, безнең исән калуда ни мәгънә!

Кадимбикә. Кил әле монда, Сабира!

Сабира. Мин монда, яныңда бит инде.

Кадимбикә. Ә син якынрак кил! Чөнки ерактан күрмисең, тоймыйсың, ахрысы!

Сабира. Нәрсәне, Кадимбикә?

Кадимбикә. Син бернәрсә дә күрмисеңме?

Сабира. Мин һәлакәт кенә күрәм, Кадимбикә.

Кадимбикә. Алайса дошман тәмам морадына ирешкән икән. Ул сине, исән калган кешене дә сукырайткан икән!

Сабира. Минем күзләрем артык күпне күрә, Кадимбикә.

Кадимбикә. Ә син артык күпне күрмә. Син дошман күрсәтергә теләгәнне күрәсең.

Сабира. Тагын нәрсә күреп була соң бу далада? Бу мәхшәрдә?

Кадимбикә. Ә син миңа кара.

Сабира. Карыйм.

Кадимбикә. Кара минем йөземә, күзләремә. Мин яшь, мин көчле. Минем йөрәгемдә шундый утлар яна ки, алар янында бу учаклар бер

очкын гына, Сабира. Эчемдә мондый ялкын дөрләгәндә, мин әкренләп туфракка әйләнә алмыйм! Юк, дошман монысын бушка өмет итә! Ул күпкә ирешге, ләкин миндәге ялкынның үзеннән-үзе сүрелүенә ирешә алмас. Анысы — булмас!»

Бу юлларга җиткәч, Даян тирәсендәге мохит кинәт үзгәргәндәй булды. Яшел эшләпәле лампадан коңгырт өстәлгә төшкән яктылык түгәрәге киңәйде, тоныкланды, анда иркен һәм шомлы дала шәйләнә башлады. Аның уртасыннан ике хатын калкып чыкты. Даян, тетрәнеп, аларның бәхәсен тыңлый башлады.

«Сабира. Минем күзләремә нур чаткысы үтеп керерлек түгел инде, Кадимбикә. Аякларымның ничек атлаганын да тоймыйм. Ирләребез, балаларыбыз үтерелгәндә, безнең дә җаннар алынды. Безнең өчен бу төн мәңге үтмәс, кояш мәңге чыкмас.

Кадимбикә. Ач күзләреңне, Сабира. Үз өметең югалса, минем өметем сиңа нур чәчсен!

Сабира. Нинди өмет? Нәрсәгә өмет?

Кадимбикә. Минем Нариманым исән, Сабира.

Сабира. Акылыңа кил, Кадимбикә! Бу сугышта меңнәр ятып калды.

Кадимбикә. Кара минем йөземә. Сизәсеңме җанымның ничек сызлаганын? Бер күңел генә бу кадәр сызлый алмас иде. Минем газапларыма аның сызланулары килеп өстәлә, Сабира. Ул исән, ул сызлана! Мин аны табарга тиеш!

Сабира. Син аны каян эзләмәкче буласың?

Кадимбикә. Минем юлым әнә шуннан башланыр.

Сабира. Анда дошман явы, залим Хаким. Безне җиңүләрен бәйрәм итәләр. Аларның канга сусавы басылмаган әле, Кадимбикә! Алар күзенә чалынудан курык!

Кадимбикә. Бу — минем үз җирем. Мин монда качып-посып йөрергә күнекмәгән. Мин барам, юлым туры булыр».

«Шулай, шулай, туры тот сыныңны, Кадимбикә»,— дип, эчтән аны хуплады Даян. Кадимбикә гаҗәп дәрәҗәдә Исмегөлгә охшаган иде. Даян кинәнеп көлемсерәде: «Ә, шулаймы? Синең, чалбар киеп, машиналар арасында ыгы-зыгы килгән заман чытлыгын уйныйсың килә идеме? Ә менә мин сине теләсә кайсы илгә, теләсә кайсы заманга күчереп куям да, ничек телим, шулай яшәтәм. Телим икән — бәхет диңгезендә йөздерәм, телим икән — михнәт чиктерәм. Сине хан кызы ясау да, ярлы баласы итү дә минем ихтыярда, беләсең килсә! Бу дөньяда кайсы гашыйкның мәгъшукасы язмышын шушы рәвешле үз кулында тотканы, үзенчә генә яшәткәне һәм үз сүзен генә сөйләтә алганы бар? Ә менә мин синең һәр адымыңа, һәр сүзеңә хуҗа. Өстәлемдә сине теләсә ничек биетәм, һәм син сәхнәдә дә шулай биергә тиеш булачаксың!»

Даян үз кодрәтенә үзе хәйран калган иде.

### 3

«Театрның баш режиссеры иптәш Әмир Әнвәрбәковка Татарстанның халык артисткасы Шәфика Абиловадан гариза.

Иптәш Әнвәрбәков! Әмир! Сүземне яңыңа кереп кенә сөйләр идем дә, мине тыңлап бетерергә вакытың да, сабырлыгың да җитмәс, дип куркам. Синең белән, эчне бушатып, рәхәтләнеп сөйләшеп утырырлыкмы соң! Ул өстәлеңдәге ару-талуны белмәс телефоның, ул туктаусыз кереп-чыгып торган халык, үзеңнең дә баскан урыныңда, тик тора белми, әрле-бирле таптануың! Ачыктан-ачык сөйләшергә күп тапкырлар талпынып карадым инде — булмады. Син бит соңгы вакытта үзең генә сөйләргә ярата башладың, кеше сүзен теләсәң ишетәсең, теләмәсәң юк. Кайчак мин әйтәм, әллә соң бу кешенең колагына сүзләрне сортларга гына бүлеп үткәрә торган берәр төрле электрон җайланма куелды микән, дим. Соңгы вакытта шундыйрак җайланма күзләреңдә дә бар шикелле тоела башлады. Чөнки кеше аеру күзләреңдә дә сизелә — теләсәң күрәсең кешене, теләмәсәң юк. Шулай итеп, мин синең өчен күзгә күренмәс, сүзе ишетелмәс бер күләгәгә әйләндем бугай инде».

Бу сүзләрне укыгач, Әмир, авыр көрсенеп, утырган урындыгын шыгырдатып, боргаланып куйды. Уф! Моңа хәтле җыен тозсыз сүзне күзгә карап сөйләп теңкәгә тияләр иде, хәзер инде кәгазьгә язып, шуны укытып бәгырьгә төшә башладылар.

«Әмма йөрәк түрендә кайнаганны йотып калыр хәлем юк. Шуңа күрә әйтәсе килгәнемне гариза рәвешендә язып бирергә булдым. Минем үземнән мең сылтау табып кача аласың син, ләкин җитәкче буларак, үз кул астыңда эшләүче кешенең язма рәвештә бирелгән гаризасын укымыйча, тикшермичә, җавап бирмичә кала алмыйсың».

Әмир, врачта теш суырткан кеше кебек, йөзен җыерды. Дөньяның рәтен белми, дигән булалар тагын бу Абилованы. Җаен тапкан бит менә, укымый булмый! Кабинетта чакта вакыт тимәде, инде менә өйгә кайткач, телевизор карыйсы, я инде, һич булмаса, Гыйззәт Бикашинның күптән көтә торган яңа пьесасы белән танышасы урында, шушы мәгънәсез «гариза»ны укып, эч пошырып утыр менә! Әмир аның ни теләгәнен белмәс, ди микән, нәрсәгә шушы хәтле озын итеп язгандыр. «Баш рольне миңа бир!» — дип дүрт сүз белән язса да бик җитә иде бит инде.

«Хикмәт шунда: мин Кадимбикәне күреп беләм...»

Әмирнең урындыгы тагын шыгырдады. Әһә! Шәфиканең дә Кадимбикәне уйныйсы килә икән. Актрисаларның шул Кадимбикәгә авыз суы корытып йөрүеннән үк тә күренә инде театрдагы кадрларның үсеш дәрәҗәсе. Тапканнар... «Борын-борын заманда, кәҗә команда, саескан сотник, үрдәк урәтник булган заманда, илне дошман явы басып алган», ди имеш. Чын сәхнә әсәре шулай башланамыни? Ул илне һәм чорны кайсы чыганаклардан өйрәнергә? Ул вакыйгалар тарихта нинди эз калдырган да хәзерге заман кешеләренең язмышына нинди йогынты ясаган? Берсе дә ачык түгел. Ә ансыз чын спектакль куеп буламыни? Баштанаяк ниндидер ясалма пафос белән тулган әсәр бу, бөтен нәрсә маңгайга бәреп әйтелә. Тамашачыга бер җиңеләеп көлеп алырлык, җанны ял иттерерлек күренешләре дә юк бит ичмасам. Режиссер Әнвәрбәков үзе туйганчы көлдерә һәм шул көлү аша уйландыра торган сатирик әсәрләр куярга ярата. Кызганыч ки, андый үткен пьесала́р язарга көчләре җитми шул хәзерге драматургларның!

Әмир фикеренчә, «Кадимбикә» Даянның соңгы елларда язылган әсәрләреннән иң йомшагы иде. Репертуарга эчтән сыкранып кына кертә аны Әмир, актрисаларның яше-карты бу хәтле шашынасын белгән булса, кертмәгән дә булыр иде.

«Хикмәт шунда: мин Кадимбикәне бик яхшы беләм,— дип укуын дәвам итте ул.— Кадимбикә яшьрәк чакта ак йөзле, дулкынланып торган сары чәчле, сыгылма гәүдәле, ифрат пластичный хатын иде. Боларны укыгач, Шәфика үзен яза, дип уйлый күрмә тагын. Кадимбикә биленә төшеп торган толымлы иде һәм ул Мөкәррәмә исемле.

Кешенең асыл сыйфатлары, язмышының хәтәр сынаулары килгәндә, бик ачык күренә. Әйтик, без такыр юлдан җай гына барганда, кинәт аяк астында җир убыла, ди. Шунда күбебез, куркып, артка чигенә, ә арадан берәү туктап калмый, алга талпынып, чокырны сикереп үтә, артыннан бау суза, аннары басма сала. «Менә бит син нинди батыр икәнсең, моңарчы без генә белмәгән»,— дибез без, ул салган басмадан сакланып кына чыкканда.

Ил тыныч яшәгәндә, Кадимбикә дә, мөгаен, гади генә кыз булып күренер иде, шулай бит? Иленә яу килмәсә, аның тәвәккәллеген кем белер иде?

Бер атлы, унике балалы гаиләдә дүртенче кыз булып үсеп килгән Мөкәррәмәне дә язмыш шундый кискен борылыш чорында — Гражданнар сугышы зилзиләсендә сыный.

Мин аның тормышын, сәхнә күренешләре кебек, өзек-өзек вакый-

галар рәвешендә күз алдыма китерәм. Хәер, безнең яшәешнең чын мәгънәсен гомумән көн итүебез түгел, ә бәлки тормышыбызда кискен хәлләр килеп чыкканда, үз-үзебезне ничек тотуыбыз билгели дә бит инде. Менә ул, уналты яшьлек кыз, иңенә көянтә асып, җәйге таңда текә ярдан елгага су алырга төшеп килә. Күп әсәрләрдә тасвирланган, җырларда җырланган, һәркемгә таныш картина: алсу таң, чыклы үлән, томанлы су өсте, талларга басып сайраган сандугач тавышы. Һәм яшь, чибәр кыз. Шунда кинәт таллар арасыннан кыз каршына берәү килеп чыга. Өстебашы пычранган, чәче-башы тузган, караңгы чырайлы адәм бу. Як-ягына куркынып карана, бик мыштым гына килә. Нишләр иде шунда башка бер кыз булса? Чәрелдәп кычкырып җибәрер иде дә, көянтә-чиләкләрен ташлап, кире үргә йөгереп менеп китәр иде. Без бит элекке заман кызларын басынкы, изелгән, куркак һәм җебегән итеп күз алдына китерергә күнеккәнбез. Батырларының да кыюлыгы ирләре белән әрепләшүдән узмый. Син үзең дә андыйларны сәхнәгә күп чыгардың. Шулай бит? Хәлбуки, татар кызлары без тасвирлаган төсле генә булмаган. Һич юк. Мин аны Мөккәррәмәдән генә дә беләм. Ул башка яшьтәшләре белән бергә абыстайга йөреп, укырга өйрәнгән, әтисеннән кача-поса булса да рус мәктәбендә дә дәресләр тыңлаган. Куаклар арасыннан куркыныч кыяфәтле кеше килеп чыккач, ул каушап калмый, сабыр гына аның сүзен көтә. «Сеңелкәй, зинһар, мине берәр җиргә качырсана! Аклар тотып алса, мине үтерәчәкләр!» — ди теге кеше.

Хәзер сөйләгәндә бик ансат тоела бу. Ләкин аклар кулындагы шәһәрчектә кызылармиячене чормада яшереп тотуның, шуннан соң аны урманга, партизаннар янына качыруның, аннары партизаннар биргән акчага базардан азык-төлек алып урманга илтүнең никадәр батырлык таләп иткәнен күз алдына китерү дә кыен. Әгәр бу эшне белеп алсалар, унике балалы гаиләдән беркем исән калмас иде бит.

Әлбәттә инде, Мөкәррәмә боларны бик яшерен эшләргә тырышкан, ләкин ата кешенең күңеленә берәр шик кергәндер, ахрысы. Ул кызын тизрәк урнаштырырга ниятли — муллага икенче хатынлыкка бирергә риза була. Аны да аңларга кирәк: ата кеше буларак, газиз баласына яхшылык тели бит ул, заманы шундый, абыстай булып яшәү, аныңча хатын-кыз өчен бәхетнең иң зурысы. Мөкәррәмә урынында башка берәү булса, елар-елар иде дә, язмышына буйсынмый булдыра алмас иде. Аңа нибары уналты гына яшь бит әле, нибары уналты!

Ләкин Мөкәррәмә — бара торган юлы кинәт өзелгәнен күрүгә чигенә торганнардан түгел, упкын аша сикерә торганнардан: ул партизаннар отрядына бөтенләйгә качып китә.

Мин, аның гомерен сәхнә күренешләре рәвешендә күз алдыма китерәм, дидем. Бу — сүз өчен генә әйтелмәде. Мөкәррәмәнең гомере чыннан да сәхнәдә узды. Мең үлемнән могҗиза белән генә исән калган ач-ялангач сугышчылар концертларны, спектакльләрне бик яратып карый торган булганнар, тамашадан үзләренә юаныч тапканнар. Театр ул — рухи икмәк, ач яшәп булмаган шикелле, театрсыз да яшәп булмый. Мөкәррәмә шул рухи икмәкне булдыруга катнашкан, концертларда җырлап-биеп йөргән.

Партизан отряды Шамил Усманов полкына килеп кушылгач, профессиональ театр труппасы булдырырга карар кылынган. Мине тагын шул нәрсә гаҗәпләндерә һәм сокландыра: ул чакта ук Кызыл Армиядә театр дөньясын яхшы белгән, әзерлекле, хәтта гыйлемле кешеләр булган икән. Труппага кем теләсә шуны җыймаганнар, ә бәлки тикшереп, сәләтлеләрне генә алганнар.

Менә минем күз алдымда тагын бер күренеш җанлана: ярлы җиһазлы авыл өе, түрдә кызыл постау ябылган өстәл. Аның артында эскәмиядә гимнастерка кигән, түшләренә аркылы-торкылы каешлар буган, кырыс, ябык һәм сабырсыз егетләр утыра. Бу — хәзергечә әйткәндә, жюри. Менә алар каршына галифе чалбарлы кыз кереп баса. Шигырен

тыңлагач, аңа болай диләр: «Шушы минутта бүлмәдә ут чыкты, ди. Син нишләр идең?» Этюдның ни икәнен ул чакта Мөкәррәмә белдеме икән, юкмы, ләкин ул аны-моны уйлап тормый: «Пожар, пожар!» — дип кычкыра да, өстәлдән постауны сыдырып алып ябына һәм эскәмиягә сикереп менеп, тәрәзәгә китереп тибә. Тышкы яктан кызыл гаскәриләрнең куркынышкан йөзләре күренә. «Булды, җитте! Төш аннан! — ди жюри кызга.— Без сине театр труппасына кабул итәбез».— «Ә кая соң ул?» — «Хәзергә тылда».— «Ә сез кайда буласыз?» — «Безнең бурыч бер инде, акларны куу».— «Ә шулаймы? Сез акларны куасыз, мин тылда каламмы? Юк инде, алай булмый, мин сездән калмыйм. Куркак икән бу, дияр идегез бугай».

Шуннан соң тагын бер күренеш: кичке эңгердә зур бер авыл урамы буйлап Мөкәррәмә бара — аның каршына яшь кенә бер егет — Шамил Усмановның адъютанты килә. «Тимеркүкне күрмәдеңме?» — дип сорый ул кыздан. Тимеркүк—комиссарның аты. «Югалттыңмыни?» — дип сорауга сорау белән җавап бирә Мөкәррәмә. «Авыл очында гына калдырган идем, тышавын өзгәндер инде, бөтенләй юкка чыккан».— «Хәзер табып китерәм мин аны сиңа»,— ди Мөкәррәмә. «Каян?» — «Даладан».— «Берүзеңме? Юк инде, барсак икәү барабыз».— «Синнән кача бит ул! Яратса, яныңнан китмәс иде әле».— «Юк, барыбер үзеңне генә җибәрмим. Аклар очрап куйса...» — «Әйтеп торам ич, син булсаң, якын килми ул, дим». Мөкәррәмә бахбайларның холкын белә, чөнки алдан әйтеп үткән идем бит инде, ул атлы гаиләдә үскән кыз, абыйлары булмагач, әтисенә атны гел ул карашкан була. «Син мине монда гына көтеп тор,— ди ул егеткә.— Мин атны табып кайтыйм. Аннары... аннары мин сиңа бит очымнан пәп иттерермен...»

Шундый вәгъдә бирә ул бирүен егеткә, әмма мин үзем аның кемнән дә булса үптергәнен һич күз алдыма китерә алмыйм. Чөнки, еллар буе ир-ат арасында айкалуына карамастан, ул асылда гаҗәп беркатлы һәм керсез күңелле булып кала бирә. Паровоз мичләренә кипкән балык ягып, тәрәзәсез-ишексез вагоннарда Урта Азия басмачыларын тар-мар итәргә барган чакларда, күп төннәрне егетләр белән янәшә, идәндә йокларга туры килә аңа. Андый вакытта кыз ике арага шинелен төреп сала, чөнки егетләрнең сулышы тиюдән курка. Ул, егетләрнең сулышыннан да буйга узалар икән, дип, каяндыр ишеткән була һәм шуңа чын-чынлап ышана. Хәзерге заманда, ир-ат арасында күп айкалган хатын-кыз тупаслана, нәфислеген югалта, дип сөйлиләр. Мөкәррәмә кебекләр сафлыксадәлекләрен ничек саклый алды икән соң?

Ә Тимеркүкне даладан табып алып кайта ул. Бу хәлләр комиссарга мәгълүм була, һәм кыз, батырлыгы өчен, бер чалбарлык кызыл постау белән бүләкләнә.

Нинди генә фаҗигалар кичерсә дә, күңеле катыланмый торган кешеләр бар дөньяда. Кадимбикәне мин шундый итеп күз алдыма китерәм. Мөкәррәмә дә шундый. Ниләр генә кичерергә туры килми аңа! Бандитларның көтелмәгән һөҗүмнәре, басмачыларның кулларына төшкән кызыл гаскәриләрнең башларын кисеп, кылычка күтәреп, күз алдында чабып йөрүләре, Бохарада оешкан беренче театр труппасындагы беренче артистканы үтерүләре... Шул һәлакәттән соң театрга Мөкәррәмә килә һәм ул анда шактый вакыт бердәнбер хатын-кыз була.

Менә мин күзләремне йомам да борынгы Бохараның зиннәтле сарайларын, күккә үрелгән нечкә-нәфис манараларын күргәндәй булам. Шул сарайларның иң зурысы һәм бизәклесе эчендә йөргән кызыл чалбарлы, сары толымлы яшь бер кызны чалымлыйм. Мондый күренешнең бер әкияттә дә тасвирланганы юк әле.

«Нигә сарай эчендә»,— диярсең. Ул чакта Бохара әмире, барча хатыннарын алып, илдән чыгып киткән булган инде. Ул киткән, ә хәзинәләре, тиешенчә рәсмиләштерелеп, дәүләткә тапшырылмаган әле. Вәкаләтле кешеләр килеп җиткәнче, хан сараен һәм андагы байлыкларны

бик нықлап сакларга кирәк икән. «Синнән дә ышанычлырак кеше булмас»,— дип, хәзинәләр тулы бер бүлмәнең ачкычын Мөкәррәмәгә тапшыралар.

Менә бер заман Мәскәү каласының үзеннән махсус комиссия килеп төшә. Еникиев дигән комиссар шаһитләр алдында Мөкәррәмәдән ачкычны ала да:

— Ышанычны аклагансың, рәхмәт,— ди.— Инде без синең үзеңә шул бүлмәдән берәр әйбер сайлап алырга рөхсәт итәбез.

Кереп китә Мөкәррәмә алмазлар да якутлар, кирпеч-кирпеч алтыннар янына. Комиссия һәм шаһитләр, нишләр икән бу кызый, дип, күз тутырып карап торалар. Озак көттерми ул, зур гына төен күтәреп, килеп тә чыга. Шактый эләктергән икән, дип карашып куя кызыл гаскәриләр. Тау-тау өелеп яткан хәзинәләргә юлыгып, үзләре күтәрә алмаслык алтын алып чыгарга маташкан һәм шул комсызлыклары аркасында һәлак булган кешеләр турында әкиятләрдә күп сөйләнә. Бу кызның да күбрәк нәрсә эләктереп калырга тырышуы гаҗәпмени, дип уйлый кайберәүләр.

— Инде күрсәт: ни алдың?

Мөкәррәмә төргәген таратып җибәрә. Ни күзләре белән күрсеннәр — ул ефәк тукыма икән. Бер күлмәккә җитәрлек аллы-гөлле чын ефәк.

— Әйләндереп күрсәт! — диләр аптырашып.

Кыз ефәкне әйләндерә-әйләндерә селки, ә үзе аннан күзләрен ала алмый. Бармакларына карыйлар, колагына — берни юк! Шуннан тотыналар шаркылдашып көлешергә.

— Ә нигә? Ярамый идемени? Кире аласызмыни? — ди кыз, еларга җитешеп. Үзе ефәкне күкрәгенә кыса. Еллар буе кызыл чалбар белән гимнастерка киеп йөргән яшь кызның хәлен шунда гына аңлап ала комиссар.

— Юк, юк, алмыйбыз, бу ефәк үзеңә булсын,— дип юата ул Мөкәррәмәне. Ә үзе хәзинәләр янына керә дә, дүрт-биш алтын тәңкә, бер пар алка һәм асылташлар белән бизәлгән калфак алып чыгып, кызга бирә:

— Менә, ал боларны да. Син артист икәнсең бит, сәхнәдә уйнарга кирәк булыр.

Чыннан да, Хәмзә театры сәхнәсендә Мөкәррәмәнең ул затлы әйберләрне киеп уйнаганын минем үземнең дә күргәнем булды.

Әмир! Үзең дә күптән аңлагансыңдыр инде: Мөкәррәмә — минем әнием бит! Кадимбикә образының ачкычы — аның кулында! Минемчә, аны белми торып, бу образны дөрес хәл итеп тә булмыйдыр...»

Әмир, кулындагы зәңгәр тышлы калын дәфтәрнең калган битләрен актарып карады: ай-һай, бигрәк күп икән әле, иренмичә язган Шәфика. Барысы да анасы турында гына микән? Бүген укып та бетереп булмас ахрысы. Шәфиканың тигезле-тигезсез хәрефләреннән күзләр ачыта башлады.

Ә шулай да гомер ничек үзгәртә кешене, ә! Шәфиканың әнисе — авыр гына атлап йөри торган юан гәүдәле чал карчык. Башына озын ак шарф урый, ул гел шуып торганга, җыерчыклы кулы белән туктаусыз төзәтә. Уң кулында шомарып беткән коңгырт таяк белән зур гына кара сумка булыр.

Шушы әбекәй кайчан да булса ярсу атларны үзенә буйсындыра белгән, сәхнәдә йолдыз булып балкыган чибәр, чая кыз булды микәнни? Ышанырлык түгел, билләһи...

Әмир кинәт аңына килеп, «тфү» дип куйды. Нәрсә баш катырып утыра соң әле ул? Нигә кирәк аңа Мөкәррәмә, нәрсәгә аңа Кадимбикә? Башка кайгысы юкмы әллә?

## 4

«Бүген кич спектакль». Бу сүзләрне артист бик тирән мәгънә белән әйтә. Димәк, кичен ул сәхнәгә чыгачак, аңарчы эшләп арырга да, борчылырга да ярамый, бөтен уй-хисләрне бер ноктага тупларга кирәк.

Хәер, бөтенләй үк борчылмыйча да булмый. Артистның эше — ике сменалы, иртәнге унбердән икегә кадәр репетицияләр бара. Сәгать өченчедә театрдан чыккан Сафия, чәй эчкәннән соң, кичкә кадәр тынычкына ял итәргә ниятләп, кул эшенә утырды. Аның янарак кына бәйли башлаган кофтасы бар иде. Күксел йомшак йон җебе аның имән бармагын урап алды, ялтырап торган тимер энәләр, борчуларны куарга теләгәндәй, дәртле биешә башладылар.

Артист халкы гомумән бәйләргә, чигәргә ярата. Әгәр аларның өстендә гөл кебек кофталар, бәйләгән күлмәкләр күреп кызыксагыз, каян алдың, дип түгел, кайчан бәйләдең, дип сорагыз. Матур киемнәр күп очракта гастрольләр вакытында бәйләнгән булыр. Ә Сафия нише театр ишегалдындагы тулай торакта яшәп ятучы ялгызаклар ел әйләнәсенә кул эше белән шөгыльләнергә вакыт таба. Иҗат кешесенә вакыт-вакыт тынып торырга, утырып уйлар уйларга кирәк, ә уйлар агышын җайга салу өчен, биешеп торган энәләрдән һәм, бармакка уралып, әкрен наз белән шуышкан йомшак җептән дә яхшырак чара бар микән? Алар шулай күңелне тынычландырып, шактый вакыт элек укылып та, әле һаман кемнәр уйнаячагы хәл кылынмаган «Кадимбикә»не дә, режиссерга булган үпкә-сапкаларны да оныттырып торалар иде.

Сафия бәйләвенә мавыгып утырганда, ишек кинәт каерылып ачылды, анда җирән төлке тун һәм шундый ук бүрек кигән берәүнең тулган айдай якты йөзе күренде:

— Нишләп болай караңгыда утырасың? — диде каймак кебек йомшак, ягымлы, шул ук вакытта көчле тавыш.— Кайда әле безнең ут дигәнебез?!

Чыннан да караңгыланган икән, Сафия сизми генә утырган, гөлт итеп кабынган уттан ул челт-челт күзләрен йомгалады. Аның каршында, кош тоткандай куанган кыяфәт белән, сабакташы, ахирәте, сигез ел бергә шушы бүлмәдә яшәгән сердәше Наргизә басып тора иде.

— Нәрсә, көтмәгән идеңме? — диде ул һәм көзге яңгыр дымы сеңгән тунына Сафияне китереп кысты.— Бие, дускаем, сөен, мин кайттым. Бөтенләйгә кайттым! Илнур! Ил-ну-ур! Кая йөрисең син анда, кем урлады минем улымны?

Сафия чыланган халатын, ялангач беләкләрен сыпырып калды, ә Наргизә, бөтерелеп, кире коридорга чыгып китте. Шундук дүрт яшьлек улын сөйрәп алып керде һәм аның кулыннан зур шоколад шакмагын тартып алды. Малай авызын зур ачып еларга кереште.

— Әй бу артистларны! — дип сукранды Наргизә артына борылып.— Сабыйга шушы хәтле шоколад тоттыралармыни? Исмегөл! Кара аны, әйтеп куям Тәүфыйгыңа, бала карый белми ул, дип. Өйләнгәнче үк белеп торсын! Тукта, тукта хәзер үк,— диде аннары улына борылып.— Туктамасаң, хәзер апаң безне куып чыгара, урамда калабыз.

Сафия малайны юатып чишендерергә кереште, ә Наргизә тун төймәләрен ычкындырган килеш янә коридорга атылды:

— Кая соң әле бу таксист актыгы?! Әллә ул да Исмегөл янына каерган инде? Монда керегез, монда!

Аңа ияреп, ак җәймәгә уралган ике зур төен аскан кыска тунлы бер адәм килеп керде, кысан бүлмә ыгы-зыгы белән тулды.

— Тагын бер рейс ясыйкмы әллә? — диде ир кеше калын тавыш белән.

— Нәрсәгә тагын?

— Әйттем бит мин сезгә, телевизорны гына булса да алыгыз, дип. Савыт-саба, мебельнең бер өлешен алырга була...

— Житте-житте, хәзергә булды. Кирәгегез чыкса, телефоннан шалтыратырмын.

— Кайчан?

— Иртәгә.

— Иртәгә минем смена түгел шул.

— Алайса берсекөнгә.

— Берсекөнгә дә эшләмим.
— Алайса берсе-берсекөнгә.
— Анда, әйбер алам, дип йөри алмассыз шул инде. Бер алмасаң, кала ул.
— Сез нәрсә мине иремә каршы котыртасыз әле? Ул нинди гадәт?
Наргизә шоферны этә-төртә чыгарып җибәрде.
— Туйган монда ир-аттан! — дип калды үзе. Тунын салып, чөйгә элгән арада, сукрануын дәвам итте. — Ник әле шул хәтле обижать итим ди мин мескен Низамны? Хатынсыз калган иргә әллә тагын телевизорсыз да калырга дигәнме? Нишләр ул телевизорсыз, кичләрен ничек гомер уздырыр? Фу, бөтен бүлмәне бензин исенә гарык итеп китте бу шофер. Ач әле форточканы, дускаем!
Һич көтмәгәндә килеп чыккан бу ыгы-зыгының хикмәтен Сафия, чәй кайнатып, табын янына утыргач кына аңлый алды. Баксаң, Наргизә, биш ел яшәгән иреннән аерылып, монда торырга килгән икән. Әйе, төрлесен уйлаган иде Сафия, әмма бу кадәр үк дуамаллык көтмәгән иде Наргизәдән.
— Ничек инде ул сине бу рәвешле чыгарып җибәрде? — дип сорады ул соң дәрәҗәдә гаҗәпләнеп.
— Әй, белми дә калды. Эштә бит ул.
Монысы инде бөтенләй башка сыя торган нәрсә түгел иде.
— Тик торганда чыгып китмәгәнсеңдер бит инде?
— Нәкъ менә тик торганда. Тик торганга чыгып киттем дә инде!
Сафия дустын аңлаудан гаҗиз иде. Ниһаять, ул монын серенә төшенгәндәй итте, башын чайкап, елмаеп җибәрде.
— Шаяртасыңдыр әле, юньсез! Ялындырасың киләдер. Кич белән килсен дә аягыма егылсын, ди торгансыңдыр. Анын өчен генә бу хәтле алам-салам өстерәп йөрмәгән булсаң да ярар иде.
Наргизә яшькелт күзләре белән аңа тутырып, җитди итеп карады.
— Юк инде, дускаем, болай итеп шаярырга мин унсигездә түгел. Шаярудан узды безнең эшләр.
Ул Сафияне сихерләгәндәй, керфеген какмый аңа караган килеш, бизәкле чынаягыннан бер йотым чәй кабып куйды. Аннары, иптәшенең аңгыралыгына гаҗәпләнгәндәй, аңлатырга кереште:
— Беләсеңме, дускаем, йокым туйды минем. Уянасы килә башлады.
— Соң ул сине көчләп йоклатмыйдыр лабаса!
Наргизә анын бу сүзләрен илтифатсыз калдырды.
— Саташканың бармы синең, бастырылганың бармы? — дип сорады.
— Сирәк кенә булгалый.
— Булгаласа, беләсеңдер инде анын читенлеген. Өстеңә пәриләр менеп атлана, тынын кысыла, котың алына, әҗәлең җиткән кебек тоела. Үзең шунын төш икәнен дә беләсең, уянырга талпынасың, ә уянып булмый. Менә шундый хәлдә яшәдем мин, дускаем, сез белмәдегез генә. Ниһаять, менә, аллага шөкер, уяндым! Пәриләр качты, сулышым иркенәйде, күзем ачылды.
Ул урындыгыннан сикереп торды да чәчләрен ике чигәсе турыннан бармаклары белән өскә таба тарап җибәрде. Үзе кебек үк җирән бөдрәле, мәхәббәт алласы Амур төсле түгәрәк Илнур килеп аягына сарылган иде, аны читкәрәк этәрде:
— Сыланма әле, атаң сыңары, ирегемне кысма, тышаулама мине!
Баскан урынында тик тора алмыйча, таралып яткан төеннәрен аягы белән читкәрәк этәреп, ишек турыннан әйләнеп килде. Анын алтынсу-сары йон күлмәге гәүдәсенең сылулыгын күрсәтеп тора, куллары шундый сыгылмалы, хәрәкәтчән, гүяки сөяксез иде. Шулай да Наргизәнең иң зур байлыгы — баш түбәсеннән иңбашларына ташкын булып төшкән, куе җирән бөдрәләре, ак көмеч кебек нурлы, якты йөзе иде.
Хәер, кемгә ничек бит, кайберәүләргә җирән чәчле кызлар бөтенләй ошамый. Артист кеше өчен анын бер җайсызлыгы да бар: сәхнәдә

татар кызларын уйнаганда, ул бөдрәләрне каралтып, шомартып азапланып бетәсен. Шулай ук Наргизәдән тыелгысыз булып ургып торган кайнар хисселекне дә бер агымга юнәлтү, рольнең кысасына кертү режиссерга җиңел генә бирелми иде.

Алай да шактый йөрәкләргә ут салган иде Наргизә. Ләкин ул үзе бирәүгә дә мөкиббән китмәде, гыйшык тотучыларга көлеп кенә карады. Ахырда, һич уйламаганда, кайсыдыр кичәдә танышып, берәр ай гына очрашып йөргән Низам исемле егеткә чыгып та куйды. Ул егетнең сәүдә оешмасында ниндидер зур урында эшләгәнен белеп, кайберәүләр, муллыкта яшисе килгәндер, дип тә чыш-пыш килгәннәр иде. Ләкин Наргизәнең байлыкка кызыкмаганын Сафия бик яхшы белә.

— Ашыкма, аны да, үзеңне дә сына бераз,— дип киңәш биргәннәр иде ул чакта өлкәнрәкләр.

— Ашыктың ни дә, ашыкмадың ни, киләчәктә күрәчәкне барыбер белеп булмый,— дип җавап биргән иде андыйларга Наргизә.— Тормыш кору лотерей инде ул, һәркемнең отасы килә, тик отышлы билеты гына сирәк кешегә эләгә. Алай да бер сынап карамый булмый.

— Син аңа гашыйк түгел бит, ансыз да яши аласың,— дигән иде аңа Сафия.— Сөймәгәнгә сөйкәнмә, диләр, кияүгә аңа сөюеңнән тәкатьсез булгач кына барырга кирәк.

— Синме соң инде бу эштә акыл өйрәтер кеше! — дип көлде аннан Наргизә.

Ул чакта Низам да гашыйкка бер дә охшамаган, эч пошканнан гына Наргизә тирәсендә тулгана сыман тоелган иде. Бәлки, шул салкынлыгы белән кызны үз ягына аударгандыр да инде. Бик күп очракларда без үзебезне яратканнарның кадерен белеп бетермибез бит, яратмаганның күңелен кузгату, салкын йөрәктә учак кабызу кызыграк булып тоела. Хәер, Наргизә үзенең бу адымын башкачарак аңлатты:

— Холкы тыныч,— диде.— Ә минем үземдәге ут ике кешегә җитәрлек. Эше дә бик җайлы — иртә китә, кич кайта. Спектакльләр бетүгә, кайнар аш өлгертеп куя торган итәр.

Чыннан да, егет бик тыныч күренә, юктан кабынып китми, күп сөйләшми, кара чәченең бер генә бөртеге дә тырпаеп тормый, артистларның шаяруларына да, таза тешләрен җемелдәтеп, елмаеп кына җавап бирә иде. Беренче елларда Наргизәнең өметләре тулысынча акланды булса кирәк,— алар бик пар һәм бәхетле күренәләр иде. Ләкин, бала туып, бераз тернәкләнә төшкәч, егетнең ак, тигез тешләре башкачарак елтырый башлады, ахрысы. Низамның күңел томаны Наргизәнең йөрәк ялкынын әкренләп баса бара иде шикелле.

— Мин гомер буе театр ишек төбен каравыллап йөри алмам, хатын икәнсең, хатын була бел, ана икәнсең, ана була бел, дип әйтә бит, нишлим,— дип зарланып алды Наргизә бер заман Сафиягә.— Үзем дә сизәм инде: баланы теләсә кемгә ташлап, иртә-кичен өйдән чыгып китүләре бик читен...

Кыскасы, декрет ялы тәмамланганнан соң, Наргизә театрга кире кайта алмады, зур гына культура сараена эшкә урнашты.

Инде менә барыбер җаны түзмәгән, театрсыз яши алмаслыгына тәмам ышанган икән.

Ләкин мондый мәсьәләләр болай дәррәү генә хәл ителми! Тәмам буталды Сафиянең башы. Спектакльгә хәтле бераз зиһенемне җыйыйм дип, ул театрга иртәрәк кереп китте.

Төнлә, ул кайтып кергәндә, уртадагы өстәл түр тәрәзә буена күчерелгән, уң яктагы диван-карават җәелгән, анда иркенләп Илнур йоклап ята иде. Ә Наргизә, өстәл лампасын кулына тоткан хәлдә, сул стенадагы портрет алдында басып тора.

— Искитәрлек! — диде ул Сафиягә таба борылмыйча.— Артистканың бүлмәсендә шушындый әйбер эленеп тора бит, ә! Кара инде син моның рамын! — ул озын кызыл тырнагы белән акка буялган кысага чирткәләде.— Кара син аның киндерен! — Ул, рамны күтәреп, башын



*Зифа Мөхәммәтҗанова рәсеме.*

кыегайтып, аның астына карады.— Я хода, җөйле киндер куйганнар бит шуңа да. Әйе-е-е, бу инде синңа өч меңлек антиквар түгел, дускаем! Моның ише белән әллә кая китә алмыйсың.

— Ә миңа ошый,— диде Сафия җиңелчә үпкәләп.

— Шулаймы-ыни? — Наргизә лампасын аның йөзенә таба борды.— Алай дисең. Тик син моны миңа гына әйт, дускаем, бүтәнгә ычкындыра күрмә. Югыйсә, зәвыгы бик түбән икән бу артистканың, дип уйларлар.

— Хикмәт киндердәмени, рәсеме матур булсын.

— Син беләсеңме, үзен үзе уважать иткән художник беркайчан да яхшы картинасын, ишетәсеңме, яхшы дип санаган картинасын, мондый киндергә ясамый һәм мондый рамга куймый да. Әйдә, моны стенада тотып, дәрәҗәбезне төшермик. Үзеңне күрәсең килсә, фотоңны зурайтып элрбез.

Портрет янында чын-чынлап тарткалашып алырга туры килде. Ахырда аны урынында калдыруга көч-хәл белән ирешкәч, Сафия коридордагы газ плитәсендә чәй кайнатып керде. Идән уртасына җәелмә ятакка урын салынды, икесе дә төнге күлмәкләрен киеп куйдылар һәм кара-каршы чәй эчәргә утырдылар. Йокы качкан, сөйләшеп эчне бушатасы килә иде. Ләкин Сафиянең зарлары күңелендә түгелмәгән килеш калды, ул дускаен тыңлады. Наргизә терсәкләре белән өстәлгә таянып, бармакларын бөдрәләре арасына батырган да, карашын аска төбәп сөйли, әйтерсең лә, уйларын бер тәртипкә китерергә тырыша иде.

— Беләсеңме, мин аны ярата да башлаган кебек идем бит. Илнур туар алдыннан, аннан да бигрәк ул тугач, беренче айларны. Мәхәббәт тау күчерә, диләр, минем дә алар өчен тау күчерердәй чакларым булды. Тик тауны күчереп буладыр, ләкин оешып утырган болганчык томанны күчерү түгел, кузгатып та булмый икән шул. Их, дускаем, аның күңел томанына бер кояш нуры да үтми бит! Мүк үскән аның йөрәгенә! Әйтә башласаң, үз туксаны туксан: «Минем нормаль яшисем килә!» — Наргизә моны иреннәрен кысып, йөзенә катгый кыяфәт чыгарып, күрәсең, иренә охшатып әйтте.— «Нормаль яшисем килә. Нормаль яшә!» Аныңча инде нормаль яшәү — иртән эшкә китү, кайткач тыгынганчы ашау да газит кыштырдату, телевизор карау, аннары хатын җәеп биргән урынга менеп яту. Менә шул, аныңча, дөрес яшәү.

Сафия көлеп җибәрде:

— Соң, Наргизә, эштән арып кайткан кеше ашамый, ятмый нишләсен инде тагын!

— Их, дускаем, белмисең шул син үз башыңнан үтмәгәч! Шундый кешенең алдына аш китереп куеп, артыннан пычранган тәлинкәләрне җыеп йөргән чакта, нәкъ шул минутларда театрга халык җыелганын, сәхнә утлары кабынганын, пәрдә ачылганын, шунда дусларының бөтенләй башка тормыш белән, кайнап торган хисләр белән яшәгәнен күз алдына китергәч, бәгырьләрнең ничек өзелгәнен белмисең!

— Син аның белән ачыктан-ачык сөйләштеңме соң? Уйларыңны аңлаттыңмы? Артистка икәнеңне белеп өйләнде бит ул.

— Сөйләшмәгән кая! Кеше сүзен тыңлый беләмени, аның һаман үз туксаны туксан. Хатыннарның табигать кушкан үз вазифалары бар, ди. Аларның бурычы — иргә ярау да бала карау, ди. Үләрсең гарьләнеп!

Наргизә сикереп торды, каядыр талпынды, һич булмаса, йөреп килмәкче булды, ләкин ике ятак арасына кысылып калды.

— Әкрен, Наргизә, улыңны уятырсың. Синең Низамың гына түгел, ирләрнең күпчелеге шулай уйлый.

— Ә мин алай уйламыйм. Мин алай уйлый алмыйм!

Наргизә чигә турыннан бармаклары белән чәчләрен өскә күтәреп, туздырып ташлады, әйтерсең лә, башындагы ут ялкынын тышка чыгармакчы булды. Түшләре балантәк белән бизәлгән ак төнге күлмәктән булганга, аның сыны тагын да зифарак, шул ук вакытта көчлерәк һәм зуррак булып күренә. Шекспир трагедияләрендәге хисле хатын-

нарны хәтерләтә, өстәлдәге лампадан кыеклап төшкән яктылык бу тәэсирне тагын да көчәйтә иде.

— Мин әле хатын-кызмы, ирме икәнлегемне уйлап житкергәнче, иң элек йөрәк тибешемне тоям,— диде ул куләгәле почмакка күзләрен төбәп.— Жаным очына минем. Мин кеше икәнемне уйлыйм әле башта. Ә эчендә жаны булган кеше акча эшләп һәм шуны туздырып — ашап-эчеп кенә яшәргә тиеш түгел. Әле янарак кына бөек рәссам Леонардо да Винчиның китабын укып чыктым. Беләсеңме, ул нәрсә дигән? Начар гадәтле һәм буш, тупас сүзле бәндәләрнең безнең тәнебез кебек камил коралга, катлаулы анатомия жайланмасына ия булырга хакы юк, дигән. Алар өчен ризык тутыра торган бер капчык та житеп ашкан, дигән. Каты әйтә бит даһилар, ә? Ашау өчен генә яшәгән кешегә үз тәне харам, димәк. Үз тәне харам, аңлыйсыңмы? Ә ашау өчен генә жир йөзендә яшәгән кешегә ялчы булу ни дигән сүз? Шуны күз алдыңа китерәсеңме? Булса иде ул зур эшләр башкаручы, изге максатлар белән янучы, кешеләргә бик зур яхшылыклар эшләүче. Андыйның аяк астында туфрак булсаң да үкенечле түгелдер. Ә бит мин Низамның эшендә ни белән шөгыльләнгәнен дә белми идем. Бер йоклыйсың, ике йоклыйсың, аннары күздән йокы кача. Театрның шыгрым тулы заллары, биеп торган якты утлар, шул утлар яктысында балкып, сәхнәдән халыкка әйткән ялкынлы сүзләрең искә төшә...

Наргизә өстәл янына килеп утырды, куллары белән битен каплады. Сафия ни әйтергә, аны ни дип юатырга белми, зиһенен жыя алмый аптырады.

— Бергә яшәгәндә, бер-береңә ярашырга туры киләдер шул,— диде ул көрсенеп.— Сабыр итәргә, бер-береңнең көенә торырга туры килә. Гаилә тормышы корбаннарсыз булмый, диләр.

— Гомерне вак-төяккә корбан итәргәме?

Наргизә, башын күтәреп, аңа мыскыллап карады. Сафиягә урын кысан тоелды, ул торып басты да иркенрәк урынга, стенага таба чигенде.

— Әгәр кодрәтемнән килсә, мин, беләсеңме, нәрсә эшләр идем?

— Нәрсә?

— Дөньядагы бар кешене үз тиңнәрен таптырыр идем дә кавыштырып куяр идем.

— Ә үз тиңеңне таба алганың юк әле!

— Без кешеләрне шуңа өйрәтергә тиеш. Үз тиңнәрен табарга, тапкач, мәхәббәтләрен, татулыкларын саклый белергә.

— Үзебез яши белмәгәннеме? Менә минем тормышым соңгы елларда күк күкрәү төсле булды. Әле өченче көн генә шулкадәр ачуым кайнады, пешкән ашымны идән уртасына аудардым.

— Алайса кешеләрне шуңа өйрәтик: без ясаган хаталарны кабатламасыннар.

— Үзләренчә генә хаталансыннармы?

Алар икәүләшеп көлеп жибәрделәр. Тик Наргизәнең көлүе үксү кебегрәк килеп чыкты.

## 5

Пьесаны октябрьнең чытык бер көнендә укыганнар иде. Ул көнне Кадимбикә язмышы томанлы тәрәзәләр артыннан ажаган төсле яктырып узгандай булды.

Шуннан соң һавалар аязып, каты гына суытып алды, бер кар күренеп, кыш үзенең ак япмасын жиргә үлчәп карагандай итте. Ә театр һаман үзенең гадәти тормышы белән яши бирде: көндез — репетицияләр, кичләрен — спектакль. Кадимбикә исеме актрисалар арасында искә алынгаласа да, баш режиссер, әйтерсең лә, аны бөтенләй оныткан иде.

Ноябрь башланды, шәһәр өстенә янә соры болытлар ябырылды, кара көз үзенең соңгы эчпошыргыч яшьләрен түгәргә кереште. Шушы

ямансу дөньяда театр яктылыкны, жылылыкны, рәхәт чакларның истәлеген саклап торган бер почмак булып тоела иде.

Аның калын пыяладан ясалган ак кысалы парадный ишекләре көндезләрен гадәттә ябык тора. Киң ишекләр, мәһабәт мәрмәр баскыч, мәшһүр композиторның бронза сыны куелган иркен вестибюль — болар барысы да тамашачы өчен. Ә артистлар бинаның икенче башындагы кара кысалы ишекләрдән йөриләр. Ул ишек тә пыяла, аңа эчке яктан белдерү ябыштырылган: «Театр борынгы эшләпәләр, зонтлар, котелоклар һәм башка борынгы әйберләр сатып ала». Аның астында тагын берәү — зәңгәрле-кызыллы буяулар белән сырлап-сырлап язылганы, һичкайчан алынмый торганы: «Театрга балта осталары кирәк». Андый осталар һәм эшчеләр адым саен кирәк, аларны чакырган белдерүләр дә гел очрап тора. Тик менә «Артист кирәк» яисә «Сәхнә остасы таләп ителә» дигән белдерүнең бу ишектә булганын хәтерләми әле Сафия. Чыннан да, бүгенге көндә: «Кадимбикә ролен башкаручы эзлибез»,— дип язып элсәләр, бу минутта ишек төбенә ничә кеше йөгереп килер иде икән?

Сафия, үзалдына елмаеп, авыр кысалы ишекне этеп ачты да эчкә керде. Бу — театрның өйалды, сулда эчкә керә торган ишек, уңдагысы ишегалдына чыга, ә каршыда, фанер белән бүлеп алынган куышта, вахтер утыра. Әнә ул шакмаклап уелган тишектән башын тыгып карады. Үз вазифасының мөһимлеген аңлый Җәмил абзый — түгәрәк мөлаем йөзенә кырыс кыяфәт чыгарган. Шулай булмыйни! Көндезге сәгатьләрдә театрның төп хуҗасы бит ул, аның рөхсәтеннән башка моннан уңга да, сулга да беркем үтә алмый. Артист халкы, шаярып, Җәмил абзыйны «оҗмах сакчысы» дип атый. Өстәвенә артистларның икмәге дә күпмедер дәрәҗәдә аның кулы аша үтә диярлек, чөнки аларның радиода, телевидениедә, киностудиядә һәм газит-журналларда эшләгән акчасы килгәнен белдергән почта кәгазьләре нәкъ менә вахтер өстәленә килеп төшә. Шуңа күрә, иртәнге якта артистлар «оҗмах сакчысы»ның күзләренә мөлдерәп карыйлар. Сафия, шакмаклы уем аша башын эчкә сузып, өстәлгә күз салды.

— Бар-бар, сиңа да бар! — диде Җәмил абый.— Унбиш тәңкә!

Һәм «хәбәр»ләрнең берсен алып, аңа сузды. Сафиянең йөзендә ризасызлык күреп, аптырап китте, аннары шап итеп маңгаена сукты:

— Ә-ә, хат та бар бит сиңа! Анысын җыебрак куйган идем.

Ул өстәл тартмасыннан чәчкәле конверт чыгарды.

Сафия ишегалдына узды да, стенага сөялеп, конвертны ертты, эре-эре түгәрәк хәрефләрне ашыгып күздән кичерде. Хат озын иде, ул аны бер сулыш белән укып чыкты, аннары, өйдә тәмләп, иркенләп укып рәхәт чигәсе барын уйлап, кесәсенә тыгып куйды.

Театрның ишегалды шактый иркен: түрдә гараж, аның каршында кечкенә автобус тора. Бүген авылларга спектакль белән китмәгәннәр, димәк. Сулда — кыршылып беткән, коңгырт буяулары купкан ишекләрнең берсеннән артистлар йөри. Янында катыргыдан ясалган өрәңге агачы сөялеп тора, бер ботагы сынып, эченнән калын тимерчыбык тырпаеп чыккан. Эчтә, тар баскыч мәйданчыкларында һәм коридорларда да сәхнә кирәк-яраклары: яшел сандык, кәкре аяклы, сырлы өстәл, биек аркалы кәнәфи.

Сафия белән Исмегөлнең грим бүлмәсе икенче катта, коридорның бирге башында, труппа җитәкчесе Алсу Шаһназарованың бүлмәсе каршында. Алсуның ишеге гадәттәгечә ачык тора, әнә ул үзе дә — башын өстәлгә иеп, нидер язып утыра, кара шома чәче тонык кына ялтырый.

— Сәлам, Алсу, нихәлләр бар?

Сафия аны-моны сорамады, чөнки, яңалык булса, Алсу үзе үк сикереп торып әйтәчәк. Бар да искечә ахры, ул карасу озынча йөзен чак кына калкытып:

— Сәлам! Хәлләр хәер әле хәзергә,— генә диде.

— Исәнме, Сафия апа! — Атылып, Исмегөл килеп чыкты.— Ай, соңга кала яздым, радиога чакырганнар иде.

Алар грим бүлмәсенә керделәр. Исмегөл бер борылды — ишек янындагы чөйгә пальтосын салып элде, икенче борылды — көлмәге үзеннән-үзе диярлек очып, баш очыннан атылып төште дә, пальтосы өстенә кунды, өченче бөтерелүендә стенадагы элгечтә торган күлмәк аның сынын урап алды — итәк очындагы балитәкләр каурыйлар булып җилпенде. Исмегөл тирәсендә җансыз әйберләр дә күнелле биешеп, аңа ярдәм итә иде сыман. Менә ул, яшьлекнең һәм сафлыкның үзе булып, зур күзләрен балкытып, тулы иреннәре арасыннан ак тешләрен күрсәтеп, Сафиягә елмаеп карап тора. Шундый итеп елмая, каһәр, көнләшеп тә булмый үзеннән, сокланып кына була. Бөтенесе нәкъ кирәгенчә, бөтенесе килешле, хәтта ирен өстендә, бераз сулдарак чекерәеп торган нәни кара миңне дә, үзе анда чыкмаса, ясап куярга кирәк булыр иде шикелле. Менә ул көзгесе каршына утырды, көлсу чәч алкаларын ике яктан шома яңаклары тирәсенә җайлап куйды һәм, грим тартмасын ачып, болай да кара керфекләрен нәни щетка белән каралтырга кереште. Бүлмәгә затлы «Сигнатюр» хушбуе исе таралды.

Үзенә кирәкне хәзер эләктереп ала ул, бер генә ишетсен. Узган айны бугай, бер репетициягә инде пенсиядәге халык артисткасы Сания апа Иделская килеп утырган иде. Бөдрәләре тузгыган Гөлгенәне сәхнәдә күреп, чыраен сытты да, гадәтенчә шактый ук кычкырып:

— Их, мин үзем репетицияләргә барганда иң матур күлмәкләремне кия идем, иң затлы хушбуйларымны сөртә идем, мине партнерларым яратсын, режиссер яратсын, карап торган кешеләр яратсын, дип тырыша идем,— диде. Шуннан соң инде Исмегөлдән аерата татлы исләр аңкый торган булды, шуннан соң инде аның чәчләре әле генә парикмахердан чыккан кебек тәртиптә була, тырнак буявы купканын да күрмәссең.

— Әмир абый килеп җитмәгән икән әле, аллага шөкер,— диде Исмегөл иреннәрен очлайтып — ул авыз читен коңгырт карандаш белән буяп азаплана иде. Режиссерның юклыгын да кай арада белеп өлгергән, диген!

Сафия бүлмәдән чыкты.

Коридордан әз генә эчкәрәк керсәң, ул, киңәеп, иркен генә зал хасил итә. Анда кием шкафлары, алар янәшәсендә зур, чуар стена газетасы, ә сулда — тәрәзә, аның бер ягында — зур көзге, икенче ягында пыяла каплаган такта эленеп тора. Белдерүләр тактасы. Артистлар теле белән әйткәндә — «Язмышлар тактасы». Аларның күрәчәге тәкъдирләр дәфтәренә түгел, әнә шуңа язылып бара: кайчан нинди спектакльнең кайда куелачагы һәм анда кемнәр катнашачагы — шунда, яңа спектакльләрдә кемнәргә нинди роль биреләчәге — шунда. Залда тагын урындыклар һәм өстәл бар — өстәл гел бер урыннан икенче урынга күчеп йөри. Сафия барып кергәндә, өстәл өстендә Абилова аягын болгап утыра иде. Зәңгәр пальтосының изүен чишеп җибәргән, бәйләгән ак беретын сары бөдрәләре өстеннән артка шудырган.

— Исәнмесез, Шәфика апа.

— Миңа баш рольне бирүдән куркалар шул алар, котлары оча,— диде ул Сафиягә зәңгәр күзләрен төбәп.

— Нидән куркалар, Шәфика апа?

— Баш рольне уйнатсалар, миңа РСФСРның атказанган артисты исемен бирергә туры киләчәк. Шуннан куркалар. Исемне бирәселәре килми, җәллиләр.

Шунда гына Сафия аның карашы үзенә түгел, ә бәлки читкәрәк — «Язмышлар тактасы»на төбәлгәнен аңлап алды. Йөрәге дертләп куйды — ул кисәк борылды, күз карашы урта бер җиргә эленгән кәгазь битенә төште. Аңа эре хәрефләр белән «Кадимбикә» дип язылган иде. Икенче юл — ваграк хәрефләр белән: «Кадимбикә — Н. Яруллина». Яруллина? Кайсы Яруллина?.. Ә-ә, Наргизә Яруллина... Димәк, Исмегөл дә түгел, Шәфика да, ә Наргизә... Әле театрга кайтып та өлгермәгән, борыны керсә, койрыгы кереп җитмәгән, дигәндәй, ә инде баш рольне биреп тә куялар.

Сафия белдерүнең калган юлларын укый алмый азапланды: хәрефләр күз алдында биешә башлады, һич кенә дә сүз булып оешырга

теләмәделәр. Соңгы юлга җиткәч кенә, ниһаять, алар сикерешүдән туктады: «Режиссер — Р. Бикбау».

Әһә, имәндә икән чикләвек! Димәк, спектакльне баш режиссер Әнвәрбәков үзе түгел, ә яшь режиссер Рәмзи Бикбау куя, билгеле инде, яңа себерке үзенчә себерә.

— Үләремне белә идем, мондый хәл булырын белми идем.

Кем әйтте моны, әллә үзе дә сизмичә, Сафия ычкындырдымы? Юк ла, Шәфика икән. Ул да такта янына килеп баскан. Менә аның ак бармагы тактаны каплаган пыялага килеп төртелде дә, «Яруллина» сүзен сытарга теләгәндәй нык басылып, бөгелеп килде.

— Нинди Кадимбикә булсын инде ул Наргизә, ә?

Шәфиканың күзләреннән бөркелгән зәңгәр ялкын әле һаман тактага текәлеп торган Сафиянең яңагын пешергәндәй итте.

— Сәхнәдән шактый бизгән инде ул, әле кайчан нормага керә,— диде Шәфика.— Режиссерның бөтен тырышлыгын юкка чыгарачак бит ул, күр дә тор!

— Бикбау үзегезнеке бит, Шәфика апа, аңа әйтергә кирәк иде.

Рәмзи Бикбау — Шәфиканың ире, шуңлыктан өлкән артистканың бу рәвешле сукрануы һич тә аңлашылмый иде.

— Әллә син Бикбау сүзен санга сугалар дисеңме? Әнвәрбәков шулай куша. Аның эше бу.

— Сезнең белән киңәшеп эшләсә, бу хәлгә төшмәс иде Бикбау, шулай бит?

Сафия белән Шәфика дәррәү борылып карадылар: Зыятдин Гарәфиев икән, озын буе югарылыгыннан үчекләп, зур авызын ерып карап тора. Сафия тизрәк кире тактага борылды, чөнки теге аның кәефсезләгән күрер дә үчекләргә тотыныр, дип шикләнде. Шәфиканы исә Зыятдинның чиметүе отыры котыртты гына.

— Әмиргә кереп, турысын әйтеп сөйләшим әле. Житте монда бөтен нәрсәне шәхси симпатияләргә корырга. Бер чик куелырга тиеш мона!

Ул пальто чабуларын җилфердәтеп, чыгу юлына юнәлгән иде, каршына килеп кергән Бикбауны күргәч, сөртенгәндәй туктап калды.

— Рәмзи,— диде.— Рәмзи...— Аннары артында авыз ерып торган Зыятдинга борылып карады, тирән итеп сулыш алды.— Без синең белән кайткач сөйләшербез,— диде. Һәм ирен әйләнеп үтте дә чыгып китте.

Яшь режиссер күпереп торган мыегын тешләштереп, залдагыларга шикләнеп күз салды.

— Нәрсә, Рәмзи малай, хатынны үпкәләттеңме әллә? — диде аңа Зыятдин.— Талантка үсәргә ирек бирмисеңмени? Хи-хи-хи...

Рәмзи кызарынып чыгып китте.

— Ә син, Сафия, нишләп әле болай калышасың? — диде Зыятдин.— Чап тизрәк син дә Әмиргә!

Их, бу Зыятдинның телен! Тел урынына без таккандыр аңа табигать! Берәүне дә кызганмый, бәгырьнең иң авырткан төшенә китереп төртә, явыз!

Сафия баскыч мәйданчыгына чыкты. Анда астан салкын җил бәрә, ишекне ачык калдырганнар иде булса кирәк. Аяклар туңып китте, баш та бераз суынды. Ә нигә әле ул режиссерга бармаска тиеш? Башкалар үзләре теләгән рольне сорап заявка биргәлиләр ич, алган чаклары да юк түгел. Әгәр икенче составка куюларын сорыйсың икән, аның ни гаебе бар?

Тик бу хакта Бикбауның үзе белән сөйләшергә кирәк, әлбәттә. Бикбауның исә Сафиядә хәбәре юк һәм булмаячак, аның үз хатыны белән сөйләшеп аңлашасы бар әле. Димәк, андый мөмкинлектән дә файдаланып булмый бу очракта...

Аста аяк тавышлары ишетелде,— кемдер баскычтан менеп килә иде. Сафия, үзен кулга алырга тырышып, кире өскә юнәлде. Алсу Шаһназарова кычкырып телефоннан сөйләшә, ишеге шар ачык булганга, тавышы бөтен коридорга яңгырап тора иде:

— Әмир абый килеп җитмәде бит әле, обкомга чакырып алганнар.

ахрысы. Секретарена шулай дигән. Кайчан киләсен әйтә алмыйм шул.

Сафия залга узды, почмактагы урындыкларның берсенә барып утырды. Әнә, Абилова да борылып килде, такта янында кергән-чыккан артистлар белән сөйләшә. Гомергә шулай инде: артист театрга унбергә килә, эше бармы-юкмы, икеләргә кадәр шушы тирәдә түлгана. Аннары: «Сигез сәгатьлек эш күнә безгә кагылмый шул ул, без көне-төне эштә»,— дип зарланып йөри.

Сафиянең кешеләрне читтән генә күзәтеп, тыныч кына утырасы килә иде. Ләкин ирек бирәләрме соң? Әнә Зыятдин аңа таба борылды, авызын ерып, янына килде, йөзенә иелә төшеп:

— Юкка моңаеп утырма, и сылу! — диде.— Зарыгып көткән кешең килде әнә! Сикереп тор да йөгереп барып каршы ал!

Ишектә Гыйззәт Бикашин күренде.

## 6

Гыйззәт Бикашинның исеме театр тарихында аталмый, сәхнә даһилары арасында саналмый, әмма Сафия аны һәр санаудан соң әйтелә торган «һәм башкалар»га керәдер дип исәпли иде. Бу, аныңча, Гыйззәтнең дәрәҗәсен тамчы да төшерми, чөнки «һәм башкалар»ны да кемдер тәшкил итәргә тиештер бит инде. Менә Сафия үзе бөтен гомерен театрга бирә, талантсыз да түгел, әмма тарихка кереп калырмын дип өметләнми, аңа да шул «һ. б.»лар арасында булуны өмет итәргә генә кала иде. Бик киң мәгънәгә ия бит ул «һ. б.»: анда һәркем үзен бар дип исәпли ала.

Заманында, әле Гыйззәтләр яшь вакытта, татар театры, әдәбияты, музыкасы бер казанда кайнап, бербөтен булып яшәгән дип сөйлиләр. Бу түгәрәк дөнья соңгы елларда ничектер таралыбрак китте, әйтерсең лә, аерым күзәнәкләргә бүленде. Музыка үзенә, әдәбият үзенә аерым йортлар салып, башка чыккан кебек булдылар. Театрда үзенең яңа пьесасын куйдыру хыялы белән йөргән драматурглардан башка шагыйрьләр күренсә, артистлар сәерсенебрәк карый, чөнки кайберләрен бик үк танып та бетермиләр. Ә Бикашинны күргәч, аларның күз карашында, нишләп соң бу абзый монда тинтерәп йөри икән, ник ул өендә рәхәтләнеп карчыгы белән чәй эчеп кенә утырмый икән, дигәндәй гаҗәпләнү чагыла иде. Театрда Гыйззәтне бердәнбер якын күрүче кеше Сафия иде, ахрысы. Моның беркемгә дә, шул ук вакытта абзыйның үзенә дә мәгълүм булмаган сәбәбе бар иде.

Әгәр дә Сафия, бу язучының исеме минем күңел түремдә сигез яшемнән бирле саклана, дисә, моңа хәйран калырлар иде. Хәлбуки бу нәкъ шулай: Гыйззәт Бикашин исеме аның матур истәлекләренә бәйле. Сафия исән чакта ул хатирәләрнең бизәге уңмас-үзгәрмәс инде. Чөнки аларда әтисенең кыяфәте, тавышы саклана.

Сафия икенче класста укыганда, аның әтисе авыл клубында Гыйззәт Бикашинның «Урман шавы» исемле пьесасында уйнаган иде. Сугышта ике аягы да яраланган булып, яралары һаман үзләрен сиздереп торганга, сәхнәдә ул авырлык беләнрәк йөрде. Әмма аның сак, салмак атлавы да Сафиягә роль буенча нәкъ шулай тиештер кебек тоелды. Әтисенең:

> Жилдән житез чаптарларга
> Сус йөгән кидермәбез;
> Жаннан газиз жанкайларга
> Жил-янгыр тидермәбез,—

дип жырлаганын әле кичә генә ишеткән шикелле. Бу күренеш һаман искә төшеп, үзәкне өзеп, гел яңарып тора, аңа узган елларның тузаны утырып өлгерми иде.

Сафия, театр дөньясында Бикашин исеме бик олылап телгә алынадыр, дип уйлаган иде. Ләкин алай булып чыкмады. Ул исем бер дә ишетелмәгәч, Актерлар йортының китапханәсендә актарынды кыз, ки-

рәкле китап анда да табылмагач, башка җирләрдән эзләтте. Ниһаять, аның кулына саргаеп беткән кечкенә брошюра тоттырдылар. Ул латин хәрефләре белән басылган, кайсыдыр киштәләрдә хәрәкәтсез ятып, туз-ган, искергән иде. Сафия брошюра битләрен тетрәнгән бармаклары белән ачты һәм, беренче юлларны укуга, әтисенең елмаю балкышын күргәндәй, тавышын ишеткәндәй булды:

Җаннан газиз җанкайларга
Җил-янгыр тидермәбез!

Их, тидерми иде лә ул җил-янгырларны Сафиягә! Тик гомере кыска булды шул, газиз кызын язмышның көйсезлекләреннән аралап бетерә алмады!

Юк, башка яшь актерлар кебек, үткән заманнарның тере шәүләсе итеп кенә карый алмый иде Сафия Гыйззәткә, өлкән яшьтәге бу абзый аның өчен күңелне кузгата, йөрәкне нечкә сызландыра торган бик якын бер кеше иде. Очрашкан чакларда йөзе үк үзгәреп китә, күрәсең, ар-тистлар да сизеп алганнар, әнә бит ничек үртә Зыятдин. Бикашин, Сафияне күргәч, тураебрак басты, моңарчы кирәксез булып күренгән бер кешедән биредәге тормышның мөһим бер кисәкчегенә әверелгән-дәй булды. Әле генә кибет киштәсеннән алынгандай өр-яңа пөхтә күксел эшләпәсен салып, кулы белән андагы яңгыр тамчыларын сыпырып тө-шерде, туры инбашларын тагын да күтәреп, шундый ук күксел төстәге ыспай пальтосын каккалады. Аның ялтырап торган пеләш башыннан, чиста ак йөзеннән, җыйнак гәүдәсеннән һәм сул кулының чәнти барма-гындагы ифрат калын һәм гадәттән тыш сары йөзегеннән (ул йөзек хакында Зыятдин, саф алтын шуның төсле була, карап калыгыз, 960 нчы пробалы ул, дигән иде) — кыскасы, бу кешенең бөтен кыяфәтеннән шундый затлылык бөркелде ки, залның караңгылыгы, урындыкларның искелеге, идән-түшәменең кыршылганлыгы, көннең басынкылыгы тагын да ныграк сизелде. Әйе, хак әйтә Зыятдин, әгәр дә, алтын балдакларга мөһер сукан шикелле, адәм балаларына да пробаны күрсәтеп мөһер сугыла торган булса, Бикашинга 960 лы тамга куелыр иде. Зыятдин, гадәтенчә, кешедән көлә, билгеле, ләкин аңа карап кына, Сафиянең өлкән яшьтәге драматургка мөнәсәбәте үзгәрми.

Менә Гыйззәт Сафиянең каршына ук килеп туктады, кечелек белән баш иеп, сәлам бирде, килүенең сәбәбен аңлатуны кирәк тапты:

— Әмирне эзләп йөри идем.

— Килеп җитмәде шул әле ул, Гыйззәт абый. Обкомга чакырып алганнар, ди.

— Обкомда аны көне буе тотарлар микән?

— Кем белә, бәлки, кайтып та җитәр. Үзебез дә репетициягә кил-гән идек, шуны көтеп утырабыз. Көтегез соң Сез дә бераз.

— Яңа пьесамны укырга биргән идем,— диде Гыйззәт елмаю аша авыр сулап.— Ике ай тота инде, ни унга, ни сулга бер рәтле сүз әйткә-не юк. Шушы арада тагын бер әйләнеп чыгарсың дигән иде.

Сафия, кырыйгарак шуышып, янындагы урындыкка ымлады:

— Утырып торыгыз.

Гыйззәт, пальтосын салып, пөхтәләп төрде дә урындык аркасына элеп куйды, аннары, Сафия белән ике арада мөмкин кадәр күбрәк ара калдырып, менә-менә кузгалып китәргә әзер кебек, тарсынып кына, урындыкның кырыена утырды. Алар икесе дә керең-чыгып йөргән ар-тистлардан кыенсыналар иде.

— Миңа монда кат-кат килеп йөрүләре бер дә җиңел түгел шул,— диде Гыйззәт, тез башларын сыпыргалап.— Аякларның үзеннән-үзе шушы тарафка атлап торган чаклары узды хәзер. Ник дисәң, безнең ишеләргә якты чырай күрсәтүче юк монда. Элек кенә ул, ишектән керүгә, кая, ни яздыгыз, дип, каршыңа йөгереп киләләр иде. Ә хәзер малаең яшендәге кешенең бер кәлимә сүзенә түгел, керфек сирпеп кара-вына тилмереп йөрисең. Карт ди торганнардыр инде, санга сукмау-ларыдыр. Алар минем белән утырып чәй эчми, турысын әйтеп, ачыктан-

ачык сөйләшми. Тиң күрмиләр шул, чит итәләр. Минем белән яшьләрчә сөйләшеп булмый, дип исәпләүләре.

Сафиянең аны бик тә юатасы килә иде.

— Андый сүзне телегездән дә ычкындырмагыз,— диде ул. Аннары бераз вакыт сүз таба алмый азапланып торды.— Сез әле шундый... шундый... Сез әле яшь егетләргә биргесез!

Ә үзе, арттырып җибәреп, хәтерен калдырмадыммы тагын дип, сиздермәскә тырышып, Гыйззәт тарафына керфек сирпеде. Карады һәм аның кинәт үзгәргәнен күреп алды. И, яхшы сүзнең шифасы, сихере! Җылы сүз ишетсәк, күрәләтә ялганга да мөкиббән китеп куанабыз шул без! Гыйззәт, сынын тагын да турайтыбрак, иркенәебрәк утырды, Сафиягә якынрак авышты.

— Күңелнең бер дә картаерга исәбе юк әле анысы,— диде.— Минем чыннан да акыл белән, нык итеп яши башлар чагым гына. Самый эшләр елларым әле. Синең кебекләр бар чакта, театрда да өмет бетмәс, насыйп булса. Ишек ачып монда кергәндә, синең ачык йөзеңне күреп кенә дә юанам. Мәрхүмә Нәгыймә Таҗдарова шулай бик йомшак, күңелгә ягымлы елмая торган иде. Аның белән чагыштырганга үпкәләмисеңдер бит?

Ничек үпкәләсен инде Сафия! Әле менә үзенең дә күңеле ифрат төшенке чак, үзен дә театрда артык кеше итеп хис кыла иде бит ул. Күз төпләрендә, менә-менә түгеләм дип, ачы дәрья чайпала иде. Гыйззәт килеп кергәч, ул дәрья түгелми генә кире чигенде.

Коридорда Алсу Шаһназарова күренде:

— Әнвәрбәков булмый бүген,— диде шактый ук күтәренке тавыш белән.— Ике көнгә районга җибәргәннәр. Әле генә хатыны шалтыратты. Ишетмәгәннәргә әйтегез анда!

Сафия көрсенеп куйды. Димәк, өйгә кайтырга кирәк. Һәм Наргизә дускайны ачык чырай белән котларга. Эчтә нинди генә утлар янса да, сер бирмәскә, йөзгә-күзгә чыгармаска!

— Миңа үч итеп йөрүедер инде, качуыдыр,— диде Гыйззәт тә янә күңеле төшеп.

— Сез киләсене белә идемени?

— Мине күрүгә, моннан берәрсе шалтыраткандыр. Кызык ясыйлардыр, әвәрә булсын әле, башы әйләнсен, эче пошсын, диләрдер.

Сафия ирексездән көлеп җибәрде:

— Сез нәкъ артист кебек икәнсез, Гыйззәт абый. Мин дә шулай уйлап куйган идем.

— Миннән кача, дипме?

— Юк, бездән качып йөрми микән дип!

— Әллә син дә пьеса яздыңмы?

Гыйззәт Сафиянең йөзенә сагаю белән текәлде.

— И-и, Гыйззәт абый! Кая инде безгә пьесалар язу! Башкалар язган пьесада уйнатсалар да канәгать булыр идек әле!

— Әллә роль бирмиләрме?

Моны ул чиксез гаҗәпләнеп сорады.

— Яхшы рольләр бөтен артистка да җитми бит ул, Гыйззәт абый!

Һәм Сафия тыелып кала алмады, көлемсерәү аша гына булса да, Кадимбикә турында, аны уйнарга хыялланувы һәм бу рольнең башка берәүгә бирелүе хакында әйтте.

Бикашин, башын иеп, зур дикъкать белән тыңлады. Сафияне юатырга ашыкмады, режиссердан ризасызлыгын белдермәде. Ләкин бөтен кыяфәтеннән ишеткәннәрен йөрәге аша үткәргәне сизелеп тора иде.

— Мондагы хәлләр минем генә башыма сыймыйдыр дигән идем. Син дә аптырагансың икән,— диде соңыннан тирән уйланып.— Шундый рольне синдәй артисткага бирмәгәч, ничек яши соң бу театр бүгенге көндә?

Арттырып җибәрде Гыйззәт абзый, чаманы белмичәрәк күтәреп куйды Сафияне. Ләкин чын күңелдән әйтелмәгән мактау иде бит бу,

Сафия аның күрәләтә арттыру икәнен аермачык аңласа да, каршы әйтә алмады, җылы сүз йөрәккә май булып ягылды да телгә бал булып уралды.

Бер-берсен юатышкач, икесенә дә җиңелрәк булып китте. Алар шулай сөйләшеп-гәпләшеп бергә чыгып баралар иде, баскыч мәйданчыгында Сафияне Фәгыйлә тотып алды:

— Синең белән сөйләшәсе сүз бар иде.

Гыйззәт белән хушлашып калырга туры килде. Инде пенсия яшен күптән узуына карамастан, сәхнәдә бик еш күренә торган, гадел-чая апаларны бик табигый уйнаучы, юан гәүдәле, киң битле Фәгыйлә тормышта да туры сөйләшә һәм күңелендәген яшереп тота белми иде. Ул зур коңгырт сумкасында актарынып нидер эзләргә кереште. Бу шактый озакка сузылды. Сафия сумкадан берәр язу чыгамы әллә дип уйлаган иде, әмма кабартмадай кул аннан яшел алма табып алды. Фәгыйлә апа аны шырт итеп тешләде дә калын тавыш белән:

— Ниләр сөйли?— дип сорады.

— Кем?

— Гыйззәтне әйтәм. Нишләп йөри?

— Драматург бит ул, Фәгыйлә апа, яңа пьеса язган.

— Ә-ә, пьеса язганмыни!— Фәгыйлә күзен кыса төшеп, алма чәйнәде.— Башка йомыш белән килгәнме әллә дип торам тагын. Пьеса язган икән алайса. Бөтенләй юк нәрсә артыннан йөри икән, карт пиюс. Пьесаны аны шушы яшькә җиткәч язалармыни? Комың коела башлагач?

— Фәгыйлә апа! Ә соң «Урман шавы»? Талантлы бит ул!

— Талантлы?— Фәгыйлә нәрсәдер эзләгәндәй, баскычтан аска карады.— Талант дисең. Анысы булгандыр да, бәлки. Гөнаһсына кермим. Ләкин бер талант белән генә әллә кая китеп булмый бит әле!

— Ә ни кирәк тагын?

— Тагынмы?.. Тагын... батырлык кирәк әле, җаный. Гайрәт кирәк. Талант бит ул, Сафиякәй, кайбер заманнарда бик авыраеп китә. Ифрат зур йөккә әверелә ул кайчакларда. Аны күтәреп барганнарга һәлакәт яный башлый. Аннан котыласы, ташлап качасы килә. Эх, рәхәт килде шул сезгә замана! Бүгенге талант ияләренә башны балта астына куеп иҗат итәргә туры килми. Инде хәзер Гыйззәт абзаңның да теге чакта ташлап качкан талантын эзләп алырга дәрте купкан, күрәсең.

— Ай-һай каты сөйләшәсез, Фәгыйлә апа! Бер әсәр белән тарихка кереп калган шәхесләр бар. Талантын ташлап качкан дип, аларны кем гаепли?

Фәгыйлә, кулындагы алма үзәген, тагын берәр тешләр җире юкмы дип әйләндергәләп карады да баскычтан аска ыргытты.

— Алай икән,— диде битараф тавыш белән.— Талант дисең. Тик мин сиңа, аның белән җитәкләшеп, югалган талантын эзләргә чык дип киңәш бирмәс идем.

— Бу дигән сүз инде?

— Бу шулай дигән сүз: Гыйззәт үзенең заяга узган гомерен кызгана, яшьлеген сагына. Талантлы буласы килә, яшь буласы килә. Яшь, чибәр артистка белән шаяра, дигән дан кирәк аңа, гайбәт кирәк. Шул гына кирәк тә...— дип, сузып кабатлады Фәгыйлә һәм Сафиянең күзенә тутырып карады.

— Ни сөйлисез Сез... Мин аңа... Теге «Урман шавы»н куйганда, авылда чакта...— Сафия сүзләренә буталды, аннан да бигрәк бу урында, бу ямьсез сөйләшү арасында «әти» сүзен телгә алырга күңеле кушмады. Борылды да, йөгереп, баскычтан төшеп китте.

Ул кайтып кергәндә, Наргизә бизәкле ефәк халатының озын итәкләре белән идәндәге бала-чага уенчыкларын, таралып яткан әйберләрне себереп, әрле-бирле йөренә, кулындагы кәгазь битләрен ачып-ачып карый, аннан-моннан укый, көлә иде.

— Бикбаудан «Кадимбикә»нең бер нөсхәсен талап алдым әле,— диде кәгазь битләрен җирән бөдрәләре өстендә учак утында җилпенгәндәй итеп.— Килде бәхет, килде миңа да, асыл кош койрыгыннан әләкте! Бар ул ходай, бар, биш ел газап чиккәнемнең әҗерен кайтара миңа!

Ул Сафиянең тәбрикләвен ихлас кабул итте, дускаеның кичке спектакльдә катнашмавы аңа тагын бер куаныч өстәде.

— Дару эчереп яткырсана шуны,— дип, мышкылдаган Илнурны Сафиягә тапшырды да тиз-тиз киенеп чыгып та китте.

Баланы җиренә җиткереп, тиешенчә карыйм дисәң, меңнәрчә хәрәкәт ясарга һәм аларның барысын да сабыйның күңелен күтәрерлек йомшаклык, төгәллек белән, назлы-матур сүзләр кушып башкарырга кирәк: чишендерергә, төнге киемнәрен киендерергә, ашатырга, эчертергә, елатмыйча дару эчертергә, башын сыйпарга, юрганын рәтләргә. Һәм, әлбәттә, әкият сөйләргә...

— Борын-борын заманда, кәҗә команда, саескан сотник, үрдәк урәтник булган заманда, яшәгән ди, булган ди, Илнур исемле бер малай. Ул бик батыр булган ди, ул бик матур булган ди. Әнкәсен яраткан ди, апасын яраткан ди...

Сабыйның күзләре ышаныч белән, җан тынычлыгы белән карый. Менә аның куе-озын, алтынсу керфекләре эленә башлады, күзләрендә матур төшнең яралгысы шәйләнде. Менә ул тыныч кына мышлап йокыга талды. Аның йомылган керфекләре гүяки Сафия күңелендәге сызлавыкларны да төшкә әверелдерде. Әйтерсең лә, әле күптән түгел генә Сафия йоклаган, шактый гына күңелсез төш күргән, ләкин менә хәзер инде уянып киткән һәм күңелсез хәлләрнең төштә генә булуына куана.

Күзгә тиз генә йокы керерлек түгел иде әле. Сафия, өстәлне бүлмә эченәрәк тартты да тәрәзә янына барып басты. Тәрәзә театрның ишегалдына чыга, бу яктан караганда аның сарыга буялган стенасы бик гадәти күренә. Ләкин Сафия белә: бу бина урам ягыннан бөтенләй башкача, көзге моңсулыкны һәм төн караңгысын үз тирәсеннән куып, борынгыга тартым лампалары белән яктырып тора. Нәкь менә шушы минутларда ул дәртле адымнар белән килгән халыкны үз янына җыя. Бераздан аның ишек тирәсе бушап, тынып калыр.

Күпмедер вакыттан соң аның ишекләре тагын ачылыр, эчке яктан ташкын булып халык чыга башлар. Ләкин бу инде бая аның эченә кергән кешеләр булмас: аларның уйлары бүтәнчә агар, йөрәкләре башкача тибәр, йөзләре яктырып торыр, сүзләре бөтенләй башка нәрсәләр турында барыр.

6 Театр инде бөтенләйгә тынып калыр, урамнан караганда ул да, башка биналар кебек үк, йокыга талгандай күренер.

Әмма бу бинада төнге сәгатьләрдә гаҗәеп хәлләр була торгандыр. Караңгыда иксез-чиксез тоелган сәхнәдән кайчандыр меңнәрчә кешеләрнең күңелен тетрәндергән шәхесләрнең шәүләләре шуышып үтәдер. Киң ак баскычтан, яңа пьесасын күтәреп, очына-очына талантлы драматурглар менәдер. Көндезләрен һәм кичләрен, фойедагы ыгы-зыгыга битараф хәлдә бер читкә карап, күңелендә яңгыраган көйне тыңлап утырган мәшһүр композитор да, бронза кулларын күтәреп, җилпеп җибәрәдер, һәм тирә-юнь сихри моңга күмеләдер. Икенче каттагы музейда спектакльләрнең кичерәйтеп ясалган декорацияләре зураядыр, һәм аларда чын кеше тормышыннан да зуррак, мөһимрәк, тәэсирлерәк язмышлар кайный башлыйдыр.

...Ә иртән театр бинасы, гримын сөртеп, сәхнә киемнәрен салып, гадәти генә киенгән артист төсле, янәшәсендәге башка биналар белән тигезләшеп калыр. Бары тик аның стенасындагы мемориаль такталар һәм ике ягындагы зур фотовитриналар гына кичке бәйрәмнәрне искәртеп торырлар.

Әнвәрбәковны берәү дә югары оешмага чакырмады һәм районга командировкага да җибәрмәде. Ул хатыны Айзирәктән театрга юри ялганлап шалтыраттырды. Спектакльдә рольләр бүленешен игълан иткән көнне театрда чуалырга башына тай типмәгән бит әле аның!

Андый көнне баш режиссер тынгы белми һәм кирәкле эш белән шөгыльләнә алмый. Бүлмәнең ишеге ачылып-ябылып кына тора: выжт! шарт! выжт! шарт! Нинди дә булса сәбәп тапкан булып, берберсенең күзенә бик үк чалынмаска тырышып керәләр аның янына. Кайсы көчәнеп елмайган, кайсы кашын-күзен җыерган. Сүзне читләтеп, ерактан башларга тырышкан булалар, ләкин, иләп кенә сорашканнан соң, теләкләрнең асылы бер икәнлеге ачыклана: һәркем үзенә нәкъ менә шушы куелачак спектакльдә зуррак, күренеклерәк роль бирелүен тели. Дөрес, аларның барысын да бөтен көченә эшләтәсе, һәр талантны бөтен колачына ачасы бик килә Әмирнең. Һәркайсының көен табып, җаена торып сөйләшергә туры килә, ләкин барыбер күңелләрен күреп бетереп булмый, чөнки теләкләрен үтәү мөмкин түгел.

Сүз белән ничек кенә майларга тырышсаң да, иҗат кешесенең әрнегән йөрәге бу хакыйкать белән килешергә теләми. Шунлыктан, мондый сөйләшүләр дуслыкны ныгыта дип һич әйтеп булмый иде.

Соңгы вакытта Әнвәрбәков котылу чарасын тапты: бер-ике көнгә югалып тора торган итте. Йөрәк ярсуларыгызны үзегезгә генә басарга туры килер инде, хөрмәтле туташлар һәм ханымнар! Үпкә сүзләрегезне тыңлар кеше юк бит әле, килмәгән. Ашыгыч эш белән еракка җибәргәннәр баш режиссерны. Куып тотарлык кына да түгел. Менә бер-ике көннән килер, аннары сөйләшерсез...

Ләкин бер-ике көннән сөйләшү инде җайга салынмаган оркестр шавына охшап тормас, аерым музыка кораллары тонында гына барыр. Ул чакта инде актрисаларның тиз кабынучан йөрәге ургуын киметкән, бераз җаена төшкән булыр. Күпчелек үз сүзләрен генә сөйләп маташмас, кеше сүзен дә тыңлый алыр.

Шуларны уйлап, Әмир, давылдан качкан юлчы кебек, өендә посып утыра иде. Әйдә, Бикбауны талкып алсыннар әле, яшь кеше, бераз өйрәнә-чыныга торыр. Әмир, авызын турсайтып, чал кергән мыегын кармалап, ничә атналар буе кулы бармаган һәм искә төшкәндә үк саруны кайната торган бер әйберне — Гыйззәт Бикашинның «Теге якта» исемле пьесасын, ниһаять, укып чыкты. Укып чыкты да, шактый вакыт башын иеп, аптырап утырды. «Исеме җисеменә бик туры килә икән,— дип уйлады моңаеп.— Әсәре дә теге якта шул, сәнгатьнең теге ягында».Нигә шушындый әйбер язалар икән дә нигә аны күтәреп йөриләр икән? Һәм, иң аянычы, нигә шуларны укырга баш режиссерны мәҗбүр итәләр?

Кульъязма янына тагын берничә кәгазь бите куелып, аларда шактый абруйлы дүрт-биш кешенең бу әсәрне укып чыгуы һәм бик тә хуплавы әйтелгән иде. Ә нигә мактамасыннар алар? Рәхәтләнеп мактыйлар, авторга ярыйлар һәм... бетте-китте аларның эше шуның белән! Әгәр режиссер булмаса, Әмир дә шулай итәр иде һәм Гыйззәт каршында бик яхшы күренер иде. Ә режиссер дөресен әйтергә мәҗбүр, чөнки пешмәгән әсәрне яхшатланып мактый алмый, мактаса, аны сәхнәгә чыгарырга тиеш.

Кире кайтарырга туры киләчәк иде бу әйберне, һәм бик тә, бик тә күңелсез эш иде бу. Әнвәрбәковның да эчендә җаны бар, аның да кеше кәефен кырасы килми. Яхшылык кылып, башкаларны сөендерүгә һәм үзең дә куануга ни җитә!

Әмир кульъязма папкасын читкәрәк, гәзит-журнал өеменең астынарак шудырды. Папка күздән югалды, ләкин аның урынына өем астыннан зәңгәр тышлы калын дәфтәр килеп чыкты. Абилованың «гариза»сы. Барыбер кәеф кырылган иде инде, берочтан Әмир аны да укып бетерергә

ниятләде. Дөресен генә әйткәндә, бу дәфтәр аңа Бикашин пьесасыннан кызыклырак тоелган иде. Бер уйласаң, әллә нинди сәләтләр ята бу артистларда, ачылмаган мөмкинлекләр әрәм була. Абиловага да, бәлки, язучы һөнәрен дә үзләштерергә кирәктер? Язарга ярата икән бит, тырыша торгач, тагын да остарып китәр иде әле. Менә, теге көнне туктаган бите дә бөкләнеп куелган икән. Әмир җайлабрак утырды.

«Мин театрда, сәхнә артында үстем,— дип укырга кереште ул.— Уенчыкларым — әнинең грим савытлары, ялган асылташлар, бакчам — декорацияләр, сулаганым — буяу-җилем исе һәм сәхнә тузаны булды. Хәер, тормышның зилзиләләре мине шуннан да эзләп табып, бөтереп алып бәргәләгәннәр. Биш айлык чагымда мине басмачылар урлап киткән. Әтием ЧКда эшләгән минем, шуны белгәннәрдер инде. Биш айлык чагымда мине, алыптай зур бер ир кешегә алыштырып, кире әниемә кайтарганнар. Күрәсез, иптәш Әнвәрбәков, ул чакта ук безнең башлар бәяле иде».

«Шунда да чеметеп алырга җай таба үзе»,— дип уйлап куйды Әмир.

«Бүтән балалар кебек, миңа, үскәч, кем булырмын икән дип, баш ватып интегергә туры килмәде. Дөньяда әллә ничә мең төрле һөнәр барын белерлек яшькә җиткәнче, мин сәхнәдә беренче рольләремне күптән уйнаган идем инде һәм театрдан читтә яшәүне күз алдына да китерми идем.

Менә Хәмзә театрында «Любовь Яровая» бара. Минем әни — Баронесса. Балитәкле купшы күлмәк, каурыйлы эшләпә кигән, таныклык та түгел. Ул, киң селтәнеп, муенына озын ак яка — горжетка салганда, чыннан да җиде буын аксөяктән бер дә ким булмагандыр.

Спектакльдә миңа да роль бирелде — урам баласын уйнарга куштылар. Режиссер абый мине өйрәтә: «Син — ятим малай, атаң-анаң юк,базарда аны-моны урлап тамак туйдырасың,—ди.—Сәхнәдә берәрсенең әйберен чәлдерергә тырыш. Тик шундый оста итеп урла, артист үзе сизмәсен, тамашачы исә аермачык күреп торсын». Күрәсез, иптәш режиссер, шул чакта ук инде минем алга тәҗрибәле актерлар гына чишә алырлык иҗади бурычлар куела иде. Һәм мин ул бурычларны җиренә җиткереп үтәп тә чыктым. Тормышчан образ тудыруның катлаулылыгын әнә шулай сигез яшемдә үк аңладым. Чыннан да, тамашачы күреп торырлык, ә артист үзе сизмәслек итеп, кемнең нәрсәсен чәлдерергә? Төннәр буе йоклый алмый, шул хакта баш вата идем. Чын мәгънәсендә иҗади эзләнүләр иде бу. Ә хыялларым һаман бер тирәдә — Баронессаның озын горжеткасы тирәсендә бөтерелә. Курчагымның бишмәт якасына бик тә матур булачак иде андый ак мех.

Шулай итеп, мин героемның эчке дөньясын тудырырга тырыштым, ә тышкы дөньясын тудыру минем өчен берни тормый, чөнки әтием инде берничә ел вафат, әнинең гомере театрда уза, мин исә шул урам малайлары белән сугышып үсеп килә идем. Премьерага барганда, мин куенына кайчы яшердем. Спектакльнең бик кызган минутында әнинең тамашачыга аркасы белән борылганын сагалап тордым да, чыжт итеп горжетка якасын телеп тә алдым. Залда халык эче катып көлә — баронесса берни сизми. Халык шаулатып кул чаба — ә ул үзен алкышлыйлар дип уйлый. Мин исә түбәм түшәмгә тиярлек булып кинәнәм.

Тамашачы хуплавының, алкышларның сихерле балын мин шул кичтә беренче тапкыр эчтем һәм гомерлеккә агуландым. Авыз ерылган, эчтән куаныч ташый, тизрәк әнине дә сөендерәсе килә. Ул сәхнәдән чыкканда, мин аны горжетка кыйпылчыгы сузып каршыладым. Башта ул берни аңламады. Ә мин көләм, тәгәрәпләр китәм. Менә ул муенындагы горжеткасын күтәреп карады, эшнең нидәлеген аңлады һәм... мине үзенчә тәгәрәтеп җибәрде. Мин сикереп тордым да сәхнә артындагы әйбер-кара арасыннан сикерә-салулый чабып киттем, ул мине куа башлады. Мин чабам — ул куа. Режиссер ярдәмчесе, сөйкемле генә бер апа, әнине ко-

чаклап туктатмаган булса, белмим, ни белән тәмамланыр иде бу качыш-куыш уены. Әнинең талканы бик коры иде яшь чакта, кызып китсә, чаманы белми иде. «Син сәхнәгә кайчы алып чыга торган булма, әйбер-кара турап йөрмә»,— диде шуннан соң миңа режиссер. Мин яңа кәсепкә керештем, икенче спектакльдә Любовь Яроваяның чәч тарагын чәлдердем. Сара апа уйный иде Любовь Яроваяны. Ул да берни сизмәде. Ә халык күреп тора, халык көлә, кул чаба. Танылган артисткада түгел тамашачының күзе, миндә! Җиңдем тегене, уздырдым! Актерлык гомеремдә минем бүтән беркайчан да шулай куанганым, бернинди шикләнүсез, мөлдерәмә тулы бәхет кичергәнем булмады. Чөнки аннан соң башкарган рольләремнең иң уңышлыларында да җитешсезлекләр табарга өйрәндем. Ә ул чакта әле мин, бәхеткә, үзүземнән гаеп эзләү кебек начар гадәттән азат идем, тәнкыйтьчеләр дә минем белән булышу кәсебенә керешмәгәннәр иде.

Кызганычка каршы, ул бәхет тә озакка бармады. «Җитте, моннан ары сәхнәдә караклык белән шөгыльләнмә, еламсырап, хәер эстәп кенә йөр»,— дигән күрсәтмә бирелде. Күрәсез, иҗатымны чикләүче беренче кеше сез түгел, иптәш Әнвәрбәков.

Болай иркенләп яза башлагач, күңелдә калмасын, барысын да әйтим инде: син минем бер үзенчәлегемне әллә аңламыйсың, әллә аңлап та исәпкә-санга сукмыйсың. Җәйге таңда тәрәзәләрен сандугач моңына ачкан яшь кыз кебек, минем күңел тәрәзәләрем моңга, музыкага гына ачыла. Алты яшемнән балет мәктәбенә йөрдем, сугыш башланып, Казанга кайткач, кордебалетта да биедем. Мин хисләремне моңга кушып белдерергә яратам. Кызганычка каршы, безнең театрда соңгы вакытта музыкаль спектакльләр сирәк куела. Нигә соң театрда музыканы күбрәк яңгыратмаска! Күп актрисаларга канат үсәр иде. Минем көй уңаена гына ачыла алганым укыган чакта ук билгеле булды. Мәскәү студиясенә кергәндә, шактый сәхнә тәҗрибәм бар иде инде, шуңа күрә үземне мәктәп партасыннан аерылып кына килгән курсташларымнан бер башка өстен дип уйлаган идем. Әмма, ни гаҗәп, уку миңа ифрат авыр бирелде. Этюдлар уйный башласам, бөтен сүзем, хәрәкәтем ясалмалык, фальшь килеп керә, шуны үзем дә тоеп агачланам да калам. Инде студияне ташларга кирәк дигән фикергә килә башлаган идем, укытучыбыз Анна Ивановна Ельцова тотып калды.

— Күрегез дә торыгыз, безнең Шәфика менә дигән героиня булачак,— ди торган иде ул.

Икенче курста чакта Хәбир Батыркаев белән икебезгә «Курчак» этюдын әзерләргә туры килде. Хәтерлисеңдер, ул сүзсез, музыка белән генә бара. Шунда минем җаным-тәнем кинәт уянгандай булды. Аңарчы мине моңсызлык миңгерәүләткән, тәмам изгән икән. Үземне, ярда озак әлсерәп ятканнан соң, кинәт дулкын бәреп, киң диңгезгә чумган балыктай хис иттем. Һәр хәрәкәтем төгәл, иркен, нык, һәр адымым ышанычлы булып китте.

— Менә күрдегезме, әйттем ич мин сезгә!— диде шунда Анна Ивановна минем курсташларга.

Яшьлектә көткән бәхет килми калмый, хәзер генә менә өметләрем акланмый торган чак җитте...

Хәбирне беләсең, тик тора алмый ул. Ниләр генә уйлап чыгармады ул шул «Курчак» белән! Мин (Курчак) ватылам, ул (Оста) төзәтә. Шуклык өстенә шуклык өсти торгач, без аны егерме минутлык концерт номерына әйләндердек. Шул номер белән, филармония бригадасына кушылып, җәйге айларда күп кенә авылларда да булдык. Тамашачылар минем «Курчак»ны хәзер дә онытып бетермәгәннәр әле. Актриса Абилова менә шуннан башланды да инде. Хәбирнең дә режиссерлык сәләте шунда ачылды.

Минемчә, «Кадимбикә»не музыка белән сугарып куярга кирәктер.

Кадимбикә төшләремә моңга уралып керә. Әйтерсең лә, мин Кадимбикә булганмын һәм талгын моң ритмына атлап йөрим...»

Бу урында Әмир, күзләрен йомып, сынын турайтты, башын артка ташлап, кәнәфи аркасына терәлде. Нәрсәне хәтерләтте соң әле Шәфиканың бу сүзләре! Кем шулай аяк очлары белән күңел кылларын чиртеп узгандай атлый белә иде?

Хәдичә! «Гүзәлем Әсәл»дәге Хәдичә-Абилова. Әмир бер спектакль вакытында, хисләренә түзә алмый, сәхнә артына йөгереп менгән иде: «Нишлисең син, пәри кызы! Нишләтәсең йөрәкне? Сихерче икәнсең, билләһи!»

Әгәр дә Кадимбикә аяк басулары белән генә дә күңелләрне шулай кузгата торган булса, ә?

Ләкин Әмир хәзерге Абилованы күз алдына китереп көлемсерәде генә. Кая китте аның адымнарының кешеләрне тәкатьсез итә торган тылсым көче! Сәхнәдән йөрәк түренә баса-баса чыкканын тетрәнеп көткән минутлар кайда калдылар? Кайчан, кайсы көннең ничәнче сәгатендә Шәфика дигән гүзәл кыз шушындый болганчык «гариза»лар язып, роль сорый торган Абиловага әверелде? Ай-һай шәфкатьсез икәнсең син, вакыт!

Театрда Солтанбаевалар барда, Абиловаларга әкрен генә арткарак чигенергә вакыт житә башлаган ахры, ләкин кайчан кайсы артистның үз теләге белән артка чигенгәне бар да, олыгайгач, кайсының сөенә-сөенә пенсиягә киткәне бар! Алар, сәхнә тузанын сулап, үтәли жилләрдә, көчле утлар яктысында гына үсә алган гөлләр кебек, өй һавасына күчереп утыртуга мантудан туктыйлар. Әле менә Сания апа Иделскаяны, житмеш еллыгын бик зурлап үткәргәннән соң, кадерләп пенсиягә озатканнар иде. Аңарчы бөтерелеп йөргән апа, берике ай эчендә бөрешкән карчыкка әйләнгән дә куйган. Кайчак репетицияләргә килгәли, бер читтә тын гына утыра. «Нихәлләрең бар, Сания апа?»— «Хәл юк инде, каян булсын. Өйдә тик утыра-утыра кабер ташы исләре килә башлады». Кабер ташының да үз исе бар, күрәсең.

Бер уйласаң, сәер халык та инде бу артистлар. Әйт син менә шушында берәр эшчегә, хезмәткәргә, эшкә барып йөрмәсәң дә була, акчаны болай гына да бирөп торырбыз, диген. Күпчелек бу тәкъдимне ишеткәч, сөенеп бетә алмаячак. Артистларга шулай дип әйтеп кара — коелып иңәчәкләр. Аларга гомер буе роль житми. Көненә икешәр спектакльдә уйнарга, алсыз-ялсыз эшләргә әзер алар. Синнән Кадимбикә чыкмый дип, ышандырып кара син актрисаларның берәрсен!

Бәхеткә, Шәфиканы ышандыру Әмиргә йөкләнми иде. «Ашыгыбрак язгансыз бит бу гаризагызны, иптәш Абилова,— диде Әмир эченнән генә.— Бераз сабыр итәсегез калган. Гаилә хәлләрегез дә бик түгәрәк түгел ахрысы. Югыйсә, ирегезнең яңа спектакль куярга әзерләнүен белмичә, кичләр буе моны язып утырмас идегез. Хәер, язудан гына зыян булмас анысы. Без аны тиешле кешесенә житкерербез».

Ул дәфтәрнең беренче битен ачты да, сул чатына кыеклап, эре итеп: «Режиссер ип. Бикбауга, җавап бирү өчен»,— дип язды һәм бик тәмләп имзасын сырлады.

8

Кеше алдында сер бирмәскә тырышты Шәфика, ләкин эчендә иренә үпкәсе чутсыз-чамасыз иде. Өйгә кайтса, әнисе алдында ярсуын тыя алачагына ышанмады, шуңа күрә училищеда дәресе башланган сәгать житкәнче, театрда тулганды. Ниһаять, сәгать өченчедә генә күрше урамдагы культура йортына төшеп китте. Театр училищесының бинасы бик кысан булганга, сәхнә хәрәкәте дәресләре шунда үткәрелә иде.

Юл буе күзенә ак-кара күренмәде, юл буе ул эченнән Рәмзине

тиргәп барды: «Тешләк! Спектакльне мин куям дип ялгыш та ычкындырмады бит ичмасам! Ә мин, адәм хуры булып, Әмиргә Идел буе гаризалар язып утырам! Куенымда кара елан асрап ятам икән!»

Уйлары бүтәндә булганга, ул дәресен дә рәтләп алып бара алмады. Юк кына нәрсәгә дә йөрәге ярсып, артык кызып китүдән көчкә-көчкә генә тыелып калды. Алай да берсендә бөтенләй үк тыелып бетә алмады, кинәт кабынды. Эльвира белән Яхъя исемле студентлар этюдын тикшергәндә булды бу. Этюд бик күңелле һәм төсмерләргә бай иде. Эльвира ларекта бал сатып тора, имеш. Аның янына савыт тотып, бер-бер артлы хатын-кызлар килә, ә сатучы бик дорфа кылана, әрепләшә, үчекли. Ә инде янына чибәр егет килеп баскач, бөтенләй алыштырып куйгандай була, елмая, аның күзләренә генә карап тора, ярарга тырыша, бал белән сыйлый. Алар баш очында безелдәгән шөпшәләрне куалар, парлашып җырлап алалар, кич очрашырга сүз куешалар.

Этюдны Шәфика Эльвира өчен махсус сайлап алды. Тар чалбар белән кысан свитер киеп йөри торган бу кыз бөтен торышы, кыланмышлары белән үсмер малайны хәтерләтә иде. Озын муен, ак чырай, каш өстеннән тигезләп киселгән көлсу, шома чәч. Нечкә беләкләр, кечкенә күкрәкләр. Мондый тыйнак хәзинәне кысан свитерлар, тар чалбарлар белән алай ук күрсәтеп куярга ярамас иде, киң җиңле, балитәкле күлмәк килешәрәк төшәр иде. Ләкин инде ул кадәресен үк күзгә карап әйтергә кыенсына Шәфика, ә читтән суктырып әйткәнне Эльвира аңлап җиткерми, бәлки, укытучысының зәвыгы белән килешәсе дә килмидер.

Этюдның беренче өлешен — сатучы кызның хатыннар белән ызгышканын әйбәт кенә тасвирлый. Ләкин инде егет каршында сөйкемле итеп елмая да, җанга ятышлы итеп кылана да белми. Мондый кызлар егетләр белән бер кашыктан бал ашарга түгел, янәшә басып тәмәке тартатергә генә ярый. Шәфиканың анда ничек тә булса нәфислек, нечкәлек, мөлаем тыйнаклык уятасы килә иде.

— Булмаса да булмый икән инде,— диде ул кинәт кызып.— Ничә тапкыр әйттем бит инде мин сиңа: өйдә көзге каршында күнегүләр ясарга кирәк.

— Ясыйм мин, ясыйм,— диде Эльвира керфеген дә какмый аның йөзенә туры карап.— Көн саен ясыйм.

— Ясагач, күрмисеңмени егетләрне гашыйк итәрлек түгеллегеңне? Менә бит син юк кашыкны бар итеп тота беләсең, аның астыннан тамган балны ышандырырлык итеп сыпырып аласың. Ник син шуны йомшак, нәфис итеп эшләмисең, тупас кыланасың ә? Бу егетне син балга баткан бармагыңа гашыйк итә бел! Ә синең агач бармагыңа, төртеп тишәрдәй терсәгеңә нинди егет гашыйк булсын инде, я! Яшь бит әле син, пенсионер карчык түгел!

Шәфиканың күңелендәге ярсуы, кинәт буасын ерып ташыган су шикелле, Эльвираның көлсу чәчле йомры баш түбәсенә шарлавык булып коелды. «Пенсионер» сүзен ишеткәч, кыз, электр тогы суккандай, дерт итте, кисәк башын күтәрде. Аның болай да ак чыраеннан кан качкан, яңаклары тимгелләнеп чыккан, ә күзләре... яшел сөрмә тарткан соры күзләр шар ачылганнар, алардан җан газабы бөркелә иде. Таныш караш иде бу, таныш газап! Рольне начар башкарган өчен тәнкыйтьләнгән артистлар шулай һушыннан язып кала. Үсмер малайга охшаш бу кызның хәсрәтендә Шәфика үз-үзен бүген иртәдән бирле газаплаган әрнү белән уртаклык күренде.

Ул, бу карашка түзә алмый, керфекләрен түбән төшерде, башка студентлар белән сөйләшкән булды, аларның этюдларын тикшереп азапланды. Ләкин эшенең дә, сүзенең дә рәте юк сыман тоелды, чөнки ул һаман әле Эльвираның әрнүле карашын сизеп тора иде. Аңа бик оят иде, кызып китеп, шундый авыр сүзләр әйтеп ташлавына, бигрәк тә моның башка студентлар, егетләр алдында әйтелүенә үкенә иде

Шәфика. Нигә шул хәтле каты бәрелде соң әле шәкертенә? Яшьлегендә үзе дә шундыйрак язмыш кичермәдемени? Күпме йөрде бит ул сабакташлары арасында сәләтсезрәге булып! Ләкин Анна Ивановна аңа каты бәрелмәде, «Ачылачак әле безнең Шәфика, менә күрерсез»,— дип, һаман үсендереп торды. Абилова бу студентларның анасы урынына куелган кеше, ә ана кимчелекле баласын ныграк яратырга, аңа саграк килергә, игътибарлырак булырга тиеш.

Кеше газапларын үзенекеннән авыррак кичерә, берәрсенең бармагы киселгәнен күрсә дә һушыннан язарга житешә торган Шәфика, яшь кызның жаны әрнүен сизеп, үз хәсрәтләрен бөтенләй онытып жибәрде.

Ул дәресен иртәрәк тәгәлләде. Октябрь бәйрәменә хәтле башка очрашмаячакларын истә тотып, барысын да котлады.

— Авылдан килгәннәр өйләренә кайта торгандыр инде,— диде.— Әти-әниләрегезне минем исемнән дә тәбрикләгез.

— Кайтабыз, котларбыз,— диештеләр. Эльвира гына дәшмәде. Ул тәрәзә янагына сөялеп, кулларын күкрәгенә кушырып баскан, йөзе күләгәдә калганга, ни уйлаганын белеп булмый иде. Әгәр шунда берәр сәләтле рәссам туры килсә, бу кызның нечкә сынын үзенең «Сагыш» яисә «Моңаю» исемле картинасына өлге итеп ала алыр иде.

— Ә син, Эльвира?

— Безнең Себер ерак бит, Шәфика Сафиулловна. Дүрт көн эчендә генә кайтып та житеп булмый. Самолеты очамы-юкмы әле мондый көннәрдә.

Башкалар китте, ә Эльвира калды. Шәфика да ничектер тиз генә чыгып китә алмады.

— Хәзер нишлисең инде?

— Фатирыма кайтам да... ятам.

— Квартирың ничегрәк соң синең?

— Бер авыру әби белән торабыз.

— Бергә үкмени?

— Бер бүлмәдә.

Училищеның тулай торагы юк, шунлыктан булачак артистлар студент тормышының бик күңелле бер ягыннан — бергәләшеп гөрләшеп яшәү бәхетеннән мәхрүм иделәр.

— Әйдәле, Эльвира, мине озатып куй.

Әллә ничек уйлап житкермичәрәк әйтеп ташлады моны Шәфика. Эльвира, сискәнеп, тәрәзә янагыннан аерылды, аның күзләре күләгәдә ялтырап китте.

— Сезнеме? Яхшы булырмы соң?

— Үзем чакырам икән, бару яхшырак.

Эльвира, кире уйламасын бу тагын дигәндәй, тиз-тиз атлап, ишек янына барды, урындыктан кара курткасын һәм озын баулы сумкасын алды.

— Мин үзем, кыюлыгым житеп, Сезнең ишекне барып кага алмас идем әле.

Шәфика, бүген беренче тапкыр күңеле жылынып, көлеп жибәрде:

— Нигә, бер дә якын итмисеңмени мине?

— Сез бит шундый олы кеше, Шәфика Сафиулловна. Шундый олы!

— Ну, актриса өчен олы булу кимчелек кенә ул.

— Юк, мин яшь ягыннан әйтмим, талантыгыз белән, ирешкәннәрегез белән олы Сез!

— Минем яшькә житкәндә, син алай гына да булмассың әле.

— И, кая инде ул безгә!

Шәфика телен аркылы тешләде, баягы сүзләре исенә төште.

Урамда салкын яңгыр кыска-кыска бәрә, тротуар кырыеннан гөрләвек йөгерә, машина тәгәрмәчләре астыннан пычрак су чәчри иде.

Ел тәүлегендә була торган иң шыксыз көннәрнең берсе иде бу. Ләкин соры болытлар аларның күңелен басмады, салкын яңгыр туңдырмады, чөнки алар икесе дә баягы үпкә-кыйналуның үтүенә сөенәләр иде. Шәфика үзенең дә баштарак авыр ачылып китүе, тик укытучысының аннан өметен өзмәве хакында сөйләп алды. Эльвираның бераз карлыкканрак тавышы башка чакта Шәфиканың эчен пошыра иде, ләкин бу юлы ул үзенчәлекле, тирән, күкрәк түреннән чыккан сыман булып тоелды. Күп кенә кызлар яшеренеп тә, ә кайчакта ачыктан-ачык та тәмәке тарткан бу заманда актрисаларның калын-карлыккан тавышы хәтта модага да кереп бара иде бугай инде. Һәрхәлдә, үзәк телевидениедән андыйлар шактый еш чыга. Кыскасы, бу кызга да үз стилен табарга ярдәм итәргә кирәк. Килбәтсез үрдәк бәбкәсеннән мәгърур аккош үсеп чыга кайчакларда.

Баскычтан менгәндә үк, кызган май исе сизелде, ишек ачкан Мөкәррәмә, кунакны күреп, елмаеп исәнләште, куллары юеш булганга гафу үтенеп, алпан-тилпән атлап, ашыгып, түр яктагы кухняга кереп китте.

Курткасын салып элгәч, Эльвира бик кыенсынып кына, музейга кергән кыяфәт белән залга үтте. Стеналарга эленгән пыяла шкаф киштәсенә, китапларга сөяп куелган фотоларны карап чыкты, Шәфиканың төрле рольләрдә шулкадәр күп кыяфәтләргә керүенә сокланды.

— Мин сезнең бик аз рольләрегезне генә беләм икән бит, Шәфика Сафиулловна! Ә сез менә нинди бай икәнсез!

— Барысын да белергә син яшь бит әле. Аны байлык дип тә булмый инде. Артистның иҗатыннан, калса, менә шушы фотолар гына кала.

Кухня ягыннан шулчак:

— Кызым, кил әле, өлгерә алмыйм,— дигән тавыш ишетелде.

— Туктале, әни, өсне дә алыштырып өлгермәдем ич, — диде Шәфика ризасызлык белән.— Азапланасы да түгел иде,— дип өстәде тавышын әкренәйтеп.— Нәрсәгә соң ул пылау, юанаер өченме тагын?

— Мин барып килсәм ярыймы соң, Шәфика Сафиулловна? Бәлки, берәр ярдәм кирәктер?

— Теләгең бар икән, рәхим ит!

Шәфика халатын киеп чыкканда, Мөкәррәмә белән Эльвира газ плитәсенә куелган чуен казан тирәсендә кара-каршы басып торалар иде. Кыз Шәфикага борылды да:

— Мин пылауны гел дөрес пешермим икән бит, Шәфика Сафиулловна,— диде.— Карагыз әле, май ничек кызган, янына барырлык түгел.

— Майны төтене агарганчы кыздырырга кирәк,— диде Мөкәррәмә иреннәрен кысып, үзе уң кулының учын түбән каратып, казан өстендә уңга-сулга талгын гына йөртте.— Әнә, күрәсезме? Булып жита бугай инде. Май болгаткан чүмечне чи иткә тигереп карасаң да ярый. Чүмеч иткә ябышса, май әзер дигән сүз. Аңа иң әйбәте — мамык мае инде. Көнбагыш маенда алай тәмле булмый ул. Мамык маен миңа Ташкенттан җибәреп торалар. Әнә, Шәфика белә.

— Миңа сөйләгез сез, миңа, — диде Эльвира илһамланып.— Шәфика Сафиулловна болай да белер.

— Пылауны әни пешерә бездә,— диде Шәфика.

— Әниләр...— дип нидер әйтмәкче иде дә, сүзен өзде Эльвира. Ләкин шундук яңасын тапты.— Сез бик бәхетле, Шәфика Сафиулловна, гомерегез буе әниегез янында яшисез. Ә менә мин... Миңа пылауны үземә пешерергә кала.

Ул майлы сөремнән каралган түшәмгә карап көлемсерәде, башын чайкады, аның бу хәрәкәте һич көтмәгәндә кызларча нәфис, ягымлы килеп чыкты. Ул казанны каян алганнарын сорады — анысын да Мөкәррәмәгә Үзбәкстаннан җибәргәннәрен белгәч, әкренләп сүзне элекке заманнарга күчерде. Өлкән артистка өчен бу — көтелмәгән сөенеч булды, чөнки кызы янына яшьләр килгәләсә дә, Мөкәррәмә бе-

ләп ачылып сөйләшмиләр, әллә өлкәннәр сүзенең кызыгын тапмыйлар, әллә алар белән сүз ялгый белмиләр. Ә бу кызчык күңелгә әнә ничек майлагандай шома үтеп керә икән бит! «Юк, мин үзем гаепле, мин аңа ачкыч таба алмыйм, ахрысы»,— дип уйлады сиздерми генә шәкертен күзәтеп торган Шәфика.

Казан янында өч кешегә урын тар иде. Шәфика зал ягына чыгып, үз эшенә утырды. Тегү эшен ярата ул, күп кенә рольләренә костюмнарны үзе уйлап чыгара, үзе тегә иде. Гомумән, театрда костюмнарны тегү, аларның эскизларын ясау эше тиешле дәрәҗәдә җайга салынмаган. Абилованың костюмнар тегү осталыгы рольләрен уңышлы башкарып чыгуга бик тә ярдәм итә иде. Аның тутый кошлар, күз күрмәгән чәчәкле агачлар чигелгән ак ефәк пижамасы бар иде. Кытайда тегелән пижама. Элегрәк гастрольләрдә йөргәндә, Шәфика аны кигәли иде һәм ул костюм аның зифа буена бик тә килешә иде. Хәзер шул тараеп киткән, ләкин ефәге нык әле, чигешләре дә уңмаган. Шәфика шуның чалбарыннан итәк чыгарып, халат итмәкче иде.

Башка вакытта кул эше аңа җан тынычлыгы иңдерә торган иде. Ләкин бу юлы күңеле бер генә дә урынына утырмады. Баскычта аяк тавышлары ишетелгән саен йөрәге урыныннан кузгалып куйды, әмма адымнар узып китә тордылар. Хәер, Рәмзи бүген алай иртә кайтырга тиеш тә түгел, элегрәк үзе куйган «Сагыну» спектаклен бүген тагын бер тапкыр карап кайтырга ниятләгән иде ул. Әле кичә генә «язмышлар тактасы» янында Зыятдин, бөтен грим бүлмәләренә ишетелерлек итеп: «Рәмзинең «Сагынуы» бетеп тә килә инде,— дип, кычкырып сөйләп торган иде.— Тузып беткән ул спектакль, бик пычранган. Мин моны худсовет члены буларак әйтәм, режиссер үзе барып карасын әле. Бик нык тазартырга кирәк ул спектакльне. Икенче пәрдәнең уртасына гына игътибар итегез — анда Тәүфикъ ни кыланганын бөтенләй чамаламый, тәмам йөгәненнән ычкына». Кичә кич Шәфика шул сүзләрне, билгеле, шактый йомшартып, иренә кайтып әйткән иде. Чыннан да, бер үк спектакль төрле көнне төрлечә уйнала. Ул артистларның кәефенә, залдагы тамашачыларга, сәхнә эшчеләренә һәм хәтта һава торышына да бәйле. Начар якка үзгәреп китүе дә бик ихтимал. Хәзерге минутларда Рәмзи үзе куйган спектакльне урыны-урыны белән үзе таный алмыйча хәйран калып утырадыр, бәлки. Ләкин шулай да күңел сагаеп аны көтә, баскычта аяк тавышлары ишетелгән саен, йөрәк урыныннан кузгалып куя иде.

Бүлмәгә, кызган ит һәм эссе май исенә уралып, Эльвира килеп керде.

— Мөкәррәмә апа мине кухнядан куа.— Ул Шәфика янына, диванга килеп утырды.— Син артист кеше, кухня һавасы белән агуланма, үзеңне сакла ди.— Эльвира көлеп куйды. Аның бит очлары кызарып чыккан, күзләре яктырган иде.— Ярты сәгать эчендә генә әллә ни булмас иде әле!

— Исәнлек шулай азлап-азлап, сиздерми генә китә дә инде ул.

— Әллә сез авырып торасызмы? — Эльвираның тавышында борчылу чагылды.

— Нишләп алай сорыйсың?

— Сез бүген һәрвакыттагыча түгел, үзгә, бүтәнчә.

— Анысы тән сырхавы түгел, күңел ярасы гына. Үтә торганы.

Ничек килеп чыккандыр, әле бер-ике генә сәгать элек килбәтсез үрдәк бәбкәсе булып күренгән чандыр кызыйның үзенә сердәш булып киткәнен сизми дә калды Шәфика. Уйламаганда гына дигәндәй, Кадимбикә исеме телдән ычкынды. Юк, Шәфика үзенең аны уйнау турындагы яшерен хыялын чишмәде, билгеле, Рәмзи өчен борчылганын әйтте. Эльвира аны ярты сүздән аңлап алды: пьеса тарихын ул да бик яхшы белә булып чыкты.

— Ай-һай, оста да соң инде Әнвәрбәков,— диде ул.— Күңелгә ятышлы әйбер булса, үз кулыннан ычкындырыр идеме соң. Куярга

авыр, шуңа юри Рәмзи абыйга тапшыра. Бик авыр хәзер Рәмзи абыйның хәле, шулай бит, Шәфика Сафиулловна?

Шәфика аңа гаҗәпләнеп карады. Каян белгән әле бу кызыкай аның театрда әйткән сүзләрен?

— Нишләп авыр булсын? — диде үзе шактый ук төксе итеп.— Спектакль куйдырмасалар яхшырак булыр идеме әллә? Рәмзинең аңа гына таланты җитәрлек.

— Туктагыз әле, Шәфика Сафиулловна, сез дөрес кисмисез, минемчә. Чигүен мондарак туры китерсәгез, матуррак булачак бит.

Эльвира аның кайчы тоткан кулын сак кына читкәрәк этәреп, өстәлдәге ак ефәк кисәкләрен башка тәртиптә тезә башлады.

— Әйе шул, бөтенесе шулай уйлый, Әнвәрбәков Бикбауны күтәрә, диләр,— диде ул эш арасында.— Спектакль артыннан спектакль куйдыра егеткә, имеш... Сез менә бу төшен үтүкли торсагыз да була... Әйе, күтәрә Әнвәрбәков Рәмзи абыйны. Шундый итеп чөеп җибәрә, яшь режиссерны бөтенләй теләксез калдыра. Егылу куркынычы бик нык көчәя. Сезгә шулай тоелмыймы?.. Менә бу төшен ышкып җибәрегез әле... Үзегез беләсез бит, Шәфика Сафиулловна, танылган режиссерлар һәм артистлар янында эшләү яшьләр өчен ифрат читен. Өлкәннәрдән мең яхшырак эшләсәң дә, бер җылы сүз әйтмиләр, чөнки тегеләрдән уздырып мактаудан куркалар, аларның электән килгән даны күзләрен чагылдыра. Ә инде берәр кимчелегеңне тапсалар, чыдап кына тор! Тәмләп-тәмләп камчыларга тотыналар. Сезне өлкән дип әйтеп булмый әле, сүзнең турысын яратасыз. Шуңа күрә ачыктан-ачык әйтәм: картлар алар, телиме-теләмиме, барыбер яшьләрнең юлына аркылы ята. Рәмзи абыйга да Әнвәрбәков кул астында эшләү бик авыр. Ярый әле, сез бар аның янында, югыйсә, баш түбәсенә төеп кенә торырлар иде. Сез аңа таяныч!

Шәфика аны шаккатып тыңлады.

— Ай, Шәфика Сафиулловна, яндырасыз бит!

Менә сиңа үсмер малайга охшаган аңгыра кыз! Менә сиңа килбәтсез үрдәк бәбкәсе! Шәфиканың үрдәк дигәне башка кош булып чыга түгелме? «Кадимбикә»не дә укыган икән, автор берәрсенә биреп торган да, шуны кулдан-кулга күчереп йөрткәннәр булса кирәк.

— Кадимбикәгә күпләр кызыга,— диде Эльвира ак ефәккә иелеп җөй типчегән арада. Күзләре керфек астыннан күренми иде, Шәфика, аның тавышында астыртын көлемсерәү сизелмиме дип, сагаеп тыңлады, ләкин кыз ихластан сөйли иде булса кирәк.— Юмор юк анда,— дип дәвам итте кыз.— Катлаулы характер юк. Ә мин андый акыл иясе рольләренә кызыкмыйм.

Ул энә-җепле кулын күтәреп, күкрәгенә кысты:

— Их, Шәфика Сафиулловна, ныклап аягына гына бассын Рәмзи абый, ул сезнең өчен махсус спектакльләр куячак әле. Сезне өр-яңадан ачачак әле ул!.. Әйдәгез, итәген үлчәп карыйк, бил сызыгы ничек икән?

Ул Шәфиканы бер чишендереп, бер киендереп, каршында әйләндерә, гүяки остазын үзенә буйсындыра һәм аның күңеленә үз фикерләрен сеңдерә иде. Шундый ышандырып сөйли, каһәр! Шәфика сүз сөрешенең уңаен аңламыйчарак торды, шәкерте фәлсәфәсенә кушыла алмады, тыңлау белән чикләнергә мәҗбүр булды.

— Нишләргә дә белгән юк бит әле, Шәфика Сафиулловна,— дип дәвам итте Эльвира.— Мине бер театрга да чакырмыйлар. Мәскәүдәге актрисаларның үткенрәкләре мондый очракта җаен таба табуын. Танылган режиссерларның берәрсенә кияүгә чыгалар да куялар, карт-фәлән дип тә тормыйлар. Әйбәт режиссер янында күзгә күренеп була анысы...— Ул иелеп көлмәк итәген бөгә иде.— Безнең тирәдә андыйлар юк шул, булганнарын күптән эләктереп бетергәннәр.

Бу сүзләр Шәфиканың зиһенен тәмам таратып җибәрде.

— Ничек инде роль алам дип кияүгә чыгарга? — диде ул соң дәрә-

жадә аптырап.— Аның белән яшисе дә бар бит!

— Мине ир белән яши алмас дисезме әллә?

Эльвира шундый өздереп карады, әйтерсең лә, бая аны артистлыкка ярамас итеп чыгарган Шәфиканың хәзер хатынлыкка ярамас итеп чыгаруын көтә һәм рухын шул авыр сүзне җиңелрәк үткәреп җибәрергә әзерли иде.

— Юк-юк, киресенчә, сине зур мәхәббәткә, үзеңә тиң бер яшь, яхшы кеше белән гомер итәргә лаек дип саныйм,— диде Шәфика ашыгып.

— Иҗади дуслык булганда, мәхәббәт үзе килә,— Эльвира моны шундый ышаныч белән әйтте, Шәфиканың башына кадак белән кагып куйгандай итте.— Аның шул ягы да бар бит әле: хатын-кыз берәрсен кайгыртып яшәргә тиеш. Мәхәббәт дигән булып, бер пүчтәк адәмгә хезмәт иткәнче, талантлы кешене карап, тәрбияләп яшәү яхшырак түгелмени? Андыйны тормыш мәшәкатьләреннән бушатып, иҗатына мөмкинлек тудыру үзе генә дә сәнгатькә хезмәт итү бит.

Тыштан караганда үсмер тоелган бу кызыкайның акылы-күңеле шактый җитлеккән икән. Аның һәрнәрсәгә үз карашы, алай гына түгел, каккан казык кебек, какшатып булмастай ышанычы бар. Кайбер студент кызларның шушы рәвешлерәк фикер йөртүе Шәфика өчен сер түгел иде түгелен. Ләкин шулай да ул бу юлы югалып калды. Кеше тормышында кычкырып сөйләп булмый торган нәрсәләр бар. Кайчакларда үз күңелеңә дә йөз кызартырлык уйлар килүе ихтимал. Андый очракта кеше үзалдына кызарынып чыга һәм тиешсез уйлардан тизрәк арынырга тырыша. Шәфика фикеренчә, аларны башка берәүгә, бигрәк тә остазыңа сөйләү оят иде. Ул шәкерте өчен оялып куйды. Эльвира ак ефәктән йөзен күтәрмәде, әмма ничектер укытучысының халәтен сизеп алды, ахрысы.

— Минем хакта начар уйлый күрмәгез тагын, Шәфика Сафиулловна,— диде.— Аптыраган үрдәк арты белән чума диләр, чарасызлыктан әйтүем. Артист язмышының «са»лары бик күп бит аның, үзегез беләсез. Драматург сиңа ошарлык роль язса, пьесаны театр алса, режиссер ул рольгә сине куйса, спектакльне худсовет хупласа, партнерларың яхшы уйнаса, тамашачы яратса... Шуларның берсе генә булмаса да артист уңышка ирешми. Шул «са»ларның берәрсе туры килмәү аркасында күпме талантлар ачылмый калган бит! Сез менә Ельцованы бик еш телгә аласыз. Талантлы идеме ул?

— Андый талантлар дөньяга сирәк туа,— диде Шәфика.

— Ә бит театр тарихына кирәрлек роль уйный алмаган. «Бирнәсез кыз»да Лариса турында хыялланган — бирмәгәннәр. Инде санга керә башлаганда, олыгаеп киткән, Ларисаның анасын уйнарга гына ярый алган. Менә шул рәвешле әрәм була инде талантлар.

— Ләкин Анна Ивановна үзе безгә бер дә алай дими иде. Ул безне сәнгатьтә фәкать туры юлдан гына барырга, үз талантыңа гына таянырга өйрәтте.

Моны Шәфика кырыс итеп әйтте. Ләкин аның һәр сүзенә каршы Эльвираның дәлиле әзер иде, бу сөйләшү гүяки аның алдан язып куйган сценарие буенча бара иде.

— Сезнең заман бөтенләй башка булган ла ул, Шәфика Сафиулловна! Ул чакта диплом алган яшь актерларны һәр театрда кочак җәеп көтеп торганнар. Ә хәзер безнең ишеләр буа буарлык, кайсыбыз яхшырак икәнен дә белеп бетерерлек түгел. Төртеп күрсәтүче, «бу кыз талантлы!» — дип бөтен дөньяга кычкырып торучы кирәк, шунсыз мантып булмый.

Сөйләшү Шәфика өчен шактый күңелсез, эч пошыргыч була башлаган иде инде. Бәхеткә каршы, ишек кыңгыравы зыңлады. Эльвира, ак ефәк өстендәге тутый кошларны һәм чәчкәләрне тизләреннән шудырып, сикереп торды, ләкин, Шәфикага карагач, кире утырды.

Шәфика белән Рәмзи арасында аерма ун яшь, ләкин бу артык нык күзгә ташланмый, чөнки егетнең нык бәдәне янында хатыны кечерәебрәк күренә. Соңгы елларда Рәмзи мыек та үстерде, бу аның гамьсез-сөйкемле йөзен бераз җитдиләндереп, олыгайтып җибәрде.

Заманында, Шәфика беренче ире Хәбир белән яшәгәндә, Рәмзи театр училищесында укыды. Режиссер Әнвәрбәков Рәмзинең талантына бик үк мөкиббән булмаса да, Шәфика егетне театрда калдыруга ирешге. Рәмзи берничә ел актер булып йөрде, ләкин остазы Абилова өмет иткәнчә үк ачылып китә алмады. Шуннан соң, Шәфиканың киңәше белән һәм режиссерның фатихасын алып, ул Мәскәүгә режиссерлыкка укырга китте. Аның укуын тәмамлаганына ике ел һәм Шәфика белән яши башлаганнарына алтынчы ел китте. Әгәр дә егет Мәскәүдә укыганда урык-сурык күрешүләрне дә исәпкә алсаң...

Ул ишек бусагасын атлап керүгә, күзләрен елтыратып, хатынына гаепле кешедәй карады. Ләкин Шәфиканың тыныч йөзен күргәч һәм өйдә чит кеше барын белгәч, иркенәеп китте, җирәнсу мыегы белән кытыклап, хатынын бит очыннан үбеп алгандай итте.

Бу күренешне зал ишегеннән Эльвира күзәтеп тора икән — ул китәргә кузгалган, имеш.

— Юк-юк, җибәрәмме соң,— диде кухня ягыннан күренгән Мөкәррәмә.— Пешкән ризыкны ташлап китәргә син безнең кара дошманыбызмы әллә?

Кызның кыюлыгы кая киткән, диярсең, ул тагын теге килбәтсез үрдәк бәбкәсенә охшап калган иде. Ашаганда тәлинкәсеннән күзен күтәрми генә тавыш-тынсыз утырды, кашыгын шалтыратмады, сүзгә катнашмады. Соңыннан, шулай ук тавышсыз гына, Мөкәррәмәгә кашыксавытны җыярга булышты.

Кәефе килгән чакларда Рәмзи кәрт сугарга ярата. Шәфика аның бу гадәтен өнәп бетерми, шунлыктан кара-каршы гына уйнап утыру берсенә дә ләззәт бирми иде. Бу юлы Шәфика иренә кәртләрне киштәдән үзе алып бирде, Эльвираны тагын берзага токкарлады, кухнядан Мөкәррәмәне көчләп диярлек алып керде:

— Савыт-саба качмас, дүртенче кеше кирәк безгә.

Шулай бер түгәрәк булып, күңелле генә уйнап алдылар.

— Бу бәйрәм арасында балыкка барып килсәң шәп булыр иде инде,— диде диванга иркенләп утырган Рәмзи тәмам хыялга бирелеп.

— Мине сөйрәп барырга уйлама тагын,— диде Шәфика.— Җәен иртәнге салкыннарда яр буйларында тилмереп утырганнарым да бик җиткән.

— Ә мин утырыр идем,— диде Эльвира, кинәт калкынып.— Су буенда уйлар уйлап утыру бик рәхәт бит ул.

Рәмзи аңа, каян килеп кысылдың әле син дигәндәй, сәерсенеп һәм яратмыйча карап алды.

— Барыгыз соң бергә, Рәмзигә чәй кайнатып торырсың,— диде Шәфика иренең бу карашын күрмәгәнгә салышып.

Рәмзи бу юлы дәшмәде, аскы иренен бүлтәйтеп мыегын чәйнәргә азаплангандай итте дә, кулындагы уен алтысын Шәфика куйган карга дамасына ыргытты. Калган ике кәртен хатынының ике иңенә салды:

— Менә хәзер погонлы булдың, команда бирергә дә ярыйсың,— диде.— Югыйсә кирәк-кирәкмәгәнгә тыгыла идең.

Эльвира кызарып-пешеп чыкты, сикереп торды да алгы яктагы чөйдән курткасын йолкып алды.

— Бар-бар, озатып куй, кара төндә кыз бала ялгызы йөрмәсен,— диде Шәфика Рәмзигә.

— Кирәкми, Шәфика Сафиулловна, курка торган гадәтем юк минем!

— Рәмзидән озаттырасың килмәсә, үзем чыгам алайса.

Эльвирага риза булмый чара калмады.

Рәмзи тиз әйләнеп керде. Бу кызның язмышы, борчулары, сәер фәлсәфәсе хакында Шәфика аның белән иркенләбрәк сөйләшмәкче иде дә, ире сүзне озакка сузарга ирек бирмәде.

— Урта кул актрисалар язмышын уйлап баш ватар хәл юк әле.

— Аның яхшы яклары да бар бит. Мәсәлән, ул юк әйберләрне бик ышандырырлык итеп тота. Тик хәрәкәтләре генә нәфис түгел, йомшаклык, мөлаемлык җитми. Ача белергә кирәк аны, аңлый белергә.

— Кирәк кеше ачар да, аңлар да. Бүтән кайгың юкмы әллә?

Ничек булмасын инде Шәфиканың башка хәсрәте! Әмма кеше гамен сөйләү ансат, үз кайгыңны ачу читен. Эчендәге үпкә-рәнҗүне әйтергә җай таба алмады Шәфика. Урынга ятып, утны сүндергәч, Рәмзи тирән көрсенде дә, чалкан яткан килеш, сүз башлады:

— Син Әмиргә гариза язгансың икән.

Шәфиканың йөзенә юрган астыннан ялкын бөркелгәндәй булды. Ул тиешсез, килешсез, очраклы уйларын башкага сөйләгәндәй оялды.

— «Кадимбикә»не син куясын белмәдем бит мин, әйтмәдең,— диде.— Җай чыккан инде сезгә икәүләшеп миннән көләргә. Ни ди соң? Әйтәсе сүзен синең аркылы җиткерергә булдымыни? Үзенә килгән үтенечкә үзе җавап бирсен иде, язма рәвештә.

— Җавап бирү минем өскә төште инде. Теләсәң, хәзер язып бирәм.

Шәфика дәшмәде. Аның елыйсы килә иде. Чыннан да, яз дисәң, торып, өстәл янына утырыр иде микәнни Рәмзи? Ни язар иде икән? Ул роль өчен син карт инде дипме? Әллә бүтән берәр ярамаган җирен табар идеме Шәфиканың? Ә тапкан бит ул хатынының кимчелеген, бүтән берәүне аннан яхшырак күргән. Язар сүзен дә табар һәм моңарчы сәхнә күгендә йолдыз булып балкыган Абилованы урыныннан кузгатыр... Шәфиканың колакларына барабан каккан, өзек-өзек, шомлы итеп гобой кычкырткан авазлар ишетелгәндәй булды. Алар йөрәккә тигезсез, авыр китереп бәрәләр, тынны кысалар, ә Шәфика гүяки сәхнәдә басып тора, сәхнә исә әйләнә, аны якты, иркен, җиләс мохиттан караңгылыкка, сулышны буа торган тынчу бушлыкка сөйри иде. Ә яктыда калганнар берсе дә, хәтта ире дә аңа кул сузмый. Шәфикадан ераклаша, аерыла...

Ах, әгәр дә бу — ирдән аерылу гына булса икән... Ир бирмәк — җан бирмәк диләр, әмма иң авыры бу түгел икән әле. Бу сүзләрне сәхнә уртасындагы урыныңны башка берәүгә бирү хәлләрен белмәгән кешеләр әйткәндер, актрисаларның күңелен аңламаган адәмнәр уйлап чыгаргандыр.

Әгәр шунда күзгегә карый алса, Шәфика күзләреннән тоташ газап бөркелгәнен, йөзеннән кан качканын күрер иде һәм үзенең бүгенге репетиция вакытында өнсез торган Эльвирага охшап калганын тояр иде.

И сәхнә, нинди газапларга дучар итәсең син кешеләрне? Нинди аяусызлык белән әйләнеп торасың, нинди игелексез син! Күпме корбаннарга барды Шәфика синең хакка: бөтен көчен, хисен сиңа бирде, яшәешнең синнән читтәге бер рәхәтен дә күрмәде, синнән аерылып торудан куркып, ана булудан баш тартты. Табигать тарафыннан һәр хатын-кызга бирелә торган шундый зур бәхеттән мәхрүм итте үзен! Ә син шуларның һәммәсенә битараф әйләнеп кенә җавап бирәсең...

— Әмир минем белән бик каты сөйләште,— диде Рәмзи. Колакларда чыңлаган музыка аша аның сүзләре зиһенгә бик тонык килеп иреште.— Татар түрә булса, чабатасын түргә элә, син алай итмәссең, башкаручылар исемлеген үз хатыныңнан башламассың инде, диде. Минем беренче уем синең хакта иде, югыйсә.

Сәхнә шып туктагандай булды, ямьсез тавышлар, дирижер таякчыгына буйсынгандай, туктап калдылар. Ни булды соң әле? Бу — Рәмзинең шифалы сүзләре дәһшәтне туктатты. Йөрәккә суга торган барабаннарга, «тын калыгыз»,— дип әмер бирде, сәхнә уртасыннан, яктылыктан Шәфика кулын сузды. «Минем беренче уем синең хакта иде»,—

ди бит! Димәк, Шәфиканы яраксызга чыгармаган, гаебен дә ул тапмаган! Барысына да Әнвәрбәков кына гаепле! Иртәгә үк кереп мыегына ябышырга, чын йөзен ачарга, артистларга күренер җирен калдырмаска!

Күңелдә янә моң кузгалды. Ләкин бу юлы. йөрәк тибешен рәхәт бер көйгә сала торган, күңелне тынычландыра торган көй иде инде бу.

— Әйтсәм, сине борчу була, әйтмәсәм тагын читен,— дип аңлата иде әле Рәмзи.— Шулай аптырап йөри-йөри әйтелми килде инде ул.

— Ә Наргизәне куярга Әмир куштымы?

— Наргизә күпмедер дәрәҗәдә яңа материал бит ул. Әнвәрбәков стиленнән бераз булса да аерылып торган актриса. Үз-үзен тотышы табигый, фактурасы әйбәт. Бер күрүдә истә кала торган. Яшь дип мине кимсетмәс, сүземне тыңлар дип тә уйладым. Өлкәннәргә тотынып күп йөрелде, үземә тәпиләп карарга вакыт. Син ничек уйлыйсың, һаман кулымнан җитәкләп йөртергә кирәкме әле мине?

Шәфиканың хәтеренә Эльвира әйткән: «Танылган шәхесләр янында яшьләргә үсү авыр»,— дигән сүзләр килде. Чыннан да, бер яктан баш режиссер текәлеп карап тора Рәмзигә, икенче яктан — хатыны. Адым саен өйрәтеп, күрсәтеп торсалар, берәүгә дә рәхәт түгел. Иҗат өлкәсендә уңышка ирешим дисәң үз сүзеңне әйтергә кирәк, ә монда кеше әйткәнне кабатлап кына йөрергә туры килә. Күптән мөстәкыйльлек бирергә вакыт инде Рәмзигә!

— Син күтәреләчәксең әле, зур уңышларга ирешәчәксең,— диде Шәфика иренә сыенып. Рәмзи, тын алдырмаслык итеп, көчле куллары белән хатынын үзенә кысты. Аның сулышыннан назга уралып рәхмәт хисе бөркелде:

— Аз гына башымны калкытсам сине күтәрәчәкмен әле мин,— диде ул.— Синең өчен махсус спектакльләр куячакмын. Сәхнә күгендә Абилова исеме өр-яңадан йолдыз булып калкачак әле. Без синең белән «Антоний һәм Клеопатра»ны куярбыз, «Медея»ны! Беркем куймаганча, берәүнең дә башына килмәгәнчә итеп!

Ире иркенәеп, изрәп йокыга талгач та шактый вакыт уяу ятты Шәфика. Бу минутларда үзен бәхетле тойганга, уйлары моңлы-зарлы кыз бала — Эльвира хакында иде аның. Болай тыныч уйлаганда, кыз сөйләгәннәр ул кадәр үк ямьсез күренми икән. Шәфика училище тәмамлаган яшь кызларның хәлен күз алдына китерде дә: «Төрле уйлар уйласалар да гаҗәп түгел икән шул»,— дип куйды.

Артист ул укыган чагында ук мең караш астында. Эшкә урнашу ягы да четерекле; режиссер яратса гына театр кабул итә. Анда урнашкач та тагын бер тапкыр энә күзеннән үткәрәләр әле.

Шәфиканың күңелендә бик моңлы итеп виолончель уйнаган кебек иде. Эльвираны, башка шәкертләрен кызганудан аның күзләренә яшь килде. Ул, ирен уятмаска тырышып, сак кына борынын тартты һәм җаймә почмагы белән күзләрен сөртте.

## 9

«Бер көнең ничек узганны бәйнә-бәйнә яз әле, дигәнсең. Яннарыңа барып кайткандай, күз карашларыңның минут саен үзгәреп торганын күргәндәй булыр идем, дигәнсең. Элек тә миңа: «Эчеңдәгең тышыңда, бар уйларың йөзеңдә, кешенең әйтми калган сүзен дә сизәсең, шуңа карап кәефең үзгәрә»,— дип, ярым шаярып, әйткәли идең. Кинәт һәм еш үзгәреп торуны артист өчен зарури сыйфатка саный идең. Әмма бар уйлаганы-кичергәне йөзенә бәреп чыкса, сәхнәдә ничек уйнар соң кеше?

Бу араларда миңа уй-хисләремне тирән яшерергә, тормышта да уйнарга кирәк булды әле. Кемнән яшерергә, кем каршында уйнарга, диген. Яшьлек дустым Наргизә каршында уйнарга, эчемдәге утларны аннан яшерергә... Бу хатны да ул өйдә юкта гына язам.

Сиңа бер көнемне генә түгел, бөтен гомеремне сөйлисем килә минем. Танылган артистлардан: «Кайда тудың, ничек үстең, сәхнәгә ничек килдең»,— дип интервьюлар алалар, алар турында газеталарга язалар. Безнең кебекләрнең язмышы газета хәбәрчеләрен кызыксындырмый, ә баштан узганнарны сөйлисе, эчне бушатасы килгән көннәр булгалый. Күңелем нечкә, гамьнәрем күп. Бергә чакта без синең белән гади танышлар гына булып калдык, эч серләребезне уртаклашыр дәрәҗәдә дуслашып өлгермәдек. Күңелемә синең никадәр якын икәнлегеңне мин хәзер генә аңлый башладым шикелле.

Ә бәлки, бу — сине торган саен ныграк якын итүем — эшләгән һәм яшәгән җиремдә үземне япа-ялгыз тоюымнан да киләдер. Моңарчы мин ялгызлык дигән бәхетсезлекнең чын асылын аңлап бетермәгәнмен икән. Чөнки әти-әнием бер-бер артлы вафат булып, тулы ятим калган көннәремдә дә, авылдан шәһәргә килеп, ят мәктәпкә укырга барган чагымда да, хәлемне аңлаган, хәсрәтемне уртаклашкан кешеләр булган. Аларның беренчесе — бертуган абыем Гамир. Икенчесе — Наргизә иде.

Безнең өйдәге гөлләр миңа тугыз яшь тулгач шиңде. Күрше апа керде дә, тәрәзә төбендәге хәлсезләнгән яраннарга карап: «Гөлләр сизә,— диде.— Әгәр алар хәл алса, әниегез дә савыгыр».

Мин аларны сулышым белән җылытып, йөрәк тибешем белән дәртләндереп, күз яшьләрем белән сугарып тергезергә әзер идем. Әмма безнең күз яшьләребез язмыш каршында бигрәк көчсез икән шул! Яраннар, башка язлардагы кебек күкрәп бүрек-бүрек чәчкә атмады, әнинең күзләре мәңгегә йомылганда алар тәмам корыган иде инде.

Шуннан бирле мин өемдә яраннар үстермим.

Гөлләр чыннан да кешеләрнең хәсрәтенә сизгер икән. Наргизә дә шундыйрак хәлне сөйләде: ире белән бозылышкач, аларның да яраны чирләшкәгә әйләнгән. Их, кешеләр дә шундый сизгер булса икән!

Хәер, болай уфтануым белән мин абыемны рәнҗетәмдер, ахрысы.

Авылда абыйның сөйгән яры бар иде — чибәр, чая кыз иде ул. Ләкин аларга кавышулар насыйп булмады — араларына мин төштем. Әйе, минем аркада өзелде аларның арасы, әмма минем ихтыярым белән түгел. Әни үлгәч, кардәш-ыру абыйга болай дигән: «Сөйгәнеңнең холкы бик кыска, дуамал, аңа өйләнсәң, сеңелең көн күрмәс». Абыйның шул чакта моңайганын, уйланганын, ябыкканын мин дә сиздем. Авылның иң оста гармунчысы иде ул. Кызыл күрекле гармунын тезләрендә тибрәтеп тәрәзә каршында җырлап утырганнары әле хәзер дә күз алдымда:

> «Биек тауның башларына утырып уйлар уйладым,
> Утырып уйлар уйлар өчен үскән икән буйларым»

Сеңелем боекмасын, аның балачагы кимсенеп узмасын дип, үз мәхәббәтеннән баш тарткан кешене минем әлегәчә әдәбиятта да, сәхнәдә дә күргәнем юк. Ә минем абыем шундый корбанга барды. Сөйгәнен калдырып, башкага өйләнде, тыйнак-сабырга, кардәш-ыру димләгән кызга. Авыл урамында сөйгәне белән очрашкалап тору аның өчен бик читен булгандыр, күрәсең, без Казанга күчеп килдек һәм зур баракта яши башладык.

Хәзерге вакытта: «Мәхәббәт өчен көрәшергә кирәк, сөю хисе бар нәрсәне аклый»,— кебегрәк сүзләр ишеткән саен, мин абыемны исемә төшерәм. Әгәр дә ул үз хисләрен бар нәрсәдән өстен куйса, минем язмыш ничегрәк булыр иде икән?

Кардәш-ыруның сүзе рас килде: җиңги мине какмады, сукмады. Миннән беркайчан да ятимлек, боеклык бөркелеп тормады, кыяфәтем мескен булмады. Ә шулай да... ананы алыштырып була микән? Әнине җирләгәннән соң беренче айларда төштәгедәй яшәдем: менә-менә уянып китәрмен дә, аны янымда күрермен, кочагына сыенырмын кебек иде.

Шәһәр тормышы да минем өчен саташу кебегрәк башланып китте.

Авылда халык бертигезрәк яши, урамдагы бала-чага да кием-кыяфәте белән бер-берсеннән әлләни аерылып тормый. Шәһәрдә исә дөньяның җае бүтәнчәрәк икән. Баракта күрше бүлмәләрдә яшәүче кызлар — Разия белән Тәслимә миңа беренче сентябрьдә мәктәпкә бергә барырга вәгъдә биргәннәр иде. Ул көнне алдан ук әзерләнеп, аларны урамда көтеп алдым. Менә алар икесе янәшә килеп чыктылар: өсләрендә коңгырт күлмәк, ак алъяпкыч, манжет-якалар, кулларында өр-яңа портфельләр, затлы чәчкә бәйләмнәре — танырлык та түгел. Чөкердәшеп, көлешеп, кәс-кәс атлап, минем тарафка күз дә сирпемичә узып киттеләр болар. Торып калдым авыз ачып. Алар шактый ерак-лашкач кына аңыма барып җитте: боларның урам буйлап минем белән янәшә барасы килми. Гарьләнәләр. Чөнки өстемдә җиңгәмнең югач утырган кофтасы, аякта йон оекбаш белән галушлар, кулда киндер тастымалдан теккән букча.

Аңладым мин боларны, кимсендем, ләкин бернишләр хәл юк, бер ун адым калышып иярдем артларыннан. Берзаман җирән толымлы бер кыз куып җитте мине. Гади генә киенгән, бер кулында портфель, икенчесендә бәрхет гөл чәчәкләре.

— Кайсы мәктәпкә барасың? — дип сорады миннән.

— Сиксәненчегә.

— Кайсы класска?

— Өченчегә.

— Мин дә өченчегә. Ә чәчкәләрең юкмыни? Әйдә, минекен бүләбез!

Ул кулындагы бернечә гөлен миңа аерып бирде.

— Әнә тегеләрне күрәсеңме? — дип алдан барган кызларга күрсәтте.— Безнең класста укыйлар, кыланчыклар. Әйдә, шуларны узып китәбез!

Куып та җиттек, алардан алда класска барып та кердек. Шуннан бирле Наргизә белән гел дус яшәдек. Аның да язмышы минекенә охшаш булып чыкты: әнисе кияүгә чыккан да башка шәһәргә киткән, Наргизә әбисе белән яшәп ята икән.

Класста берәүне дә уздырмый идек без. Ни әйтсәләр дә иң элек Наргизә чәчрәп чыга. Акробатика түгәрәгенә язалармы?

— Мин! — дип сикереп тора ул.

— Мин дә! — дип кулымны сузам.

Концерт куярга кирәкме?

— Мин! — ди ул.

— Мин дә! — дип кушылам аңа.

Театрга культпоходны кем оештыра?

— Без!

Әйе, шәһәр театрын мин беренче тапкыр класс белән бергәләп культпоходка баргач күрдем. Һәм таң калдым. Залның зурлыгы, затлылыгы күк гөмбәзедәй биек түшәмдәге люстраның кояш баегандай талгынлык белән сүрелә баруы һәм тәнәфес вакытында шулай ук әкрен генә яктыруы, төрле төсләргә кереп җемелдәве... Ул сәхнәдәге әкияти дөнья... Анда пәйда булган калкулык һәм агачлар, шунда чыгып баскан гүзәл кызлар. «Уртадагысы Абилова, кара нинди матур! — дип пышылдый колагыма Наргизә.— Шуның кебек артист булсаң икән, дускаем, ә?»

Аның кебек булырга? Шушы сәхнәдә уйнарга? Минем өчен бу — күккә менеп йолдыз чүпләү кебек үк буй җитмәс хыял булып тоелган иде.

Ләкин Наргизәгә алай түгел, ул моны чынлап әйткән икән. «Анда да мөгезле кешеләр уйнамый»,— дип кенә җибәрде.

Тормыш гаҗәп бит ул: башка сыймас хәлләр була кайчакта. Сигезенче класста укыганда, классыбызга Абилова үзе килеп кермәсенме! Тынсыз-өнсез калдым аны күргәч. Ул миңа сәхнәдәгедән дә матуррак тоелды: алтын кебек чәчләре, зәп-зәңгәр күзләре, сары майдай

йомшак тавышы. Үзенә сиздермичә зәңгәр костюмының җиңен тотып карагач кына аның фәрештә түгел, чыннан да кеше икәненә ышана алдым. Ә килүенең сәбәбе бик табигый булып чыкты: театр училищесының укытучысы буларак, сәләтлерәк укучыларны барлап йөрүе икән.

— Укучылар, кайсыгызның артист буласы килә!

— Мин!

— Мин!

Гадәтебезчә икәүләшеп сикереп тордык без.

— Алайса, хәзер үк имтиханнарга әзерләнә башлагыз.

Тотындык әзерләнергә. Шигырь ятлыйбыз, этюдлар уйныйбыз — аның ни икәнен дә белдек, театр турында китаплар укыштырдык.

— Ни сорасалар да, беләм, эшлим, дип чәчрәп торырга кирәк,— ди Наргизә.— Җебегән кеше артист була алмый!

Әмма кыюлык кына җитми, кыяфәт тә кирәк — аны да аңлыйбыз. Теге беренче тапкыр мәктәпкә барганда күрше кызларының ни кыланганы бик нык күңелгә сеңеп калган иде. Ә кием ягыннан тагын кыенлык килеп чыкты. Нәкъ шул кышны барагыбыз янып китте. Абый белән җиңги уттан ике яшь балаларын, бер мендәрне генә алып чыга алдылар. Безгә шуннан соң шактый вакыт заводның тулай торагында яшәргә туры килде.

— Училищега иске форма киеп бармыйбыз, дускаем,— диде Наргизә.— Син болай да ябык, кечкенә, бала-чага диярләр, алмаслар.

Җиңги бер көнгә танышларыннан ак бөрчекле зәңгәр күлмәк алып торды. Имтихан бирергә шуны киеп бардым.

Шигырьне чатнатып сөйләдем, этюдны ялт итеп уйнап күрсәттем... Этюд дигәннән, шактый кызык күренеш уйнарга куштылар миңа.

— Менә син музейда картиналар карап йөрисең, ди. Шунда сине арттан килеп бераү кочаклап ала. Борылып карасаң — ят бер егет икән. Сине башка бераү белән бутаган. Шуны уйнап күрсәт әле,— диделәр.

Махы бирмәдем, бөтенесен кыландым: бик кызыксынып караган-дай стена буйлап киттем, бераздан башымны гына борып артка күз салгандай иттем, йөземә ачу галәмәте чыгардым, аннары иягемне как-тым: теге егетнең гафу үтенүенә шулай җавап бирәм, янәсе. Янә стенага борылдым, ә үзем әледән-әле борылып карыйм — теге егетне күзәтәм, янәсе. Үземнең дикъкать өстәл артындагы апа белән абыйларда инде, тик моны сиздермәскә генә тырышам. Күрәм: яраттылар болар минем кыланмышны.

— Җырлый беләсеңме?

Ул көнне минем белмәгән нәрсәм юк иде! Бар көчемә кычкырып, озын, моңлы көй башлап җибәрдем. Тик монысында артыграк тырышып ташладым. Татар көйләренең бормалары күп, көчәнеп кычкырганда, аларга кереп бетеп булмый, дулкын өстеннән басма салып узган шикелле, өстән генә үтеп киткәнеңне сизми дә каласың. Кычкырам шулай, үзем күрәм: өстәл артындагы абый-апаларның иреннәре мимылдый, иңбашлары калтырый башлады. Ә киң чырайлы бер абый, кесәсеннән эре шакмаклы кулъяулык чыгарып, битен каплады, аннары миңа кул изәде:

— Җитте-җитте, авылыгызда ишеткәннәрдер инде!

Һәм, күз яшьләрен сөртеп, пырхылдап көлеп җибәрде, башкалар да моңарчы чак тыелып торган икән, дәррәү аңа кушылдылар.

Алар көлә — мин еламсырыйм. Бетте баш, дим, кабул итмәячәкләр болай булгач. Чөнки безнең халык артистны иң элек яхшы җырлаучы дип кабул итә, матур җырлый белмәгәнне элегрәк бөтенләй артистка санамаганнар.

Әмма юкка борчылганмын икән. Бәлки, чыннан да кыюлыгым алдыргандыр — мине училищега кабул иттеләр. Театр дөньясына, гомере буе курчак уены уйный торган сакаллы сабыйлар арасына мин менә

шулай килеп эләктем. Яхшылык, мәрхәмәт алып килде мине бирегә. Әгәр абыем яшьли сөйгән ярын оныту өчен шәһәргә күчеп килмәсә, әгәр дә мин Наргизә белән бер класста укымасам, язмышым бөтенләй башкача булыр иде, мөгаен.

Үз юлымны үзем сайламадым, кешеләр җитәкләп алып барды. Башка юлдан алып китсәләр, бәлки, яхшырак та булган булыр иде. Бүтән һөнәр ияләренең уңышы иң элек үзләреннән тора диләр бит. Менә, мәсәлән, син. Институтны тәмамлауга, сине авыл больницасының баш врачы итеп билгеләгәннәр. Бинасын үзең торгызгансың, кешеләрен туплагансың, операцияләр ясагансың. Зур эшләргә тотынырга мөмкинлегең, кодрәтең булу — нинди олы бәхет! Мин, күрәсең, башка токымнан. Артистлар гомумән берьюлы өч анадан җим өмет итеп авызын ачкан кош балалары сыман. Драматургтан — сүз, режиссердан — роль, театр директорыннан зуррак эш хакы һәм дәрәҗәле исем көтәләр.

Арада иң йомшагы, кешегә ияреп йөрергә күнеккәне, җил уңаена гына баручысы мин түгелме икән әле!... Эшемдә дә, тормышымда да. Синең белән булган мөнәсәбәтләрдә дә... Язмыш җиленә булган бөтен каршылыгым — сиңа язган хатларымда һәм моңлы җырларымда гына булса кирәк.

Хәтерлисеңме, безнең ике тавышка җырлаганны? Шул чакларда, үзебезнең аерылышу сагышларын көйлибездер дип кем уйлаган! Җанкаем-бәгърем, синең өчен мин дә мәңге чит-ят булып калырмын микәнни инде? Машиналар, поездлар йөргән, самолетлар очкан шушы заманда да аралар ераклыгы бер-берсенә омтылган йөрәкләрне шушылай аяусыз рәвештә аерып куя аламыни соң? Хәтерлисеңме безнең ничек саубуллашканны? Ул чакта, аэродром буйлап искән кайнар җил кочагында, синең бер сүзеңне генә көткән идем бит. Ул сүз күзләреңнән зәңгәр нур булып түгелде, әмма тел очыннан өзелеп төшмәде. Аның урынына миннән: «Нишләп болай агарындың?» — дип сорадың. Аерылышу сагышлары җанымны өшеткән иде. Әйе, шул эсседә туңып калтырангандай булдым. Күңелемә никадәр якын икәнлегеңне шунда тоя башладым. Ничек итеп тимер баскычтан самолетка менә алдым да, аякларым ничек сыгылып китмәде икән?

Кешелекнең талантлы уллары, илаһи акылларын, йөрәк ялкыннарын эшкә җигеп, шушындый мәһабәт очкычлар ясаган чагында, гашыйкларны бер-берсеннән аерыр өчен тырыштылар микәнни? Нигә алып калмадың син мине шул чакта? Сәхнәдә гомер буе икенче я өченче булып, бүтәннәр күләгәсендә гомер сөрүгә караганда, яныңда бердәнбер булып яшәсәм, бәхетлерәк булмас идеммени мин?

Әйтәсе сүзләрне әйтә алмадык, мәңгелеккә аерылдык. Әйе, мәңгелеккә, чөнки безгә очрашулар насыйп булмас инде. Язмыш моңа да каршы, күрәсең. Хәтерлисең микән, соңгы хатларымның берсендә нәзер әйткән идем: «Кадимбикә ролен миңа бирсәләр, яныңа барып, аны берүзеңә уйнап күрсәтермен», — дип язган идем. Күрешеп сөйләшү өчен бер сылтау булыр иде ичмасам, ләкин, юк, аннан да мәхрүм иттеләр — Кадимбикәне Наргизәгә бирделәр! «Мин дә!» — дип сикереп чыгып булмый, очрагы ул түгел!

Шул ук вакытта бу чарасызлыгымның тормышымда бер борылышка сәбәп буласын да тоям. Иҗатымда артка китүнең башлангычыдыр бу.

Нишләргә миңа, нинди чара табарга?

Үткәннәремә карыйм, киләчәгемә күз салам. Ятимлектән мине абыем йолып калган, балалар арасындагы ялгызлыктан — Наргизә. Бу очракта янымда андый кеше юк, син — ерак. Ә үземнең уңганлыгым — йөрәккә кан сауганны иң якын дустымнан яшереп елмая белүгә — тормышта уйнауга гына кайтып калыр микәнни?

Һәркемнең дә гомерендә бөтен язмышын хәл кыла торган кискен адым ясарга тиешле минутлары буладыр. Берәүнең дә кулына тотынмыйча, үз акылы, гайрәте белән, тәвәккәл рәвештә ясарга тиеш кеше ул

адымны. Минем тормышымда да шундый сынау вакыты житте.

Тик ничек, ни рәвешле ясарга ул адымны?

Син белгән, син талантлы дип санаган Сафия мена шушындый сорауларга җавап таба алмыйча бәргәләнеп яши».

## 10

Әдәбият, сәнгать әсәрен халыкка житкерү бик еш кына аны иҗат итүдән дә авыррак була. Чөнки синең халыкка барыр юлында кемнәрдер тора, шуларның фатихасы һәм теләктәшлеге белән генә әсәреңне зур дөньяга чыгару мөмкинлеге ачыла.

Режиссер Әнвәрбәков драматург Гыйззәт Бикашин өчен менә шул юлдагы киртә булып чыкты да инде. Аны алып ташлап та булмый, әйләнеп үтү дә мөмкин түгел иде.

— Ай-яй йөрәксез дә адәм икән бу Әмир,— дип зарланды Гыйззәт беркөнне Сафиягә.— Атасы Рәхимҗан бик ачык кеше иде югыйсә, монысы кемгә охшап тугандыр.

Гыйззәт Сафиянең хуплапмы, каршы килепме бирәр сүз әйткәнен көтеп, яшьләрчә үткен күзләре белән текәлеп карады. Җавап булмагач, дәвам итте:

— Монда алар бер иш оешып алганнар инде, араларына бүтәннәрне кертмиләр. Әнвәрбәковның аның Ризванов белән генә борчагы пешә, безнең ишене кирәксенми.

Мондыйрак сүзләрнең элегрәк тә колакка чалынгалаганы бар иде, тик Сафия аларга илтифат бирми килде. Әмма бу юлы Гыйззәт бик тә кызганыч күренде, шунлыктан кыз уйга калды: чыннан да, драматургның әсәре хакында бер генә кеше фикер йөртеп, үз башына килгәнчә хөкем чыгарып утырырга хаклы микән? Әгәр дә ул ялгышса, хаталанса? Яхшыны начар дисә? Ул чакта язучыны кем яклар да дөреслекне кем ачар?

— Әсез болай гына бирешмәгез, Гыйззәт абый. Әгәр үзегезне хаклы дип саныйсыз икән, көрәшергә кирәк.

Гыйззәт иреннәрен җәеп, учы белән авыз читен сөртеп алды. Сафиянең башына һич кирәкмәгәндә: «Тешләре ясалма икән»,— дигән уй килде.

— Ничек көрәшергә соң, синеңчә? — дип Сафиягә сынап карады драматург.

— Башкалар да укып карасын. Худсоветка куйдырырга була.

— Башка чара калмады шул чыннан да,— диде Гыйззәт уйга калып.— Әнвәрбәков тирәсендә күпме генә йөз суы түгеп йөрсәң дә, рәт чыкмас, ахрысы.

Декабрь урталарында «Язмышлар тактасы»на Гыйззәт Бикашинның «Теге якта» исемле драмасы укылачагы хакында игълан эленде.

Кышның әле яңа, карның яшь вакыты, җиңелчә салкынның бик тансык чагы иде. Кар сафландырган һаваны күкрәк тутырып сулыйсулый, ак юлларны таптап урамда күбрәк йөрисе урында, көн үзәгендә дә яктырып бетә алмаган бүлмәләрдә озаклап утырырга берәүнең дә дәрте юк иде. Актерлар бу җыелышка теләр-теләмәс, эленке-салынкы гына җыелдылар. Укуның грим бүлмәләре янындагы кечкенә залда үткәреләчәген белеп, кайсылары гаҗәпләнеп куйды.

— Минем кабинет — рәсми урын, кайберәүләрнең үз сүзен әйтергә кыенсынуы бар,— диде аларга Әнвәрбәков.— Ә монда тел яшермичә, иркенләп сөйләшергә була.

Бүлмәләрдән урындыклар алып чыгып, шаулашып утырыштылар. Кучеп йөри торган кечкенә өстәлне тәрәзә янына шудырдылар. Әнвәрбәков үзе, очраклы рәвештә генә килеп кергән чит кеше сыман, коридор почмагына сөялеп басты.

Әсәрне халык алдында үзең укуга караганда, берәр артисттан укыту яхшырак, моны һәр язучы белә. Гыйззәт тә, кулындагы папка бавын чишә-чишә, әле генә кереп килгән Зыятдингә таба юнәлде. Зыятдин, аны яхшырак ишетергә тырышып, үзен илтифатлы, итәгатьле күрсәткән булып, иелә төште, тырпаеп торган сул колагын драматургның пеләшенә тигезә язып, аның шыпырт әйткән сүзләрен тыңлады. Аннары тураеп:

— Кхм-кхм, тамак авыртып тора бит әле минем, Гыйззәт ага,— диде. Сәхнәдән сөйләргә өйрәнгәнчә кычкырып, кечкенә залны яңгыратып әйтте.— Хатын юк бит әле минем.

Гыйззәт кисәк башын күтәреп, хәйран калып, аның йөзенә текәлде: хатынның монда ни катнашы бар?

— Кич спектакльдән кайтуга чәй куеп торучы юк, салкын су эчәргә туры килә,— диде Зыятдин бик җитди итеп.— Сырхаулаганда дару бирүче юк!

Артистлар пырх-пырх көлештеләр. Гыйззәт каушап китте, өстәл янына чигенде һәм кесәсеннән зур кулъяулык алып, күзлеген сөртергә керешге. Пьесаны уку аның үзенә калды.

Әсәр фаҗигале заманны — Ватан сугышын чагылдырган иде. Анда сүз дошманга әсирлеккә төшкән сугышчыларның, алданып, кыйналып-җәзаланып, легионнарга кертелүе турында бара икән. Шундый аяусыз чынбарлыкта пьесаның персонажлары да кырыс телдә, өзек-өзек җөмләләр белән аңлашалар иде. «Унтер-офицер керә. Унтер. Башкаларга аңлатыгыз, кушканны җиренә җиткереп үтәгәннәргә бүген обедта берәр плитка шоколад биреләчәк. Хәснулла. Эшләрбез, герр унтер. Унтер чыга... Унтер керә...»

Гыйззәт каушаудан тотлыга, сүзләрнең бәгъзеләре аның ясалма тешләре арасыннан шома гына чыгып китә алмыйча, кысылып калып изелә, ул бик еш яулыгы белән авызын сөртергә тиеш була иде. Үзара кара-каршы гына сөйләшкәндә ягымлы тоелган тавышы да, бер генә авазны туктаусыз сузгандай, һаман бертөрле, төссез булып тоела иде.

Театрда кем генә, нинди генә пьеса укымасын, бу вакыйга Сафия өчен һәрчак тирән кичерешләр белән бәйле. Автор өчен йөрәк мае сыза Сафиянең, ул пьесаның яхшы дип кабул ителүен, макталуын һәм тиз арада куелырга карар кылынуын тели иде. Әйтерсең лә, авторның тетрәнүен, каушавын, борчылуларын әлегә фән тарафыннан ачылмаган ниндидер бер сизгер үткәргеч аркылы тоеп тора, алай гына да түгел, ул хисләрне бергәләп кичерә иде ул. Бу очракта да, Гыйззәт укый башлауга, аның миен эссе томан чорнап алгандай булды, ул сүзләрне рәтләп аңлый алмады, аның урынына залдагыларның мөнәсәбәтен гадәттән тыш сизгерлек белән тоеп торды. Баштарак барсы да шым булып, тын гына утырдылар. Ләкин шунда ук эчке бер сагаю, ятсыну, кабул итәргә теләмәү сизелә иде инде. Бераздан кемдер урындыгын шатырдатып шудырды, почмакта пышылдашып алдылар, кайсыныңдыр ачкычы идәнгә шалтырап төште, аякларын чыштырдатып, иелешеп аны эзләргә керештеләр. Зыятдинның: «Карале, кызык икән моның сүзләре, ә,— дигәне ишетелде.— Җөмлә эчендә бер-берсенә ипле ялганасы урында, эт белән мәче шикелле...» Куркыныч итеп әйтте: җөмлә эчендә сүзләр эт белән мәче кебек. Ничек шулай әйтергә теле бара бу Зыятдинның! Сафия бөтен дикъкатен туплап тыңларга, пьесаның эчтәлеген аңларга тырышты, ләкин аның борчу баскан зиһенендә һаман бертөрле сүзләр генә килеп әләгә иде: «Унтер керә... унтер чыга...» Сафия янында җәелеп утырган Фәгыйлә Батталовадан мич эсселәре килә иде. Менә ул үзенең көрән сумкасын тез башына куеп, аны актарырга керәште: андагы кәгазьләр, роль кисәкләре, кулъяулык, иннек, ачкычлар арасыннан яшел алма табып алды да, шытырдатып тешләде. Сафиянең канәгатьсез күз карашына җавап итеп: «Миндә шикәр чире бит, режимны

бик сакларга кушалар»,— дип җавап бирде. Тәүфикъ кесәсеннән кәгазьләр чыгарып тез башына куйды да иреннәрен кыймылдатырга керешге: төштән соң аның телевидениега барасы бар икән. Китте шуннан чыш-пыш, шыгырдау, берәүгә дә аерып шелтә ясап булмый торган гомуми бер тынгысызлык, кимсетүле дикъкатьсезлек. Гыйззәт ара-тирә башын күтәреп, алтын күзлеге өстеннән калын-кара кашларын җыерып карап куйганда, залдагылар әз генә тынып торалар да, ул кәгазьләренә иелүгә, янә үз эшләренә керешәләр иде. Сәхнәдә уенны чынга әйләндерә белгән бу кешеләр чын тормышта икейөзләнүне гаеп санныйлар, әчендәгене яшерергә теләмиләр иде. Кыскасы, һәркем үз эшендә. Гыйззәт укуында, бары тик аның өчен ут йотып утырган Сафия генә, стеналарга бәргәләнеп юкка чыккандай яңгыраган авазларны колаклары белән аулап калырга тырышып, тураеп утыра иде. «Унтер керә... унтер чыга...»

Кинәт арттарак шартлап урындык ауды:

— Сволочь!

Кем бу? Кем кычкыра? Сафия дә, дәррәү артка борылып караган бүтәннәр дә баштарак берни аңламый тордылар. Аннан берәү тәрәзә ягына, Гыйззәткә таба кизәнеп талпына иде:

— Хәшәрәт! Сволочь!

Бәй, бу соң вахтер Җәмил абый бит! Яшь актрисаларны шаярткалап, өлкәннәрен үртәштереп утыра торган, һәрчак ачык чырайлы, йомшак тавышлы «оҗмах сакчысы»! Йөзе карасуланып, озынчаланып килгән, күгәренгән ирен читләреннән, кырыслык тамгасы булып, тирән буразналар уелып төшкән. Ничек керәсе иткән әле ул монда? Пьеса тыңлау вахтер вазифасы түгел ләбаса!

— Кара син аны, ничек баш күтәргән, күсе! — дип хырылдап кычкыра ул.

Гыйззәт күзлеген салып, соң дәрәҗәдә гаҗәпләнеп аңа текәлгән иде. Ул кесәсеннән яулыгын чыгарып, авыз читен сөртте дә, режиссерга борылып:

— Бу ни дигән сүз? Кем бу? — дип сорады.

— Җир бит! — дип, рәтләр өстеннән йодрык болгап аңа таба очынды Җәмил.— Монда килеп, оялмыйча, фашистлар кулыннан шоколад тыгынып ятканнарга мәдхия җырлыйсыңмы? Без кан коеп йөргәндә кайда идегез соң сез, ә? Фашист итеге ил-җирне таптаганда кайда идегез?

Җәмил үз сүзләренә үзе буылды.

Залдагылар берни аңламый иде әле. Күренеп тора: Әмир дә бу хәлдән хәйран калган иде. Фәгыйлә Батталова алма тешләргә дип ачкан авызын ябарга оныткан, Тәүфикънең тезендәге кәгазьләр идәнгә чәчелеп төшкән. Барысы да, сәхнәдәге сүзсез күренеш рәвешендә, башларын артка каерып, хәрәкәтсез калганнар.

— Кем әле син ул хәтле? — диде Гыйззәт. Аның тавышы тыныч, үз-үзенә ышанычлы чыкты. Шуның белән генә дә ул тиресеннән чыгардай ярсыган Җәмилдән өстенлеген күрсәтеп тора иде.— Кем син андый пычрак сүзләр белән миңа кизәнергә? Монда шаһитлар җитәрлек, җавап бирәсе булмасын! Кешегә нахак бәла яга торган заманалар күптән узган, курка торган күлмәгем тузган!

Белмәгәндәй кыланса да, Җәмил белән аларның электән таныш икәне сизелеп тора иде. Җәмил, урындыклар өстеннән очып барып, Гыйззәтнең пеләшен чукырга омтылган яшь әтәч кебек очына иде:

— Син! Без кан коеп Берлинга барганда, таракандай посып яткан адәм актыгы! Кемнән качып яттыгыз сез анда?

Гыйззәт тагын Әмиргә борылды:

— Сез бу кешене махсус чакырдыгызмы инде монда?

Әмир юан гәүдәсен почмактан аерып, кулларын кесәсеннән чыгарды. Ләкин ни дә булса әйтергә ашыкмады.

— Син әле монда килеп, кемнең кая барырга тиешлеген тикшереп йөрмәкчеме, кара таракан! — дип кычкырды Җәмил.

Гадэттэ йомшак һәм шактый ук хәлсез күренгән бу кешедән таулар актарырлык гайрәт бөркелә, әгәр урындыклар һәм аларда утырган артистлар араны бүлеп тормаса, ул шул минутта Гыйззәтне ялан куллары белән ботарлап ташлаячак иде. Әгәр хисләр күзгә күренә торган булса, бу минутта ул тоташ учак булып үрләр иде, аннан чәчрәгән чаткылардан башкаларның йөрәге көйри башлаганы сизелер иде. Әйе, йөрәкләргә ут капты, алардан күтәрелгән эсселек сулышны буды, иреннәрне көйдерде. Хәзер бүлмәне ялкын урап алачак һәм драматург Бикашиннан кара күмер генә калачак!

Сафия урыныннан сикереп торды:

— Җәмил абый! Җәмил абый, тынычланыгыз!

Ул арада Җәмил янына Җиһангир килеп басты, рәтләрне аралап Зыятдин алар янына ашыга иде.

— Әйдәле, Җәмил абый, чыгып сөйләшик әле,— диде Җиһангир үзенең шифалы, йомшак тавышы белән.— Урыны түгел аның монда, андый бәхәснең вакыты түгел.

— Кулда автомат барда очрамадың, кызганыч! — дип кычкыра иде Җәмил.— Эх, шунда очраган булсаң! Фашистларны бетергәндә йөзгә-йөз килгән булсак! Пычрак итекләрең белән театр идәнен таптый алмас идең!

Барсы да үрелеп Бикашинның аякларына карадылар, ул үзе дә ихтыярсыздан карашын аска төшерде — аның коңгырт ботинкалары ялтырап тора, аларда кер эсәре юк иде.

Берничә егет, Җәмилне үгетләп тә, мәҗбүрләп тә дигәндәй, алып чыгып киттеләр. Залда сәер бер халәт урнашты. Баягы таркаулыкның, игътибарсызлыкның эзе дә калмаган, барысы да дикъкать белән, бик жентекләп Бикашинга текәлгәннәр иде. Гыйззәт яулыгы белән битен сыпырып, каушавын юып төшергәндәй итте, алтын кысалы күзлеген киде һәм янәдән кәгазьгә иелә төшеп, укырга кереште: «Унтер керде... унтер чыкты...» Тавышы баягыча ук салмак, тыныч, саңгырау иде аның. «Молодец, нык икән, җебеп төшмәде»,— дип уйлады Сафия. Әгәр кеше алдында аның үзенә шундый сүзләр белән кизәнсәләр, ул инде бу залдан күптән чыгып йөгергән булыр иде.

Ниһаять, Гыйззәт кулындагы соңгы кәгазьне дә өстәлгә куйды — укуын тәмамлады, күзлеген махсус савытка салып, биген япты. Бикнең шартлап ябылганы арткы рәтләргә дә ишетелде. Театрның әдәби бүлек мөдире, чандыр буйлы Разия Туктамышева аның белән янәшә басып:

— Әйдәгез, иптәшләр, фикер алышыйк,— диде.

Җәмилне озатып кергәннән соң Әмирнең җилкәсе аша башын сузып тыңлап торган Зыятдин:

— Фикер таралыбрак китте бит әле,— диде.— Әллә соң берәр биш минут тәмәке тартып алабызмы?

Эчү-тарту хакында күп сөйләшә торган бу кешегә Гыйззәт бик тә яратмыйча карап куйды. Менә хәзер барсы да «Тартып керәбез»,— дигән булып, таралышачаклар һәм аннары... Моны сизеп алган Сафия, сикереп торып:

— Кемгә ничектер, ә миңа пьесада материал җитәрлек булып тоелды,— диде. Башкаларның гаҗәпләнеп аңа борылганын күргәч, отыры кызып: — Ошады миңа пьеса! — дип кычкырып ук әйтте.— Әлбәттә, әле эшләргә кирәктер, акцентларны ачыкларга, образларны калкурак итәргә була. Ләкин, минемчә, эшләргә җирлек бар. Автор үз материалын яхшы белә.

Аның соңгы сүзләреннән кемдер күңелсез генә көлеп куйды.

— Белә, белә, анысына сүз әйтерлек түгел,— диде Зыятдин.— Менә, әсәр турында бер фикер булды да инде.

Кемнең дә булса башка берәүнең фикер әйтергә нияте юк иде. Һәммәсе, эткәләшеп-төрткәләшеп диярлек, тар коридор башына тыгылдылар. Кайсы телевидениегә, кайсы радиога ашыга икән... Берсенең

режимы каты — ашар чагы үтеп бара, икенчесенең кемедер өйдә сырхаулап ята — кайтып карамый булмый. Разия Туктамышеванын бер эшләрне генә булса да тотып калырга тырышуы бушка китте: халык, иләкгән саркыган су кебек, шома гына таралып, юкка чыкты.

— Сүзеңне сүз итәр өчен ниләр генә уйлап чыгармыйсың син, ә? — диде Гыйззәт Әмиргә.— Каравылчыны да миңа каршы котыртып куйгансың!

— Кем котыртсын аны? — диде Әмир сабыр гына.— Әсәр тыңларга кергән кешене куып чыгарып булмый, ул да тамашачы. Пьеса хакында һәркем үз сүзен әйтергә хокуклы. Хәзер менә худсовет членнарын җыеп, минем кабинетта сөйләшербез. Алсу, әйт анда кирәк кешеләргә, миңа керсеннәр.

Сафия грим бүлмәсенә кереп, башын өстәлгә салды. Кинәт бушап калган бинаның тынлыгыннан колаклар чыңлый иде. Сафиянең күңеле тулды. Бик ямансу иде аңа. Бу хәлләрдән соң Гыйззәткә булган мөнәсәбәтен өр-яңадан ачыкларга кирәк булачак иде. Бик зур гаеп ташланды бүген Бикашинга һәм моның нинди дер астыртын нијат белән эшләнгәненә ышанып та булмый иде. Җәмилнең ярсуы, ачуы ясалма булу һич мөмкин түгел, аның бөтен сүзләре ихластан, йөрәк түреннән кайнап чыкканга әйтелде, билгеле. Ләкин... Әтисенең изге хатирәләре белән бәйле кеше турында, шушы көнгәчә зурлап искә алынган шәхес турында ничек кенә бер селтәнүдә фикерен тамырдан үзгәртеп куя алсын соң Сафия! Сүзләренә караганда, Җәмил Гыйззәтне сугыш вакытында очратмаган, күрмәгән. Димәк, аның гаепле икәнен дә ачык кына белә алмый. Сугыш вакытында әсирлеккә төшкән һәр кешене гаепләү дөрес тә түгел, алар арасыннан күпмесе чын батырлыклар күрсәткән һәм бу хакта күпме язылды да бит инде!

Ләкин... нинди көчле иде аның ярсуы, нинди көйдергеч иде нәфрәте һәм ничек үзгәртеп куйды ул бөтен кешенең мөнәсәбәтен. Әйтерсең лә Бикашин белән башкалар арасында упкын ясады да, шуннан узган гомерләрнең төтенле сөреме, утлы давыллары күтәрелеп, күзләрне томаланды, сулышны кисте. Әле соңыннан моны искә төшергәч тә, Сафиянең йөрәге жу итеп куйды.

Без нәфрәтнең ни икәнен әле белмибез, ахрысы. Кемнедер кўралмыйм, яисә нәфрәтем зур, дип сөйләгәндә, гадәттә үзара үпкәләшүләрне, вактөяк ыгы-зыгыларны күз алдында тотабыз, ә бу — бала уенчыгын чын танк белән янәшә куярга маташу гына икән. Нәфрәт хисенең үтергеч ачысын һәм кешене тоташ ялкын теленә әйләндерә торган кодрәтле утын күз алдына китерә алмыйбыз икән. Моны фәкать революцияне һәм сугышны кичкән кешеләр генә белә торгандыр.

Менә нинди утлар яна икән сугыш утын кичкәннәр йөрәгендә, Кадимбикә кебекләрдә. Әйе-әйе, Кадимбикә дә Хакимгә карата шундый ук хис кичергәндер.

Бу чагыштыру Сафия күңеленә ихтыярсыздан килде.

Ул киенеп урамга атлаганда, ян ишектән каршына Гыйззәт килеп чыкты.

— Рәхмәт сиңа, батыр икәнсең,— диде ул Сафиягә.— Үз фикереңне ярып әйтә беләсең икән. Театрда синнән гайре ихлас күңелле бер кеше табылмады!

## 11

«Хакимнең затлы чатыры. Чатыр түрендә походларга алып йөри торган тәхет. Хаким, сугышчан киемнән, кылыч тоткан хәлдә, гасабиланып, әрле-бирле йөренә. Ишек япмасын күтәреп Газизҗан керә.

Газизҗан. Галиҗәнап, җиңү! Дошман явының соңгы калдыклары юк ителде! Бу шәһәрдә синең кодрәтеңә каршы торырлык бер генә җан иясе дә калмады!

Хаким. Озакка сузылды! Озакка! Ә син миңа ни диген идең?

Газизҗан. Мин... җиңү синең якта буласына ышанган идем, галиҗәнап!

Хаким. Син, Газизҗан, бу каланы, бу халыкны минем гаскәремә бер

генә сәгать тә каршы тора алмаячак, дигән идең. Моннан бер ай элек шулай дигән идең син. Бер ай элек!

Газизҗан. Ләкин бу ил халкының ахмаклыгы, үҗәтлеге адәм башына сыя торган булмады, галиҗәнап. Алар калалары, балалары, хәтта үз җаннары хакында уйлый белмәделәр. Сиңа баш июгә караганда һәлакәтне артыграк күрделәр.

Хаким. Ә син, Газизҗан, шул калада үсеп, үз туган халкынның холкын моңарчы белми идеңме?

Газизҗан. Моңарчы илдә тынычлык, иминлек иде бит, галиҗәнап, алар бик гади яшәде. Иген иктеләр, көтү көттеләр, йортлар салдылар, китаплар яздылар. Бу кадәр башсыз булырлар дип кем уйлаган?

Хаким. Димәк, алар арасында башлы кеше бер син генә булгансың инде, Газизҗан. Минем якка чыккан син бердәнбер бит?

Газизҗан. Мин язмышка буйсындым. Адәм баласының язмышы алла кулында түгел, көчле кулында. Синең кулда, галиҗәнап!

*(Ишектә йөзбашы күренә.)*

Йөзбашы. Бер илче килде, галиҗәнап. Янына кертүне таләп итә.

Хаким. Кем илчесе? Кайсы мәмләкәттән?

Йөзбашы. Сүзем — Хакимнең үзенә генә әйтә торган, ди.

Хаким. Ни хакында?

Йөзбашы. Сүзем гаять мөһим, мине кертмәсәгез, Хаким сезне җәзалар, ди.

Хаким. Керсен.

*(Ишектән зур бүрек кигән бер адәмне өрткәләп кертәләр. Ул башын югары күтәреп басып тора.)*

Йөзбашы. Тезләнгалиҗәнап каршына! *(Илчене төртеп җибәрә, илче аягөсте кала, бүреген сала, бүрек астыннан толымнар шуып төшә. Бу — Кадимбикә.)*

Кадимбикә. Минем каршымда — гаскәр башлыгы. Ә гаскәр башлыгы белән сынны туры тотып сөйләшәләр.

Хаким. Сүзеңне әйт.

Кадимбикә. Галиҗәнап! Сүзем синең өчен генә. Ят колакларга ишетерә торган түгел!»

Сәхнәдә репетиция бара, ә Сафия караңгы залдан күзәтеп утыра иде. Биредә аның яраткан, күптән күнеккән урыны бар — уникенче рәтнең урта өлешендә, сулдан беренче урындык.

Сәхнә уртасында иркенәеп, иске китель белән төсе уңган зәңгәр хәрби чалбар кигән, биленә бутафор кылыч таккан Җиһангир Биктаһиров басып тора. Хаким өчен яңа костюм тегелмәгән әле, ә үз киемең белән репетициягә керсәң, бөтен кадерен бетерәсең: сәхнәдә ятарга да, аунарга да туры килә, ниләр генә кыланып бетмисең. Шунлыктан, кием цехыннан ни дә булса алып кияләр. Хәер, шушы иске кием белән дә Җиһангир үзен чын патшаларча тота белә: сыны мәһабәт, кыяфәте горур, карашы салкын һәм мәгърур — бөтен рәвешеннән теләсә кемне баш идерерлек гайрәт бөркелә.

Нинди генә кыяфәтләргә кереп бетмәде инде Җиһангир бу сәхнәдә? Нинди генә тормышлар белән яшәмәде! Гаскәр башлыгы, уңган житәкче, ялчы, ишан, ил агасы, хәтта палач... Бу артист өчен амплуа дигән төшенчә бөтенләй юк, ахры. Кем рәвешенә генә кермәсен — һәркайсы тере, чын, сокландыра яки нәфрәт уята. Шул ук вакытта ул һәрчак үзе — мөлаем, күңелгә якын Биктаһиров булып кала. Дөньяда сәхнә мөлаемлыгы дигән нәрсә бар, янәшә торганда сөйкемле күренгән кайберәүләрнең, сәхнәгә менгәч, тамашачыны бөтенләй битараф калдыруы мөмкин. Театр дөньясының җөмләдән бер аяусызлыгыдыр инде бу.

Сәхнәдә күренү белән бар карашларны үзенә җәлеп итә алган актер нинди бәхетле! Һәм андыйлар белән бергә уйнаучылар, әйтик, менә шушы минутта Җиһангир каршында басып торган Наргизә дә...

«Кадимбикә. Тыңла, галиҗәнап, сиңа әйтер сүземне! *(Җырлап җибәрә.)*

Хаким. Бу ни дигән сүз?

Кадимбикә. Сүзем — шушы жырда, галиҗәнап.

Хаким. Аңлаешлы итеп әйт!

Кадимбикә. Җырны сүз белән аңлатып булмый, галиҗәнап. Җырда бөек сер ята. Илнең хакиме өчен гаять мөһим сер. Аны белми торып, ил белән идарә итеп булмый.

Хаким. Җырла тагын бер кат.

Кадимбикә *(җырлый)*.

Җиһангир-Хаким, Кадимбикәгә карамый, залга текәлеп тынып калган. Ни дияр ул телен тибрәтсә, янында җыр сузып торган хатынның язмышын кая борыр? Үлемгә хөкем итәрме, яшәргә мөмкинлек бирерме? Кадимбикәнең язмышы — иксез-чиксез биләмәләрнең хуҗасы булган шушы кодрәт иясе кулында. Яуда да, гыйлемлектә дә, мәхәббәттә дә — яшәешнең мең төрле тармагында Хаким үзен барлык адәм затларыннан өстен саный һәм бу ышанычын бер күз карашы белән бүтәнnәргә сеңдерә.

Ничек соң әле ул Кадимбикәнең җырын тыңлап тора? Пьесаны кат-кат укып, уйланганнан соң, Сафия бу сорауга җавап тапты. Хикмәт шунда: бу көн — Хаким тормышында борылыш көне. Ул күптәннән хыялланган максатына ирешкән — зур бер дәүләтне яулап алган. Ләкин җиңү авыр бирелгән, шунлыктан ул артык очынып куанмый, хәтта бераз канәгатьсез дә кебек. Аның әле бер зур эшне төгәлләп, икенчесенә тотынмаган чагы, бушрак вакыты. Таш күңелләр дә бер заман ялга мохтаҗ була. Кадимбикә белән сөйләшү Хаким өчен шундый бер ял. Бу хатынның башбаштаклыкка тиң тәвәккәллеге, бәйсезлеге, кыюлыгы аны гаҗәпләндерә, кызыксыну уята.

> «Сандугачның балаларын саныйсым калган икән,
> Күз керфекләрем талганчы карыйсым калган икән»,—

дип җыр суза Кадимбикә-Наргизә аңа карап.

— Алгарак кил, алгарак, күзләрең тамашачыга яхшы күренсен,— диде беренче рәттә утырган Рәмзи урыныннан калкына төшеп. Аннары түзмәде, ак беләкләрен җилпеп, сәхнәгә сикереп менде. Җиһангирны арткарак күчереп бастырды, Наргизәне рампа кырынарак тартты. Артистлар, нишләтсәң дә барыбер дигәндәй, күндәм һәм битараф кыяфәттә аңа буйсындылар. Режиссер ничектер үз-үзенә ышанмый, артистлар сүлпән, сәхнәдә хәрәкәт, хисләр кайнавы юк, ә ансыз театр да була алмый иде.

Сафия һаман бер сорауга җавап эзләде: нинди җыр җырлый иде соң Кадимбикә залим Хакимгә? Ә үзе кем соң ул — Кадимбикә?

Пьесадан аның турында кайбер нәрсәләр белеп була. Кадимбикә — изелгән, томана хатын түгел. Үз халкының культурасын үзләштергән һәм бүтән илләр казанышыннан да хәбәрдар кеше ул. Шулай булмаса, патша хәтле патша белән болай кыю сөйләшергә аның акылы да, рухи ныклыгы да җитмәс иде.

«Синең телең минем өчен чит, галиҗәнап, әмма мин күңелемдәге сиңа җиткерү чарасын беләм».

Төрле телләрдә сөйләшүче кешеләр бер-берсен аңлый аламы? Халыклар бер-берсен аңлаша аламы? Менә нинди сорауга җавап бирергә тиеш бу күренеш! Җыр менә шундый югарылыкта булырга тиеш!

Ни турында җырлый Кадимбикә? Туган иле турындамы? Әмма андый җыр залим патша йөрәген кузгата алмас. Чөнки аның өчен туган җире үзе яулап алган башка илләрдән газизрәк түгел.

Мәхәббәт хакындамы? Ләкин Хаким мәхәббәтне уенга гына саный.

Нинди җыр җырлый Кадимбикә? Ниндине генә булмасын, бу минутта Наргизә сузганны түгел. Түгел!

Сафия тагын Җәмилне, Бикашинның пьесасын укыган көнне аның тоташ ялкын теленә әверелгәндәй нәфрәт белән янып, Гыйззәт өстенә очынган минутларын күз алдына китерде. Кадимбикә дә Хакимнән шулай

нәфрәтләнә бит! Ничек бугазына ябышмый! Ярсуын тыя ул, үзен тыныч тота. Шулай да Хакимне үзенә карату аның башына килмәс. Анысы һич мөмкин түгел! Ә Рәмзи бу күренешне нәкъ менә шулай — Кадимбикә Хакимне гашыйк итәргә тырышкандай хәл итмәкче. Ләкин бу бит андый хатыннарны кимсетү, алардан көлү булып килеп чыга!

Сафия әтисен, әнисен күз алдына китерде. Әгәр әнисе дошман белән йөзгә-йөз очрашса, ул хәтта ирен коткару өчен дә андый адымны ясый алыр идемени?

Сафиянең йөрәге какты, тәне кызышты. Ул сәхнәдәгеләрнең тавышын ишетмәде, торып басты да, өстенә кызыл ут белән «чыгу юлы» дип язылган ишеккә юнәлде. Баскыч мәйданчыгының каршы ягындагы музей ачык икән, шунда керде. Стеналардагы афишалардан кайчандыр халык күңелен тетрәндергән сәхнә даһилары аңа сынап карагандай булдылар.

Нинди җыр җырлый Кадимбикә?

Сафиянең хәтеренә яран гөлләре сулып шиңгән көннәр, әнисенең тирәнәеп калган моңлы күзләре, үзенең аягөсте төш күреп йөргәннәре килде.

Иленнән мәхрүм ителгән, ирен югалткан, өч баласын җирләгән Кадимбикәнең хәсрәте әнисе үлгәндә Сафия кичергәннәргә, бәлки, бераз охшаштыр?

Сафия түгәрәк узды, декорация макеты куелган бер өстәл янына барып тезләнде һәм башын иеп, әкрен генә җырлап җибәрде. Гомумән, аның уйланган, сагышланган минутларында, күңеленә килгән сүзләрне йөрәк түреннән саркып чыккан көйгә салып, моңаеп йөри торган гадәте бар. Бу юлы да җанда моңарчы ишетелмәгән көй яралды, сүзләр үзләреннән-үзләре аңа ярашып тезелделәр:

«Йом-йом, улым, күзләреңне,
Курыкма һич тә;
Синең иминлекне саклый
Әткәең чиктә».

Хәсрәте чиктән ашкан ананың, бик киеренке бер минутта, кайчандыр газиз улларына көйләгән бишек җырын сузып җибәрүе гаҗәпмени? Аннары бит... Залим Хакимнең дә булгандыр әнисе көйләгән җырга бишектә тирбәлеп, тәмле йокыга талган гөнаһсыз сабый чаклары...

«Дошман явы керә алмас,
Төн тыныч үтәр;
Сайрап уятырлар сине
Былбыллар иртән».

Бишек җыры! Барча халыклар, һәммә кешеләр өчен уртак, бар күңелләргә үтеп керә торган изге моң бит ул. «Ишеттем мин кичә: берәү җырлый чын безнеңчә матур, моңлы көй, әллүки-бәллүки»,— дип язган Тукай. Халык шуны җырлый. Ә бит «Әллүки» — бишек җыры! Әгәр аны олысы-кечесе йөрәктән саркыган сагыш белән суза һәм онытылып тыңлый икән, димәк ул — балалар күңеленә генә түгел, өлкәннәр күңеленә дә бик якын моң. Ул безгә гомер буена кадерле булып кала.

Бу җырны башка берәүгә ярар өчен генә көйләп булмый. Кадимбикә аны гомеренең хәтәр минутында чарасызлыктан җырлагандыр, бәлки.

Менә ул, күз яшьләрен көчкә тыеп, башын тагын да түбәнрәк иде. Кинәт ишек ягыннан дәһшәтле тавыш яңгырап, аны сискәндерде:

— Син, мәкерле хатын, мине җырың белән сихерләргә килдеңме әллә?

Анда аякларын киң ерып, кылычына таянып, Хаким басып тора, ул мәрхәмәтсез карашын Сафиягә төбәгән иде. Сафия сынын турайтып аягөсте басты:

— Кем сөйли моны? Колакка каты томана бер колмы әллә? Тел ялганны сөйли ала, ләкин җыр алдый алмый!

Алар пьесаның бер өзеген уйнауны дәвам иттеләр. Тик автор сүзләрен төгәл әйтеп түгел, үзләренчә сөйләделәр. Монда бәрелешне, кичерешләрне, фикерне дөрес бирү мөһим, ә сүзләр соңрак үзеннән-үзе ятланыр.

«Кадимбикә. Минем җырымда ил хакиме өчен кирәкле сер бар.

Хаким. Хакимгә иң элек корал һәм гаскәр кирәк. Ә алар миндә җитәрлек. Мин җиңдем! Бу ил хәзер минеке!

Кадимбикә. Юк әле, галиҗәнап, ул бөтенләе белән синеке түгел. Аны тәмам үземнеке итим дисәң, син халык күңелен яулап алырга тиешсең. Ә күңелләрне кылыч белән генә яулап булмый.

Хаким. Кылычка башын имәгәнне алтын белән сатып алырга була.

Кадимбикә. Алтынга сатып алынган адәм ышанычлы түгел, галиҗәнап. Күбрәк алтын бирүчегә ул тагын сатылачак.

Хаким *(уйланып)*. Ә шулай да таныш көй бу... Таныш моң... Кайчандыр, кайдадыр ишеткән идем мин аны... Бик күптән, күптән... Ә-ә, әнием җырлый иде аны!

Кадимбикә. Төрле халыкларның аналары бишек җырын төрле телләрдә җырлый, ләкин моңы бер, хисе бер...

Хаким. Син нинди максат белән килдең монда? Ник җырладың? Минем күңелемне йомшартып, берәр явызлык кылмакчы буласыңмы? Ниятең яхшы түгел, күреп торам. Әй, алып китегез бу хатынны!»

Хакимнең бу сүзләреннән Сафиянең йөзенә үлем суыгы бәргәндәй итте. Аның сыны катты. Ләкин ул курыкканын сиздермәде. Хакимнең мылтык көпшәседәй дәһшәтле күзләренә туры карады.

«Кадимбикә. Син мине юк итә аласың, галиҗәнап. Әмма хакыйкатьне үтереп булмый.

Хаким. Алып китегез!»

— Браво-браво, афәрин! — дип кул чапты берәү.

Икесе дә борылып карадылар: аларның тамашачысы да бар икән ләбаса. Ишектән Револ Имайкин карап тора.

— Молодцы, булдырасыз.

— Чынлапмы? Ә без юри генә,— диде Сафия.

— Яшереп маташмагыз инде, яңа спектакльгә репетиция ясыйсыз бит! Кадимбикәне сиңа бирделәрмени?

Соңгысын Револ шикләнеп әйтте, күрәсең, яңа пьесаның тарихы аңа да яхшы таныш иде.

— Юк, этюд кына бу,— диде Сафия.

— Яңа ел кичәсенәме әллә?

Аның болай төпченүе Сафиягә ошамады.

— Шулайрак,— диде дә Җиһангирга борылды ул.— Ничегрәк соң, киртәсенә керәме?

— Начар түгел!

Бу сүзләрдән кызның калкынып китkәнен күреп, Җиһангир өстәп куйды:

— Нигезе нык. Тик менә хисләрне артыграк тышка чыгарабыз, ә без аларны яшерергә тиеш бит... Әле тәнәфескә туктаган идек. Бая синең залдан бик нәүмизләнеп чыгып киткәнеңне күреп калдым да, ни булды икән дип, монда кергән идем... Җырың әйбәт. Бу урында чыннан да бишек җыры кирәктер, мөгаен.

— Шәп инде, шәп, сүз дә юк,— диде Револ.— Әллә, мин әйтәм, шуннан бер унбиш минутлык концерт номеры ясыйсызмы? Кичәләрдә чыгыш ясарга менә дигән булыр иде.

Сүзен дикъкать белән тыңлаучы югын күрсә дә, исе китмәде, андыйдан гына югалып кала торган егет түгел иде Револ Имайкин.

## 12

Талант ияләренең күпчелеге, иҗатында гадәттән тыш зирәк һәм тапкыр булуына карамастан, гадәти тормышның юк кына мәсьәлә-

ләрен хәл иткәндә дә югалып кала. Әйтерсең лә, алар яшәешнең сикәлтәле борылышларында кинәт аңгыраеп, сукыраеп куялар һәм житәкләп йөртүгә мохтаж булалар.

Бәхеткә, танылган артистлар, спортчылар, шагыйрьләр тирәсендә үткен күзле, житез хәрәкәтле, елгыр адәмнәр һәрчак очрап тора. Кайберәүләр мондыйларга, шөһрәтле шәхесләр тирәсендә туенырга чамалый дип, кимсетеп карый. Ләкин, икенче яктан уйласаң, талант иясен вактөяк мәшәкатьләрдән арындырып, бар көчен ижатка юнәлдерү бик тә кирәкле, изге эш түгелмени? Исән кешеләргә ярдәм иткәнне гаепләргә ашыкмыйк, мәрхүм даһилар тирәсендә дан эстәп, тамак туйдыручылар да житәрлек.

Револ беренчеләрдән — исәннәр тирәсендә бөтерелүчеләрдән. Ул монда үз кеше, заманында театр училищесында укыган, бераз уйнап та алган. Тар, текә маңгайлы, бәләктәй зур иякле бу егет кеше арасында ерактан күренеп тора, чөнки кара чәчле зур башы таза муенга, ә муены киң җилкәгә утыртылган. Театр фойесында актерлар белән сөйләшеп торганын күрсәләр, тамашачылар иң элек баш иеп аны сәламлиләр, арада иң шөһрәтлесе ул дип уйлыйлар. Табигать үз баласына бирсән бирсә, икенчесен кызгана: гәүдәле адәмнең тавышы нечкә була, яисә чандыр гәүдәле берәүнең нечкә бугазыннан һич көтмәгәндә гөрелдек аваз бөркелеп чыга. Ә Револның тавышы бәдәненә лаек: калын, йомшак, көчле, йөрәккә ятышлы. Тик менә талант мәсьәләсендә генә бераз саранлык күрсәткән безнең табигать-әнкәбез. Хәер, шомара торгач, Револдан да уртачарак артист чыгар иде, әмма гайрәтле егетнең тынгысыз күңеле сәхнәдә икенче-өченче булып калуга ризалашмады, актерларның шактый тыйнак эш хакын да түрләчә санап карагандыр инде. Кыскасы, сәхнә мәйданы аның өчен кысан күренде, ул аның артына бәреп керде һәм үзенә лаеклы мәйданны шунда, артистларның грим бүлмәләре тирәсендә тапты.

Моның өчен аны хупларга гына кирәк: егет үз талантын дөрес бәяләде һәм вакытында тиешле нәтиҗәне ясады. Ә күпме кеше үз мөмкинлекләренә дөрес бәя бирә белми, һәм шуның аркасында сәхнәдән китә алмый. Нәтиҗәдә театр аягына таккан ташка әйләнә, үзе дә мантымый, партнерларга да игелек күрсәтми, тамашачыны да куандырмый.

Револ исә үз урынында — сәхнә артында төп рольне бернинди дублерсыз башкара. Монда аның көндәшләре юк. Пөхтә костюмлы, яңа кырынган булса да, каралып торган яңаклы һәм иякле, әмма алланып күренгән иренле бу кешене күрүгә, аның гөрелдек тавышын ишетүгә, артистларның иелгән башы күтәрелә, зарлану сүзләре ярты юлда өзелә, җыерылган кашлар языла, чытык чырайлар ачыла. Бу егетнең костюмы аша уйнаклап торган таза җилкәләренә бар ваемнарны рәхәтләнеп өяргә булыр сыман. Берәрсенә яңа костюм яисә каеры тун кирәкме? Револ менә дигәнен табып бирә. Юбилейга чәчәкләр һәм азыктөлек таба алмый аптырыйлармы? Револ барысын да булдыра. Премьера көнне залның алгы рәтләрендә, алтыннарын елтыратып, күз явын алырдай киемнәр белән балкып, тук чырайлы, үз-үзеннән бик тә канәгать кыяфәтле тамашачыларны күрсәгез, болар шул Револның танышлары булыр. Кул кулны юа, ике кул битне юа. Хәер, күренекле сәүдә әһелләрен зур сәнгатькә якынайту шулай ук изге эш.

Берәр атна театрда күзгә чалынмый торса, Имайкинны юксына башлыйлар: «Нишләп Револ күренми? Апам авырып киткән иде, мумие сорый. Бер аптекада да юк икән, ул табып бирер иде».— «Үзем дә шуны эзлим әле. Улым Мәскәүгә барасы иде дә, иртәгәге поездга билет юк, диләр.»

Ул үзенең исемен «революция»дән алынган дип аңлата. Әмма Зыятдин ага «Револьвер» дип, басымны икенче иҗеккә төшереп эндәшә:

— Әнә, Револьвер килә, кемгә ни кирәк — куянмы, төлкеме, момент атып бирер.

Әле дә аның Батталова юбилеен үткәрүдә ярдәмләшеп йөрүе икән. Шуны эзләп, музейга килеп кергән дә, Сафия белән Җиһангирның «Кадимбикә»не уйнаган чагына юлыккан.

— Фәгыйлә апа кич «Галиябану»да була,— диде аңа Сафия. Аның Револдан тизрәк котыласы, Җиһангир белән иркенләбрәк сөйләшәсе килә иде, ләкин егет терәлеп торып калды. Җиһангир кире репетициягә кереп китте.

— Исмегөл дә буламы? — дип сорады Револ.

— Ә? Ни дисең? — Сафиянең зиһене таралган иде.

— Галиябануны дим, Исмегөл уйныймы?

— Шул инде, дублеры юк бит аның.

Револның сорашуы юкка булмаган, кызык ясарга йөргә икән. Кичке спектакль тәмамланганда, инде Хәлил башын сәхнәгә куеп, күзләрен йомгач һәм Галиябану яшь аралаш соңгы җырын җырлагач, тамашачыларның кайберләре мышык-мышык борынын тартып, күз яшен киптергәндә, артистларның рольдән айный башлап та үз халәтенә кайтып җитмәгән хәлдә оялып һәм каушап залга баш игән минутында, сәхнә кырындагы баскычтан мәһабәт гәүдәсен очыртып кына Револ менеп житте. Шул минутта сәхнә артыннан билетерша Мәрьям апа килеп чыкты. Аның кулында бер кәрзин чәчәк — ак кашкарый белән куе кызыл канәферләр иде. Револ кәрзинне Галиябану-Исмегөлнең аяк очына куярга кушып, мәһабәт ишарә ясады. Аннары, чәчкәләр аша үрелеп, яулык чите белән ышыкланырга тырышкан Исмегөлнең бит очыннан үбеп алды. Хәлилне уйнаган бөдрә чәчле Тәүфикъ арттарак буталып калган икән, ул кинәт нечкә сыны белән алга таба ыргылды, юлына туры килгән Галимә-Фәгыйләнең юан гәүдәсен тиз генә әйләнеп үтә алмыйча бәргәләнде. Менә, ниһаять, башкаларны эткәләп алга чыкты да йодрыгы белән Револга кизәнде. Тамашачы моны бер шаяру дип кабул итте, пырхылдан көлгән, берән-сәрән кул чапкан тавышлар ишетелде, тизрәк гардеробтан киемнәрен алырга ашыккан тәрбиясез халык та ишек төбендә өелеп туктап калды һәм дәррәү сәхнәгә борылды. Әмир залдан йөгереп кереп, режиссер ярдәмчесенә кулын болгады: ябыгыз тизрәк пәрдәне! Ябыгыз!

Пәрдә ябылып беткәндә, берничә егет Тәүфикъны ике яктан тотып торалар, ә ул алар кулыннан талпына иде: «Ипи шүрлегең жимерәм әле мин аның!» Егетләр көлешәләр, тынычландырырга тырышалар: «Кызма юкка! Халык каршында үпкәннең ни гөнаһы булсын! Сәхнә бит ул!» — «Андый кызны ничек үпми түзәсең?» — «Чәчкә әҗере генә лә ул!» Тәүфикъ аягы белән кәрзингә типте, кызыл канәферләр һәм ак кашкарыйлар җилпенеп кәрзине-ние белән читкә тәгәрәде. Ә Исмегөл сәхнә артында режиссер ярдәмчесе Гөлсинәнең сырган пинжәк итәге белән битен ышкый иде. (Бер-ике ел элек кенә сәхнәне биегәйтеп, ремонт ясадылар, шуннан соң сәхнә артында бик яман үтә җил уйный торган булып калды (Гөлсинә шуңа сырган пинжәк киеп йөри). Исмегөлнең чибәр йөзен жирәнү хисе ямьсезләгән иде: «Ныгытып юарга кирәк иде битне,— диде ул.— Монда берәрсенең кер юу порошогы юк микән?»

Аның бу сүзләрен Револ да ишеткән ахрысы. Сафия өенә кайтканда, алар троллейбус тукталышында очраштылар, һәм егет шунда зарланып алды:

— Кыланмышлары кырга сыймый,— диде.— Алай укасы коела торган булгач, кеше арасына чыгармасын иде Исмегөлен, маңгаена, бу минем хатын дип, пичәт бассын иде дә, өендә генә ябып асрасын иде.

— Хатыны түгел, кәләше ул Тәүфикъның,— диде Сафия.— Алар жәйгә туй ясарга вәгъдәләшкәннәр.

— Вәгъдәләшү ул суга сәнәк белән язган нәрсә генә әле. Карарбыз, безне мыскыл иткән болай гына үтмәс.— Һәм Револ сүзен ныгыткандай, кин ияген өскәрәк күтәреп куйды.

Болай әйтүе юкка булмаган икән, икенче атнада, «Галиябану» барасы кичне, Сафия артистлар йөри торган ишек янында янә Револга тап булды. Егет тагын бер кәрзин чәчкә күтәргән иде.

— Үлсәм үләм, үземнекен итәм, дисең инде,— диде Сафия көлеп.

— Ул маңкаларның кыланышларыннан үлеп тормабыз, ләкин үзебезнекен дә итми калмабыз,— диде Револ серле итеп.

Бу юлы да спектакль тәмамлангуга, ул сәхнәгә сикереп менде. Кәрзинне үзе күтәргән иде, шат елмаеп, артистлар рәте алдыннан, сәхнә

бүйлап, уннан сулга житез атлап китте бу. Тәүфикъ Исмегөл янында ук тора. Револны күрүгә аның чырае каралып чыкты, йодрыклары йомарланды. Ул инде кизәнә дә башлаган иде, ләкин Револ аңа да, Исмегөлгә дә күз салмады, туктап тормады, сәхнәнең уң кырыена барып житкәч кенә туктап, кәрзинне Галимәбану-Фәгыйлә каршына куйды. Ләкин бу зур бүләк Батталовага да түгел икән. Револ аны елмаеп читкәрәк этте һәм өлкән артистка артында торган Сафиянең кулыннан тартып алгарак чыгарды, аны кәрзин янына бастырды да, иелеп, кытыршы яңагын кызның кул аркасына ышкыды.

— Гади тамашачыдан! — диде залга ук ишетелерлек итеп.

Зал тынып калган иде. Әллә инде Сафиянең генә колагы томаланып киттеме соң? Ул үз күзләренә үзе ышана алмый торды. Ничек ышанмак кирәк — спектакль буена нибары ике-өч авыз сүз әйткән, Галиябануның дус кызларыннан берсе булып, кечке уенга гына катнашкан артисткага ни өчен инде шундый зур бүләк бирсеннәр ди? Һич мөмкин эш түгел бу! Аннары моның икенче ягы да бар бит әле. Юк кына рольне уйнаган артистны бу рәвешле зурлау, аңа чәчәк биреп, баш рольне башкаручының уенын юкка чыгару, аны халык каршында хур итү дигән сүз иде. Исмегөлнең яңагы грим аша тимгелләнеп чыкты.

Сафия моны бик ачык күрде һәм ак кашкарыйларның, кандай кызыл канәферләрнең Исмегөл белән Тәүфикъка үч итеп кенә үзенә бирелгәнен аңлады. Ә нигә соң аның йөрәге талпынып типте һәм халыкның сирәк-мирәк кенә кул чабуыннан да нигә башы әйләнде? Нигә? Бу минутта авыз ерып, елмаеп торырга ярамаганын да, Револның учыннан кулын тизрәк тартып алырга кирәклеген дә бик яхшы аңлый иде бит ул югыйсә...

Ләкин... шулай да... Кечке уенда ул үзенең иң тере, иң чая, иң шат кызны уйнаганын белә иде. Нишләп әле тамашачы артистның уенын күпме сүз сөйләгәненә карап бәяләргә тиеш ди? Радио тыңларга килмәгән бит ул бирегә, уен карарга килгән! Әгәр ул Сафия рәвешендәге бер авыл кызының саф күңеле канатланып очынганын, хисләреннән исергәнен, аяклары жиргә тими атлаганын, аның күмәк уеннарда дәртләнеп уйнаганын күрә икән, монда сүзләрнең ник кирәге бар? Сафия, сәхнәдә үткәргән унбиш минут эчендә, күп күзләрнең үзенә таба текәлгәнен тоеп тора иде. Аның үзенең театрдан калган беренче матур хатирәсе дә шуның белән — урманда жиләк жыеп йөргән кызларның матурлыгы белән бәйле иде бит. Аларның сүзләре әллә кайчан онытылган инде, кыяфәтләре һаман күз алдында.

Юк, Сафия тетрәнеп торган тере чәчәкләргә тибә алмады, Револ үпкән кул аркасын сөртергә дип Гөлсинәнең сырган пинжәк итәгенә дә барып ябышмады. Ни өчен әле бөтен чәчәкләр Исмегөлгә генә бирелергә тиеш? Аларга Сафиянең дә хакы бар!

Шулай дип уйлады ул.

Сәхнәдә Сафиягә чәчәк бирүләре беренче түгел, ә шулай да мондый кәрзин белән чәчәкне ул беренче тапкыр кабул итеп алды. Үзенә биргәнне үзе алды, кайбер башка артистлар шикелле, тамашачы бүләк иткән чәчкәне шундук бүтәннең кулына күчләп тоттыру гадәте юк аның. Тамашачы чәчкәне үзе теләгән кешегә бирә, дип исәпли иде ул.

Урамга чыкканда кәрзинне ничек кирәк алай шарфы белән каплаштырды, чәчкәләре туңып китмәсен дип, йөгереп кенә өенә кереп китмәкче булды. Ләкин үзарга ирек бирмәделәр. Ишектән чыгуга, аны Шәфика туктатты:

— Анда Рәмзи күренмәдеме? Мине эзләп йөри инде әллә, һаман чыкмый.

— Юк шул, Шәфика апа, күрмәдем.

Аннан аерылып, капкага барып житәм дигәндә генә, пилотка кебек итеп тегелгән бәрән бүрекле берәү юлына аркылы төште:

— Саумы, Сафия.

Сафия аны башта танымыйчарак торды. Таныгач, аптырап китте:

— Гыйззәт абый, сез икәнсез әле. Троллейбус көтәсезмени?

— Сине көтә идем, Сафия.

Сафия кәрзинен җилдән ничек тә ышыкларга тырышып, урам якка аркасы белән борылды.

— Теге хәлләрдән соң сәхнә артында буталып йөрергә йөрәк җитми башлады. Бер күрергә зар булдым сине.

Сафия аның чыннан да байтактан күзгә чалынмаганын исенә төшерде.

— Ничек булып бетте соң, Гыйззәт абый, пьесаның язмышы?

— Авторы язмышы төсле инде: бирәүгә дә кирәге юк. Мал иясенә охшый, диләр бит.

Троллейбус чыжлап килеп туктауга, каралып торган халык төркеме шуңа ябырылды, савылып эчкә үтте, ишекләр чыжлап, авырлык белән ябылды, троллейбус кузгалып китте. Әле генә ыгы-зыгылы булып күренгән урам кинәт бушап, тынып калды. Читтәрәк ялгызы басып торган кайры тунлы, биек бүрекле берәүнең сыны бу ямансулыкны ничектер көчәйтә генә кебек иде. Текәлебрәк карагач, Сафия бу кешенең Револ икәнен таныды. Һәм күңеле белән сизеп алды: егет аны көтә иде.

— Троллейбус китте бит, Гыйззәт абый. Бу сәгатьтә алар сирәк йөри, икенчесен озак көтәргә туры килмәгәе.

— Бер сөйләшеп утырасы килә иде,— диде Гыйззәт аны ишетмәгәндәй.— Синең белән сөйләшәсе сүзләр бар иде, Сафия. Тик менә, элекке кебек, почмактагы урындыкка янәшә утырып булмый шул инде хәзер.

— Урындык беткәнмени, Гыйззәт абый.

— Чыннан да, бер иркенләп сөйләшеп утырыр җай табылса, син ничек карар идең, Сафия?

Гыйззәтнең тавышында җанлану, өмет ишетелде.

Ә Сафия чәчкәләре өчен борчыла, җитмәсә кечкенә чәшке якасы шәлсыман итеп киселгән, муенны каплап җиткерми, изүдән җил үтә иде. Ләкин Гыйззәт аның хәлен аңламады.

— Ник сөйләшмәскә, мин сезнең белән сөйләшергә рәхәтләнеп риза.

— И, рәхмәт яусын яхшы сүзеңә. Бигрәк тәмле телле инде син, Сафия. Синсез бу дөнья миңа бик караңгы күренер иде. Алайса мин синең янына бер килермен әле.

Сафия бу сүзләрнең мәгънәсен дә аңлап җиткермичә, хушлашырга ашыкты. Ләкин бу юлы да капкадан җәлт кенә кереп китә алмады, эчкә атлауга аны җиңеннән Револ эләктерде.

— Мин әйтәм, өеңдә мыгырдап яткан ирең дә, елап яткан балаң да юк, бераз йөреп киликме әллә? Йокы алдыннан моцион ясарга врачлар бик куша.

— Чәчкәләр туңа бит, Револ.

— Чәчкәләрне кертеп куярга да була бит аларны. Хәтерлисеңме бер мәзәкне? Урман юлыннан барганда бер шофер яшь балалы хатынны очратып, машинасына утырткан да, шактый озак барганнар, ди. Инде машинадан төшкәч, бу хатын әйтә икән: мин шундый курыктым, шундый курыктым, ди икән. Нәрсәдән курыктың, дип сорый икән шофер. Син мине үбә башларсың дип курыктым, ди бу. Синең балаң бар бит, ди икән шофер. Баланы аны, ди икән теге хатын, читкәрәк куеп торып та була. Шуның сыман, чәчкәләрне аларны хәзер менә баскыч төбенә, эчкә куеп торып та була бит.

Бу ямьсез мәзәк һәм Револның Сафияне җилбәзәк хатын белән янәшә куюы әле генә күтәренке күңелне кинәт төшереп җибәрде. Ишегалдының түрендә, бер-берсенә елышкан, ике шәүлә күренде, алар да ничектер теге мәзәкнең бер чагылышы булып тоелдылар. Әйтергә кирәк, театрның бу як ишегалды бик кысан, тулай торак бинасы белән театр бинасы арасында тар аралык кына калган. Аралыкта төнлә лампалар янмый, караңгы. Ярый әле, Сафиянең бүлмәсенең тәрәзәсе бу башка, яктыга чыга, урам ягы һәм стенаның да агартылган, матуррак өлеше күренә.

Кыскасы, бу аралыктан икәүнең бер-берсенә елышкан хәлдә килеп чыгуы Сафияне сискәндереп җибәрде. Тегеләр бик кеше күзенә чалынырга теләмиләр иде булса кирәк, бөтенләй туктап калдылар һәм стена күләгәсенә яшеренделәр.

— Әнә күрәсеңме, эчендә җаны булган кеше хәзердән кереп йок-

ларга ятмый,— диде Револ, тегеләр дә ишетсен дигәндәй, шактый ук кычкырып.

— Әкренрәк. Оялтырсың кешеләрне.

— Болар оят белә торган түгел.

— Ничек инде белмәгән кеше турында алай сөйлисең?

— Беләбез. Кемнән качып монда йөргәннәре дә билгеле.

— Кемнән?

— Син бая күрмәдеңмени Шафаның урам буйлап, ары-бире чабып, ирен эзләп йөргәнен? Бикбау монда килеп кармакка эләккән инә.

— Фу, бигрәк ямьсез сөйлисең! — дип йөзен чытты Сафия.

— Әше нинди, сүзе шундый. Укытучысының ирен тартып алган кызлар турында матур сүзләр уйлап чыгармаган әле халык. «Агыйдел-нең аръягында болыт тора, яңа ярлар иске ярны оныттыра»,— дип язган бер шагыйрь. Бикбауны күздә тоткандыр инде.

Сафиянең уң кулында кәрзин, сулы белән якасын күтәреп муенын чапларга тырыша иде. Револ аның бармакларын якасыннан каерып алды да, кайнар учына кысып:

— Боз булган,— диде, әкрен, әмма каршы торып булмаслык көчле итеп, кызның бармакларын иреннәренә китереп терәде. Аның бу үбүе сәхнәдәгечә түгел, артык кайнар, хисле, серле килеп чыкты. Сафия кулын тартып алырга ашыкты.

Өйгә кереп, күрше ишегалдындагы багана башыннан төшкән як-тылыкта гына чишенеп, җәймә ятакны сак кына җәйгәннән соң, Сафия бик озак йоклый алмый ятты. Урамнан сирәк кенә узган машиналар-ның чыжлавын, капка турында туктаган троллейбусларның ишеге ачы-лып-ябылуын, төннең күреп-ишетеп булмый, әмма йөрәк аша сулкыл-дап үтә торган агышын тоеп ятты. Вакыт-вакыт аның күз алдында кызыл чәчкәләр тибрәлгәндәй булды, колагында алкыш тавышлары, хуп-лау авазлары чагылып узды. Револ үпкән сул кул аркасы уттай кызышты.

Ә нигә, аның хакында уйлау Сафиягә гөнаһ идемени? Ә сез утыздан узып та ялгыз яшәп карагыз, белерсез шунда акылга буйсынмый торган хисләрнең һәм дуамал уйларның көчен, сихерен.

Узган елгы җәйге гастрольләр вакытында Револ белән очрашып сөйләшеп утыру искә төште. Сафияләр бер авылга килеп төшкәндә, Ре-волның концерт бригадасы китәргә җыенган иде. Нәкъ ул көнгән йортка Сафияләрне кертттеләр. Нишләптер бик озак машина көтәргә туры килде аларга. Сафия чәчен юды да, киптерергә ишегалдына, бүрәнәләр өстенә кояшка чыгып утырды. Шунда булган иде Револ белән сөйләшү.

Карале, моңарчы бер дә аны искә төшергән юк иде, хәтернең бер почмагында барсы да аермачык сакланган икән. Әйе, сулда келәт, аның кырыенда коймa артыннан яшь алмагач ботаклары сузылган. Юын-гыч урынына коймага кечкенә ак самавыр эленгән, аның борынынnan су бик саран ага, озаклап юынырга туры килә иде. Әйе, җәйге гастроль-ләр чорында ашыгасы, кабаланасы булмый иЧмасам, шундый саран су агымы астында кушучны озаклап тотып торып була. Ә кая ашыгырга? Роль бүлешү юк, репетицияләр юк, ашау байдан, үлем ходайдан, дигән-дәй, машинага утырып, бер авылдан икенчесенә сәяхәт кылып йөри бирә-сең. Ике кулга бер эш — кичке спектакль, анысының инде җае алынган.

Күңелнең иркенәеп, ачылып китүе сәбәп булгандыр инде, аңарчы очрашкан чакларда исәнме-саумыдан узмаган Сафия белән Револ кўп-тәнге сердәшләр кебек, озаклап үз хәлләрен сөйләшеп утырдылар. Дөресрәге, Револ сөйләде. Ә Сафия чәче тизрәк кипсен өчен, озын кара бөдрәләрен бармаклары белән тарап туздыргалап, аны тыңлады.

— Карале, моңарчы игътибар итми идем, чәчең бик матур икән си-нең,— диде Револ.— Үзе кап-кара, үзе кояшта алтынсуланып елкылдап тора. Буядыңмы әллә?

— Юк ла, булмаганны,— диде Сафия, андый комплиментларга күнекмәгәнгә, оялып.

— Син гаҗәп бит, игътибар белән карасаң, театрда аерылып тора-сың,— дип, дымлы күзләре белән туп-туры текәлеп дәвам итте Револ.— Японнар булса, сине карточкага төшереп, открытка ясап сатарлар иде.

Син бераз аларга тартым. Япон хатын-кызлары дөньяда иң чибәр санала бит, беләсеңме?

Сафия оялуыннан бүрәнә ярыгына кереп посарга әзер иде.

— Син... син нишләптер бик моңсу күренәсең әле, Револ,— дип сүзне тизрәк икенчегә күчерергә ашыкты ул.— Болай күргәнем юк иде әле.

Револ ул көнне чынлап та күңелсез иде.

— Ә сез мине бер гамьсез, ахмак бәндә итеп күрергә күнеккән инде,— диде ул иреннәре белән генә елмаеп.

— Үзең һаман гөр килеп, шаркылдап йөрисең бит.

— Төшенке күңел кемгә кирәк? Менә мин күпме чуалам сезнең тирәдә, берәүнең дә әле: «Револ дускай, нихәлләрдә яшисең, ул-бу гамең юкмы, ярдәм кирәкмиме?» — дип чын күңелдән сораганы юк.

Сафия чәчен йөзенә үк төшерде: аңа бөтен артист кавеме өчен кыен булып китте. Чыннан да, театрда, Револдан тегене сорарга кирәк тә, моны таптырырга кирәк, дигән сүзне күп ишетәсең, ә менә, Револның хәле шулайрак бит әле, ярдәм итик, дигән сүз берәүнең дә авызыннан чыкканы юк. Үзебезгә игелекле кешеләргә карата никадәр битарафлык күрсәтәбез без кайчакларда! Ә бит ваемсыз кеше юк бу дөньяда, берәүнең дә хәсрәт капчыгы буш тормый. Револның да күңеле мөлдерәмә тулы икән. Тыңлардай кеше очраганны көтеп кенә йөргән, ахрысы, ул шунда ук, каты тырнагы белән бүрәнә кайрыларын куптаргалап, үз башыннан узган үкенечле вакыйгаларны сөйләде.

Театр училищесында укыган чагында ук, авылдан килеп төзелешкә урнашкан Нәсиха исемле бер кызга өйләнеп куйган булган икән. «Кеше карбыз түгел, эчен ярып булмый, ә болай үзе сөйкемле генә, йомшак кына мөгамәләле кыз кебек иде». Дөрес, өйләнешүләре хакында алар беркемгә әйтмәгәннәр — загска бармаганнар, ата-анага белгертмәгәннәр. Ник дисәң, егетнең әле укып кына йөргән чагы, ни акчасы, ни баш тыгар урыны юк, дигәндәй, оя корырлыкмыни? Хатын да тулай тораклагы бер тимер караватка гына хуҗа булып санала, анысы да вакытлыча гына. «Ярый әле, медицина андый очракларда ярдәмгә килә...»

Әйе, эче тулы хәсрәт икән Револның да. Тик ул кайгыларын ялтырап торган тышкы кабыгы эчендә бик тирән яшереп йөртә белә икән.

Кайбер гаиләләрне уртак хәсрәт ныгыта, кичерешләр араны якынайта. Әмма бу хәсрәт Нәсиха белән Револ арасына упкын булып яткан.

— Ул бөтен гаепне миңа аударды,— дип сөйләде Револ.— Син — ир кеше, төптәнрәк уйларга тиеш идең, диде. Әйтерсең, хатыннарга үз хәлләрен үзләре белмәсә дә ярый. Көйсезлек килгән саен бәгырьне талый торган булса, аның белән ничек яшәп бетермәк кирәк? Ай түздем, ел түздем, ахыр килеп, сабыр канатларым сынды. Бөтен әйберне калдырып, чыгып китәргә туры килде. Хәзер инде башка кызларга ышанырга да куркасың, берәр җәйсызлык килеп чыкса, эчләреннән каралык ургылып ташыр сыман.

Ул чакта Сафия юату сүзләре әйтә алмады, әнгәмә шунда өзелде — машина килде дә егетне башка авылга алып китте. Баштарак бу сөйләшү ничектер әледән-әле искә төшеп, күңелне борчый иде, ләкин тора-бара бүтән гамьнәр басты, Револ бөтенләй онытылды.

Ә менә бүген уттай кызышкан бармаклар тиз генә суынырга теләмәде, бу эссе лек күңелгә саркып, йөрәк түреннән кызгану хисе тартып чыгарды.

Әгәр бер ялгыз кеше икенче бер ялгызның газапларын уйлап сызлана икән, бу бик табигый түгелмени?

*Дәвамы киләсе санда*

**Җ. З. Вәлиуллин,**

КПССның Мөслим район комитеты
беренче секретаре.

# ЯМЬЛЕ ЫК БУЙЛАРЫНДА

*Уралып-уралып ага*
*Мөслимнең Ык сулары...*

Татарстанның атказанган артисткасы Зифа Басыйрова башкаруындагы моңлы да, бер үк вакытта дәртле дә бу җырны тыңлап, кемнәр генә ләззәтләнмәгән дә кемнәр генә рухи көч, илһам алмаган! Аңа гына хас тирән моң, сагышлар аша да яктылыкны күрә белү атаклы җырчыга Мөслим тугайларыннан, шигъри Ык суларыннан да күчкәндер. Бер генә мәртәбә килеп күргән кешенең дә хәтеренә бу яклар бик озакка яисә гомерлеккә кереп кала. Мөслим турында берсеннән-берсе матуррак җырлар иҗат ителүе шуңа бәйледер дә. Киләчәктә алар тагын да язылыр әле. Чөнки табигатебез гаять бай һәм гүзәл, кешеләребез эшчән һәм талантлы.

Районыбыз Татарстанның көньяк-көнчыгышына урнашкан. Һава торышын тыңлаганда, күпләр игътибар итәдер: эссе вакытта иң югары, ә салкында иң түбән температура бездә булучан. Моңа Мөслимнең иң түбән җиргә урнашуы да, башка шартлар да сәбәптер. Ничек кенә булмасын, табигатебезнең хикмәтле яклары байтак. Әйтик, СССР Фәннәр Академиясенең метеоритлар комитетында барысы 166 метеорит теркәлгән. Шуларның берсе безнең Вәрәшбаш авылы басуыннан табылган.

Районны икегә бүлеп Ык елгасы агып үтә. Кайбер елларда ул шулкадәр ташый ки, Мөслимнең бер өлеше су астында калып, кешеләр урамда көймәдә йөрергә мәҗбүр булалар. Тагын шуны әйтергә кирәк: Ыкның бирге ягындагы басуларда язын дым каплауга керешкәндә, аргы яктагы кырларда кар әле эреп тә бетмәгән була. Моның сәбәбе урманнарга бәйле. Алар барлык җир мәйданының 20 процентын (утыз мең гектар чамасы) билиләр һәм нигездә Ык аръягына туры киләләр. Туфрак та төрле. Киров исемендәге колхоз үзәге урнашкан Мөслим, Мәлләтамак басулары ярмаланып торучы кара туфраклы, ә инде шул ук хуҗалыкларның Иске Вәрәш, Вәрәшбаш, Нарат Асты бригадасы кырлары соры урман-дала туфраклы. 92650 гектар җир биләүче сөрүлекләребездә андый урыннар шактый. Корылыклы еллар күп. Ун елның бишесе коры килү очраклары бар. Мәсәлән, җитмешенче елларда шулай булган. Артык зур булмаган район территориясе өчен контрастлар күбрәк, әлбәттә. Җирләребезнең рельефы да үзенчәлекле: Урал тавы итәгенә хас кечкенә калкулыклар тезмәсеннән тора ул. Вак инешләр, күлләр, әрәмәләр күп тә түгел, аз да түгел — бер чама гына.

Мөслим зур шәһәрләрдән, тимер һәм су юлларыннан шактый еракта урнашкан. Казан безгә — 320, Бөгелмә — 110, Брежнев шәһәре 80 километр чамасы ераклыкта.

Районда 24208 кеше яши. Күпчелеге татарлар, ун рус, өч мари авылы бар.

Кешенең нинди шәхес булуы аның биографиясендә чагылган кебек, тегеяки бу төбәктәге халыкның тормышын яхшырак аңлау өчен гадәттә аның тарихына мөрәҗәгать итәләр. Бу очракта да кайбер тарихи штрихларга тукталып китү урынлы булыр.

Башка милли төбәкләрдәге шикелле үк бу якларда да халыкның аңын патша хөкүмәте гасырлар буе хокуксызлык, милли изү, наданлык сөреме белән томалап килгән. Ләкин халык күңелендә иреккә омтылыш беркайчан да сүрелмәгән. Пугачев явы башлангач, азатлык тойгылары көчле ялкын булып кабына. Үзәк дәүләт архивы материалларыннан күренгәнчә, Туғаш авылында — 500 кешелек, Дусайда — 200, Катмышта — 100, Чишмәдә — 150, Күбәктә — 400, Ташлыярда — 60, Крәш. Шуранда 50 кешелек отрядлар була. Олы

Чакмак авылыннан Әбделкәрим Рахманкулов Пугачев армиясендә старшинадан полковник дәрәҗәсенә үсә.

Крестьян күтәрелешенең ахыры мәгълүм. Патша хөкүмәте баш күтәрүчеләрне канга батыра: элеккечә үк җәбер-золым дәвам итә. Коточкыч факт: 1859 елда Крәш. Шуран авылының бертуган алпавытлары Катанскийлар Сембер губернасындагы алпавытларның берсеннән ау эте бәрабәренә дүрт гаилә крепостной крестьян сатып алалар. Кеше өчен моннан да түбәнрәк хурлыкны әйтеп була микән?

Октябрь революциясен халык шатланып каршылый һәм, кулына корал тотып, үз азатлыгын якларга күтәрелә. Безнең якташларыбыз гражданнар сугышы чорында Петроградны, Мәскәүне саклауда, Көньяк, Көнчыгыш фронтларда, Деникин, Юденич, Колчак бандаларына, ак чехларга каршы көрәшләрдә актив катнашалар. Мөслим егетләре И. Кузьмин, Ш. Галимов, Н. Гыймаев, Н. Хәмидуллин һәм башкаларның бу утлы елларда күрсәткән батырлыгы, ныклыгы бүген дә халык хәтерендә саклана. Иске Карамалыдагы каһарманнар кабере, Шуган авылы уртасындагы өч партизан кабере ул чордагы сыйнфый бәрелешләрнең шаһиты булып торалар.

Азатлык алган халыкның иҗтимагый-политик активлыгы үсә. Авылларда наданлыкны бетерү, халыкның культурасын күтәрү, революция казанышларын ныгыту буенча киң колачлы эш җәелдерелә. Бу эшләрдә партия членнары, комсомоллар һәм яшьләр башлап йөри. Комсомолка Хәнифә Мортазина ВЛКСМның III съездына делегат итеп сайлана, Ленинның атаклы чыгышын тыңлау бәхетенә ирешә.

Колхозлар төзү кискен сыйный бәрелешләр аша бара. 1929 елда Теләнче (хәзерге Октябрь) авыл Советы председателе комсомолец Рәхмәтулла Исмәгыйлов кулаклар тарафыннан үтерелә. 1931 елның октябрендә Үрәзмәт авылының ашлык хәзерләүдә эшләүче фәкыйрь колхозчысы партия члены Ханнановны мылтыктан атып яралыйлар. Мәлләтамак авылында колхоз идарәсенә ут төртәләр... Мондый фактлар бернична дистәгә җыела.

1930 елның көзендә Минзәлә өязенең Мөслим волосте район итеп үзгәртелә. Шул елны алдынгы колхозчы Әмирҗан Әгъләмов беренче «Фордзон» тракторын алып кайта. Колхоз строеның адымнары ныгый бара. Менә районда чыккан «Күмәк хуҗалык» газетасының 1932 елның 21 февраль санынан бер информация: «Яңа Карамалы авылы «Кызыл бүләк» колхозы комсомол ячейкасы, колхоз активистлары белән берлектә, язгы чәчүгә бүгеннән сабанга чыгарлык хәзерләнделәр. 116 центнер солы, 10 центнер бодай, 33 центнер борчак, 16 центнер җитен, 7 центнер 63 килограмм киндер, 5 центнер 60 килограмм тары һ. б. чәчүлек орлык чистартып куелды. Иген кораллары пландагыдан арттырып төзәтелде: 30 арба, 49 атлык сбруй хәзерләнде.

Хәзер комсомол оешмасы орлыкларны саклау, тирес һәм көл җыйнау эшләрен башкара. Ячейка секретаре Солтанова Г.»

Бу юлларны укыганда, горурланасың да, күңел бераз йомшап та китә. Нинди еллар аша килгәнбез бүгенге көннәргә!

Мөслимлеләр Бөек Ватан сугышы сынауларын да лаеклы үттеләр. Туган илне сакларга барысы 8140 кеше фронтка китте. Шуларның 4164 е яу кырында ятып калды. Районыбыз егетләреннән Илдар Маннанов, Гыймазетдин Вәҗетдинов һәм Петр Днепров Советлар Союзы Герое исеменә лаек булдылар, Бәдигъ Салиховның батырлыгы I, II, III дәрәҗә Дан орденнары белән бәяләнде. Ул Мәскәүдә Җиңү парадында да катнаша.

Тылда «һәр башак — җиңү өчен, һәр бөртек — дошманга пуля!» дигән девиз астында хатын-кызлар зур батырлыклар күрсәттеләр. Сугыш башлангач, авылдашлары Газизә Мөхтәрованы «Дусай» колхозы председателе итеп сайлыйлар. Аның оста җитәкчелеге нәтиҗәсендә хуҗалык ел саен дәүләткә дүрт мең — дүрт мең биш йөз центнер ашлык сатып, планны 140—150 процентка үтәп бара. Мондый коллективлар күпләр була. Үзләре ачялангач булуга карамастан, авыл кешеләре сугышчылар өчен кием-салым, «Татарстан колхозчысы» дигән танк колоннасы өчен акча җыйнауга зур өлеш кертәләр. 1941 елның 30 ноябрендә «Күмәк хуҗалык» газетасы «Алга» колхозында үткән комсомол җыелышы турындагы язмада түбәндәгеләрне хәбәр итә: «Х. Вахитов үзенең 27 хезмәт көненә, А. Маслова — 24, З. Гайсина — 17, Н. Харисов 15 хезмәт көненә туры килә торган доходны танк колоннасы төзү фондына бирергә булдылар. Бу эшкә күп кенә союздан тыш яшьләр дә кушылды».

Ниһаять, озак көткән Җиңү сәгате суга. Ул тыныч көрәш сәхифәләрен ача. Район партоешмасы җитәкчелегендә сугыш җимерекләрен торгызу, авылларны электрлаштыру, хуҗалыкларны эреләндерү, производствоны специальләштерү һәм механикалаштыру буенча грандиоз эшләр башкарыла. Хәзер район колхоз-совхозлары эре социалистик предприятиеләргә әверелделәр. Әгәр 1930 елда районда 5 трактор, 2 комбайн, 2 автомашина булса, хәзер хуҗалыкларның техника паркларында 986 трактор, 532 комбайн, 458 автомашина тупланган. Унберенче бишьеллыкта гына да, төп производство фондлары, унынчы бишьеллык белән чагыштырганда, 73 процентка артты.

1930 елда бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 8 центнер уңыш алынган. Уникенче бишьеллыкның беренче елында ул 24,5 центнер тәшкил итте. «Татарстан» колхозы, «Шу-

ган» совхозы, Куйбышев исемендәге колхоз бодайның аерым участокларыннан 44-54 әр центнер уңыш үстереп алдылар. Район дәүләткә ашлык сату планын — 129, яшелчәне — 115, бәрәңгене — 132, шикәр чөгендере хәзерләү буенча 102 процентка үтәде. Интенсив технология кулланып игелгән 8592 гектар бодай 35,1 центнер уңыш бирде.

Бездә корылыклы елларның күп булуын алда әйтеп үткән идем. Мондый шартларда сугарулы мәйданнардан башка уңышка исәп тотып булмый. Табигый сулыклардан тыш 289 гектар буалар төзедек. Сугарулы мәйданнарның гомуми күләме 7 мең гектардан артты. Әлеге чаралар терлек азыгы әзерләүдә уңай борылыш ясарга мөмкинлек бирде. 1986 елда без һәр шартлы терлеккә 25 центнер азык берәмлеге туплый алдык.

Район уникенче бишьеллыкның беренче елында дәүләткә терлекчелек продуктлары сату планнарын барлык төрләр буенча уңышлы үтәде. Шуны гына әйтү дә җитә: 1930 ел белән чагыштырганда, ит хәзерләү — 54 мәртәбә, сөт — 79, йон хәзерләү 28 тапкыр артты.

РСФСР Верховный Советы депутаты, Ленин ордены кавалеры Мирхаҗиян Сәлахов җитәкчелегендәге «Урожай» колхозының текә күтәрелешендә район хуҗалыкларының үсеш тенденциясе аеруча ачык гәүдәләнә. Хуҗалык соңгы биш бишьеллык дәвамында дәүләткә авыл хуҗалыгы продуктлары сату планнарын барлык төрләр буенча уңышлы үтәп килә. Урожайлылар 1982, 1984, 1985 елларда Бөтенсоюз социалистик ярышында КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының күчмә Кызыл Байрагын яуладылар. Колхоз СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендәге Бөтенсоюз Мактау тактасына кертелде. Терлекләрне кышлату чорында ирешкән уңышлары өчен колхоз дүрт мәртәбә Бөтенсоюз Мактау грамотасына лаек булды. 1986 елда урожайлылар бөртеклеләрдән 30 центнердан артык уңыш алдылар, дәүләткә ашлык сату планын 131 процентка үтәделәр. Ит хәзерләүнең еллык планы июнь аенда, ә сөт һәм йонныкы 1 октябрьгә хәл ителде. Моны тизләнеш адымнары димичә ни дисең? Соңгы ике-өч ел эчендә генә дә хуҗалык ысулы белән инженерлык комплексы, барлык автомобиль һәм тракторлар өчен җылы гаражлар, терлекчелек торaклары һәм башка производство объектлары төзелде. Барлык авылларда да заманча культура йортлары, клублар, мәктәпләр, балалар бакчалары һәм ясләләр салынды. Хуҗалыкның пионер лагере бар. Колхоз ел саен яшьләр өчен барлык уңайлыклары булган 13-15 квартира төзи.

Хуҗалык күп еллардан бирле нәсел атлары үрчетү белән шөгыльләнә. Аның юрткалары һәм чабышкылары республикада гына түгел, Бөтенсоюз күләмендәге ярышларда да катнашалар. 1975 елда нәселле ат фермаларының Бөтенсоюз конкурсында урожайлылар өченче премиягә («Москвич-412» автомобиле һәм 1500 сум акча) лаек булдылар. Җиде елдан соң шундый ук конкурста икенче урынны алу хуҗалыкка «УАЗ-469» автомобиле һәм 2500 сум премия китерде. Хуҗалык ел саен республика колхоз-совхозларына 20-25 баш нәсел биясе һәм айгыры сата. Шуннан гына да унберенче бишьеллыкта 273 мең сумнан артык саф табыш алынды. Колхоз үзенең кымызы белән дә тирә-якта дан тота.

«Трудовик» тәҗрибә-житештерү хуҗалыгы элита сортлы орлыклар җитештерә һәм республикабызның шушы зонадагы 18 районына сата.

Районда 700 гектардан артык мәйданда орлык өчен чөгендер игелә. Бу бик мәшәкатьле, әмма игелекле эш белән «Михайловка» һәм «Үзәк» совхозлары шөгыльләнә. Чөгендер орлыгы шулай ук республика колхоз-совхозларына бирелә.

Мөслимдә майсызландырылган коры сөт заводы эшли. Аның продукциясе республикабыздан тыш илебезнең бик күп өлкәләренә озатыла. Предприятие елга биш миллион сумлык коры сөт, май һәм күп төрле башка продукция җитештерә.

Экономикадагы тирән үзгәрешләр мәгариф, культура өлкәсенә, тормышның башка сфераларына уңай йогынты ясый. 1930 елда районда бер җидееллык, берничә башлангыч мәктәп булган, барысы 116 укытучы эшләгән. Хәзер уналты урта, 8 сигезьеллык мәктәптә яшь буынга югары һәм урта махсус белемле йөзләрчә укытучы белем һәм тәрбия бирә. Мәктәпләрнең материаль-техник базасы яхшырды. Укыту һәм хезмәткә өйрәтү нигездә класс-кабинетларда алып барыла. Җәйләрен күпчелек укучылар производство бригадаларында эшли. Иң куандырганы — ел саен урта мәктәп тәмамлаучыларның 80-85 проценты туган авылларында эшкә кала.

Район хезмәтчәннәренә 27 культура йорты, 21 клуб, 31 китапханә хезмәт күрсәтә. Өч филиалы булган музыка мәктәбе, халык театры эшли. Район культура йорты каршындагы академик хор Кремльнең Съездлар Сараенда, Чехословакиядә, тугандаш республикаларда чыгыш ясады. Район газетасы каршында «Тугай моңнары» әдәби-музыкаль берләшмәсе эшли.

Безнең җирлектә туып-үсеп, тәрбияләнеп, иҗтимагый-политик тормышта, авыл хуҗалыгы производствосында, фән, культура, мәгариф, медицина, әдәбият-сәнгать өлкәсендә олы мәртәбәгә ирешкән кешеләребезнең исемен хөрмәт белән телгә алмый мөмкин түгел. Бездән Ф. М. Бубекова Советларның VIII съездында, «Урал» колхозының элекке председателе М. Б. Гаттаров КПССның XXV съездында делегат булып катнаша. Вәрәш-

баш авыл Советы башкарма комитеты председателе, II һәм III дәрәҗә Сугышчан Дан орденнары кавалеры М. Гәрәев районнан беренче булып СССР Верховный Советы депутаты итеп сайлана.

Киров исемендәге колхозның элекке председателе Л. Мусин һәм «Михайловка» совхозы механизаторы З. Кашапов Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булдылар. Унбиш кеше Ленин ордены белән бүләкләнде. Бездә Татарстан һәм Россия Федерациясе күләмендә атказанган дистәләрчә колхоз-совхоз җитәкчесе һәм белгече, укытучылар, культура һәм медицина работниклары эшли. Мөслим җире Л. Шәрифуллин, Г. Гәрәев кебек фән докторлары, В. Гайфуллин, М. Вәлитов, Р. Ганиев, Д. Галләмова, Р. Мөхәмммәтҗанов, Р. Шәймәрданов, И. Сөләйманов кебек фән кандидатларын бирде. Усы авылында туып-үскән татар егете Н. Р. Егоров озак еллар буе Жуковский исемендәге хәрби һава академиясенең кафедра мөдире булып эшләде, космонавтларны укытты, шул исәптән беренче галәм лачыны Ю. Гагаринның остазы булды.

Якташларыбыз арасында филология фәннәре докторы тәнкыйтьче Флүн Мусин, шагыйрьләр Зөлфәт, Харрас Әюпов, прозаик Фәрит Гыйльми, драматург Фоат Садриев, яшь авторлардан Шәмсия Җиһангирова, Асия Минһаҗева, Флүс Латыйпов һ. б. исемнәре бар. Татарстанның атказанган артисты Наил Әюпов, композитор Котдус Хөснуллинның уңышларын да якташлары сөенеп күзәтә.

Сүземнең агышын талгын Ык сулары кебек тагын Мөслимгә борам. 1896 елның 29 мартында волостной старшина Садыйков тутырган бер документта Мөслим авылында 303 хуҗалык булуы, 1677 кеше яшәве, ике мәчет, ике лавка эшләве күрсәтелә. Бүгенге Мөслим — ул 70 тән артык предприятие, оешма һәм учреждениене берләштерүче, елдан-ел зурая баручы эшчеләр поселогы. Анда 5604 кеше яши. Күпчелек урамнар асфальтланган, йортлар тезек. 1986 елдан табигый газ кертү башланды. Район үзәгендә берничә төзелеш идарәсе, кирпеч, асфальт, катнаш азык заводлары, ашлык һәм чөгендер кабул итү пунктлары бар. Торак йортлар төзү киң колач белән алып барыла. Әгәр моңа кадәр район үзәгендә ел саен уртача 1 миллион сумлык төзелеш эшләре башкарылган булса, хәзер ул 5 миллионга җитте. Узган ел гына да «Дуслык» кафесы, 120 урынлы больница корпусы, 624 урынлы урта мәктәп бинасы эксплуатациягә бирелде. Хәзерге вакытта 400 урынлы культура сарае, элемтә узелы, поселок Советы, РАПО биналары, балалар бакчасы, торак йортлар салына. Яңа аэропорт төзибез. Ул ЯК-40 һәм башка зур самолетларны да кабул итәчәк.

Әйе, мөслимлеләр тизләнешле адымнар белән киләчәккә атлыйлар. Уртак тырышлыгыбыз партиябезнең XXVII съезды карарларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән... Безнең максат — 12 бишьеллык ахырына бөртеклеләрдән 30 ар центнер уңыш алу, һәр сыердан 3000 килограмм сөт саву, барлык төр авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләүне сизелерлек арттыру. Район хезмәтчәннәренең хезмәт активлыгы әлеге бурычның уңышлы үтәләчәгенә шик калдырмый.

### ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

23 декабрьдә Татарстан Язучылар союзының ачык партия жыелышы булып узды. Ул яңа таләпләр яктылыгында ижат эшләрен үзгәртеп коруда партия оешмасының роле һәм яшь әдәби алмаш әзерләү мәсьәләләренә багышланган иде.

Әлеге тема буенча Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателенең яшь язучылар белән эшләү буенча урынбасары И. Юзеев доклад сөйләде. Өстәмә доклад белән союзның әдәби консультанты Ә. Мушинский чыкты.

Яшь әдипләр С. Шәмси, Р. Зәйдуллин, Э. Блинова, Л. Кожевников үзләренең ижат планнары белән уртаклаштылар.

Фикер алышуларда Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, язучылар Г. Бәширов, Г. Ахунов, Ш. Галиев, Н. Орешина, Р. Мөхәммәдиев, Р. Кәрами, Р. Мингалимов, Р. Гатауллин, М. Зарецкий чыгыш ясап, күтәрелгән мәсьәләләр буенча эшлекле тәкъдимнәр әйттеләр.

### ТАТАРСТАН ЖУРНАЛИСТЛАР СОЮЗЫНЫҢ XI СЪЕЗДЫ

14 январьда Казанда КПСС өлкә комитетының Политик мәгариф йортында Татарстан Журналистлар союзының XI съезды булды.

Татарстан Журналистлар союзы идарәсе эше һәм КПССның XXVII съезды карарлары яктылыгында республика массакүләм информация һәм пропаганда чаралары работникларының бурычлары турында отчет докладлы белән ТАССР Журналистлар союзы идарәсе председателе, ТАССР телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт комитеты председателе И. К. Хәйруллин чыкты.

Докладлар буенча фикер алышуда «Советская Татария» газетасы редакторы Е. А. Лисин, «Казаньпромстрой» трестының ташчылар бригадиры, СССР Дәүләт премиясе лауреаты, эшче-хәбәрче Г. Х. Хәйруллин, ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Т. А. Миңнуллин, «Татарстан коммунисты» журналының баш редакторы урынбасары В. И. Пискарев, «Ялкын» журналының баш редакторы Р. Р. Туфитулова, СССР Журналистлар союзы идарәсе секретаре Р. Н. Мосеев һ. б. катнашты.

Съездда КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Г. И. Усманов катнашты һәм чыгыш ясады.

Съезд эшендә КПСС өлкә комитеты бюросы членнары һәм членлыкка кандидатлар, совет, профсоюз, комсомол органнары житәкчеләре, кайбер партия комитетлары секретарьлары, ижат союзлары вәкилләре катнашты.

### ХУДОЖНИКЛАР СОЮЗЫ ЮБИЛЕЕ

19 декабрьдә Казанның Актерлар йортында Татарстан Художниклар союзының оешуына илле ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды. Аны ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов ачты.

КПСС өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев сынлы сәнгать осталарын олы юбилей белән кайнар котлады һәм ТАССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасын тапшырды.

Художниклар союзының ижат юлы һәм күпкырлы эшчәнлеге турында доклад белән ТАССР Художниклар союзы идарәсе председателе, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, республикабызның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты В. М. Маликов чыкты.

Ижат союзын юбилее белән РСФСР Художниклар союзы идарәсе секретаре Н. Ф. Новиков, республикабыз хезмәт коллективлары, ижат союзлары һәм культура учреждениеләре вәкилләре котлады.

Аннары Татарстан сәнгать осталары концерты булды.

Тантаналы кичәдә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова, КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре Ф. Г. Зыятдинова катнашты.

### ТУКАЙ МИРАСЫН ӨЙРӘНҮ ЮЛЫНДА

Г. Тукайның 100 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә аның әсәрләренең яңа биштомлык басмасын чыгару эше төгәлләнде. 22 декабрьдә СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы конференц-залында шушы басманы тикшерүгә багышланган киңәшмә булды. Аны филология фәннәре докторы Ф. Мусин ачты.

Тикшерелә торган мәсьәлә буенча докладлар белән филология фәннәре докторы И. Нуруллин һәм филология фәннәре кандидаты М. Әхмәтжанов чыкты. Фикер алышуларда ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, Татарстан китап нәшрияты директоры Г. Шәрәфетдинов, язучылардан Ә. Еники, Ә. Исхак, Р. Ишморат, М. Мәһдиев, тарих фәннәре докторы М. Госманов, филология фәннәре докторы Г. Халит, филология фәннәре кандидатлары Ш. Абилов, Ф. Урманчеев, Н. Хисамов катнашты. Алар яңа басманың дөньяга чыгуына зур көч салган Р. Гайнанов, Л. Гайнанова, басманың фәнни редакторы Г. Халит, нәшрият редакторы Р. Даутовка рәхмәтләрен белдерделәр.

Сөйләшүгә СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры филология фәннәре докторы М. Зәкиев йомгак ясады.

Киңәшмәдә: Г. Тукай әсәрләренең яңа басмасы анык мирасын фәнни нигездә чыгару юлында җитди адым дип бәяләнде. Бу өлкәдә алда торган бурычлар һәм хәл итәсе мәсьәләләр ачыкланды.

## ШАГЫЙРЬ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Татарстанның халык шагыйре, РСФСР һәм ТАССР Дәүләт премияләре лауреаты, күренекле җәмәгать эшлеклесе Сибгат Хәкимнең күпмилләтле совет әдәбиятын үстерүдәге зур хезмәтен искә алып, Казан шәһәр Советы башкарма комитеты ТАССР Министрлар Советына Театральная урамындагы шагыйрь яшәгән 13 нче йортка мемориаль такта кую турында үтенеч белән керде. Бу үтенечтә шулай ук Совет районы, Азино-2 массивындагы 1 нче һәм 2 нче микрорайоннар буйлап узачак урамга Сибгат Хәким исеме бирү турында да әйтелә. Ул урам йортлары киләсе елда төзелә башлый.

Республика хөкүмәте «РСФСР һәм ТАССР Дәүләт премияләре лауреаты шагыйрь Сибгат Хәким истәлеген мәңгеләштерү турында» карар кабул итте.

## КАЛӘМДӘШЛӘР БӘЙРӘМЕ

Мари АССР Язучылар союзы органы булган «Ончыко» («Алга») журналының беренче саны чыгуга 60 ел тулды. Зур хезмәтләре өчен һәм юбилее уңаеннан журнал «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнде.

Йошкар-Олада уздырылган юбилей тантанасында Башкортстан, Чувашия, Удмурт, Мордва, Коми автономияле республикаларының Язучылар союзларыннан кунаклар катнашты. Татарстан язучылары исеменнән котлау сүзе белән «Казан утлары» журналының җаваплы секретаре С. Маннапов чыгыш ясады.

# ӘДИПНЕҢ ПОРТРЕТЫ

Әдәбиятыбыз классигы, галим һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның үзе исән вакытта ясалган бердәнбер портретын танылган рәссам Павел Петрович Беньков иҗат иткән.

Зыялыларга хас киң һәм биек маңгай, җитди караш, арыганлыктан бераз суырыла төшкән йөз чалымнары рәсемдә әдипнең киеренке рухи тормышын, иҗат процессындагы тирән акыл эшчәнлеген гәүдәләндерә. Шушы тышкы гадилектә һәм тынычлыкта, ачык күз карашында катлаулы язмышка ия булган шәхеснең ихтыяр көче һәм бетмәс-төкәнмәс энергиясе дә чагыла сыман. Үзенең бөтен барлыгын, белемен һәм көчен туган халкына багышлаган әдип, Татарстан республикасын оештыру эшендә башлап йөрүчеләрнең берсе булды. Соңрак ул республикабызда киң колач белән җәелгән фән һәм халык мәгарифе эшенә җитәкчелек итте. Портрет 1926 елда, Г. Ибраһимов эшчәнлегенең иң югары ноктасына ирешкән чорда язылган.

Г. Ибраһимов фигурасының нейтраль фонда сурәтләнүе, төсләр колоритының саранлыгы да портрет композициясенең җитди аныклыгын ассызыклый. Дулкынланып торган кара чәч, язучы өстендәге кара куртка яшел төстәге дивар белән тыйнак төсләр гаммасы тудыра. Рәссам карашының астан төбәлгәнлеге исә образга галилек һәм монументальлек өсти.

Павел Петрович Беньков озак еллар Казан рәссамчылык мәктәбендә укыта. Танылган портрет остасы буларак, ул үз рәсемнәре өчен гадәттә рухи дөньясы белән дә, психологик бөтенлеге белән дә башкалардан аерылып торучы көчле шәхесләр эзли. Егерменче елларда иҗат ителгән әсәрләр арасында «Фирсова портреты», «Эшче» һәм шул җөмләдән «Галимҗан Ибраһимов портреты» нәкъ шундыйлардан.

РСФСРның атказанган рәссамы Бакый Урманче бу портретның язылу тарихын болай дип хәтерли:

«Бу портретка мин битараф була алмыйм, чөнки аны тудыруда беркадәр дәрәҗәдә үзем дә катнаштым дип әйтә алам. Бервакыт Павел Петрович татар әдәбиятының алдынгы эшлекләреннән берәрсенең рәсемен ясарга теләве турында әйткән иде. Мин аңа Галимҗан Ибраһимовны тәкъдим иттем.

Әдип үзе дә бу эшкә теләп риза булды. Портрет гаҗәп уңышлы чыкты. Мин Ибраһимовны күреп белә идем, һәм шунлыктан, язучының тышкы кыяфәте генә түгел, ә бәлки аның эчке дөньясы да зур осталык һәм төгәллек белән чагылдырылуын бер дә шөбһәләнми әйтә алам. Анын портретын моннан да яхшырак итеп язарга мөмкин түгел. Бу — иң югары нокта!»

**В. А. ЦОЙ,**
Татарстан сынлы сәнгать
музееның бүлек мөдире.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Казанның үзәгендә Мулланур Вахитов һәйкәле.

**Юрий ФИЛИМОНОВ** һәм **Рөстәм МАНСУРОВ** фотолары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ (на татарском языке)